**Вахит ИМАМОВ**

# ТАТАР ЯУГИРЛӘРЕ

*(Татарлар Пугачев явында)*

Тарихи очерк

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2003
УДК 821.512.145-4
ББК 84(2Рос=Тат):63.3(2)46
И48

*Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Имамов Вахит**
Татар яугирләре (Татарлар Пугачев явында): Тарихи очерк.— Казан: Мәгариф, 2003.— 335 б.
ISBN 5-7761-1336-9

Китап XVIII гасыр тарихында аерым урын алып торучы Пугачев явына багышлана һәм восстание узган бик зур төбәкләрне колачлый. Шушы яуга кушылып киткән татар каһарманнарын барлавы һәм алар күрсәткән батырлыкларны тарихи чыганакларга таянып раславы белән әлеге хезмәт аеруча әһәмиятле.

ISBN 5-7761-1336-9
© «Мәгариф» нәшрияты, 2003

*КЕРЕШ*

Заманында Рәсәй империясен дер селкеткән һәм бөтендөнья тарихына кереп калган Емельян Пугачев явы моңа кадәр фәнни хезмәтләрдә һәм матур әдәбиятта фәкать берьяклы — крестьяннарның патша администрациясе, җирле алпавытлар изүенә каршы юнәлтелгән сыйнфый көрәше буларак кына яктыртылып килде. Бу теманы язуга алынган совет галимнәре өчен дә, бүленмәс һәм бердәм совет халкы тәрбияләүгә йөз тоткан сәясәтчеләр өчен дә шундый тәкъбир отышлырак, файдалырак иде.

Казанда яшәп иҗат иткән тарихчы Н. А. Фирсов 1869 елда «башкортлар урыс хакимиятеннән котылып, бәйсез, мөстәкыйль ислам ханлыгын төзү өчен, татарлар элекке ханлыкларын һәм иске тәртипләрне торгызу өчен көрәшкәннәр» дип язса да, моңа охшаш фикер совет галимнәре тарафыннан аяусыз тәнкыйтькә дучар ителде. Коммунистик, ялган идеология чәчәк аткан чорда гына түгел, бәлки инде «үзгәртеп кору» дигән этап башлангач та, галимнәр Пугачев фетнәсен «сыйнфый көрәш явы» дип тәкрарлауны дәвам иттеләр. Мисал өчен, 1988 елда дөнья күргән «Воззвания и переписка вожаков пугачевского движения в Поволжье и Приуралье» дигән зур һәм, һичшиксез, мактаулы хезмәт авторлары да элекке совет фәне калыпларыннан котыла алмады. Алар да безне Пугачев явында катнашкан инородецлар (ягъни урыс түгелләр) фетнә барышында милли мәнфәгатьләрне алга куймаганнар, бәлки, барча халык, бердәм булып, иң элек, сыйнфый изүгә каршы көрәшкән, дип ышандырырга, тарихи документларны шул күзлектән чыгып өйрәнергә чакырдылар.

Әмма тарихи фактлар киресен сөйли. «12 ел буена качып йөргәннән соң, Җаек буенда пәйда булган падишаһ галиҗәнаплары Петр Федорович» үзенең беренче указ һәм манифестларында ук ирек вәгъдә итә. Аның «ничек теләсәгез, шулай яшәгез», «бабаларыгыз ничек гомер иткән булса, сез дә шундый тормыш корыгыз», «тугры хезмәтегез өчен мин сезгә елга һәм далалар, мәңгелек азатлык вәгъдә итәм, дини ирек бирәм», «мин сезне элек түләп килгән ясак һәм салымнардан, податьлардан (бурычлардан) азат итәм», дип язган сүзләрен урыс булмаган милләт вәкилләре, иң беренче чиратта, милли азатлык вәгъдәсе дип кабул итәләр. Гадел, изге патшага өмет тоту уе хәтта XX—XXI гасырда яшәгән «цивилизацияле» кешеләр күңелендә дә бар. Үзебезнең газиз татар халкы да, «Мәскәү безгә ирек бирмәсме» дип, әүвәл Ленинга һәм Сталинга табынган. 1985 елдан соң без шундый ук өмет белән Горбачев авызына карап тордык. Беркатлы татар халкы ничә еллар буе «азатлыкны нинди күләмдә йота алсак, шулкадәр бирергә» вәгъдә иткән Ельцинның изгелегенә өметләнеп яшәде. Без, XXI гасырга аяк баскан буын, шулай алданганны, XVIII гасырның 70 нче елларында яшәгән крестьян «падишаһ Петр Федорович» вәгъдәсенә әлбәттә ышанган. Нәкъ шуңа күрә урыс булмаган милләт вәкилләре Пугачев гаскәренә күмәк рәвештә кушылган. Шуңа күрә Пугачев гаскәрендә татар, башкорт, мари, удмурт, чуваш халкының гади крестьяннары гына түгел, бәлки шактый зур байлыкка ия булган тарханнары, старшина һәм йөзбашлары хезмәт иткән, алай гына да түгел, шул байлар әле фетнәче отрядларны күп очракта үзләре туплаганнар һәм үзләре үк отряд башлыклары булып йөргәннәр.

Тарихтагы әлеге хакыйкатьне хәтта пугачевчыларга каршы җибәрелгән барлык җәза армиясенең башкомандующие булган явыз, кансыз генерал П. Панин да таныган. Аның 1774 елның 31 декабрендә Оренбург губернаторы И. Рейнсдорпка фетнәчеләрдән штраф атлары җыярга кушып юллаган Указындагы мондый сүзләр, безгә калса, һичнинди өстәмә аңлату яки яклауга мохтаҗ түгел: *«Нам известно, что (среди иноверцев) богатые более склонность имели к злодейству, а бедные их примеру последовали»* (Оренбург өлкәсенең дәүләт архивы, 3 фонд, 1 тасвир, 146 эш, 35 бит).

Без тагын шуны да башта ук һәм ассызыклап әйтергә тиешбез: *урыс алпавытлары арасыннан бер генә вәкил дә үз теләге белән Пугачев ягына чыкмаган. Бер генә урыс алпавыты да, байлыгын калдырып, Пугачев гаскәрендә отряд башлыгы булып йөрмәгән.*

Тагын бер аеруча мөһим һәм четерекле нәрсәгә игътибар итик. Совет фәнендә Пугачев явы — ул һәрчак, иң элек, урыс крестьяннарының урыс алпавытларына каршы сыйнфый көрәше итеп яктыртылган. Ягъни урыс явы, урыс фетнәсе. Ә урысныкы булгач, билгеле инде, монда башка милләт вәкилләренә урын бик аз бирелә. Әмма тарих ялганны сөйми. Инде тарихи мәгълүматларга сүз бирик. Татар халкы телендә Әби патша булып йөргән *Екатерина II Пугачев явында катнашкан крестьяннар санын 200 меңгә тиңләгән* (*С. Алишев*. «Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании», с. 192). Әлбәттә, Екатерина мондый санны түшәмнән алмаган, ә үзенә рапорт бирүче министрлар һәм генералларның мәгълүматына нигезләнгән. Башта ук күңелгә салып куйыйк, бу сан дөрес тә булмасын, шактый киметелсен, ди. Бу урында, бәлки, «Кайсы чор мәгълүматлары дөресрәк? Патша министрлары гаделрәкме, әллә совет сәясәтчеләре, совет галимнәре хакыйкатьне шәбрәк күрәме?» дигән нигезле сорау туар. Бу бәхәстән читләшү өчен безгә, мөгаен, бер-ике факт кына китерү дә җитәр. Совет сәясәтчеләре Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарны бүгенгә кадәр әле 20, әле 27 миллионга (миллионга!) тиңли. Ә 1917 елдан бирле Советлар Союзы территориясендә кырылган халыкның төгәл санын бүген беркем дә белми. Аны 110 миллионга тиңләүчеләр дә бар, әмма моның фәнни нигезе юк. Чөнки кайсы политбюрочы яки кайсы генерал кайда күпме халыкны кырган? Моны берәү дә исәпкә алып тормаган.

Шушы мисаллардан соң кабат Пугачев явына кайтыйк та 200 мең тирәсендә фикер йөртик. Архив мәгълүматларына караганда, яу барышында 11 552 фетнәче, безне аеруча кызыксындырган *Казан губернасында — 4526, Оренбург губернасында 4739 крестьян һәлак булган яки хәбәрсез югалган* (*С. Али-*

*шев*, шул ук хезмәт, 193 б.). Бу саннар тулы түгел. Ә шулай да ул 200 мең санын кайсы милләт вәкилләре тәшкил итә соң?

«Крестьянская война 1773—1775 гг. на территории Башкирии» дигән документлар җыентыгына кушымта итеп төзелгән (ә ул архив материалларына нигезләнгән, әмма тулы түгел дип искәртелә) карта мәгълүматларына караганда, ул чагында Оренбург губернасы составына кергән **Уфа провинциясендә яшәүче урыс булмаган 86 541 крестьян (ирләр) фетнәдә катнашкан. Шуларның 42 114 е — башкорт, 35 097 се — татар һәм мишәр, 9330 ы — мари, чуваш, удмурт крестьяннары.**

*(Чагыштыру, уйлану өчен тагын өстәмә саннар китерик. 1767 елның май аенда төгәлләнгән ревизия (сан алу) буенча 6 провинциядән хасил Казан губернасында 2 миллион 471 мең кеше (ике җенес тә) яшәве ачыкланган (Н. Дубровин.* «Пугачев и его сообщники», т.1*). Дөрес, 1768 елда Сембер һәм Пенза провинцияләре Казан губернасыннан аерылып чыккан һәм нәтиҗәдә Сембер губернасы төзелгән. Әмма моны искәртүебез гомуми санга һич тә тәэсир итми. Чөнки Пугачев явы шул ук Сембер һәм Пенза провинцияләре аша да шаулап үткән. Бу очракта аларны бербөтен итеп карау хакыйкатькә хыянәт итми, саннарга үзгәреш кертми. Ул елларда Оренбург губернасында 400—500 мең чамасы кеше (ике җенес тә) яшәгән. «Емельян Пугачев» китабын язучы В. Буганов бу саннарны бернинди тарихи мәгълүматлар белән дә нигезләми. Тарихчы А. Чулошников 1750 елда Уфа провинциясендә яшәгән башкортлар санын 106 176 җанга яки 11 863 йорт башына тиңли. Бу очракта ул ике җенес вәкилен дә күз алдында тота. Әлеге саннарга да ышанасы килми. Шуңа күрә без тарихчы галим С. Алишевның «Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании» хезмәтенә мөрәҗәгать итик. Аның мәгълүматлары буенча, 1770—1771 елларда Оренбург губернасында урыс милләтеннән булмаган 236 770 ир-ат яшәгән. Шуның 95—100 мең чамасын — башкорт (моны башкорт милләте дип түгел, ә башкорт катламына язылган крестьяннар дип уку дөресрәк) һәм тагын 100 мең чамасын татар ирләре тәшкил иткән.)*

Саннарны тагын кабатлыйк. Оренбург губернасында урыс булмаган 236 770 ир яшәгән, ә шул губернаның бер өлешен генә тәшкил иткән Уфа провинциясендә 86 541 кеше фетнәдә катнашкан (еллар тәңгәл килеп бетми, шулай да кулланыйк). Әмма Оренбург губернасының бөтен территориясендә фетнәдә катнашучы татар, удмурт, мари, башкорт крестьяннарының саны 86 мең 541 кеше белән генә чикләнә алмый. Чөнки Бөгелмәдәге Земская конторага буйсынучы зур территориядәге йөзләгән авылларда яшәүче татарлар һәм башкортлар бу сан эченә керми. Ә ул төбәктә фетнә отрядлары аз булмаган. Иң эреләрен генә санап үтик: Муса Мостафин җитәкчелегендәге 700—800 кешелек отряд, Тимербулат һәм Әит Үрәзмәтовлар төзегән ким дигәндә 900 кешелек отряд, Самара каласыннан 20 чакрымда татарлар тарафыннан нигезләнгән, халкы Самара линиясендә казак булып хезмәт иткән Мачын бистәсе отряды. Ул саны буенча һич кенә дә аз булмаска тиеш, чөнки әлеге отряд 1774 елның 14 февралендә Бозаулык крепосте янында генерал П. Мансуров җитәкләгән җәза полкларына каршы торган, әмма җиңелгән һәм Илецк шәһәрчегенә чигенгән. Тагын санargyйк. 1767 елгы комиссия депутаты Гаврила Давыдов кул астында Богырыслан бистәсендә төзелгән 500 кешелек отряд. Шул ук төбәктә хәрәкәт иткән 500—800 әр кешелек Солтангол Имәнканкаев, Иван Черняев, Йосыф Енгалычев, Попов отрядларын да онытмыйк. Оренбургның үзенә терәлеп торган һәм Пугачев гаскәренә 500 кешелек полк биргән Каргалы бистәсенең татарлары да әлеге 86 мең хисабында юк. Һәм тулысынча диярлек татарлардан торган һәм 22 мартта Татищево янындагы яуда аерым отряд булып катнашкан Красногорская крепостеның казакларын хәтерлик. Патша генералы В. Кар командалыгындагы җәза отрядлары килә башлагач та, Бөгелмә һәм Оренбург арасында тезелеп утырган Дүсмәт, Сарманай, Мостафа, Йөзәй, Имәнгол, Биккол кебек авыллардагы йөзәрләгән татар крестьяннарының, отрядларга тупланып, Пугачев армиясенә качуын яки җәзачыларга һәртөрле каршылык күрсәтүен, шушы ук авыллардагы ирләрнең 1774 елның яз һәм җәендә баш күтәрүен искә алыйк. Бирдә бистәсенең үзендә 1773 елның октябрендә Казан өязе вәкиле Абдул кул астында 500 кешелек яңа бер татар полкы оешуын, гыйнварда Габдерәшит Әитовның янә бер полкка башлык булып билгеләнүен онытмыйк. Шуларга өстәп, Җаек казаклары сафында да бик күп татар булуын, шулар арасыннан 20 кешенең 1773 елның 16 сентябрендә үк Пугачевның иң тәүге 80 казаклы отряды сафында булганлыгын — һәммәсен искәртик. Исет провинциясендә Иван Грязнов һәм Григорий Туманов җитәкчелегендә 5000 кешелек отряд хәрәкәт итүен, аның составында ким дигәндә 2000 татар-башкорт җайдагы булуын да, Урал заводларында эшләгән килеш яки Оренбургның үзеннән качып чыгып Пугачев гаскәренә кушылган татар крестьяннарын, һөнәрчеләрен дә истә тотыйк. Тагын дистәләгән вак отрядлар, йөзәрләгән билгесез фетнәчеләр... Шуннан соң без Оренбург губернасы территориясендә фетнәгә катнашучы урыс булмаган крестьяннарның саны, чыннан да, 86 мең белән генә чикләнә алмавына ышанырбыз. **Безгә калса, ул әле 100—110 меңдә дә тукталмый.**

Безнең кулда Оренбург губернасындагы кайсы милләт вәкилләренең Пугачев явында ничек катнашуын раслаучы икенче төр мәгълүматлар да бар. Ул — Екатерина II тарафыннан төзелгән Оренбург Яшерен комиссиясенең карарлары. Шуларга игътибар итик. Әлеге комиссия карары буенча 11 фетнәче мәйданда чыбыркы белән суктырыла, шуларның 8 е татар, 3 есе казак. Камчы белән җәзаланган 266 фетнәче арасында: 120 татар, 3 керәшен, 7 башкорт, 81 казак, 35 крестьян, 4 солдат, 1 поп, 1 калмык, 2 хатын-кыз, 2 бала, 1 карт һәм тагын сөргенгә сөрелгән 9 кеше. Яшерен комиссия җәлладлары тарафыннан кыйный-кыйный сорау алынган, әмма җәза бирмичә иреккә чыгарылган 713 фетнәче турында күрсәткечләр: 217 казак, 111 татар, 7 башкорт, 84 керәшен, 45 калмык, 21 солдат, 110 крестьян, сөргенгә сөрелгән 87 кеше, 6 сәүдәгәр, 2 ногай, 7 яшүсмер, 7 хатын-кыз һәм тагын билгесез 9 кеше («История Татарии в документах и материалах»). Оренбург комиссиясендә исемнәре теркәлгән барлыгы 1002 фетнәче бар. Алар арасында крестьян, казак, керәшен, сәүдәгәр, солдат булып теркәлгән 561 кешенең милләтен без төгәл белмибез. Әмма инде ачыклаганнары арасында да 239 татар бар, һәм шуларның 128 е җәзалауга хөкем ителгән, димәк, фетнәдә күрсәткән активлыклары һәм кыюлыклары өчен татарларны гафу итү мөмкин булмаган. Әлбәттә, югарыда китерелгән саннар тайпылышсыз күрсәткеч була алмый, алар тулы да түгел. Ләкин алар уйланырга һәм хакыйкатькә якынаерга ярдәм итә.

Инде хәзер Пугачев явы шаулап үткән **Казан губернасын алыйк. С. Алишев үзенең хезмәтендә бу территориядә фетнәдә катнашучы татарларның санын 50 меңгә тиңли.** Без дә санап карыйк.

*1767 елда Казан губернасында ясак түләүче яки Адмиралтействога буйсынучы (лашманлык бурычын үтәүче) 110 840 татар ире яшәгән (Н. Дубровин). А. Чулошниковның «Восстание 1755 г. в Башкирии» дигән хезмәтендә китерелгән саннарга нигезләнеп исәпләсәк, Казан губернасында 1770 еллар башында тагын 35—45 меңгә якын керәшен татары да яшәгән. Болар өстенә 17—18 меңгә якын татар крестьяны металл кою һәм күкерт җитештерү заводларына беркетелгән (Н. Дубровин). Ә инде сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, алпавытларга коллыкка төшкән крестьяннар, завод һәм фабрика эшчеләре арасында күпме татар вәкиле булуын без белмибез. Шулай да бу күрсәткечнең 20—30 меңдә генә тукталмавы шиксез (саннарның һәммәсе ирләр хакында гына сөйли, шуны онытмагыз).*

Санауны шушы урында туктатыйк та янә Пугачев явына әйләнеп кайтыйк. Әгәр Оренбург губернасында яшәгән 95—100 мең башкорт ире арасыннан 42 мең фетнәче чыгуын искә алсак һәм шушы чагыштырманы Казан губернасында яшәгән татарларга карата кулланcак, бу хакыйкатьтән ераклашмас, әмма бик үк дөрес булып та бетмәс иде. Шуңа күрә без моңарчы фәнни хезмәтләрдә яктыртылган һәм Казан провинциясендә (губернасында түгел!) кузгалган фетнә хәрәкәтенә күз салыйк.

Җаек буенда «падишаһ Петр Федорович»ның пәйда булуы турында хәбәр алынгач та, Казан провинциясендә яшәгән крестьяннар әле октябрь башында ук беренче отрядларга оеша, мондый хәрәкәт тиздән бөтен губернаны камап ала. Без тарихи документларда ныклы эз калдырган кайбер төбәкләрне генә санап үтик: Арча юлында 3000 кешегә җиткән Мәсәгуть Гомәров отряды; Алабуга каласын камаган 6000 фетнәче; Зәй — Бөгелмә арасында хәрәкәт итүче 400 кешелек Тимерхан Мостафин отряды; Зәй крепостен 15 гыйнварда алган 2000 крестьян; 16 гыйнварда Аксар янында тар-мар ителгән 600 фетнәче; Яр Чаллы, Орловка, Мальцево, Котловка авыллары янында карательләр тарафыннан куып таратылган 8000 крестьян; Әгерҗе районы территориясендә Габделҗәлил Сөләйманов кул астына җыелган 700—800 фетнәче; Пьяный Бор авылы янында тар-мар ителгән 2000 кешелек отряд; Юскәй Кудашев кул астында оешып, Әгерҗе районыннан Ижевск заводына юнәлгән 800 кешелек отряд; 1774 елның май — июнь айларында Казан янында, карательләрнең борын төбендә хәрәкәт иткән 600 кешелек Надыйр Туктаргалин отряды; Ижевск ягына яуга юнәлгән Бакый Абдуллов, Шмота, Андрей Носков, 1774 елның гыйнварында Биләр крепостена һөҗүм ясарга хәзерләнгән атаман Иванов һәм Юлкәй Әиткулов отрядлары. Аерым рәвештә, тик үзләре генә хәрәкәт иткән тагын дистәләгән отрядларны санап тормыйк. Без монда Минзәлә, Бөгелмә, Нагайбәк, Бакалы тирәсендә яу чыгып йөргән меңәр кешелек отрядларны аңлы рәвештә искә алмадык, чөнки аларның, мөгаен, бик күбесе Уфа провинциясе буенча төзелгән мәгълүматларга кертелгәндер. Әмма инде югарыда телгә алынган отрядлар да әле Пугачев шәхсән үзе килеп кергәнче үк Казан провинциясендә фетнәгә кушылган крестьяннар санының ким дигәндә 30—35 меңгә җиткән булуы турында ачык сөйли.

Ә инде Пугачев Казан провинциясе территориясендә хәрәкәт иткән вакыт — ул тарих фәнендә крестьян явының иң югары ноктасы дип санала. Моны Мәскәүдәге җәзалаулар һәм сорау алулар чорында Пугачев үзе дә, аны карательләр кулына тотып тапшырган хыянәтче казаклар да таный. Пугачев Татарстан территориясенә 1774 елның 29 июнендә Әгерҗе аша килеп керә, ул чакта аның кул астында 8—12 мең кешелек отряд була (аның шактый өлеше татарлардан тора), 11 июльдә ул Казанны камый. Бу вакытта Пугачев гаскәрендәге фетнәчеләр саны 25 меңгә җитә. 12 июльдә Пугачев Казанны ала һәм яндыра. Шул көнне кич белән ул подполковник И. Михельсон карательләре белән бәрелешә. 800 гә якын фетнәче һәлак була, 737 крестьян әсирлеккә эләгә. Меңәрләгән крестьяннар Пугачев гаскәрен ташлап кача. Шуңа күрә

Пугачев тирә-як авылларга Исхак Әхмәтов, Сәлим Гаделшин кебек командирларны яңа отрядлар туплау өчен юллый. 15 июльдә булып узган соңгы яуга Пугачев 15 мең кешелек гаскәр белән керә. Яу барышында тагын 2000 нән артык крестьян һәлак була, 5000 кеше әсирлеккә эләгә. Ләкин шушы кадәр коточкыч югалтулар кичерүгә дә карамастан, Казан провинциясендә көрәш тукталмый. Хәзерге Теләче, Мамадыш, Питрәч, Балык Бистәсе районнарына караган авылларда июль ахырына кадәр Бәхтияр Канкаев кул астына тупланган 3000 кешелек отряд хәрәкәт итә. Кама аръягы районнарында Канзафар Усаев, Галибай Морзаголов җитәкчелегендәге отрядлар яу чыгып йөри. Июль — август айларында шунда ук Усман Тимеров, Герасим Иванов отрядлары сугыша. Һәм тагын әле Арча, Алат, Җөри юлларында хәрәкәт иткән дистәләгән вак-вак отрядлар бар.

Без югарыда Казан провинциясендә декабрь — гыйнвар һәм нигездә июнь — июль айларында хәрәкәт иткән фетнә отрядларын гына санап үттек. Әмма шушы 4 ай дәвамында көрәш алып барган отрядлардагы фетнәчеләр саны да 55—60 мең чиген узып китә. Бу — фәкать Казан провинциясендә генә хәрәкәт иткән крестьяннар саны, әле моннан тыш губерна составында тагын 5 провинция бар. Зөя, Вятка, Пермь, Пенза, Сембер провинцияләрендә дә крестьяннар гадел яуга күпләп кушылган, һәм ул провинцияләрдә дә дистә меңнәрчә татар яшәгән бит. Ә татарлар әле бу ике губерна территориясендә генә түгел, әйтик, Урал аръягында, Себердә, Чиләбедән 280 километр ераклыктагы Курган каласы (хәзер өлкә үзәге) тирәсендә 1774 елның 15—20 мартларында татар есаулы (ни өчен есаул гына, әллә Пугачев әлеге каһарман һәм аның отряды хакында белмәде дә микән?) Иван Илекәев һәм атаман Семен Новгород җитәкчелегендә 3000 кешелек отряд хәрәкәт иткән (валлаһи, гаҗәпләнерлек, кая гына сибелмәгән дә, беркайда да баш ими бөек татар!). Әмма туктаусыз һәм озакка сузылган санауларны без әлегә туктатыйк. Чөнки ике төбәктә — Уфа белән Казан провинцияләре территориясендә фетнәдә катнашкан татарларның гомуми саны болай да таң калдырырлык. **Пугачев явында ким дигәндә 85 мең, ә безнең исәп буенча 100—105 мең чамасы татар катнашкан.** Екатерина патшабикә әйткән 200 мең фетнәчене искә төшергәндә, **Пугачев явы — ул яртылаш диярлек татар явы.**

Гаҗәпләнү бу гына түгел әле. Без урыс булмаган милләтләрнең Уфа провинциясе территориясендә 86 500 фетнәче бирүен хәтердән чыгармыйк һәм Казан губернасындагы кимендә 50 мең татар фетнәчесен дә шуңа кушыйк. **136 меңнән артык урыс булмаган фетнәче.** Оренбург губернасының тагын өч провинциясендә «онытылып калган», Түбән Новгород (Нижегород) губернасында, элеккеге Касыйм ханлыгы территориясендә яшәгән килеш фетнәгә кушылган һәм безнең хисаплауга керә алмаган татарларны, Оренбург янында Пугачевка килеп кушылган казах, каракалпак һәм калмыкларны да исәпкә алсак, **ким дигәндә 140 мең урыс булмаган фетнәче.** Ләкин әле бу сан да чик түгел. Без Казан губернасы территориясендә яшәгән 180 мең чамасы — чукынган, 5 мең чамасы чукынмыйча калган мари, чуваш, удмурт ирләре *(Н. Дубровин)* хакында бер сүз дә әйтмәдек. Дөрес, алар фетнәдә татар яки башкорт халкы кебек актив катнашмыйлар. Чөнки алар инде динен алыштырган, димәк, рухлары сынган, аннан алар татар кебек элек дәүләт тотып яшәгән халык түгел. Шулай да Уфа провинциясе фетнәчеләр сафына 9300 мари, чуваш, удмурт вәкилен биргән икән, димәк, **Казан губернасында** мондый күрсәткеч 10—15 мең тәшкил иткәндер. Бу санны да кушсак, урыс булмаган 150—160 мең фетнәче килеп чыга. Сәер, гаҗәп! **200 мең** (ярар, бу сан шактый гына киметелгән дә булсын) **пугачевчының 150 меңе** (без дә гел киметеп бардык) **урыс кешесе түгел!**

Бәрәкалла! Ә совет галимнәренә Пугачев явын урыс явы итеп күрсәтү нигә кирәк булды икән? Җавабын без хәзер генә төшенәбез. Партияләштерелгән фән һәм совет сәясәте өчен Пугачев явы сыйнфый көрәш явы булса отышлырак иде. Ул әнә шулай итеп совет империясенең бердәм һәм бүленмәс булуын исбатларга, нигезләргә тырыша, ә безнең һәммәбездән гомумсовет кешесен (милләтсез, телсез, тарихсыз, йөзсез манкорт, ә чынында исә «өлкән агай» сафын тулыландыручы кавем) тәрбияләргә җыена иде.

Пугачев явына кушылган крестьяннарның милли составын һәм урыс булмаган милләтләрнең бу яуда ни өчен катнашуын берникадәр ачыклап чыктык кебек. Тагын бер тарафка игътибар итми булмый.

Урыс телендә Пугачев явына багышланган фәнни хезмәтләр дә, матур әдәбият әсәрләре дә йөзләп. Бу өлкәдәге тырышлыклары, хезмәтләре өчен Башкортстан галимнәренә һәм язучыларына да фәкать ихтирам вә соклану гына белдерергә кирәк. Шуларның фидакарьлеге һәм Мәскәү ярдәме белән Салават Юлаев исеме мәңгеләштерелде, аны дөнья белә. Ә менә татар галимнәре арасында бүген Миркасыйм Госманов белән Сәлам Алишев кына Пугачев явының белгечләре булып санала. Махсус шушы темага багышланган фәнни хезмәтләр һәм әдәбият әсәрләре дә бик аз. Иренми санап чыгыйк.

*Мәхмүт Галәү*. «Пугачев явы» — драма.

*Афзал Таһиров.* «Ямәлкә тавы» — 54 битлек әдәби әсәр.

*Газиз Гобәйдуллин.* «Пугачев явында татар-башкортлар» — газетада очерк.

*Газиз Гобәйдуллин.* «Пугачев явы» — 20 битлек әдәби әсәр.

*Әхмәт Фәйзи.* «Пугачев Казанда» — драма.
*Сәлам Алишев.* «Пугачев полковнигы» — журналда очерк.
*Сәлам Алишев.* «Бәхтияр Канкаев» — журналда очерк.
*Сәлам Алишев*. «Исхак Әхмәтов» — китапта очерк.
*Сәлам Алишев, Миркасыйм Госманов.* «Бөек крестьяннар сугышына 200 ел» — журналда һәм китапта очерк.
*Туфан Миңнуллин.* «Канкай углы Бәхтияр» — драма.
*Салям Алишев.* «Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании».

Ниндидер әсәрнең онытылып калуы мөмкин. Әмма, барыбер, инде сизгәнсездер: югарыда саналган исемлектә **татар халкының Пугачев явында күпләп катнашуын дәлилләүгә юнәлтелгән бердәнбер китап бар, анысы да урыс телендә һәм тиражы да фәкать 5 мең генә. Пугачев явы турында татар телендә нәшер ителгән бер генә китап та юк!** Шуннан соң гаҗәпләнергә туры килә. Университет һәм институтларның аспирантураларына ел саен дистәләгән милләттәшләребез укырга кереп тора. Кемдер шунда «ата кара тараканның кан әйләнеше», «урам һәм тыкрык, эт һәм мәче кушаматлары», «иялек килешендәге -ның/-нең кушымчаларының дөнья әдәбиятында тоткан роле» яки тагын әллә никадәрле темаларга диссертацияләр язып чиләнә, кайбер «үткерләре» хәтта шуны яклый, соңыннан «галим» булып күкрәк киереп йөри. Күпме кәгазь белән кара әрәм була, артык штатлар тотыла, лабораторияләр, кафедралар ачыла, дәүләтнең акчасы җилгә оча. Ә менә яртысы татарлардан торган Пугачев явы турында язучы юк, аны өйрәнүче, күтәреп чыгучы юк. Нәтиҗәдә яңадан-яңа буын үз милләтенең тарихын белми үсә, милли горурлык дигән хистән мәхрүм кала. Шуңа күрә без бүген Салават Юлаевка карап сокланабыз, күрше халык тарихындагы факттан көнләшәбез. Үзебезнең милләт пугачевчылар сафына нәкъ Салават шикелле үк бригадир дәрәҗәсенә ирешкән өч каһарман үстереп биргән. Әмма Бәхтияр Канкаев, Канзафар (Ханзәфәр) Усаев, Яркәй Кадермәтов (Ярмөхәммәт Кадыйрмөхәммәтов) атлы бу өч батырның да, Пугачев армиясе сафында атаман яки полковник дәрәҗәсенә ирешеп, зур-зур отряд башлыклары булып йөргән тагын 40 ка якын каһарманыбызның да тормыш һәм көрәш юлларын гына түгел, хәтта исемнәрен дә белмибез. Тагын бер гаҗәеп, искиткеч факт турында әйтеп китик. Салават Юлаевның фетнәдә үз әтисе Юлай Азналин белән бергә катнашуы, аларның отрядлар төзеп зур хәрби дәрәҗәләргә лаек булуы, соңыннан хөкүмәт җәзалауларын, сөргеннәрне бергә кичерүе бөтендөнья халыкларында соклану хисләре уятты. Ә татар халкы тарихында башкортларныкыннан да гыйбрәтлерәк һәм гаҗәеп үрнәк бар. Әлмәт районының Түбән Абдул (хәзерге Елховой) авылында туып үскән татар крестьяны Әит Үрәзмәтов әүвәл 1760 елда Морат мулла фетнәсендә катнаша. Шуның өчен аны патша җәлладлары Петербург каласына алып барып газаплыйлар. Пугачев явы башлангач, Әит тагын фетнәгә кушыла, отряд туплый, карательләргә каршы зур тәвәккәллек күрсәтеп сугыша. Пугачев Әитне, фетнәчеләр арасыннан бердәнбер кешене, корпус старшинасы дигән дәрәҗә белән олылый. Әитнең бертуган энесе Тимербулат походный старшина дәрәҗәсенә лаек була. Әмма Әит бик аз көрәшеп кала. Ул карательләр кулына эләгә. Җәлладлар аны Казан төрмәсендә җәзалап үтерәләр. Әитнең эшен аның улы, Пугачев гаскәрендә полковник дәрәҗәсенә ирешкән Габдерәшит дәвам итә. Җәлладлар кулына төшкәнче, ул да тынгы белми. **Фетнәчеләр сафында зур хәрби дәрәҗәләргә ирешкән Үрәзмәтовлар гаиләсе — ул бөтен Пугачев явындагы бердәнбер очрак.** Ни кызганыч, шушы фактны хәтта фән докторлары арасында да белүче юк. Мөгаен, тарихыбызга шулай гамьсез булганга күрәдер, Мәскәү, Петербург галимнәре Пугачев армиясендәге юлбашчылар исемлегенә бүген 30 башкорт, 20 татар җитәкчесен генә кертә һәм гомуми санны 200 белән киртләп куя.

Без фәнни чыганаклар, тарихи мәгълүматлар белән нигезләнгән мондый хезмәтне язу турында 1990 елларга хәтле уйламый да идек. 80 нче еллар башында, тарихи чыганаклар белән таныша башлаганда, ниятебез бүтән — Пугачев явында катнашкан татарлар хакында әдәби әсәр язарлык мәгълүмат туплау иде. Тарих — шундый өлкә, ул кешене сазлык сыман һаман-һаман тирәнгәрәк тарта. Шуңа күрә Уфа, Белорецк, Оренбург, Уральск, Свердловск, Мәскәү, Казан китапханәләрен йөреп чыктык, Петербургтан китаплар кайтарттык, архивларга кердек. Нәтиҗәдә алда бәян ителәчәк мәгълүматларның чама белән 80 процентын без 1990 елга кадәр үк үзләштергән идек. Ул чагында ук матбугат ирекле иде. «Татар галимнәре арасында XVIII гасыр тарихын, Пугачев явын өйрәнүчеләр бар бит, нигә соң язмыйлар? Милләтебез үткән олы, авыр юлны алар нишләп халыкка җиткермиләр?» — дип үрсәләнә-газаплана көттек. Ни кызганыч, фән дә, матбугат та без өйрәнгән чорны яктыртмады. Ә мөстәкыйль, азат Татарстан төзү өчен 1989 елда башланган милли хәрәкәт халкыбызга үзенең үткән тарихын һичшиксез кайтарып бирергә кирәклекне исбатлады. Сезгә тәкъдим ителгән хезмәтнең зарурлыгы туды.

Янә бер нәрсәне искәртик. Моңа кадәр татар матбугатында Пугачев явын яктырткан хезмәтләр күренсә дә, авторлар, гадәттә, Казан провинциясендә яшәгән татарларны гына телгә ала, ахыр чиктә Татарстанның бүгенге территориясеннән ары узмый иде. Мәскәү, Петербург, Уфа гына түгел, хәтта инде Казан

галимнәренең дә татар тарихын бүгенге Татарстан — шул ук Мәскәү тарафыннан, Ленин һәм Сталин тарафыннан кискәләнгән һәм өч-дүрт мәртәбәгә киметелгән Татарстан белән генә киртләп куюы безне һәрчак шаккатырып килде. Әйтерсең лә бүген Башкортстан территориясендә яшәгән бер ярым миллион, Оренбург, Чиләбе, Екатеринбург, Самара, Саратов, Ульяновск, Пермь, Киров һәм тагын әллә кайсы өлкәләргә чәчелеп гомер сөргән биш миллионга якын татар безнең туганнар түгел дә, аларның гомумтатар тарихына катнашы юк. Күрше республика, күрше өлкәләр белән сәер дуслык, сәер бердәмлек хакына фән өчен дә, мәгърифәт һәм мәдәният өчен дә читтә яшәгән татар бик еш кына үги булып калды. Татар шәхсән үзе күрмәгәч, газиз тарихының тулылыгы өчен үзе көрәшмәгәч, Оренбург, Чиләбе, Самара, Пенза... галимнәре, әлбәттә инде, татар каһарманнарының исемнәрен күтәреп чыкмады, тарих өчен кадерле һәм гыйбрәтле вакыйгаларны «эчкә» йотты. Ә бүгенге Башкортстан территориясендә яшәгән татарлар тарихы турында сөйләп торасы да юк. Әле 1926—1979 еллар эчендә генә дә биредә 373 авылда (!) яшәгән татар вәкиле мәҗбүри рәвештә «башкортлаштырылган» икән («Идел», 1993, №9), тарихи гаделлек турында нинди сүз булуы мөмкин?!

Ә XVII—XVIII гасырда яшәгән күпме татар каһарманы бүген матбугатта «башкортныкы» булып йөри икән? Моны хәтта тарихи документлар эчендә казынган белгечләргә дә аеруы кыен. Менә шуңа Пугачев явында атаман яки походный старшина булып йөргән (рядовой крестьяннарны әйтеп торасы да юк) Балтач Сәетов, Зәйнәш Сөләйманов, Батыркай Иткинин, Гадел Бигашев, Бүләк Якупов, Сөләйман Күзкәев, Зөлкәрнәй Йосыпов, Нурый Ишәев, Сәлим Әитов һәм тагын әллә никадәрле җитәкчеләр Мәскәү, Уфа, Казан галимнәре тарафыннан әле башкорт, әле татар дип телгә алына. Ә галимнәрне шул — ел саен «башкортлаштыру» сәясәтенә буйсына барган, «үлгән» татар авылларының исемлеге аптырашка кертә. Пугачев явын гына өйрәнергә дип архивка кергән галим, әйтик, бер кәгазьдә «Бикмәт авылыннан старшина Балтач Сәетов» дигән сүз очратса, бу авылның тарихын ачыклап тормый, гадәттә, соңгы елларда нәшер ителгән рәсми исемлеккә мөрәҗәгать итә бит. Анда исә Башкортстандагы Бикмәтләрнең һәммәсе диярлек бүген инде «башкорт авыллары» дип үзгәртелгән. Бу әле ялгыш юлга кергән, ялгыш нәтиҗә ясаган галимнәрнең бер төркеме генә. Шуның өстенә тарихи документларда телгә алынган авыл һәм шәхесләрне Башкортстанның бүгенге территориясенә һәм исемнәрнең төркичә яңгырашына «ерактан» карап кына «башкортлар» исемлегенә теркәп утыручы Мәскәү һәм Петербург галимнәре дә бар. Аларны Башкортстан территориясендә яшәгән татар һәм башкортларның аерым-аерым саны һәм миграция процессы да, андагы авыллар тарихы да бик үк кызыксындырмый.

Ә без бер-ике мәгълүматка гына мөрәҗәгать итик. 1688 елда ук инде Уфа воеводалыгындагы Уса юлының Уран волостенда 50 татар, мари, удмурт авыллары булган, аларның кайберләре бу төбәктә 60 ел элек үк нигезләнгән *(Д. Рамазан*)*. 1693 елда шушы ук төбәктә тагын Карышбаш, Богдан, шул ук чорда Чурталы күл, Уразай, Янбай, Начар кебек яңадан-яңа татар, мишәр авыллары барлыкка килгән *(Ә. Әсфәндияров)*. 1705 елда башланган Алдар — Күчем явыннан соң Казан, Сембер өязләрендә яшәгән татарларның башкорт җиренә күчеп утыруы аеруча күмәк төс алган. Шул чор документлары, ул чакта Казанда вице-губернатор булып торган Н. Кудрявцев, губернатор А. Волынский, тарихчы П. Рычков раславына караганда, **XVIII гасыр башында башкорт халкының (дөресрәге, рәсми кәгазьләргә үзен башкорт дип яздырган халыкның) саны ким дигәндә ике мәртәбә арткан.** Ул елларда Петр патшаның яңа указлары буенча елына җан башыннан 1 сум 10 тиен салым түләргә мәҗбүр ителгән татар өчен дәфтәргә башкорт булып теркәлү отышлырак булган. (Мисал өчен, 1753—1793 елларда Кыр-Елан волостена күчеп утырган һәм типтәр булып теркәлгән Уразаев, Әлмәмәтов, Йосыпов, Дүсмәкәев, Ишкилдин кебек татарлар һәр йорттан (!) елына унар (!) гына тиен салым түләргә тиеш булганнар. *(Ә. Әсфәндияров)*. Билгеле булганча, Уфа провинциясендә яшәгән мишәрләргә бары тик 1747 елда гына, анда да җан башыннан 25 тиен, типтәрләрдән 80 тиен (ә татарлардан ул чагында — 1 сум 70 тиен — 2 сум, 1770 елларда инде 2 сум 70 тиен күләмендә) салым түләү тәртибе кертелә. Мондый катламнарга бүленү һәм аеруча башкорт катламы булып язылырга омтылу Уфа провинциясендә яшәгән халыкларга әле соңрак та өстенлекләр китерә. 1832 елгы закон буенча, мәсәлән, башкортларның һәр ир-атына — 40, типтәр һәм мишәрләргә — 30, ә татар белән чувашка 15 дисәтинә генә имана җире бирелә *(Ә. Әсфәндияров)*. Шушы мәгълүматларны барлап чыкканнан соң, XVII—XVIII гасырда татар ирләренең ни өчен «башкорт»ка әйләнүен күзаллау читенмени. Бәлки, нәкъ менә шуңа күрәдер, җирдән файдалану буенча өстенлекләр беткәч (Ленин белән Сталин талап алганнан соң крестьян җирсез калгач), дистәләгән «башкорт» авылларының халкы үз милләтен «татар» дип яздырган да. Мисал өчен, Башкортстанның Балтач районындагы — Чыпчык, Илтуган, Әтҗетәр, Шәрәй, Кыешкы, Уразай, Олы күл, Тимкә, Еләзе күл, Начар; Краснокамадагы — Иске Кабан, Ялгыз нарат; Ярмәкәйдәге — Әбделкәрим, Усман-Ташлы, Абдулла, Шаһ, Ярмәкәй; Гафури районындагы — Ялгыз каен, Базык; Кырмыскалыдагы — Колыш; Борай районындагы — Карабай һәм тагын әллә ничә районнардагы дистәләгән авыллар 1920—1926 елларда үзендә яшәгән

халыкның милләтен татар дип яздырган! Тик, ни гаҗәп, алар бүген исемлектә янә «башкорт» авыллары булып йөри. Ә исемнәре әле генә санап кителгән бу авылларның һәммәсе 1773 елга кадәр үк нигезләнгән, аларда татарлар яшәгән *(Ә. Әсфәндияров)*. Шушы авыл татарларының кайберсе Пугачев явында каһарманлык кылган, икенчеләре шәһит киткән. 1773—1774 елгы документларда «Абдулла яки Олы күл авылыннан фәлән углы фәлән» дип искә алынган кеше, кичә-бүген язылган хезмәтләргә «Уфа өязендәге башкорт йөзбашы яки башкорт крестьяны» булып кергән.

Ә Башкортстан территориясендә татар һәм башкорт гаиләләреннән торган катнаш милләтле авыллар 1773 елда күпме булган да, алар хәзер ничә? Моңа төгәл генә итеп җавап бирә алучы кеше гомумән бар микән? Ә Пугачев фетнәсен чагылдыручы документларда искә алынган Үтәк, Морак, Котлыхуҗа, Акташ (Гафури районында), Кабак (Кырмыскалыда), Туйчыбай, Сәйтәк, Кансөяр, Мишәр, Илекәй (Балтачта), Иске Бөртек, Ногай, Ат күл (Краснокамада) һәм тагын йөзләгән авылларда 1773 елда бер үк урамда күршеләр булып татарлар да, башкортлар да яшәгән *(Ә. Әсфәндияров)*. Бу авылларның һәммәсе диярлек хәзер исемлектә «чиста башкорт» авыллары булып йөри. («Башкирская АССР. Административно-территориальное деление».) Әнә шулай — тулы авыллары яки урамнары белән аралашып урнашкан волость һәм түбәләрдә (волостьлар 3—4 түбәгә бүленгән) яшәүче татар вә башкорт крестьяннары үзләренең старшиналары яки йөзбашлары итеп, гадәттә, җир хуҗасы (вотчинник) булган башкорт вәкилен сайлаган, кайбер волостьларда гына һәр милләт үзенең аерым старшиналарын билгеләгән. Сүзебез дәлилсез булмасын өчен, архив материалына мөрәҗәгать итик. Һәркайсында татар белән башкорт укмашып яшәгән волостьларда 1774—1775 елларда сайланып куелган старшиналар: Шәмшәдедә — башкорт Ямбулат Мостаев, Сеңгерәндә — башкорт Бакый Сәфәров, Кыргызда — башкорт Кадергол Баисланов һәм **татар** Табыш Абдуллин, Бүләрдә — башкортлар Имангол Кутлин һәм Ихсанай Мөслимов, Елдәктә — башкорт Баязит Бикмәмәтов, Кыпчакта — башкорт Ишкәр Арысланов, Дүнәвәйдә — башкорт Ихсан Баязитов, Енәйдә — башкорт Гали Ярмөхәммәтов һәм башкалар (Оренбург өлкәсенең дәүләт архивы — ОӨДА, 3 фонд, 1 тасвир, 148 эш, 36 бит). Менә шуларны белгәннән соң, архив эшләрендә исеме мәңгеләштерелгән мөселман фетнәчесен фәкать аның туган авылына йә булмаса старшинасының, йөзбашының милләтенә карап кына бүген — 50 ел эчендә 373 авылдагы халыкның милләтен партия өлкә комитеты кушуы буенча «алыштыра» торган заманада — кистереп һәм ялгышмыйча, «татар яки башкорт» дип мөһерләү мөмкинмени?

Аннан соң, тагын шунысын да искәртү артык булмас. Әби патша — Екатерина чакыруы буенча ул чорда Рәсәйгә меңәрләгән немец хәрбиләре, сәүдәгәрләре, һөнәрчеләре һәм тагын әллә никадәрле белгечләр күчеп килгән. Пугачев явы аеруча шаулап узган Казан һәм Оренбург губерналарында юньләп урыс телен дә белмәгән Я. Брандт һәм И. Рейнсдорп хакимнәр булып утырган. Пугачев гаскәренә, фетнәче крестьяннарга каршы көрәштә җәза отрядларын В. Кар, Ф. Венцель, Я. Данненберг, И. Деколонг, Отто Демарин, О. Дуве, К. Кених, А. Корф, А. Миллер, И. Михельсон, К. Муфель, А. Папава, И. Фегезак, А. Фейервар, И. Фок, Ф. Фрейман, Д. Вульф, Ф. Беенке, А. Рас, Валленштерн, Баннер кебек немец офицерлары һәм генераллары җитәкләгән. Пугачев явын чагылдырган документларның бик күбесе шулар тарафыннан иҗат ителгән. Ә кичә генә Рәсәйгә килеп төшкән немец дворяны башкортны татардан, казахны калмыктан һичшиксез аера белмәгән. Шуңа күрә үз рапортларында әлеге дворяннар фетнәчеләрне «толпа сволочей», «воры» дип кенә телгә алган. Бәхтияр Канкаев, Салават Юлаев, Канзафар Усаев, Гадел Бигашев, Галибай Морзаголов һәм башка каһарманнар кул астына тупланган отрядларның да немец дворяннары милли составларын ачыклап тормаганнар, күп очракта «башкирцы» дип кенә тамгалаганнар.

Безгә калса, татар белән башкорт халыкларының тарихын бүген бер-берсеннән аерып карап булмый. Гасырлар дәвамында бер үк территориядә яшәү, кәләш бирә-бирә кан алмашу, урыс коллыгыннан котылу өчен иңгә-иң торып көрәшү бу ике милләтнең тарихын һәм язмышын шул дәрәҗәдә бер-берсенә үреп бетергән ки, хәзер инде йомгакны сүтәргә маташу да, ниндидер чиста дан, чиста шөһрәткә дәгъва кылу да мөмкин түгел. Татар белән башкорт хәят һәм ихтилал учагын мәңге-мәңге бергә яккан икән, бүген шуның көлен яки күмерен бүлешүдән ике якка да бер файда да юк.

Кереш сүзгә нокта куйыйк. «Бүгәлә һәм хакимлек ит» дигән кагыйдәне мәкерле рәвештә кулланып, большевиклар партиясе 1919—1920 елда безне, татар-башкортны, Ык һәм Сөн елгалары буенча икегә бүлгән. Империя коллыгыннан котылыйк дисәк, юлыбыз, язмышыбыз кабат кушылырга тиеш. Безнең бергәлекне тарих күп раслаган. Сезгә тәкъдим ителгән әлеге хезмәттә чагылдырылган вакыйгалар да безнең тарихи бергәлеккә яңа мисал.

Без бу хезмәттә абсолют яки какшамас хакыйкатькә дәгъва белдермибез. Безнең максат таррак. Дистә еллар буена халыкны үзенең газиз тарихыннан аерып торган кара пәрдә ачылырга тиеш. Пәрдә артына ниләр яшерелгән? Моны халык белсен. Ә хезмәткә тиешле бәяне ул, иншалла, үзе бирер.

# ПУГАЧЕВ ҺӘМ КАЗАН

1773—1775 еллардагы крестьяннар явының юлбашчысы Емельян Пугачев исеме Казан тарихы белән турыдан-туры бәйле. Кайбер мәгълүматларга караганда, ул Казан губернасына беренче мәртәбә 1765—1766 елларда ук аяк баскан. Өч ел буена Германиягә каршы сугышларда катнашып, аннан соң Польша җиренә качкан урыс крестьяннарына каршы көрәшеп йөргән Пугачев алыпсатарлык кәсебе ярдәмендә бик тиз генә баеп китәргә хыяллана. Дегет, ятьмә ише товарларны ерак җирдән очсыз хакка алып, Донга кайткач аларны кыйбат бәядән сатарга ният корган Пугачев, үзе шикелле үк елгыр казак белән бергә, Кама елгасына кадәр килеп җитә. «Кәсепчеләр» сәяхәт вакытында Балык Бистәсе, Чистай, Мамадыш, Сарсаз, Котловка авыллары яныннан үтеп китәләр, Көнгер өязенә кадәр барып җитәргә ниятлиләр. Әмма бу чорда бөтен Кама буен Уралдагы заводларга йөреп эшләүдән баш тарткан крестьяннар фетнәсе чолгап алган була. «Алыпсатарлар»ның юлы уңмый, һәм алар Дон буена буш кул белән генә кайтып китә.

Аннан соң ике ел буена Емельян урыс-төрек сугышында катнаша. Авырып китү сәбәпле, 1771 елда туган җиренә — Дон елгасы буендагы Зимовейская станицасына кайтып төшкән хорунжий (кече офицер) Пугачевны казакларның югары власть вәкилләре ат урлауда һәм Кубаньга качарга җыенуда гаеплиләр. Пугачев, чыннан да, Терек (дөресе Төректер инде) елгасы буена качып китәргә омтылыш ясый. Власть вәкилләре аны шуның өчен кулга алалар. Ләкин Пугачев бик оста итеп ике-өч мәртәбә алар кулыннан качып котыла һәм, бай казакларның үзен иректә калдырмаячагын аңлагач, бөтенләй Польша җиренә үк китеп бара. Польшага киткән качакларны патшабикә Екатерина II тарафыннан гафу итү турында указ чыгарылуга, Пугачев Добрян форпостында паспорт ала. Польшадан Рәсәйгә чыккан качакларны Екатерина Идел аръягында, Иргиз (Кыргыздыр инде) елгасы буенда нигезләнергә чакыра. Пугачев та 1772 елның көзендә Казан губернасына килә.

Пугачев утлар-сулар кичеп йөргән чакта, Рәсәй төрле сәер хәбәрләр белән тула. Әле Царицын каласында, әле Воронеж өлкәсендә яңа «падишаһлар» пәйда була. Аларның һәркайсы үзен хыянәтче Екатерина тарафыннан тәхеттән куылган Петр Федорович дип игълан итә. Гәрчә чын Петр патша 1762 елның 5 июлендә Екатерина тарафдары Алексей Орлов тарафыннан буып үтерелгән булса да, Богомолов, Рябов, Асланбеков, Евдокимов кебек батырлар үзләрен явыз патшабикә кулыннан очраклы рәвештә качып котылган «падишаһ» итеп танытырга тели. Тик аларның «тантанасы» озак дәвам итми. Шулай да Рәсәйне иңеннән-буена йөреп чыккан Пугачев аларның фаҗигале язмышы турында да, Петр III хакында да ишетеп кала һәм бу хәбәрләрнең һәммәсен мыегына чорный бара.

Идел аръягына чыгып, Сембер провинциясенә аяк баскач, Пугачев әүвәл Малыковка авылында (хәзерге Вольск шәһәре) һәм Мәчет бистәсендә (хәзер Саратов өлкәсендәге Пугачев каласы, Олы Иргиз елгасы буенда) туктала. Бу төбәктә яшәгән крестьяннарның һәм Җаек казакларының тормышы, кайгылары белән кызыксына.

Ә Җаек казаклары бу вакытта яраларын ялап ятучы җанварны хәтерләтә. 1772 елның гыйнварында комсыз старшина һәм атаманнарның рәхимсез талавына каршы күтәрелгән казакларның фетнәсен бастыру өчен, патша хөкүмәте Җаек шәһәрчегенә (хәзерге Уральск) генерал фон Траубенберг командалыгындагы коралллы отряд юллый. Башимәс казаклар беренче бәрелеш вакытында генералның үзен дә, хөкүмәткә сатылган атаман Петр Тамбовцевны, Яков Колпаков, Суетин, Федор Митрясов, Иван һәм Семен Тамбовцев кебек старшиналарны юк итәләр. Фетнәне бастыру өчен җибәрелгән отряд та, бай старшиналар да кулга алына, шәһәрдә ярлы казаклар тантанасы башлана. Ләкин патша хөкүмәте февраль аенда ук казакларга каршы генерал-майор Ф. Фрейман командалыгында яңа гаскәр юллый. Июнь башында Фрейман Җаек шәһәрчегенә килеп җитә һәм казаклар гаскәрен куып тарата. Йөзләгән казак кулга алына, төрмәләргә ябыла. Җәлладлар 47 кешене асып, 3 казакның башын өзеп, 12 кешене кисәкләргә чапкалап үтерәләр (*В. Буганов*. «Емельян Пугачев»). Дистәләгән казакны мәйданнарда камчылар белән кыйныйлар. Бик күп кеше далага качып кына җәзалаудан котылып кала. Казакларга 36 756 сум штраф салына.

Казакларның аяныч хәле турында ишетүгә үк, Пугачев сәүдәгәр сыйфатында Җаек шәһәрчегенә ашыга, 22 ноябрь көнне ул Денис Пьянов дигән казак йортына килеп төшә. Бер атна чамасы базар һәм урамнарда йөргәннән соң, Пугачев казакларның барча михнәтләрен дә, ниятләрен дә аңлап ала.

Көннәрдән бер көнне ул Пьяновка үзенең сәүдәгәр түгел, бәлки Екатерина үченнән качып йөрүче «падишаһ Петр Федорович» булуын «ачып сала». Әгәр аны патша итеп танысалар, Пугачев казакларны Кубаньга — чикләнмәгән ирек хөкем сөргән җиргә алып китәргә, анда аларга «Петр III»гә төрек солтаны «вәгъдә иткән» 5 миллион сум акчаны өләшергә антлар бирә. Пугачев тагын берничә көн базарларда йөри, аннан соң Семен Филиппов дигән бай крестьян белән бергә Малыковкага кайтып китә. Шушында Филиппов, власть вәкилләренә барып, Пугачевның «падишаһ»лыгы турында сөйли. 19 декабрь көнне

Пугачевны кулга алалар һәм Сембер төрмәсенә озаталар. 1773 елның 4 гыйнварында ул инде губерна башкаласы Казанга китерелә.

Бу вакытта губерна башлыгы булып шактый өлкән яшьтәге һәм авыру немец генералы Яков фон Брандт утыра. Ул үзенең карамагына никадәрле куркыныч җинаятьче китерелүен дә, аның нидә гаепләнүен дә аңлап бетерми. Губерна канцеляриясендә сорау алганнан соң, Пугачевны Кремль төрмәсенә ябып куялар. Ул ике айдан артык вакыт буена Консисторская манарасы астындагы подвалда куллары-аяклары богауланган килеш тотыла. 27 март көнне аны, башка тоткыннар белән бергә, подвалдан төрмә ишегалдына күчерәләр. Губерна канцеляриясенең сәркатибе А. Аврамов кушуы буенча, Пугачевның кул-аякларына тагылган авыр богауларны җиңелрәк зынҗырларга алыштыралар (Аврамов соңыннан «хезмәтендәге кимчелекләре өчен» Себергә сөргенгә озатыла. — «Следствие и суд над Пугачевым»). Пугачевка Казан урамнарына чыгып хәер сорашырга һәм Арча кырына (хәзерге М. Горький исемендәге Мәдәният һәм ял паркы тирәсе) барып төрле эшләрдә катнашырга рөхсәт ителә.

Төрмәдә утырган чагында Емельян тоз сату итеп бөлгенлеккә төшкән сәүдәгәр Парфен Дружинин белән таныша. Казанда Дружининнең хатыны һәм 17 яшьлек улы Филимон яши. Пугачев белән Дружинин тоткынлыктан качарга план коралар. Шәһәргә чыгып хәер җыйган чакта, алар Филимон белән бу турыда сүз беркетеп куялар. Төрмәдә каравылчы солдат булып торган Григорий Мищенковны да үзләре белән качарга үгетлиләр. 29 май көнне Пугачев белән Дружинин хәер җыю өчен шәһәргә чыгарга рөхсәт сорыйлар. Аларны озатып йөрергә Денис Рыбаков атлы солдатны билгелиләр. Мищенков аларны «саклап» йөрергә үзе теләк белдерә.

Урамга чыгуга, Иван Ефимов дигән рухани йортына барып, качаклар Рыбаковка шәраб эчертәләр. Якында ук аларны кибитка эчендә Филимон көтеп тора. Шул атка утырып качаклар Казаннан чыгып китә. Рыбаковны Царицыно авылы янында ташлап калдыралар. (Тоткыннарны качырган өчен, Рыбаковны соңыннан коточкыч кыйныйлар. Шул кыйнау нәтиҗәсендә 1774 елның кышында Рыбаков вафат була. — «Следствие и суд над Пугачевым».)

Качаклар Алат юлы буйлап китәләр. Чыршы авылында туктап, бер тәүлек буе яшеренеп торалар. Дружинин бирёдәге крестьяннардан тагын бер ат сатып ала. Чыршы авылында көтеп торган Дружинин гаиләсе белән бергә янә бер тәүлек буена урманда яшеренеп яталар. Аннан соң, сакланып кына юлга чыгып, Вятка елгасын кичәләр. Кама буендагы Котловка авылына барып җитәләр.

Сәүдәгәр Дружинин 1760—1762 елларда Демидовларның Уралдагы заводларына йөреп эшләүдән баш тарткан фетнәче крестьяннарның юлбашчысы Карп Карасевны («Карп Карась») инде күптән белгән була. Бу вакытта инде шактый олыгайган, ап-ак чәчле картка әверелгән әлеге Карптан Пугачев 7 тиенгә балык сатып ала. Аннары Дружининнар белән Пугачев Каманың сульягына чыга. Сарсаз авылы (Зәй районында) янына җиткәч, Пугачев Дружининнар гаиләсе белән аерылыша. Емельян шушында яшәүче Алексей Кандалинцев дигән крестьян хуҗалыгында 5 атна буе качып ята. Фәкать шуннан соң гына Пугачев белән Кандалинцев Җаек казаклары янына юлга чыгалар. (Кандалинцев соңыннан, 1774 елның апрель ахырында Җаек каласында җәзалап үтерелә. — «Следствие и суд над Пугачевым».)

## ҖАЕК БУЕ ҺӘМ ОРЕНБУРГ. ЯУНЫҢ БАШЛАНУЫ

15 августта Емельян Җаек шәһәрчегеннән 60 чакрымдагы Таловая дигән елга буена урнашкан юлханәгә килеп җитә. Юлханә хуҗасы Степан Оболяев белән ул әле 1772 елның ноябрь аендагы «визиты» вакытында ук танышкан була. Бу юлы, мунчага баргач, Пугачев инде Оболяев каршында да үзенең «падишаһ» икәнлеген «ачып сала».

Бераздан юлханәгә «падишаһ»ны күрү өчен, Җаек шәһәрчегеннән иң ышанычлы һәм абруйлы казаклар килә башлый. «Император Петр Федорович» казакларга чикләүсез ирек, яхшы хезмәт хакы, икмәк, тоз, балыклы елгалар һәм печәнле болыннар вәгъдә итә. Бай старшиналар изүеннән, патша хөкүмәте урнаштырган яңа тәртипләрдән туйган казаклар, алларында ялган падишаһ торуын аңласалар да, Пугачевны азатлык өчен көрәш байрагы итәргә риза булалар. Аны император дип таныган казаклар, тәре үбеп, тугрылыкка ант итәләр. «Падишаһ» өчен бүрек, кафтан, сәркатип, байракка яраклы тукыма эзләү башлана.

Пугачев Усиха елгасы буенда, Җаек шәһәрчегеннән 55 чакрымда урнашкан Кожевниковлар хуторында яшеренеп яткан чагында ук аның янына татар халкының беренче вәкилләре дә килә башлый. Бу вакытта Пугачевның «император» икәнлеген Җаек казаклары арасында санаулы гына һәм аеруча зур абруй, ышаныч казанган кешеләр генә белә. Аның кайда яшеренеп ятуын, киләчәккә нинди планнар коруын

искиткеч зур сер итеп саклыйлар. Бу хакта хәтта урыс крестьяннарына да сер чишмиләр. Шул ук вакытта Барын Мостаев, Идеркәй Мәхмүтов, аның туганы Балтай, Аптыш Тангаев, Уразкилде Аманов (Ураз Әминов), Т. Булатов, Биткул Сәетборһанов, Акбирде Давытов кебек татарлар, «император» әле халык каршына чыгып күренгәнче үк, куркыныч заговорның шаһитларына һәм дәһшәтле восстаниене оештыручыларга әвереләләр. Татарлар Җаек буенда кайчан пәйда булган, казаклар каршында алар ничек шул кадәрле абруй яулаган соң?

Татар вәкилләре Җаек буена, хәзерге Оренбург өлкәсенең далаларына һаман да шул патша хөкүмәтенең аяусыз талау-изүенә түзә алмыйча кача. Беренче татар качаклары Җаек буена XVI гасыр ахырында ук килеп урнашалар һәм казаклар арасында бик тиз арада зур абруй, ышаныч яулыйлар. Җаек казаклары арасында татар качакларының саны сизелерлек була. Нәкъ менә шуңа күрә әле Михаил Романов идарә итә башлаган чорда ук патша янына Җаек буенда яшәгән халыкларның тулы хокуклы вәкилләре булып бер христиан казагы һәм бер татар кешесе җибәрелә. Нәкъ шулар казакларны Рәсәй составына алуны сорыйлар (*В. Буганов* «Пугачев»).

XVIII гасыр дәвамында Казан губернасында татарларны дини, сыйнфый һәм милли яктан изү аеруча көчәя. Әле Петр I заманында җан башыннан 1 сум 10 тиен күләмендә акчалата еллык салым түләгән булсалар, 1770 еллар башына аның күләме 2—3 сумга җитә. Шушы гасырның 40—60 нчы еллары дәвамында гына да губернадагы алпавытларның саны — бер ярым, ә аларга коллыкка төшкән крепостной крестьяннарның саны ике тапкыр арта. Казан, Вятка, Пермь, Зөя (Свияжск), Сембер, Пенза кебек алты провинциядән торган губернада яшәгән халыкның гомуми саны 1767 елда 2 миллион 500 мең кеше исәпләнә. Бер ир-атка уртача 7,2 дисәтинә (8 гектар) имана җире туры килә, ә чәчүлек мәйдан 1,7 дисәтинәсен генә тәшкил итә. Крестьянга хуҗалыкны алып бару, гаиләсен исән-сау тоту, салым түләү өчен җир җитми башлый. 1750 елда, мәсәлән, губернадагы крестьяннарның 84 меңе салымнарны түли алмый, ягъни бөлгенлеккә төшә (*С. Алишев*. «Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании»).

Акчалата талау өстенә, татар крестьяннарын төрле казна эшләренә йөртеп җәфалыйлар. 1770 елда лашманлык, ягъни урман кисү эшенә беркетелгән крестьяннарның саны 70 меңгә җитә. Крестьяннар туган йортларыннан йөзәр чакрымга — Уралдагы 84 заводка барып, анда 30—50 шәр тәүлек буена, коточкыч шартларда эшләргә мәҗбүр ителәләр. Хуҗаларына, власть вәкилләренә буйсынмаган крестьяннарны Екатерина II нең 1765 елгы указы нигезендә сөргенгә озатырга хокук бирелә. 1767 елгы яңа указдан соң крестьяннарга үзләренең хуҗалары өстеннән зарлану, шикаять язу да тыела. Алпавытларга үз утарларында зинданнар төзергә, крестьяннарны камчы белән җәзаларга рөхсәт ителә. Кешеләр хайван белән бер дәрәҗәгә төшерелә, аларны ау этләренә яки атларга алыштыра, балаларын әти-әниләреннән аерып сатып җибәрә башлыйлар.

XVIII гасыр уртасында татарларны көчләп чукындыру коточкыч төс ала. Патшабикә Елизавета Петровнаның 1742 елгы указы нигезендә Казан губернасындагы 536 мәчетнең 418 е җимерелә. 30—50 нче елларда губернада көчләп чукындырылган ир-ат крестьяннарның саны 270 меңгә (алар арасында 3670 е генә татар) җитә. Татар халкы аеруча менә шушы көчләп чукындыру сәясәтен гафу итә алмый. XVIII гасыр буена татарлар, туган җирләрен ташлап, Кама аръягына, Урал тавы, Агыйдел һәм Җаек буена кача.

1735 елда Җаек ярында Оренбург каласы нигезләнгәч, татарлар бу төбәккә күмәк рәвештә күчеп утыра башлый. 1744 елда Оренбургтан 18 чакрым ераклыкта Каргалы (Сәгыйть) бистәсе барлыкка килә. Шуннан соң Казан белән Оренбург арасында инде Бөгелмәдән ары Кандыз, Усман, Якуб, Әшир, Ибрай, Абдул, Котлымбәт, Нәүрүз, Дүсмәт, Сарманай, Мостафа, Йөзәй, Биккол, Имәнгол, Камышлы, Урта һәм Түбән Чебенле кебек дистәләгән татар авылларыннан торган чылбыр хасил була. Бүгенге көндә дә Оренбург өлкәсенең шактый өлешен татар авыллары тәшкил итә, аларның күбесе XVIII гасырда нигезләнгән. Җаек шәһәрчеге янәшәсендә дә Ташлы, Солтангол кебек татар авыллары барлыкка килә.

Оренбург далаларына, Җаек буена күчеп килгәннән соң, татарлар игенчелек, һөнәрчелек белән көн итә башлый. Шулай ук аларның бик күбесе казак гаскәре сафларына баса һәм Җаек елгасы буенда Рәсәйнең көнчыгыш чикләрен саклауда катнаша. Казах Җүзләре чигендә төзелгән Красногорск, Верхне-Озерск, Борск крепостьларының гарнизоннары нигездә татар казакларыннан тора. 1774 елгы документларда Нижне-Озерск крепостенда да Муса Мөслимов белән Тимер Ямбулатов шикелле татар казакларының хезмәт итүе телгә алына («Документы ставки Е. И. Пугачева, повстанческих властей и учреждений»). Самара линиясендәге Мачын бистәсе татарларының һәммәсе казак хезмәтен башкара. Каргалы авылында, Ильинская, Сакмар крепостьларында, Оренбург каласы белән Җаек шәһәрчегенең үзендә дә казак-татарлар аз булмый. Өстәвенә, бай старшиналар һәм казаклар нindidер йөкләмә (повинность) үтәүгә яки ерак походларга билгеләнгән чакта үзләре урынына татарларны яллыйлар. Бай старшиналарның хуторларында иген үстереп, мал карап көн күрүче татарлар да була.

Җаек казаклары электән үк нинди дә булса өстенлекләрдән файдаланалар. Хөкүмәт аларга даими рәвештә хезмәт хакы  (елына 12 сум чамасы) түли, болынлыклар бүләк итә, елгаларда балыкны бушлай тоту хокукын бирә. Шуңадыр, күрәсең, хәрби походлар вакытында исемлеккә теркәлгән һәм өстенлекләрдән файдаланган казакларның саны һаман арта тора. 1767 елда, мәсәлән, Оренбург  белән Гурьев арасында, Җаек елгасы буйлап урнашкан крепостьларда 4200 кеше хәрби хезмәттә (жалованье алып) тора, ә исемлектә 12 мең казак исәпләнә (*В. Буганов*. «Пугачев»). Уральск педагогия институты галиме, тарих фәннәре кандидаты, «пугачевчы» А. Белыйның  әйтүенә караганда, 1770 еллар башында Җаек буендагы татар казакларының саны 2200 гә җитә. Патша хөкүмәте казаклар арасында ревизия үткәрә башлагач, байтак татар, өстенлекләрдән коры калмау өчен, христиан динен кабул итә.

Һәм, билгеле инде, үзенең укымышлылыгы, сату-алу эшенә маһирлыгы белән танылган татар халкының йөзләгән вәкилләре Урта Азия белән ике арада сәүдәгәр, гаскәр сафында тылмач булып йөри. Җаек буена килеп урнашкан татарлар ярлы казаклар белән һәрчак дус яши, аларның кайгы-михнәтләрен бергә бүлешә, ихтирамын казана һәм иң яшерен серләрен дә ишетеп-белеп тора. Менә шуңа күрә үз иленнән куылган, кимсетелгән, изелгән татар вәкилләрен заговорчы казаклар Пугачев каршына бернинди шикләнүсез алып килә.

Усиха елгасындагы Кожевниковлар хуторында пәйда булган «император» турындагы хәбәрләр бай старшиналарга да ишетелә. Власть вәкилләре Пугачевны кулга алу өчен махсус отряд юллый. Бу отряд турында хәбәр алынуга ук, үзенең «якыннары» белән бергә Пугачев Җаек шәһәрчегеннән 100 чакрымда урнашкан Толкачевлар хуторына кача. Берничә кеше, өстәмә көчләр алып килү өчен, авылларга һәм крепостьларга озатыла. 16 сентябрь көнне заговорчыларга 30—40 лап казак һәм Идеркәй Мәхмүтов алып килгән 20 татар кушыла. Пугачев байрагы астына тупланган фетнәчеләрнең гомуми саны 80 кешегә җитә (*В. Буганов.* «Пугачев»).

Казаклар арасында укый-яза белүче 17 яшьлек Иван Почиталин да була. Ул «падишаһ» исеменнән указ яза һәм 17 сентябрь көнне иртән «Петр Федорович»ның әлеге фәрманы казакларга игълан ителә. Меңәрләгән корбаннар китерәчәк дәһшәтле восстание шулай кабына.

Шушы ук көнне, Идеркәй Мәхмүтов тәкъдиме буенча, казах ханы Нурали исеменә хат языла. Аны Уразкилде Аманов алып китә. Ул тиздән бай казаклар кулына әсирлеккә эләгә. Әмма «император» турындагы хәбәр Нурали ханга инде болай да ишетелгән була. 18  сентябрь көнне Пугачев янына Нурали ханның сәркатибе — Казан татары Зәбир мулла килә.

Зәбир мулла Нурали хан исеменнән «падишаһ»ка шәп аргамак, ефәк чапан, кылыч һәм көмеш белән бизәлгән кечкенә балта бүләк итә. Зәбир мулла элеккерәк елларда Петербург каласына барган һәм анда Петр III не күргән кеше була. Хәзер инде, казаклар каршында, Зәбир мулла «падишаһ»ны «таный». Билгеле инде,  мондый «раслау» Пугачев өчен бик зур ярдәм була.

18 сентябрь көнне Пугачев янына җыелган казакларның саны 200 гә җитә, аларның 40 ка якыны татар була (*С. Алишев.* «Татары...»). Фетнәчеләр бернинди каршылык та күрмичә, атышсыз-яусыз гына Бударино һәм Чаган форпостларын барып алалар. Бай старшиналар тарафыннан шымчылыкка җибәрелгән казак Алексей Скворнин фетнәчеләр кулына эләгә, һәм аны шул ук көнне асып үтерәләр. Беренче корбан пәйда була, кан коела, һәм бу хәл фетнәчеләргә чигенү юлын бикли. Кич белән Пугачев Җаек шәһәрчегенә юнәлә. Аңа каршы кораллы отряд җибәрелсә дә, андагы казакларның яртысы «падишаһ» ягына чыга. Кул астында бер мең сугышчысы булган полковник Симонов шәһәргә кереп бикләнә. Пугачев гаскәрендәге фетнәчеләр саны инде 500 ләп исәпләнә, тик аларның туплар белән коралланган шәһәрне штурмларга куәте җитми. Шәһәрне урап үтеп, Пугачев Оренбургка юнәлә. Аңа кадәр юлда 2 шәһәрчек, 4 крепость, 9 форпост ятса да, Пугачев бер-бер артлы аларның һәркайсын алуга ирешә. Нижне-Озерск крепостенда ул Бикбау Усманов исемле татар казагын асып үтерә (*А. Пушкин*. «История Пугачева», *Р. Овчинников.* «Над Пугачевскими страницами Пушкина»). Шушы ук крепостьта Пугачев гаскәренә Мостафин, Габдерәшит мулла, Калбый, Алкынов, Әшрәф Мортазин, Туктамышев, Бикинеев кебек татарлар да кушыла *(С. Алишев)*. Р. Овчинников китабында  тагын Бикмурат Ниязов атлы татар казагының да шушы крепостьта Пугачев гаскәренә кушылуы хакында әйтелә (соңыннан Ниязов Җаек шәһәрчегенең Яшерен комиссиясендә җәзалана). Җаек шәһәрчегеннән качып, Пугачевка кушылган Муханай Сәфәров белән Хәлил мулла Идеркәй Мәхмүтов төзегән указларны күчереп язучыга әйләнәләр.

30 сентябрь көнне Пугачев инде Оренбургтан 28 чакрымда урнашкан Чернореченск крепостен яулап ала. Шушында «падишаһ» каршына Каргалы татарлары юллаган махсус делегация килә, һәм алар Пугачевны кунакка чакыралар.

Каргалыда да Җаек буендагы гаҗәеп хәлләр турында күптән хәбәрдар булалар. Оренбург губернаторы генерал И. Рейнсдорп әмере буенча Каргалының 300 татары Әхмәр Әбләзов дигән старшина җитәкчелегендә Пугачевка каршы җибәрелә. Ләкин Пугачевның Татищево крепосте янында полковник

Елагин һәм бригадир Билов отрядларын тар-мар итүе турында ишетүгә үк, алар туган авылларына борылып кайталар.

Пугачев Каргалыга 1 октябрь көнне килә. Татар халкы «падишаһ»ны мәйданга затлы келәмнәр җәеп, келәм уртасына зур кәнәфи куеп, җиргә тезләнеп каршылый. Бай крестьяннар, сәүдәгәрләр Оренбургка качкан була. Әмма Каргалы бу вакытта инде Оренбургның үзенә караганда да зуррак сала булып исәпләнә. Каргалының үз халкыннан тыш, биредә әле тагын Казан өязеннән килеп, бай сәүдәгәрләргә ялланып эшләүче 500 ләп ир була *(С. Алишев.* «Татары...»*)*. Пугачев килгәч, каргалылар арасыннан 500 дән артык ир фетнәчеләр сафына кушыла. Алар арасында Казан өязенең Тимершык, Олы Кандалы, Балыклы, Ачы, Үр, Ашыт, Кече Тархан, Урта Шөн, Кече Шәле, Каратай, Яңавыл авылларыннан килеп эшләүче татар крестьяннары да була. Каргалыдан сәүдәгәр Муса Алиев дигән старшина әлеге полкның командиры итеп билгеләнә. Шушы ук көнне Каргалы татарлары, «падишаһ» исеменнән махсус мөрәҗәгать һәм указлар язып, ышанычлы кешеләр аша аларны Уфа провинциясендә, Оренбург — Казан юлында яшәгән татар-башкортларга тараталар. Аптыш Тангаев дигән татар казахларның Кече Җүз ханы —Нурали янына ук озатыла. Нурали хан «падишаһ» эмиссарына 200 кешелек отряд биреп җибәрә. (Тангаев соңыннан, 1774 елның июлендә Җаек каласында кисәкләргә чапкалап үтерелә. — «Следствие и суд над Пугачевым»).

2 октябрь көнне Пугачев Сакмар крепостена юнәлә, аннан соң тагын бер мәртәбә Каргалы авылына кайтып килә. 4 октябрь көнне Пугачев, Сакмар елгасын кичеп, Оренбургка юл ала. Аның армиясен бу вакытта 1500 дән артык казак, 300 ләп качкын солдат һәм 600 дән артык татар тәшкил итә («По родному краю»). Пугачев гаскәрендә нибары 20 ләп кенә туп исәпләнә.

Борын төбендә генә шушындый дәһшәтле көч пәйда булудан тәмам куркып калган губернатор Рейнсдорп Оренбург стеналары артына кереп бикләнә. Үзенең кул астында регуляр хезмәттәге 1600 ләп солдат, 500 казак, Каргалыдан килгән 350 татар, болардан тыш тагын 500 ләп кораллы ир, 70 туп булуга да карамастан, Рейнсдорп Пугачев гаскәренә каршы чыгарга батырчылык итми (*Н. Дубровин*. «Пугачев и его сообщники», т.2). Ә 5 октябрьдә инде фетнәчеләр гаскәре Оренбург каласын тулысынча камап ала. 6 октябрь көнне Рейнсдорп, майор Наумовка 1300 кешелек отряд биреп, фетнәчеләр лагерена һөҗүм итеп карый. Ләкин бу бернинди дә нәтиҗәләр бирми. Наумов отряды янә шәһәргә кереп бикләнә. Фетнәчеләр белән шәһәр гарнизоны арасында көндәлек атышлар һәм бәрелешләр башлана. 8, 12 октябрь көнне гарнизон яңа һөҗүмнәр оештыра, әмма һәр очракта хурлыклы рәвештә чигенергә мәҗбүр була.

Ә ул арада Пугачев гаскәре һаман көчәя бара. Октябрь башында фетнәчеләр янына башкорт старшиналары Кинҗә Арысланов һәм Ямансарый Яппаров җитәкчелегендәге башкорт-мишәр отрядлары килеп кушыла. Оренбург тирәсендәге, Агыйдел, Җаек, Сакмар буйларындагы авылларда крестьяннар алпавытларның утарларын туздыра-талый башлый. Һәр тарафтан Пугачев янына вак-вак отрядлар агыла. Фетнәчеләр лагерендагы татарлар саны да арта. Бирдә бистәсенә хәтта Казан өязенең үзеннән качкан татарлар да барып җитә. Яр Чаллы янындагы Ерыклы авылыннан барган бертуган Йосыф, Ибрай һәм Хәлил Сөяргололовлар шул чорда ук Пугачевның ныклы ышанычын казаналар. Төрле яктан килеп кушылган татарлар 500 кешелек яңа бер полкка берләшәләр. Алар белән Абдул исемле Казан татары җитәкчелек итә. Пугачев килгәндә, Оренбург эчендә Рейнсдорп тарафыннан көчләп калдырылган татарлар да, шәһәр стеналары янында бәрелеш булган саен, фетнәчеләр ягына качып чыга башлый. 200 ләп татар октябрь — декабрь дәвамында әнә шул рәвешчә пугачевчы булып китә (*С. Алишев*. «Татары...»).

Кыш иртә килү сәбәпле, көчле салкыннар башлана. Пугачев 18 октябрь көнне үз гаскәре белән Оренбургтан 5 чакрымдагы Бирдә бистәсенә күченсә дә, шәһәрне камалышта тоту тукталмый. Пугачев хәзер бөтен көчен яңа отрядлар туплауга, аларны кораллandыруга сарыф итә. Шул максат белән ул берничә отрядны якын-тирәдәге крепостьларга, заводларга юллый. Пугачев атаманы Соколов-Хлопуша Урал буендагы Воскресенск, Авзяно-Петровск заводларына килүгә үк, Казан губернасындагы Олы Шырдан, Бездна, Чүпрәле, Кәкерле һәм башка авыллардан йөреп эшләүче Әмиров, Ишимов, Мәхмүтов, Сәмиев, Әбдрәзәков, Габдрахманов, Мирсәлимов, Бикмәтов, Бәхтияров, Рәҗәпов кебек дистәләгән татар крестьяннары аның отрядына кушыла.

Болардан тыш, фетнәчеләр гаскәрендә моңа кадәр казак булып хезмәт иткән татарларның да саны арта бара. Гарнизоны һәм халкы тулысынча диярлек татарлардан торган Кызылтау (Красногорск) крепосте әле октябрь башында ук фетнәчеләр ягына күчә. Бу крепостьның язмышы бик гыйбрәтле, шуңа күрә аңа аерым тукталу кирәк.

Пугачев сәркатибе И. Почиталин 4 октябрь көнне Красногорск крепостеның коменданты Б. Улановка, аны «падишаһ» гаскәренә кушылырга өндәп, махсус указ яза. Сакмар казагы В. Дураков икенче көнне кәгазьне, баш өстенә тоткан хәлдә, Улановка илтеп тапшыра. Крепостьтагы казаклар таләп иткәч, Уланов указны кычкырып укырга мәҗбүр була. Казаклар Пугачевны патша итеп таный. Шуның өчен соңыннан Уланов белән Дураковның икесен дә ярты ел буена төрмәдә тоталар, соңгысын камчы белән җәзалыйлар.

Ә хәзергә крепостьта фетнәче казакларның башлыгы булып есаул (йөзбашы) Гомәр Ермаков кала. Әмма фетнәчеләр һичнинди дә тантана кичерергә өлгерми. Җаек буендагы башбаштаклыктан файдаланып, крепостька казах ханының сәрбазлары бәреп керә. Алар казакларның 233 баш атын, 636 сыерын талап алып китәләр. Әхмәт Габдуллов, Сибәй Колымбәтов, Әиткол Ишмәтов, Алчыгол Исәйкин, Кәлимулла Сәетколов, Күкләш Бикташев, Ишкуәт Тимәкәев, Рәфыйк Бикеев кебек казакларның һәркайсы 10—15 аттан, 10—36 сыердан коры кала. Дөрес, бу — аяныч вакыйга, ләкин саннар Рәсәй чигенә качып гомер иткән татар казакларының иркен, мул тормыш белән яшәүләре хакында сөйли.

Ә красногорскилылар күрергә язган михнәт моның белән генә дә төгәлләнми. 9 ноябрь көнне крепостька бригадир Корф җитәкчелегендәге 2450 кешелек патшабикә гаскәре килеп җитә. Екатерина II гә хыянәт иткән казакларны хәзер инде хөкүмәт солдатлары талый. Солдатлар фетнәче казакларның хуҗалыкларыннан аларның исән калган ат һәм сыерларын гына түгел, хәтта мендәренә, кашыгына, стаканына кадәр алып чыга. Крепостьтан барлыгы 2500 сумлык байлык талана. Ул чактагы бәяләрне һәм казак хуҗалыгында булган байлыкны күз алдына китерү өчен есаул Ермаков йортыннан таланган әйберләрне генә санап чыгыйк: 19 сум акча, 1 әр сумлык ике янчык, 2 шәр тәңкәлек 2 сыер, 7 сумлык 1 ат, 75 тиенлек чалгы, 50 тиенлек 1 пар итек, 23 әр тиенлек 7 каз, 4 сумлык ястык, 40 ар тиенлек 5 күлмәк һәм ыштан, 1 тәңкәлек яулык, 3 әр сумлык 2 бишмәт, 1 тәңкәлек чапан, 1 сум 10 тиенлек сабан, шул ук хактагы 1 пар пәрдә, 1 әр тәңкәлек 5 тун, 1 сумлык ияр, 50 тиенлек ук савыты, 25 әр тиенлек 4 стакан, 1 әр тиенлек 30 кашык, 35 әр тиеннән 20 пот бодай оны, 2 сумлык 1 пот май, 30 тиенлек казан, 70 әр тиенлек 7 баш сарык, 40 тиенлек 1 пот тоз һәм башкалар — барлыгы 84 сумлык мал-мөлкәт. Моңа кадәр әле казахларның да шушы хуҗалыктан 19 ат, 16 сыер талап китүен искә алган чакта, есаул Ермаковның тормыш хәле чыннан да сокландыра («Документы ставки Пугачева...»). Өстәвенә, татар есаулы төзегән документ белән ике гасырдан соң танышкан вакытта да милләтебез вәкилләрен аларның укымышлылыгы, зирәклеге, пөхтәлеге өчен тирән хөрмәт белән искә алырга туры килә. Шул ук вакытта крепостьтагы урыс казакларының берешәр-икешәр ат, күп булса 7 баш сыер белән генә яшәп ятуларын күрү гаҗәпләнергә һәм уйланырга да мәҗбүр итә. Шартлар бер үк булган, ә урыс казаклары нигә болай ярлы яшәгән соң?..

Тик красногорскилылар, әлбәттә, ул чагында югалган мал-мөлкәтләре турында кайгырганнар. Гомәр Ермаков, крепостьтагы һәр хуҗалыктан таланган терлекләр һәм зиннәтләр турында исемлек төзеп, «император Петр Федорович» исеменә үтенеч кәгазе дә юллап карый. Әмма, билгеле инде, аларга фәкать Ходай ярдәменә ышанырга һәм үз көчләренә генә таянырга кала. (Шунысын да искәртик: Пугачевның махсус фәрманы белән Гомәр Ермаков һәм Кызылтау татарлары 1774 елның мартында Бирдә лагерена чакыртыла. Алар 22 мартта Татищев крепосте янындагы яуда катнашалар. Гомәр әсирлеккә эләгә, Оренбургта чыбыркы белән суктырыла һәм рядовой дәрәҗәсенә төшерелә...)

Бу хәлләрнең һәммәсе дә читтә булып уза. Ә Пугачев октябрь аенда әле яна-көя үз байрагы тирәсенә һаман гаскәр туплый. Бирдә бистәсендәге йортларга сыймый башлагач, фетнәчеләр, землянкалар казып, шунда да урнашалар. 22, 27 октябрь, 2 ноябрь көннәрендә Пугачев шәһәрне туплардан көчле утка тота. 6 ноябрьдә Пугачев Бирдәдә Хәрби совет һәм Хәрби коллегия оештыра. Моннан соң фетнәчеләр гаскәре белән шулар идарә итәргә тиеш була. Каргалы татары Садыйк Сәетов (Сәгыйтов) һәм башкортларның баш полковнигы Кинҗә Арысланов Хәрби советның тулы хокуклы әгъзалары итеп билгеләнә. «Падишаһның шәхси сәркатибе» Идеркәй Мәхмүтов коллегиядә эшли.

Җаек буенда кузгалган дәһшәтле восстание һәм җиһанда «пәйда булган» яңа «ире» турында Екатерина 14 октябрь көнне генә белеп ала. Зур хафага төшкән патшабикә икенче көнне үк Дәүләт Советын җыя. Казаклар һәм крестьяннар фетнәсен бастыру өчен төрле шәһәрләрдән хәрби командалар җибәрергә әмер бирелә. Барлык хәрби көчләр өстеннән башлык итеп генерал-майор В. Кар билгеләнә. Аның ярдәмчесе итеп әле бер ел элек кенә Җаек казакларының җәллады буларак танылган генерал Ф. Фрейман җибәрелә.

Билгеле инде, Себер, Казан, Оренбург губернаторлары Чичерин, Брандт, Рейнсдорп та үзләренең кул астында булган көчләрне ашыгыч рәвештә шушы төбәккә тупларга керешә. Чичерин Троицк крепостеның коменданты бригадир Фейерварга үз отряды белән Оренбургка юнәлергә боера. Ә Троицкиның үзенә һәм Орск крепостена генерал Деколонг отряды җибәрелә. Брандт Сембер коменданты полковник П. Чернышевны Бозаулык крепостена юллый. Генерал-майор А. Миллерга отставкадагы солдатлардан махсус отряд җыярга һәм губернаны Чирмешән елгасы буйлап сакларга әмер бирелә. Секунд-майор Астафьев йомышлы татарлардан аерым отряд тупларга һәм Бөгелмә янындагы Кичү крепостенда генерал Карны каршыларга тиеш була. Премьер-майор Варнстедтка да, губерна территориясендәге крепостьларның гарнизоннарын җыеп, Бөгелмә каласына килергә кушыла.

Рейнсдорп исә Верхнеозерск дистанциясенең командиры бригадир Корфка ашыгыч рәвештә Оренбургка ярдәмгә килергә боера. Уфа провинциясе башлыкларына, ким дигәндә 5 мең башкорт һәм мишәр җайдакларын җыеп, фетнәчеләргә каршы җибәрергә әмер бирелә. Патшабикә губернаторы әнә шул

рәвешчә Пугачев гаскәрен һәрьяклап капкынга төшерергә җыена, ләкин аларның ниятләре сабын күбеге шикелле шартлый, җимерелә.

Карательләрнең командующие генерал Кар Кичү крепостена 30 октябрьдә килеп төшә. Патша хөкүмәте корган исәп буенча, Астафьев белән Варнстедт Бөгелмәдә 2600 дән артык сугышчы җыеп торырга тиеш була. Ләкин 2 ноябрь көнне Карны бирεдә 1467 генә кораллы ир каршылый. Аларның 740 ы гарнизоннардан җыелган, 631 е хәрби командалардан тупланган солдатлар була. Ә секунд-майор Астафьев Казан провинциясендә нибары 96 гына татарны «падишаһ»ка каршы юнәләчәк отрядка туплауга ирешә (*Н. Дубровин*. «Пугачев и его сообщники», т. 2). Гәрчә Астафьев үзенең кул астына әүвәл 800 ләп татар җайдагын җыйса да, Казаннан Кичүгә таба барган чакта, Акташ авылы янында татарларның күпчелеге качып китә, һәм соңыннан алар Пугачев гаскәренә барып кушыла (*С. Алишев.* «Татары...»).

Шушы 1467 кешелек отряд белән генерал Кар Оренбургка юнәлә. Ул юлда тоташ линия булып яткан Усман, Якуб, Әшир, Ибрай, Нәүрүз, Дүсмәт, Сарманай, Мостафа шикелле татар авыллары аша үтеп китә. Әмма бу авылларда да татарлар карательләргә бөтенләй диярлек кушылмый. Киресенчә, карательләр якынлаша башлагач, авыллардагы ирләр Пугачев лагерена качып китә.

Шушы урында тукталыш ясап, без тагын бер гыйбрәтле очракны яктыртырга телибез. Оренбургта камалышта калган губернатор Рейнсдорп нәкъ шушы көннәрдә генерал Кар белән бәйләнешкә керергә омтылып карый. Шушы максатта Рейнсдорп әле фетнә башланганчы ук, Мостафа авылыннан икмәк сатарга дип килеп, Оренбургта бикләнеп калган татар крестьяны Исхак Әхмәтов ярдәменнән файдаланырга өметләнә. Оренбург губернасындагы казна заводлары башлыгы, коллежский советник И. Тимашев тәкъдиме буенча, губернатор янына шушы татар крестьянын чакыралар. Рейнсдорп Әхмәтов кулына генерал Карга тапшыру өчен 2 пакет бирә. Әхмәтов бу эшне намус белән башкарган очракта аңа ат, олау һәм башка бүләкләр вәгъдә итә. Әмма шәһәр капкасыннан чыгуга ук, Исхак Әхмәтов фетнәчеләргә барып кушыла. Аны Бирдәдәге «падишаһ» йортында Пугачев үзе кабул итә. Пугачев татар крестьянының тугрылыгын югары бәяли. Әхмәтов татарлардан торган Муса Алиев полкына йөзбашы итеп билгеләнә. Генерал Карның Оренбургка якынлашуы турында хәбәр килеп җиткәч, шушы ук Исхак кул астындагы крестьяннар Бөгелмә — Оренбург арасында утырган татар авылларына андагы халыкны фетнәгә кушылырга үгетләү өчен озатыла. Нәтиҗәсе белән без инде танышып уздык: Кар отрядына бу авылларда татар крестьяннары бөтенләй диярлек кушылмый (*С. Алишев.* «Татары...»).

Ә генерал Кар өчен алда Йөзәй авылы күренә. Кар 400 солдат, 92 җайдак биреп секунд-майор Шишкинны шунда җибәрә. Ләкин авылга кереп килгәндә, көтмәгәндә аларга Пугачев атаманнары А. Овчинников, Чика-Зарубин (кушаматы —Чика) җитәкчелегендәге 1000 кешелек казаклар һәм Идеркәй Мәхмүтов кул астындагы 1500 гә якын татарларның отряды һөҗүм итә (*В. Буганов.* «Крестьянские войны...»). Шишкин командасындагы 18 татар җайдагы шундук Зарубин ягына качып чыга. Шулай да, мылтык һәм тупларга каршы тора алмыйча, фетнәчеләр чигенергә мәҗбүр була. 7 ноябрь кичендә Шишкин Йөзәйгә керә. Иртәнге сәгать 4 тә бирегә Кар үзе дә килеп җитә.

8 ноябрь көнне, таң аткач, Йөзәйне янә фетнәчеләр отряды камап ала һәм тәүлек буена Карны бер якка да чыгармый. Шушы көнне төнлә Йөзәй авылына, Карга ярдәмгә, гренадерлар ротасы килергә тиеш була. Бу ротаны үзләренең олаулары белән озатып куярга алынган татарлар гренадерларны, алар йоклап барган көенчә, фетнәчеләр кулына илтеп «тапшыралар».

9 ноябрь  иртәсендә Йөзәй авылын янә 2000 нән артык фетнәче камый. Кар үзенең отряды белән Мостафага таба чигенә башлый. Карны чанада татар крестьяны Салих Ишкинин алып бара. Фетнәчеләр аларны 17 чакрым буена озатып килә, атышлар 8 сәгать дәвам итә. Шушы ук көнне Эстәрлетамак пристаненнан патша офицерлары җыеп алып килгән башкорт һәм мишәрләрнең беренче отряды пугачевчылар сафына кушыла.

Губернатор Рейнсдорпның 9 октябрьдә юллаган әмере буенча, Уфа провинциясенең воеводасы А. Борисов башкорт һәм мишәр вәкилләреннән 5 мең кешелек отряд тупларга һәм аны Пугачев гаскәренә каршы яуга җибәрергә тиеш була. Бу эш воевода ярдәмчесе П. Богдановка, секунд-майорлар Осип (Йосыф) Тәвкилев белән Н. Головка, капитан кенәз  И. Ураковка, мишәр старшиналары Миндәй Тупеев белән Солтанморат Янышевка һәм башкорт старшинасы Галибай Морзаголовка йөкләнә. Ләкин Рейнсдорп таләп иткән 5 мең урынына Эстәрлетамакка 2355 кенә татар-башкорт җайдагы җыела *(И. Гвоздикова)*. Аларның инде бик күбесе әле монда килгәнче үк Оренбург янындагы фетнә турында да ишеткән, «падишаһ» исеменнән язылган указлар белән танышкан була. Шуңа күрә байтак кеше, шул исәптән мишәрләрнең йөзбашы Канзафар Усаев, октябрь ахырында ук фетнәчеләр ягына качып китә.

Эстәрлетамакта тупланган бу отрядлар Биккол авылы янында Бөгелмәдән Оренбургка баручы Кар гаскәренә кушылырга тиеш булсалар да соңга калалар. 10 ноябрь көнне капитан И. Ураков һәм Галибай Морзаголов алып килгән, составында Салават Юлаев та булган 1200 кешелек беренче отряд Биккол

авылына җиткән чакта, Кар инде алардан 50—60 чакрым ераклыкта Мостафадан Сарманайга, аннан соң Дүсмәт авылына таба чигенеп бара. Мишәр, татар, башкорт җайдакларының отряды хәзер инде тулы көенчә Пугачев гаскәренә килеп кушыла. Подпоручик М. Ураков, старшина М. Тупеев җитәкчелегендәге икенче отрядның Сарманай авылы янында Кар гаскәренә ярдәм итәргә мөмкинлеге булса да, мөселман җайдаклары яуга керүдән баш тарта. Бу отряд та 11 ноябрьдә старшина Качкын Самаров кул астында пугачевчылар сафына өстәлә *(И. Гвоздикова)*. Өмете сүнгән, рухы сынган генерал Кар Бөгелмәгә кадәр чигенә.

13 ноябрь көнне фетнәчеләр янә зур җиңүгә ирешә. Пугачевчылар полковник Чернышев җитәкчелегендә Сембердән килгән отрядны бернинди яусыз-нисез диярлек кулга төшерәләр (тарихи хезмәтләрдә Чернышев отрядында булган сугышчыларның саны төрлечә күрсәтелә: Н. Дубровин хезмәтендә — 849, Х. Муратовта — 1000, И. Гвоздикова белән В. Буганов буенча — 1200, А. Пушкин язмасында — 2000, С. Алишев китабында — 2200). Чернышев отрядындагы С. Гаделшин, У. Тимеров, А. Ибраев, Б. Бикмиев, А. Турбыков кебек дистәләгән татарлар Пугачев ягына беренче минутларда ук качып чыга (*С. Алишев*. «Татары...»). Әлеге җиңүдән соң фетнәчеләр тантана итә башлый. Верхнеозерск дистанциясенең командиры бригадир Корф фетнәчеләрнең шушы гамьсезлегеннән файдаланырга өлгерә. Ул, үзенең кул астындагы 2500 солдат белән бергә кичке караңгыда фетнәчеләрнең каравыл постларын узып, Оренбургка керә һәм камалышта ятучы гарнизонга кушыла. Өстәмә көч килү шатлыгы белән рухланган Рейнсдорп, икенче көнне үк шәһәрдән чыгып, Пугачевка һөҗүм итеп карый. Әмма Пугачев, составында нигездә Җаек казаклары һәм татар-башкорт җайдаклары булган 10 мең кешелек гаскәр белән килеп, карательләрне шәһәргә кире куып кертә. 1774 елның апреленә кадәр сузылачак камап тору башлана. Пугачев шәһәрдәге гарнизонны ачлыктан интектереп кулга төшерергә исәпли. Ул хәзер Оренбург тирәсендәге крепостьларны, Урал тавы, Агыйдел, Сакмар, Җаек, Кама буйларына урнашкан заводларны кулга төшерү тактикасына күчә. Ерак төбәкләрдә яшәгән крестьяннарны күмәк восстаниегә күтәрү, фетнә утын һәр тарафка тарату өчен үзенең махсус эмиссарларын юллый. Бәхтияр Канкаев, Канзафар Усаев, Салават Юлаев, Каранай Моратов, Качкын Самаров, Вәлит Торнов, Муса Мостафин, Бакый Абдуллов кебек каһарманнар Красноуфимск, Көнгер, Уфа, Минзәлә, Нагайбәк, Бөгелмә, Сарапул тарафына озатыла. Казан провинциясе андый эмиссарларны көтеп ятмый, ул инде күптән азатлык өчен көрәш мәйданына әверелгән була.

# КАЗАН ПРОВИНЦИЯСЕ

Җаекта башланган восстание турындагы утлы хәбәр Казан губернаторы генерал Брандтка октябрь башында килеп ирешә. Брандт зур шөбһәгә төшә. Чөнки бу вакытта губернада төрле гарнизоннарда торган 3 кенә батальон солдат була. Пугачев Оренбургны камап алгандагы 2500 кешелек гаскәре белән Казанга таба поход башласа, губернада аны тоткарларлык көч булмый.

Ә сәүдәгәрләр һәм олаучылар «падишаһ» турындагы беренче хәбәрләрне губернага 23—25 сентябрьләр тирәсендә үк алып кайта. Пугачев штабында хезмәт иткән сәркатип татарлар, билгеле инде, Идел буендагы туганнарын да онытмыйлар. Тиздән Казан, Бөгелмә тирәсендәге, Чирмешән буендагы авылларда Пугачев указлары пәйда була башлый. Оренбург янындагы Каргалы татарлары Казан төбәгенә махсус сәфирләр дә юллыйлар. Әйтик, бертуган Хисаметдин һәм Хәбибулла Зәйнелгабидиновлар озатыла. Әмма алар тиздән кулга алына һәм 12 декабрьдә сорау алуга дучар ителә («Крестьянская война... на территории Башкирии»).

Җирле администрация вәкилләре кулдан кулга күчеп йөргән, сан ягыннан һаман ишәя барган указларга да, татар халкының рухи күтәренкелек кичерә башлавына да игътибар итмиләр. Аларның төп игътибары-көче Оренбург янындагы фетнәчеләргә каршы җибәрү өчен ашыгыч рәвештә гаскәр туплауга сарыф ителә. Губернатор Брандт үзе 15 октябрь көнне Кичү (Кичуй) крепостена чыгып китә. Казан коменданты полковник А. Лецкий да, каладагы дворяннарны җыеп, Кама елгасы буйлап урнашкан крепостьларның гарнизоннарын ныгыту өчен озатыла. Җирле администрация вәкилләре дә, патшабикә тарафыннан җибәрелгән генераллар Кар белән Фрейман да Оренбург янындагы восстаниене тиз арада бастырырга, фетнә ялкынын башка төбәкләргә үткәрмәскә ниятлиләр. Ләкин, инде әйтеп узганыбызча, Йөзәй һәм Сарманай авыллары янында хурлыклы җиңелүгә дучар булганнан соң, патша генералларының планы чәлпәрәмә килә. Кимсетелгән, туздырылган җәза гаскәрләре Бөгелмә каласына кайтып егыла. Генераллар арасында паника башлана, һәм алар хәвеф тулы бу төбәктән тизрәк качу ягын чамалыйлар. Иң беренче булып, Бөгелмәдән генерал Брандт кача, һәм 16 ноябрь көнне ул инде Казан каласына кайтып җитә. Патша хөкүмәте зур ышаныч баглап озаткан Кар да озак тормый. «Сөякләренең сызлавына түзә алмаганга күрә» гаскәрен 18 ноябрь көнне генерал Фрейман карамагына калдырып, ул да әүвәл Казанга, 23

ноябрьдә инде Мәскәүгә кадәр үк качып китә. Башкомандующийның гаскәрне ташлап качуы Казан губернасындагы барча дворяннарны зур хафага төшерә. Алар Пугачев отрядларының Казанга һөҗүм итүеннән курка башлый. 29 ноябрьгә каршы төндә Казандагы йөзләгән дворяннар һәм сәүдәгәрләр гаиләләрен, берникадәр байлыкларын алып шәһәрдән чыгып качалар. Губернатор Брандт та үз гаиләсен Козьмодемьянск каласына илтеп куя. Казан яртылаш диярлек бушап кала.

Фетнәчеләр яулаган зур җиңү турында һәм генераллар, Казан дворяннары арасында купкан паника хакында крестьяннар әлбәттә ишетеп-белеп тора. Шулай ук алар губернада фетнә кузгатучы отрядларны бастырырлык хәрби көч булмавын да чамалыйлар. Шушындый башбаштаклыктан файдаланып, крестьяннар вак-вак төркемнәргә берләшергә тотына. Төрле төбәкләрдә кабынган фетнә ялкыны тиз арада бөтен Казан губернасын чолгап ала.

### *АРЧА ЮЛЫ*

#### *Мәсәгуть Гомәров*

Фетнәчеләрнең иң зур отряды ноябрь ахырында Казан өязенең Арча юлында оеша. Аны Кукмарадан 7 чакрымдагы Пычак авылында туып үскән һәм байтак еллар буена лашманлыкта газап чиккән 27 яшьлек Мәсәгуть Гомәров җитәкли. Мәсәгуть шул көннәрдә үк Пугачевның урыс һәм татар телләрендә язылган указларын кулга төшерә. Якын-тирәдәге авылларга йөреп, шул указларны халыкка игълан итә. Аның кул астына 200 кеше җыела. Йөзбашы Аккулай Пулатов аның ярдәмчесенә әверелә. Мәсәгуть шул отряд белән Вятка аша чыга һәм Бемыш заводын яулап ала. Биредә Мәсәгуть отрядына бик күп крестьян кушыла, һәм алар 2 декабрьдә инде Пыжман заводын да кулга төшерәләр. Бүгенге Удмуртия территориясендәге Аргабаш, Кизнер, Усады, Кулыга, Куршино кебек дистәләгән авылларның крестьяннары Мәсәгуть отрядының «казаклар»ына әверелә. Мәсәгуть үзе полковник дәрәҗәсен йөртә башлый. Мәсгуть Назыйров, Габдерәшит Бикеев, Әбдеш Уразаев, Иван Андреев, Габдулла Габдерәзәкев кебек йөзбашлары — вак отряд командирлары үсеп чыга. Фетнәчеләр сафына Таиш заводы крестьяннары да кушыла. Өстәвенә, Казан гарнизонында хезмәт итүче татар солдатлары да фетнәчеләр ягына качып чыга. Исмәгыйль Туктамышев, Рәхим Якупов, Рәхимкул Габделкәримов кебек байтак солдатлар декабрь аенда Курса авылы янында крестьяннар сафына кушылалар. Отрядтагы сугышчылар саны 1700 гә җитә. Мәсәгутьнең абруе гаҗәеп үсә һәм декабрь аенда аңа хәзерге Татарстанның Кукмара, Мамадыш, Саба, Арча, Балтач, Питрәч; Киров өлкәсендәге — Вятские Поляны, Малмыж; Удмуртиядәге Кизнер, Бемыш районнарындагы авыллар буйсына башлый.

Казаннан кул сузымында гына дәһшәтле фетнә уты кабынудан тирән хафага төшкән власть вәкилләре Мәсәгуть отрядына каршы декабрь азагында хәрби көч юллыйлар. Капитан Г. Кардашевский гусарлары Арча юлы буйлап хәрәкәт итә һәм хәзерге Балтач районына барып җитә. Кариле авылы янында Кардашевский 38 фетнәчене, шул исәптән Мәсәгуть Гомәровның әтисен, абыйсын һәм хатыны Мәрфуганы әсирлеккә төшерә. Аларны кулга алуда Балтач, Кариле авылының бай татарлары «ярдәм» итә. Кардашевский йөзбашы Мәсгуть Назыйровны шундук асып үтерә, калганнарын зур сак астында Казанга юллый. Әсирлеккә төшкән фетнәчеләрнең эше 24 декабрь көнне Казандагы Яшерен комиссия тарафыннан тикшерелә. Казандагы 3 нче батальонда хезмәт итеп, фетнәчеләр ягына качып киткән солдат Габдерәшит Бикеевны 29 декабрь көнне Арча кырында асып үтерәләр, һәм аның гәүдәсе 2 атна буе дар агачында асылынып тора. Башка әсирләрне халык алдында камчылар белән җәзалыйлар. Әлеге каһарманнар патша җәлладлары тарафыннан җәзага һәм хөкемгә тартылган беренче пугачевчылар була.

Ә Мәсәгуть Гомәровның абыйсын һәм хатынын зинданга ябалар. 70 яшьлек әтисен — Гомәр Әшировны, Мәсәгуть аның янына килмәсме һәм шул чагында аны кулга төшереп булмасмы дип, юри иреккә чыгарып җибәрәләр. Әмма җәлладларның мәкерле нияте тормышка ашмый.

Мәсәгуть гыйнвар аенда үз отрядын хәзерге Кукмара районындагы Камышлы, Пычак, Сазтамак авылларына һәм Мамадыш районындагы Югары Шөн янына туплый. Иске Салавыч авылы крестьяны, Мәсәгуть отрядының йөзбашы Әбдеш Уразаев Арча юлындагы, Балтач тирәсендәге авылларны буйсындырып йөри. Декабрь аенда җәза отрядлары белән бәрелешүгә дә карамастан, Мәсәгуть отряды һаман үсә бара, һәм гыйнвар башында фетнәчеләр саны 3000 кешегә җитә. Мәсәгуть бу вакытта Казанда җитди хәрби көчләр юклыгын төгәл белешеп тора. Шуңа күрә ул үз отряды белән Арчага, аннан соң Казанга һөҗүм итәргә хәзерләнә башлый. Ләкин көтмәгәндә аңа Пугачевның Хәрби коллегиясеннән фәрман килеп төшә. Мәсәгуть үз кул астындагы көчләрнең бер өлешен Минзәлә, Алабуга һәм Уфа янында хәрәкәт иткән фетнәчеләргә ярдәмгә җибәрергә тиеш була. Мәсәгуть үз гаскәреннән 1500 кешелек команда аерып ала да

йөзбашы Гали Гаделев кул астында аларны Минзәлә, ә 250 кешелек икенче отрядны Мөхәй Сәгыйтов җитәкчелегендә Алабугага озата. Әле шуннан соң да Мәсәгуть отрядында 1700 дән артык сугышчы кала.

Гыйнвар башында ук Мәсәгуть үзенең төп көчләре урнашкан Камышлы авылын ныгытылган лагерь рәвешенә китерә башлаган була. Шул максаттан ул авылга алып килә торган юлларда, зур-зур агачларны аударып, тозаклар төзи. Авыл каршындагы ачык мәйданны атлар һәм крестьяннардан таптатып, сугыш кыры хәзерли.

Җәза отрядлары озак көттерми. 4 гыйнвар көнне Казаннан шул ук капитан Г. Кардашевскийның җәза отряды чыга. Алар Чокырчы, Пычак авыллары янында фетнәчеләрне тар-мар итәләр. Камышлы янындагы кырда зур бәрелеш була. Фетнәчеләр карательләрнең туплар белән коралланган регуляр көчләренә каршы тора алмыйлар. Крестьяннар, вак-вак отрядларга бүленеп, төрле якка чигенә. Йөзбашы Аккулай Пулатов Минзәләне камалышта тотучы Каранай Моратов һәм Сәнфин карамагына китә. Мәсәгуть үзе Башкортстанның хәзерге Бакалы районындагы Нагайбәк крепостена чигенә һәм анда Пугачев полковнигы Вәлит Торнов отрядына кушыла. Мәсәгуть гаскәренең старшина Иван Костылев җитәкчелегендәге бер отряды Арчага таба кача. Бу отрядны тиздән Алабуга янындагы фетнәчеләр башлыгы Шәрип Якупов үз карамагына чакыртып ала. Соңыннан алар Хуҗамәт Ишмәтов командалыгындагы отряд составына кертелә. Ә Мәсәгуть Гомәров, үзе әүвәл Пугачев янына барып махсус указ-йөкләмә алырга җыенса да, Вәлит Торнов отрядында яшәп кала. Ул әле байтак вакыт буена Нагайбәк, Эстәрлетамак районнарында сугышып йөри.

***АЛАБУГА***

Казан провинциясендәге икенче зур ялкын Кама буенда, Алабуга тирәсендә кабына. Татар, удмурт, урыс крестьяннарыннан төзелгән вак отрядлар Алабугага беренче мәртәбә әле ноябрь башында ук һөҗүм итеп карыйлар. Уңышка ирешә алмагач, бирегә өстәмә көчләр туплау башлана. Төрле якка чапкыннар озаталар. Отрядлар өстеннән Казан өязенең ясаклы татарлары — йөзбашы һәм атаман Шәрип Якупов, старшиналар Хуҗамәт Ишмәтов (Күзмәт Ишмәнев) һәм Шәфи Тәүфыйков (Туйхуҗин), Пугачев армиясенең йөзбашлары Үтәгән Моратов, Балта Юлдашев, Василий Иванов, Илбакты крестьяны Назар Алексеев җитәкчелек итә. Алабуга янындагы Сарайлы (хәзерге Бехтерево) һәм Танайка авыллары фетнәчеләрнең үзәк лагерена әверелә. Фетнәчеләрнең атаманы Шәрип Якупов Сарайлыда тора. Шәрип Якупов белән Хуҗамәт Ишмәтов, әле монда килгәнче үк, Мамадышның үзен һәм аның тирәсендәге урыс авылларын яулап алган була. Мамадыш һәм Арча өязендәге күп кенә авылларның крестьяннары аларның отрядына кушыла. Декабрь аенда исә фетнә ялкыны Каманың ике як ярындагы дистәләгән авылларга тарала. Чаллы, Тихогорская, Омар волостьларының крестьяннары фетнәчеләр сафына баса. Боровецкое, Чаллы һәм Орловка авылларыннан 100 крестьян есаул Тимофей Григорьев кул астында Алабуга янына килеп җитә. Есаул Федот Николаев җитәкчелегендә Тарловка крестьяннары фетнәгә кушыла. Авзяно-Петровск һәм Ижевск заводларына беркетелгән Олы һәм Кече Шильна авылы крестьяннарын керәшен татары Григорий Артемьев әйдәп йөри *(Х. Муратов)*. Бәтке авылындагы крестьяннарны фетнәчеләр сафына пристаньдагы солдат Үтәгән Моратов алып килә.

Сарайлыдагы лагерьга хәтта ерак Сөн буендагы Байсар, Терпеле, Яхшый авылларыннан да ярдәмче отрядлар килеп җитә («Воззвания...»). Минзәлә өязендәге авыллардан җыелган 600 кешелек отряд, Бәтке пристане янында Кама аша чыгып, әле ноябрь башында ук Алабуга тирәсендәге фетнәчеләр сафын тулыландыра.

Крепость стеналары артында 6 меңнән артык фетнәче туплану, әлбәттә, Алабуга гарнизонын зур хафага төшерә. Крепость янындагы бер басуда гарнизон вәкилләре һәм фетнә отрядларының җитәкчеләре арасында сөйләшүләр дә алып барыла. Фетнәчеләр шәһәр вәкилләренә «император» указларын биреп җибәрәләр. Әмма шәһәр башлыклары, крепостька кайткач, указларны халыктан яшерәләр. Шәһәр яуга хәзерләнә башлый.

Нәкъ шушы ук вакытта фетнәчеләрнең зур бер отряды Минзәлә крепостен да камалышта тота. Бу хәбәр Казанга да барып җитә. Губернатор Брандт Минзәлә гарнизонына ярдәмгә премьер-майор Афанасий Перский җитәкчелегендәге 100 кешелек команда җибәрә. Перский 27 декабрь көнне Алабуга крепостена килеп җитә.

Шуңа да карамастан фетнәчеләр 6 гыйнвар көнне беренче мәртәбә Алабуганы штурмларга ташланалар. Туплар һәм мылтыклар белән коралланган гарнизон аларны кире чигендерә. 10, 13 һәм 19 гыйнвар көннәрендә фетнәчеләр яңадан-яңа һөҗүмнәр оештырып карыйлар («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Ләкин коралсыз һәм таркау крестьян отрядлары бернинди дә уңышка ирешә алмый.

22 гыйнвар көнне шәһәр янына секунд-майор С. Неклюдов җитәкчелегендәге 400 кешелек карательләр отряды килеп җитә. Яу кузгала, әмма ачык кырда крестьяннар җиңелүгә дучар булалар һәм тәртипсез рәвештә чигенә башлыйлар. Гусарлар, беренче булып, Танайка авылындагы лагерьга ташлана. Фетнәчеләр бу авылны инде ташлап качкан була. Ләкин Неклюдов гусарлары һичкемне аралап тормый. Җәлладлар урамда очраган һәркемне кылыч белән тураклый. Алар хәтта чарлакларга, базларга, мунчаларга качкан хатын-кызларны һәм сабый балаларны да чапкалап үтерәләр. Соңыннан крестьяннар мәетләрне авыл артындагы ике чокырга чыгарып күмәләр.

Гусарлар Алабуга тирәсендәге башка авылларга ташлана. 17 авыл талана, шуларның әллә ничәсе нигезенә кадәр яндырып юк ителә. Әсирлеккә төшкән Назар Алексеевны Неклюдов җәлладлары башка крестьяннарның котын алу өчен асып үтерәләр. Фетнәчеләр һәм карательләр арасында бәрелешләр әле тагын Бәтке, Тарловка, Сарайлы, Хлыстовка, Котловка авыллары янында да булып уза. Карательләр Мальково (Мальцево), Яр Чаллы, Орловка авыллары янында 8 меңләп фетнәчене куып тараталар (*С. Алишев*. «Татары...»).

### *ЗӘЙ*

Кама аръягында урнашкан Зәй каласы да ноябрь аенда тоташ фетнә ялкыны уртасында калган утрауны хәтерләтә. «Император»ның тәүге указлары турында ишетүгә үк, крестьяннар алпавытлардан үч ала һәм аларның утарларын талый башлыйлар. Зәй тирәсендә фетнәчеләрнең берничә отряды хәрәкәт итә. Сәвәләй, Иске Елан, Рус Акташы һәм Югары Акташ авыллары янында бүгенге Сарман районындагы Ләшәү-Тамак крестьяны Тимерхан Мостафин отряды хакимлек итә. Әлеге отрядта 400 дән артык фетнәче исәпләнә. Федотово авылы крестьяннарын йөзбашы Бикбау Муллаголов җитәкли. Йөзбашлары Габдулла Токмәтов (Төхбәтов) белән Исмәгыйль Биккулов җитәкләгән отряд Зәйдән 30 чакрымдагы Сухарево авылында урнаша. Зәйдән 6 гына чакрымда урнашкан Аксар авылы крестьяннары Аренкол Асеев отрядына туплана.

Зәй тирәсендәге фетнәчеләрнең активлашуы турында хәбәрне алуга ук, Бөгелмәдә тупланып ятучы карательләрнең башлыгы генерал Фрейман бу төбәккә капитан Евсеев командалыгындагы махсус отряд юллый. 24 декабрь көнне Евсеев солдатлары Александровка авылында тупланган фетнәче крестьяннарны куып тараталар. Кыска гына яудан соң Югары Багряж авылының берничә керәшен татары җәлладлар кулына әсирлеккә эләгә, калганнары качып котыла. Евсеев Зәй каласында бер төн уздыра да 25 декабрь көнне инде камалышта ятучы Минзәлә гарнизонына ярдәмгә чыгып китә. Җәлладлар китүгә, Зәй тирәсендәге фетнәчеләр тагын да активрак хәрәкәт итәргә керешә. Алар Минзәлә каласын камалышта тотучы һәм Нагайбәк крепостенда тупланган зуррак отрядлар белән бәйләнешкә керәләр. Ә Минзәлә һәм Нагайбәк янындагы фетнәчеләр өстеннән Пугачев тарафыннан махсус рәвештә юлланган полковниклар Каранай Моратов белән Вәлит Торнов җитәкчелек итә. Торнов Чалпы авылы (хәзерге Азнакай районында) каһарманы Нагайбәк Әсәновка татар һәм башкорт крестьяннарыннан торган 900 кешелек отряд биреп, Зәй каласын штурмлау өчен озата. Бу отряд та килгәч, Зәй — Сарман тирәсендәге Александровка, Ерыклы, Югары Багряж, Ләке, Бәтке, Әхмәт, Тоба авыллары крестьяннары да фетнәчеләр сафына кушыла. Крестьяннар хәзер инде Зәй каласын тулы камалышка ала. Зәйне саклаучы гарнизон башлыклары Кама елгасы ярында урнашкан крепостьлар белән дә, өяз үзәге Минзәлә белән дә бәйләнешкә керә алмый. Камалышта ятучы кешеләр һәм маллар өчен ризык җитми. Көннәрнең берсендә шәһәр башлыклары 16 кешене кырга, печән алырга дип чыгарсалар да, бу отряд фетнәчеләр кулына төшә. Ул да булмый, калада яшәүче отставкадагы подпрапорщик Богдан Буткевич фетнәчеләр ягына качып чыга да «император» указын алу өчен, Нагайбәк крепостендагы Вәлит Торнов янына юнәлә. Кабат Зәйгә әйләнеп кайтканнан соң, ул инде шәһәр халкын фетнәчеләрне тезләнеп каршыларга, «император»ны танырга үгетли башлый.

Күмәк тырышлык җиңүгә китерә. 15 гыйнвар көнне иртән Зәй каласын 2 меңнән артык фетнәче камап ала. Бу вакытта Зәй каласы ике елга һәм махсус ерым уртасындагы биек тауда урнашкан, тирә-ягы имән стеналар, 6 манара белән ныгытылган мәһабәт крепость булса да, аны саклаучы гарнизон һәм шәһәр кешеләре арасында икеләнү туа, каршылыклар башлана. Крепость коменданты, 70 яшьлек капитан Мертвецов каланы үз ихтыяры буенча «император» кулына тапшырырга карар кыла. Шәһәр капкалары ачыла. Крепостьның рухание Прокофий Андреев фетнәчеләр гаскәрен чаң кагып, ә шәһәр вәкилләре ипи-тоз тотып каршылыйлар, «император»га тугры булырга ант итәләр. Секунд-майор Лопатин, капитаннар Мертвецов белән Савинич фетнәче крестьяннарның башлыкларын комендант йортына чакырып кунак итәләр. Әмма бу рәвешчә хөрмәт күрсәтү дә аларны бәлаләрдән коткарып кала алмый. Старшина Нагайбәк Әсәнов әмере буенча хөкүмәт офицерларының өчесен дә кулга алалар һәм 16 гыйнвар көнне иртән Вәлит Торнов янына озаталар.

Кызганычка каршы, фетнәчеләргә озак вакыт буе тантана итәргә туры килми. Полковник Юрий Бибиков командалыгында Казаннан юлга чыккан 650 кешелек карательләр отряды 13 гыйнварда Сухарево авылы янына килеп җитә. Бибиков бирегә урнашкан А. Токмәтов һәм И. Биккулов отрядын шундук куып тарата һәм Аксар авылына таба кузгала. Аксарда 16 сында карательләрне ясаклы татар Аренкол Асеев җитәкчелегендәге 600 крестьян 4 туптан ут ачып каршылый. Ләкин карательләр туплар белән җавап бирүгә һәм гусарлар һөҗүмгә ташлануга ук, крестьяннар кача башлыйлар. Подполковник Бедряга гусарлары шушы яуда 200 дән артык татарны ачык кырда куып җитеп, кылычлар белән чапкалап үтерә. Шушы ук көнне Ерыклы һәм Тоба авылларында тупланган фетнәчеләр дә җиңелүгә тара. Карательләр һичкемне кызганып тормыйлар. Әсирлеккә төшкән фетнәчеләр асып үтерелә. Качып котылган крестьяннар Зәй крепостеның имән стеналары артына кереп бикләнә. Фетнәчеләр саны хәзер инде 1200 гә генә кала.

Бибиков үзенең отряды белән Зәй янына 17 гыйнвар иртәсендә килеп җитә. Юлда 6 татар авылын яндыра. Зәйдә фетнәчеләр гаскәре белән Нагайбәк Әсәнов җитәкчелек итә. Ул, атлы крестьяннарны алып чыгып, карательләр белән әүвәл ачык кырда яуга керә. Регуляр гаскәр һөҗүменә каршы тора алмыйча, фетнәчеләр янә шәһәр эченә чигенергә мәҗбүр булалар. Нагайбәк Әсәнов әле 15 гыйнвар көнне генә фетнәчеләр кулына төшкән канонирларны туплар артына басарга мәҗбүр итә. Канонирлар, өч тупны крепость эчендәге тау өстенә куеп, шулардан карательләргә ут ачалар. Бибиков та шәһәр читендәге тау өстеннән туплар белән җавап бирә, ләкин бу көтелгән нәтиҗәләргә китерми.

Шуннан соң Бибиков үз отрядын өч колоннага бүлә. Секунд-майор Неклюдов, капитан Плахута, поручик Кошелев җитәкчелегендәге әлеге колонналар шәһәр янындагы, бистәләр арасындагы тирән ерымнар аша хәрәкәт итеп һөҗүмгә ташлана. Карательләр тиздән бистәләргә, аннан соң инде крепость эченә бәреп керә. Шәһәр тышындагы һәм штурм вакытындагы бәрелешләрдә карательләр 300 дән артык крестьянны юк итәләр. Исән калган фетнәчеләр Бәтке тракты буенча Александровка авылына таба чигенә. Аларны куа барып, подполковник Бедряга гусарлары ачык кырда тагын 100 дән артык крестьянны чапкалап үтерә. Бу көнне барлыгы 500 гә якын фетнәче һәлак була. Юрий Бибиков үзенең 17 гыйнвар көнне язган рапортында 22 татар авылын буйсындыруы турында шапырына. Ә Ерыклы, Тоба авыллары тулысынча яндырып юк ителә.

Яудан исән чыккан крестьяннар Кәшер авылына (хәзерге Сарман районында) җыела. Фетнәчеләр атаманы Нагайбәк Әсәнов та 18 гыйнварда шушында килә. Әүвәл Тәкермән авылында, соңыннан Бикбауда торган полковник Каранай Моратовтан фәрман килгәч, Зәй төбәге крестьяннары да шул төбәккә, Бикбау авылына юнәлә.

Зәйгә кергәч, Бибиков фетнәчеләр сафына кушылган шәһәр кешеләреннән үч алу оештыра. 15 гыйнвар көнне корал ташлаган солдатларны строй аша үткәреп җәзалыйлар. «Император»га озын гомер теләгән руханиларны халыкның күз алдында камчылыйлар. Майор Лопатин, капитаннар Мертвецов һәм Савинич, подпрапорщик Буткевич кулга алынып, Казандагы Яшерен комиссия карамагына озатыла. (Соңыннан Лопатин белән Мертвецов хәрби дәрәҗәләреннән һәм дворянлыктан мәхрүм ителә һәм Азов крепостена гомерлек каторгага озатыла. Савинич исә әле хөкем карары чыгарылганчы ук төрмәдә вафат була. — «Документы ставки Е. И. Пугачева...»)

Бибиковка мөмкин кадәр тизрәк барып Минзәләне камалыштан коткарырга әмер бирелсә дә, карательләр полковнигы һаман Зәй каласында тоткарланырга мәҗбүр була. Чөнки аның каршына гафу үтенеп килергә ашыгучылар күренми. Фетнәчеләрнең зур отряды Алабуга каласын камалышта тота. Ваграк отрядлар Поручиково, Никольское, Сәрәпәле, Әхмәт, Урсай кебек авылларга туплана. Бибиков Алабуганы азат итү өчен подполковник Бедряга кул астында 400 кешелек команда юллый. Ә үзе Зәй тирәсендәге авылларны буйсындырып йөри. Бибиков шул чакта патша хөкүмәтенә: «Минем яныма көн саен 4 әр мең крестьян гафу үтенеп килә», — дип, рапортлар юлласа да, билгеле инде, бу үзен каһарман итеп күрсәтергә тырышкан һәм генерал дәрәҗәсе алырга хыялланган полковникның ялган фантазиясе генә була.

Бибиков 26 гыйнвар көнне Зәй каласыннан Минзәләгә юнәлә. Ләкин ике кала арасындагы санаулы гына чакрымнарны да аңа 4 тәүлек буена үтәргә туры килә. Чаллы, Тәкермән һәм башка авыллардагы фетнә отрядларының каршылыгын сындырып, Бибиков Минзәләгә 30 гыйнварда гына барып җитә.

## *МИНЗӘЛӘ*

Минзәлә тирәсендәге авылларда беренче фетнә отрядлары октябрь ахырында ук оеша. Исәнгол, Әхмәт, Сарсаз, Юшады, Үрмәт авылы крестьяннары, яңа «император» турында хәбәр алуга ук, алпавытларның утарларына һөҗүм итә башлыйлар. Исәнгол крестьяннары Кадермәт исемле каһарман отрядына берләшә.

Күп кенә авылларның крестьяннарын Байсак Биктимеров атлы кеше үз отрядына туплап йөри. Сөяргол җитәкчелегендәге бер отряд, Әхмәт авылында татар баен талап, аның әйберләрен үзара бүлешә. Түбән һәм Урта Үрмәт, Иске Каран авылы крестьяннарыннан торган фетнә отряды 10 ноябрьләр тирәсендә оеша, һәм андагы фетнәчеләр саны 150 кешегә җитә. Мәлкен һәм Әсән авылы крестьяннары ясаклы татар Мөхәммәтәмин Әитов отрядына кушыла. Каркын (Каран — ?) һәм Юшады авылларында урнашкан отрядларның һәркайсында 3 әр йөз фетнәче исәпләнә (*С. Алишев*. «Татары...»).

Билгеле инде, данлы-шаулы восстаниедән ул вакытта Минзәлә өязенә кергән Актаныш төбәге дә читтә калмый. Гәрәй, Кыргыз, Сеңгерән волостьларына караган авылларда старшиналар Әтнәгул Тимеров, Мөхәммәтрәхим Йосыпов, Ишкуәт Дәүләтбаев, Мәсгуть Мусакаев, Ишки Уразаев, Табыш Габдуллин, Үрәтгол Тәвкилев, Габдулла Агафеев, Сабир Якупов, Сәет Давытов җитәкләгән отрядлар оеша. Такталачык, Куян, Тыңламас, Чишмә, Пучы, Әнәк, Балтач, Суыксу, Адай, Байсар авылларының һәркайсыннан 30—115 крестьян фетнәчеләр сафына кушыла. Актаныш төбәгендә оешкан әлеге отрядларның зур күпчелеге Минзәлә, Алабуга, Зәй тирәсендә хәрәкәт иткән фетнәчеләргә иярә *(С. Хәйретдинов, И. Сирматов)*.

Кама буенда фетнә кузгатуга Пугачев шәхсән үзе дә зур игътибар бирә. Минзәлә өязендәге фетнәчеләр өстеннән җитәкчелек итү өчен бу төбәккә ул үзенең шәхси эмиссарын — Уфа провинциясендәге Бөрҗән волостеның йөзбашы, полковник Каранай Моратовны озата. Каранай килеп төшүгә, вак отрядлар Минзәлә янына туплана һәм каланы тиз арада камалышка ала. Наратлы Кичү авылы крестьяны Сәнфин, Ишбулды (?) авылы вәкиле Ярмөхәммәт Кадермәтов һәм Байлар (Елан) волостеның (хәзерге Минзәлә, Сарман районнары территориясе) Бикмәт авылыннан Балтач Сәетов Каранайның иң ышанычлы ярдәмчеләренә әвереләләр. Минзәлә янындагы фетнәчеләр Пугачев армиясенең икенче төп штабы — Уфа янындагы Чесноковка авылы белән даими бәйләнешкә керәләр. Пугачевның Чесноковкадагы атаманы Чика-Зарубин минзәләлеләр өчен дә башкомандующий булып исәпләнә.

Бу вакытта инде Уфа каласы да тулысынча камалышта яткан була. Зарубин белән Каранай, үзара сүз беркетеп, Уфа һәм Минзәләнең һәркайсына бер үк көнне һөҗүм итәргә карар кылалар. Ул 23 декабрь көненә билгеләнә.

Минзәлә ул вакытта имән стеналар артына яшеренгән ныклы крепость булып исәпләнә. Ләкин шуңа да карамастан Минзәлә воеводасы Можаров, шәһәрне ташлап, Казанга кача (карательләр гаскәренең башкомандующие генерал А. Бибиков 8 гыйнварда аны хәрби трибуналга озата). Кама аръягында җирләрне колонияләштерү сәясәтенең һәм хөкүмәткә каршы чыккан крестьяннарны җәзалау үзәге булганга күрә, татар-башкорт халкы бу каланы аеруча сөйми. 23 декабрьдә бирегә 10 меңгә якын крестьян җыела. Алар, Минзәлә елгасының икенче як ярында урнаштырылган 14 туптан атып, каланы утка тота башлыйлар. Аларга каршы капитан Тихановский батареясы җавап кайтара. Кайнар атышлар көне буе дәвам итә. 25 декабрь көнне фетнәчеләр шәһәрне янә көн буена утка тоталар. 26 декабрьдә күмәк штурмлау башлана.

Көндезге сәгать бердә фетнәчеләрнең 1500 кешелек отряды Панская бистәсе ягыннан шәһәргә һөҗүм итә. Ләкин гарнизон башлыклары, Минзәлә елгасындагы суны җибәреп, фетнәчеләрнең юлларын биклиләр. Ярсыган крестьяннар шәһәрнең икенче ягыннан һөҗүмгә ташлана. Биредә аларны Нагайбәк крепостеннан качып килгән капитан Алексеев җитәкчелегендәге карательләр каршылый. Каты яудан соң фетнәчеләр шәһәр читендәге урамнарга бәреп керәләр. Берничә йорт һәм амбарларга ут каба. Фетнәчеләр 6 карательне юк итәләр. Сугыш кичке караңгыга кадәр дәвам итә. Тик крестьяннар патша гаскәренең тупларына каршы тора алмыйча кире чигенәләр. Шәһәрне саклаучы гарнизон белән инде шактый зур хәрби тәҗрибә туплаган майорлар Ф. Петров, Н. Голов, Я. Ляхович, капитаннар С. Превлацкий, И. Тихановский, Рушинский, Алексеев, дистәгә якын унтер-офицерлар җитәкчелек итә. Сугыш гыйлемен белеп көрәшүче гарнизон 10 мең кешелек фетнә отрядын да чигендерүгә ирешә. Фетнәчеләрнең 3 тубы, 10 крестьян карательләр кулына төшә.

Крестьяннар, шуннан соң Дәвек һәм Маҗын авылларына чигенеп, лагерьлар корып урнашалар. Махсус «илчеләр» килеп, Минзәлә гарнизонынннан «Петр Федорович»ка кушылуларын таләп итәләр. Кайбер көннәрдә шәһәрне 3—4 туп белән генә утка да тоталар. Ләкин күмәк штурмны кабатламыйлар.

Ул арада Минзәлә гарнизонына ярдәмгә Зәйдән капитан Евсеев командасы килеп җитә. Шәһәрдә печән дә, ризыклар да җитми башлый. 12 гыйнвар көнне гарнизон, крепостьтан чыгып, фетнәчеләр лагерена һөҗүм итәргә карар кыла. Алар, бу көнне әүвәл шәһәр стеналары янына килеп, атларда «кәпрәеп» йөргән 300 ләп крестьянны куаклар, чокырлар артына яшеренеп каршылыйлар. Карательләр крестьяннар отрядына ике яктан берьюлы һөҗүм ясыйлар һәм 22 кешене юк итәләр. Чигенә башлаган крестьяннарны капитан Евсеев һәм майор Голов солдатлары куа чыга. Алар Маҗын авылына тупланган крестьяннарны куып тараталар. Шул ук көнне Дәвек авылындагы лагерьга да һөҗүм оештырыла. Ул көнне Дәвектә 500

ләп кенә татар крестьяннары тупланган була. Алар карательләргә каршы җан-фәрман сугышалар. Кайнар бәрелеш вакытында крестьяннар капитан Тихановскийны юк итәләр, капитан Алексеевны авыр яралыйлар. Әмма үзләре дә зур югалтулар кичерәләр. 50 гә якын крестьян карательләр кулына эләгә. Калганнары якын-тирәдәге авылларга качып котыла (*Р. Игнатьев.* «Осада г. Мензелинска...»).

12 гыйнвардагы шушы ачы җиңелүдән соң крестьяннар Тәкермән авылында кабат бергә җыела. Каранай Моратов белән Сәнфин 19 гыйнварда штабларын Бикбау авылына күчерәләр. Ләкин Минзәләне камалышта тоту һич туктамый. Туктаусыз хәрәкәт итеп торган фетнә отрядлары карательләргә юлны биклиләр. Минзәләнең ярсыган гарнизоны, крепостьтан чыгып, әледән-әле фетнәчеләр лагерена һөҗүм оештыра. 20 гыйнвар көнне, мәсәлән, Сарсаз авылы янында зур яу була. Фетнәчеләр 45 кеше һәм 50 ат югалталар. Карательләр коралсыз һәм бөтенләй гөнаһсыз булган кешеләрне дә кызганып тормыйлар. Ул көнне Сарсаздагы 22 ир белән бергә 3 хатын һәм бер кыз да үтерелә. Крестьяннарның үз арасында да хыянәт туып тора. Әйтик, Ишкуәт Дәүләтбаев дигән старшина поход вакытында Сарсаз авылындагы урыс крестьянының өендә тора. Фетнәчеләрнең җиңелүен ишеткәч тә, әлеге урыс Ишкуәткә сәнәк белән кадый. Ишкуәт авыр ялалардан Бикбау авылында дөнья куя («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Ләкин шушындый каршылыкларга да карамастан, фетнәчеләр үч алу теләге белән яна. Минзәләне штурмлау өчен ярдәмгә Кукмара ягындагы Мәсәгуть Гомәров, Кәшер авылындагы Нагайбәк Әсәнов һәм Әгерҗе янындагы Әбҗәлил Сөләйманов отрядлары чакырыла. Әмма бу вакытта инде Кама буена полковник Ю. Бибиков һәм капитан Г. Кардашевский җитәкчелегендәге җәза отрядлары да килеп җитә. Крестьяннар, вак-вак отрядларга берләшеп карательләргә каршы торып карасалар да, билгеле инде, уңышка ирешә алмыйлар. 30 гыйнвар көнне Бибиков отряды Минзәлә каласына керә. Крестьяннарның күпчелеге туган авылларына таралырга мәҗбүр була. Ә бер өлеше, Кама аша чыгып, Пьяный Бор авылында туплана.

31 гыйнвар көнне Бибиков подполковник Бедряга командалыгындагы гусарларны Пьяный Борга юллый. Фетнәчеләрнең 2000 кешелек отряды аларны агачларны егып ясалган тозаклар һәм бүрәнәләрдән хасил койма артына яшеренеп каршылый. Гусарлар бу юлы да, нәкъ Зәйне штурмлагандагы шикелле үк, өч колоннага бүленәләр. Туплардан һәм мылтыклардан атыш 4 сәгать буена дәвам итә. Әмма тиздән гусарлар лагерьга бәреп керә һәм фетнәчеләрне әзәрлекли башлый. Тирән көрт крестьяннарга качарга комачаулый. Гусарлар 400 дән артык фетнәчене чапкалап үтерәләр. Калганнары зур кыенлык белән качып котыла.

Шушындый коточкыч югалтуларга да карамастан, крестьяннарда азатлыкка омтылу дәрте барыбер сүнми. Полковник Бибиков үзенең карательләре белән Нагайбәк крепостена таба юнәлүгә үк, фетнәчеләр янә Минзәлә крепостен камап ала. Каранай Моратов «падишаһ»тан ярдәм сорау өчен Бирдә бистәсенә китеп барса да, крестьяннар таралмый. Февраль —март айларында Минзәлә янындагы отрядлар белән Сәнфин, Кадермәт, Байсак Биктимеров, Ярмөхәммәт Кадермәтов кебек татар каһарманнары җитәкчелек итә.

### *ӘГЕРҖЕ*

Татар халкын милли, сыйнфый, дини изү хөкем сөргән кара заманда да, буйсыну белмичә, 1742—1744, 1764—1767 елларда дәһшәтле восстаниеләргә күтәрелгән Тирсә волосте крестьяннары, әлбәттә инде, ил өстендә Пугачев явының ялкыны кабынгач та читтә калмыйлар. Чукынган татар алпавыты, секунд-майор Осип (Йосыф) Тәвкилев утарлары әле октябрь аенда ук фетнәче крестьяннар кулына төшә. Фетнәчеләр алпавытка һәртөрле салым түләүдән һәм аның утарында эшләүдән баш тарталар. Тәвкилев, үзе Казан губернаторы Брандт тарафыннан әмер алып, Оренбургны камалышта тотучы Пугачев гаскәрләренә каршы татар-башкорт җайдакларын җыйнау өчен Уфага (ул анда 28 октябрьдә барып җитә), аннан соң Эстерлетамак пристанена озатыла. 9—10 ноябрь көннәрендә Йөзәй авылы янында Пугачев армиясе тарафыннан хурлыклы җиңелүгә дучар булганнан соң, генераллар Кар һәм Фрейман белән бергә майор Тәвкилев тә Бөгелмә каласына әйләнеп кайта. Кул астына 400 татар-башкорт җайдагы биреп, Фрейман Тәвкилевне 5 декабрьдә Нагайбәк крепостена тупланган фетнәче крестьяннарны куып тарату өчен җибәрә. Ләкин Бөгелмәдән 25 чакрымдагы Кырым-Сарай һәм Акбаш авыллары (хәзерге Ютазы районында) уртасына җитүгә, Тәвкилев отрядына Пугачев эмиссары Качкын Самаров җитәкчелегендәге 600 татар-башкорт җайдагы һөҗүм итә. Бәрелеш башлануга ук, Тәвкилев отрядындагы җайдакларның күпчелеге Самаров ягына чыгып кушыла. Тәвкилев үз янында калган берничә ярдәмчесе белән бергә Акбаш авылына кереп бикләнә. Ләкин фетнәчеләр алар яшеренгән йортларга ут төртәләр. Тәвкилев тиздән әсирлеккә төшә. Ярсыган крестьяннар еллар буе татар халкын изгән сатлык алпавытны 6 декабрь көнне җәзалап үтерәләр.

Аның кырда ташлап калдырылган мәетен Бәйрәкә байлары, соңыннан үзләренең авылларына алып кайтып, кача-поса гына гүргә иңдерәләр.

Тирсә волосте крестьяннары бу вакыйгалар турында әлегә берни дә белми. 3 декабрь көнне тирсәлеләр авылның гомуми җыенына җыела. Крестьяннар, Минзәлә янындагы фетнә отрядларының башлыгы Каранай Моратов янына вәкил җибәреп, «патша» указын алырга һәм шуның нигезендә «алпавыт изүеннән котылырга» карар бирәләр (бу факт үзе, бер яктан, татарларның кәгазь ярдәмендә азатлык алырга омтылучы беркатлы халык булуын күрсәтсә, икенче яктан, патша хөкүмәте җәзасыннан шул кәгазь ярдәмендә акланырга исәп тоткан шулай ук  беркатлы хәйләкәрлеген дә раслый). Каранай янына барырга тиешле вәкил итеп, Тәвкилев кул астындагы Тоба авылының крепостной крестьяны Әбҗәлил Сөләйманов сайлана. Үз каршына баш иеп килгән Әбҗәлилне Каранай Тирсә волостеның старшинасы итеп билгели. Тирсә волостеннан килгән крестьяннар белән бергә Әбҗәлил Минзәләне камалышта тотуда катнаша. Шулай ук, Нократ волостена барып, крестьяннардан отряд туплап йөри. Ул югында волость белән крестьяннар тарафыннан сайлап куелган ызба җитәкчелек итә. Ызба авыллардагы хәлне контрольдә тота, волостька җәза гаскәрләрен кертмәү өчен махсус отрядлар төзи. Крестьяннар Тәвкилевнең Барҗы-Алексеевск заводын талыйлар, аның кою мичләрен җимереп бетерәләр. Карин бакыр кою заводы да шундый ук язмышка дучар була.

Минзәлә яныннан Әбҗәлил Тирсәгә 60 кешелек отряд белән әйләнеп кайта. Шуннан соң ул, волостьтагы авылларга чыгып, халыкка «падишаһ» указларын, шуның нигезендә крестьяннарның һәртөрле салым түләүләрдән һәм крепостнойлыктан азат булулары хакында игълан итеп йөри.

Билгеле инде, мондый указларны халык хуплап каршылый. Үз азатлыкларын һәм кыерсытылган, гадел «падишаһ»ны яклау өчен крестьяннар отрядларга берләшә. Фетнәчеләрнең саны тиз арада 500 кешегә җитә, һәм Ә. Сөләйманов полковник дәрәҗәсенә лаек була.

Әбҗәлил фетнәчеләр хакимиятен Тирсә волостенда урнаштыру белән генә канәгатьләнми. Ул үзенең отряды белән удмурт җиренә дә юнәлә һәм Сарсак-Омга, Чутри, Подки, Чер- ноул, Воваж Можга, Мултан Туклы, Большие Учи авылларын буйсындырып йөри, аларда Әбҗәлил отрядына янә 40 ар, 80 ешәр крестьян өстәлә.

Тирсә волосте тиздән шушы төбәктәге барча урыс, удмурт, татар авылларының восстание үзәгенә әверелә. Тирсәлеләр Пугачевның Оренбург янындагы Бирдә лагерена һәм Чика-Зарубинның Чесноковкадагы гаскәренә азык-төлек һәм фураж җибәреп торалар. Крестьяннар Кама буендагы барча юлларга даими каравыл постлары куялар. Шундый постлар, мәсәлән, декабрь һәм гыйнвар айларында граф И. Воронцовның Шомбыттагы (хәзерге Балык Бистәсе районында)  аракы заводыннан Көнгергә шәраб илтә баручы дистәләгән олауларны кулга төшерәләр. Балык Бистәсе, Шумково, Трой-Урай, Анатыш авылларыннан Воронцов заводына беркетелгән 100 гә якын крестьян үзләре алып барган аракы мичкәләре белән бергә Чесноковкадагы штабка озатыла. 10—15 гыйнвар көннәрендә алар исән-сау көенчә кабат Балык Бистәсенә кайтарып җибәрелә («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Тирсә волостендагы фетнә ялкыны Казаннан Кама буена җәза отрядлары җибәрелгәч тә сүнми. Ю. Бибиков җәлладлары 31 гыйнварда Пьяный Бор авылы янында 2 мең кешелек отрядны тар-мар итсәләр дә, алар Тирсә волостена аяк басмый. Пугачев Оренбургны камалышта тота, Нагайбәк крепостенда Вәлит Торнов отряды хакимлек итә, Бөгелмә тирәсендә Муса Мостафин, Әит Үрәзмәтов, Гаврила Давыдов, Осип (Йосыф) Енгалычев отрядлары «тузынып» йөри. Патшабикә хөкүмәте һәм генераллар төп көчне әнә шул тарафка — Пугачевка каршы тупларга боера. Шуңа күрә Ю. Бибиков башкисәрләре, Пьяный Бор янындагы җиңүдән соң инде Әбҗәлил отряды белән «вакланып, мәшәкатьләнеп» тормыйча гына, Нагайбәк крепостена таба юнәлә. Пугачев ярдәме һәм Ю. Бибиков «мәрхәмәте» нәтиҗәсендә Тирсә волосте карательләрнең җәзалавыннан «мәхрүм» кала. Волость халкы, ярты ел буена  һичнинди үч алу һәм яу күрмичә, бәхетле гомер кичерә, волость белән крестьяннар сайлап куйган ызба идарә итә.

Волостьта ныклы тәртип хөкем сөрә. Авыллардагы отрядларның  барысы да Әбҗәлил Сөләймановка буйсына. Әбҗәлил волость аша үтеп китүче һәртөрле фетнә отрядларына ярдәм күрсәтә. Еш кына аңа хөкемдар-казый бурычын башкарырга да туры килә. Март аенда, мәсәлән, Чундырь авылы крестьяннары Пугачевны патша дип танымаган Караваев атлы руханины Әбҗәлил каршына бәйләп китерәләр.

Тирсә волостендагы ирекле тормыш, җиңү тантанасы 1774 елның маена кадәр дәвам итә. Кама буендагы әлеге «азатлык утравы», билгеле инде, губерна администрациясен тырнак астына кадалган шырпы сыман әрнетеп тора. Шуңа күрә май аенда тирсәлеләргә каршы  Казаннан поручик Красильников җитәкчелегендәге җәза отряды озатыла. Карательләрнең якынлашуы турындагы хәбәрне алуга, Әбҗәлил волость чикләрен саклау өчен ашыгыч чаралар күрә. Төрле якка чапкыннар юлга чыга. Аккүз, Төрнәле, Балтач авылларының крестьяннары Әбҗәлил отрядына килеп кушыла. Чапкыннар Казан өязенең Арча һәм Җөри юлларыннан да ярдәмгә крестьяннар чакыралар.

Әбҗәлил янына бик күп крестьян ярдәмгә килеп җитә. Ләкин Пугачев полковнигы нибары 200 ләп кешене генә коралландыра ала. Шул көч белән ул поручик Красильников командасына каршы чыга. 11 май көнне Тирсәдән 18 чакрымдагы кырда кайнар яу башлана. Әмма карательләр туплардан ут ачуга ук, крестьяннар чигенергә мәҗбүр була. Әбҗәлил берничә иптәше белән бергә Иж елгасы аръягына кача. Ләкин Красильников отрядына кушылган хыянәтче татарлар, өч көн үткәч, Әбҗәлилне әсирлеккә төшерәләр, аны көрәштәшләре белән бергә Казандагы Яшерен комиссиягә озаталар.

Красильников бер-бер артлы Тирсә, Нәҗәр, Мордвинкино, Чишмә, Балтач, Тоба, Биктау авылларын буйсындыра һәм крестьяннарны җәзага тарта башлый. Красильников җәлладлары коточкыч җәзалауларга да карамастан, крестьяннар Екатерина патшабикәгә тугрылыкка ант бирергә ашыкмыйлар.

6 июнь көнне Казандагы Яшерен комиссия Әбҗәлил Сөләймановны Тирсә авылында, «башкаларның котын алу өчен» асып үтерергә хөкем чыгара. Бу эш секунд-майор Ф. Скрипицын җитәкчелегендәге махсус командага йөкләнә. Пугачев гаскәрләре тарафыннан камалышта ятучы Уса крепостеның гарнизонына ярдәмгә барышлый Скрипицын Тирсә авылында туктала. Татар каһарманының гомере 12—14 июнь тирәсендә дар агачында өзелә. Бик тиздән Пугачев шәхсән үзе Әбҗәлил Сөләйманов өчен вәхшиләрдән аяусыз үч ала.

### *ӘГЕРҖЕ — ИЖЕВСК*

Тирсәлеләр көрәше 1773 елның көзендә үз волостьларында азатлыкка ирешү белән генә тукталып калмый. Тирсәлеләр күрше волостьларда милли һәм дини яктан изелеп яшәүче яки заводларга эшкә йөреп газап чигүче крестьяннарны да милли-азатлык хәрәкәтенә кушарга тырышалар.

Әбҗәлил Сөләйманов отрядыннан тыш, Тирсә волостенда әле декабрь башында ук 800 кешелек тагын бер отряд оеша. Татар, башкорт, удмурт крестьяннарыннан торган әлеге отрядны Тирсә авылының каһарманы, алпавыт Йосыф Тәвкилевнең крепостное Юскәй Кудашев җитәкли. Бу отряд, хәзерге Татарстан җиреннән Удмуртиядәге заводларга йөреп эшләүче крестьяннарны коллык хезмәтеннән азат итү өчен, декабрь аенда махсус походка юнәлә.

1770 елларда Рәсәйдә 180 нән артык тимер һәм бакыр кою заводы исәпләнә. Аларның 84 е Уралда, ике-өч дистәгә якыны Кама елгасы буена урнашкан була *(В. Мавродин)*. Рәсәй территориясенә карап фикер йөрткәндә, заводларның күпчелеге чагыштырмача якын арада урнашканга күрә, алардагы коточкыч шартларда эшләү дә, иң беренче чиратта, Казан губернасы крестьяннарының җилкәсенә төшә. Тимер һәм бакыр коюда тоткарлыклар булмасын өчен, һәр заводка билгеле бер өяз яки волость крестьяннарын беркетәләр. Лаеш, Чистай, Мамадыш, Казан өязләреннән 25 мең ир-ат Кама һәм Агыйдел буйларындагы Ижевск, Воткинск, Авзяно-Петровск, Вознесенск, Рождественск, Таиш, Шилва заводларына беркетелә. Крестьяннарның һәркайсы, туган авылыннан йөзәр чакрым ара үтеп, каторга, зиндан шартларында елына ким дигәндә 17—42 көн эшләргә тиеш була. Юлда үткән һәм һәртөрле штрафларны түләү өчен сарыф ителгән вакытны исәпкә алганда, крестьяннарга ел саен заводларда 77—156 көн газап чигәргә туры килә *(В. Мавродин).*

Ижевск, Воткинск, Рождественск заводларына баручы-кайтучы крестьяннарның юлы һәрчак Тирсә волосте аша үтә. Тирсә крестьяннарының да бик күбесе шул заводларда интегә. Удмуртия чигендә урнашкан әлеге волость вәкилләренә заводлардагы коточкыч хезмәт шартлары да, изелү-гарипләнүләр дә, билгеле инде, яхшы таныш була. Үз төбәкләрендә азат тормыш урнаштыруга ук, алар менә шуңа күрә заводларга каршы юнәләләр дә инде.

Үзләрен коллыктан азат итү өчен Тирсәдән зур отрядның юлга чыгуы турында ишеткәч, Ижевск заводы крестьяннары аларны каршы алырга махсус делегация җибәрә. Делегация Кудашев отрядын Әгерҗе һәм Ижевск арасындагы Юськи авылында ипи-тоз белән каршылый. Кудашев, үз отрядының бер өлешен аерып, Сива волостеның Ильинское авылы крестьяны Андрей Носковны аның командиры итеп билгели һәм Ижевск заводын штурмларга озата.

Шуннан соң Юскәй Кудашев үзе Уфа янындагы Чесноковка лагереның башлыгы Чика-Зарубин белән очрашуга бара. Урыс телен дә, татар телен дә яхшы белүче укымышлы Юскәй анда Пугачевның Бирдәдәге сәркатибе Идеркәй Мәхмүтов тарафыннан 1 декабрьдә язылган «падишаһ» указын урысчага тәрҗемә итә. Чика-Зарубиннан тиешле күрсәтмәләр алгач, Юскәй янә үзенең отряды янына ашыга.

Бу вакытта инде Уса юлы буйлап та Ижевск заводына таба татар халкының тагын бер каһарманы — Пугачев тарафыннан Кама буендагы заводларны алу өчен махсус озатылган эмиссар Бакый Абдуллов отряды да якынлашып килә. 24 декабрь көнне Бакый Рождественск заводын ала. Аннан соң ул Камбарка, Аннинск, Шермеяитск заводларын үз кулына төшерә. Декабрь ахырында Кудашев, Абдуллов, Носков отрядлары бергә кушылалар. 1 гыйнвар көнне фетнәчеләр Ижевск заводын алалар, 9 мең сум акча, күп кенә

мылтык, дары, атлар һәм тупларга ия булалар. Завод башлыкларының конторaларын талыйлар, штраф һәм бурыч кенәгәләрен яндыралар. Кудашев Чесноковкада чагында үзе тәрҗемә иткән «падишаһ» указларын завод эшчеләренә урыс һәм татар телләрендә игълан итә. Соңыннан Абдуллов белән Кудашев завод эшчеләренә үз исемнәреннән «саклау грамоталары» да язып тапшыралар.

Бу көнне заводтагы бик күп крестьяннар фетнәчеләр сафына кушыла. Абдуллов белән Кудашев 170 крестьянны, завод кассасыннан алынган акчаларны, 2 туп һәм атларны Чесноковкага, Чика-Зарубин карамагына озаталар.

Шуннан соң фетнәчеләрнең зур бер отряды Воткинск заводына юнәлә. Андрей Носков җитәкчелегендәге шушы отряд аны 10 гыйнвар көнне алуга да ирешә. Ләкин алар арасында Юскәй Кудашев инде үзе булмый. Чөнки Алабуга, Минзәлә төбәгенә Ю. Бибиков җитәкчелегендәге җәза отрядының якынлашуы турындагы хәбәрне алуга ук, Кудашев Каранай Моратов һәм Сәнфин янына ярдәмгә ашыга. Карательләр биредә аның отрядын да тар-мар итәләр. Кызганычка каршы, Юскәй Кудашев шуннан соң хәбәрсез югала.

Ә аның Тирсә волостенда төзеп, Удмуртия территориясендә калдырган отряды әле байтак вакыт буена Пугачев армиясенә хезмәт итә. Крестьяннар Ижевск заводында туплар коеп, аларны Чика-Зарубин карамагына озатып торалар. Андрей Носков җитәкчелегендәге отряд Уса юлына юнәлә һәм андагы авылларны буйсындырып йөри. Ләкин Ижевск һәм Воткинск заводларының управляющийлары И. Алымов белән А. Клепиков та бу вакытта инде җәза отрядларын туплап өлгерәләр. 25 гыйнвар көнне карательләр Воткинск заводына якынлаша. Носков үзенең отряды белән чигенә башлый. Әмма 29 гыйнвар көнне заводтан 40 чакрымдагы Полозово авылы янында аларны карательләр куып җитә. Крестьяннар отряды җиңелүгә дучар була һәм Сарапулга чигенә. Ә Носков үзе, Юскәй Кудашев шикелле үк, эзсез югала.

***БӨГЕЛМӘ***

Тирә-ягындагы дистәләгән авыллары белән бергә Бөгелмә каласы ул вакытта Оренбург губернасы составына керә. Пугачев восстаниесенең чишмәсе — Җаек шәһәрчегенә иң якын урнашкан нокта буларак, Казан губернасындагы фетнә ялкыны да иң әүвәл шушы Бөгелмә төбәгендә кабына. Пугачев үзенең тәүге манифестын 17 сентябрь көнне игълан иткән булса, «падишаһ Петр Федорович» һәм аның указлары турындагы хәбәр Бөгелмә янындагы авылларга инде 23—25 сентябрьдә үк килеп ишетелә. Без Бөгелмә һәм Оренбург арасында татар авылларыннан төзелгән тоташ коридор булуы турында инде язган идек. Ә татар авыллары үзара һәрчак хәбәрләшеп торган, өстәвенә алар арасында сәүдәгәрләр юлы өзелмәгән. «Яңа патша» хакындагы хәбәрләрне дә Бөгелмә төбәгенә һәм, гомумән, Казан губернасына, иң беренче булып, татар сәүдәгәрләре яки аларның булышчылары алып кайткан.

Крестьяннарның алпавытларга каршы беренче чыгышлары инде октябрь башында ук күзәтелә. Абдул авылы (Түбән Абдул, хәзерге Елховой — Әлмәт районында) крестьяннары шул вакытта ук Пугачев янына үзләренең шәхси вәкилләрен озаталар.

Тимербулат Үрәзмәтов тиздән Пугачев белән очраша. «Падишаһ» аңа кафтанга яраклы ал материя бүләк итә, гаскәр җыярга фәрман биреп җибәрә. Туган төбәгенә әйләнеп кайтуга ук, Тимербулат үзенең абыйсы Әит белән бергә «падишаһ» гаскәренә көчләр туплый башлый. Әитнең улы Габдерәшит тә беренче көннәрдә үк этисенең һәм абыйсының тугрылыклы ярдәмчесе була. Аларның отрядына 200 дән артык крестьян җыела.

Ләкин бик тиздән Әлмәт янындагы Кичү крепосте белән Бөгелмә каласы карательләр лагерена әверелә. Пугачевка каршы юнәлтеләчәк төп көчләрне патша хөкүмәте Бөгелмәдә туплый. Бирегә Брандт, Кар, Фрейман кебек генераллар килеп җитә. Җәза гаскәрләре кайнап торган үзәктә, билгеле инде, крестьяннар үзләрен тыныч, күндәм тотарга мәҗбүр булалар. Әмма ноябрь башында җәза отрядлары Йөзәй авылы янында хурлыклы җиңелүгә очрый. Кар белән Брандт Казанга кача. Исән калган барлык солдатлары белән бергә генерал Фрейман Бөгелмә каласына кайтып бикләнсә дә, крестьяннар явындагы күмәк күтәрелеш бу төбәк авылларын да урап узмый. Шунысы гаҗәп: борын төпләрендә генә куәтле җәза гаскәре тупланган булуга да карамастан, бу төбәк крестьяннары аеруча зур кыюлык һәм активлык белән азат, гадел тормыш өчен көрәшкә күтәрелә. Биредә инде ноябрь ахырында ук дистәдән артык фетнә отряды барлыкка килә. Алар сафында **15 мең- нән артык крестьян** исәпләнә, тупларның саны да 30 га җитә (*С. Алишев*. «Татары...»).

Бөгелмә төбәгендәге фетнә отрядларын Муса Мостафин, Әит Үрәзмәтов, Осип Енгалычев, Иван Черняев, Гаврила Давыдов, Попов һәм башка каһарманнар җитәкли. Пугачев шәхсән үзе декабрь аенда шушы ук төбәккә, Бөгелмәдән 70 чакрымдагы Нагайбәк крепостена башлык итеп, христиан диненә күчкән

фарсы кешесе Вәлит Торновны да җибәрә. Нагайбәктән 7 чакрымдагы Чалпы авылының старшинасы Габделкәрим Рахманкулов (Нагайбәк Әсәновның авылдашы) Торновның ярдәмчесенә әверелә. Пугачев фикере буенча, Бөгелмә төбәгендә хәрәкәт итүче фетнә отрядларының һәммәсе дә Чесноковкадагы атаман Чика-Зарубинга буйсынырга һәм Оренбургка юнәлүче җәза гаскәрләренең юлын бүләргә, аларга һәртөрле комачаулык тудырырга тиеш була.

Муса Мостафин декабрь башында үзенең кул астына 700 дән артык татар һәм башкорт крестьяннарын туплый. Бөгелмәнең көньягында урнашкан Кандыз, Сәйтәнгол, Дмитриевка, Спас кебек авылларны буйсындырып йөри. Декабрь аенда ул Пугачев белән «танышу» өчен Бирдә бистәсенә бара. 28 декабрь көнне алар күрешәләр. «Падишаһ» исеменнән атаулы указ һәм походный старшина дәрәҗәсе алып, Мостафин кабат үзенең отрядына әйләнеп кайта.

1767 елгы Комиссия депутаты, Зөя өязенең Бикеево (Бәки) авылыннан чыккан ясаклы крестьян, керәшен татары Гаврила Давыдов әле 1773 елның ноябрь аенда ук Богырыслан бистәсендә фетнәчеләр отряды оештыруга ирешә. Аның отряды да Бөгелмәнең көньягында, Муса Мостафин фетнәчеләре белән янәшәдә генә хәрәкәт итә. Отрядларга өстәмә көчләр килгән чакта, алар крестьяннарны үзара бүлешәләр. Татар-башкорт җайдакларын — Муса, ә урыс крестьяннарын Гаврила үз отрядларына туплый. Давыдов отряды хәзерге Оренбург өлкәсендәге Богырыслан бистәсен дә үз кулында тота. Давыдов, Бирдә бистәсенә барып, Пугачев белән күрешә, атаман дәрәҗәсенә лаек була. Богырысланга әйләнеп кайтканнан соң, ул үз отрядындагы крестьяннар санын 500 кешегә җиткерә. 8 февраль көнне ул полковник Хорват җитәкчелегендәге карательләр отрядына каршы сугыша һәм җиңелүгә очрый. Апрель аенда ул инде генерал П. Голицын гаскәренә каршы яуга чыга. Крестьяннар Суровцево авылы янында тәмам җиңелүгә дучар була, Давыдов үзе хыянәтче башкорт старшинасы Кыдрач Муллакаев кулына әсирлеккә төшә. Аны Казан төрмәсенә озаталар. Патшабикә тарафыннан 1767 елда «кагылгысыз кеше» дип игълан ителгән депутат Давыдовны төрмә сакчылары 12 июль көнне, Казанга Пугачев гаскәре бәреп кергәч, камерада чәнчеп үтерәләр (*Г. Голынский*. «Бугурусланский сподвижник Пугачева»/ Под знаменем Пугачева.— Челябинск, 1973).

Крестьян юлбашчыларының күбесен алда әнә шундый аяныч язмыш көтә. Тик отряд башлыкларының күңеле 1773 елның кышында әле чиксез ышаныч белән тулы була, алар үз-үзләрен аямыйча патшабикә җәлладларына каршы көрәшәләр.

Морзалар нәселеннән булган керәшен татары Осип Енгалычев отряды да үзенең көрәш юлын Бөгелмә төбәгеннән башлый. Җаек буенда Пугачев восстаниесе башлану турында ишетүгә үк, Енгалычев Бөгелмәгә юнәлә. Анда ул шәһәр воеводасы Иван Кирьянов белән очраша. Аны «падишаһ» ягына чыгарга өнди башлый. Кирьянов баш тарткач, Енгалычев үз авылына кайтып китә. Тиздән аны Абдул авылы крестьяннары эзләп киләләр һәм фетнәчеләр отрядының башлыгы булырга өндиләр. Енгалычев, шул рәвешчә, крестьяннар юлбашчысына әверелә. Аның отряды Бөгелмәдән алып хәзерге Нурлат районына кадәр юл уза. Чирмешәннән 25 чакрымдагы Калярино авылы Енгалычевның төп лагере булып исәпләнсә дә, аның хакимияте Әлки, Аксубай, Октябрьск, Чирмешән, Лениногорск районнарына һәм хәзерге Самара өлкәсенең төньягындагы дистәләгән авылларга да тарала. Укымышлы Енгалычев һәр авылда крестьяннарга урыс һәм татар телләрендә «падишаһ» указларын игълан итә. Аның гаделлеге турында ишеткән крестьяннар Енгалычевка үзләрен изеп-талап яшәүче алпавыт һәм руханиларны хөкемгә алып киләләр. Ул Биляр-Озеро, Девлезери авылларында руханиларны асып үтерә, отставкадагы капитан Мальковскийны, Сиделькино авылындагы руханины җәзага тарта. Алпавыт һәм руханилардан таланган байлыкны Енгалычев ярлы крестьяннарга өләшә. Бер тапкыр ул үзара очрашкан вакытта Әит Үрәзмәтов отряды крестьяннарына алпавытлардан таланган 10 олау байлыкны бүләк итә. Енгалычев отрядының кыю хәрәкәте Казан өязенең Ногай юлында яшәүче крестьяннарны да көрәшкә күтәрә. Аксубай районындагы Кривоозерск авылы крестьяны Герасим Владимиров, мәсәлән, 1773 елның декабрендә 200 кешелек отряд белән Енгалычев чирүенә килеп кушыла.

Әит Үрәзмәтов җитәкчелегендәге фетнәчеләр отрядының Бөгелмә төбәгендә әле октябрь аенда ук оешкан булуы турында инде әйткән идек. Генерал Кар Йөзәй авылы янында җиңелүгә очрагач, җәза гаскәре тулы көенчә Бөгелмә каласына кайтып бикләнә. Кар качканнан соң, карательләр өстеннән җитәкчелек Фрейманга кала. Тик бу генерал да игътибарга лаек һичнинди җиңүгә ирешә алмый. Якынтирәдә хәрәкәт иткән фетнә отрядлары һәр якка юлны биклиләр. Бөгелмә тулы камалышта кала. Ул да түгел, крестьяннар каладан чыккан вак отрядларга һөҗүм итә башлыйлар. Әит Үрәзмәтов, мәсәлән, секунд-майор Шишкинның Рәҗәп авылыннан (Самара өлкәсендә) Бөгелмәгә юллаган азык-төлек олавына һөҗүм ясый. 40 чана ризык һәм сугыш кирәк-яраклары крестьяннар кулына төшә. Үрәзмәтов олауны озатучы команданы тар-мар итә, офицерын Маклауш авылында (Самара өлкәсендә) асып үтерәләр.

Шуннан соң Үрәзмәтов инде Шишкин җитәкләгән җәза отрядына һөҗүм итәргә карар кыла. Бу вакытта аның отрядында татар, башкорт, удмурт, чуваш крестьяннарын берләштергән 900 дән артык сугышчы исәпләнә. Шушы тирәдә үк хәрәкәт иткән Иван Черняев, Гаврила Давыдов Рәҗәп авылында бикләнгән Шишкин командасына бердәм һөҗүм итү турында сүз куешалар. Башка командирлар сөйләшенгән вакытка килеп җитми. Шуңа да карамастан Үрәзмәтов Рәҗәп авылына һөҗүм башлый. Ул, ике туптан атып, авылны әүвәл утка тота. Аннан соң үзенең сугышчыларын һөҗүмгә ташлый, тик тиешле нәтиҗәләргә ирешми. Давыдов отряды яу кырына бик соңарып кына килеп җитә. Шулай да, Давыдов отряды белән кушылганнан соң, фетнәчеләр саны 3 мең кешедән артып китә. Крестьяннар кичке караңгыга кадәр сугышалар. Җиңүгә өметен югалткан Үрәзмәтов инде төнлә белән кайбер отрядларын туган якларына кайтарып җибәрә. Икенче көнне һөҗүмне кабатлап тормыйлар. Давыдов үз отряды белән Сок-Кармала авылына китә. Үрәзмәтов белән Черняев Баулы районындагы Ташлы авылына чигенә. Әит энесе Тимербулатны һәм үзенең улы Габдерәшитне шушыннан Бирдә бистәсенә, «падишаһ» янына юллый. Рәҗәп авылы янындагы яуда күрсәткән батырлыклары өчен Әит Үрәзмәтовка корпус старшинасы (!) дигән дәрәҗә бирелә. Тимербулат походный старшина дәрәҗәсенә лаек була һәм кабат Ташлыга кайтып китә. Ә Әитнең улы Габдерәшит «падишаһ»ның күңеленә аеруча хуш килә, күрәсең. Ул Габдерәшитне полковник дәрәҗәсе белән зурлый һәм үз янында, Бирдә бистәсендә «хезмәт итәргә» калдыра. Габдерәшит Оренбург янына тупланган татарларның яңа бер полкы белән җитәкчелек итә башлый. Ул тиз арада Пугачевның бик якын, ышанычлы кешесенә әверелә һәм байтак походларда аны озатып йөри («Под знаменем Пугачева»). Ә Ташлы авылындагы Үрәзмәтовлар отрядының кыюлыгы нәтиҗәсендә әле озак вакыт буена Фрейман — Бөгелмәдән, Шишкин Рәҗәп авылыннан чыга алмыйча ята.

Гыйнвар аенда Үрәзмәтов отряды Черняев, Енгалычев, Давыдов, М. Дмитриев, Попов чирүләре белән бергә хәрәкәт итеп, Мәләкәс заводын чолганышка ала, Тиинск, Биляр-Озеро авылларын кулга төшерә, җәза командаларының бер өлешен Чирмешән крепостена бикләп куя. Составында 2 меңнән артык фетнәче, 5 туп булган отряд Подлесный авылы янындагы урманда лагерь төзеп урнаша. 16 гыйнвар көнне Үрәзмәтов Казан губернасындагы хәрби гарнизоннар командиры генерал А. Миллерга кимсетүле хат яза. Ул аны «падишаһ»ның һәм «граф Чернышев»ның (Чика-Зарубинның) «искиткеч зур җиңүгә ирешүләре» белән куркыта, генералны фетнәчеләр ягына чыгарга чакыра. Бу хат шул көнне үк Чирмешән крепостеның коменданты секунд-майор Иван Токаревка, аннан соң генерал Миллер (ул Биләр крепостена бикләнеп ята) белән губернатор Брандтка тапшырыла. Карательләрнең берләштерелгән гаскәре 20 гыйнварда Давыдов, Үрәзмәтов һәм Енгалычевларның берләштерелгән отрядына һөҗүм итә. Крестьяннар җиңелә, Әит Үрәзмәтов, Осип (Йосыф) Енгалычев, Попов әсирлеккә төшә. Аларны Казандагы Яшерен комиссиягә озаталар. Генерал кадәр генералны кимсетеп хат язарга батырчылык кылган Үрәзмәтовны җәлладлар кызганып тормый. Сорау алу вакытындагы аяусыз җәзалауларга түзмичә, Әит 7 февральдә төрмәдә җан бирә.

Яшерен комиссия, хөкем карары чыгарып, Осип Енгалычев белән Поповны Миллер карамагына юллый. Миллер аларны 13 февраль көнне Биләр крепостенда асып үтерә.

### *НАГАЙБӘК*

Татарстан чигендә урнашкан Нагайбәк крепосте ул чорда Уфа провинциясенең Минзәлә өязенә, бүгенге көндә Башкортстанның Бакалы районына керсә дә, крестьяннар явы барышындагы аның ролен һәм әһәмиятен аерым әйтеп үтү кирәк. Чөнки әлеге крепость Татарстанның Кама аръягында ятучы барча районнары өчен дә восстаниенең беренче этабында төп штаб ролен башкара. Отряд башлыклары Бирдә бистәсендәге һәм Уфа янындагы Чесноковка авылына урнашкан лагерьлар белән ныклы элемтәдә торса да, Нагайбәк крепосте крестьяннар өчен иң якындагы терәк тә, авыр чакта ярдәм күтәрдәй ышанычлы үзәк тә була.

Нагайбәк крепостен фетнәчеләр 1773 елның декабрь аенда кулга төшерә. Кораллы крестьяннар Нагайбәкне камап алуга ук, Бөгелмәдә бикләнеп ятучы генерал Фрейман крепость гарнизонына ярдәмгә секунд-майор О. Тәвкилев җитәкчелегендәге 400 кешелек отряд җибәрә. Ләкин бу отрядтагы татар-башкорт җайдакларының зур күпчелеге Акбаш авылы янында фетнәчеләр ягына чыга, Тәвкилевнең үзен кыйнап үтерәләр. Бу хәл Нагайбәктә камалышта ятучы гарнизонга да хәвефле тәэсир ясый. Крепостьның коменданты секунд-майор Рушинский белән капитан Алексеев, Нагайбәкне ташлап, Минзәләгә качалар. Гарнизондагы казаклар Нагайбәк Әсәнов, Габделкәрим Рахманкулов җитәкчелегендәге фетнәчеләргә кушыла. Крепость шулай итеп крестьяннар кулына төшә.

Әлеге җиңү турында ишетүгә үк, 15 декабрь көнне Пугачев крепостька үзенең шәхси эмиссары итеп Вәлит Торновны юллый. Ул вакыт эчендә крестьяннар инде Бакалы крепостен да, Шаран (Архангельск),

Барҗы-Алексеевск заводларын да яулап өлгерәләр. Нагайбәккә килеп төшүгә, Торнов бөтен Бөгелмә төбәгендәге һәм Кама буенда хәрәкәт иткән фетнә отрядларының юлбашчысына әверелә. Ул Пугачевның Минзәләдәге эмиссары Каранай Моратов белән даими элемтәдә тора. Үзе Чесноковкадагы «граф Чернышев» — Чика-Зарубинга буйсына. Сугышчан җитди планнар хәзерләгән чакта, аның янына да барып кайта. Ул киткәндә, крепость белән Чалпы авылы крестьяны Габделкәрим Рахманкулов җитәкчелек итә.

Гыйнвар аенда Торнов Татарстанның көнчыгышында фетнә хәрәкәтен көчәйтү өчен күп көч куя. Шул максат белән ул Нагайбәк Әсәновны, 900 кешелек отряд биреп, Зәй каласын штурмларга озата. Шул рәвешчә, ул Каранай Моратовка да ярдәм итә. Алабуга янында хәрәкәт итүче отряд башлыклары да Торновны үзләренең җитәкчеләре итеп таный. Сәер бер хәл: кул астында меңәрләгән солдат булса да, генерал Фрейман Бөгелмәдән чыгып Нагайбәккә һөҗүм ясарга батырчылык итми.

Кызганычка каршы, Нагайбәк крепостендагы тантана ай ярым чамасы гына дәвам итә. Гыйнвар аенда бер-бер артлы Алабуга, Зәй һәм Минзәлә калаларын фетнәчеләр камалышыннан азат иткәннән соң, полковник Ю. Бибиков солдатлары төп ударны Нагайбәк крепостена юнәлтәләр. Аны саклап калу өчен Торнов Чесноковкадагы Чика-Зарубиннан да өстәмә отрядлар һәм туплар сорап карый. Чика-Зарубин аңа соңарып кына ярдәм җибәрә. Өстәвенә, крепостька Минзәлә янында карательләр тарафыннан тар-мар ителгән фетнә отрядларының башлыгы Каранай Моратов та килеп төшә. Хафага калган ике эмиссар-полковник ярдәм сорау өчен Пугачев янына, Бирдә бистәсенә китеп бара. Крепостьта фетнәче крестьяннар юлбашчысы булып Г. Рахманкулов, Нәдер волостеның старшиналары Ибрай Уразбахтин, Абдулла Ягъфәров, Кукмара янында җиңелеп килгән Мәсәгуть Гомәров торып кала.

Татарстан территориясен фетнәчеләрдән азат итү турында фәрман алган Ю. Бибиков 6 февраль көнне Нагайбәк крепостена килеп җитә һәм аяусыз яудан соң аңа бәреп керә. Крестьяннар Нагайбәктән 38 чакрымдагы Бакалы крепостена чигенәләр. Бибиков аларны эзәрлекләп бара һәм 11 февраль көнне Бакалыны да ала. Яу барышында 400 дән артык фетнәче һәлак була. Карательләрнең төп удары Бирдә бистәсенә юнәлтелгән булу сәбәпле, Бибиков шуннан соң крестьяннарны эзәрлекләүдән туктый һәм Бөгелмәгә китә. Ул китүгә үк 2 меңләп фетнәче Чесноковкадан Чика-Зарубин юллаган полковник Илья Ульянов, бригадир Иван Кузнецов, башкорт старшиналары Кәип Зиямбәтев, Ишкәр Арысланов җитәкчелегендә янә бер йодрык булып туплана һәм 17 февраль көнне Бакалыны кабат үз кулларына төшерә. Ул арада Пугачев яныннан, тиешле күрсәтмәләр алып, Бакалы янына Вәлит Торнов белән Каранай Моратов та кайтып төшә. Алар Нагайбәк крепостеннан 20 чакрымдагы Балыклы күл авылында (Бакалы районында) янә крестьяннарны үз командаларына туплыйлар һәм Нагайбәк крепостен штурмларга юнәләләр. Бибиков Нагайбәктә Алабугадан килгән секунд-майор Перский җитәкчелегендәге бер рота солдат калдырган була. Карательләр ярсыган крестьяннарның һөҗүменә каршы тора алмыйлар. Фетнәчеләр 19 февраль көнне крепостька бәреп керә, Перский үтерелә.

Әмма бу вакытта Бөгелмәдә карательләрнең куәтле, зур гаскәре тупланып өлгерә. 4 февраль көнне бирегә генерал-майор П. Голицын командалыгындагы өстәмә полклар килеп җитә һәм ике ай ярым буена камалышта яткан генерал Фрейман белән кушыла. 20 февральдә аларга Ю. Бибиков отряды өстәлә. 24 февраль көнне Бөгелмәгә генерал-майор А. Ларионов җитәкчелегендә Казан дворяннарыннан төзелгән корпус килеп төшә.

Генерал Голицын февраль башында Нагайбәк һәм Минзәлә янында тупланган фетнәчеләргә каршы Ильин командалыгындагы җәза отряды җибәреп карый. Крестьяннар Ильин отрядын Кырым-Сарай, Акбаш, Сумароково авыллары янында каршылыйлар һәм карательләрне кире Бөгелмәгә чигенергә мәҗбүр итәләр. Зәй белән Бөгелмә арасында да Тимерхан Мостафин җитәкчелегендәге 400 кешелек фетнә отряды карательләрнең вак командаларына каршы сугышып йөри.

Бөгелмәгә карательләрнең тулы бер армиясе тупланганнан соң гына, генерал Ларионов үз корпусы белән Нагайбәккә таба походка кузгала. 27 февраль көнне ул Акбаш авылын ала. Ике арада 60 кына чакрым ятса да, Ларионов 6 март көнне генә Нагайбәк крепостена килеп җитә. Баштанаяк коралланган карательләр корпусына каршы тора алмыйча, Вәлит Торнов, Каранай Моратов, Нагайбәк Әсәнов, Мәсәгуть Гомәров, Кыдрач Муллакаев, Кәип Зиямбәтев, Ишкәр Тарханов (Арысланов) җитәкчелегендәге фетнәчеләр Эстәрлетамакка таба чигенәләр. Карательләр алар артыннан куа чыга һәм 10 март көнне Эстәрлетамакны ала.

12 март көнне Ларионов корпусы Бакалыга килеп җитә. Ульянов отряды карательләрне туплардан ут ачып каршылый. Чарасыз калган карательләр капитан Кожин командалыгында һөҗүмгә ташланалар. Фетнәчеләр Кожинны үтерә, отрядын куып тарата. Аяусыз яу кичке караңгыга кадәр дәвам итә. Карательләр бу төнне ачык кыр өстендә уздырырга мәҗбүр була. Ә 13 март көнне Ульянов, карательләргә каршы торырга бер ядрәсе дә калмаганга күрә, Бакалыны калдырып, Уфага таба чигенә. Яу барышында бригадир Иван Кузнецов һәлак була. Апрель аенда фетнәчеләр арасында тәүге хыянәтчеләр дә күренә

башлый. Башкорт старшинасы Кыдрач Муллакаев Торновны, аның сәркатибе Исмәгыйль Туктамышевны, барлыгы 25 кешене кулга ала һәм 13 апрель көнне Бөгелмә коменданты полковник Кожин кулына илтеп тапшыра. Крестьяннар сугышының беренче этабы Татарстан җирендә шулай тәмамлана.

Ә Бөгелмә төбәгендәге фетнәчеләрнең юлбашчысы Вәлит Торнов һәм аның белән бергә әсирлеккә төшүчеләр Казанга озатыла. Хөкүмәт гаскәрен ташлап 1773 елның 22 декабрендә үк Курса авылы янында фетнәчеләр ягына кушылган Исмәгыйль Туктамышевны Казанның Иске һәм Яңа Татар бистәләре арасындагы кырда дар агачына асып үтерәләр. Торновны 12 июль көнне Казан төрмәсеннән Пугачев азат итә. Торнов Казан янындагы авылларның крестьяннарыннан төзелгән полкның командирына әверелә. Казаннан Царицынга кадәр сугышчан юл үтә. Ул 25 августта Черный Яр янында булган аяусыз яудан соң янә әсирлеккә эләгә. Бу төзәлмәс, башимәс фетнәчене Мәскәүгә алып китәләр. Аны Екатерина тарафыннан төзелгән махсус суд хөкемгә тарта. 1775 елның 10 гыйнварында ул Мәскәүдә Пугачевны җәзалап юк итүләрен карап торганнан соң гына асып үтерелә.

* * *

Без, Пугачев восстаниесендә беренче этапның хәзерге Татарстан җирлегендә барышын сурәтләгәндә, фетнәнең аеруча нык кабынган үзәкләренә һәм зур отрядларның язмышына гына тукталдык. Әлбәттә, Татарстан территориясендәге восстание югарыда саналган төбәкләр һәм отрядлар белән генә чикләнми. Казан губернасында әле тагын Биләр крепосте янында Юлкәй Әиткулов һәм Герасим Иванов җитәкчелегендәге зур отряд хәрәкәт итә. Кыязлы, Ибрай, Үзи, Кораса, Сүнчәләй, Кривоозерки, Мокшино авылларындагы крестьяннардан төзелгән бу отряд Чирмешән крепостен камалышта тота, аннан соң Биләр крепостена юнәлә. Ләкин генерал Миллер аларга каршы поручик Иосиф Владимиров кул астындагы махсус отряд юллый һәм крестьяннарны куып тарата. Бу отряд калдыклары соңыннан Усман Тимеров кул астындагы икенче бер отряд белән кушылалар. Тимеров үзе әле озак вакыт буе Сөлчә һәм Чирмешән елгалары буенда яу кылып йөри. Казан янында, җәза гаскәрләре тупланып яткан үзәк ояның борын төбендә генә хәрәкәт иткән Надыйр Туктаргалин җитәкчелегендәге 600 кешелек отряд губерна администрациясенең котын ала. Ул Шехазда, Аркатово, Страховка һәм башка авылларны буйсындыра. Ә 50 шәр, 100 әр кешедән генә торган фетнә отрядларының саны дистәләрчә була, һәм алар, үз чиратында, алпавыт утарларын талауны дәвам итә, карательләрнең вак төркемнәренә һөҗүм оештыра. Тарихчы С. Алишев хисаплавына караганда, Пугачев явының беренче этабында гына да Казан провинциясендә фетнәче крестьяннарның 70 тән артык отряды карательләргә, хөкүмәт администрациясенә, урыс алпавытларына һәм христиан руханиларына каршы милли-азатлык көрәше алып бара.

Дөрес, гасырлар буе аяусыз изелүдән газап чиккән крестьян отрядларының хәрәкәтен һәр очракта да оешкан, үзара килешү буенча алып барылган яу дип атап булмый. Восстаниенең барышы кайбер төбәкләрдә анархия рәвешен дә ала, бер авыл крестьяннарыннан төзелгән отрядлар кайчакларда икенче авылга барып, үзләре шикелле үк ярлыларны да талап кайткалыйлар. Әйтик, 1773 елның 27 ноябрендә Чирмешән һәм Биләр авылларына калмыклар отряды һөҗүм итә һәм крестьяннардан 300 баштан артык ат, 100 баш чамасы сыер, 800 баш сарык талап китә («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Яки, менә 1774 елның гыйнварында Наратасты, Ямады, Тимәнәк авылы крестьяннары Әбдеш Сөләйманов, Әбделҗәлил Әҗмәтов, Имангол Сабанаев, хәзерге Әлмәт районындагы Ямаш авылына барып Исмәгыйль Тимәнәев исемле крестьян йортын талыйлар. Нагайбәк Әсәнов, 15 кешелек отряд җибәреп, аларны камчылар белән кыйнатырга мәҗбүр була («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Ата улын, ана кызын белми торган шушы мәхшәр чорыннан файдаланып, баеп калырга ашыгучылар да бик аз булмый. Габбас һәм Гомәр Мерәсев дигән агалы-энеле крестьяннар, мәсәлән, Каракачели авылына барып, алпавыт Сумороков йортын талыйлар, аның бер атын суеп ашыйлар, икмәк һәм печәннәрен үзләштерәләр. Икенче бер команда атлары өчен фураж сорап килгәч, шул Мерәсевләр фетнәче туганнарына печән бирүдән дә баш тарталар («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Шулай ук акча, байлык талап йөрүчеләр дә очраштыра. Әйтик, 24 декабрь көнне Рождественск заводын алганнан соң, Бакый Абдуллов бу завод эшчеләрен һәртөрле талаулардан саклау турында махсус грамота биреп китә. Шуңа да карамастан гыйнвар аенда заводка Сәйдәш Даутов һәм Семен Илишев җитәкчелегендәге башкорт отрядлары килә. Алар завод казнасындагы 2017 сум акчаны талап алып китәләр, ә Чесноковкадагы Чика-Зарубин янына баргач, бу сумманың 1500 сумын гына аңа тапшыралар. Зарубин бу эш буенча тикшерү оештырырга мәҗбүр була («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Аннан соң отряд башлыклары арасында да бер-берсен санга сукмау бик еш күзәтелә. Моңа кадәр гади крестьян булып, восстание башлангач, старшина яки йөзбашы итеп билгеләнгән ирләрнең, билгеле инде, горурлыгы арта. Ә восстаниегә кадәр үк түбә яки волость старшинасы булып торган мөхтәрәм кешеләрнең

«сәнәктән көрәк булган» мондый командирларга буйсынасы килми. Инде Пугачевның («падишаһ»ның!) шәхсән үзе тарафыннан отряд башлыгы, полковник яки атаман булып билгеләнгән крестьяннарда минминлек, тәкәбберлек, һавалану хисе бигрәк тә нык сизелә. Минзәләне камалышта тотучы отрядлар башлыгы Каранай Моратов, мәсәлән, Нагайбәктә торучы Вәлит Торновка хәбәр юллаганда үзенең хатын «рапорт» дип тамгалый, аны «баш командир» дип атый һәм «түбәнчелек белән белдерәбез» дигән сүзләр өстәргә дә онытмый. Ә Торнов Чесноковкадагы Чика-Зарубин янына очрашуга киткәч, Нагайбәктә аның урынына башлык булып калган Габделкәрим Рахманкуловка 26 гыйнварда җибәргән хәбәрен Моратов инде «белдерү» дип кенә атый, хәтта «боерам» дигән сүзләр кулланудан да тартынмый. Каранай, кечерәк отряд командирларына боерык юллаганда, үзен бигрәк тә эре тота, хәтта Торновка буйсынып хәрәкәт иткән отрядларны үзенең кул астына чакырудан да читенсенми. Алабуганы камалышта тотучы Шәрип Якупов һәм Зәйдә сугышучы Нагайбәк Әсәнов белән Аренкол Асеев та аңа буйсына. Фетнә гаскәрләренең төп юлбашчылары арасында шушындый башбаштаклык булу нәтиҗәсендә, гадәттә, гади крестьяннар авырлык күрә. Әйтик, Бикмәт авылы крестьяны, фетнәчеләрнең походный старшинасы Балтач Сәетовка бер үк вакытта диярлек Уфаны камалышта тотучы Качкын Самаров та, Минзәлә янындагы Каранай Моратов та отряд алып килүен таләп итеп фәрман юллыйлар. Буйсынмаган очракта аларның һәр икесе «падишаһ» исеменнән җәзага тарту белән яный. Балтач Сәетов, чыннан да, декабрь аенда ук үзенең кул астына отряд туплауга ирешә. Сәетов әүвәл 6 атна буена Минзәлә янында «хезмәт итә», аннан соң Уфа янында шулай ук 6 атна буена сугышып йөри. Сәетов Бикмәт авылында туплаган отрядтан 45 кеше — Зур армия составында (димәк, Бирдәнең үзендә, Оренбург өчен сугышларда), 25 крестьян — Уфа янында, 12 кеше Көнгер өязендә яу кыла. Җитмәсә, март аенда Минзәлә янындагы отрядлар башлыгы булып калган Ярмөхәммәт Кадермәтов та Балтач Сәетовтан үз янына тагын өстәмә сугышчылар таләп итә. Ярмөхәммәтнең әлеге фәрманына инде Качкын Самаров каршы чыга һәм Сәетовка Уфа янында калырга «рөхсәт бирә» («Воззвания...»). Мондый башбаштаклык, һичшиксез, күмәк эшкә зыян китерә. Отряд башлыклары арасында да, милли состав буенча төзелгән отрядлар арасында да үзара каршылыклар туып тора. Каршылыклар отрядларга бердәм йодрык булып тупланырга, күмәк хәрәкәт итәргә комачаулый.

Хәзерге Татарстан территориясендәге авыл һәм кала крестьяннарыннан төзелгән фетнә отрядларына Пугачев явының беренче этабында озак вакытлар буе яу кылып йөрергә ирек булмый. Генерал Кар 18 ноябрьдә Бөгелмәдәге җәза полкларын ташлап качуга ук, зур хафага төшкән патша хөкүмәте Пугачев восстаниесен бастыру өчен ашыгыч чаралар күрергә тотына. 25 ноябрь көнне Екатерина фетнәчеләргә каршы җибәрелгән җәза гаскәренең башкомандующие итеп генерал-аншеф Александр Бибиковны билгели. Ораниенбаум (Санкт-Петербург өлкәсендәге хәзерге Ломоносов), Нарва, Шлиссельбург (хәзерге Петрокрепость) шәһәрләрендәге өч полкка ашыгыч рәвештә Казанга юнәлергә әмер бирелә. Ул чакта Польшада сугышчан походлар алып барган Чугуев казаклар полкына һәм Венгр гусарлар полкына Рәсәйгә кайтырга һәм Мәскәүгә таба хәрәкәт итәргә фәрман җибәрелә. 28 ноябрьдә Екатерина Дәүләт Советын җыя һәм анда да фәкать Пугачев восстаниесенә каршы чаралар турында гына сүз алып барыла. Башкомандующий булып билгеләнгән А. Бибиков үзенә янә өстәмә гаскәр таләп итә. Хәрби коллегия 30 ноябрьдә Кексгольм (хәзерге Приозерск), Дерпт (Тарту) шәһәрләрендә, Могилев губернасында торган карабинер һәм драгун полкларын Казан тарафына күчерү турында фәрман юллый. Башкомандующийга тагын өч генерал — Павел Мансуров, Федор Щербаков һәм Петр Голицын ярдәмчеләр итеп билгеләнә.

А. Бибиков, Петербургтан 9 декабрьдә чыгып китсә дә, Казанга 26 сында гына килеп җитә. Әле юлда чагында ук ул хөкүмәттән үзенә тагын өстәмә полклар, бигрәк тә драгуннар бирелүен таләп итә башлый. Казанга килгәч тә, Бибиков өяздәге бөтен дворяннарны җыеп ала. Озакламый калада дворяннар корпусы төзелә, А. Бибиковның туганы генерал А. Ларионов аның командиры итеп билгеләнә.

Генерал А. Бибиков мәкерле адымнарга барудан да тартынып тормый. Ул Пугачев гаскәренә кушылган мөселман крестьяннарын фетнәдә катнашудан үгетләү өчен уннан артык татар мулласын Кама аръягына һәм Бирдә бистәсенә юллый. Әмма карательләр генералының мондый чарасы бернинди уңышка да китерми. Халкын саткан Җанбәк Якупов, Илкәй Күлмәнәев, Азамат Дүсмәтов, Ибрай Таһиров, Сәгыйть Сәфәров, Вәлишә Солтанов, Уразгилде Туктаров һәм башка муллаларның барысын да фетнәчеләр асып үтерәләр (*С. Алишев.* «Татары...»).

Инде гыйнвар башында ук Казанга җәза полклары туплана башлый. Изюм, Владимир, Архангельск, Томск полклары килә. Генерал Бибиковка буйсынган карательләрнең саны 16 мең кеше исәпләнә. Шуннан соң гына ул полкларга төрле маршрут буенча Оренбургка таба хәрәкәт итәргә әмер бирә. Казан өязендәге, Кама аръягындагы крестьяннарның фетнәсен бастыру өчен, ул үзенең туганы полковник Ю. Бибиков һәм тагын капитан Г. Кардашевский кул астындагы җәза командаларын юллый. Ул командалардагы җәлладларның котырынуын һәм явызлыгын, пугачевчылар арасында иң беренче булып, Казан өязендәге татар крестьяннарына татырга туры килә. Аеруча зур кансызлык белән хәрәкәт итеп, карательләр Кукмара,

Алабуга, Зәй, Минзәлә, Пьяный Бор, Нагайбәк, Бөгелмә, Биләр, Чирмешән янындагы дистәләгән отрядларны куып тараталар. Меңәрләгән крестьяннар үтерелә, дистәләрчә авыллар яндырыла, әллә никадәрле кеше дар агачларында, зинданнарда һәлак була.

Карательләрнең кансызлыгы нәтиҗәсендә гыйнвар ахырында — февраль башларында Татарстан территориясендәге фетнә хәрәкәте бастырыла. Генерал Голицын, 4 февраль көнне Бөгелмәгә җитеп, анда ике ай ярым буена камалышта яткан генерал Фрейман гаскәре белән кушыла. Биләр крепостена бикләнгән генерал Миллерга да азатлык килә. Полковник Хорват камалышта интегүче Чирмешән крепосте тирәсен дә фетнәчеләрдән «арындыра». Пугачев восстаниесенең Татарстан җирендәге беренче этабы фетнәчеләр өчен шундый ачы җиңелүләр белән тәмамлана. Карательләр хәзер инде бөтен көчне Оренбург янындагы Пугачев лагерена һәм Уфаны камалышта тотучы Чика-Зарубин гаскәренә каршы юнәлтәләр. Генерал Бибиков бу айларда патшабикә исеменә күпме генә горурланып, шапырынып рапортлар юлламасын, җәлладларның тантанасы озак дәвам итми. Без шунысын да искәртик: генерал-аншеф А. Бибиков шәхсән үзе дә фетнә кайнап торган Казан провинциясе буйлап хәрәкәт ясарга җөрьәт итми бит. Казанга 26 декабрьдә килеп төшсә дә, әле 8 мартка кадәр ул Кремль стеналары артына ячеренеп ята һәм провинция фетнә отрядларыннан арындырылган шикелле булгач кына, ниһаять, Бөгелмә каласына юнәлә. Җитмәсә, Татарстан да җәлладлар каршында тулысынча тез чүккән территория булмый бит әле. Аның төньяк-көнчыгышында Тирсә волосте крестьяннары тулы азатлык бәхете кичереп яши. Минзәләне исә февраль — март айларында Ярмөхәммәт Кадермәтов һәм Сәнфин отряды камалышта тота. Биләр, Чирмешән тирәсендә Усман Тимеров отряды көрәшә. Арча юлының Измайлово (?) авылы крестьяннары, «падишаһ»ка тугрылык белдерү өчен, Рәхим Әсвиевны Бирдә лагерена, Пугачев янына озаталар. Йөзләргә, дистәләргә бүленгән тагын әллә никадәрле крестьян отрядлары урманнарда ячеренеп йөри. Җәза полклары үткәннән соң, Татарстан җире һәртөрле яулардан тынып калган шикелле тоелса да, бу давыл алдыннан була торган тынлыкны гына хәтерләтә.

# УФА ПРОВИНЦИЯСЕ

Пугачев явы хакында сөйләргә керешкәнче, иң элек әлеге провинция турында берничә сүз.

Оренбург губернасы төзелгәч, 1742 елда Уфа провинциясе шуның составына кертелә. Провинция элеккечә үк 4 өлешкә — Казан, Уса, Себер, Ногай юлларына бүленеп йөри. Бүгенге заман картасыннан ул юлларны Уфа — Казан, Уфа — Уса, Уфа — Екатеринбург, Уфа — Оренбург аралары дип күз алдына китерергә мөмкин.

1773 елда провинция 60 волостьтан тора. Казан юлында — 21, Уса арасында — 3, Себер ягында — 11, Ногай юлында 25 волость исәпләнә (*Ә. Әсфәндияров*, I китап, 6 б.). Ыруглар һәм кабиләләр белән тарханнар идарә итә, аларга батырлар һәм морзалар буйсына. Патша администрациясе тарафыннан алынган ярлыклары булганга күрә, тарханнар һәм аларның гаиләләре, туганнары салым түләмиләр. Ә волостьлар һәм түбәләр белән халык тарафыннан сайланып куелган старшиналар һәм йөзбашлары идарә итә. Тарихчы С. Алишев мәгълүматларына караганда, 1770—1771 елларда Оренбург губернасында (Уфа провинциясе аның бер өлеше генә) 10 976 тархан, 94 962 башкорт (шул сан эчендә күпмедер калмык) һәм ким дигәндә 100 мең чамасы татар ире яши.

Хәзер инде Пугачев явына күчик. Күпмилләтле Уфа провинциясе яу барышында туктаусыз кайнап торган казанны хәтерләтә. Ул Пугачевның шәхсән үзе һәм «падишаһ» армиясенә кушылган фетнәчеләрнең иң актив хәрәкәт иткән төбәкләрнең берсе булып санала. Моны саннар да раслый. Яу барышында Уфа провинциясендә урыс булмаган 86 541 фетнәче катнаша, шуларның 42 меңе башкорт (башкорт катламына язылган крестьяннар), 35 меңнән артыгы татар була. В. Буганов үзенең 1984 елда чыккан хезмәтендә Уфа провинциясендә фетнәгә кушылган мөселман старшиналарының санын да ачыклап китә. Ул провинциядәге 125 мөселман старшинасы арасыннан 77 башкорт, 37 татар вәкиле «падишаһ»ны яклый һәм фәкать 9 башкорт, 3 татар старшинасы гына Пугачевка каршы чыга дип күрсәтә.

Пугачев явына аеруча Казан һәм Ногай юлларында яшәгән крестьяннар күпләп кушыла. Уфа белән Минзәлә арасында яткан волостьларда 21 мең татар һәм 13 мең башкорт «падишаһ казагы» булып китсә, Ногай юлы Пугачев гаскәренә 18 меңнән артык башкорт һәм 6 меңгә якын татар-мишәр сугышчысын бирә («Крестьянская война 1773—1775 гг. на территории Башкирии»).

Оренбург губернасының хакиме генерал И. Рейнсдорп, Уфа өязенең Ногай юлында, Җаек елгасы буенда яшәүче татар һәм башкорт халыкларына атап, 1773 елның 25 сентябрендә үзенең беренче указын яза. Волость старшиналарына һәм йөзбашларына адресланган бу тәүге мөрәҗәгатьне ул **яшерен** рәвештә генә игълан итә. Указда Пугачевның «падишаһ» исемен алуы турында бер сүз дә юк. Чөнки Рейнсдорп бу

вакытта әле  Пугачев отрядын җитди көч дип уйламый, аны бик тиз һәм җиңел генә юк итәргә хыяллана һәм шуңа күрә ул ярдәмгә 500 генә җайдак чакыра. Әмма мишәр старшинасы, почта комиссары Миндәй Тупеев алып килгән әлеге тәүге указда ук инде генерал-губернатор үзенең мәкерле йөзен күрсәтә. Ул Пугачевның башы өчен 500 сум акча вәгъдә итә, татар-башкорт старшиналарына фетнәчеләрдән талап алынган байлыкны үзләштерергә рөхсәт итә.

Ләкин, билгеле булганча, Рейнсдорпның өмете акланмый. 1 октябрьдә үзләренең авылларында Пугачевны «падишаһ» дип кабул иткән Каргалы татарлары Уфа провинциясендә яшәүче татар һәм башкортларны «падишаһ» гаскәренә кушылырга чакырып хат язалар. Әлеге хат та, Оренбург тирәсеннән килгән хәбәрләр дә Уфа провинциясендәге күпмилләтле халыкны аптырашка сала. Гәрчә Рейнсдорпның 25 сентябрьдә язган тәүге указы нигезендә секунд-майор П. Демидов Исет провинциясендә 469 кешелек отряд тупласа да, бу отряд «падишаһ»ка каршы барудан баш тарта һәм Урал тауларына кача («Крестьянская война... на территории Башкирии»). Җайдаклар отряды тупларга дип озатылган «ышанычлы» Миндәй Тупеев та бернинди уңышка ирешми. Ямансарый Яппаров җитәкчелегендәге 300 (кайбер документларда — 400) татар-башкорт җайдагы 8 октябрьдә Пугачев гаскәренә килеп кушыла. «Ышанычлы» М. Тупеев үзе җайдаклар җәзасыннан көч-хәл белән генә качып котыла. 9 октябрьдә инде Пугачев янына Кинҗә Арысланов җитәкчелегендәге 500, кайбер документларда 300 кешелек икенче отряд та килеп кушыла *(Ю. Лимонов, В. Мавродин, В. Панеях)*. «Падишаһ» үзенә тугрылык күрсәткән башкорт старшиналарының тырышлыгын югары бәяли. Кинҗә — башкортларның баш полковнигы, Ямансарый полковник дәрәҗәсен ала.

9 октябрьдә ордер язып, Рейнсдорп Уфа провинциясенең воеводасы А. Борисовтан инде 5000 кешелек башкорт-мишәр отряды туплауны катгый рәвештә таләп итә, ләкин шушы фәрманда да Пугачевның төп җинаяте — үзенә «падишаһ» исеме алуы хакында яшереп калдырыла. Фәкать 16 октябрьдә язган указында гына губернатор, ниһаять, бу хакта белдерә, ләкин Рейнсдорп бу фәрманда да ялганлаудан туктамый: ул Пугачев «каракларын» 1000, аларга кушылган «хыянәтче» башкортларны 300 кеше дип күрсәтә.

Әлбәттә, Пугачев армиясенең юлбашчылары да хөкүмәт чиновниклары арасында туган шөбһә һәм башбаштаклыктан файдаланып калырга ашыгалар. Урал заводларында эшләүче крестьяннарны, Ур (Орь), Җаек, Сакмар елгасы буенда яшәгән казакларны, Уфа провинциясендәге мөселманнарны «падишаһ» гаскәренә кушу өчен көрәш, үгетләү башлана. Мөселманнарга адресланган хатларны моңа кадәр татарлар гына башкарып килсә, 17 октябрьдә инде Кинҗә Арысланов та Ногай юлындагы Кыркулы-Мин волостеның баш старшинасы Галибай Морзаголовка «падишаһ» чирүенә кушылырга чакырып беренче хат яза. 20 октябрьдә Кинҗә, яңа хат язып, Ногай юлындагы татар-башкорт старшиналарын янә «падишаһ»ны танырга өнди. Уфа провинциясендәге мөселманнарны идеологик яктан эшкәртү өчен Рейнсдорп-Брандт администрациясе һәм Пугачев ярдәмчеләре арасында барган көрәшнең нәтиҗәсен алдарак язып узган идек. Галибай Морзаголов һәм Качкын Самаров җитәкләгән 2355 татар-башкорт җайдагы 10 һәм 11 ноябрьдә Биккол, Сарманай авыллары янында Пугачев гаскәре ягына чыга. Тиздән бу ике башкорт юлбашчысы да Пугачев фәрманы буенча кабат Уфа провинциясенә озатыла. Галибай Морзаголов — Ногай юлында, Качкын Самаров  Уфа янында «падишаһ» гаскәре өчен отрядлар тупларга, үзләре барган төбәкләрдә фетнә учагы кабызырга, карательләргә каршы көрәшергә тиеш була.

Дөрес, бу чорда Уфа провинциясендә яшәгән күпмилләтле халык «падишаһ» эмиссарларын гына көтеп ятмый. Минзәлә өязендә кузгалган фетнә турында без инде язып үттек. Уфа өязенең үзәгендә дә фетнә ялкыны озак көттермичә кабына.

### *УФА ӨЯЗЕ. НОГАЙ ҺӘМ КАЗАН ЮЛЛАРЫ*

Уфа каласының тирә-юнендә кузгалган фетнә турындагы тарихи документлар 1773 елның ноябрь ае белән тамгалана. Агыйдел, Чәрмәсән, Дим, Бөре елгалары буйлап утырган авылларда фетнә отрядлары шул айда оеша, һәм Пугачев штабының күрсәтмәсеннән башка да аларның төп удары Уфа каласына юнәлтелә. Уфа янына тупланган фетнәче крестьяннар саны тиз арада бер меңгә җитә. Әмма каланы штурмлау өчен көчләре җитмәү сәбәпле, алар ноябрь аенда ук «падишаһ»ка туп сорап мөрәҗәгать итәләр. Хатка Мәгъсүт Үтәгәнев, Ихсан Баязитов, Гали Хөсәенов, Сөләйман Мостафин, Габделкәрим Мәгъсүтов, Сәлим Мостафин кебек старшиналар, 1767 елгы Уложение комиссиясе депутаты Габделҗәлил Мәгъсүтов, соңыннан Нагайбәк крепосте янындагы яуларда танылып полковник дәрәҗәсен алачак Габделкәрим Рахманкулов кул куя. Г. Рахманкулов документта сәркатип буларак кына искә алынса да, ул күп төрле өстәмә мәгълүмат бирә. Габделкәрим тумышы белән бүгенге Азнакай районының Чалпы авылыннан. Һичшиксез, ул Уфа тирәсенә очраклы рәвештә, берьялгызы гына барып чыкмаган. Димәк, Уфаны штурмлау өчен көчләр шактый ерак аралардан, Минзәлә өязенә кергән татар авылларыннан да тупланган.

Гәрчә Минзәлә үзе татар крестьяннарының ачуын нык китерсә дә һәм ул башка отрядлар тарафыннан ноябрь аенда камалышка алынса да, Ык, Сөн елгалары буенда яшәгән халык Уфаны штурмлауны аеруча мөһим бурыч итеп санаган. Шуңа күрә Минзәлә өязендәгеләр Минзәләне алу өчен кирәк булган көчне, «үз авызларыннан өзеп», Уфа янындагы җитәкчеләр карамагына җибәргәннәр. Хәлнең нәкъ менә шулай булганлыгын без әле алдагы мисалларда да кабатларбыз.

Уфа каласын штурмлау максаты белән Ногай юлыннан да күп отрядлар килә. Губернатор Рейнсдорптан һәм бер үк вакытта Пугачев-«падишаһ» даирәләреннән яуга чакырып хатлар һәм указлар килгән чакта Уфа провинциясендә, шул исәптән Ногай юлында яшәгән халыклар арасында аптырау һәм икеләнү хөкем сөргән булса, 2355 кешелек татар-башкорт гаскәре Пугачев ягына чыкканнан соң, авыл һәм волостьларда фетнә отрядлары оешу күмәк төс ала. Ногай юлында оешкан отрядлар Эстәрлетамак авылы янына җыелалар һәм 19 ноябрьгә каршы төндә аңа бердәм һөҗүм ясыйлар. Эстәрлетамак пристаненда бу вакытта комендант И. Маршилов һәм секунд-майор Голов командалыгында 70 кенә солдат була. Бу көч белән генә фетнәчеләргә каршы тора алмаячакларын аңлап, Маршилов белән Голов 40 чакрымдагы Табын крепостена качалар. Фетнәче крестьяннар, чыннан да, Эстәрлетамакны тиз алалар һәм Екатерина офицерларын куа чыгалар. Котлары очкан Маршилов белән Голов Табын крепостенда да берничә сәгать буена гына тукталып торалар. Бу ике майорга Табын коменданты капитан А. Моисеев та кушыла һәм 19 ы көнне үк алар Уфага качалар («Крестьянская война... на территории Башкирии»).

Хәлләрнең бу рәвештә куерып китүе Уфа коменданты полковник С. Мясоедовны да тирән хафага сала. Ул Мәскәүгә чыгып качкан В. Карны алыштырган генерал Ф. Фрейманнан Уфаны саклау өчен өстәмә көчләр сорый. Әмма фетнәчеләр тарафыннан Бөгелмәгә бикләнгән Фрейман аңа ярдәм итә алмый.

Башкорт, татар, мишәр, урыс, мари, удмурт, чуваш вәкилләреннән торган 1000 нән артык фетнәче 24 ноябрьдә Уфадан 12 чакрымдагы Чесноковка авылына туплана. Шушы көнне үк бирегә Бирдәдән Пугачев тарафыннан походный старшина дәрәҗәсе бирелеп махсус җибәрелгән эмиссар Качкын Самаров та килеп җитә. 26 ноябрьдә фетнәчеләр Уфаны тулысынча камалышка алалар.

Уфада ул вакытта 9 урам була. Сутолока елгачыгы Агыйделгә кушылган җирдә, шәһәр уртасындагы тау башында имән бүрәнәләр белән ныгытылган крепость тора. Шәһәрдә өлкән яшьтәге ике җитәкче — провинциянең воеводасы А. Борисов һәм комендант С. Мясоедовтан тыш майор Пекарский, капитан К. Пастухов, воевода ярдәмчесе П. Богданов, Табын крепостеннан килгән Маршилов, Голов, Моисеев яшәп ята. Камалышта калган дворяннар тиз арада 250 кешелек ополчение төзиләр һәм Пекарскийга буйсыналар. 150 ләп сәүдәгәр һәм һөнәрче шулай ук ополчение төзи, үзләренең башлыгы итеп Ростов шәһәреннән килгән И. Дюковны сайлый. Сафка бастырырдай барлык солдатларны, казакларны, сәүдәгәр, һөнәрче һәм дворяннарны туплагач, шәһәрдә 1000 гә якын (тарихчы Н. Дубровин раславынча, 1650) сугышчы җыела, алар 40 ка якын (икенче төркем документларда — 20) туп белән коралланган була (*Р. Игнатьев.* «Осада г. Уфы...»).

29 ноябрьдә фетнәчеләр Уфа башлыкларына беренче ультиматум юллыйлар һәм шәһәрне «падишаһ» гаскәренә тапшыруны таләп итәләр. Кораллы бәрелешләр булып ала, ләкин Борисов белән Мясоедов баш ияргә уйламый. Шуннан соң фетнәчеләрнең вак-вак отрядлары якын-тирәдәге алпавыт утарларын һәм авылларны таларга ташлана. Башкорт отрядлары — урыс авылларын, урыс крестьяннары мөселман авылларын талый башлый. Шуның аркасында төрле милләтләр арасында каршылыклар туа. Мөселман фетнәчеләренең башлыклары булып торучы Качкын Самаров белән Канбулат Юлдашев, христиан динендәге крестьяннар җитәкчесе, Уфа казагы һәм вак сәүдәгәр Иван Губанов милли каршылыкларны туктата алмыйлар. Уфа янындагы фетнәчеләр арасында туган ызгыш хакында хәбәрләр Бирдә лагерена, «падишаһ»ның шәхсән үзенә барып җитә. Укый-яза да белмәгән, надан Пугачев бу ызгышның нинди куркыныч белән янавын бик тиз аңлап ала һәм ашыгыч рәвештә Уфага үзенең инде яуларда нык сыналган Иван Чика-Зарубин белән аның туганнан туганы Илья Ульяновны озата. Пугачев әмере буенча Зарубин моннан ары «граф Чернышев» (Петербургтагы Хәрби коллегия президенты Захар Чернышев, имеш) дип аталырга тиеш була.

Зарубин Чесноковка лагерена 14 декабрьдә килеп төшә. Бу вакытта Уфаны камалышта тотучы фетнәчеләр сафында 4000 гә якын «казак» исәпләнә. Алар арасында татар, мишәр крестьяннары аз булмый. Уфа янына инде Уса, Ногай, Казан юлларыннан, Бөре, Минзәлә, Көнгер өязе волостьларыннан байтак сугышчылар җыела. Крестьяннарны Уфа янына алып килгән старшиналар декабрь башында һаман да яңа отрядлар туплау эшен дәвам итә. Уса юлының атаманы Нурый Ишәев, походный старшиналар Бабтай (Сәетбаттал) Мөслимов, Габделкәрим Мәгъсүтов, Ихсан Баязитов, мулла Сәлим Мостафин үз төбәкләрендә яшәгән мишәрләрне «падишаһ» гаскәренә туплау өчен 8 декабрьдә эмиссарлар юллыйлар («Воззвания и переписка...»). Ногай юлының Нәдер волостендагы ясаклы татарлар старшинасы Ибрәш (Ибраһим) Уразбахтин, Уфа өязенең татар старшиналары Сәгыйт Сәйтуганов, Мәсәгуть Бикмәмәтов

декабрь аенда сугышчылар, ат һәм корал туплауда активлык күрсәтәләр («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Бикмәт авылыннан килгән татар крестьяны, походный старшина Балтач Сәетов 12 декабрьдә старшиналар К. Самаров, И. Мерәсев һәм К. Юлдашев фәрманы белән Минзәлә өязенең Елан (Байлар) волостена «падишаһ» командаларына сугышчылар туплау өчен озатыла («Воззвания и переписка...»).

*(Балтач Сәетовны төрле тарихчылар төрлечә сурәтли. Имеш, ул элеккеге Бөре өязендәге Бикмәттән (хәзер Чакмагыш районындагы Яңа Бикмәт). Аны «Казан юлының Байлар волостенда яшәгән башкорт» дип тә күрсәтәләр («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Бәхәс кузгатмас өчен, әлегә бер нәрсәне генә искәртик. Бүгенге Сарман районындагы Иске Бикмәт тә, Чакмагыштагы Яңа Бикмәт тә — һәр икесе татар авыллары.)*

Уфаны штурмлау өчен менә шул рәвешле гаскәр туплау башкорт, татар, мишәр старшиналары тарафыннан ноябрь ахырында, декабрь башларында да алып барыла. Ә Чесноковка авылына Зарубин да килеп төшкәч, ул аеруча активлаша. Төрле якка чапкыннар озатыла. Ногай, Себер юлындагы, Урал һәм Кама арасындагы заводлардан күп кенә эшчеләр дә бирегә килә. Уфаны камалышка алган фетнәчеләр саны тиз арада 10 меңгә җитә. Уфа, Көнгер, Минзәлә, Бөре өязләрендәге, хәтта Сарапул янындагы отряд башлыклары да — һәммәсе «граф Чернышевны» үзенең җитәкчесе итеп таный.

Кыскача гына булса да, Бөре (Бирск) төбәгендә кузгалган фетнәчеләр хәрәкәтенә дә кагылып узыйк. Җаек буенда «Петр патша» пәйда булу турындагы хәбәрне алгач та, Бөре яны крестьяннары иң актив хәрәкәт иткән төбәкләрнең берсенә әверелә. Инде 1773 елның ноябрь ахырында ук биредә татар-башкорт крестьяннарыннан торган беренче отрядлар туплана. Алар Подымалово авылына (Уфа районында) барып, андагы урыс крестьяннарын да «падишаһ»ка тугры булырга ант иттерәләр. Шуның янындагы Кызылъяр авылы тиздән фетнәчеләрнең кечкенә бер лагерена әверелә. Отрядлар алпавыт утарларын талый, андагы ат һәм икмәкне бүлешергә тотына. Килеп туган хәвеф Бөредәге казаклар башлыгы вахмистр Мясниковны куркуга сала, ул, һичкемгә рапорт та биреп тормыйча, шәһәрдән чыгып кача. Тиздән аның үрнәгенә Бөре воеводасы премьер-майор Ф. Моисеев та иярә һәм Кама аръягындагы Каракүл авылына качып китә. Ләкин бик тиздән Моисеев һәм Сарапул волостеның идарәчесе Орлов (икенче бер документта Федор Михайлов) фетнәче крестьяннар атаманы А. Вязовой кулына төшә. Вязовой исә аларны Чесноковкага, «граф Чернышев» карамагына алып килә. Чика-Зарубин әмере буенча, фетнәчеләр Моисеев белән Орловны март аенда дарга асалар. Ә Бөре каласы тирәсендә урнашкан авылларда фетнә ялкыны һаман көчәя бара. Әмма провинциядә халыкны талау һәм изеп тотуның төп үзәге Уфа булганга күрә, бөрелеләр дә үз отрядларын Зарубин карамагына озаталар.

23 декабрьдә Уфа каласын штурмлау башлана. Яуда Уфа провинциясенең дүрт юлыннан да башкорт, татар, мишәр, мари, удмурт, чуваш крестьяннары катнаша. Зарубин үзе Ногай юлы яки Чесноковка авылы ягыннан, Агыйдел өстеннән шәһәргә һөҗүм итә. Губанов Себер ягыннан һөҗүм итүче отрядларны җитәкли. Ләкин яу барышында Губанов активлык күрсәтми. Чөнки шәһәр властьлары Губановның Уфада калган хатыны Дарья белән улы Ефимны кулга алган булалар һәм фетнәчеләр калага бәреп кергән очракта аларны асып үтерү белән яныйлар (*Р. Игнатьев* «Осада г. Уфы...»). Иртәнге сәгать 7 дә башланган аяусыз яу кичке 3 кә кадәр дәвам итә. Фетнәчеләр уңышка ирешә алмыйча чигенәләр. Штурм барышында 30 крестьян һәлак була. Шуннан соң Зарубин да, Оренбург янындагы Пугачев кебек үк, Уфаны ачлык белән интектереп алу тактикасына күчә. Кала даими чолганышта тотыла, еш кына вак бәрелешләр булып тора, ачлыкка түзмичә, шәһәрдәге берничә кеше фетнәчеләр ягына чыга. Зарубин һаман гаскәргә өстәмә көчләр туплау белән шөгыльләнә. Ижевск, Воткинск заводларын алган Бакый Абдуллов белән Юскәй Кудашев кебек татар каһарманнары да гыйнвар аенда Зарубинга ярдәмгә завод эшчеләрен озаталар.

Гаскәр туплау өчен туган якларына озатылган отряд башлыклары да гыйнвар аенда кабат Уфа янына җыела. Югарыда без исемен телгә алган походный старшина Балтач Сәетов 15 гыйнварда үзенең өч иптәше белән бергә кабат юлга чыга. («Документы ставки Е. И. Пугачева...» китабында күрсәтелгәнчә, Б. Сәетов 10 гыйнварда Ярмөхәммәт Кадермәтов биргән билет белән Уфага төбәп юлга чыга. Анда: «Б. Сәетов Байлар волостеның походный старшинасы, ул үзенең командасы һәм туп белән бара»,— дип әйтелә.) Аларны Минзәләне камалышта тотучы фетнәчеләрнең вакытлыча башлыгы булып калган Рахманкул Исаев билет биреп озата. Ә Балтачның командасы инде бу вакытта аны Уфа янында көтә. Балтач Уфа янына баргач, үз командасы белән Кызылъяр авылында 6 атна буе тора. Йөзбашы Шамай Мусаилов кабат аның Минзәлә янына кайтуын таләп итсә дә, полковник Качкын Самаров, 11 мартта боерык язып, Б. Сәетовны үз янында калдыра («Воззвания и переписка...»).

Зарубин кул астына тупланган фетнәчеләр саны 12 меңгә җитә, һәм Уфаны алу өчен яңа генераль штурм 25 гыйнварда башлана. Бу көнне дә мылтык, җәя, сәнәк, сөңге белән коралланган крестьяннар һәм завод эшчеләре калага берьюлы 4 яктан һөҗүм итәләр, аяусыз яу иртәнге 8 дән кичке 6 га кадәр сузыла. Ләкин патшабикә офицерлары тарафыннан су сибеп махсус катырылган боз стеналарны яулап алу, имән

крепость эченнән туктаусыз ут яудыручы тупларга каршы коры кул белән бару мөмкин булмый. Шәһәр стеналары янында 200 дән артык мәет калдырып, фетнәчеләр кире чигенәләр. 50 крестьян хөкүмәт солдатлары кулына әсирлеккә эләгә (*Р. Игнатьев*. «Осада г. Уфы...»).

Шуннан соң Зарубин янә Уфаны озак вакытлы камалышта тоту һәм ачлык белән интектереп алу тактикасына күчә. Үзе бер Уфа гына түгел, бәлки Красноуфимск, Уса, Сарапул, Ижевск, Минзәлә, Нагайбәк, Бакалы, Бөре тирәсендә хәрәкәт итүче дистәләгән отрядлар белән җитәкчелек итә. Ул төбәкләрдәге барлык полковник һәм атаманнар да «граф Чернышев»ны үзләренең башкомандующийлары дип саныйлар, аңа берсүзсез буйсыналар.

Ләкин февраль ае Чесноковка лагерена тупланган зарубинлылар өчен дә хәвеф һәм кыенлыклар алып килә. Казаннан полковник Ю. Бибиков командалыгында юлга чыккан карательләр 6 февральдә (Ю. Лимонов, В. Мавродин, В. Панеях хезмәтендә — 8 февральдә) Нагайбәк крепостен, 11 ендә Бакалыны ала. Бу турыда хәбәр килеп җитүгә, Зарубин үзенең туганнан туганы полковник Илья Ульяновны һәм Көнгер яныннан кайтып төшкән атаман Иван Кузнецовны, туплар белән коралланган отряд биреп, карательләргә каршы озата. Ульянов һәм Кузнецов, 2000 кешелек отряд туплап, 17 февральдә — Бакалыны, 19 ында Нагайбәкне кабат үз кулларына төшерәләр *(Н. Дубровин)*.

Кызганычка каршы, Чесноковка лагерена тупланган фетнәчеләргә дә хәвеф-хәтәрсез яшәү өчен санаулы көннәр генә калган була. Февраль ахырында Бөгелмәгә карательләрнең меңәрләгән солдатлы гаскәре җыела. Аларның төп өлеше 28 февральдә генераллар Ф. Фрейман һәм П. Голицын, полковник Ю. Бибиков кебек тәҗрибәле хәрбиләр командалыгында Оренбургка, Пугачев лагерена каршы юнәлә. Карательләрнең икенче өлеше — барлыгы 15 ротага (ә ул вакыттагы артикул-устав буенча бер рота 146 пехота солдатын, 52 егерьне, 65 драгунны һәм тагын 4 тупка хезмәт күрсәтүче солдатларны берләштерергә тиеш була; ләкин бу роталарда, күрәсең, ул кадәрле хәрби булмагандыр) тупланган зур отряд генерал Ларионов җитәкчелегендә Уфага таба хәрәкәт итә. Карательләр 6 мартта — Нагайбәкне, 10 ысында — Эстәрлетамакны, 13 ендә Бакалыны ала. Һәр яу барышында дистәләгән крестьян, ә Бакалы янындагы сугышта — Чесноковкадан Зарубин җибәргән атаман, Уфа — Оренбург арасындагы Табын крепостеның казагы Иван Кузнецов һәлак була. Тиздән үзенең кул астындагы 6 рота солдат белән Бакалыга 1756—1763 елгы Рәсәй-Пруссия сугышларында чыныккан подполковник И. Михельсон да килеп җитә. Моңа кадәр бик акрын, куркак рәвештә хәрәкәт иткән генерал Ларионов үзенең туганы, карательләр армиясенең башкомандующие А. Бибиков тарафыннан читләштерелә, һәм Уфага юнәлтелгән полкларның командиры итеп шушы подполковник — Пруссия сугышларында А. Бибиков полкында яу кылып йөргән Михельсон билгеләнә. Михельсон 18 мартта Бакалыдан чыга һәм, юлында очраган һәртөрле отрядларны тар-мар итеп, Уфага ашыга. Зарубин 20 мартта аңа каршы 4 туп белән коралланган 2000 кешелек отряд юллый. Әмма Михельсон бу отрядны урап уза. Түреш, Кара Якуп, Арово, Кляшево, Третьяковка (Ключи) авыллары (күбесе Чишмә районында) аша үтеп, Чесноковкадан 5 километрдагы Зубовкага якынлаша.

Карательләр отрядының хәрәкәте турында Зарубин, әлбәттә, алдан ук белеп тора. Ул Михельсонны сугышчан хәзерлек белән каршылый, аны тозакка эләктерү өчен хәйлә кора. Зарубин 3000 кешелек отрядны Зубовка авылы каршындагы кырга туплап куя. Чаңгы кигән, атларга меңгән тагын 4000 крестьянны, икегә бүлеп, Зубовкадан Чесноковкага алып килүче юлның як-ягына, вак әрәмәләр артына яшерә. 24 март иртәсендә Михельсон карательләре пәйда булгач, фетнәчеләр аларга берьюлы өч яктан һөҗүм башлый. Канлы яу озын көн буена дәвам итә. Татар һәм башкорт крестьяннары аеруча Зубовка авылында, карательләрнең туплары һәм обозы өчен барган бәрелештә каты сугышалар. Әмма нигездә ук-җәя, сәнәк-сөңге белән коралланган крестьяннар 21 ротаны тәшкил иткән регуляр гаскәргә каршы тора алмыйлар. Карательләр белән канлы бәрелештә 500 дән артык фетнәче һәлак була, 1560 кеше әсирлеккә төшә. *(Уфа галиме Ә. Әсфәндияров үзенең 1993 елда нәшер ителгән «История сел и деревень Башкортостана» дигән китабында әсирләр санын 560 кына дип күрсәтеп ялгыша. Һәм әле шул 560 кешенең дә 540 ын ул Твердышев заводына беркетелгән крестьяннар ди. Ә патшабикә офицеры (советныкы түгел!) И. Михельсон үзенең генерал А. Бибиковка юллаган рапортында төгәл санап күрсәтә: Чесноковка юлында 700 кеше + пугачевчылар ягына чыккан 119 солдат + отставкадагы 106 солдат + 543 завод крестьяны + 93 татар һәм башкорт — «Крестьянская война... на территории Башкирии», док. №67). Хәер, дворян галиме (советныкы түгел!) Н. Дубровин да үз хезмәтендә 1 560 санын куллана. «Советныкы» дигән сүзгә басым ясавыбыз юкка түгел. Лимонов, Мавродин, Панеях, Муратов кебек совет галимнәре, чыннан да, әсирлеккә эләгүчеләр санын урап кына үтәләр, ягъни моның ише «вак-төякне» телгә алып та тормыйлар. Кем белә, бәлки, аларга 1 560 эчендәге 93 саны ошап бетмәгәндер?)* Исән калган фетнәчеләр Уса һәм Бөре ягына, шулай ук Ногай юлына да чигенә. Аларны капитан Г. Кардашевский гусарлары һәм чаңгылы солдатлар Уфадан 30 чакрымдагы Кызылъяр авылына кадәр куа. Михельсон

Чесноковканы алган беренче көндә үк үз кулына әсирлеккә эләккән Сарапул атаманы А. Вязовойны һәм тагын ике крестьянны «гыйбрәт өчен» дарга аса.

Уфа төбәгендәге фетнәчеләрнең башкомандующие Зарубин үзенең туганы И. Ульянов, Уфа казагы И. Губанов һәм тагын 20 ләп «казак» белән бергә Табын крепостена кача. Табын казакларының йөзбашы Алексей Кузнецов аларга Бирдәгә, Пугачев янына качарга (кызганыч, алар «падишаһ»ның 22 мартта Татищев крепосте янында тар-мар ителүен белмиләр, юкка ашыгалар) алмаш атлар табып бирә алмый һәм Зарубин төркемен крепостьтан 3 чакрымдагы Богоявленский заводына алып китә. Монда аларны завод приказчигы (фамилиясе билгесез) каршылый, ашарга утырта. Шуннан соң Зарубин һәм аның яраннары мәкерле тозакка эләгәләр. Приказчикның хатыны аларны нык итеп аракы белән сыйлый. Тегеләр исереп егылышкач, шушы хатын өйрәтүе буенча аның ире һәм А. Кузнецов фетнәчеләрне бәйләп ташлыйлар. Иртән заводка карательләр отряды килеп җитә. Атаманнар «җылы» көенчә җәлладлар кулына эләгә. «Граф Чернышев» кулында 1243 сум акча табыла («Крестьянская война... на территории Башкирии»). «Юмарт» Михельсон шуның 500 сумы белән, әлбәттә инде, беренче чиратта «акыллы» хатынны, аннан соң А. Кузнецов һәм завод приказчигын бүләкли. Ә Зарубин, Губанов, Ульянов Табын крепостена озатыла һәм шундук коточкыч җәзаларга тартыла *(Ә. Әсфәндияров, И. Гвоздикова, Р. Овчинников)*. Шуннан Зарубин Уфага, Казанга, соңрак Мәскәүгә озатыла. Аның өчен бер елга сузылачак газаплар шулай башлана. Зарубинны 1775 ел башында гына кабат Уфага алып кайталар. Әүвәл аны Чесноковка авылына алып барып җәзалыйлар, аннары 24 гыйнварда Уфада башын чабып өзәләр. Аның башы биек казык өстенә кадап куела, гәүдәсе яндырыла. Губановны исә шулай ук Уфа каласында 1774 елның 19 октябрендә башын чабып үтерәләр. Ульянов Рогервик портына каторга газапларын кичәргә озатыла («Өфө тарихы»).

Ә Чесноковка янында Михельсон карательләре тарафыннан куып таратылган крестьяннар, санаулы гына көннәр үтүгә үк, яңа отрядларга туплана башлыйлар. Ногай юлында Кинҗә Арыслановның улы Селәүсен Кинзин, Галибай Морзаголов, Кәип Зиямбәтов кебек башкорт старшиналары кул астындагы фетнә отрядлары инде ноябрь — декабрь айларыннан бирле хәрәкәт итә. Минзәлә һәм Уфа янындагы җиңелүләрдән соң шушы ук Ногай юлындагы волостьларга Каранай Моратов, Качкын Самаров, Канбулат Юлдашев кайтып төшә. Бу чорда инде бөтен Бөгелмә—Оренбург арасы җәза полклары белән мыжгып торуга да карамастан, секунд-майор Тютчев командалыгындагы җәза отряды Уфа—Эстәрлетамак арасындагы авылларны «буйсындырып» һәм талап уза, Михельсон үзе Табын крепостена юнәлә. Крестьян отрядларының җитәкчеләре 22 мартта Татищев крепосте янында Пугачев гаскәренең тар-мар ителүе турындагы хәбәрне дә алып өлгерәләр. Хәлләрнең шулай кисәк кенә аяныч төс алуы Ногай юлындагы фетнәче старшиналарны хәйләгә барырга мәҗбүр итә. К. Самаров, К. Зиямбәтов, Г. Морзаголов, К. Әҗәтев, И. Мерәсев кебек берничә старшина 4—7 апрельдә Михельсон каршына кылган «гөнаһлары» өчен «гафу үтенеп» килә һәм патшабикәгә тугры булырга «ант» китерә. Дөрес, арада «гаебен» чынлап торып «юарга» омтылучы сатлык старшина да табыла. Шундыйларның берсе Кыдрач Муллакаев Нагайбәк крепостеның атаманы булып торган Вәлит Торновны мәкерле рәвештә әсирлеккә төшерә һәм 13 апрельдә Бөгелмә коменданты полковник Кожин кулына тапшыра. Шул ук көннәрдә хыянәтче Кыдрач Богырыслан бистәсендә атаман булып торган, әмма генерал П. Голицын тарафыннан тар-мар ителгәч, 17 ярдәмчесе белән качкан депутат Гаврила Давыдовны да әсирлеккә ала һәм аны да җәзачыларга тапшыра.

Шундый ук икенче сатлык җан — мишәр старшинасы Миндәй Тупеевның мәкерле тозагына татар каһарманы Мәсәгуть Гомәров та эләгә. Ул, Уса, Көнгер ягында яшәгән 60 ка якын урыс крестьянын үз кул астына туплап, дары алу өчен Чесноковка авылына кайтып килгән була. Пугачев һәм Зарубин командалыгындагы лагерьларның тар-мар ителгән булуын да белми. Отрядларны бергә кушабыз, дигән ялган белән Миндәй Тупеев аны кулга ала һәм 16 апрельдә Уфага, Михельсонга илтеп бирә («Крестьянская война... на территории Башкирии»).

Ләкин Ногай юлында хәлләр шулайрак булса да, башка төбәкләрдә крестьян отрядлары һәм аларның җитәкчеләре гафу үтенергә дә, җәзачыларга бирелергә дә атлыгып тормыйлар. Михельсон тарафыннан апрель башында Бакалыга озатылган майор Харин командасы барча авылларны «буйсындырып» узса да, ул Уфага кайтып китүгә, бу төбәк авыллары янә баш күтәрә. Бөре каласына кадәр булган араны «караклардан һәм әшәке җаннардан («сволочьтан») арындырырга» дип озатылган җәза отряды бер уңышка да ирешә алмый. 13 апрельдә Михельсон Бөрегә таба Эстәрлетамак һәм Табын крепостьларыннан рейд белән кайтып кергән майор Тютчев командасын юллый, аңа сатлык мишәр старшиналары Солтанморат Янышев белән Миндәй Тупеев кул астындагы җайдакларны да бирә. 22 апрель көнне Тютчев карательләрен мишәр старшинасы Сөләйман Күзкәев җитәкчелегендәге 1000 кешелек крестьяннар отряды каршылый. Теперәш авылы (Чишмә районында) янында булып узган аяусыз яу барышында 200 дән артык крестьян һәлак була, 36 фетнәче әсирлеккә эләгә. Карательләр аларның берничәсен шунда ук дарга асалар, хәтта фетнәчеләр кулында булган мөселман байракларын да дарга кадаклыйлар. Яуда Тютчевка Сөләйман

Мостафин, Габделҗәлил Мәгъсүтов кебек, җан һәм байлыкларын саклау хакына карательләр ягына чыгып өлгергән мишәр старшиналары да ярдәм итә.

Әйе, бу яуда да крестьяннар җиңеләләр. Әмма исәннәре качып котыла һәм, санаулы гына көннәр үтүгә үк, яңадан-яңа отрядларга туплана. Михельсон, генерал Ф. Щербатовка язган рапортында Уфадан юллар ачылды һәм фетнә куркынычы юк, дип шапырынса да, җәза гаскәрләренә тынычланырга иртәрәк була әле. Менә шуңа күрә апрель ахырында Михельсон үзе Себер юлына, Сим заводында торган Салават Юлаев отрядына каршы юнәлә. Ә үзенә буйсынган капитан А. Мельгуновка инде 5 майда ук Уфадан янә Бөрегә, кабат отрядларга тупланган фетнәчеләргә каршы чыгарга әмер бирә. (Әмма воевода Мясоедов, шәһәрне гаскәрсез калдырудан куркып, Мельгуновны Уфадан җибәрми.) Бакалыда калдырылган майор Отто Дуве отряды да Бөрегә юнәлә. Ләкин бу немец офицерына юлда бик озак тоткарланырга туры килә. Чөнки аңа юл күрсәтергә алынган ике хыянәтчене фетнәчеләр кылычлар белән тураклап ташлыйлар, вак отрядлар белән бәрелешләр була. Боз киткәннән соң, ярларыннан ташыган елгалар да, күперләр булмау да Дувега тиз хәрәкәтләнергә комачаулый. Нәтиҗәдә Дуве отряды Бөрегә 26 май көнне генә килеп җитә. Ә бу вакытта инде бөтен Уса һәм Көнгер юлы волостьлары икенче кат фетнәгә күтәрелә. Бөре камалышта кала. Июнь башында бирегә яуларда сыналган Бәхтияр Канкаев, Яркәй Кадермәтов, Габдулла Туктаров, Балтач Сәетов, Гадел Бигашев кебек татар каһарманнары килеп җитә. 5 июнь көнне крестьяннарның берләштерелгән отрядлары Бөрене алуга да ирешә. Ләкин бу турыда соңрак сөйләрбез. Без әле Уфа провинциясенең Уса һәм Себер юлларына күз салмадык.

### *УСА ҺӘМ СЕБЕР ЮЛЛАРЫ*

Башкортстан галимнәре төзегән мәгълүматларга караганда, Пугачев явы барышында Уса юлында 3800 татар-мишәр, 4100 башкорт, 6700 чамасы мари һәм удмурт крестьяннары, Себер юлында исә 4700 татар-мишәр, 6700 гә якын башкорт һәм 1100 мари вәкиле фетнәдә катнаша.

*Безгә калса, бу мәгълүматлар һич тә тулы түгел, аеруча Уса, Көнгер төбәгендә яшәгән килеш яуга кушылган татар-мишәрләренең саны тиешенчә исәпкә алынмаган. Без Уса юлында инде 1688 елга кадәр үк 50 татар, мари, удмурт авылларының булуын әйтеп үткән идек. XVIII гасыр башында, 1705 елгы Алдар—Күчем фетнәсе барышында да биредәге Танып, Тол (Тулва), Ар елгалары буенда тагын Нөркәй, легендар Батыршаны үстергән Карышбаш, Чуртанлы күл, Уразай, Янбай, Начар, Чокалы, Тимкә, 1730—1770 еллар эчендә Мишәр, Усман, Иске Яхшый, Богдан, Көндәшле, Бигелде, Чишмә, Иштирәк һәм башка дистәләгән татар авыллары барлыкка килгән. Моннан тыш татарлар һәм мишәрләр башкортлар тарафыннан нигезләнгән Түшкыр, Көнтүгеш, Кансөяр, Сәйтәк, Туйчыбай шикелле авылларда да күпләп яшәгәннәр (Ә. Әсфәндияров). Аннан соң Пермь өлкәсе территориясендә калган Барда районы бүген һәркемгә тоташ рәвештә диярлек татарлар яшәгән төбәк буларак билгеле (соңгы елларда сан алу нәтиҗәсендә игълан ителгән мәгълүматлар исәпкә керми, алары пычрак сәясәт җимешләре). Ә андагы татар авылларының байтагы 1773 елга кадәр үк нигезләнгән һәм алар- дагы крестьяннар Пугачев явында күпләп катнашкан бит. Бер генә мисал китерик. 1774 елның сентябрь башында Салават Юлаев кул астында 1000 гә якын фетнәче була, әмма шул көннәрдә аның гаскәренә* 2000 кешелек Тулва (бу нигездә Барда районы дигән сүз) татарларыннан торган отряд *килеп кушыла (И. Гвоздикова). Ә бу әле бер генә отряд һәм игътибар итик — ул инде Пугачев явы аяусыз рәвештә бастырылган чор бит. Шулай икән, Уфа—Уса арасында яшәгән татар-мишәр фетнәчеләрен 3800 саны белән генә чикләп кую һич кенә дә дөрес була алмый.*

*Хаклы булуыбызны раслау өчен, икенче төр мәгълүматлар да китерә алабыз. Дөрес, алар — 1795 елда үткәрелгән 5 ревизия йомгаклары. Пугачев явыннан соңгы 21 ел эчендә халык саны күпмедер дәрәҗәдә (10—12 процентка) арткан, дип исәпләргә кирәк (галимнәр, халык саны 100 елга 1,6 тапкыр арта, дип исәплиләр). Ләкин 1773—1774 еллар дәвамында шактый гына ирләр кырылуын искә алсак, бәлки ирләр саны арасында бик зур аерма да юктыр. Ничек кенә булмасын, әмма уйлану-үлчәү өчен 1795 ел мәгълүматларын да кулланырга ярый.*

*5 ревизия Бөре өязендә (ә ул Уса юлының бер өлеше генә; Тулва татарлары, Барда районында яшәүчеләр аңа керми) төрле милләттәге 80 мең кеше (ике җенес бергә) яшәвен ачыклаган. Шуның 20 меңе генә башкорт катламына теркәлгән кешеләр булган (алар арасында татарлар да байтак булуына шигебез юк). Типтәр һәм мишәр булып язылганнар 26 мең кеше тәшкил иткән (А. Асфандияров. «История сел и деревень Башкортостана», III кн., с. 118). Әсфәндияров «ни өчендер» ясаклы татар булып язылган крестьяннар санын китермәгән. Ләкин Бөре өязендә татарларның икеләтә күбрәк булганлыгы болай да аңлашыла. Билгеле инде, Пугачев явында да татар вәкилләре башкортларга караганда сан ягыннан күбрәк*

*катнашканнар. Татарлар Уса юлында һәм Бөре өязендә фетнәне хәрәкәтләндерүче төп көч булган. Язма барышында сез моңа тагын да ышанырсыз.*

*Инде 1994 елда «Сәет батыр» китабы басылып чыкканнан соң ачыкланган мәгълүматны өстик. Бүген Бардада яшәүче тарихчы Әмир Фатыйхов язуынча, Пугачев фетнә- сендә Уса юлыннан 9435 ясаклы татар, 263 мишәр һәм 1373 башкорт ире катнашкан («Гайнә иле», 103 б.).*

*Шушы экскурстан соң Пугачев явы башланган көннәргә кайтыйк.*

Уса һәм Себер юлларында, Көнгер өязендә фетнәчеләрнең беренче отрядлары ноябрь ахырында оеша. Гайнә һәм Урман-Гәрәй волосте крестьяннары Елпачиха авылы (Пермь өлкәсенең Октябрь районында, татарча исеме Үдик. Үзендә яшәгән татарлар аны «Сараштьі» дип тә йөри. Барда районында Сараш, Сараштыбаш бар, алар да татар авыллары) вәкиле, походный старшина дәрәҗәсен алган Әбди Абдуллов һәм Җумакай Әскәров отрядларына оешалар һәм Сарапул тирәсендә хәрәкәт итә башлыйлар. Декабрь башында Уса юлында (Башкортстанның Балтач, Борай, Мишкә, Тәтешле районнарын, Пермь өлкәсендәге Барданы күз алдында тотыйк) яшәгән татар-мишәрләр «падишаһ Петр Федорович хәзрәтләренә» тугры булырга ант итәләр («Воззвания и переписка...»). Декабрь уртасында алар Алдар авылыннан (Борай районында) Рахманкул Гомәров, шул ук Елпачихадан булган Әдигут Тимачев кебек муллалар *(тарихи документларда әлеге ике җитәкче, алардан тыш Канзафар Усаев һәм Кинҗә Арысланов, тагын берничә юлбашчы «мулла» дип телгә алыналар. Аларның һәммәсе дә дин әһеле булуы мөмкин түгел. Алар заман- дашлары арасында укымышлылыклары белән аерылып торган һәм «мелла» дип хөрмәтләнгән шәхесләр түгел микән?)* кул астында отрядларга оеша башлыйлар. Шул ук көннәрдә Гайнә волостеның Усман авылы (икенче исеме — Тау авыл) йөзбашы Батыркай Иткинин җитәкчелегендәге отряд Уса юлында хәрәкәт итә. *(Усман авылы — Балтач районында, аны 1738 елда ясаклы татарлар нигезләгән — Ә. Әсфәндияров. «Воз- звания и переписка...» китабын төзүчеләр Батыркайны «Гайнә волостеның Усть-Тунтор авылыннан» дип күрсәтәләр. Алар И. Гвоздикова мәгълүматларына ияргәндер, дияр идек, әмма Гвоздикова, Батыркайны «Уса юлындагы Кущин волостеның Усть-Тунтор авылыннан башкорт йөзбашы», дип раслый. Ә Кущин волосте ул Себер юлына кергән. «Түнтәр»гә охшаш исемле авыл Башкортстанда бөтенләй юк. Барда районында Усть-Турка бар, ул да татар авылы. Ләкин Батыркай шәхсән үзе 1773 елның 20 декабрендә: «Мин Уфа өязенең Уса юлындагы Гайнә волостеның Усман авылы йөзбашы», — дип, ачыктан-ачык язган бит. Шулай булгач, 200 елдан соң бу шәхеснең туган җирен бутау, милләтен яшерү кемгә һәм ник кирәк икән?)* Крестьяннарның берләштерелгән отрядлары Усага таба хәрәкәт итәләр һәм декабрь уртасында әлеге каланы алуга ирешәләр *(И. Гвоздикова)*. Уса воеводасы поручик Ф. Пироговский «падишаһ Петр III» гә тугры булырга ант китерә. Алай гына да түгел, ул үзе белән бер бакыр туп, 10 пот дары, ике олау бакыр акча алып Чесноковкага, «граф Чернышев» каршына баш ияргә бара. «Граф» рәхмәт йөзеннән аның чәчен казакларча итеп кыркыта һәм, саклау билеты биреп, кабат Усага озата *(Н. Дубровин)*.

Бу вакытта инде крестьяннарның юлбашчылары Усадан Көнгергә таба юнәләләр. Юлда 3 урыс авылын, сәүдәгәр И. Осокинның Югов заводын алалар һәм декабрь ахырында Көнгергә килеп җитәләр. Крестьяннар үченнән курыккан воевода Миллер 23 декабрьдә үк, каланы ташлап, Чусовка шәһәрчегенә кача. 24 декабрьдән башлап атаман дәрәҗәсен йөртүче Батыркай Иткинин җитәкчелегендәге фетнә отряд- лары гыйнвар башында Көнгерне камап ала *(бу урында махсус тукталып, бер нәрсәгә игътибар итәргә һәм отряд җитәкчеләренең вөҗданлылыгына соклану белдерергә тиешбез. Пугачев явы барышында бер генә мөселман да үз-үзенә нинди дә булса хәрби дәрәҗә алмый. Батыркай Иткинин да атаман булып йә үз иптәшләре — отряд командирлары арасыннан сайланган, йә Чесноковкадагы Зарубин тарафыннан билгеләнгән булырга тиеш).* 3 гыйнварда Батыркай Иткинин, кулларына Пугачев тарафыннан 1 декабрьдә яздырылган манифестны тоттырып, калага Ф. Попов һәм И. Лукин исемле ике попны озата, крепость эченә бикләнгән гарнизоннан һәм байлардан каланы «падишаһ» гаскәренә тапшыруларын таләп итә (*И. Гвоздикова*; Ә «Крестьянская война... на территории Башкирии» китабында бер генә поп телгә алына. Анысының исем-фамилиясе — Афанасий Колесников). Каладагы офицерлар «падишаһ»ны таныган попларны богаулап зинданга ташлыйлар, ә фетнәчеләргә бертөрле дә җавап кайтармыйлар. 4 гыйнвар көнне Көнгергә Екатеринбургтан, полковник Василий Бибиков тарафыннан ярдәмгә юлланган подпоручик Посохов командалыгындагы 100 кешелек отряд килеп җитә. Батыркай кул астындагы фетнәчеләр беренче мәртәбә шушы көнне каланы штурмларга ташланалар. Ләкин крепость стеналары крестьяннарны туплардан ут ачып каршылый. Ул да түгел, капкалардан чыгып, Посохов командалыгындагы казаклар фетнәчеләрне куа башлый. Батыркай чигенергә әмер бирә, Посохов казаклары крестьяннар артыннан ташлана һәм алдан ук оста корылган засадага эләгә. Посохов үтерелә, казаклар кабат крепость стеналары артына кереп бикләнә.

5 гыйнварда Батыркай янә бер мәртәбә каланы штурмлап карый, әмма уңышка ирешми. Крестьяннар күршедәге авылларга чигенә. Шул көнне үк Көнгердәге гарнизонга ярдәмгә секунд-майор А. Папава

(икенче төркем документларда — Попов) командалыгындагы 400 кешелек карательләр отряды килеп җитә. 6 гыйнварда Чусовка шәһәрчегеннән 300 кешелек отряд алып, воевода Миллер да Көнгергә кайтып төшә. Каладагы гарнизон шул рәвештә кисәк көчәйсә дә, Батыркай Иткинин җитәкчелегендәге крестьяннар Көнгерне камап торуларын дәвам итәләр. 9 гыйнвар көнне аларга мишәр каһарманы Канзафар Усаев җитәкчелегендәге яңа отряд килеп кушыла *(Н. Дубровин).*

Уфадан 60 чакрым ераклыкта урнашкан Бозаяз авылында (хәзер Кырмыскалы районында) әүвәл мулла, соңрак йөзбашы булып торган Канзафар Усаев әле 1773 елның октябрь аенда ук Оренбургны камалышта тотучы Пугачев гаскәренә барып кушыла. Канзафар Хәрби коллегиядә, Кинҗә Арысланов белән янәшәдә сәркатип булып хезмәт итә башлый. Оренбургны штурмлау өчен барган яуларда катнаша һәм кыюлыгы өчен Пугачев тарафыннан полковник дәрәҗәсен ала. Канзафар Оренбург янында бер ай чамасы хезмәт иткәннән соң, Пугачев аны, Башкортстанның төньяк районында, Красноуфимск һәм Көнгер тирәсендә фетнә отрядлары туплау өчен махсус эмиссар итеп озата. Декабрь аенда Канзафар үзенең кул астына 500 кешелек отряд туплауга ирешә һәм Көнгергә таба юнәлә. 1 гыйнвар көнне ул Богородское авылын ала, андагы халыкны «падишаһ»ка тугры булырга ант иттерә. Мондагы 25 крестьян Пугачев «казаклары» сафына баса. Ә Канзафар үзе ял итәргә тукталган йорт хуҗасы Иван Белобородовны шул казакларның йөзбашы итеп билгели. Аның кул астына, үз отрядыннан аерып, тагын 12 сугышчы бирә *(Ю. Лимонов)*. Алар бергәләп Көнгергә таба юнәләләр. Юл уңаенда Осокинның Ирга һәм Шуртан заводларын (хәзер Екатеринбург өлкәсендә) алалар. Соңгысында Канзафар үзенең көрәштәше Белобородовка «падишаһ» исеменнән атаман дәрәҗәсе һәм аның кул астына тагын 100 сугышчы бирә *(Н. Дубровин)*. Шуннан соң Канзафар үзе Ачыт крепостен штурмларга юнәлә, ә Белобородов отрядын Бисерт заводын алырга озата.

*Без шушы урында янә тукталыш ясарга һәм Пугачев явын өйрәнгән кайбер галимнәрнең эзлексезлегенә гаҗәпләнү белдерергә мәҗбүрбез. Тарих фәннәре докторы дәрәҗәсенә ия булып Ростов университетында укыткан һәм 1954, 1979, 1980 елларда өч зур китап чыгарган Хикмәтулла Моратовның үз хезмәтләрендә туктаусыз ялгышуын аңлап булмый. Аның соңгы китабыннан бер өзекне укыйк: «19 гыйнвар көнне Көнгер каласына Салават Юлаев, Канзафар Усаев кул куйган указны китерәләр. Бу чакта воевода Миллер шәһәрне ташлап качкан була. Ә 500 солдат белән Казаннан килеп төшкән майор Папава указны халыктан яшерергә тели. Әмма халык таләп иткәч, аны укырга мәҗбүр булалар. Указны мәйданда Осокин заводына беркетелгән крестьян Иван Белобородов та тыңлый. Ул авылдашлары тарафыннан йөзбашы итеп сайлана һәм 100 казак өстеннән башлык итеп Екатеринбургка таба озатылган була» («Крестьянская война под предводительством Пугачева 1773—1775 гг.».— М: Просвещение, 1980.— с. 88). Хәзер ялгышларын санап карыйк. 1. Миллер 6 гыйнварда Көнгергә кабат кайта. 2. Папава 500 түгел, 400 сугышчы белән килә. 3. Белобородов — заводка беркетелгән крестьян түгел, бәлки бал, балавыз һәм башка товарлар белән сату итеп көн күрүче вак сәүдәгәр. Башка ялгышларын әлегә күрсәтмик тә, китапның 98—100 нче битләрендә язылган җөмләләрне китерик: «Көнгердән 100 казак белән чыккан Белобородов Екатеринбург юлында тагын 600 кеше туплый, Шайтан, Билимбай заводларын ала һәм 6 гыйнварда Ачыт крепостен кулга төшерә». Менә шушы җөмләләрдән соң инде Моратовта булган мантыйксызлык, ялган бөтенләй акылга сыймый. 1. 19 гыйнварда Белобородов Көнгер каласына үзе белән бергә указ тыңлау өчен 100 фетнәче «казакны» да алып барган микәнни? 2. 19 гыйнварда 100 сугышчысы булган Белобородов ничек итеп 6 гыйнварга кадәр тагын 600 фетнәче җыйган? 3. Бөтенләй кыргый сорау: 19 гыйнварда да әле фетнәче булып хәрәкәт итә башламаган кеше 6 гыйнварда Ачыт крепостен алырга мөмкинмени? 4. Көнгердән Билимбай заводына кадәр ара бүген чама белән 300 километр тәшкил итә. Билимбайдан Шайтан заводына кадәр — 100, ул заводтан Ачытка кадәр ким дигәндә янә 200 километр. XVIII гасыр кешесе гыйнвар уртасында, яулар кичерә-кичерә, мондый араны ничек үтте икән?*

*Бу кадәр ваклануыбыз юкка гына түгел. Мавродин, Панеях, Лимонов шикелле Петербург галимнәре дә урыс сәүдәгәре Иван Белобородовны җитез һәм оста юлбашчы итеп тасвирлау өчен фәнни манипуляция юлына басканнар. Алар үз хезмәтләрендә, Белобородов 1774 елның 1 гыйнварында Канзафар Усаев отрядына кушыла дип, ачыктан-ачык искәртәләр. Әмма Канзафар ирешкән җиңүләрне татар каһарманына бирәсе килмәү хисе аларны фәнни ялганга барырга мәҗбүр итә кебек. Алар үз хезмәтләрендә, Канзафар белән Белобородовны 1 гыйнвардан 6 сына кадәр бергә хәрәкәт иткәннәр һәм бер-бер артлы Суксун, Бисерт, Ревда, ниһаять, Ачыт крепостен алганнар, дип күрсәтәләр. Ә менә Белобородов яшәгән Богородскоедан Суксунга кадәр — 70, Суксуннан Бисертка — 85, Бисерттан Ревдага — 120, Ревдадан Ачытка кадәр 150 чакрымнан артык ара булуын да, кышкы юлда мондый ераклыкны атлар белән 4—5 көн эчендә үтеп булмавын да алар исәпләми. Петербург галимнәренең Белобородовны каһарман итеп күрәсе килә һәм вәссәлам! Әмма тарих андый ысул белән язылырга тиеш түгел!*

Инде үзебезнең геройларга кайтыйк. Әйе, Белобородов Бисерт заводына, аннан Екатеринбургка таба юнәлә һәм 18 гыйнварда Билимбай заводына килеп җитә. Ә безнең татар каһарманы Канзафар Усаев 6 гыйнварга каршы төндә Ачыт крепостен камый.

Бу вакытта крепостьта Екатеринбургтан Уралдагы казна заводларының идарәчесе полковник В. Бибиков тарафыннан фетнәчеләргә каршы озатылган махсус отряд тора. Капитан Воинов командалыгындагы әле отрядны 6 туп, 5 пот дары белән коралланган 136 солдат тәшкил итә. Алардан тыш крепостьта әле отставкага чыккан карт солдатлар һәм офицерлар да була. Фетнәчеләр искәрмәстән һөҗүм ясамасын өчен, Воинов крепостька килүче барча юлларга атлы сакчылар — разъездлар җибәрә.

Менә шул разъездларның берсендә сакчылар крепостька якынлашып килүче Канзафар Усаев отряды ягына чыгалар һәм хәйлә коралар. Сакчылар, крепостька кайтып, андагы төнге каравылчыларны «падишаһ» гаскәренә тугрылык күрсәтеп каршыларга үгетли. Канзафар отряды крепостька һичнинди тавыш-гауга кузгатмыйча үтеп керә. Гарнизон коралсызландырыла. Капитан Воиновны, йокысыннан уятып, кулга алалар. Отряд җитәкчеләре ике көн буена Воиновтан сорау алалар һәм хөкем карары чыгаралар. Ул карарга һәммә отряд командиры кул куя (архивта бүгенге көннәргә кадәр сакланган әлеге кәгазьдә урыс галимнәре каһарман итеп күрергә хыялланган Белобородовның исеме дә, имзасы да юк!). 8 гыйнвар иртәсендә капитан Воиновны дарга асалар. Гарнизон «падишаһ» гаскәренә кушыла. Крепостьта калган фетнәчеләрнең атаманы итеп Канзафар керәшен Иван Аширминны, йөзбашлары итеп Иман Галәүсинов (Аладинов), Ишмәт Мәмәтов (Мәмәткулов), Түләй Сәгыйтов атлы крестьяннарны билгели. Алар Красноуфимскидан алып килә торган юлны карательләрдән сакларга тиеш була («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Канзафар отряды шул көнне үк юлга чыга һәм Суксун заводын ала. Заводка беркетелгән крестьяннарның 54 мең сумлык «бурыч» кәгазьләре яндырып юкка чыгарыла. 9 гыйнвар таңында крестьяннар Көнгер каласы янына килеп җитәләр. Батыркай Иткинин һәм Канзафар Усаев отрядлары бергә кушыла һәм Көнгерне штурмларга ташлана. Әмма бу юлы да нигездә сәнәк, чалгы, сөңге белән коралланган крестьяннар тупларга каршы тора алмыйлар. Шәһәр капкаларыннан чыгып һөҗүмгә күчкән Папава солдатлары фетнәчеләрне куып тарата. Батыркай белән Канзафар отрядлары Шубино һәм Неволино авылларына чигенә. 11 гыйнвар көнне крестьяннар Көнгерне янә камалышка алалар, ләкин Папава карательләре аларны тагын чигенергә мәҗбүр итә. Фетнәчеләрнең төп көче бу юлы Усть-Кишерть авылына чигенеп туплана. 15 гыйнвар көнне бирегә инде Папава үзе һөҗүм ясый. Фетнәчеләр Старопосадское (икенче исеме — Троицкое) һәм Тихановское авылларына чигенә. Ә өч көннән соң Көнгер янына Салават Юлаев, Михаил Попов, Сөләйман Күзкәев, Илчегол Иткулов җитәкләгән яңа отрядлар да килеп өлгерә.

Менә башкорт каһарманы Салават Юлаевның сугышчан юлы белән дә танышырга вакыт җитте. Ләкин фетнәнең бу этабында аны Бәхтияр Канкаев эшчәнлегеннән аерып карау мөмкин түгел. Шуңа күрә кыскача гына рәвештә һәр икесенә тукталыйк.

Бәхтияр Канкаев Башкортстандагы Мәчетле районының Олы Ака авылыннан. Ул чагында бу авыл Уфа өязенең Себер юлындагы Кущин волостена кергән. Бәхтиярның туган елы да, Пугачев явына кадәрге тормышы да билгесез. Фетнәгә ул 1773 елның октябрь аенда ук, Бирдәдәге лагерьга барып кушылган булырга тиеш. Чөнки 3 декабрьдә аңа Пугачев шәхсән үзе атаулы указ бирә һәм аны Башкортстанның төньягына — Красноуфимск (хәзер Свердловск өлкәсендә) янына фетнә ялкыны кабызу бурычын куеп озата. Мөселман җитәкчеләре арасында мондый үтә дә җаваплы задание Бирдә лагерена килеп «падишаһ» каршында зур ышаныч яулаган һәм, гадәттә, фетнәгә кадәр үк үзенең туган төбәгендә волость, түбә старшинасы яки һич югы йөзбашы булып торган Каранай Моратов, Качкын Самаров, Муса Мостафин, Канзафар Усаев кебек абруйлы шәхесләргә генә бирелгән. Пугачев тарафыннан юлланган мондый эмиссарлар белән чагыштыргач, Бәхтияр хакында да үз авылында йөзбашы яки туган төбәгендә абруйлы кеше булган дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

Без инде әйтеп өлгердек: Бәхтиярга Пугачев указы 3 декабрь көнне тапшырыла, аңа походный старшина дәрәҗәсе бирелә. Бәхтияр үзенә ярдәмгә йөзбашы дәрәҗәсенә лаек булган Габделкәрим Күзкәев атлы мишәр вәкилен ала. 12 декабрьдә алар Уфа өязенең Ногай юлында, Тор елгасы буена урнашкан Воскресенск заводы аша узалар. Пугачев тарафыннан Уфа провинциясе территориясендәге барлык фетнә отрядларының юлбашчысы итеп билгеләнгән, «граф Чернышев» дәрәҗәсе алган Чика-Зарубин белән очрашалар. Зарубин Бәхтиярга һәр ике йорттан бер крестьянны «падишаһ казагы» итеп алырга һәм татар-мишәр вәкилләре белән генә чикләнмичә, урыс, мари, башкорт кешеләрен дә үз отрядына тупларга әмер бирә.

Бәхтияр отрядны әүвәл үзенең туган төбәгендә туплый башлый. Мәчетле районына кергән Абдулла, Олы һәм Урта Ака авылларының татар-мишәр крестьяннары «падишаһ» гаскәре сафына теләп баса.

Аннары Бәхтияр хәзер Свердловск өлкәсенә кергән Урта Богалыш исемле татар авылындагы, бүген билгесез Шарами авылындагы крестьяннарны да үз отрядына куша. Декабрь ахырында Бәхтияр үзенең кул астына шактый зур күләмдәге отряд туплап өлгерә. Аның төгәл генә санын әйтү мөмкин түгел. Ләкин декабрь — гыйнвар айларында Бәхтиярга буйсынучы Юскә Юнысов, Юныс Касыймов, Габделкәрим Күзкәев, Юлбарыс Учупов (Юсупов — ?), Нурмөхәммәт Корычев, Атнабай Биккенин, Мөслим Мусин, Бәшир Мусин, Кадыйр Якупов, Әхмәр Мөхсинов, Ерукай (Яркәй — ?) Гайсин, Куган Якупов, фамилияләре билгесез Монасыйп, Сәет кебек дистәдән артык йөзбашы яки иллебашы булу да отрядны ким дигәндә 800—1000 сугышчы тәшкил итүен күрсәтә («Воззвания и переписка...»).

Бәхтияр гыйнвар башында үз отряды белән сәүдәгәр И. Осокинның Санар (Саранинск) заводына юнәлә. Заводта эшләүче крестьяннарны «падишаһ гаскәренә» буйсынырга чакыру өчен, Бәхтияр алдан ук 4 үгетче җибәрә. Завод эшчеләре, Бәхтияр отрядын авылдан 7 чакрым алга чыгып, ипи-тоз белән каршы алалар, шунда аңа ике ат бүләк итәләр. Бер туп, 93 ядрә, байтак кына дары, мылтык, ат һәм олаулар фетнәчеләр кулына эләгә, 15 эшче Бәхтияр отрядына кушыла («Воззвания и переписка...»).

Шундый ук ысул белән Бәхтияр Канкаев Красноуфимск каласына да үгетчеләр җибәрә. Бу юлы инде крепость кадәр крепость яусыз-нисез фетнәчеләр гаскәре каршында тез чүгә. Шәһәр воеводасы Н. Бахматов, җиңелгән очракта крестьяннарның үч алуыннан куркып, төрле хәйлә белән гарнизондагы казакларны коралсызландыра *(Н. Дубровин)*. Аннан соң үзе үк, каладан чыгып һәм дәүләт әләмнәрен түбән иеп, Бәхтияр отрядын каршы ала. Шунда, кыр уртасында ук, 4 туп, 24 пот дары, хисапсыз күләмдәге ядрәләр фетнәчеләр гаскәренә тапшырыла («Воззвания и переписка...»). Фетнәчеләр 9 гыйнвар көнне калага тупларның күмәк салюты астында килеп керәләр. Бәхтияр биредә үз отрядын тагын казаклар белән тулыландыра. Крепостьта табылган казна акчасын (аракы сатудан җыелган — 6, тоз сатудан кергән 90 капчык бакыр акчалар) Чесноковкадагы «граф Чернышев»ка озата. Каладагы идарә тәртибе үзгәртелми. Воевода Н. Бахматов та, Красноуфимск крепостенда хезмәт иткән казакларның йөзбашлары — аталы-уллы Григорий һәм Афанасий Овчинниковлар, отставкадагы атаман М. Калашник та үз урыннарында калдырыла («Воззвания и переписка...»).

Нәкъ шул көнне үк Красноуфимск каласына Себер юлындагы Кущин волостеның старшинасы Илчегол Иткулов җитәкчелегендәге башкортлар отряды да килеп керә. Әлеге крестьяннар Себер юлында Салават Юлаев туплаган отрядның аръергарды (алдынгы өлеше, разведчиклары) була. Илчегол Красноуфимскидан 110 чакрымдагы Котыш авылында «падишаһ» полковнигы Салаватның алардан хәбәр көтеп ятуы турында хәбәр итә. Бәхтияр белән Илчегол Красноуфимск чиркәвендә пономарь булып торган 19 яшьлек Макар Поповны Котышка (Мәчетле районында) Салават отрядын чакырырга озаталар. 3 көннән соң, 12 гыйнварда калага Салават үзе дә килеп җитә. «Падишаһ» полковнигын воевода Бахматов үзе һәм есаул Г. Овчинников каладан 2 чакрым читтә каршы ала («Крестьянская война... на территории Башкирии», *М. Попов* күрсәтмәсе, 59 эш).

Безне төп темадан читкә тайпылырга мәҗбүр итә торган җитди сәбәпләр бар. Әмма укучының түземлеген сынамас өчен, иң әүвәл һәм, ниһаять, Салават белән таныштырып үтик.

Салават Юлаев Уфа провинциясенең Себер юлындагы Шайтан-Көзәй волостеның Тәкәй авылыннан (хәзерге Салават районындагы Юлай авылы, халык телендә «Юлай-Шаганай»), 1752 елда туган. Әтисе Юлай Азналин 1768 елдан соң шушы волость старшинасы булып тора. Үзе надан була, әмма Салават укырга-язарга өйрәнә. Яшьлегенә карамастан, 1773 елда Салаватның инде 3 хатыны, 2 улы була. Оренбург губернаторы И. Рейнсдорп тарафыннан Уфа провинциясендә яшәгән башкорт һәм мишәрләрдән 5000 кешелек гаскәр туплау турындагы 9 октябрь указы килеп җиткәч, старшина Юлай үзенә буйсынган 115 йорттан 80 (икенче төркем документларда 95) кешелек отряд җыя. Бу отряд өстеннән башлык итеп Салаватны билгели һәм «карак» Пугачевка каршы озата. Салават отряды Эстәрлетамак пристанена 28 октябрьдә килеп җитә (*И. Гвоздикова*. Отряд юлда 15 көн буе бара). 10 ноябрь көнне Ногай юлындагы Кыркулы-Мин волостеның баш старшинасы Галибай Морзаголов җитәкчелегендәге, составында Салават та булган 1200 кешелек татар-башкорт отряды Биккол авылы янында фетнәчеләр ягына чыга. Салават «падишаһ» янына килеп Бирдәдә хезмәт итә башлый. Оренбург өчен барган сугышларда катнаша. Шул бәрелешләрнең берсендә батырлык күрсәтә. Аның кулы, аркасы һәм яңагы яралана. «Үз отрядында булган башкортлар үтенече буенча» аңа Пугачев тарафыннан полковник дәрәҗәсе бирелә. Декабрь аенда Салават яуда алган яраларыннан савыгу һәм Себер юлындагы крестьяннарны фетнәгә күтәрү, Красноуфимск, Көнгер калаларын алу өчен, үзенең туган төбәгенә озатыла.

1773 елда Уфа провинциясенең Себер юлында 2255 башкорт, 770 мишәр хуҗалыгы (дворы) була. Башка катлам вәкилләре турында нәкъ шул елгы мәгълүматлар юк. 1764 ел күрсәткечләрен файдалансак, шушы ук төбәктә әле тагын 2866 татар һәм мари ирләре дә яшәгән *(И. Гвоздикова)*. Аларның зур күпчелеге, һичшиксез, татар булган. Мисал өчен, Мәчетле, Салават, Учалы, Дуван, Кыйгы, Аккатай, Бело-

рет районнарында бүген бер генә мари авылы да юк. Әмма ул вакытта Себер юлында, барыбер, азмыкүпме мари яшәгәндер. Чөнки шушы юлдагы 19 старшина арасыннан берсе — Каникей Яшпохтин фетнәче марилар җитәкчесе булып торган.

Салават Юлаев исеме чагылган тарихи документлар 1774 елның 13 гыйнварыннан гына башлана. Салаватның төгәл кайсы көндә үз кул астына фетнәчеләр отрядын туплый башлавы хакында әйтеп булмый. Әмма декабрь ахырында аның отряд туплаган булуы шик тудырмый. «Падишаһ» исеменнән чакыру буенча аның кул астына үз отряды белән мишәрләр старшинасы Сөләйман Күзкәев, мари К. Яшпохтин, башкорт старшиналары Илчегол Иткулов, Собханкол Килтәков, Яун Чювашев (нигә «Чювашев»?), Өметәй Үрәзембәтев, Алахуҗа Бакынов килә *(И. Гвоздикова)*. Фетнәчеләр туплау этабында Салават зур активлык күрсәтә. Салават отрядында булырга теләмичә, Юлай-Шаганай авылындагы үз йортларына кереп бикләнгән бертуган Мөхәммәткилде, Яхшымбәт, Сыярымбәт Әбдерәковлар кораллы бәрелеш вакытында янып үләләр. Салават әле киләчәктә дә үзенең фәрманына буйсынмаган кешеләрне Әбдерәковлар кебек юк итү белән куркыта *(И. Гвоздикова, Ю. Лимонов, В. Панеях, В. Мавродин)*.

Декабрь ахырында Салават отрядына башкорт, татар, мишәр, мари, чуваш вәкилләре булган 800 крестьян туплана (*И. Гвоздикова*; «Крестьянская война... на территории Башкирии»). Салават Красноуфимскига юнәлә. Ә анда кайчан һәм ничек килеп җитүен без сөйләдек инде.

**Менә хәзер темабыздан читкә тайпылыйк.** *Моңа безне һаман да шул совет галимнәре тарафыннан күрсәтелгән эзлексезлек, башбаштаклык, ялган мәҗбүр итә. Красноуфимск каласын алу вакыйгасын кемнәр генә үзенчә сукаламаган да, кайсы галим генә бу җиңүне бүтән каһарманнарга, бүтән отрядларга «ябыштырып» куймаган? Шунысы гаҗәпләндерә: геройлар үзләре һәлак булганнан соң 200 ел үткәч, бер кешенең җиңүен бүтәннеке итеп күрсәтү, ясалма каһарман әвәләү, тарихи вакыйгаларны буташтыру нилә өчен, кемнәр өчен генә кирәк соң?!*

*Моңа кадәр безнең өчен шактый ышанычлы булган «буржуазия» тарихчысы Н. Дубровинның «Пугачев и его сообщники» китабыннан башлыйк. Ул Красноуфимск каласын* ***Канзафар Усаев һәм Салават Юлаев җитәкчелегендәге башкорт*** *крестьяннары алган дип күрсәтә. Шуннан соң, имеш, шушы ике юлбашчы Батыркай Иткининны — Көнгер, ә Иван Белобородовны Чиләбе крепостьларын штурмлау өчен озаталар. Дубровин үзе үк, Батыркай Көнгер янына 4 гыйнварда килеп җитә, дип раслый. Әлеге тарихчы хезмәтендә мантыйк булмау күзгә бәрелеп тора. 1. С. Юлаев Красноуфимск каласына 12 гыйнварда гына килеп җитә, ә К. Усаев бу крепостьта бөтенләй дә булмый. 2. 12 гыйнварда Красноуфимскига килгән С. Юлаев тарафыннан озатылган Б. Иткинин 4 гыйнвар көнне берничек тә Көнгер каласына барып җитә алмый. 3. И. Белобородов Чиләбе тирәсендә гыйнварда гына түгел, бәлки восстаниенең бөтен дәвамында да бөтенләй дә булмый. Әйткәнебезчә, Белобородов бу вакытта Екатеринбургка таба хәрәкәт итә, 18 гыйнварда Билимбай заводын ала. 4. Красноуфимск каласын башкорт кына түгел, бәлки зур күпчелеге татар-мишәрләрдән торган, шулар арасында күпмедер санда урыс, мари, чуваш, башкорт вәкилләре булган Бәхтияр Канкаев, Илчегол Иткулов җитәкчелегендәге отрядлар ала. Без урыс әдәбиятында Уфа провинциясендә яшәгән бар милләт вәкилләрен дә, бу төбәктә хәрәкәт иткән отрядлардагы фетнәчеләрне дә ике очракның берсендә «башкорт» дип гомумиләштерүләренә әллә ни гаҗәпләнмибез. «Галим» исемен йөртүче кешеләр милләтләрне аера белү «түбәнлегенә» төшәргә теләми яки алар фәкать бер милләт вәкилләрен генә күрә икән — монысы инде аларның намус эше.*

*Инде совет галимнәре хезмәтләрендәге «ачышларны» да санап китик. Аларның һәммәсе дә бердәм булып, Салават Юлаевның декабрь аенда (датасы билгесез) Пугачев тарафыннан озатылуын һәм Салаватның иң әүвәл туган ягына кайтуын, шунда отряд туплый башлавын раслыйлар. Панеях, Мавродин, Лимонов кебек Петербург галимнәре: «Декабрьнең икенче яртысын һәм гыйнвар башын Салават Юлаев Себер юлында зур отряд туплауга багышлый», — дип яза («Пугачев и его сподвижники», 124 с.). Ләкин икенче җөмләдә үк әлеге галимнәр бөтенләй сәер булып аңгыраган фикерне әйтә: «Шушы чорда ук Салават Юлаев Себер юлында булмаган волость үзеге Сарапулны ала». Берничә җөмләдән соң авторлар аның датасын да күрсәтәләр — 25 декабрь көне. Шушы ук датаны үзенең хезмәтендә В. Буганов кабатлый. Уфада яшәп иҗат итүче И. Гвоздикова да, С. Юлаев декабрьдә Сарапулны алган, дип расларга тырыша.*

*Әмма, ни гаҗәп, әлеге авторларның берсе дә Салаватның Оренбург янындагы бәрелештә шактый нык (кулы, аркасы, яңагы) яраланган булуын да, аның туган ягына савыгу өчен кайтуын да искә алмыйлар. Ә даталар һәм ара ераклыгы дигән үлчәмнәр белән эш йөртү, безгә калса, аларда бөтенләй юк.*

*Һәммә галим, Салаватны Бирдәдән туган төбәгенә кайтып киткән, дип бара. Бирдә белән Тәкәй авылының арасы бүген самолет яки вертолет белән очкан очракта да 450—480 километр. Декабрь аенда кар ерып, Урал таулары аша юллар үтеп, ат өстендә яралы килеш кайтканда, 600—650 километрга әйләнәчәк мондый араны үтү өчен 9—10 көн генә һичничек тә җитми. (Искә төшерик: Салават отряды*

*1773 елның октябрендә Тәкәйдән Эстәрлетамак пристанена кадәр булган 400 чакрым араны да 15 көн буе узган.) Инде туган ягына кайткач та, Салаватның соңыннан үзенә кушылачак 7 старшинага (ә алар Юлай Азналин волостеннан шактый ерак арада яшиләр) хәбәр итәсе, аларның отряд туплап килгәнен көтәсе бар. Әле аларның тәүге чакыру буенча гына килмәүләре дә, Салаватның үзенә аларны волость-ларына барып үгетләргә туры килүе дә мөмкин. Әбдерәковлар белән булган очрак шуны раслый. Кыш көнендә Урал таулары буйлап йөри-йөри отряд туплау да ким дигәндә 6—7 көн генә вакытны алачак. Әмма барысы да уңай торсын һәм Салават Сарапулга карап юлга чыксын, ди (ни өчен нәкъ менә Сарапул — монысы һич аңлашылмый. Сарапулга төбәп барганда янда гына Уфа, Бөре калалары калачак, югыйсә аларны да аласы бар бит әле). Юлай авылы белән Сарапул арасы бүген самолет белән очканда 350—400 километр. 800 кешелек отрядны тукландырып, ял иттереп, әйдәкләп бару өчен һәм җайдакларга кыш көне 450—550 километрга әйләнәчәк бу ара да 8—9 көнлек кенә юл түгел (чагыштырып карау өчен полковник Ю. Бибиковны искә төшерик. Әлеге каратель Казаннан 5 гыйнварда чыга һәм 250 чакрымдагы Зәй янына 16 сында гына килеп җитә). Бәс, шулай икән, Салаватның инде 25 декабрьдә үк һәм аяусыз, канлы штурмнан соң Сарапулны алуы мөмкинмени? Болар гына җитмәсә, В. Буганов әле, Салаватны К. Усаев, И. Кузнецов белән берлектә, 4 мең кешелек гаскәр белән инде 30 декабрьдә үк Красноуфимск каласын алган, дип күрсәтә (Сарапул — Красноуфимск арасы самолет өчен 300 километр). Панеях, Лимонов һәм Мавродин, Салаватны Сарапулдан Көнгер янына Собхангол Килтәков белән Бәхтияр Канкаев чакырган, дип баралар. Бу авторлар раславы буенча Бәхтияр инде декабрь ахырында ук Красноуфимск каласы янында хөкүмәт отрядлары белән канлы бәрелешләр алып барган һәм шул көннәрдә үк крепостьны алган икән. Ләкин без беләбез: Бәхтияр 9 гыйнварда гына бу каланы алган, ә С. Килтәков бу көннәрдә Котыш авылында Салават кул астында торган (Илчегол Иткулов 9 ы көнне пономарь Поповка Салават урнашкан авылны тәгаен әйтеп озата, димәк, үзе ким дигәндә 7 гыйнварда аны шунда калдырып килгән).*

*Урыс авторларының мондый «ачышларын» без әле тагын да саный алыр идек. Әлегә җитеп торыр. Хәзер инде иң мөһим дәлилне кабатлыйбыз: Салаватның исеме тарихи документларда (галимнәр түгел, бәлки фетнәчеләр яки карательләр язган кәгазьләрдә) беренче мәртәбә 1774 елның 13 гыйнварында гына телгә алына. Ә Салаватның декабрь аенда Сарапулны алуы мөмкин түгел. Чөнки, бердән, Сарапулны А. Вязовой белән И. Васев җитәкчелегендәге фетнәчеләр һәм бары тик февраль аенда гына ала («Крестьянская война... на территории Башкирии»; В. Буганов). Икенчедән, Салават Юлаевның шәхсән үзенең декабрь аенда Сарапул янында хәрәкәт итүен чагылдырган бер генә тарихи документ та юк. Соңыннан Салават отрядына барып кушылачак кайбер крестьяннар яки йөзбашларының декабрь аенда Сарапулда сугышып йөрүенә яки шуларның исем-фамилиясенә карап кына Салаватны Себер юлы белән Сарапул арасында бүлгәләү, гомумән гөманлап нәтиҗә ясау, фараз кылу — фәнни нигезләнгән хезмәт була алмый. Салаватны поезд яки самолет тизлеге белән бер өлкәдән икенчесенә (Оренбург — Башкортстан — Пермь — Башкортстан — Свердловск) күчереп йөрткәнче, вакыйгаларның 1773 елның зәһәр салкынлы кышкы, юлсыз айларында баруын да, башкорт каһарманының бу вакытта яралы булуын да — һәммәсен исәпкә алу кирәк иде. Салаватны «декабрь аенда — Сарапулны, гыйнвар башында Суксун заводын һәм Красноуфимскины алган», дип күрсәтү хакыйкатькә һич тә туры килми. Салават бүгенге «галимнәр» яки сәясәтчеләр тарафыннан «әвәләнгән» ясалма «җиңүләргә» мохтаҗ түгел. Фәкать үзе генә кылган батырлыклары өчен дә Салаватның исеме башкорт халкының тарихына алтын хәрефләр белән язылуга лаек. Шундый озак һәм урау юллар үткәннән соң, янә төп темага кайтыйк.*

Салават Красноуфимск каласына 1774 елның 12 гыйнварында килеп төшә. «Падишаһ»ның шәхсән үзе тарафыннан полковник дәрәҗәсен алган Салават, билгеле инде, походный старшина, йөзбашы булган мондагы командирларның җитәкчесенә әверелә. Икенче көнне үк, указлар һәм билгеләмәләр язып, ул шәһәр тормышына үзгәрешләр кертә башлый. Воевода Н. Бахматов, комиссар Д. Попов, вахмистр Я. Савинов, есаул Г. Овчинников, сәркатип М. Мальцев — һәммәсе дә урыннарыннан бушатыла һәм кулга алына. Красноуфимскидагы фетнәче казакларның атаманы һәм шәһәр идарәсенең башлыгы итеп Салаватны Котыш авылына барып каршы алган 19 яшьлек Макар Попов билгеләнә. Аның ярдәмчесе итеп Салават казаклар есаулы М. Чигвинцевны куя.

Красноуфимскида 3 көн торганнан соң, 15 гыйнварда Салават, үзенә буйсынучы С. Килтәков, С. Күзкәев, И. Иткулов, М. Попов отрядларын алып, Көнгергә юнәлә. Красноуфимскида фетнәче крестьяннарның башлыгы булып Уфа өязенең Себер юлындагы Кызылбай авылыннан (хәзерге Мәчетле районында, анда татарлар, мишәрләр һәм башкортлар яши) килгән һәм полковник дәрәҗәсенә ия булган Ишмән Иткулов (ул да документларда мулла дип телгә алына) калдырыла.

*Укучы, мөгаен, 9 гыйнвар көнне Красноуфимск каласын яусыз алган мишәр каһарманы Бәхтияр Канкаевның исемен югалткандыр. Әйе, 12 гыйнварда калага полковник дәрәҗәсендәге Салават килеп*

*төшкәч, Бәхтияр инде биредә җитәкче рольне үти алмый. Көнгер каласын штурмларга юнәлгән отряд командирлары арасында да аның исеме юк. Һәм, ниһаять, фетнәче төп көчләр Көнгергә киткәннән соң да, Красноуфимскида башлык булып бу каланы үзе килеп алган Бәхтияр түгел, бәлки аның якташы Ишмән Иткулов калдырыла. Бәхтияр ни өчен Салаваткa ияреп китмәгән? Һәм Салават ни өчен Бәхтиярның батырлыгын, олы җанлылыгын (Салаватны, «падишаһ» полковнигын чакыру өчен 110 чакрымдагы Котыш авылына М. Поповны махсус сәфир итеп юллавы һәм аның отрядын воевода Бахматов тарафыннан каршылауны оештыруы өчен нәкъ шулай дип кенә бәяләргә кирәк) күрмәгән дә, нигә аңа тиешенчә бәя бирмәгән? Югыйсә Бәхтиярны булдыксызлыкта, наданлыкта, куркаклыкта гаепләрлек бер мисал да юк. Хәтта, киресенчә, Бәхтияр әле алда да үзенең талантлы юлбашчы булуын күрсәтәчәк һәм санаулы гына кешеләр арасында Пугачев тарафыннан баш полковник яки бригадир (патша армиясендәге генерал һәм полковник арасындагы чин) дәрәҗәсе белән олыланачак бит. Шулай булгач, гыйнвар аенда Красноуфимскида Салават белән Бәхтияр арасыннан ни сәбәпле кара мәче узган соң?*

*Сәер бер документны телгә алырга мәҗбүрбез. Алдан ук кисәтик: анда язылган сүзләрнең байтагына ышану авыр, хәтта мөмкин түгел. Шул ук вакытта аны тоташ ялганнан гына тора, дип бәяләп тә булмый. Чөнки анда саналган күп кенә вакыйгалар (Санар заводы, Красноуфимскины алу, Ишмән Ишкуловның үлеме) хакыйкатькә туры килә. Документтагы бер генә исем яки фамилия дә уйлап табылмаган, димәк, бу кешеләрне күреп һәм сөйләшеп хакыйкатьне ачыкларга мөмкин булыр иде. Документта язылган вакыйгалар уйдырма булган очракта Бәхтиярны Пугачев тарафыннан җәза, хәтта үлем көтү мөмкинлеген дә онытмыйк. Әмма бу документ совет галимнәренең һәммәсе тарафыннан «ялa» дип бәяләнгән.*

*Без Бәхтияр Канкаевның февраль ахырында яки март башында Пугачевның Хәрби коллегиясенә язган хаты турында сүз алып барабыз. Бәхтияр бу хатта 1774 елның гыйнварында Красноуфимскида булган хәлләрне искә ала, һәм әлеге документ аның Салават Юлаев өстеннән язган шикаяте булып яңгырый:*

*«Шәһәрдән качып китмәсеннәр өчен, без крепость башлыгы Н. Бахматовны, комиссар Д. Поповны, отставкадагы атаман М. Калашникны, есаул Г. Овчинниковны кулга алган һәм богаулаган идек. Әмма Салават Юлаев белән Илчегол Иткулов һәм Сөләйман Күзкәев акча (выкуп) бәрабәренә аларны иреккә чыгардылар. Комиссар белән М. Калашник аларга йөзәр сум акча бирде. «Ник аларны азат итәсез?» — дип сорагач, алар минем кулымнан падишаһ биргән указны тартып алдылар һәм каравыл сагы астына утырттылар. Командирларның ул каракларны иреккә чыгаруын каладагы урыслар да ошатмады. Аннан алар, муеныма элмәк тагып, мине дарга асу белән янадылар. 12 сум акчамны, 2 атымны, 8 фузей һәм 2 төрек мылтыгын талап алдылар. Иреккә чыгарылганнан соң, теге караклар (Бахматов һәм башкалар) Көнгердәге хыянәтчеләр (ягъни карательләр) белән бәйләнешкә керделәр, солдатлар чакырдылар. Каракларны азат иткәндә, бу эштә Ишмән Иткулов та катнашкан, һәм ул да алардан 100—120 шәр сум акча алган иде. Хыянәтчеләр килгәч, шул караклар аның башына җитте» («Воззвания и переписка...» — Укучыга аңлашылсын өчен, өзек редакцияләнде һәм фамилияләр тулыландырылды).*

*Кабат кисәтәбез: без Бәхтияр Канкаев язган хатны хакыйкать дип якларга җыенмыйбыз. Әмма әлеге хат бер тарафны ачык исбатлый: 1774 елның гыйнварында Красноуфимскида торган чакта, Салават белән Бәхтияр арасыннан, чыннан да, кара мәче узган, алар бер-берсен гафу итмәс дәрәҗәдә ачуланышкан, бозылышкан бит. Моны алда язылачак документлар һәм булачак вакыйгалар да раслый. Бәхтияр үзе язган хат янына әле тагын Сидор Симонов дигән урыс крестьяны биргән бер кәгазьне дә терки. Анда старшина Юлайның, бил каешын салдырып, Сидорны асып үтерү белән янавы һәм 30 сум акча талап алуы хакында әйтелә. Бәхтияр үзе тагын апрель аенда һаман шул ук Илчегол Иткулов өстеннән дә атаман И. Белобородовка шикаять яза. Ул Илчеголны, исерек хәлдә бер авылга килеп, Бәхтияр отрядына кушылган фетнәчеләрне кыйнауда гаепли, «миңа кушылган крестьяннарны мәҗбүри рәвештә үзенең отрядына алып китә» дип раслый. Һәм тагын бер мөһим дәлил: кайбер тарихчылар Бәхтиярны «ул Пугачев явының кайсыдыр этапларында Салаваткa буйсынган» дип кичерәйтеп күрсәтергә тырышса да, монысы дөрес түгел. Юк, Бәхтияр берчакта да Салават Юлаевка буйсынмаган. Канзафар Усаев, Каранай Моратов, Качкын Самаров, Галибай Морзаголов шикелле үк, Бәхтияр да Салаваттан читтә хәрәкәт иткән. Бәхтияр белән Салаватның сугышчан юллары 1774 елның гыйнварыннан соң берчакта да кисешмәгән.*

*Ә шулай да Салават белән Бәхтиярны ызгыштырырлык берәр нинди нигез булганмы соң? Пугачев явы башында әлегә алар күренми. Ә инде тарихның алдагырак сәхифәләренә мөрәҗәгать итсәк, алар бар да сыман. Әйтик, 1735—1740 елларда шаулап узган Акай-Килмәк явы. Бу чорда байтак кына мишәр старшиналары һәм алар туплаган отрядлар фетнәчеләргә каршы сугышып йөргән. Шушы тугрылыклары өчен хөкүмәт Уфа провинциясендә мишәр старшиналарының һәркайсына — 200, йөзбашларына — 100,*

*рядовой карательләргә 50 шәр дисәтинә җир бүләк итеп биргән. Моннан тыш җәза отрядларында йөргән мишәрләргә яуда үтерелгән фетнәченең байлыгын үзләштерергә, хатыннарын һәм балаларын коллыкка алырга рөхсәт ителгән (И. Акманов, А. Чулошников). Мишәрләр 1747 елга кадәр казнага бер төрле дә салым түләмәгән яки башкорт җирбиләүчеләренең үзенә дә эләкмәгән өстенлекләрдән файдаланган. Әйе, тарих битләрен актара башласак, Салаватта мишәр вәкиле Бәхтиярга карата үч тупларлык нигез бар да кебек. Әмма үткәнгә карап кына фараз кылсак, бу фәнни дәлил белән нигезләнгән хезмәт булмаячак. Шуңа күрә без Красноуфимск каласында туган бер күренешне билгеләп үтик. Салават белән Бәхтиярның уртак тел тапмавы, хәтта бозылышуы — бу Красноуфимскида хасил булган киеренке хәлнең бер мисалы гына. Иң яманы: нәкъ Уфа янындагы шикелле үк монда да төрле милләт вәкилләре арасында кискен каршылыклар килеп чыга. Башкорт отрядлары урыс авылларын, урыслар мөселман йортларын талый башлый. Мондый хәл турындагы хәбәр Чесноковкадагы Зарубинга барып җитә. Ул тиз арада биргә фетнәгә кадәр Табын крепостенда казак булып хезмәт иткән, яу башында зур батырлыклар күрсәткән Иван Кузнецовны юллый. Кузнецовка «бөтен урыс һәм азиат гаскәрләренең юлбашчысы» дигән дәрәҗә бирелә. Ул әлегә юлда. Ә без Красноуфимск каласына кайтыйк. Һәм әлегә ятлап куйыйк: Бәхтияр Канкаев биредә Ишмән Иткулов атлы полковник буйсынуында кала. Салават Юлаев 19 гыйнварда Көнгер каласы янына барып җитә.*

Көнгерне камалышта тотучы Батыркай Иткинин, Канзафар Усаев белән Салават отрядлары Старопосадское (Троицкое) һәм Тихановское авылларында бергә кушыла. 19 ы көнне үк отряд җитәкчеләре, Көнгерне саклаучы гарнизонга атап, белдерү язалар, офицер һәм сәүдәгәрләргә «падишаһ» гаскәре каршында нәкъ Красноуфимск каласы кебек үк тез чүгәргә тәкъдим итәләр. Белдерүгә Салават Юлаев, Канзафар Усаев, Илчегол Иткулов, Сөләйман Күзкәев, Гадел Бигашев, Макар Попов кебек отряд башлыклары кул куя («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Хатны шәһәргә Красноуфимск казагы И. Дружинин алып китә *(И. Гвоздикова)*. Көнгердәге офицерлар аны шундук төрмәгә ябалар, фетнәчеләргә җавап кайтармыйлар.

20 гыйнвар көнне Көнгер янына Зарубин җибәргән «юлбашчы» И. Кузнецов килеп җитә. Ул да шәхсән үз исеменнән хат яза, «мин» алмашлыгын бик еш куллана, гарнизонга монда тупланган 15 мең (билгеле, арттыра инде, чынында исә 4 мең чамасы крестьян, шуның 1000 гә якыны гына урыслар була) кешелек гаскәр белән яный. Шунысы гаҗәп: Кузнецовның хатына Канзафар Усаев та, Илчегол Иткулов белән Сөләйман Күзкәев тә кул куймый. Гарнизон Кузнецов хатына да җавап бирми.

23 гыйнварда Көнгерне беренче мәртәбә күмәк көч белән штурмлау башлана. Фетнәчеләр, икегә бүленеп, Монастырское, Вознесенское авыллары ягыннан һөҗүм итәләр. Крестьяннар кулында булган 17 тупның һәркайсы кала өстенә 35 әр ядрә очыра. Кайбер урыннарда шәһәр стеналары һәм капкалар җимерелә, ядрәләр урамнарга төшеп шартлый. Фетнәчеләр, озын чылбыр сыман тезелеп, шәһәр стеналарын штурмлый. Һөҗүм иртәдән кичке караңгыга кадәр дәвам итә. Ләкин воевода Миллер һәм секунд-майор Папава отрядлары каланы уяу саклыйлар. Фетнәчеләр чигенә.

24 гыйнварда Канзафар Усаев белән Салават отрядлары тагын бер мәртәбә шәһәр стеналарына һөҗүм ясап карый. Ләкин яу барышында Салаватның аягы пуля тиеп авыр яралана *(И. Гвоздикова)*. Башка бик күп галимнәр тарафыннан, Салават 23 е көнне яраланган, дип күрсәтелә, моны карательләр кулына әсирлеккә эләккән С. Килтәков та раслый. Әмма без, барыбер, 24 гыйнвар дип алдык әле.

Отряд командирлары яңа штурмны 26 гыйнварга билгелиләр. Әмма нәкъ менә 26 гыйнварга каршы төндә Көнгер янына секунд-майор Д. Гагрин командалыгындагы 400 кешелек карательләр отряды килеп җитә һәм шәһәргә уза. Яңа отряд өстәлгәч, билгеле инде, гарнизонның сугышчанлыгы көчәя. 26 гыйнвар таңында фетнәчеләрнең шәһәргә һөҗүме бик сүлпән башлана. Булган ядрәләрен 23 гыйнвар көнне атып бетергәнгә күрә, бу юлы туплар дәшми. Иван Кузнецов, Г. Кашин исемле чапкын җибәреп, Салаватны җебегәнлектә гаепли, аннан кискен һөҗүм таләп итә. Канзафар Усаев тарафына да шундый ук ризасызлык белдерелә. Ләкин туктаусыз рәвештә туплардан ядрәләр атып торган шәһәр стеналарын сөңге-уклар белән генә штурмлап булмый. Һөҗүм нәтиҗәсез төгәлләнә.

Алган ярасы азып китү сәбәпле авырый башлаган Салават Юлаев 26 гыйнварда үзенең туган төбәгенә — Тәкәй авылына кайтып китә («Документы ставки Е. И. Пугачева...», «Крестьянская война... на территории Башкирии»; *Муратов, Панеях, Мавродин, Лимонов*). Үз урынына башкорт крестьяннарының җитәкчесе итеп фетнәгә кадәр Уса юлының Гайнә волостенда 2 ел буе старшина булып торган 35 яшьлек Чүрә Рәсүловны калдыра.

Хәзер без сезнең игътибарны тагын бер сәер вакыйгага юнәлтергә мәҗбүрбез. Чесноковкадагы Зарубин тарафыннан «бөтен урыс һәм азиат гаскәрләренең юлбашчысы» булып озатылган И. Кузнецов 26 гыйнвар көнне «падишаһ» полковнигы Канзафар Усаевны кулга ала («Документы ставки Е. И. Пугачева...» китабында И. Кузнецов К. Усаевны 25 е көнне кулга ала һәм үзе Чесноковкага китә дип күрсәтелә. Әмма

безнең кул астында Кузнецовның 26 гыйнвар иртәсендә С. Юлаевка язган хаты бар — «Крестьянская война... на территории Башкирии»). Ул аны М. Попов авырый башлаганнан соң, Красноуфимск казакларының башлыгы итеп куелган һәм үзе белән Көнгер янына килеп төшкән М. Мальцев кулына тапшыра. Ә Кузнецов үзе Зарубиннан ярдәм сорау өчен Чесноковка лагерена китеп бара (без аның соңрак, 13 мартта Бакалы янындагы бәрелештә һәлак булуы турында әйттек инде).

*Полковник кадәр полковникның кулга алынуы — фетнәче крестьяннар армиясендә булган шактый сәер хәл (дөрес, моңа охшаш вакыйга Исет провинциясендә, хәзерге Екатеринбург өлкәсе җирендә дә булган. Анда фетнәчеләр атаманы И. Белобородов, туктаусыз эчүчелек белән шөгыльләнгән һәм авыллар талап йөргән өчен, Җаек казагы, полковник И. Шибаевны кулга ала. Соңыннан инде Мамадыш авылында Пугачев Шибаевны дарга астыра). Бу вакыйга төрле милләт вәкиле һәм төрле хәрби дәрәҗәгә ия булган хәрби җитәкчеләр арасында каршылыкларның кайчакларда шактый кискен төс алуы турында сөйли.*

*Кузнецов һәм Канзафар арасындагы каршылыкның сәбәпләрен тарихи документлар буенча ачыклау мөмкин түгел. Әлеге каршылыкның Кузнецов Көнгер янына килеп төшкән беренче көнне үк башлануы да мөмкин. Чөнки Көнгер каласына бикләнгән гарнизон өчен 20 гыйнвар көнне Кузнецов язган белдерүгә Канзафар кул куймый. Шулай ук анда башка отряд командирлары булган Батыркай Иткинин, Илчегол Иткулов, Сөләйман Күзкәевнең дә куллары юк. Кузнецов —Чесноковкадагы Зарубин тарафыннан Көнгер янына барлык милләт командирларын да дуслаштырырга, ызгышларны туктатырга дип озатылган кеше. Көнгер янына килеп төшкәч, әллә ул үзен текә, кискен һәм тәкәбберрәк тотканмы? Әллә «падишаһ»ның шәхсән үзе тарафыннан полковник дәрәҗәсен алган Канзафар Чесноковкадагы Зарубин (гына!) «юлбашчы» итеп озаткан Кузнецов каршында бил бөгәргә теләмәгәнме? Әллә Көнгерне штурмлау өчен Кузнецов тәкъдим иткән сугышчан планны Канзафар бөтенләй яраксыз дип санаганмы? Бу сорауларга җавап табуы читен. Әмма Кузнецов Көнгер янына тупланган отряд командирлары, мөселманнар белән уртак тел таба алмый. Монысы бәхәссез. Кузнецов, чапкын юллап, Салаватны да кыюсызлыкта гаепли. Димәк, отряд командирлары арасында алдан ук беркетелгән катгый килешү, төгәл план булмый. Шуңа күрә Көнгерне 2—3 мәртәбә штурмлау да сүлпән һәм таркау бара. Ә ахырда инде Кузнецов Канзафарны кулга ала, үзе шикаять белән һәм ярдәм сорап Зарубин янына китә (кача?). Көнгерне яулый алмавы өчен гаепне шулай мөселман командирларына (Кузнецов Канзафардан башка тагын бер җитәкчене кулга ала, аның исем-фамилиясе билгесез) аударырга җыенуымы бу аның, әллә инде, чыннан да, бу очракта ул үзенең көчсезлеген таныймы? — моны аңлап булмый. Ә нәтиҗәдә Көнгер янына тупланган 4 мең крестьян зур хәрби дәрәҗәгә лаек булган 3 җитәкчесез (Салават, Канзафар, Кузнецовсыз) кала. Әлеге вакыйга исә фетнәчеләрнең тиздән тар-мар ителүендә сизелерлек бер фактор булып тора.*

Көнгер  крепостена бикләнгән гарнизон А. Папава һәм Д. Гагрин командалыгында каладан чыга. 30 гыйнвар көнне карательләр Ильинское (икенче исеме Ордынское) авылында торган фетнәчеләргә каршы юнәлә. Башкорт отрядларының җитәкчеләре итеп калдырылган Чүрә Рәсүлов һәм Собхангол Килтәков карательләр белән яуга керергә теләмиләр. Шуның өчен аларны 20 гыйнварда Кузнецов белән бергә Көнгер янына килеп төшкән Иван Суконников (ул Чесноковкада Зарубинның сәркатибе була) кулга ала һәм Суксун заводына илтеп бикли. (Атаман М. Мальцевның 1 февральдә Чика-Зарубинга язган рапортына караганда, Ордынское авылы янындагы яуда башкортлар да катнашмый. Алар Мальцевка буйсынырга теләмиләр һәм Суксун заводына чигенәләр. — «Документы ставки Е. И. Пугачева...».) Иректә калган отряд командирлары Гадел Бигашев, Сөләйман Күзкәев һәм башкалар ныклы оборона оештыра алмый. Папава һәм Гагрин карательләре фетнәче отрядларны тар-мар итә, 113 крестьян һәлак була («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Суконников яңадан, карательләрне җиңгәннән соң килеп дарга асарга «вәгъдә» иткән Чүрә Рәсүлов белән Собхангол Килтәков подвалга бикләнгән хәлдә Папава һәм Гагрин кулына төшәләр. 17 февральдә әлеге старшиналарның икесен дә Көнгер каласында дарга асалар («Крестьянская война... на территории Башкирии»).

Тар-мар ителгән крестьяннарның отрядлары Красноуфимск каласына чигенә. Аларның эзенә басып карательләр отряды килә. 19 февраль көнне тагын яңа һәм аяусыз бәрелеш була. Монда полковник Ишмән Иткулов белән Бәхтияр Канкаев отрядлары да катнаша. Ләкин бу юлы да крестьяннар тар-мар ителә. Ишмән хыянәтчеләр кулыннан һәлак була. Командирлар, үзләренең отрядларын алып, туган якларына тарала башлый. Башкорт старшиналарыннан Илчегол Иткулов — үзенең Кущин волостена, Алахуҗа Бакынов, Миндияр Арукаев — Дуванеи, Өметәй Үрәзембәтев Сарт волостьларына кайтып китә («Крестьянская война... на территории Башкирии»).

Карательләр 19 ы көнне Красноуфимскига керә. Пугачевны «падишаһ» дип таныган, фетнәчеләргә ярдәм күрсәткән кешеләр кулга алына. (Аларның алдагы язмышын да әйтеп үтик. 19 яшьлек М. Попов 1774 елның 22 маенда 100 мәртәбә чыбыркы белән суктырыла, яңагына «мөһер» салына һәм сөргенгә

озатыла. Поповтан соң Красноуфимскидагы фетнәче казакларның атаманы булып йөргән М. Мальцевны 1774 елның май ахырында, атаман ярдәмчесе М. Чигвинцевны 15 ноябрьдә Көнгер каласында асып үтерәләр. Крепость коменданты яки шәһәр воеводасы поручик Н. Бахматов Екатерина II указы буенча рядовой дәрәҗәсенә төшерелә. Хәтта «тугры» казаклар есаулы булып торган Григорий Овчинников та җәзасыз калмый. 1774 елның 22 июнендә 50 тапкыр чыбыркы белән суктырылганнан соң, ул сөргенгә озатыла. — «Документы ставки Е. И. Пугачева...».)

*Мишәр каһарманы Канзафар Усаевның язмышын да ачыклап үтик. И. Кузнецов кулга алганнан соң, ул 30 гыйнварга кадәр Алтынное авылында тотыла. Әмма шуннан соң М. Мальцев тарафыннан Чесноковка лагерена озатылган Канзафар юлда ниндидер хәйлә белән качуга ирешә. Ул хакыйкатьне эзләп Зарубин янына барып тормый, ә туп-туры Бирдәгә Пугачев янына юнәлә. Күрешеп аңлашканнан соң, Пугачев янә аны 7 иптәше белән бергә Уфа төбәгенә И. Белобородовка отряд туплауда ярдәм итү өчен озата. Канзафар 23 мартта Чесноковкага Зарубин янына килеп төшә. Ә шуның икенче көнендә Чесноковка лагере тар-мар ителә, Канзафар Михельсон карательләре кулына эләгә. Михельсон аның кем икәнлеген дә, кылган эшләрен дә тикшереп тормый. Аның ялган үкенү һәм антларына ышанып, ул Канзафарны азат итә. 5—10 апрельләр тирәсендә Канзафар туган авылы Бозаязга кайта һәм, «янарал Фрейман шулай кушты» дип, мишәр старшиналары Мөхсин Әбдесәламов белән Ишмөхәммәт Сөләймановтан (имеш, карательләргә ярдәмгә) 500 кешелек отряд таләп итә. Әмма мишәр старшиналары бу вакытта инде генерал Фрейманнан, Канзафар пәйда булган очракта аны карательләргә тапшырырга дип, фәрман алган була. Канзафар кабат кулга алына һәм Уфага озатыла. Ләкин кайсыдыр чуваш авылына җиткәндә, Канзафар богауларыннан ычкына һәм тагын кача. Бу утта янмас, суда батмас каһарман санаулы гына көннәр эчендә 200 кешелек яңа отряд туплауга ирешә, үзенең ярдәмчесе итеп ясаклы татар крестьяны Аллакул Акаевны билгели. Апрель ахырында, май башында Канзафар Ногай һәм Себер юлындагы волостьларда хәрәкәт итә, үзенең отрядына яңадан-яңа сугышчылар туплый. 5 июньдә «падишаһ» тарафыннан баш полковник дәрәҗәсе бирелә («Документы ставки Е И. Пугачева...»; Ә. Әсфәндияров).*

Сөйләм барышында без шактый алга киттек. Ә Кузнецов кулга алганнан соң, командирсыз калган, Канзафар туплаган беренче отряд турында без оныттык. 30 гыйнварда Ордынское авылы янында җиңелгәннән соң, Канзафар отряды да Красноуфимск каласына таба чигенә. 10 февральдә әлеге отряд Ачыт крепосте янында карательләр белән тагын бер мәртәбә бәрелешә. Әмма фетнәчеләр тар-мар ителә, крепость Папава һәм Гагрин карательләре кулына эләгә. 19 февральдә Красноуфимск янында булган яуда да усаевлылар җиңелә. Отрядның бер өлеше туган авылларына тарала, бер өлеше Чесноковкадагы Зарубин гаскәренә барып кушыла. Көнгер янында яу чыгып йөргән мишәр старшинасы Сөләйман Күзкәев, Уса юлыннан килгән Гадел Бигашев отрядлары да шундый ук язмышка дучар була. Карательләрнең аяусыз һөҗүме нәтиҗәсендә Красноуфимск һәм Көнгер тирәсендә тупланган фетнә отрядлары куып таратыла.

Бәхтияр Канкаев үз отряды белән Себер юлына чигенә. Яулардан соң сан ягыннан кимегән крестьяннарны Бәхтияр йөзбашлары Габделкәрим Күзкәев, Йосыф Юнысов карамагына калдыра. Ә үзе Бирдә бистәсенә Пугачев янына китә.

Инде мәгълүм: карательләр 19 февральдә Красноуфимскины ала, фетнәче 4 мең кеше куып таратыла. Крестьян отрядлары Уфа елгасы буйлап чигенә, нигездә татарлар яшәгән Урта Богалыш авылы (Ленин һәм Сталин аны Екатеринбург өлкәсенә «бүләк» иткәннәр) фетнәчеләр лагерена әверелә. Озакламый бирегә Көнгер янындагы сугышта алган ярасыннан савыккан Салават Юлаев әйләнеп кайта.

Бу вакытта Красноуфимск карательләр тарафыннан саксыз кала. Секунд-майор Д. Гагрин атаман И. Белобородов артыннан куып йөри. Подполковник А. Папава Көнгер каласына кайтып киткән була. Салават Юлаев менә шушы уңайлы очрактан файдаланып калырга ашыга. 2000 кешелек гаскәр алып, ул Красноуфимскига юнәлә һәм 12 мартта бернинди каршылыксыз рәвештә аңа барып керә. Әмма бу хәл Көнгергә билгеле була, һәм 14 мартта Красноуфимск янына янә Папава отряды килеп җитә. Фетнәчеләр Папаваны шәһәр читендә каршылыйлар. Канлы яу башлана. Салават отрядында 21 крестьян һәлак була, 26 сы әсирлеккә эләгә (24 се шул ук төндә «яралардан» үлә). Фетнәчеләр Богалыш авылына чигенә, Папава аларны куа килә. 17 мартта биредә яңа бәрелеш була. Бу юлы яуга кергән мең ярым крестьянның 36 сы һәлак була, 8 кеше карательләр кулына төшә («Крестьянская война... на территории Башкирии»). Яудан соң, билгеле, крестьяннарның бер өлеше туган якларына качып китә. Сан ягыннан шактый кимегән Салават отряды Әй елгасы артына чигенә. Салават үзе һаман яңа көчләр туплау белән шөгыльләнә. Шул максат белән, ул йөзбашы Иләтбай Илембаевны 23 мартта Уса юлына озата. Иләтбай 135 сугышчы туплый һәм апрель аенда Салават янына әйләнеп кайта. Ул «падишаһ казагы» булырга теләмәгән крестьяннарга каршы тәвәккәл эш итә. Шундый 60 крестьян 17 апрельдә Бырма авылында бикләп тотыла («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Апрель аенда Уса, Себер юлларында да фетнә хәрәкәте сүлпәнәя. Моның өч сәбәбен күрсәтергә мөмкин: 1. Бу төбәктә крестьяннар Гагрин һәм Папава карательләре тарафыннан берничә кат тар-мар ителә. 2. Пугачевның 22 мартта Татищев крепосте, 2 апрельдә Сакмар шәһәрчеге янында, Зарубинның 24 мартта Чесноковкада тар-мар ителүләре крестьяннарда төшенкелек уята. 3. Апрель аенда боз кузгалу, елгалар ташу нәтиҗәсендә, юллар бикләнә. Соңгы фактор фетнәчеләргә дә, карательләргә дә вакытлыча тын алырга җай тудыра.

Уфа провинциясендә кузгалган фетнә хәрәкәте турында хикәятебезне шушы урында туктатып торыйк. Шактый ерак төбәкләргә дә күз саласыбыз бар.

# ИСЕТ ПРОВИНЦИЯСЕ. УРАЛ, СЕБЕР

«Урал», «Себер» сүзләрен телгә алгач, бүгенге укучының «Автор Пугачев явы турында тулысынча сөйләргә җыена түгелме соң?» дигән сорау куюы мөмкин. Татарлар турында гына язуга алынгач, ерак төбәкләргә, бүтән отрядларга кагылмас идек тә бит, әмма чарабыз юк. Чөнки, беренчедән, Пугачев фетнәсе — ул болай да яртылаш диярлек татар явы. Икенчедән, Рәсәйдә татар барып җитмәгән, татар төпләнмәгән бер төбәк тә юк. Өченчедән, Пугачев фетнәсе дәвамында татар катнашмаган берәр яу, составына татар кермәгән берәр отряд гомумән булды микән? Болай дип раславыбыз дәлилсез сүз булып калмасын өчен, әүвәл ике генә мисал китерик.

1774 елның 15—20 март көннәре тирәсендә Курган янында Иван Илекәев исемле татар (керәшенме, түгелме — билгесез) есаулы һәм атаман Семен Новгород кул астында 3000 кешелек отряд хәрәкәт итә. Аларга каршы Курганнан капитан Смольянинов командалыгындагы 1200 кешелек карательләр отряды юлга чыга. Әмма солдатлар юлда Смольяниновны әсирлеккә алалар, аны Илекәев кулына тапшыралар. 1200 солдат тулысынча крестьяннар ягына чыга. Фетнәчеләр Курган каласын ала. 24 март көнне бирегә карательләрнең яңа отряды килеп җитә. Аяусыз бәрелештән соң гына, карательләр Курган шәһәрен кабат кулга төшерә *(Х. Муратов)*.

1774 елда Сарайчык крепосте янында (ә бу инде Казахстан җирендә!) хәрәкәт иткән 500 кешелек казах (казах кына микән?) отряды белән Хәсән Мостаев атлы татар җитәкчелек итә. Хәсән фетнәгә кадәр Җаек казагы булган. Күрәсең, ул Казахстанга отряд туплау, бу төбәктә дә фетнә учагы кабызу өчен Пугачев тарафыннан махсус озатылгандыр. Хәсән озак вакыт буена Сарайчык крепостен камалышта тота (*С. Алишев*. «Татары...»). Әлеге ике җитәкче турында да өстәмә мәгълүматлар табып булмый. Себергә һәм ерак Казахстанга барып җиткән шушы ике җитәкченең үрнәге генә дә татар халкының өлгерлеге, каһарманлыгы турында сөйли. Без бүтән дәлилләр китереп тормыйк, Урал тирәсенә кайтыйк әле.

Инде язган идек: Оренбург губернаторы И. Рейнсдорп тарафыннан 5000 кешелек татар-башкорт гаскәре туплау турында фәрман булгач, секунд-майор П. Демидов Исет провинциясендә 469 җайдаклы отряд җыйнаса да, андагы татар-башкортлар «падишаһ»ка каршы чыгудан баш тарта һәм Урал тауларына кача («Крестьянская война... на территории Башкирии»). Октябрь аенда Уралдагы заводларга йөреп эшләүче, шул төбәктәге авылларда яшәүче крестьяннар да аерым отрядлар оештыра башлый. Ә Урал заводларында бүгенге Татарстан җирләреннән йөреп эшләүче крестьяннар да аз булмый. Әйтик, 1760 елларда ук инде Лаеш, Чистай, Мамадыш, Казан өязләреннән Кама, Агыйдел елгалары буендагы, Урал тауларындагы заводларга беркетелгән крестьяннарның саны 25 меңнән артып китә. Аларның зур өлеше И. Твердышев һәм И. Мясниковның Воскресенск һәм Богоявленск (хәзер Красноусольск), Е. Демидовның Авзяно-Петровск, граф Сиверсның Вознесенск (хәзер Ыргызлы), Н. Демидовның Каслинск заводларына йөреп эшли *(А. Чулошников, В. Мавродин)*.

Җаек буенда «падишаһ» пәйда булу, аның Оренбургны камавы турындагы хәбәрне алгач, Урал заводларындагы крестьяннар махсус эмиссарлар да көтеп тормыйлар, үзләре үк фетнәгә кушылалар. Октябрь башында Богоявленск заводындагы крестьяннар баш күтәрә. Бөлгенлеккә төшкән Сембер сәүдәгәре Иван Грязнов (аның турында икенче төр мәгълүматлар да бар: ул — раскольник, ягъни христиан динен искечә тотучы) крестьян фетнәчеләрнең җитәкчесенә әверелә. 12 октябрьдә Воскресенск заводындагы крестьяннар фетнәгә кушыла. Фетнәчеләрнең җитәкчесе Григорий Туманов атлы кеше була.

*Әлеге шәхеснең исемен төүге тапкыр телгә алуга ук без беркадәр тайпылыш ясарга телибез. Бу каһарман фетнә ахырында эзсез югала. Архивларда аның фетнәгә кадәр кем булуы, нинди эш белән шөгыльләнүе, ниһаять, милләте турында анык сөйләүче тарихи документлар сакланмаган. Ул фәкать Твердышев заводына (кайсы заводка икәне ачык түгел: «Документы ставки Е. И. Пугачева...» китабын төзүчеләр аны — Воскресенскига, Ю. Лимонов исә — Богоявленскига) беркетелгән крестьян, дип кенә искә ала, кайбер мәгълүматлар, аны әле мастеровой, әле завод тирәсендә эшләүче тылмач, дип күрсәтә. Әмма*

*шунысы төгәл билгеле: Туманов татар һәм урыс телләрен яхшы белә, казах отрядлары белән хат алыша. Аның кулы белән язылган документлардан Тумановның гаять укымышлы, тарихны тирән белүче кеше икәнлеген, тормышны күп күргәнлеген ачыклап була. Татар вәкилләренең тирән белемле булулары һәм телләр белү ягыннан гасырлар дәвамында башка мөселманнардан аерылып торуы һәркемгә мәгълүм. Шуңа күрә бездә, нигезле рәвештә, «Туманов яңа (1731 елдан соң) чукынган татар булмадымы икән?» дигән сорау туа. Безне мондый нәтиҗәгә этәрерлек мисаллар да бар. Яр Чаллы шәһәренә терәлеп диярлек торган Кече Шилнә авылы крестьяннары, мәсәлән, Демидовның Авзяно-Петровск заводына беркетелгән була. Фетнә башлангач, бу авылдагы крестьяннарның йөзбашы булып чукынган татар вәкиле Григорий Артемьев йөри (Х. Муратов). Фетнә башланган чагында Татарстандагы Елантау, Чистай, Круглое Поле, Шилнә авылларыннан Авзяно-Петровск заводына йөреп эшләүче чукынган татар крестьяннары да аз булмый («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).*

Туманов җитәкчелегендәге крестьяннар 12 октябрьдә Воскресенск заводы идарәсенә ташлана. Администрация каршылыгы сындырыла. Завод идарәчесе прапорщик Кулалаев йорты белән бергә яндырыла. Байтак кына дары һәм мылтыклар, 30 мең сум акча фетнәчеләр кулына төшә. Заводтагы 600 крестьян фетнәчеләр сафына баса («Крестьянская война... на территории Башкирии»). Грязнов һәм Туманов отрядлары бергә кушылалар. Ноябрь аенда Грязнов Бирдә бистәсенә бара һәм Пугачев тарафыннан полковник дәрәҗәсенә лаек була.

Яңа заводлар яулап алу, аларда армия өчен туп коюны җайга салу, өстәмә отрядлар туплау максатыннан, Бирдәдәге Пугачев та төрле якка махсус эмиссарлар юллый башлый. Мондый җаваплы эш элеккеге каторжан Афанасий Соколовка (кушаматы — Хлопуша) да йөкләнә. Гаять катлаулы һәм газаплы тормыш юлын кичергән Хлопуша крестьяннар явы башланган көннәрдә Оренбург төрмәсендә богауланган хәлдә тотылган була. Крепость артыннан крепость яулап, Пугачев Оренбургка якынлаша башлагач, губернатор Рейнсдорп әллә ничә еллар буена сөргеннәрдә һәм рудникларда газап чиккән шушы тоткынны чакыртып ала. Богауланган килеш рудниктан иреккә качуы өчен Хлопушаның инде борынын да кискән булалар. Кыяфәте белән үк дәһшәт бөркеп торучы шушы тоткын ярдәмендә Рейнсдорп Пугачев явын тиз һәм җиңел генә бастырырга хыяллана. Ул Хлопушага фетнәчеләр арасына үтеп керергә, Пугачевны кулга алырга һәм аны Оренбургка алып килергә тәкъдим ясый. Шундый «тугрылыгы» өчен Хлопушага ирек вәгъдә итә. Хлопуша «ризалаша». Губернатордан казакларны акылга килергә чакырган 4 хат ала да 30 сентябрь көнне фетнәчеләр ягына юнәлә (сүз уңаенда өстик: аны Пугачев штабына кадәр Муса исемле татар алып бара. — *С. Алишев*). 2 октябрьдә Хлопуша Сакмар шәһәрчегендә «падишаһ» белән очраша, аңа Рейнсдорп казакларга дип биргән хатларны тапшыра. Пугачев Хлопушаның тугрылыгын югары бәяли. 14 октябрьдә ул Оренбургтан 330 чакрымда урнашкан Авзяно-Петровск заводына озатыла. Бу заводта Демидовның шәхси 274 колы эшли, ә 3708 крестьян Казан провинциясендәге авыллардан килеп газап чигә *(Н. Дубровин)*. «Падишаһ» указы буенча 22 октябрьдә килеп төшкән Хлопушаны завод эшчеләре колач җәеп каршылый. Приказчиклар М. Копылов, Д. Федоров, В. Набатов белән аларның тагын 3 ярдәмчесе кулга алына һәм Бирдә бистәсенә «падишаһ» хөкеменә озатыла (алар ноябрьдә Бирдәдә дарга асыла). Заводтагы 6 туп, 120 ат, 7 мең сум акча «падишаһ казнасы»на алына (*В. Буганов.* «Крестьянские войны...»). Казан өязенең Котловка, Елантау, Чистай, Ачы, Балыкчы, Круглое Поле, Шилнә, Шәле, Кармалы һәм башка авылларыннан килеп заводта эшләүче крестьяннарның бер өлеше 23 октябрьдә туган якларына кайтып китә («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Ә калганнарыннан 500 кешелек «падишаһ» полкы төзелә, һәм Хлопуша кул астында алар Бирдә лагерена юнәләләр. Хлопуша төзегән отрядта Чүпрәле, Бездна, Кәкерле һәм башка авыллардан килгән Мәхмүтов, Сәлиев, Моисеев, Габдерәзәков, Мирсәлимов, Рәҗәпов, Габдрахманов, Бикмәтев, Яковлев, Бибиков, Бәхтияров кебек йөзләгән татарлар да була *(С. Алишев)*. Шушы отряд 8 ноябрь көнне Биккол, Йөзәй авыллары янында А. Овчинников, Чика-Зарубин җитәкчелегендәге фетнәчеләр гаскәренә кушыла һәм генерал В. Кар карательләренә каршы яуга керә.

Тиздән Казан провинциясендәге авыллардан татар крестьяннары барып эшләгән башка заводларда да фетнә ялкыны кабына, мондый хәрәкәт бөтен Уралны чолгап ала. Уралдагы 84 заводның күпчелеге фетнә барышында Пугачев ягына чыга. Иван Белобородов отряды гыйнвар — февраль айларында бер-бер артлы Билимбай, Ревда, Түбән һәм Югары Шайтан, Уткы, Каменск заводларын, Бисерт, Кленов, Гробовская крепостьларын, Чусовка бистәсен ала. Крестьяннар үзләренә каршы җибәрелгән капитан Ерапольский, поручик Костин, сержант Курлов командалыгындагы җәза отрядларына каршы торалар. Белобородов отряды сан ягыннан ишәя, ул нигездә урыс һәм татар крестьяннарыннан тора. (Сүзебезне раслау өчен янә бер дәлил китерәбез. Гыйнвар ахырында Белобородов Пугачев янына Бирдәгә 10 кешелек делегация озата. Ул 5 завод эшчесеннән, 4 татардан һәм әсирлеккә төшкән 1 «казак»тан тора. Шулар «падишаһ»ның шәхсән үзе тарафыннан Белобородовка атаман дәрәҗәсе бирелү турындагы указын алып кайталар. — *Ю. Лимонов.*) Белобородов башка күп кенә командирлар кебек милләтләрне аерым йөзләргә түгел, бәлки

һәрбер йөз эчендәге кечкенә командаларга бүлә. Ул милләтара ызгыш-талаш чыгармау өчен күп тырышлык куя. Февраль уртасында Белобородов отряды инде Екатеринбургның үзенә дә яный башлый. Шуңа күрә Себердәге чик буе гаскәрләренең башлыгы генерал-поручик И. Деколонг аңа каршы секунд-майор Фишер командалыгындагы ике рота солдатны юллый. Фишер командасына поручиклар Озеров, Костин отрядлары, Уралдагы казна заводларының идарәчесе полковник В. Бибиков биргән «ирекле» казаклар да өстәлә. Шул күмәк көч белән Фишер 14 февральдә Шайтан заводын ала. Бистәдәге 1500 кешене каравыл астында Фишер Екатеринбургка озата. Ә Белобородов отрядының базасы булып торган заводны шушы каратель үзе ут төртеп яндыра. 26 февральдә Уткы заводына Көнгер ягыннан килгән Д. Гагрин отряды да бәреп керә. Һәр ике заводта йөзәрләгән (соңгысында 895.— *В. Буганов*) фетнәче крестьян әсирлеккә төшә.

29 февраль көнне Белобородов 425 кешелек отряд белән Уткы заводын янә үз кулына төшерергә тырышып карый, әмма Гагрин фетнәчеләрне куып тарата. Март башында Багаряцкая бистәсе, Евчугово авылы янында булган аяусыз бәрелешләр дә фетнәчеләр өчен уңышсыз тәмамлана. Белобородов Көньяк Уралга таба чигенә, аның эзенә Гагрин басып килә. 12 мартта Каслинск заводы янында яңа бәрелеш була, крестьяннар арасыннан 57 кеше юк ителә, 420 фетнәче әсирлеккә эләгә. Белобородов инде Сатка заводына чигенеп урнаша. Төньяк һәм Урта Уралдагы фетнә хәрәкәте март ахырында шул рәвешчә кими *(Ю. Лимонов, В. Буганов).*

Октябрь аенда ук Көньяк Урал заводларындагы эшчеләр арасында башланган фетнә дә әүвәл күтәрелеш чорын кичерә. Пугачев тарафыннан атаман һәм полковник дәрәҗәләрен алган Иван Грязнов, аның ярдәмчесе итеп билгеләнгән Григорий Туманов ноябрь аенда Сатка һәм Златоуст заводларына озатыла. Юлда барганда ук, Грязнов һәм Туманов үзләренең кул астына 300 крестьян җыялар. Златоустта аларга тагын 200 кеше кушыла. Декабрьдә Кыштым заводы эшчеләре баш күтәрә. Заводны фетнәчеләрдән саклау өчен озатылган җәза отрядларының командирлары майор Чубаров белән подпоручик Кологривов кулга алына һәм богаулап куела. Заводтагы 60 мең сум акча фетнәчеләр кулына төшә, крестьяннарның бурыч кәгазьләре юкка чыгарыла. Фетнәчеләр үзләренең командирларын да сайлап куялар. 3 гыйнварда инде Грязнов белән Туманов та Кыштым заводына килеп җитә. 4 гыйнварда Кундрава бистәсендә фетнә куба. Җәза отрядындагы солдатлар крестьяннар ягына чыга, отряд командиры М. Кирьянов асып үтерелә. Эшчеләр шул көнне бистәгә килеп җиткән Грязновны ипи-тоз белән каршылыйлар. 5 гыйнварда Чибәркүл крепосте фетнәчеләргә кушыла, алар да Грязнов отрядын тантаналы төстә каршылый. Грязнов кул астындагы фетнәчеләр саны 2000 нән арта. Аның яртысы татар һәм башкорт крестьяннарыннан тора.

2 гыйнварга каршы төндә Каслинск заводы эшчеләре дә баш күтәрә. Алар да үз командирларын сайлап куялар. Заводтагы 200 ат «падишаһ» гаскәре карамагына алына. 400 крестьян фетнә отряды сафына баса һәм Грязнов отряды белән кушылырга китә. 8 гыйнварда инде Грязнов, Чиләбе каласын уратып алып, шәһәр стеналарын штурмларга керешкән була. Каслинск заводы крестьяннары да 10 гыйнварда Чиләбегә килеп җитәләр һәм шундук яуга кушылалар.

Бу вакытта Чиләбене Исет провинциясенең воеводасы полковник А. Веревкин һәм аның ярдәмчесе премьер-майор В. Свербеев командалыгындагы җәза отряды саклый. Бу отряд нигездә якын-тирә авыллардан җыелган крестьяннардан тора. 5 гыйнварда полковник И. Грязнов кул астындагы фетнәчеләрнең Чибәркүлгә керүе турында хәбәрне алгач, Чиләбедәге казаклар һәм крестьяннар баш күтәрә. Уржумцев һәм Невзоров фетнә башлыгына әверелә. Крестьяннар Веревкин белән Свербеевны кулга ала. Әмма иректә калган офицерлар шәһәрдәге тупларны кулга төшерәләр һәм крестьяннарга каршы ут ачу белән яныйлар. Килеп туган таркаулык, тәвәккәлсезлек нәтиҗәсендә Веревкин белән Свербеев азат ителә. 68 фетнәче кулга алына. Бик күпләре шәһәрне ташлап кача. 8 гыйнварда Чиләбене Грязнов һәм Туманов отряды камый. Шәһәрне штурмлау 3 көн буе дәвам итә, әмма уңышка китерми. 11 гыйнварда Грязнов белән Туманов чигенәләр. 13 ендә исә провинция үзәге булган Чиләбегә генерал Деколонг отряды ярдәмгә килеп җитә. Карательләр кулына әсирлеккә төшкән Уржумцев белән Невзоров ерткычларча җәзалап үтерелә.

Грязнов һәм Туманов отряды гыйнвар ахырында өяз үзәкләре булган Окуневск һәм Исет шәһәрчекләрен яулап ала. Отрядны фетнәчеләр белән тулыландыру дәвам итә. Грязнов һәм Туманов кул астында булган крестьяннар саны февраль башында 4000 кешегә җитә, алар 20 туп белән кораллана. Чиләбедә торган генерал Деколонг командасы февраль башында Окуневск каласына юнәлә. Ә саклаучысыз калган Чиләбегә 8 февральдә Грязнов белән Туманов отряды килеп керә. Шәһәрдә казакларча идарә органнары сайлап куела. Григорий Тумановка походный атаман дәрәҗәсе бирелә *(Ю. Лимонов)*. 23 февральдә Грязнов белән Туманов Троицк крепостена һөҗүм ясыйлар. Әмма бригадир А. Фейервар командалыгындагы карательләр крестьяннарның һөҗүмен кире кага («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Грязнов белән Туманов якын-тирә авыллардан яңа «казаклар» җыюны дәвам итәләр. Алар

кул астындагы гаскәрдә 5000 фетнәче туплана, шуларның ким дигәндә 2 меңе татар-башкорт җайдаклары була *(Ю. Лимонов)*. Март башында И. Грязнов, отрядтагы крестьяннарның бер өлешен алып, Бирдәгә Пугачев янына юнәлә. Чиләбедә тупланган фетнәчеләр башлыгы булып Григорий Туманов кала. Миасс һәм Яткүл крепостьларына барып, Туманов тагын 500 крестьян җыеп кайта. Шулай ук Туманов, Исет провинциясендә хәрәкәт итүче башкортлар урыс авылларын талый башлагач, андагы каршылыкларны бетерү өчен күп көч куя, Першино, Казансу, Коштат авылларын башкортлардан саклау өчен, Ф. Максимов җитәкчелегендәге махсус отряд җибәрә *(Ю. Лимонов)*.

Апрель башында Исет провинциясенә каратель Д. Гагрин отряды килеп җитә. 9 апрельдә Туманов һәм Гагрин отрядлары Разлепиха авылы янында яуга керә. Бәрелеш көне буе дәвам итә. Капитан Дурново командалыгындагы җайдаклар отряды фетнәчеләр тарафыннан тар-мар ителә, Дурново үзе үтерелә. Туманов Чиләбегә чигенә. 10 апрельдә бирегә Гагрин килеп җитә. Туманов аны 5 мең кешелек гаскәр белән каршылый. Әмма Гагрин якын-тирәдәге калкулыкларны эләктерә һәм шулардан фетнәчеләргә көчле ут ача. Тумановның 2 меңнән артык татар-башкорт җайдагы белән калкулыкларны кулга төшерергә омтылуы уңышка китерми. Фетнәчеләр көнбатышка чигенә һәм Вознесенск заводында Пугачев белән кушыла.

# ЯНӘ ОРЕНБУРГ

Без Пугачев һәм аның Бирдә лагерена тупланган 10 мең кешелек армиясе белән танышуны 1774 елның ноябрь ае белән чикләгән идек. Шуны дәвам итик.

Пугачев 5 октябрьдә камап алган Оренбург каласы 18 урам, 12 бастион, 6 чиркәүдән тора. Шәһәрне бер яктан — текә, биек ярлы Җаек елгасы, икенче яктан — Сакмар, калган өлешен тирән чокыр, туфрактан өелгән үр һәм урыны белән агач, урыны белән таштан төзелгән стеналар саклый. Пугачев каланы кулга төшерү өчен 6, 12, 22 октябрьләрдә, 2 һәм 14 ноябрьләрдә генераль штурм ясап карый. Ләкин әлеге һөҗүм-нәрдә фетнәчеләр уңышка ирешә алмыйлар. Каланы озак вакыт буе камалышта тотып, анда яшәүче халыкны һәм хәрби гарнизонны ачлык белән интектереп җиңү тактикасына күчсә дә, билгеле инде, Пугачев хәрәкәтсез ятмый. Ул ерак төбәкләргә эмиссарлар юллап кына калмый, бәлки Оренбург янындагы бистә һәм крепостьларны буйсындыруны да дәвам итә. Шул максаттан Пугачев Авзяно-Петровск заводыннан кайтып кергән һәм полковник дәрәҗәсенә лаек булган Соколов-Хлопушаны, үз отряды белән, 18 ноябрьдә Ильинка крепостена озата. Юлда Хлопушага тагын 1500 ногай татары кушыла. 22 ноябрь көнне Хлопуша крепостьны ала, комендант-поручик С. Лопатин кылыч белән чапкалап үтерелә. 23 ноябрь көнне Хлопуша Верхне-Озерск крепостена төнлә, бик яшерен рәвештә һөҗүм итә башлый. Әмма бер крестьянның саксызлыгы аркасында, мылтык тавышы яңгырый. Крепость коменданты полковник Отто Демарин солдатларны аякка күтәреп өлгерә һәм Хлопушаның штурмын кире кага. Полковнигының уңышсызлыкка ирешүе турында ишетеп, аңа ярдәмгә Бирдәдән Пугачев шәхсән үзе килеп җитә. 26 ноябрь-дә алар янә бер мәртәбә Верхне-Озерскины штурмлап карыйлар, ләкин бу юлы да чигенергә мәҗбүр булалар. Ахырда, лагерь корып, Кондырак исемле татар авылына урнашалар, отряд биредә яшәүчеләр хисабына тулыландырыла. 27 сендә Ильинка крепостена премьер-майор Е. Заев командалыгындагы җәза отряды үтеп керә. Пугачев белән Хлопуша 29 ноябрьдә кабат әлеге крепостьны штурмлыйлар. Крепостька бәреп кергәч, крестьяннар Заевны кылыч белән тураклый, тагын 200 солдат юк ителә. Гарнизондагы берничә офицер, 170 солдат әсирлеккә алына һәм, Кондырак авылы янындагы кырга китерелеп, «падишаһ» каршына тезләндерелә. Пугачев солдатларны «томаналыклары» өчен гафу итә, алар фетнәчеләргә кушыла. Ә «падишаһны танымаган» 4 офицерны дарга асарга әмер бирелә. Шулвакыт җәза отрядындагы 30 солдат керәшен татары капитан Иван Башаринны: «Ул гадел офицер булды, безне берчакта да рәнҗетмәде», — дип яклап чыгалар. Башарин гафу ителә, чәче казакча кыркыла. Солдатларга ат һәм мылтыклары кайтарып бирелә. 2200 «казак», 12 туп белән Пугачев Бирдә лагерена кайтып төшә *(Н. Дубровин, В. Буганов)*.

Пугачев юклыкны белеп алып, губернатор Рейнсдорп 26 ноябрьдә 1000 кешелек корпус белән фетнәчеләр лагерена һөҗүм оештырып карый. Ләкин татар-башкорт җайдаклары хөкүмәт гаскәрен янә шәһәргә куып кертә. 29 ноябрь, 7 декабрь көнне Оренбург стеналары янында тагын бәрелешләр булып ала, алар бер якка да уңыш китерми. Ә фетнәчеләрнең тантаналы маршы һаман дәвам итә. 30 ноябрьдә Бозаулык крепосте Илья Арапов җитәкчелегендәге фетнәчеләр кулына күчә. Крепость коменданты губернатор Брандт кияве булган подполковник Вульф, әле 18 ноябрьдә үк гарнизонны ташлап, Самара каласына качкан була (Екатерина 1775 елда Вульфны армиядән һәм Рәсәйдән куа. — *Н. Дубровин*). Ә 25 декабрь көнне Самара үзе дә атаман И. Арапов кулына төшә *(Х. Муратов)*. Тоташ татарлардан гына торган

Мачын бистәсе (Самарадан 20 чакрымда) казаклары, аерым отряд туплап, Арапов полкына кушыла («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

18 сентябрьдән бирле аны «падишаһ» дип танымыйча яшәүче Җаек шәһәрчеге Пугачевка тынгы бирми. Җаек казаклары үзләре дә, билгеле инде, Пугачевны бу каланы тезләндерергә үгетлиләр. Шуңа күрә декабрь ахырында Пугачев бирегә атаман Михаил Толкачев җитәкчелегендәге 300 кешелек отряд юллый.

1613 елда нигезләнгән Җаек шәһәрчеге Пугачев явы вакытында күтәренке тау сыртына урнашкан хәрби крепость һәм аның тирә-юненә сыенып утырган бистәләрдән тора. Крепостьны урап ике яктан Җаек һәм Чаган елгалары ага. Крепостька шәһәрчек кушылып китә. Шәһәрчекне бер яктан Старица дип аталган ерым (Җаек елгасының иске эзе) һәм икенче яктан туфрак өеп ясалган үр саклый. Шәһәрчекнең төрле ягында «Татар комлыгы», «Хан әрәмәлеге», «Бакча» дип исемләнгән уйсулыклар ята. Крепость эчендә бердәнбер Михаил Архангел соборы тора, урамнары да бик аз була. Саклану өчен таш бастионнары булмаса да, комендант полковник И. Симонов шактый гына хәзерлек чаралары күреп өлгерә. Хәтта соборлы чиркәү өстенә дә ике туп урнаштырыла. Камалышта калган очракка дип, крепость эчендә күп кенә ризык, дары, землянкалар әзерләнә.

Толкачев якынлашу турында хәбәрне алгач, Симонов аңа каршы 80 кешелек отряд җибәреп карый. Ләкин Җаек казаклары һәммәсе дә Толкачев ягына чыга. Шуңа күрә башкача каршылык очратмыйча Толкачев 30 декабрьдә калага килеп керә. Солдатлар һәм бай казаклар крепость эченә кереп бикләнәләр. Толкачев штурм башлый. Симонов туплардан ут ача. Әмма ядрәләрнең күп өлеше крепостька терәлеп торган йортларга эләгә, фетнәчеләргә зыян китерми. Шуннан соң Симонов якын-тирәдәге йортларны яндырырга әмер бирә. Янгыннан соң пәйда булган ачык мәйдан фетнәчеләргә крепость стеналарына якынаерга ирек бирми. Толкачев Бирдәдән ярдәм сорый. Пугачев әүвәл бирегә атаман А. Овчинниковны 50 кешелек отряд белән юллый. Ә 7 гыйнварда инде үзе дә килеп җитә. «Падишаһ»ны биредә, әлбәттә, ипи-тоз белән каршылыйлар.

Крепостьны һәрьяктан карап чыкканнан соң, Пугачев казакларга, карательләр куйган туп батареясына туры китереп, җир асты юлы казырга әмер бирә (тышта — гыйнвар!). Казылган юл 20 гыйнварда гына әзер була. Пугачев шәхсән үзе җир астына төшеп дары мичкәсе һәм шәм урнаштыра. Шартлау фетнәчеләр көткәнчә көчле чыкмый. Батареяга зыян килми, крепостьны саклаучы үр генә җимерелә. Шулай да фетнәчеләр күмәк штурмга ташлана. Анда Җаек казаклары белән бергә татарлар, мишәрләр, калмыклар, хәтта казакларның хатыннары һәм балалары да катнаша *(В. Буганов)*. Штурм 9 сәгать буе дәвам итә, 400 гә якын фетнәче һәлак була. Пугачев чигенергә һәм әлеге крепостьны да озак вакыт буе камалышта тотудан соң алу тактикасына күчәргә мәҗбүр була. Фетнәчеләр атаманы итеп Афанасий Перфильевны билгели. Үзе Бирдә бистәсенә кайтып китә. Атаман А. Овчинников 26 гыйнварда Гурьевны ала. 20 гыйнварда калмык атаманы Федор Дербетев Ставрополь каласын «падишаһ»ка тез чүктерә, комендант бригадир фон Фегезак үтерелә *(Н. Дубровин)*.

Пугачев югыннан файдаланмакчы булып, Оренбургка бикләнгән гаскәр 13 гыйнварда Рейнсдорп әмере буенча тагын бер мәртәбә Бирдә лагерена һөҗүм итеп карый. Әмма генерал К. Валленштерн командалыгындагы гаскәр, бу юлы да хурлыклы рәвештә җиңелеп һәм 281 солдатын югалтып, шәһәр стеналары артына чигенә. Шуннан соң Рейнсдорп 2 мартка кадәр яңа һөҗүм оештырырга батырчылык итми.

Башка төбәкләрдә фетнә хәрәкәтенең уңышлы баруыннан канәгатьләнгән, әмма Җаек шәһәрчегенең тез чүкмәвенә үртәлгән Пугачев февраль уртасында Бирдәдән тагын Җаекка юнәлә. Бирегә Гурьевтан Овчинников та кайтып төшә. Пугачев бу юлы да Җаек шәһәрчегенең Симонов бикләнгән крепостена таба җир асты юлы казыта. Әмма эш ахырын көткәндә, яңа «мәшәкатьләр» килеп чыга. Җаек казаклары «падишаһ»ны өйләнергә кыстый башлыйлар һәм Пугачевның күзе төшкән 17 яшьлек Устинья Кузнецовага тукталалар. Михаил Толкачев белән «падишаһ»ның тәүге сәркатибе Иван Почиталин кода итеп билгеләнә. Кәләшне әллә ни озакка сузылмаган үгетләүләрдән соң Пугачев белән Устинья бистә чиркәвендә парлашалар.

*(Сүз уңаеннан шуларны да өстик: Устинья Кузнецова яшәгән йорт әле дә исән. Анда Пугачев музее урнашкан. Аның янәшәсендә генә Михаил Толкачев йорты, ул да исән. Ә Толкачевның күршесендә Пугачев штабында сәркатип булып йөргән Хәлил мулла яшәгән. Хәлил нәселеннән булган 84 яшьлек Хәким карт 1986—1988 елларда Уральск мәчетендә имам-хатыйб иде, бәлки хәзер дә исәндер. Пугачев музеенда директор урынбасары булып эшләүче керәшен татары Татьяна Александровна Демичева да 1773 елгы фетнәче нәселеннән булуын яшерми. Өстәвенә, ул безне Харитонов, Исаев, Белоусов, Богданов фамилияле керәшен татарлары белән очраштырды. Алар да ерак бабаларының пугачевчы булулары турындагы байтак истәлекләрне безгә ирештерде. Һәммәсенә рәхмәт!)*

19 февральдә Пугачев тагын бер мәртәбә крепость стенасын шартлата, чиркәү манарасы җиргә иңә. Гарнизондагы 45 кеше һәлак була. Ләкин фетнәчеләр лагереннан качкан бер яшүсмернең кисәтүе сәбәпле, Симонов штурмны кире кагарга хәзерләнеп өлгерә. Моны аңлаган Пугачев һөҗүмне башламый. Ул арада Бөгелмә һәм Самарадан Оренбургка таба хәрәкәт иткән карательләр турындагы хәбәрләр дә килеп ирешә. Пугачев, үзе белән 500 кешелек отряд алып, Бирдә бистәсенә кайтып китә. (Җаек шәһәрчеге турында тагын бер генә информация өстик: Татарстан җирендәге хәзерге Балык Бистәсенең Токранов, Рыжий, Владимиров атлы крестьяннары нәкъ менә шушы шәһәрдә «падишаһ» өчен шәхси мөһер ясап бирәләр. — *В. Буганов*.)

Бу вакытта Хлопуша отряды да эшсез ятмый. 16 февральдә ул Илецкая Защита крепостен ала, 90 тоткынны, шул исәптән үзенең гаиләсен дә азат итә. Үзе белән 5 туп, 20 пот дары алып, ул да Бирдәгә әйләнеп кайта.

22—27 февральдә Бирдәдәге крестьяннар Оренбург каласын, тупка тота-тота, вак-вак командалар белән һөҗүм итеп карыйлар. Бу уңышка китерми. 2 мартта Рейнсдорп Бирдәгә таба тагын бер отряд юллый, әмма хурлыклы рәвештә җиңелә. Гарнизон шәһәргә бикләнә һәм шуннан соң карательләр килеп коткарганчы тын да чыгармый.

Бирдә лагерена тупланган фетнәчеләр өчен февраль ае әле бернинди куркыныч тудырмаса да, карательләр корган боҗра кысыла бара. 29 декабрьдә үк инде Самарага премьер-майор К. Муфель һәм гвардия поручигы Гавриил Державин (шагыйрь) командалыгындагы карательләр отряды бәреп керә. Бик күп фетнәче үтерелә, 200 кеше әсирлеккә алына. Атаман И. Арапов Алексеевка бистәсенә чигенә, әмма 8 гыйнварда подполковник П. Гринев командасы фетнәчеләрне моннан да куа. Озакламый Самарага инде генерал-майор П. Мансуров кул астындагы хәрби-кыр командалары да килеп җитә. Фетнәче атаман Ф. Дербетевның Ставропольне алуы турында ишетеп, карательләр шунда ашыга. Аларга каршы тора алмасын аңлап, 7 февральдә Дербетев Ставропольне калдыра һәм Бирдәгә таба чигенә.

Пугачев явы башланганнан бирле җәза гаскәрләренең төп лагере булып торган Бөгелмә дә җанлана. 4 февральдә бирегә генерал-майор А. Голицын полклары килеп җитә һәм 3 ай буе хәрәкәтсез торырга мәҗбүр булган генерал-майор Ф. Фрейман белән кушыла. Үзләренең җебегәнлекләрен акларга омтылган шикелле, җәза полклары фетнәчеләргә каршы ашыга. 8 февральдә полковник Г. Хорват командасы Богырыслан крепостен ала, керәшен татары, депутат Гаврила Давыдов отрядын тар-мар итә *(Н. Дубровин)*. 10 февральдә генерал Мансуров Бор крепостен яулый *(В. Мавродин)*. 14 февральдә Бозаулык крепосте янында Мансуров белән Гринев командаларын атаман И. Арапов отряды һәм Җаек шәһәрчегенә барышлый Пугачев тарафыннан калдырылган полковник Габдерәшит Әитов җитәкчелегендәге татар җайдаклары каршылый. 4 сәгатькә сузылган яуда Мачын бистәсе татарлары да катнаша. Яу барышында 217 крестьян һәлак була, 286 кеше яралана. Ахырда фетнәчеләр җиңелә һәм Иләк шәһәрчегенә таба чигенә («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; Х. Муратов). 27 февральдә Богырысланга генерал Голицын полклары да килеп җитә. Оренбург губернасын 5 ай буена үз кулларында тоткан фетнә отрядларын камаган карательләр боҗрасы һаман кысыла бара. Җәзачылар якынлашу турындагы хәбәрләр, билгеле инде, Бирдә лагерена да килеп җитә. Фетнә юлбашчылары саклык чаралары күрә һәм аз санлы җәза отрядларына каршы һөҗүмнәр оештыра башлый.

6 март көнне Пронькино авылына секунд-майор В. Елагин кул астындагы карательләр отряды килеп керә. Бу турыда Сорочинск крепостенда торган Пугачевка хәбәр итәләр. Инде караңгы төн якынлашуга да карамастан, Пугачев үз кул астына 2300 фетнәчене (В. Мавродин, Н. Дубровин хезмәтләрендәге мәгълүмат. Ә Х. Муратов 1500 дип күрсәтә) туплый, шул исәптән полковник Габдерәшит Әитов, йөзбашы Исхак Әхмәтов һәм Илья Арапов җитәкчелегендәге татар җайдакларын ала. Атларда юыртып 37 километр ара үткәннән соң, 7 март таңында фетнәчеләр бердәм рәвештә һөҗүмгә ташланалар. Каравылчылар юк ителә, туплар фетнәчеләр кулына төшә. Йоклаган җиреннән йөгереп чыгып оборона оештырырга маташкан майор Елагинны җайдаклар «сөңгегә күтәреп» юк итә. Әмма тиздән авылга генерал Мансуровка буйсынган Хорват полкы килеп җитә. Пугачевчылар Бирдәгә таба чигенә. Тоцк крепостен Мансуров инде яусыз гына ала. Ә 11 мартта Бөгелмәдән килгән Голицын белән җәза походын Самарадан башлаган Мансуров полклары Сорочинск крепостенда бергә кушыла.

Карательләрнең тантаналы маршы Екатерина тарафыннан бөтен Идел — Урал төбәгендәге гаскәрләрнең башкомандующие итеп озатылган генерал-аншеф А. Бибиковка да дәрт һәм ышаныч өсти, күрәсең. Кул астында 16 мең кешелек армия була торып та 26 декабрьдән бирле Казан каласыннан аерылырга җөрьәт итмәгән Бибиков, ниһаять, 8 мартта Бөгелмәгә карап юлга чыга. Яуларда «батырлык» күрсәтеп югарырак хәрби дәрәҗәләр, орденнар һәм авылы-авылы белән яңа коллар алырга хыялланган бүтән генераллар һәм офицерлар да ярымкоралсыз крестьяннарга каршы ашыга. Генерал Фрейман 17 мартта Новосергиевск крепостен яулый. 20 мартта Голицын Переволоцк крепостен ала. Чит ил белән су-

гышларда ныклы тәҗрибә туплаган, яу алып бару тактикасының бар нечкәлекләрен белгән 3 генерал, 100 дән артык сугышчан офицер командалыгындагы, гомуми саны буенча 6500 (Х. Муратов хезмәтендә 8000) хәрбине туплаган җәза гаскәре 22 мартта Җаек елгасы буендагы Татищев крепостена килеп җитә.

Татищеводан Оренбургка кадәр 54 чакрым гына ара кала. Бирдәгә тупланган 20 меңгә якын «казак» өчен нинди зур куркыныч тууын, әлбәттә, фетнә җитәкчеләре дә яхшы аңлый. Пугачев Бирдә лагерендагы җитәкчелекне атаман Максим Шигаевка калдыра, ә үзе, 5000 кешелек отряд, шул исәптән Габдерәшит Әитов, Муса Алиев, Исхак Әхмәтов җайдакларын алып, карательләр гаскәренә каршы юнәлә. Иләк крепостенда торган атаман Овчинников кул астындагы казаклар, шул исәптән Мачын бистәсе татарлары, Красногорская крепостендагы Гомәр Ермаков җитәкчелегендәге гарнизон да Татищевога чакырыла. Пугачев әмере буенча бирегә Дербетев җитәкчелегендәге калмык отряды да килеп җитә. Нәтиҗәдә 20 мартта Татищевога тупланган һәм 36 туп белән коралланган фетнәчеләр саны 8—9 меңгә җитә. Тарихчы В. Мавродин, бу гаскәрне 3000 казак, заводларга беркетелгән 1800 крестьян, фетнәчеләр ягына чыккан 2000 солдат һәм татар, башкорт, калмык, казах вәкилләреннән торган тагын 2300 кеше тәшкил иткән, дип күрсәтә. Мавродин завод крестьяннарын (алар арасында татарлар да бик күп, әйтик, Хлопуша отряды) һәм казакларны, солдатларны (алар арасында Җаектан татар казаклары, Красногорск крепостеннан Гомәр Ермаков кул астында килгән йөзлек, генерал Кар яки полковник Чернышев командаларына алынып, фетнәчеләр ягына чыккан татар солдатлары да бар) милләтләргә бүлеп тормый. Шуңа күрә бөтен фетнә барышындагы иң шаулы, иң канлы яуларның берсендә күпме татар вәкиле катнашканын төгәл әйтеп булмый. Әмма югарыда саналган мисалларны истә тоткан хәлдә «Татищево янындагы фетнә гаскәрендә кимендә өч кешенең берсе татар булган» дисәк, без хакыйкатьтән әллә ни ерак тормыйбыздыр кебек.

Ярым-йорты гына коралланган 8—9 мең фетнәче белән регуляр гаскәргә каршы торып булмаячагын Пугачев, әлбәттә, яхшы аңлый. Шуңа күрә крепостьта ул гаять җитди хәзерлек чаралары күрә. Стеналарның җимерелгән урыннарына кар өеп һәм су коеп, фетнәчеләр ныклы үр ясыйлар. 36 тупны да стеналар өстенә Пугачев шәхсән үзе урнаштырып чыга. Крепость янындагы кырларга чөй кагып, канонирлар өчен ядрәләр төшәргә тиешле урыннарны билгели. Күрелгән чаралар гына аз булып тоелгач, Пугачев инде хәйләгә дә бара. Ул фетнәчеләргә карательләр якынлаша башлагач, тавыш чыгармаска боера, шул рәвешчә Татищевоны бушап калган крепость итеп күрсәтергә тели.

Генерал Голицын командалыгында Переволоцк крепостеннан иртәнге 4 тә юлга чыккан 6500 кешелек гаскәрне Татищево халкы үлгән крепость сыман, тын каршылый. Голицын 3 казактан торган разведка разъезды җибәрә. Татищевоның капка төбендә аларны кулларына ипи-тоз тоткан ялгыз хатын каршы ала. Аның: «Караклар китте, бер явыз да калмады. Крепость халкы князь Голицын галиҗәнапләрен көтә. Икеләнмичә килегез», — дигән сүзләре казакларда шик уята. Алар, эчкә узып, үзләре моңа инанмакчы булалар һәм шул чакта капка артына качып торучы Пугачев, Овчинников, Араповны күреп алалар. Фетнәчеләр бер шымчыны эләктерәләр, әмма ике казак качып өлгерә.

Голицын үз гаскәрен 4 өлешкә бүлә. Генераллар Мансуров белән Фрейман флангларда һөҗүм итәргә, полковник Ю. Бибиков командасы, крепость артына чыгып, фетнәчеләрнең чигенү юлын бикләргә тиеш була. Ә Голицын, үзәктәге ике калкулыкка менеп, туплардан ут ача. Туплар канонадасы 3—4 сәгать буе дәвам итә. Аннары һөҗүм башлана. Канлы яу 3 сәгатьтән артык бара. Хәлнең катлаулана баруын күреп, атаманнар Пугачевны качарга үгетли башлый. 4 җайдак (шулар арасында «патшабикә» Устиньяның абыйсы Егор һәм сәркатип Иван Почиталин) озатуында качкан Пугачевны Чугуевск полкы казаклары 3 чакрым буе куып карый. Әмма инде күптән үзенә иң гаярь аргамакларны сайлап алган «падишаһ» әлбәттә тоттырмый.

Юлбашчысыз калган фетнәчеләр коточкыч югалтулар кичереп җиңелә. Карательләр бәреп кергәч, крепость эчендә 1315 крестьян һәлак була. Татищево тирәсендә тагын 1180 кеше юк ителә. 4000 гә якын фетнәче, шул исәптән бик күп яралылар әсирлеккә төшә (Мавродин, Дубровин, Буганов һ.б. Чагыштыру өчен карательләр ягындагы югалтуларны да күрсәтик. Алар арасыннан 141 солдат һәлак була, 516 кеше яралана). Яудан чагыштырмача исән-имин чыккан һәм Татищево яныннан качып котылган фетнәчеләрнең дә байтагы соңыннан хыянәтчеләр капкынына эләгә.

22 март төнендә Пугачев Бирдә бистәсенә кайтып керә. Җаек казаклары арасыннан берничә кеше аны бәйләп Оренбургка алып китәргә ниятли. Әмма мондый мәкер әлегә барып чыкмый. 23 март таңында Пугачев янына аның иң якын киңәшчеләре — атаманнар җыела. Кайсы якка, ничегрәк качу турында бәхәс чыга. Ниһаять, юлбашчылар кечкенә генә бер отряд белән Җаек шәһәрчегенә качарга сүз куешалар (һәммәсе өчен дә бик «отышлы»: Пугачевны — «яңа патшабикә», Җаек казакларын туган төбәге көтә. Өстәвенә, өмет тә бар: Җаек шәһәрчеген Каргин, Перфильев һәм Толкачев камалышта тота). «Падишаһ», Бирдәгә тупланган гаскәр каршына чыгып, «кем кая теләсә, шунда таралырга» әмер бирә. Җыелган «казна» акчасын өләшә башлыйлар, фетнәчеләр эчеп исермәсен өчен, шәраб тулы мичкәләрне бәреп ваталар.

Соколов-Хлопуша шушы көнне, гаиләсен алып китү өчен, Каргалы бистәсенә килә. Габделрәфыйк Габдуллин, Рәхмәтулла Госманов, Габдерәхим Габделмәҗитов кебек байлар аны кулга алалар һәм 24 е көнне Оренбургтагы Рейнсдорпка илтеп тапшыралар (*С. Алишев*. «Татары...»).

*Без күңелебезне тырнап торган җитди бер төгәлсезлек, гаделсезлек белән укучыларны да таныштырырга мәҗбүрбез. Петербург галиме Ю. Лимонов 1975 елда нәшер ителгән «Емельян Пугачев и его соратники» дигән китабында Хлопушаны кулга алуда бөтенләй катнашы булмаган, алай гына да түгел, бәлки киресенчә, бөтен татар халкының, димәк, Каргалы авылының да горурлыгы булырлык каһарман шәхес исемен каралта. Мөселманнарның исем-фамилиясен дә юньләп аера белми торган шушы «галим», «Хлопушаны авыл старшинасы Муса Алиев, тимер богаулар кидертеп, Рейнсдорп кулына илтеп биргән», дип күрсәтә. Шушы ук ялгышны соңыннан Ростов университетының «атаклы галиме» Х. Муратов та кабатлый. Ә без Муса Алиев исемен инде күп тапкырлар телгә алып уздык. Муса — 1 октябрьдә Каргалы татарларыннан төзелгән полк командиры. Биккол, Йөзәй, Оренбург, Татищево янында батырлыклар кылган каһарман. Ул әле Пугачев белән бергә озын юл узачак һәм Казан янында 15 июль көнне булган яуда гына карательләр кулына эләгәчәк.*

Каргалы байларына Хлопушаның үзен генә (Яшерен комиссия әгъзалары Лунин һәм Маврин карары буенча Хлопуша 1774 елның 18 июлендә Оренбургта җәзалап үтерелә) җәлладлар кулына тапшыру аз булып тоела, күрәсең. Әби патшадан олы бүләк өмет иткән хыянәтчеләр Татищево яныннан кайтып кергән авылдашларын да кызганып тормыйлар. Бистә старшинасы Габделрәфыйк Габдуллин һәм ахун Габделнасыйр Габделгалләмов җитәкчелегендәге байлар 23—25 мартларда 42 кешене, кулга алып, Оренбургка илтеп бирәләр. Оренбургка җибәрелмичә, Каргалының үзендә базларга ябып куелган фетнәчеләр дә була. Шундыйлардан берничә кеше ниндидер юллар белән иреккә чыга һәм, Бирдәдәге «падишаһ» янына килеп, бүтән тоткыннарны коткаруда ярдәм итүен үтенә.

26 мартта Пугачев, 2000 кешелек отряд алып, Каргалы бистәсенә килеп җитә. Базларга ябылган татарлар азат ителә. Үзләрен бәйләп ташлаган байлардан хәзер инде шулар үч ала башлый. Ике байның йорты яндырыла, 5 хыянәтче дарга асыла (*С. Алишев*. «Татары...»). Алар арасында Каргалыдагы бишенче — Кызыл мәчетне 1759 елда төзеткән сәүдәгәр Мөхәммәткул Бикчәнтәев белән аның ике улы — Искәндәр һәм Әбүбәкер дә була (Оренбург өлкә музееның өлкән фәнни хезмәткәре С. Попов, фәннәр кандидаты Фәез Батталов тарафыннан әзерләнгән һәм «Каргалы авылының тарихы» дип исемләнгән кулъязма. Ул Каргалы авыл китапханәсендә саклана. Аңа ышанмаска нигез юк. С. Попов, мәсәлән, Оренбург өлкәсенә багышланган китапларда тарихи очерклар белән катнашкан автор).

Пугачев Каргалыда Тимофей Мясников кул астындагы 500 кешелек отряд калдыра да үзе Сакмар шәһәрчегенә китеп бара. Анда фетнәчеләр арасында губернатор Рейнсдорп шымчысы булып йөргән тагын бер Каргалы татарын дарга аса *(В. Мавродин)*. Ә бу вакытта инде Бирдә бистәсенә карательләрнең секунд-майор Зубов отряды бәреп кергән була. 6 ай буена фетнәчеләрнең төп лагере булган Бирдәгә тупланган һәм соңгы ике-өч көн эчендә «падишаһ»сыз, Хәрби коллегиясез, атаманнарсыз калган меңәрләгән фетнәчеләр кая барырга, ни кылырга да белмичә, төрле якка таралыша башлый. 5 меңгә якын фетнәче Оренбургка юнәлә һәм патшабикә коллары алдында «баш ия».

Шулай да 30—31 мартларда Каргалы бистәсе белән Сакмар шәһәрчегендә Пугачев кул астына 5 меңгә якын фетнәче, шул исәптән Идеркәй Мәхмүтов, Габдерәшит Әитов, Муса Алиев, Исхак Әхмәтов җитәкчелегендәге җайдаклар туплана. Дөрес, алар карамагында нибары 7 генә туп була. Генерал Голицын гаскәренең янә үзләренә каршы юнәлүен белеп, Пугачев яңа яуга керергә карар кыла. Төп көчне Пугачев Каргалыга туплый, бистәгә алып килүче юлларга туплар урнаштыра.

2 апрель иртәсендә җәза гаскәрен Каргалыдагы фетнәчеләр туплардан ут ачып каршылый. Ләкин подполковник Н. Аршеневский, капитан-поручик Толстой кул астындагы батальоннарның көчле һөҗүменә каршы тора алмыйча, фетнәчеләр Сакмар шәһәрчегенә чигенәләр. Яу юл буе дәвам итә, аннан Сакмар урамнарына күчә. Әмма берничә полкны туплаган регуляр гаскәргә каршы тору мөмкин булмый. Фетнәчеләр тар-мар ителә. Яу барышында 400 фетнәче һәлак була, 2813 кеше әсирлеккә эләгә. Җаек атаманнары Иван Почиталин, Шигаев, Витошнов, Падуров, Горшков белән бергә татар фетнәчеләренең полковнигы, ике ай элек кенә җәлладлар газаплавына түзмичә Казан төрмәсендә вафат булган корпус старшинасы Әит Үрәзмәтовның улы Габдерәшит Әитов та карательләр кулына төшә. Пугачев үз янында калган 100 казак, 100 завод крестьяны һәм 300 татар-башкорт җайдагы белән Никольское, Тимашево бистәләре аша Ташлы авылына кадәр кача. Алда аны Уфа провинциясе, Урал көтә.

## ҖӘЗАЧЫЛАР ЛАГЕРЕНДАГЫ ТАНТАНА

22 мартта Татищево янында җиңүгә ирешкәч, билгеле инде, әүвәл Бөгелмәдәге башкомандующий генерал-аншеф А. Бибиков тарафына, ә аннан Екатеринага тантаналы рапортлар «оча». Бибиковның «Сезне бөтен тынгысызлыкларның тәмамлануы белән котлыйм» дип язган рапортын һәм «явызны тулысынча, тәмам тар-мар итү» турындагы хәбәрен алгач, Екатеринаның башы күккә тия. Ул чит илдәге үзенең корреспондентларына («укымышлы» патшабикә Европаның күренекле шәхесләре белән хат алышып торуны бик яраткан) «фетнәнең тәмам бастырылуы» турында шундук хәбәр юллый. Әби патша әле 1774 елның гыйнвар ахырында гына яңа сөяркәсе — генерал-майор Григорий Потемкин кочагына кер-гән була. Һәм, әлбәттә инде, ул «оҗмахта» яши. Ә «карак» Пугачев гаскәрен «тәмам җиңү» турында хәбәр алгач, шатлыкның иге-чиге булмый. «Күренекле һәм талантлы» командирларга яңа хәрби дәрәҗәләр, орденнар, акчалата бүләкләр бирелә. Измайлов лейб-гвардия полкында премьер-майор булып исәпләнгән башкомандующий генерал А. Бибиков, мәсәлән, подполковник дәрәҗәсен ала (ә гыйнвар аенда камергер гына булып исәпләнгән Г. Потемкин Екатеринага күрсәткән «олы хезмәтләре» өчен мондый дәрәҗәгә инде 15 мартта ук лаек була!). Петербургка җиңү хәбәре китергән секунд-майор С. Е. Неклюдов (ул Алабуга янында крестьяннарны кылыч белән тураклаган җәллад) белән поручик Гиршфельд чираттагы хәрби дәрәҗәләргә лаек була. Хәтта 6 ай буена камалышта торган һәм сугышчан генерал сыйфатларын бер генә мәртәбә дә күрсәтә алмаган губернатор Рейнсдорп та коры калмый. Аңа А. Невский ордены һәм «яңа йолдызлар, тасмалар алу өчен» 15 мең сум акча бүләк ителә *(Н. Дубровин)*.

Дөрес, «күп батырлыклар кылган» генералларның һәммәсе дә бүләкләрен алып өлгерми. 9 апрельдә Бөгелмәдә яман бизгәк авыруыннан генерал А. Бибиков вафат була. Урысларның бөек шагыйре булып исәпләнгән керәшен татарлары вәкиле Гавриил Державин әлеге генералга багышлап ода да яза *(В. Ходасевич)*. Башкомандующий итеп Екатерина моңа кадәр Казанда Бибиковның ярдәмчесе булып торган генерал-поручик Ф. Щербатовны билгели. Щербатов командалыгындагы җәза гаскәрләрендә солдатларның саны инде 20 меңне дә узып китә (*С. Алишев*. «Татары...»).

Генералларның рапортларында күрсәтелгән әсирләр саны Екатеринаны яңа эшчәнлеккә этәрә. 25 апрель көнне указ язып, ул Казанда ноябрь аенда ук үзе оештырган Яшерен комиссияне икегә бүлә. Әле А. Бибиков ук юллаган капитаннар Лунин белән Маврин Оренбург комиссиясен тәшкил итә. Казанда әсирлеккә эләккән фетнәчеләрдән Собакин, Волоцкий, Горчаков кебек офицер-җәлладлар сорау ала. Бу вакытта Казан төрмәсендә — 169 (апрель ае бит — провинция фетнәчеләрдән «чистартылган», ә җәза отрядлары мыжгып тора), Оренбург зинданнарында 4700 фетнәче газаплана. Билгеле ки, ул Оренбург төрмәләренә эләккән тоткыннарның һәркайсыннан сорау алырга җитешмиләр. Аларның зур күпчелеге фетнәдә бүтән катнашмаска «вәгъдә иткәннән» һәм комиссия тарафыннан хәзерләнгән ант кәгазенә тамга куйганнан соң иреккә чыгарыла. Фетнәчеләр кул куярга мәҗбүр ителгән ул ант кәгазенең эчтәлеге белән сезне дә таныштырыйк:

«*Без (исем-фамилия, адрес), бөтен Рәсәй хакиме, бөек анабыз, изге күңелле, олы җанлы патшабикә Екатерина Алексеевна галиҗәнапләре тарафыннан гафу кылынучылар һәм азат ителүчеләр, киләчәктә бөек патшабикә галиҗәнапләренең, державаның һәм Рәсәй скипетрының тугры коллары булып калу белән генә канәгатьләнмичә, патшабикә галиҗәнапләренең иминлеге өчен бөтен каныбызны коярга; гомум тынычлыгыбызны бозучы явызларга, аеруча үзен патша дип атаган әшәке җан Емелька Пугачевка һәм аның якыннарына бөтен көчебез белән каршы чыгарга; аларны үзебезгә якын җибәрмәскә, аларга кушылмаска һәм алар белән бер нәрсә турында да сөйләшмәскә тиешбез. Без шул хакта унибыз берьюлы ант итәбез һәм һәрберебезнең анты өчен җаваплыбыз. Әгәр безнең арадан кайсыбыз да булса Ходай тарафыннан каргышны һәм патшабикә галиҗәнапләре күрсәткән бөек изгелекне онытып, байлык белән кызыктыруга яки үлем белән куркытуга карамастан, явызларга кушылса (алар янына китсә яки аларны үз янына кертсә), ул бер хыянәтче өчен безнең бөтен унлык юк ителергә тиеш. Биргән вәгъдәләребез онытылмасын өчен, унлык эчендәге һәрбер кеше ошбу ант кәгазенең бер нөсхәсен үз янында тотарга һәм, һәр бәйрәм вә ял көннәре саен кабатлап, хәтерендә яңартырга тиеш» (Н. Дубровин).*

«Гафу ителгәннәр» һәм иреккә чыгарылганнар менә шундый ант кәгазе ала. Ә Оренбург төрмәләрендә калган фетнәчеләр арасыннан да фәкать 1000 кешедән генә сорау алына, аеруча гаепле булганнары җәзага тартыла. Шул 1000 кеше арасыннан 239 фетнәченең милләте буенча татар булуын без кереш өлештә үк әйтеп үттек инде. Исәпләү һәм уйлану өчен яңа мәгълүматлар да өсти алабыз: әлеге 1000 арасында 298 казак, 14 башкорт, 87 керәшен, 135 крестьян, 25 солдат һәм башкалар бар. Ә җәзага тартылган 277 кешенең 128 е татар, 84 е казак («История Татарии в документах и материалах»).

Казан һәм Оренбург төрмәләрендәге 169 һәм 4700 тоткын турындагы рапортлар Петербургтагы Екатеринага, указ язганчы ук, димәк, 20 апрель тирәләрендә барып ирешә. Шик юк: Оренбург зинданнарына ябылган 4700 кеше — ул Татищев крепосте һәм Сакмар шәһәрчеге янында әсирлеккә төш-кән һәм төрмәләрдә 3—5 апрель тирәсендә тотылган фетнәчеләр. Ләкин Татищевода әсирлеккә эләккән

фетнәчеләрнең һәммәсе дә Оренбургка озатылмаган. Монда кулга алынган 4 меңгә якын фетнәченең 512 сен шуннан әүвәл Самарага, соңрак Казан каласына озатканнар (5 апрельдә 169 булган тоткыннарның саны, мәсәлән, 8 июльдә Казанга генерал Павел Потемкин килеп төшкәндә, 415 кеше исәпләнгән). Әмма Самара белән Казан арасында ул 512 тоткынның да 114 е алган яраларыннан һәм кыйналудан җан биргән *(С. Алишев)*. Шулай ук Оренбург төрмәләре 5 апрельдән соң да тулыланып торган бит әле. Әйтик, без югарыда телгә алган Каргалы бистәсенең хыянәтче байлары Габделрәфыйк Габдуллин белән Габделнасыйр Габдегалләмов һәм аларның куштаннары Татищево янындагы яудан исән кайткан 100 гә якын (бу — без әйткән 42 кешедән тыш) авылдашларын 11 апрельгә кадәр Оренбург администрациясенә илтеп тапшыралар *(С. Алишев).*

Карательләрнең генерал Мансуров командалыгындагы корпусы 30 декабрьдән бирле камалышта тотылучы Җаек шәһәрчегенә юнәлә. 15 апрельдә Быковка елгасы буенда атаманнар А. Овчинников һәм А. Перфильев җитәкчелегендәге 500 кешелек казаклар отряды тар-мар ителә. Яуда 100 дән артык фетнәче һәлак була, берничә кеше әсирлеккә төшә, калганнары Җаек шәһәрчегенә кайтып китә. Әмма хыянәтче казаклар, үз гомерләрен коткару хакына, Н. Каргинны, М. Толкачевны һәм тагын 7 фетнәчене кулга алалар һәм баш күтәргән халыкның яңа һөҗүменнән дер калтырап яшәгән полковник Симоновка илтеп тапшыралар. Овчинников белән Перфильев кына берничә казак белән качып котыла һәм Пугачев артыннан юнәлә. Ә карательләр Җаек шәһәрчегендә «патшабикә» Устиньяны да кулга төшерә. Генерал Мансуров аны Казанга озата. Пугачевның беренче хатыны Софья белән балалары Трофим (10 яшьтә), Аграфена (7), Христина (3) да күптән кулга алынган һәм бу вакытта инде Казан төрмәсенә китереп ябылган була.

Генераллар, дворяннар һәм хыянәтчеләр шулай тантана итә. Ә Екатерина үзе бу көннәрдә кичергән шатлык, ул язган хатлар, гомумән, аның Пугачев явы чорындагы тормышы турында аерым китаплар да язып булыр иде. Ләкин бу хезмәтнең максаты — андый түгел. Шуңа күрә әлегә өзеп әйтик: юкка гына шатланасың булыр, Әби патша. Кайнар таба өстенә эләккән шикелле сикергәлисе көннәрең алда әле!

# УРАЛ ТАУЛАРЫ АША

Сакмар буендагы яудан исән-имин котылгач, 500 җайдак иярткән Пугачев 2 апрельдә Ташлы авылына (Оренбург өлкәсенең Тюльган районында) барып җитә. Оренбург янынннан Уфа провинциясенә чигенү идеясен аңа башкорт халкының атаманы дәрәҗәсен йөртүче Кинҗә Арысланов Бирдә бистәсендә чакта тәкъдим итә. Татар каһарманнары Муса Алиев, Идеркәй Мәхмүтов, Садыйк Сәгыйтов, Исхак Әхмәтов, Сәлим Гаделшин һәм башка күренекле фетнәчеләр дә Пугачев белән бергә Сакмар буеннан качкан була. 3 апрель иртәсендә Пугачев, иң якын ярдәмчеләрен җыеп, Ташлы авылында тагын бер мәртәбә киңәшмә үткәрә. Казак атаманнары Җаек шәһәрчегенә кайтырга тәкъдим итсә, Кинҗә, Муса, Садыйк, Идеркәй Урал тауларына, башкорт даласына күчү фикерен яклыйлар. Ниһаять, шул көнне үк фетнәчеләр, Кызыл Мәчет авылы аша үтеп, Ыргызлы елгасы буендагы Вознесенск заводына (хәзер Ыргызлы авылы) юнәләләр. Әлбәттә, юлда «падишаһ» гаскәренә яңа «казаклар» туплау дәвам итә. Вознесенскида Пугачевны ипи-тоз белән каршылыйлар. Бирегә тиздән Разлепиха авылы (Чиләбе өлкәсендә) янында подполковник Д. Гагрин тарафыннан тар-мар ителгән Григорий Туманов отряды да килеп кушыла.

Фетнәчеләр санының 1500 гә җитүен күрү Пугачевка, әлбәттә, дәрт өсти. Ул шушында кабат Хәрби коллегия төзи һәм аның сәркатибе итеп Иван Шундеевны, казый итеп Григорий Тумановны билгели. Вознесенскидан соң Пугачев һәм аның кул астына җыелган фетнәчеләр Авзяно-Петровск заводына килә. Без әлеге заводта Е. Демидовның фәкать 274 кенә шәхси колы булуын, ә 3708 крестьянның бирегә Казан провинциясендәге Котловка, Чистай, Кармалы, Шилнә, Казыли, Ачы, Шәле һәм башка авыллардан килеп эшләве турында бер кат әйттек инде. 22—23 октябрьләрдә Хлопуша моннан 500 кешелек отряд алып китсә дә, завод 10 ноябрьдә прапорщик Кандалинцев тарафыннан янә хуҗасына кайтарылган була. Ә Демидов Казан провинциясендәге крестьяннарны кабат үзенең заводына килеп эшләргә мәҗбүр итә. Хәзер инде завод икенче мәртәбә фетнәчеләр кулына күчә. Мондагы крестьяннар Пугачев гаскәренә 500 кешелек отряд төзеп кушыла. «Махсус Авзян полкы» дип аталган әлеге отрядның командиры итеп шушы ук заводка беркетелгән крестьян Дорофей Загуменнов билгеләнә, ул полковник дәрәҗәсенә лаек була.

*Фетнәчеләр гаскәре Казан провинциясенә кергәч, Загуменнов Пугачев тарафыннан Мамадыш өязенә, аның да әле Кама елгасы ягындагы Котловка, Костенеево, Омар, Тавели (Тау иле), Казыли (Казый иле), Колосовка, Танайка кебек авылларыннан яңа «казаклар» туплау өчен озатыла. Пугачевның Загуменновны ул белмәгән һәм аны (Загуменновны) белмәгән авылларга җибәрүе бик икеле, безгә калса, бөтенләй мөмкин түгел. Чөнки моңа кадәр Пугачев үзенең эмиссарларын нигездә аларның туган якларына озата торган була (кагыйдәдән читкә тайпылу дип мисалга Чика-Зарубин, Торнов, Шибаев фамилияләрен генә атау*

*мөмкин). Шуңа күрә Загуменнов та, аның отрядына кергән крестьяннарның зур күпчелеге кебек үк, Казан провинциясеннән булырга тиеш.*

12 апрельдә Пугачев Көньяк Уралдагы иң биек тауларның берсе — Әрвәк-Рәз (биеклеге диңгез тигезлегеннән 1067 метр) янында, Агыйдел буенда урнашкан Белорет (Белорецк) заводына килеп җитә. Бу завод 1762 елда нигезләнгән. Төзелеш өчен (билгеле, хәйлә генә) кирәк булган 300 мең дисәтинә җирне Сембер сәүдәгәрләре И. Твердышев белән И. Мясников башкорт старшиналарыннан нибары 300 сумга гына (10 дисәтинәне 1 тиенгә!) сатып алалар. Шул ук елларда завод янында бистә һәм 4—5 километр читтәрәк Арча авылы пәйда була. 1773 елда заводта 871 кеше эшли. Июль — август айларында гына да биредә төрле калибрдагы 39 туп, 1040 ядрә, 2792 богау һәм шул богаулар өчен 476 йозак хәзерләнә. (Белорет музеендагы архив мәгълүматлары. Байтак тарихи документлар экспонатлар итеп тә куелган. *Ә хәзер игътибар! Без югарыда татар укучысын гаҗәпләндерерлек бер исем атадык — «Арча авылы». Шул кадәр ерак җирләргә барып чыккач, әлбәттә инде, авыл исеме белән дә кызыксындык. Әлеге исемне яктыртучы тарихи документларны табу мөмкин булмады. Музей хезмәткәрләре дә, авыл картлары да бу исемне «Арский» фамилияле бургомистр, ягъни завод идарәчесе белән бәйли. Имеш, явызлыгы, кансызлыгы белән завод эшчеләренең үзгенә үткән шушы кешене фетнәчеләр Пугачев килгәч кулга алганнар да бүген Арча (Арск) ташы дип аталып йөргән биек кыя өстеннән Агыйдел елгасына ыргытканнар. Ләкин бу — уйдырма, олы хаталану. Чөнки, бердән, Арча ташы белән Агыйдел арасы әле бүген дә 50—60 метр тәшкил итә. Өстәвенә, Агыйдел элегрәк бу кыядан 200—300 метр ераклыкта аккан. Кешене андый ерак арага һич ыргытып булмый. Икенчедән, музейдагы экспонатлар төгәл сөйли: 1773 елда заводның идарәчесе Карл Шемберг, приказчиклары Михаил Осипов белән Давыд Федоров булган. Арский фамилияле кеше бөтенләй юк. Һәм өченче дәлил: иманлы халык үз авылын, җитмәсә әле, кыяны да явыз кеше исеме белән атап йөртми. Инде безнең фараз: әлеге авылны нигезләүчеләр Казан янындагы Арчадан Твердышев белән Мясников күчергән кешеләр булмаганмы?*

Пугачев өчен заводны кулга төшерү, әлбәттә, олы җиңү була. Язгы ташу башланып юллар өзелү авыр яулар кичергән Пугачевка биредә 3 атна буе ял итәргә мөмкинлек бирә. Ә ял итү өчен мондагы табигать гаять кулай (совет хөкүмәте анда юкка гына сәламәтләнү үзәге һәм туристлар базасы ачмагандыр). Белоретны төрле яктан гүзәл нарат урманнары уратып алган. Уртада саф сулы Агыйдел. Агыйделгә Нура елгасы кушылган җирдә буа. (1762 елда олы-олы кыя ташлары тутырып ясалган әлеге буа шул көенчә тора. «Надан» сәүдәгәрләр белән «томана» крестьяннар төзи дә белгәннәр соң!) Үзәнлек эчендә Агыйделгә терәлгән олы завод, ә һавасы — чип-чиста! (Ике биек тау сыртының уртасына утырган һәм инде галәмәт зурайган бу заводның төтенен Агыйдел буйлап искән җил бүген дә сәгате-минуты белән читкә алып китә. «Надан» сәүдәгәр завод урынын шундый «юк-бар»га да игътибар итеп сайлаган!)

*Хәзер инде тагын бер серне ачыйк. Пугачев Авзяно-Петровск заводындагы сөяркәсе, 19 яшьлек чибәр Фаина Фоминичнаны үзе белән Белоретка да алып килә һәм янә походка кузгалган чагында шушында калдырып китә. Соңрак Фаина «Петр падишаһ»тан бала таба. Әмма власть вәкилләре аңа фетнәчеләр юлбашчысының фамилиясен кушарга рөхсәт итми. Сабый җиһанда Емельян Емельянович Петров булып йөри. Белорет музеенда аның бүгенгә кадәр дәвам иткән шәҗәрәсе күрсәтелгән, бик күбесенең фоторәсемнәре куелган. Шунысы гаҗәп: Петров дәвамында хәрбиләр күп. Хәтта бүген дә 4 вәкил Рәсәй армиясендә хезмәт итә.*

Инде янә төп темага кайтыйк. Әлбәттә, Пугачев биредә ял итеп кенә калмый, яңа бәрелешләргә дә әзерләнә. Ул байтак командирларга, үз янына дәшеп, фәрманнар юллый. Хәрби коллегиянең казые Григорий Туманов, хатлар язып, татар-башкорт җайдакларын чакыра. Урыс, татар, башкорт крестьяннары үзләре дә, «падишаһ»ның кайда икәнен ишетеп, аның кул астына ашыгалар. Нәтиҗәдә Пугачев карамагындагы фетнәчеләр саны 5 меңгә җитә. Загуменнов (яки Авзян) полкына да Белорет заводының 300 эшчесе кушыла. Ә бу вакытта карательләр лагерендагы генераллар һәм офицерлар Пугачевның эзен тәмам югалталар. Казанда генерал Щербатов белән губернатор Брандт үзара ызгышып ята *(А. Пушкин)*. Оренбургта генерал Голицын үзенең кул астындагы генерал Мансуровны — Җаек шәһәрчегенә, подполковник Аршеневскийны — Самара белән Бөгелмәгә таба, генерал Фрейманны Уфа ягына юллый. Верхнеяицк крепосте (хәзер Верхнеуральск) янында — генерал Станиславский белән полковник Ступишин, Троицк крепостенда — бригадир Фейервар, Чиләбедә — генерал Деколонг белән подполковник Гагрин, Уфада Михельсон командалары һәм полклары тора. Пугачев инде һәрьяклап җәза отрядлары белән уратылган, мондый бөҗра эченнән фетнәчеләр отрядына түгел, хәтта күсегә дә чыгып качар урын калмагандай тоела. Әмма фетнә үзеген зур армия уратып алуга да карамастан, губернатор Рейнсдорп Оренбургта генерал Голицыннан күп кенә полкларны шунда калдыруын таләп итә. Пугачевны тотып китергән кешеләргә дә бүләк күләме октябрь аенда Рейнсдорп вәгъдә иткән 500 сумнан хәзер 10 мең сумга менеп җитә! Ләкин патша хөкүмәте юкка өметләнә.

Пугачевның фәрманнарын алгач, Уфа һәм Исет провинцияләрендә фетнә отрядлары кабат активлаша. «Падишаһ»- ның Татищево һәм Сакмар янындагы яулардан исән чыгуын ишетү һәр командирга дәрт өсти.

Пугачевның Сакмар янындагы җиңелүдән соң ашыгыч рәвештә яңа отрядлар тупларга боерып 4 апрель көнне язган фәрманын атаман Белобородов 9 ында Үр-Кыйгы авылында ала. Ул бирегә Бәхтияр Канкаев белән очрашырга килгән була. Походный старшинадан ары уза алмаган Бәхтиярга, билгеле инде, атаман һәм полковник дәрәҗәсен йөрткән Белобородовка буйсынырга туры килә. Шул көнне үк Белобородов Бәхтияр Канкаев, аның отрядындагы йөзбашлары Йосыф Юнысов, Габделкәрим Күзкәев, сәркатип Исмәгыйл Иманов исеменә фәрман язып бирә. Бәхтиярның отрядын алып, Белобородов Сатка заводына юнәлә. Ә Бәхтияр үзенең ярдәмчеләре белән Кыйгыдан янә Көнгергә таба, яңа отряд туплау өчен китеп бара. Бәхтиярга милләтләренә карап тормастан һәркемне үз кул астына җыйнарга һәм, селитра табып, дары җитештерүне җайга салырга әмер бирелә.

Яңа отряд туплау эшчәнлеген Бәхтияр янә үзенең туган төбәгендә башлый. Селитра эзләү бурычы дары ясау остасы Изги Әюповка тапшырыла. Ләкин эшләр сөенерлек бармый шул. Башкорт старшинасы Илчегол Иткулов, Әби патшаның хөкеме белән янап, Изги Әюповны бу эшеннән туктата. Илчегол отряд туплауда Бәхтиярга да аяк чала. Абдул авылына килеп, ул Бәхтиярга кушылган крестьяннарны кыйнап йөри. Ә икенче бер авылда, мәсәлән, исерек килеш куркытып, Бәхтияр отрядындагы кешеләрне үзенә куша. Хәтта мишәр старшинасы Сөләйман Күзкәев тә (ул җәй җиткәч, карательләр ягына күчәчәк) Белобородов фәрманын тыңларга һәм Бәхтиярга буйсынырга теләми («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания и переписка...»).

Башка старшиналар тарафыннан шундый үчләшү һәм каршылыкларга да карамастан, Бәхтияр апрель уртасында яңа отряд туплауга ирешә. Фетнәчеләр арасында тәртип урнаштыра, карательләр Көнгер ягыннан һөҗүм итмәсен өчен, каравыллар куя. Алпавытлардан талап алынган байлыкны, тигез итеп, һәрбер командага бүлә. Апрель ахырында инде Бәхтиярга Байкы-баш авылыннан (Караидел районында) татар йөзбашы Ишмәт Мәмәткулов, Уфа провинциясенең Себер юлында яшәүче мариларның баш старшинасы Каникей Яшпохтин, урыс йөзбашы Осип, Көнгер өязе татарлары тарафыннан 1767 елда Уложение комиссиясенең депутаты итеп сайланган Бакый мулла Абдуллов, исеме билгесез авылдан, әмма Көнгер өязеннән булган татар йөзбашы Иман Аладинов кул астындагы командалар буйсына («Документы ставки Е. И. Пугачева...», «Воззвания и переписка...»).

Ниһаять, 28 апрель тирәсендә мишәр каһарманы Бәхтиярга да полковник дәрәҗәсе бирелә. Байкы-баш авылында яшәгән Ишмәт Мәмәткулов, шушы ук авыл вәкиле Зәйнәш Сөләйманов һәм башкалар 29 апрельдә язган хатларында Бәхтиярны беренче кат шулай зурлыйлар. Мондый дәрәҗә аңа апрель ахырында Белорет заводында торган «падишаһ»ның шәхсән үзе тарафыннан бирелгәнме, әллә яңа отряд туплауда күрсәткән тырышлыгы өчен аны атаман Белобородов шулай зурлаганмы — ул кадәресе турында документлар дәшми. Бәхтияр Канкаев белән Белобородов бу көннәрдә бер-берсе белән янәшәдә генә хәрәкәт итә. 27 апрельдә Ишмәт Мәмәткулов, мәсәлән, Белобородов белән очраша («Воззвания и переписка...», док. №97). Ә 29 апрельдә Ишмәт Байкы-баш авылына кайтып җитә (док. №98). Тарихи документлардан Белобородовның Түбән Кыйгы авылында Катау-Иван заводы янындагы бистә атаманын, Көнгер каласында Папава кул астында торган карательләрнең шымчысы булып йөргән урыс вәкилен дарга асуы билгеле *(Ю. Лимонов)*. Шуңа күрә Иван Белобородовны апрель ахырында Башкортстанның Кыйгы районында, май башында Сатка заводы янында (Екатеринбург өлкәсендә) хәрәкәт иткән, дип нәтиҗә ясарга нигез бар. Ә тиздән Белобородовка ашыгыч рәвештә Магнитная крепосте (хәзерге Магнитогорск) янына юнәлергә һәм «падишаһ» гаскәре белән кушылырга боерган 2 май фәрманы килеп җитә.

«Падишаһ» үзе апрель ахырында Белорет заводында ял итсә дә, 1773 елның ноябрь — декабрендә аның тарафыннан эмиссарлар итеп озатылган күренекле җитәкчеләрнең берсе дә бу көннәрдә хәрәкәтсез тормый. Каранай Моратов ай ахырында Эстәрлетамак пристане һәм Дүсмәт авылы янында карательләргә каршы яу алып бара. Уфа провинциясенең Ногай юлында хәрәкәт иткән Канзафар Усаев һәм Күчәпкул Әҗәтев (Азятов) отрядлары бу көннәрдә Каранай белән бергә кушылып хәрәкәт итәргә тырыша, ләкин аларга Табын крепостена килеп җиткән генерал Фрейман гаскәрләре комачаулык итә. Сөләйман Күзкәевнең 1000 кешелек отряды Себер юлыннан Бөрегә таба юнәлә һәм 22 апрельдә Теперәш авылы (Чишмә районындагы татар авылы) янында секунд-майор Тютчев командасы белән бәрелешә. Бөре каласын һаман Бүләк Якупов, Аладин Биктуганов, Арыслан Рангулов, Балтач Сәетов, Ярмөхәммәт Кадермәтов отрядлары камалышта тота. Ә Салават Юлаев апрельдә Сим заводы янында хәрәкәт итә. Фетнәгә аның этисе Юлай Азналин да кушыла. Салават отрядында 1000 гә якын фетнәче исәпләнә *(В. Буганов)*. Апрель ахырында ул Катау-Иван заводын ала һәм 2 майда янә Сим заводына кайта.

Бу вакыт эчендә карательләр лагере тулысынча диярлек хәрәкәтсез тора. Михельсон гына, 24 апрельдә үз командасы белән Уфадан чыгып, Көнгергә таба юнәлә һәм Богородское авылына барып җитә. Әлеге

авылга Көнгердә торучы карательләр отряды да килә һәм Иван Белобородов яшәгән йорт- ны нигезенә кадәр сүтеп, бүрәнәләрен Көнгер каласына алып китә. (Информация өчен шунысын да өстик: фетнәгә кушылганнан соң, Белобородов үзе белән бергә гаиләсен дә йөртә. — *Ю. Лимонов*). Богородскоедан Михельсон Исет провинциясенә юнәлә. Уфадан 166 чакрым ераклыкта урнашкан Сим заводына Михельсон, дистәләгән елгаларны кырык төрле михнәт белән кичеп, күп урында күперләрне үзе төзетеп, 6 майда гына килеп керә («Крестьянская война... на территории Башкирии»; «Документы ставки Е. И. Пугачева...»; *Н. Дубровин*).

Пугачев 2 май көнне 5000 кешелек гаскәр белән Белореттан юлга чыга һәм Магнитная крепостена юнәлә. Үзе киткән чакта Пугачев, завод яңадан карательләр кулына төшмәсен, аларның базасына әйләнмәсен һәм завод туп белән ядрәләр коя алмасын өчен, Белоретка ут төртергә боера. Шундый ук фәрман башка заводларда торучы отряд командирларына да җибәрелә.

5 май көнне Пугачев Магнитная янына килеп җитә. Крепостьны капитан С. Тихановский командалыгындагы 100 солдатлы, 10 туплы гарнизон саклый *(В. Буганов)*. Кул астында 5000 кешелек гаскәр булса да, крепостьны тупсыз-нисез штурмлау Пугачевка җиңү китерми. Өстәвенә, кулына ядрә кыйпылчыгы тиеп, «падишаһ» яралана. Төнлә фетнәчеләр 5 отрядка бүленә, каравылда торучы сакчылар тавыш-тынсыз юк ителә. Камалышта калган крепостьның үзендә дә фетнәчеләргә ярдәм итүче табыла, анда кемдер дары тартмаларын шартлата. 6 майда иртәнге сәгать өчтә крепость Пугачев кулына күчә. Хатыннары белән бергә Тихановский һәм поручик Можаитиновны, шулай ук крепостьтагы попны да дарга асалар *(Н. Дубровин)*. Икенче көнне Пугачевка Җаек шәһәрчеге яныннан качып котылган атаманнар Овчинников белән Перфильев килеп кушыла. Әлеге крепостьта Пугачев гаскәре тагын 500 кешегә арта.

8 майда Пугачев гаскәре Магнитнаяны калдыра һәм Карагай (Уклы-Карагай) крепостена юнәлә. Юлда аларга Белобородов кул астындагы отряд якыная. Фетнәчеләр, тигез сафларга тезелеп, байраклар күтәреп килә. Үз гаскәрен бер тапкыр да сафларга тезеп карамаган Пугачев Белобородов отрядын карательләр командасы дип кабул итә һәм яуга хәзерләнә башлый. Ләкин тиздән ялгыш ачыклана. Белобородов отряды «падишаһ»ны әләмнәрен иеп сәламли.

Карагай юлында Җаек буендагы хәрби чик дистанциясенең үзәге булып саналган Верхнеяицк крепосте ята. Аны бер үк вакытта дистанция командиры да, крепость коменданты да булып исәпләнгән полковник Е. Ступишин командасы саклый. Дистәләгән туплары, ким дигәндә 500—600 кешелек гарнизоны булган Верхнеяицк крепосте Пугачев өчен яулый алмаслык һәм дәһшәт бөркеп торган ныгытма була. Җитмәсә, нәкъ шул көннәрдә бирегә Чиләбедән килгән генерал Деколонг полклары да кушыла.

Сакмар буенда тар-мар ителүдән соң, Пугачевның Җаек шәһәрчегенә яки чик буена түгел, бәлки Рәсәй үзәгенә чигенүе, шуның белән бергә бөтен Идел буен янә фетнә ялкыны чолгау мөмкинлеге карательләр лагеренда шулкадәр каушау һәм башбаштаклык тудыра ки, моны бүген гаҗәпләнмичә күзәтүе читен. Сакмардан киткән Пугачевның эзен югалткач, хөкүмәт гаскәрләре арасында, әйтерсең, мәхшәр куба. Башкомандующий итеп билгеләнгән генерал Щербатов язгы ташудан соң юллар ачыла башлагач, Казанны ташлап, Оренбургка чыгып китә һәм аңа 19 майда гына барып җитә. Юллар өзелү сәбәпле, Табын крепостена бикләнгән генерал Фрейман апрель ахырына кадәр шунда утыра, 8 майда Авзяно-Петровск заводын ала һәм Магнитнаяга таба кузгала. Ә Фрейман калдырган, Табын крепостена, Пугачев килеп кермәсен дип, подполковник Рылеев командасы җибәрелә. 23 апрельдә генерал Голицын тарафыннан Оренбургтан озатылган Тимашев отряды Зелаир крепостена кадәр генә бара да шуннан ары китми. Пугачевның янә әйләнеп кайтуыннан куркып, Голицынның үзен Оренбургтан губернатор Рейнсдорп җибәрмичә тота. Әмма генерал Деколонг җебегәнлектә һәммәсен дә уздыра. Пугачевның Сакмар буеннан качуын ишеткәч, ул аны әүвәл Чиләбегә килеп чыгар дип курка. Шуңа күрә 24 апрельдә Чиләбене полковник В. Бибиков карамагына калдырып, көчле ныгытылган Верхнеяицк крепостена китеп бара. Ул полковник Ступишин һәм үзенең кул астындагы полкларны да азсына. Деколонг Карагай, Степная, Петропавловск крепостьларындагы гарнизоннарның да төп өлешен Верхнеяицкига дәшә. Өстәвенә, ул әле подполковник Гагринга да үз командасы белән бирегә килеп җитәргә фәрман юллый.

Верхнеяицкига тупланып һәм фетнәчеләрнең генераль һөҗүмен көтеп яткан карательләрнең һәммәсен Пугачев «кызык итә». Ул әлеге крепостьны урап үтә һәм 10 майда Карагайны камап ала. Деколонг мондагы гарнизонның төп өлешен Верхнеяицкига чакыртканга күрә, хәзер аны прапорщик Вавилов командалыгындагы карт солдатлар гына саклый. Юкка кан коймау нияте белән, фетнәчеләр хәйлә коралар. Вавиловны тез чүгәргә үгетләү өчен Белобородов крепостька кереп китә *(Ю. Лимонов)*. Шул вакытта Исхак Әхмәтов җитәкчелегендәге татар җайдаклары искәрмәстән һөҗүм ясыйлар һәм атышуларсыз гена крепостьны кулга төшерәләр. Шушы кыюлыгы өчен Пугачев Әхмәтовка полковник дәрәҗәсе бирә (*С. Алишев*. Татары...»).

Карагайдан соң Пугачев гаскәре Степная, Петропавловск крепостьларын, Подгорная һәм Санар редутларын ала. 19 майда Троицк крепостен камый. Пугачев Магнитная янында алган ярасыннан сызланып палаткада ятканга күрә, штурм белән Белобородов җитәкчелек итә (дөресрәге, җитәкчелекне Белобородовка тапшыру — ул Җаек казаклары корган мәкер була. Белобородов Златоустта завод талагандагы комсызлыгы өчен казаклар есаулы Иван Шибаевны кулга ала. Әмма Магнитная янында килеп кушылгач, казаклар Шибаевны яклыйлар һәм аңа полковник дәрәҗәсе бирдертәләр. Хәзер инде, крепостьны яулый алмаган тәкъдирдә, казаклар Белобородовны бөтенләй юкка чыгармакчы булалар. — *Ю. Лимонов*). Штурм әллә ни озакка сузылмаса да, фетнәчеләр арасыннан 30 кеше һәлак була. Аның каравы, «падишаһ»ны «танырга» теләмәгән гарнизоннан да иркенләп үч алалар. Комендант- бригадир де Фейервар белән 4 офицер дарга асыла. Фейерварның каядыр яшеренгән хатыны Анна Андреевнаны аларның хезмәтчесе Александр Васильев сата. Шул ук Васильев Аннаны явызлыкта гаепли. Фетнәчеләр Аннаны әүвәл ат койрыгына таккан көенчә сөйрәтеп газаплыйлар, аннары дарга асалар (Васильевның мондый «тугрылыгы», әлбәттә, гафу ителми. 1774 елның 8 октябрендә Рейнсдорп фәрманы буенча аны Оренбургта кисәкләргә чапкалап үтерәләр. — ОӨДА, 3 фонд, 1 тасвир, 140 эш, 30 бит).

Фетнәчеләр тантанасы озакка сузылмый. 21 майда Пугачев гаскәрен ниһаять «акылга килгән» генерал Деколонг полклары куып җитә. Пугачев 10 мең кешегә җиткән гаскәрен крепость каршындагы кырга чыгарып туплый. Деколонгны алар туплардан ут ачып каршылыйлар, аннан һөҗүмгә күчәләр. Ләкин регуляр полклар тарафыннан залп булуга ук, фетнәчеләр як-якка сибелә. Карательләр шушы көнне ак-караны аермыйча качучы 4000 гә якын фетнәчене юк итәләр, 70 кеше, шул исәптән Григорий Туманов та әсирлеккә эләгә. Пугачевның үзен әсирлектән һаман да шул махсус «падишаһ» аты гына коткара.

*Тумановны яу барышында башкача очратмабыз, шуңа күрә алдагы язмышы хакында әйтеп калыйк. Шул ук елның июнь уртасына кадәр ул Верхнеяицк крепостенда тотыла. 15 июнь көнне полковник Ступишин аны каравыл сагы астында Оренбургка озата. Июнь ахырында әлеге отряд Гөберле крепостена (Оренбург өлкәсенең Гай районында) килеп җитә. Шулвакыт отрядка кыргыз-кайсак (казах) «караклары» һөҗүм итә һәм Тумановны «коткарып», «коллыкка» алып китә. Әлбәттә, болар кол яулау хакына угрылыкка чыккан казахлар түгел, бәлки Пугачев явына кушылган ярлылар була. Өстәвенә, Тумановка казах телен белүе дә ярдәм итүе мөмкин. Чөнки Магнитная крепостеннан казахларга юлланган манифестны нәкъ менә Туманов яза. Бәлки, алар әлеге полковникны әсирлеккә эләкми калган һәм каравыл отряды артыннан күзәтеп барган берәр фетнәче чакыруы буенча килеп азат иткәндер. Ничек кенә булмасын, Тумановның фамилиясе шуннан соң тарихи документлардан югала. Губернатор Рейнсдорпның казах солтаннарына ярдәм сорап мөрәҗәгать итүе дә һичнинди нәтиҗә бирми. Керәшен татарымы ул, түгелме? Туманов, соңыннан мөселман фамилиясенә кайтып, фетнәдәге эшчәнлеген дәвам итмәгәнме? Ни кызганыч, боларны белеп булмый.*

Ә Троицк янындагы яудан исән-имин котылган фетнәчеләрнең күпчелеге, бер тәүлек вакыт узуга ук, янә Пугачевка кушылалар. Гомуми саны 2000 кешегә җиткән отряд белән Пугачев Урал заводларына таба борыла. Шул ук көнне, 22 майда, алар Кундравинская бистәсе белән Лягушино авылы арасындагы кырда Михельсон карательләре белән очрашалар. Пугачевның Деколонг тарафыннан тулысынча тар-мар ителүе турында хәбәр алган Михельсон, билгеле инде, фетнәчеләрнең бер тәүлек эчендә янә шундый зур отрядка туплана алуына гаҗәпләнә. Беренче минутларда ул фетнәчеләрне хәтта Деколонг командасы дип кабул итә. Ләкин тиздән яу башлана, фетнәчеләр кабат тәртипсез рәвештә кача башлый. Карательләр аларны 15 чакрым буе куып бара. Нәтиҗәдә 600 фетнәче һәлак була, 400 кеше әсирлеккә төшә. Әмма бу юлы да Пугачев качып котыла һәм, киткән чакта ут төртеп, 29 май — 2 июньдә Чибәр күл, Кундрава, Златоуст, Сатка заводлары аша уза. Аннары ул Үр-Кыйгы авылына юнәлә һәм мөселман отрядлары белән кушыла.

Хикәятебез барышында Салават отряды белән 2 май көнне аерылышкан идек. Хәзер Салаватның май аендагы эшчәнлегенә күз йөртеп чыгыйк.

2 майда Салават Сим заводына кайта. Уфадан 24 апрельдә чыккан Михельсон командасы бирегә 6 май көнне якынлаша. Салават аны заводтан 17 чакрым ераклыкта 500 җайдак белән ике тау арасындагы иңкүлектә каршылый. Михельсон командасында регуляр гаскәр солдатларыннан тыш хыянәтче мишәр-ләрдән төзелгән җайдаклар да була. Михельсон мишәрләр һәм Чугуй казаклары белән һөҗүм итә, фетнәчеләр таудагы урманга кереп кача. Соңыннан алар, Сим заводын узып, аннан 16 чакрымдагы Ерал авылына җыелалар. Михельсон буш калган заводка үтә, ә төнге 12 дә походка кузгалып, таң атканда инде Ерал авылына (саналган пунктлар хәзер Екатеринбург өлкәсендә) барып җитә. 1500 гә якын фетнәче, авыл-ны калдырып, Михельсонны 4 чакрым читтәге кырда каршылый. Карательләр аларны урап алырга омтылуга да карамастан, фетнәчеләр чигенми. Ләкин яу башлангач, крестьяннар кача башлый. Михельсон җайдаклары аларны 7 чакрым буе куа. 300 гә якын фетнәче һәлак була, 17 се әсирлеккә эләгә.

Салават отряды Усть-Катау заводына чигенә, Михельсон аның эзенә басып бара. 9 май көнне Михельсон фетнәчеләрне мәкер белән алдауга да ирешә. Ул үзенең отрядындагы 150 мишәрне аерып ала да, кулларына мөселман әләмнәре тоттырып, фетнәчеләр яшеренгән урманга җибәрә. Ул арада үзе, отрядын икегә бүлеп, Салаватны камарга тырыша. Мөселман байракларын күргәч, фетнәчеләр чыннан да алдана. Ләкин тиздән яу башлана. Тагын 13 крестьян һәлак була, 96 кеше әсирлеккә төшә. Калганнары Катау заводына таба качып котыла. Шуннан соң Михельсон Салаватның эзен югалта. Үзе 15 май көнне Сатка заводына килеп җитә. 16 сында Кундрава бистәсенә юнәлә һәм 22 майга кадәр шунда тора.

Пугачевның да эзен югалткан Михельсон 27 май көнне кабат Сатка заводына кайта. Салават отряды бу вакытта Сим заводында тора. Ул әлеге заводка кабат 23 май көнне килә һәм Пугачевның «киткәндә заводларны яндырырга» дигән фәрманын күптән алган була. Шул көнне үк Сим заводын да ялкын чолгый, Михельсонга баш игән 102 кеше юк ителә. Шуннан соң Салават Әй елгасы буена, Кыйгы районына юнәлә. Юлда Салават старшина Тәиш Чыныкаев отряды белән кушыла, фетнәчеләр саны 2 000 гә җитә.

Михельсон Салават һәм Тәиш отрядларын 31 май көнне куып җитә. Фетнәчеләр аңа Әй елгасы аша кичәргә комачаулыйлар. Әмма туплардан атып, Михельсон фетнәчеләргә елга буена якынаерга ирек бирми. Ул арада җайдаклар елганы йөзеп чыга. Михельсон крестьяннарны 20 чакрым буе куып бара. 150 фетнәче, шул исәптән Тәиш старшина һәлак була. 1 июньдә Михельсон Үр-Кыйгы авылына килеп җитә, икенче көнне ул авылдан 3 чакрым читтә лагерь корып урнаша.

2 июнь көнне Сатка заводына ут төрткәннән соң, Кыйгы районына Пугачев отряды да килеп җитә. Канзафар Усаев,  Салават һәм Пугачев отрядлары шушында бергә кушыла.

3 июнь таңында Михельсон лагере каршында фетнәчеләрнең 1000 кешелек отряды пәйда була. Михельсон туплардан ут ача, аннан соң җайдакларын һөҗүмгә ташлый. Фетнәчеләр Әй елгасы буена чигенәләр. Шул чагында Пугачев җитәкчелегендәге 1000 кешелек бер отряд, икенче яктан килеп, Михельсон гаскәренең олауларына һәм аларны саклаучы пехотага һөҗүм итә. Карательләр чакрым ярым чамасы чигенәләр. Хәлнең мондый аяныч төс алуын күргән Михельсон, фетнәчеләрне Әй буена кысрыклап, җайдакларны үз янына чакыртырга мәҗбүр була. Михельсон шул кавалерия белән Пугачев камалышка алган карательләрне коткарырга ташлана. Бердәм һөҗүм астында Пугачев җитәкләгән отряд 3 чакрымга чигенә. Шуннан соң ул барча фетнәчене бергә туплый һәм янә Михельсонга һөҗүм итеп карый. Михельсон бу юлы да кавалерия белән аңа каршы чыга. Пугачев чигенә. Михельсон аны 5 чакрым буе куып бара. Әлеге яу барышында 400 фетнәче һәлак була. Карательләр арасыннан 23 кеше үтерелә, 16 сы яралана. Ахырда Пугачев, үзенең кул астына 3000 гә якын фетнәчене туплап, таудагы урман эченә чигенә. Михельсон аны 12 чакрым буе кавалерия белән эзәрлекли. Ләкин фетнәчеләрнең эзен югалта һәм махсус лагерь корып тукталырга мәҗбүр була. 4 июньдә аңа Пугачевның Әй елгасы аръягына кичүен хәбәр итәләр. 5 июнь таңында Михельсон да елганы нәкъ шул урында кичә һәм Пугачев лагерена якынлаша. Әмма фетнәчеләр, алдан ук сизенеп, Михельсонны таулар арасында каршылый, көтелмәгән урыннарда һөҗүм ясый. Шулай да регуляр гаскәр басымы астында Пугачев чигенә, бәрелешләр вакытында тагын 70 фетнәче һәлак була.

Михельсонның инде Пугачевны тагын да эзәрлекләрдәй көче калмый. Генераллар тарафыннан үзенә һичнинди ярдәм күрсәтелмәвенә ачынган Михельсон кире борылырга мәҗбүр була. Отрядын солдатлар һәм корал белән тулыландыру, атларны алыштыру өчен Михельсон Уфа каласына китеп бара. 8 июнь көнне ул инде Сим заводына кайтып җитә («Крестьянская война... на территории Башкирии»).

# ФЕТНӘЧЕЛӘР  МАРШЫ

### *КРАСНОУФИМСК, БӨРЕ*

Карательләр эзәрлекләвеннән котылган Пугачев Әй елгасы буенда ялга туктала. Әле 21, 22 майларда гына ике тапкыр тар-мар ителеп, карательләр кулына эләгүдән көч-хәл белән качып котылган «падишаһ» санаулы көннәр эчендә үзенең кул астына янә 3 мең кешелек һәм тулысынча диярлек татар-башкортлардан торган гаскәр тупланугa, әлбәттә, бик сөенә. 5 июнь көне фетнәчеләр лагеренда зур тантана белән билгеләп үтелә. Кайбер документларга караганда, бу көнне «падишаһ» каршында фетнәче отрядларның хәтта парады да («смотрины») үткәрелә. Җаек казаклары басымыннан беркадәр азат булган Пугачев мөселман командирларын югары хәрби дәрәҗәләр белән бүләкли. Канзафар Усаевка — барча мишәрләрнең баш полковнигы (бригадир), Юлай Азналинга — Себер юлындагы волостьларның баш атаманы, Салават Юлаевка баш полковник дәрәҗәсе бирелә.

6 июнь көнне бирегә Бөре каласы янында хәрәкәт итүче отряд командирларыннан рапорт белән Габделкәрим Әитов килеп җитә. Рапортка җавапны Салават Юлаев яза. Ул хатта «падишаһ» гаскәренең Көнгер каласына таба юнәлүен хәбәр итә, Бөре янындагы отряд башлыклары Бүләк Якупов, Аладин Биктуганов һәм Арыслан Рангуловка да шунда юнәлергә әмер бирә. Шул көнне үк Г. Әитовка Пугачевның Хәрби коллегиясе тарафыннан есаул дәрәҗәсе дә бирелә, һәм ул, мишәр авылларыннан яңа отрядлар туплау өчен, ашыгыч рәвештә Бөре янына кайтып китә. Без укучылардан югарыда бәян ителгән вакыйгаларны күрсәтүче даталарга игътибар итүләрен үтенәбез. Чөнки урыс әдәбиятында һәм байтак тарихчылар хезмәтендә яшәп килгән гаделсезлек безне янә читкә тайпылырга мәҗбүр итә.

*Петербург галимнәре В. Панеях, В. Мавродин һәм Ю. Лимонов авторлыгында 1965, 1975 елларда нәшер ителгән хезмәтләрдә, шулай ук Ростов университетыннан безнең өчен шактый таныш «галим» Х. Муратов һәм Башкортстан тарихчысы Ә. Усманов китапларында, тагын Уфада дөнья күргән «Очерки по истории Башкирской АССР» һәм «Участие народов Башкирии в крестьянской войне 1773—1775 гг. под предводительством Е. И. Пугачева» дигән хезмәтләрдә — һәркайсында «Бөре каласын 1774 елның 4—5 июнендә Салават Юлаев алган» дип раслана. Алай гына да түгел, Петербург галимнәре, хәтта «Пугачев белән кушылганнан соң, Салават әүвәл Бөрене алырга үзенә буйсынучы Бәхтияр Канкаев һәм Аладин отрядларын юллый; тегеләр анда җиңелеп кире чигенгәч, Салават үзе юнәлә һәм штурм ясап Бөре каласын ала», дип нечкәләп тәкрарлыйлар (1965 елгы китап, 131 б.). Галимнәр шушында ук Салават һәм Юлай Азналинның Пугачев тарафыннан яңа хәрби дәрәҗәләр алуын да тасвирлыйлар, ләкин алар белән бергә татар каһарманы Канзафар Усаевның да мондый хөрмәткә ия булуын «әйтми» калдыралар. Ярар, башкорт вәкилен каһарман итеп күтәрү бәрабәренә Канзафар хакында әйтмәсеннәр, Бәхтияр Канкаевны да Салаватка буйсындырып куйсыннар һәм булдыксыз командир итеп күрсәтсеннәр, ди. Әмма, барыбер, әлеге «галимнәр»нең сукырлыгына һәм хәрәмләшүенә гаҗәпләнмичә булмый. 5 июньдә Әй буенда булып, Пугачев кулыннан бригадирлык билгеләре алган Салаватның шул ук көнне 300—500 чакрымдагы Бөре каласын штурмлавы мөмкин хәлмени?!*

Хәзер Бөре тирәсендәге фетнә хәрәкәтен тасвирлап үтик. Фетнәчеләрнең Бөрене әле 1773 елның ноябрь аенда ук камалышка алуы, шәһәр коменданты премьер-майор Ф. Моисеев белән вахмистр Мясниковның андагы гарнизонны сержантлар карамагына ташлап качуы, соңыннан шул ук Моисеевның, февраль аенда Сарапулны алган атаман А. Вязовой кулына төшеп, Чесноковкада дарга асылуы хакында без инде беркадәр язып узган идек. Бөре каласы янында фетнәчеләр белән карательләр арасындагы бәрелешләр ноябрь аеннан бирле тынмый һәм 1774 елның язында аеруча кискен төс ала. 13 апрельдә Михельсон Уфадан Бөрегә майор Тютчев командасын юллый. Тютчев 22 апрельдә Сөләйман Күзкәев отряды белән бәрелешә. Ләкин Бөре тирәсе барыбер фетнәчеләр хәрәкәтеннән арындырылмый. Михельсон үзенә буйсынучы капитан А. Мельгуновка 5 май көнне Уфадан Бөрегә юнәлергә әмер бирә, әмма фетнәчеләр һөҗүменнән дер калтырап яшәгән комендант Мясоедов Мельгуновны Уфадан чыгармыйча тота. Ниһаять, май башында Бакалыда торган полковник Обернибесов үзенең кул астындагы секунд-майор О. Дуве отрядын Бөрегә юллый. Дуве бирегә 25 май көнне генә килеп җитә. Шул көнне аңа Уфадан килүче капитан Мельгунов отряды һәм шәһәрнең яңа воеводасы итеп билгеләнгән капитан Суровцев та кушыла.

Бу вакытта Бөрене башкорт (?) старшиналары Арыслан Рангулов, Аладин Биктуганов һәм Дуван волостендагы Бәйки авылы (Кушнаренко районында) татары Бүләк Якупов җитәкчелегендәге отрядлар камалышта тота. 25 май көнне булган канлы бәрелеш нәтиҗәсендә шәһәргә карательләр үтеп кергәннән соң, югарыда саналган өч командир якын-тирә төбәкләрдә хәрәкәт итүче бүтән отряд җитәкчеләрен ашыгыч рәвештә ярдәмгә чакырып чапкыннар юллый. Без шундый бер чапкынның — Бүләк Якупов отрядында булган мишәр вәкиле Габделкәрим Әитовның — Кыйгы районына баруы һәм 6 июньдә Салават Юлаев белән очрашуы хакында әйттек инде.

Шундый ук чапкыннар полковник Бәхтияр Канкаев һәм атаман Гадел Бигашев янына да килә. Канкаев белән Бигашев ашыгыч рәвештә Уса юлына юнәләләр. Юлда отрядларны яңа фетнәчеләр хисабына тулыландыру дәвам итә. Алар май ахырында хәзерге Балтач районының татарлар, мишәрләр яши торган Уразай авылында вакытлыча лагерь корып урнашалар. Бу вакытта Бөре янындагы фетнәчеләргә яңа отрядлар кушыла тора. Бирегә татар фетнәчеләренең походный старшинасы Ярмөхәммәт Кадермәтов, 1774 елның апреленнән бирле Салават Юлаев белән бергә хәрәкәт иткән татар йөзбашы Габдулла Туктаров, Бикмәт авылы татары, походный старшина Балтач Сәетов җитәкчелегендәге отрядлар килеп җитә.

Бу көннәрдә карательләр дә хәрәкәтсез ятмый. Бөре каласына бикләнгән гарнизонның аяныч хәлдә калуын белеп, Уфадан полковник А. Якубович командалыгындагы 470 солдат юлга чыга. Аларга хыянәтче мишәр старшинасы Аблай Исмәгыйлов, башкорт старшинасы Ихсан Баязитов кул астындагы 466 кешелек җәза отряды да өстәлә. Әмма аларның берсе дә, фетнәчеләр бożрасын өзеп, Бөрегә үтә алмый.

1 июнь көнне Б. Якупов, Я. Кадермәтов, А. Рангулов, А. Биктуганов, янә чапкын юллап, Уразай авылында торучы Б. Канкаев белән Г. Бигашевны чакыралар. 2 июньдә Канкаев белән Бигашев Бөре янына киләләр һәм каланы камалышта тотучы барча отрядларның юлбашчыларына әвереләләр. Гомуми саны белән 5000 кешегә җиткән фетнәчеләр гаскәре һәрьяклап Бөрегә якынлаша. Бөре тирәсендәге Купай, Дүсмәт, Бикмәт, Бәдрәк, Күзбай, Кодаш, Каенлык һәм башка авылларда (Кушнаренко, Борай, Чакмагыш, Тәтешле районнарында) яшәгән татарларның күпчелеге фетнәчеләр сафына кушыла.

3 июнь көнне полковник Якубовичның карательләр отряды Бөренең янына ук килеп җитә. Камалышта калган майор Дуве аның янына чапкыннар юллый, аннан фетнәчеләргә һөҗүм ясавын һәм Бөрегә керүен таләп итә. Әмма Якубович урыныннан селкенми, хәтта Дувеның хатларына җавап та бирми. Җебегән полковникның ярдәменнән өмет өзгән Дуве 3 июнь көнне капитан А. Мельгуновны Уфага рапорт белән юлларга мәҗбүр була.

4 июнь таңында фетнәчеләр һәрьяклап штурмга ташлана. Иртәнге алтыда алар урамнарга бәреп керә. Бөренең һәр почмагында диярлек янгын башлана. Шәһәрне калдырып, майор Дуве Агыйделнең сулъяк ярына чыга. Чапкын юллап, ул полковник Якубовичтан янә фетнәчеләргә һөҗүм ясавын үтенә. Һөҗүм урынына Якубович Дуведан үзенә ярдәмгә 100 солдат һәм бер туп бирүен таләп итәргә тотына. Полковникка буйсынырга тиеш булган майор Дуве, аптырагач, Якубович янына 100 солдат җибәрә, үзе 160 җайдак, 40 җәяүле солдат һәм 1 туп белән кала. Ләкин Якубович бу юлы да фетнәчеләргә һөҗүм итми. Ни гаҗәп (бу полковникның җебегәнлеген бәяләрдәй сүзләрне табуы да читен), Бөре каласын ташлап, Якубович Уфаны «фетнәчеләрдән саклау өчен» кайтып китә. Чарасыз калган майор Дуве да аның үрнәгенә иярә.

Ләкин карательләр фетнәчеләр эзәрлекләвеннән котыла алмый. Бөрене алучы татар каһарманнары Бәхтияр Канкаев белән Гадел Бигашев алар артыннан аерым отрядлар юллыйлар. Бикмәт авылы вәкиле Балтач Сәетов Туктар авылына (Мишкә районында) Агыйдел аша кичү урынын саклау өчен озатыла. Уфа каласын һәрьяктан уратып алган татар авылларыннан тупланган крестьяннарның фетнә отрядлары карательләргә һөҗүм итә.

1 июньнән соң Бәхтияр Канкаевның сугышчан эшчәнлеге кискен активлаша. Ул июнь аенда Бөре янына тупланган барлык фетнәчеләрнең хәрби юлбашчысына әверелә. Моны походный старшина дәрәҗәсен йөрткән җитәкчеләр генә түгел, хәтта атаман Гадел Бигашев, татар полковниклары Ярмөхәммәт Кадермәтов, Габделкәрим Рыскулов, башкорт (?) атаманнары Арыслан Рангулов һәм Аладин Биктуганов та таный. Бәхтияр Канкаевка Бөре янында татар командирлары Бүләк Якупов, Габдулла Туктаров, Сәетьягъфәр Зәйсәнов, Габделваһап Хәсәнов, Габделкәрим Әитов, Рамазан Урманчиев, Сәлим Әитов, Зөлкәрнәй Йосыпов, Балтач Сәетов, Әмир Нәүрүзов, Усман Исламов, Салих Нәүрүзов, Ишкенә Уразов, Габдулла Мәмәтов, Габбас Мөслимов, Габделкәрим Собханкулов, Хәмит Мәхмүтов (Мөхәммәтов), Әбил Байдашев (Иван Иванов) кына түгел, бәлки башкорт старшиналары Әит Сәгыйтов, Мөхәммәт Әбдекәев, мари старшиналары Бәйки Туйкиев, Әхмәр Агеев, Федоська Янбактин һәм башка җитәкчеләр буйсына. Отряд командирларының бик күбесе Бәхтиярга юллаган рапортларында аны «гаскәр башлыгы» («войсковой предводитель») дип зурлый.

Полковник Якубович һәм майор Дувеның җәза отрядлары Уфага качса да, Бәхтияр Канкаев фетнә зонасын киңәйтү, хыянәтче старшиналардан үч алу, отрядлар санын яңа фетнәчеләр белән тулыландыру, карательләргә көтелмәгән һөҗүм ясарга ирек бирмәү өчен күп көч куя. Ул йөзбашы С. Зәйсәновны, мәсәлән, хыянәтче Нәдер Шәриповтан үч алу өчен Бишмәче авылына (хәзер Пермь өлкәсендәге Федорково) җибәрә. Шундый ук икенче отряд хыянәтче мишәр старшинасы Бәхтияр Янышев йортын талый. Походный старшина Зөлкәрнәй Йосыповны Бәхтияр, 100 кеше биреп, Суслово авылы халкын «падишаһ»ка тугрылыкка ант иттерү өчен озата. Әбил Байдашев Сатана (Емаш — Бөре районында) авылында яңа отряд туплый. Атаман Гадел Бигашев Бөре районын Казан һәм Сарапул ягыннан килүче карательләрдән саклау өчен Ангасяк заводына (Дүртөйле районында) китә. Бөрене Көнгер тарафыннан саклау өчен, полковник Габделҗәлил Рыскулов, Тимкә авылына (Балтач районында) барып, лагерь кора. Уса яки Красноуфимск ягыннан һөҗүм булмасын өчен, Бүләк Якупов белән Арыслан Рангулов Атар һәм Барда (Гайнә) юлларын саклыйлар. Шундый ук көчәйтелгән каравыл отрядлары Сухояз һәм Туктар авылларына да куела.

Отряд командирлары урынсыз талауларга һәм тәртипсезлеккә юл куймый. Мари старшинасы Бәйки Туйкиев Ангасяк заводыннан 17 ат куалап киткән була. Атаман Бигашев Туйкиевтан ул атларны фетнәче отрядларга бүлеп бирүне таләп итә. Бәхтияр Канкаев белән Ярмөхәммәт Кадермәтов Туктар кичүен саклаучы Балтач Сәетовка аның командасыннан качкан ике «казак»ны мәҗбүри рәвештә кире алып кайтырга һәм, башкаларга сабак булсын өчен, чыбыркы белән суктырырга боералар. Бәхтияр отряд командирлары арасында тиктомалга чапкын куу гадәтен дә тыя.

Билгеле инде, «падишаһ» белән бәйләнеш тоту да онытылмый. Габделкәрим Әитов Салаватның Бөре янындагы командирларны «падишаһ» гаскәре белән кушылырга чакырып 6 июнь көнне язган хатын алып кайтуга ук, Бүләк Якупов, Арыслан Рангулов, Габделҗәлил Рыскулов кебек җитәкчеләр үз отрядларын алып Пугачев янына ашыга. Г. Рыскулов, Пугачев белән күрешеп кайтканнан соң да, янә Канкаевка буйсына. Канкаев үзе дә, әлегә походный старшина дәрәҗәсен йөрткән Ярмөхәммәт Кадермәтов белән бергә, Пугачев исеменә рапорт яза һәм аның янына чапкын юллый.

Бу вакытта Пугачев үзе, карательләр тарафыннан җитди каршылык күрмичә, җиңү артыннан җиңү яулый. Әй елгасы буена тупланган 3000 ләп фетнәче белән ул 6 июнь көнне Красноуфимск каласына юнәлә. Каланы сакларлык көч булмый, һәм Пугачев 10 июнь көнне яусыз-нисез аңа барып керә. Бу хакта Көнгер каласында торучы подполковник А. Папава белеп ала һәм 4 тубы булган 810 кешелек командасы белән ашыгыч рәвештә Красноуфимскига юнәлә. 11 июньдә Папава Ачыт крепосте янында Көнгергә юнәлгән Пугачев гаскәре белән очраша. Фетнәчеләр белән бу юлы да атаман И. Белобородов җитәкчелек итә. Аяусыз яу башлана. Белобородов, фетнәчеләрне берничә группага бүлеп, Папава отрядын камарга омтыла. Туп һәм мылтыклардан ачылган көчле утка каршы тора алмыйча, Папава чигенә башлый. Һичнинди каршылык күрсәтергә дә ирек бирмичә, Белобородов гаскәре, 6 сәгать буе 20 чакрым ара үтеп, Папаваны Көнгергә таба куа.

Пугачев 12 июньдә Преображенское авылы янында тора. 13 е көнне аның гаскәре Ирга (Түбән Ырга — Екатеринбург өлкәсендә) заводына якынлаша. Завод эшчеләре «падишаһ»ны ипи-тоз белән каршылыйлар. Пугачев завод янындагы кырда төн кунарга туктала. Бирегә Бөре тарафыннан Бәхтияр Канкаев һәм Ярмөхәммәт Кадермәтов юллаган чапкын килеп җитә.

Пугачев шундук әлеге ике каһарман исеменә махсус указ яздыра. Аларга һәр йорттан, нинди милләттән булуына карамастан, мәҗбүри рәвештә берәр сугышчы алып, «падишаһ» өчен зур гаскәр тупларга, шул көч белән Пугачев походының иминлеген (ягъни Пугачев гаскәрен Уфа тирәсендәге карательләр һөҗүменнән) сакларга әмер бирелә. Фәрманны Хәрби коллегия тарафыннан есаул дәрәҗәсе белән олыланган Салих Нәүрузов алып китә. Мөгаен, нәкъ шушы ук Салих Ярмөхәммәт Кадермәтовка полковник дәрәҗәсе бирелү турындагы указны да алып кайткандыр. Чөнки 17 июньдә Кадермәтов документларга «полковник» дип кул куя башлый.

Бу вакытта Бөре районында кискен хәл туа. 13 июньдә Уфа янына карательләр арасындагы бердәнбер ару-талу белмәс командир — подполковник Михельсон кайтып җитә. Ул Бөре янында меңәрләгән фетнәче хәрәкәт итүен белеп ала һәм бу төбәктә тупланган карательләргә кичекмәстән сугышчан поход башларга әмер юллый. Бу көннәрдә полковник Якубовичның 570 солдаты (шуның составында майор Дуве биргән 100) һәм хыянәтче башкорт, мишәр старшиналары туплаган 466 кешелек җәза отряды Калинник авылында (Бөре районында) тора. Алар янына Дуве кул астындагы 200 кешелек регуляр отряд та килеп кушыла. 13 июнь көнне бергә походка кузгалып, карательләр Усак авылына (Бөредә) лагерь корып урнашалар һәм Бөре елгасындагы кичүне саклый башлыйлар.

Карательләр тудырган куркынычтан соң башкорт отрядлары «үз даругаларын саклау өчен» туган якларына кайтып китә («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания и переписка...»). Ә Бәхтияр Канкаев, Габдулла Туктаров, Ярмөхәммәт Кадермәтов, Хәмит Мөхәммәтов, Рамазан Урманчиев кул астындагы татар отрядлары Бөре елгасы буендагы Сухояз (Малосухоязово — Бөре районында, Большесухоязово — Балтачта) авылына күченәләр. 15 июнь көнне Сатана (Емаш) авылы янында Канкаев отряды белән Якубович командасы арасында беренче бәрелеш була. Фетнәчеләр 3 карательне юк итәләр, ике кешене әсирлеккә алалар (фетнәчеләр отрядларындагы югалтулар турында мәгълүмат юк). Шуннан соң Канкаев кабат Сухоязга, ә Якубович командасы Дуван (Удельные Дуванеи) авылына чигенә. Шунда карательләргә Уфадан ярдәмгә җибәрелгән майор М. Мельгунов кул астындагы 200 кешелек җәза отряды да кушыла. Якубовичның Сатана янында Канкаев тарафыннан җиңелеп Дуванга чигенүе турында хәбәр алган Михельсон да түзми. Ул, Уфадан чыгып, 17 июньдә Потехин заводына килеп җитә, биредә майор Дуве отряды белән кушыла. Бу көнне фетнәчеләр һаман да Сухояз һәм Яштебаево (Бахтыбаево — ?) авылларында торалар әле. 20 июньдә Михельсон Усак авылында полковник Якубович командасы белән кушыла. Әмма Михельсонның «каһарман» Якубович белән бергә хәрәкәт итәсе килми. Ул Якубовичны Уфа каласына озата, ә үзе Уса тарафына юнәлә. 21 июнь көнне Бөре елгасы буендагы Бурново (Старобурново) авылы янында аяусыз яу була. Фетнәчеләр, 70 кеше югалтып, Уса һәм Сарапул ягына чигенәләр («Крестьянская война... на территории Башкирии»; «Воззвания и переписка...»). Ә бу вакытта Усага бикләнгән гарнизонга «падишаһ» каршында тез чүгү өчен санаулы гына сәгатьләр калган була инде.

Әлеге көннәр — Пугачев явы барышында вакыйгаларның аеруча кайнап торган чоры. Шуңа күрә беркадәр артка чигенеп, без Уса янында туган хәлне аңлатырга тиешбез.

***УСА***

26 гыйнварда — Көнгер, 19 февральдә Красноуфимск янында тар-мар ителгәннән соң, Уса юлыннан, шул исәптән Барда төбәгеннән килгән крестьяннар кабат үзләренең туган ягына кайта. Тол (Тулва) елгасы буендагы авыллардан фетнәгә кушылган крестьяннар белән Елпачиха авылы каһарманнары Батыркай Иткинин, Әдигут Тимачев, старшина Сәйфулла Сәйдәшев, урыс крестьяны Степан Кузнецов җитәкчелек итә. Март — апрель айларында алар И. Осокинның Югов заводында лагерь төзеп урнашкан подполковник М. Башмаков карательләренә каршы көрәшәләр. Ижевск, Сарапул тирәсендә җәза отрядлары белән җитәкчелекне Кама буендагы казна заводларының башлыгы Ф. Венцель үз кулына ала. Әлеге ике җәлладка Югов, Аннинск, Ижевск, Воткинск заводларының идарәчеләре Яковлев, Бахман, Берглин (аның отрядында 1 400 кеше була), И. Алымов, А. Клепиков кул астында төзелгән җәза отрядлары ярдәм итә. Карательләр актив хәрәкәт итеп күп тырышлык куйса да, Уса — Сарапул — Әгерҗе төбәгендә фетнәчеләр көрәше тукталмый. Карательләр май уртасында бирегә 1767 елда Уложение комиссиясенә депутат итеп сайланган хыянәтче старшина Туктамыш Ишбулатов кул астындагы отрядны да җибәреп карыйлар. Фетнәчеләрне гафу итү турында патшабикә манифестларын тотып килгән Туктамыш та әллә ни зур уңышларга ирешә алмый. Үгетләүләргә бирелеп, отряд командирлары арасыннан фәкать атаман Әдигут Тимачев кына 18 май көнне Туктамыш ягына чыга. Шуннан соң Югов заводыннан Уса отряды да килеп җитә. 23 май көнне Батыркай Иткинин, Сәйфулла Сәйдәшев, Степан Кузнецов җитәкчелегендәге 3000 крестьян Яковлев һәм Туктамыш Ишбулатов кул астындагы карательләр белән бәрелешә. Туктамыш фетнәчеләр кулына әсирлеккә төшә. Крестьяннар карательләрне 15 чакрым буе куалар. Яковлев үз отряды белән Уса каласына кереп бикләнә.

Подполковник М. Башмаков, Казан губернаторы Я. Брандттан ашыгыч ярдәм сорап, чапкын юллый. Казаннан 6 июньдә майор Скрипицын командалыгындагы отряд юлга чыга. Юлда «буш кына» йөрмәсен өчен, Скрипицынга 14 майда поручик Красильников кулына әсирлеккә төшкән һәм Казан төрмәсенә китереп җәзаланган татар каһарманы, Тирсә волостендагы (Әгерҗе районында) фетнәче крестьяннар башлыгы Әбҗәлил (Габделҗәлил) Сөләймановны да биреп җибәрәләр. Скрипицын «падишаһ» полковнигы Әбҗәлилне Тирсә авылында дарга аса һәм Усага ашыга.

Скрипицынның ярдәмгә килүе турында хәбәр алгач, Усага бикләнгән Яковлев үзенең 1200 кешелек отряды белән 14 июнь көнне аңа каршы юнәлмәкче була. Ләкин фетнәчеләр Гамицы авылына бәреп керәләр һәм аның юлын бүләләр. Яковлев урап үтәргә омтылыш ясагач, фетнәчеләр Гамицыга һәм аның янындагы тагын 2 авылга ут төртәләр. Төтен Яковлевка туплар кулланырга да, һөҗүм ясарга да ирек бирми. Ул арада фетнәчеләр үзләре Усага һөҗүм ясау өчен юнәлә. Моны белеп алган Яковлев ашыгыч рәвештә кире борылырга мәҗбүр була. Шәһәрдән 3 чакрым читтә аяусыз яу башлана. Ул кичке 6 дан төнге 10 га кадәр дәвам итә. Ахырда Яковлев Усага кереп бикләнә.

Шуннан соңгы көннәрдә Яковлев, Тол елгасын кичеп, Көнгергә һәм Югов заводына таба юнәлмәкче була. Әмма фетнәчеләр, елга аша сузылган арканнарны кисеп һәм аяусыз ут ачып, Яковлевны калага чигенергә мәҗбүр итәләр. Ниһаять, 18 июнь таңында Уса гарнизонына ярдәмгә майор Скрипицын командасы килеп җитә. Паром китертеп, ул да елганы кичәргә һәм фетнәчеләргә һөҗүм ясарга хәзерләнә башлый. Ләкин шул вакытта Уса янына «падишаһ Петр Федорович» гаскәре килеп җитә.

Без Пугачев белән Ирга заводында аерылышкан идек. 14 июнь көнне ул, әлеге заводны калдырып, Пермь өлкәсе җирләренә керә. Иргадан киткәндә, ул буаның суын җибәрә, пилорамына ут төртә. 16 һәм 17 июньнәрдә Пугачев Уинск белән Шермяитск заводларын ала. 6 июньдә 3000 кешелек булган гаскәр 11—12 көн эчендә 7000 гә җитә. Билгеле инде, «падишаһ» гаскәренә Тол, Танып елгалары буенда яшәгән татарлар да кушыла.

18 июньдә фетнәчеләр гаскәре Уса каласын «тимер» боҗрага ала. Бу вакытта Пугачев янында аның күренекле ярдәмчеләре А. Овчинников, И. Белобородов, К. Арысланов, С. Юлаев, Д. Загуменнов, И. Грязнов белән бергә татар каһарманнары Муса Алиев, Садыйк Сәгыйтов, Идеркәй Мәхмүтов, Исхак Әхмәтов, Канзафар Усаев, Бүләк Якупов, Батыркай Иткинин һәм составына йөзәрләгән татар крестьяннары тупланган отрядлар да була.

Крепость гарнизоны фетнәчеләрне, шәһәр читендәге кырга чыгып, туп һәм мылтыклардан көчле ут ачып каршылый. Карательләргә якынлашкан җайдаклар аларга «падишаһ»ны мылтыкларын ташлап һәм җиргә ятып каршыларга әмер бирәләр. Чыннан да, 70 кә якын «сакчы» җиргә егыла. Фетнәчеләр һөҗүмгә күчә, әлеге 70 кеше «әсирлеккә» төшә. Карательләр крепость эченә чигенә. Шәһәр читендәге бистәләрне ялкын чолгап ала.

19 һәм 20 июнь көннәрендә дә крепостьны штурмлау өчен яңадан-яңа һөҗүмнәр оештырыла. Белобородов фетнәчеләрне печән һәм салам төялгән олаулар артына яшеренгән көе дә һөҗүмгә ташлап

карый. Тик Пугачев та бернинди уңышка ирешми. Шул ук вакытта крепостьны саклаучы Скрипицын, Яковлев, безгә яхшы таныш воевода, Чесноковка авылына барып, «граф Чернышев»ка баш игән поручик Ф. Пироговский отрядларындагы карательләр кулында да инде санаулы гына патроннар кала. Җитмәсә, 20 июнь көнне фетнәчеләр, крепостька якынаеп, аның стеналары янына күп кенә салам һәм печән дә бушаталар. Фетнәчеләр ягыннан берәрсе очына ут эленгән ук очырса, крепостьны ялкын чорнау куркынычы туа. Скрипицынга инде хәйләгә бармыйча чара калмый. Ул махсус арадашчы җибәрә дә Пугачевтан «акылга килү» өчен бер тәүлек вакыт сорый (дөрес, бу җәза отрядларының ярдәменә өметләнеп вакыт сузу гына була, шулай да Скрипицын Пугачевтан «майорны асмаска» дигән вәгъдә алырга онытмый).

Уса янында шактый гыйбрәтле «уен» да оештырыла. Гарнизон составында кайчандыр Петербургның үзендә хезмәт иткән һәм чын Петр III не күргән Петр Треногин исемле карт солдат булуын белеп, аны әле 19 ы көнне үк «падишаһ»ны «танырга» чыгаралар. Өстендәге бәрхет кафтанын салып гади киемгә төренгән Пугачев берничә казак белән бер сафка басарга мәҗбүр була. Треногин һәр казак йөзенә текәлеп саф буенча йөри һәм, чыннан да, Пугачев каршында туктала. Казаклар Треногиннан «падишаһ»ны тануын таләп итәләр. Әмма карт солдат Пугачев каршында: «Син аңа охшаган охшавын. Мәгәр Петр падишаһ ул вакытта яшьрәк һәм сакалсыз иде. Җитмәсә, бик күп еллар да үтте. Өзеп кенә әйтә алмыйм», — дип «акланырга» мәҗбүр була.

20 се көнне, инде крепостьны саклау өчен ядрә һәм патроннар калмагач, җитмәсә стена буена печән белән салам өеп куелгач, гарнизондагылар Треногинны янә «падишаһ» янына чыгаралар. Казаклар тагын сафка тезелә. Треногин бу юлы да Пугачевны эзләп йөри һәм «танып» туктала: «Менә хәзер ышандым. Син, валлаһи, безнең падишаһ...»

Треногин крепостька әйләнеп кайткач, әлбәттә инде, байтак кеше Скрипицынны «падишаһ» каршында тез чүгәргә үгетли башлый.

21 июнь көнне, ниһаять, крепость капкалары ачыла. Скрипицын белән Пироговский кул астындагы бөтен гарнизон «падишаһ»ны чаң кагып, икона һәм ипи-тоз тотып, җиргә тезләнеп каршы ала. Гарнизон да, офицерлар да гафу ителә. Әмма фетнәчеләрнең җелегенә үткән Яковлев дарга асыла. «Падишаһ»ны «танырга» теләмәгән Манаков утка ыргытыла. Шулай ук җансыз крепость та «падишаһ» үченнән котыла алмый, ул Пугачев әмере буенча яндырыла. «Падишаһ»ка кушылган солдатлардан 1100 кешелек Казан полкы төзелә. Пугачев майор Скрипицынны әлеге полкның командиры итеп билгеләп, хәтта аңа полковник дәрәҗәсе дә бирә.

23 июнь көнне Пугачев Ижевск тарафына юнәлә һәм Кама елгасы ярына килеп җитә. Шушында «падишаһ» үз янына тугрылыклы бригадиры Канзафар Усаевны, Уса каласын штурмлаган чакта янә аягы яраланган Салават Юлаевны һәм тагын 4 полковникны чакыртып ала. (Байтак тарихи хезмәтләрдә Усаны штурмлауда Юлай Азналин да катнашкан, һәм ул шушы 6 кеше арасында булган дип күрсәтелә. Ләкин бу хакыйкатькә туры килми. Юлай Азналин 19 июнь көнне үз отряды белән Катау-Иван заводын штурмлый, әмма уңышка ирешә алмый һәм чигенә. — *В. Мавродин, И. Гвоздикова*). Әлеге җитәкчеләрнең һәркайсына указ биреп, Пугачев яңа отрядлар туплау һәм «падишаһ»ны эзәрлекләүче карательләрнең юлын бүлү өчен аларны Уфа провинциясенә озата.

Шушы көнне үк бер хыянәт тә ачыла. Уса янында Пугачевка тугры булырга «ант» китергән майор Скрипицын, капитан Смирнов, Югов заводы идарәчесе Бахман, Строгановлар заводының приказчигы Клюшников ашыгыч рәвештә ярдәм җибәрүләрен сорап подполковник М. Башмаков һәм губернатор Брандт исеменә хат язган булалар. Әлеге «хыянәт»не әле кичә генә Скрипицын кул астында булып, бүген Пугачевка «ант» китергән подпоручик Минеев «ача». Шушы «хыянәт» өчен әлеге 4 карательне Пугачев агач ботакларына астыра, ә «тугры» Минеев полковник дәрәҗәсен ала һәм Казан полкының командиры итеп билгеләнә.

Шушы көнне, ягъни 23 ендә, Пугачев Каманы кичә һәм Рождественск заводына юнәлә. Бу вакытта аның гаскәрендә 5000 нән артык фетнәче (соңыннан, сорау алу вакытында Пугачев үзе бу көннәрдәге гаскәренең күләмен 7000 кеше дип күрсәтә) исәпләнә *(В. Мавродин)*.

### ***УДМУРТИЯ***

Удмуртия җиренә аяк баскач, Пугачев әүвәл Кама яры буйлап туп-туры Татарстанга юнәлә. Аннан кискен рәвештә уңга борыла һәм Воткинск заводына китә. Кама буендагы казна заводларының башлыгы полковник Венцель, Пугачевның Каманы кичүен белеп, ашыгыч рәвештә завод эшчеләрен коралландыра һәм 1300 кешелек отряд туплый. Ижевск эшчеләренең башлыгы итеп Иван Алымов билгеләнә, Воткинск отрядын А. Клепиков җитәкли. Алымов белән Клепиков Воткинск заводын сакларга юнәләләр. Ә Венцель

Ижевск шәһәрендә отставкадагы секунд-майор Николай Алымов җитәкчелегендәге 210 кешелек яңа отряд туплый.

Бу вакытта инде Пугачев каршылыксыз-нисез генә Воткинск заводын алган була. 26 июньдә Завьялово авылы янында фетнәчеләрне И. Алымов һәм Клепиков отрядлары каршылый. Яу башлана, әмма завод крестьяннары шундук кача башлый. Алымов белән Клепиков әсирлеккә эләгә.

*Шушы урында тукталыш ясап, без бер нәрсәне искәртик. Заманында граф Шуваловларныкы булган Ижевск һәм Воткинск заводларына 1754 елдан бирле Казан провинциясенең Мамадыш, Алабуга, Яр Чаллы тирәсендәге Сарсаз, Маврино, Тавели (Тау иле), Боровецкое, Акташ, Шилнә, Костенеево, Тойма, Казыли (Казый иле) һәм башка авыл крестьяннары йөреп эшли. Алар, завод газапларыннан котылу өчен, 60 нчы елларда бер ничә мәртәбә баш күтәрәләр, үзләренә каршы җибәрелгән җәза отрядлары белән яуга да керәләр. 1774 елның июнендә, Пугачев килеп җиткәндә, бу заводларда, һичшиксез, Казан провинциясеннән килеп эшләүче крестьяннар да була һәм завод администрациясе аларның тугрылыгына, ярдәменә өметләнеп нык ялгыша. Күренгәнчә, алар, «падишаһ» гаскәренә кушылу өчен, уңайлы очрак кына көткәннәр икән.*

27 июньдә Пугачев Ижевскига якынлаша. Завод осталары, крестьяннар аны җиргә тезләнеп һәм иконалар тотып каршылый. Полковник Венцельне крестьяннар йорт түбәсенә качкан җирендә таба. Николай Алымовны да тотып китерәләр. Венцельне соңыннан ике крестьян кисәкләргә чапкалап үтерә. Бертуган Алымовлар белән Клепиков дарга асыла. (Дворян галиме Н. Добротворскийның бәян итүенә караганда, крестьяннар Николай Алымовны — йорт түбәсе, ә Венцельне тирес астына яшеренгән җирләреннән табып алалар. Шуннан соң, имеш, Николайны әүвәл кулларын, аякларын, аннары гына башын чабып үтерәләр. Ә Венцельне, янәсе, 4 мәртәбә дарга асалар да, һәр очракта бавын бушатып газаплыйлар. Имеш, Венцель шулай дөмегә. Әмма бу авторның хезмәтендә ялгышлар санап бетергесез. Шуңа күрә аңа ышануы мөмкин түгел.) Шушы көнне үк крестьяннар буаны җимерәләр һәм заводка ут төртәләр.

28 е көнне Пугачев гаскәре Удмуртия авыллары аша үтә. 29 июньдә «падишаһ» Әгерҗегә керә.

*Хезмәтебезнең кереш өлешендә «Пугачев Татарстан җиренә 12 мең кешелек гаскәр белән керә» дип язсак та, Пугачев явын бәйнә-бәйнә тасвирлауга күчкәч, Казан галиме С. Алишев күрсәткән әлеге мәгълүматны янә кабатлаудан без аңлы рәвештә тыелдык. Чөнки Пугачевның 1774 елның 29 июненә кадәр 12 мең кешелек гаскәр туплый алуы безнең күңелләрдә олы шик уята. Сәбәпләрен сезгә дә бәян итик.*

*Пугачев явын өйрәнүче барча тарихчылар арасыннан фәкать С. Алишев кына Пугачев гаскәренең 29 июньгә кадәр тупланган көчен нәкъ 12 мең фетнәче дип күрсәтә («Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании», 149 с.). Мондый санны нинди чыганактан алуы хакында С. Алишев әйтми. Башка бер генә тарихчы хезмәтендә дә бу дата юк. Саннар белән эш итүче галимнәр Пугачев гаскәренең Кама елгасын кичкән чактагы, фәкать 23 июньдәге күләмен генә искә алалар. Ул саннар да гаять каршылыклы. Пугачев соңыннан, Мәскәүдә сорау алганда, Уса янында Каманы кичкән фетнәчеләр санын 7 000 дип атый. Дворян тарихчысы Н. Дубровин белән Ростов галиме Х. Муратов нәкъ шул мәгълүматларны кабатлыйлар, яңа сан өстәмиләр. Петербург галиме В. Мавродин әлеге санны 5000 гә генә калдырып күрсәтә һәм, безгә калса, бик үк ялгышмый да кебек. Чөнки «Уса каласын штурмлаган чакта Пугачев кул астында күпме фетнәче булган, шулар тулысынча Кама аша кичкән һәм Казанга юнәлгән», дип нәтиҗә ясарга һич ярамый. Крестьяннар нигездә үз төбәкләрендә урнашкан шәһәр һәм крепостьларны штурмлаган чакта гына фетнәгә актив кушылганнар, ә отряд җитәкчеләре яңа районнарга юнәлгәндә, фетнәчеләрнең бик күбесе туган җирендә калган. Шуңа күрә отрядларда даими состав, ныклы тәртип, көчле корал базасы булмаган. Һәм, һичшиксез, Уса янында да шушы ук күренеш кабатланган. Безгә калса, Красноуфимск яныннан килгән башкортларның, Тулва татарларының, шулай ук урыс, мари, удмурт крестьяннарының байтагы, «падишаһ»тан аерылып, Каманың сул ягында калганнар.*

*Инде тарихчы В. Бугановның «Емельян Пугачев» дигән хезмәтен дә искә алыйк. Ул анда Пугачев гаскәренең Ижевск заводыннан чыккан чактагы көчен (ә бу 28 июнь) 5—8 меңгә тиңли (158 б.). Ә Панеях, Лимонов, Овчинников, Добротворский һәм башка тарихчылар, бу чорны тасвирлаганда, саннар белән эш итүдән бөтенләй читләшәләр. Без кабатлап чыктык, сез күрдегез: С. Алишевтан кала бер генә тарихчы да 8 меңнән зуррак санны телгә алмый. Һәм, безгә калса, нәкъ шул 8000 саны Пугачев гаскәренең 29 июньгә кадәр булган көчен чагылдыручы иң гадел сан, мөгаен. Нигезсез дә түгел. Әгәр Пугачев үзе 23 июньдәге гаскәрен 7000 кешегә тиңләгән икән, 24—28 июнь дәвамында Воткинск һәм Ижевск заводларында «падишаһ»ка 1000—1500 кеше генә кушыла алган. Чөнки югарыда инде тасвирлап уздык: Пугачевның Кама аша кичүен белгәннән соң, Венцель, Клепиков, Алымовлар әлеге ике заводтан нибары 1500 эшчене генә туплап «падишаһ»ка «каршы» юллый алганнар. Ул 1500 эшченең һәммәсе дә Пугачев гаскәренә*

*кушылган, дип нәтиҗә ясау шулай ук урынлы булмас. Шуңа күрә өзеп әйтик:* Татарстан җиренә кергән чакта, Пугачев гаскәрендәге фетнәчеләр 8000 кешедән артык булмаган!

# ЯНӘ БӨРЕ ТӨБӘГЕ

Казанны штурмларга юнәлгәндә, Татарстан җиренә Пугачев түгел, ә бәлки Бөре янында хәрәкәт итүче отряд командирлары беренче булып керә. Шуңа күрә без ихтыярсыз рәвештә янә Бөре төбәгендәге хәлләргә әйләнеп кайтырга мәҗбүрбез.

Без Бәхтияр Канкаев, Ярмөхәммәт Кадермәтов, Габдулла Туктаров җитәкчелегендәге отрядларның 15 июнь көнне Сатана авылында торган полковник Якубович командалыгындагы карательләргә һөҗүм итүе турында инде әйткән идек. Гәрчә Якубович кул астында 770 солдат (шул исәптән Дуве командасы) һәм Аблай Исмәгыйлов, Ихсан Баязитов җитәкчелегендә мишәр-башкортлардан төзелгән 466 кешелек хыянәтчеләр отряды булса да, алар фетнәчеләр белән яуда җиңеләләр һәм Дуванеи авылына чигенәләр. Бәхтияр Канкаев та үзенең Сухояз авылында корган лагерена кайтып урнаша. Алдагы якшәмбе көненә (числосы билгеле түгел, 17 се булырга тиеш) ул янә карательләр лагерена һөҗүм итәргә хәзерләнә, шуның өчен полковник Габделҗәлил Рыскуловның да ярдәмгә килеп җитүен таләп итә. Әмма Бәхтиярга Дуванеи авылына һөҗүм ясарга насыйп булмый. 16 июнь тирәсендә Сухоязга есаул Салих Нәүрүзов «падишаһ» указын кайтарып җиткерә. Түбән Ырга заводында 13 июнь көнне язылган указ нигезендә Бәхтияр Уса юлына чигенергә һәм Пугачевның Усага юнәлгән гаскәрен Уфа ягыннан килүче карательләр һөҗүменнән сакларга тиеш була.

Бәхтияр Сухоязга тупланган көчне икегә бүлә. Ул үзе белән походный старшина Хәмит Мөхәммәтовны һәм берничә йөз фетнәчене ала да Курча авылына (Борай районындагы Иске Күрзә) «падишаһ» фәрманын үтәү өчен юнәлә. Ә полковник Ярмөхәммәт Кадермәтовны Сухояз лагерендагы фетнәчеләр башлыгы итеп билгели. Походный старшина Габдулла Туктаров белән йөзбашы Рамазан Урманчиев отрядлары да Сухоязда кала. Яртылаш кимегән көч белән Я. Кадермәтов, билгеле инде, Дуванеи авылына һөҗүм итә алмый. Киресенчә, Сухояз лагерендагы көчнең яртылаш кимүен белеп алган Якубович карательләре активлаша, 18 е көнне карательләр Сухояз авылына һөҗүм итәләр. Я. Кадермәтов Бәхтияр Канкаев киткән юл буйлап чигенә. Ә карательләр шул төбәктәге авылларны талый башлый. Җитмәсә, ару-талу белмәс Михельсон 17 июнь көнне Уфадан чыга һәм 20 июньдә Усак авылында булдыксыз Якубович командасы белән кушыла. 21 июнь көнне Михельсон да Бөре төбәгендәге фетнәче отрядларны тар-мар итә башлый. 22 июньдә Я. Кадермәтов янә Бәхтияр Канкаев белән кушылырга мәҗбүр була.

Бу көннәрдә Бәхтияр Канкаев Уса юлында хәрәкәт итә. Курча авылында торган чакта аның янына полковник Габделҗәлил Рыскулов һәм йөзбашы Сәетьягъфәр Зәйсәнов отрядлары да килеп кушыла. Бәхтияр үз отрядына яңа сугышчылар туплауны җәелдереп җибәрә. «Падишаһ» гаскәрен дошман һөҗүменнән саклау өчен аңа һаман да көнбатышка таба күченергә һәм, Борай районы аша үтеп, хәзерге Краснокама районына керергә туры килә. Бәхтияр Пугачевның Усадан соң кайсы якка таба хәрәкәт итәсен белми, ул аны Сарапулга килер дип көтә. Шуңа күрә Бәхтияр үзе Калтай исемле мари авылына килеп урнаша һәм хәзерге Краснокама җирлегендә хәрәкәт итүче, карательләргә каршы көрәшүче аерым отрядлар белән турыдан-туры җитәкчелек итә.

Касево авылына (Краснокама районында) тупланган карательләр отряды, 17—18 июньнәр тирәсендә Бөрегә таба хәрәкәт итеп, Челкак авылында (Борай районында) тупланган фетнәчеләрне тар-мар китерәләр, йортларны талыйлар, анда яшәүче байтак крестьяннарны үтерәләр. Карательләрнең активлашуы турындагы хәбәрләр килеп ирешкәч, Ангасяк заводы тирәсендә хәрәкәт итүче атаманнар Гадел Бигашев белән Аладин Биктуганов 18 июньдә Бәхтияр Канкаев янына чапкын озаталар һәм аның ашыгыч рәвештә ярдәмгә килеп җитүен сорыйлар. Хәтта язган хатларында Бәхтиярны Сухояз авылын ташлап китүдә, туган ягына качарга җыенуда гаеплиләр һәм бу хакта «падишаһ»ка хәбәр итү белән дә яныйлар. Әлбәттә, алар Бәхтиярның 16—17 июнь көнне Пугачевтан шәхси указ алуы, шул фәрманны үтәү максатыннан, Сухоязны калдырып китәргә мәҗбүр булуы һәм аның хәзер тагын да җаваплырак бурыч үтәве, ягъни «падишаһ» походының иминлеген тәэмин итүе хакында белмиләр.

Шулай да Бәхтияр Канкаев ике көрәштәшенең хәбәрен игътибарсыз калдырмый. Ул мари старшиналары Бәйки Туйкиев белән Федоська Янбактинга, старшина Әит Сәгыйтов һәм Биккенә Уразовка үз отрядлары белән Касево авылы крестьяннарыннан төзелгән карательләргә каршы чыгарга әмер бирә. Шул старшиналар кул астындагы отрядлар 24 июнь көнне 600 дән артык карательне Чурумак (Енактаево)

исемле мари авылы янында тар-мар итәләр. Исән калган карательләр әүвәл Касево авылына, аннан Березовка елгасы буена һәм шуннан соң, Каманы кичеп, Сарапул ягына кача («Воззвания и переписка...», №127—129).

*Вакыйгалар агышыннан читкә тайпылышлар ясау укучыны мөгаен ялыктырадыр. Үзебезгә дә адым саен чигенешләр, тукталышлар ясау җиңел түгел. Ләкин кайбер «галимнәр»нең хезмәтендәге күрәләтә ялган безне шушы урында тукталырга һәм гаҗәпләнү генә түгел, хәтта ризасызлык белдерергә мәҗбүр итә.*

*Без әле генә тарихи документлар белән танышып чыктык. Июнь ахырында Бәхтияр Канкаев Краснокама районында тора (27 сенә кадәр торуында шик юк, ул документлар белән раслана. Кара: «Воззвания и переписка...», док. №131—132). Без югарыда санаган Б. Туйкиев, Ф. Янбактин, Ә. Сәгыйтов, Б. Уразов кебек старшиналарның һәммәсе дә бу вакытта турыдан-туры Бәхтияр Канкаевка буйсыналар. 24 июнь көнне язган рапортларында да алар Бәхтияр белән Яркәй Кадермәтовка «гаскәр башлыклары» дип хөрмәтләп мөрәҗәгать итәләр.*

*Әмма Уфада яшәүче И. Гвоздикова, Салават Юлаевны ару-талу белмәс һәм «канатлы» каһарман итеп күрсәтү максатыннан, тагын күрәләтә ялганга бара. Ул 23 июньдә Уса каласы янында калган һәм аягы яраланган Салаватны 5 көн дәвамында кайсы тарафларга гына «күчереп» куймый да аннан нинди генә «батырлыклар» эшләттерми. Имеш, Салават «отряды» 23 еннән 27 сенә кадәр Касево авылына да килеп җиткән, Кама буендагы заводлар аша да үткән, ә 28 е көнне инде Аннинск, Бизярск заводларын алырга һәм Көнгергә һөҗүм итәргә хәзерләнгән. Әлеге «батырлыклар»ны кылган чакта Әит Сәгыйтов белән Бәйки Туйкиев Салаватның «тугры ярдәмчеләр»е булган икән (Гвоздикова китабында 166—167 битләр). Гвоздикова соңыннан әлеге ялганын җәлладлар сорау алганда Бәйки Туйкиев биргән күрсәтмәләргә нигезли. Әгәр фетнәче нинди дә булса командирга каршы күрсәтмә бирә икән, ул гаепләре өчен шул командирларның җәзага тартыласын, аларның хөкүмәт каршында зур җинаятьче булып саналасын һичшиксез белә. Бу очракта Бәйки Туйкиев ни өчен бар гаепне башкорт командирлары өстенә ташлаган, димәк, аларны «батырган» да, нинди максат белән татар командирларын яклаган? Бу кадәресе безгә мәгълүм түгел. Монысы инде Бәйки Туйкиевның шәхсән үз эше. Әмма «галим» булып йөргән Гвоздикованың чынбарлыктагы шартлар белән һич кенә дә исәпләшергә теләмәве тәмам аптырата. Уса белән Касево арасында — 250 чакрым, Касево белән Аннинск арасында 300 чакрымлык юл ята, һәм Аннинскидан соң Көнгергә кадәр дә 100 чакрым үтәсе бар бит әле. Гвоздикова ялганына ышансак, яралы Салават гайре табигый кеше булып, җитмәсә, аның атлары да канатлы булган, ахры? Өстәвенә, 23 июнь көнне Канзафар Усаев һәм тагын 4 полковник белән бергә 6 олауга утырып юлга чыккан яралы Салават кай арада отряд җыеп өлгергән? Һәм 24 июнь көнне карательләргә каршы яуда йөргән һәм турыдан-туры Бәхтияр Канкаевка буйсынган Әит Сәгыйтов белән Бәйки Туйкиев бер үк вакытта ни рәвешле Салават Юлаевның да «тугры ярдәмчеләр»е була алдылар икән? Башкорт вәкилен каһарман итеп күрсәтәм дип, ни өчен Бәхтияр Канкаевны бу кадәр түбәнгә төшерә ул? Мондый «галим» белән бәхәскә керүләр валлаһи туйдырды. Укучылар өчен генә әйтеп үтик: июнь аенда Бәхтияр Канкаев кул астында көрәшкән Габдулла Туктаров, Аладин Биктуганов, Әит Сәгыйтов, Бәйки Туйкиев, Бүләк Якупов, Арыслан Рангулов, Габделҗәлил Рыскулов кебек командирлар үз сугышчылары белән бергә сентябрьдә генә Салават Юлаевка барып кушыла. Ике-өч айдан соң гына Салават белән бергә хәрәкәт итәчәк бу командирларның июнь аенда ирешкән җиңүләрен башкорт каһарманының уңышы итеп тасвирлау тарихи гаделлек була аламыни? Күңелдә ихтыярсыз рәвештә сорау туа: бу ханым, Салаватны канатлы каһарман итеп сурәтли-сурәтли «тарихи» хезмәт язган чакта, үзен, ялгыш, С. Юлаев премиясенең булачак лауреаты итеп тоймадымы икән?..*

Менә шундый күңелсез әйләнечтән соң янә вакыйгалар агышына кайтыйк. Бәхтияр Канкаев үз отряды белән, Бөре, Борай, Краснокама районнары буенча хәрәкәт итеп, июнь аенда «падишаһ» армиясенең тылын, ягъни аны Уфа ягындагы карательләр һөҗүменнән саклый һәм Пугачевка Усадан Ижевскига, аннан Татарстанга таба хәвефсез рәвештә хәрәкәт итәргә мөмкинлек тудыра.

Әмма Бөре өязенең үзендә хәлләр көннән-көн катлаулана. 17 июнь көнне Уфадан чыккан Михельсон үз юлында очраган фетнә отрядларын берәм-берәм тар-мар итә башлый. Ул Танып елгасы буендагы, Уфа — Уса арасындагы авылларны фетнәчеләрдән арындыра. Шул көннәрдә үк Уфадан майор М. Мельгунов отряды да чыга һәм Ангасяк заводына таба хәрәкәт итә. Шушы ук төбәккә Кара Табын волосте старшинасы Кулый Балтачев (бу әшәке җанның әтисе Иске Балтач авылын нигезләгән, әлеге төбәк соңыннан Балтач районына әверелгән.— *Ә. Әсфәндияров*) төзегән хыянәтче башкортлар отряды да бәреп керә һәм Ангасяк заводы, Борай авыллары янында фетнәчеләрне тар-мар итә башлый. Купай, Дүсмәт, Бикмәт, Бәдрәк, Күзбай, Кодаш, Каенлык, Тукран һәм башка татар авыллары карательләр тарафыннан талана, фетнәгә кушылган бик күп татар крестьяннары юк ителә яки хәбәрсез югала.

Карательләрнең котырынуы турындагы хәбәрләр, билгеле инде, Бәхтияр Канкаевка да килеп ирешә. Ул, тар-мар ителгән һәм таланган авыллардагы фетнәче крестьяннарны кабат туплау, аларны карательләргә каршы юнәлтү өчен, 24—25 июньнәр тирәсендә полковник Ярмөхәммәт Кадермәтовны Бөре төбәгенә озата. Я. Кадермәтов старшина Сәлим Әитов, йөзбашы Җамай һәм Ишкенә Сәетов, походный старшина Габделкәрим Собханкулов кебек командирларны, төрле авыллардагы тар-мар ителүдән соң таркалган вак-вак фетнә отрядларын кабат үз кул астына җыя. Ул аларны янә Ангасяк заводы тирәсенә туплый һәм, 26 июнь көнне Бәхтияр Канкаев исеменә рапорт язып, алдагы дүшәмбедә (?) кабат аның янына килеп кушылырга вәгъдә бирә. Ләкин Бәхтияр «падишаһ» тарафыннан үзенә аның тылын саклау бурычы җиткерелгәнен онытмый. Пугачев кай тарафка юнәлсә, аның үзенә дә шул якка хәрәкәт итәргә туры киләчәген дә яхшы аңлый. Һәм шул ук вакытта ул Бөре янында хәрәкәт итүче фетнә отрядларын язмыш кулына ташлап китәргә ярамавын да бик яхшы төшенә. Шуңа күрә атаман Гадел Бигашев исеменә хат язып, Бәхтияр Бөре төбәгендәге барча фетнә отрядларының башлыгы итеп Ярмөхәммәт Кадермәтовны билгеләргә куша. Әлеге хатка мишәр командирлары — полковник Габделҗәлил Рыскулов, походный старшина Хәмит Мәхмүтов (Мөхәммәтов), йөзбашы Сәетьягъфәр Зәйсәнов та кул куя, ягъни алар да Бәхтияр тәкъдимен яклый («Воззвания и переписка...»).

Тиздән Бәхтияр «падишаһ»ның Воткинск, Ижевск заводларын алуы һәм Казанга юнәлүе турында ишетә. Бәхтияр үзенең дә Минзәлә өязенә күченергә һәм элеккечә үк «падишаһ» гаскәрен Уфа ягындагы карательләр һөҗүменнән саклап барырга тиешлеген аңлый. Әмма ул Минзәлә — Уфа арасында яшәгән татар авылларын да карательләр талавына дучар итеп яки язмыш кулына ташлап китә алмый. Шуңа күрә ул үз кул астындагы көчне янә икегә бүлә. Габделҗәлил Рыскулов, Хәмит Мөхәммәтов, Сәетьягъфәр Зәйсәнов җитәкчелегендәге отрядлар Бөре төбәгендә кала, һәм хәзер инде алар Ярмөхәммәт Кадермәтовка буйсынырга тиеш була. Ә 29—30 июньнәр тирәсендә Бәхтиярга ай буена Уфа — Бөре арасындагы Туктар кичүен саклаган, әмма 28 е көнне карательләр тарафыннан тар-мар ителгән походный старшина Балтач Сәетов җитәкчелегендәге отряд килеп кушыла. Үзе белән бергә шул отрядны да алып, Бәхтияр Канкаев, 30 июнь — 1 июль тирәсендә Агыйделне кичеп, Татарстанга керә. Ул республикабызның Актаныш, Минзәлә, Тукай, Алабуга районнары аша үтә, үзе узган һәр авылда аның отрядына яңадан-яңа сугышчылар кушыла. 4—7 июль көннәренең берсендә Бәхтияр үзе туплаган отрядны, Мамадышка алып килеп, «падишаһ» карамагына тапшыра.

# ҖӘЗАЧЫЛАР ЛАГЕРЕНДАГЫ ЫГЫ-ЗЫГЫ

2 апрель көнне Сакмар буенда тар-мар ителеп качкан Пугачевның эзен югалту, җитмәсә аның май — июнь дәвамында үз кул астына тагын меңәрләгән кешелек гаскәр туплавы, Урал заводларыннан соң, Рәсәй үзәгенә килеп, Красноуфимск, Уса калаларын, Ижевск, Воткинск заводларын алуы һәм Казанга юнәлүе турындагы хәбәрләр җәзачылар лагеренда чын мәхшәр тудыра. Җәза полкларының командирлары арасыннан бер генә кеше дә Пугачевның иртәгә кай тарафка таба хәрәкәт итәсен белми, һәм шушы хәл һәр төбәктә хәвеф уята. Патшабикә генералларының, провинция воеводаларының, шәһәр комендантларының һәркайсы үз иминлеге турында гына кайгырта башлый. Ана улны, ата кызны белмәс ыгы-зыгы куба.

21 май көнне Пугачевны Магнитная крепосте янында тар-мар иткән һәм мантыйк буенча фикер йөрткәндә, «карак»ны һаман да эзәрлекләргә тиеш булган генерал Деколонг 27 се көнне янә Чиләбе крепостена кайтып бикләнә, рапортларында исә һаман гаскәр җитмәүдән зарлана, шул ук вакытта, әгәр «карак» Екатеринбург ведомствосында пәйда булса, аны юкка чыгарырга «вәгъдәләр» бирергә дә онытмый. Генерал Фрейман май ахырында һәм июнь башында Кизиль крепостенда хәрәкәтсез ята. Июнь ахырында әлеге генерал Оренбургка кайтып «егыла». Җәза гаскәрләренең башкомандующие генерал Щербатов губернатор Рейнсдорп «үтенече» буенча һаман Оренбург каласында тора һәм, янәсе, губерна үзәген Пугачевның «булачак» һөҗүмнәреннән саклый. Ниһаять, 4 июль көнне генә ул фетнә утының Казан губернасына күчүен белеп ала һәм Бөгелмәгә төбәп юлга чыга (ә 4 июльдә Пугачев инде Мамадышка җитә). Шунысы гаҗәп: Щербатов Пугачевның Казан губернасында хәрәкәт итүен белсә дә, ни өчендер һаман Оренбургны саклау турында кайгырта һәм биредә генерал Фрейман карамагында 5 эскадрон, 4 батальон, 2 рота регуляр гаскәр, 418 казак, 283 калмык һәм татар, шуларга өстәп тагын 139 солдат, 20 туп калдырып китә. Генерал Мансуров элеккечә үк Җаек шәһәрчеген «саклый». Подполковник Муфель — Бозаулыкта, полковник Кожин — Бөгелмәдә, полковник Обернибесов отрядлары Бакалы белән Минзәләдә тора. Генерал Голицын Уфаны саклау өчен Оренбургтан 8 июнь көнне үк юлга чыкса да, ул фәкать 12 июльдә генә (Пугачев — Казанда) барып җитә. 4 июльдә Голицын әле Бугульчан крепостенда тора

(Пугачев — Мамадышта) һәм ни өчен ул шуннан соң Казанга түгел, бәлки Уфа каласына (бөтенләй кире якка) юнәлгәндер? Моны бернинди мантыйк белән дә аңлатып булмый.

Бу чорда бары тик Уфа янына тупланган җәза отрядлары гына беркадәр активлык күрсәтә. Хәтта куркаклыгы белән дан алган полковник Якубович та Михельсон басымы астында фетнәчеләргә каршы юнәлергә мәҗбүр була. 27 июнь көнне ул, Чесноковка янына килеп, янә биредә зур отряд туплый башлаган фетнәчеләр лагерен тар-мар итә. Җәзачылар кулына әсирлеккә эләккән 6 актив көрәшче, шул исәптән татар каһарманнары Юзәй Биктимеров, Әлмөхәммәт Хөсәенов һәм Солтакай Габдекәев (алар Авыргазы районындагы Карамалы, Балыклы күл, Лекәнде авылы вәкилләре) Уфага кайтарылып, 2 июль көнне дарга асыла («Крестьянская война... на территории Башкирии»; *И. Гвоздикова*).

Патшабикә командирлары арасында бер Михельсон гына тынгы белми. 23 июнь көнне ул Ангасяк заводы янында (Дүртөйле районында) атаман Гадел Бигашев кул астына тупланган фетнәчеләрне тар-мар итә. 25 июнь көнне Танып елгасы буендагы Тазла (?) авылына барып җитә, шушы көнне ул Усаның Пугачев каршында тез чүгүе, хәтта Салаватның, яраланып, туган авылына кайтып китүе турындагы хәбәрне дә ала. Ул, Пугачевны Усадан соң Уфага һөҗүм итәр, дип уйлый. 27 июнь көнне Изәк елгасы буендагы Тазлар авылында (Иске Тазлар — Борай районында) тора. 29 июньдә янә Танып елгасы буендагы Садыбаш (?) авылында яу чыгып йөри. (Бу төбәктә Тазла, Садыбаш авыллары билгеле түгел. Михельсонның үз рапортында мөселман исемнәрен бутавы да мөмкин. Әгәр дөресе Тазтүбә, Сүлҗибаш яки Сумсабаш авыллары булса, алар хәзер Борай районына керә.) 27 се көнне Михельсонны Пугачев Усадан Сарапулга бара, дип алдыйлар. Михельсон Каракүл авылына (Удмуртия республикасында) таба юнәлә, әмма тиздән Пугачевның Татарстанга керүен белеп ала. Көймәләр һәм күперләр фетнәчеләр тарафыннан юкка чыгарылган яки алып кителгән булу сәбәпле, ул 2 июль төнендә көч-хәл белән Кама елгасын кичә. 3 июльдә Пьяный Бор (Красный Бор) авылына керә. 5 июль көнне генә, ниһаять, ул Әгерҗе районында Ык елгасын кичә һәм Пугачев артыннан куа чыга. Ә бу вакытта инде 15 мең кешелек гаскәр туплаган «падишаһ» Мамадышта ял итә.

Әле апрель аенда гына Пугачев гаскәрен тулысынча тар-мар итү турында шапырынулы рапортлар юллаган, патшабикәне олы җиңү белән котлаган генералларның май —июньдә шушы кадәр хурлыкка калуы һәм «карак маркиз»ның Рәсәй үзәгенә, Мәскәүгә һөҗүм итү мөмкинлеге, әлбәттә инде, Екатеринаны да олы хафага төшерә. Җитмәсә, май аенда Петербургта Екатеринаны агулау өчен Пугачевның бирегә «махсус кеше юллавы» турындагы ялган хәбәр дә тарала. Коты очкан патшабикә Царское Селога чыгып кача. Петербургта пәйда булган һәр шикле кеше тирәнтен тикшерүгә дучар ителә.

Билгеле инде, оештыруның яңа чаралары да күрелә. Екатерина Казанда һәм Оренбургта төзелгән Яшерен комиссияләрне (фетнәчеләрдән сорау алу органы) кабат берләштерергә фәрман бирә. Аларның башлыгы итеп Екатерина үзенең сөяркәсе Григорий Потемкинның кардәше Павел Потемкинны билгели. Шул ук Григорийның «үтенече» буенча, әле 17 март көнне генә генерал-майор дәрәҗәсенә «лаек» булган Павел төрек фронтыннан чакыртып алына һәм, «дәүләткүләм җаваплы» бурычны үтәү өчен, Казанга җибәрелә. Павел Потемкин 8 июль көнне Казанга килеп төшә һәм, «бөек» патшабикәне тынычландыру өчен, шапырыну тулы хатлар юлларга ашыга. Пугачев һөҗүменнән коты очкан Екатерина аның рапортларын көтеп ятмый. Ул көньякта сугыш алып баручы фельдмаршал А. Румянцев янына, аның теләсә нинди шартларда Рәсәй — Кырым солыхын төзүен таләп итеп, ашыгыч рәвештә чапкын җибәрә. Ә 8 июльдә указ язып, ул Ф. Щербатовны башкомандующийлыктан алып ташлый һәм аның урынына нәкъ Щербатов шикелле үк булдыксыз, әмма чибәрлеге белән дан алган генерал П. Голицынны билгели. Әмма генераллар ул фәрманны алып өлгермиләр. Ул арада Рәсәй өстенә яңа, тагын да хәтәррәк хәвеф ава.

# ПУГАЧЕВ ТАТАРСТАНДА

Пугачев 8 мең кешелек гаскәр белән 29 июнь көнне Татарстанга керә. Әгерҗе авылы крестьяннары аны мәчет мәйданында зур-зур казаннар асып каршы ала. Якын-тирәдәге авыл халкы «падишаһ» гаскәре өчен сарык, үрдәк, каз, тавык алып килә. Забегалово авылы крестьяннары, зур чанга салып, арба белән 2 потлы мәрсин балыгы да китерәләр. Балык әле һаман да тере була һәм мондый сирәк бүләк, әлбәттә, «падишаһ» күңеленә хуш килә. Мәйдан читләренә зур-зур өстәлләр тезелә. «Падишаһ» бу көнне «үзенең малае» — Павел Петровичның туган көнен бәйрәм итә. Һәр кешегә икешәр тәңкә акча өләшенә. Әгерҗедә үк «падишаһ» гаскәре якын-тирә авыллардан килеп кушылган крестьяннар хисабына тулылана башлый. Аеруча Уклы-Карагай крепосте янында полковник дәрәҗәсен алган Исхак Әхмәтов полкы татар крестьяннары исәбенә ишәя.

Икенче көнне Пугачев янә юлга чыга. Ул, Данилово, данлыклы Тирсә, Сарсак-Омга, Аккүз, Сукман, Алнаш, Камай, Бондюг авыллары аша үтеп, 1 июльдә Алабуга янына килеп җитә. Алабуга руханилары «падишаһ»ны каладан 7 чакрым алга чыгып иконалар белән каршылыйлар. Пугачев, аларга гыйнвар аенда «падишаһ» отрядларына буйсынмаган өчен шелтә белдерсә дә, билгеле инде, соңыннан гафу итә. Ул фетнәчеләрне Алабугага озата, ә үзе Сарайлы (Бехтерово) авылында, бай сәүдәгәр И. Красильников йортында төн кунарга кала (икенче төркем галимнәр аны Алабуга күле буенда чатыр корып кунган дип тасвирлый).

*Укучылар игътибарын сәер бер вакыйгага юнәлтәсе килә. Тирсә авылы аша узган чакта, крестьяннар «падишаһ»ка үзләренең дошманнары — алпавыт Йосыф Тәвкилевнең кызын тотып китергән булалар. Ә дворян тарихчысы Н. Дубровинның тасвирлауларына караганда, «падишаһ» үзе тукталган һәр урында ике чатыр корып урнаша һәм, аңлашыла ки, ялгыз кунмый. Безнең фараз: Пугачев Алабуга янында да шундый ук «батырлык» кылырга ымсынып карамадымы һәм аның «авызы пешмәдеме» икән? Чөнки ни сәбәпледер, Пугачев икенче көнне, кинәт, Котловка авылында яшәгән һәм заманында аңа балык саткан Карп Карасевны исенә төшерә дә Тәвкилев кызын аңа «бүләк» итеп юллый. Чәче чаларган һәм «комы коелган» 70 яшьлек Карп Карась ул «бүләк» белән ни эшләргә тиеш булгандыр инде? Монысы аңлашылмый. Әлбәттә, әлеге вакыйганы искә алуыбыз — лирик чигенеш кенә. Хәзер җитдиләник.*

2 июль көнне Пугачев Алабугадан чыга һәм Лекарево, Танайка авыллары аша үтә. Мондагы крестьяннарга декабрь —гыйнвар аенда күрсәткән тугрылыклары өчен рәхмәт белдерә. Аннан соң ул Мурзиха аша үтә, Нократ елгасын кичә, 4 июль көнне Мамадышка керә.

Татарстан җиренә кергәннән соң, әле Әгерҗе районында торган чагында ук, Пугачев төп армиядән алда үзенең аерым полкларын һәм отрядларын җибәрә. Шермяит заводына килеп эшләүче крестьяннарны ул, мәсәлән, ике судного утыртып, Камадан түбәнгә таба юллый. Никитин белән Игнатьев кул астына тупланган фетнәчеләр дә икмәк һәм он төялгән баржалар белән Котловка авылына кадәр төшәргә тиеш була. Ләкин Бәтке пристане янында завод крестьяннары да, Никитин белән Игнатьев суднолары да полковник Обернибесов карательләренең кулына эләгә. Завод крестьяннары каравыл сагы астында Минзәлә төрмәсенә озатыла, ә икмәк тулы баржалар, Пугачев киткәннән соң, Алабугага китерелә.

Аның каравы, коры җирдән юлланган отрядларның эшчәнлеге бик уңышлы бара. Полковник Дорофей Загуменнов кул астындагы Авзян полкы Мамадыш өязенең Кама елгасы буенда урнашкан авылларында йөзәрләгән крестьяннарны яңа отрядларга туплый. Котловка авылының үзендә генә дә, мәсәлән, йөзбашлары Иван Зотов һәм Андрей Кириллов җитәкчелегендә 170 кешелек отряд төзелә. Котловка янында Кама ярына лагерь корып урнашкан Загуменновка тирә-як авылларның һәркайсыннан яңадан-яңа отрядлар килеп кушыла.

Фетнәгә кадәр Уктус заводына беркетелгән крестьян, хәзер исә «падишаһ» полковнигына әверелгән Григорий Филинковны Пугачев үзенең уң канаты итеп алдан юллаган була. Филинков Толубачево, Верхняя Тойма, Матвеево кебек авыллар аша үтә һәм Арча юлына чыга. Әлеге эмиссар да тиз арада үз кул астына яңа полк туплый һәм аны Мамадышка «падишаһ» карамагына алып килә *(В. Мавродин)*.

Әлбәттә, Казан провинциясендәге крестьяннар «падишаһ» эмиссарларын гына көтеп ятмыйлар. Пугачевның Казанга таба юнәлүен белеп алуга ук, провинциянең барча почмагында 1773 елның көзенә караганда да дәһшәтлерәк фетнә кузгала. Бик күп төбәкләрдә крестьяннар христиан руханиларын һәм урыс алпавытларын юк итәләр, аларның утарларын, авылларын талыйлар. Красная Горка, Олы Елан, Ушма, Юкәче, Карабаян кебек байтак авыллардагы крестьяннар, чакыруны да көтмичә, Мамадыш авылына килә һәм Пугачевка кушыла.

Мамадышта Пугачев явы тарихына аерым сәхифә булып кергән шактый гыйбрәтле вакыйгалар да була. Шуларны санап үтик.

Пугачев Мамадышта торган чакта, аның янына Котловка авылы вәкилләре итеп сайланган Карп Карасев һәм тагын 2 крестьян килә (безгә калса, алар Иван Зотов белән Андрей Кириллов булырга тиеш). Авыл мәйданында махсус кәнәфидә утырган «падишаһ»ны күргәч, Котловка вәкилләре аның каршына килеп тезләнә. Карп Пугачевка икмәк һәм берничә кыяр суза. Шул вакытта Пугачев белән Карп арасында шушындыйрак әңгәмә булып үтә:

— Мин узган ел сәүдәгәр Дружинин белән килеп, синнән 7 тиенгә балык сатып алган идем бит. Син мине таныдыңмы?

— Юк, мин сине танымадым. Син — падишаһ.

— Ә мин сиңа бүләк итеп җибәргән икмәк белән алпавыт Тәвкилев кызын алдыңмы соң?

— Юк, алмадым.

— Алар озакламый сиңа килеп җитәр. Алпавыт кызын үзеңдә тот.

(«Падишаһ бүләкләре» Карп карамагына килеп җитмәячәк. Никитин, Игнатьев сагында озатылган ул судноларның Бәтке янында полковник Обернибесов кулына төшүе хакында без кисәттек инде.)

Карп Карасевның Пугачевны танымавы һәм сер сатмавы «падишаһ» тарафыннан югары бәяләнә. 1761—1762 елгы фетнә чорыннан ук Карп Карасевны яхшы белгән Дорофей Загуменнов тәкъдиме буенча (Загуменновның шушы төбәктәге бер авыл крестьяны булуына яңа дәлил) 70 яшьлек картка полковник дәрәҗәсе бирелә, һәм ул Котловка волостеның баш атаманы итеп билгеләнә. (Әлеге мөхтәрәм карт исемен башкача телгә алмабыз, шуңа күрә аның алдагы язмышын да ачыклап үтик. Волость атаманы булып билгеләнгән Карп үзен гадел юлбашчы итеп таныта. Крестьяннарны аяусыз талавы өчен, ул Мурзиха авылының приказчигы Михаил Гавриловны чыбыркы белән суктыра. Пугачев Казан янында тар-мар ителгәннән соң, ул әүвәл 2 атна буе Черенга авылы янындагы урманда качып яши. Ашарына беткәч, Котловка урманына кайта, аннан Слутки авылына таба китә. Әмма 18 августта патшабикә карательләре кулына эләгә. Пугачевның «карак» икәнлеген яшергән һәм аны халык алдында «падишаһ» дип таныган өчен, 70 яшьлек Карп Степанович Карасевны генерал Павел Потемкин әмере буенча Зәйдә дарга асып үтерәләр.)

Мамадышта чагында Пугачев Җаек казагы, Исет полкының командиры итеп билгеләнгән Иван Шибаевны да хөкем итә. Апрель аенда Урал заводларына фетнә отрядлары туплау өчен озатылган әлеге казак, Златоустка килгәч, завод конторасын талаганда, казна малын үзләштерүе һәм хәмер яратуы белән «дан казана». Шул «каһарманлыгы» өчен аны Иван Белобородов кулга ала. Әмма Магнитная крепосте янында кушылганнан соң, Җаек казаклары Шибаевны яклап чыгалар. Аларның басымы астында Пугачев Шибаевка полковник дәрәҗәсе бирергә һәм аңа Исет полкын тапшырырга мәҗбүр була. Ә Шибаев казна талавын һәм эчүчелек белән шөгыльләнүен һич туктатмый. Хәзер исә Пугачевка да кыюлык өстәлә. Чөнки аның тирәсендә яңадан-яңа җитәкчеләр, киңәшчеләр пәйда була. Гомуми саны белән 15 меңгә якынайган гаскәр эчендә Җаек казакларының тәэсире, абруе, куәте нык кими. Чөнки Җаек казакларының күләме 400 кешедән артмый (Сакмар буеннан Пугачев шәхсән үзе алып киткән 100 казак + Овчинников белән Перфильев кул астында Магнитная янында килеп кушылган 300 казак). Шуңа күрә хәзер Пугачев инде кискен карар чыгара һәм полковник дәрәҗәсен йөрткән Иван Шибаевны дарга астыра. Аның урынына Исет полкының командиры итеп Григорий Филинков билгеләнә.

Пугачев янына Мамадышка үз отряды белән Бәхтияр Канкаев та килеп кушыла. Бәхтияр бу төнне Пугачев янында, Мамадышта үткәрә. Шушында Пугачев Бәхтияр Канкаевка баш полковник (яки бригадир) дәрәҗәсен бирә. Моннан соң Бәхтияр үзе инде башка командирларга полковник дәрәҗәсен бирү хокукын ала. Ә икенче көнне, ярдәмгә нибары 6 кеше генә биреп, Пугачев Бәхтиярны, яңа отряд туплау һәм «падишаһ»ның Казанга походын Кама аръягындагы карательләр һөҗүменнән саклау өчен, Җөри юлына озата. Без Бәхтиярның 6 ярдәмчесен дә хатасыз рәвештә санап чыга алмабыз. Әмма алар арасында походный старшиналар Габдулла Мостаев, Балтач Сәетов белән сәркатип Әбүбәкер Teләчев булуына шигебез юк.

8 июль көнне иртән Пугачев гаскәре Мамадыштан чыга һәм Казанга юнәлә. 9—10 июльдә Пугачев Югары һәм Түбән Курса авыллары (Арча районында) аша уза. Биредә ул үзен «падишаһ» дип танымаган Зәид Сөләйманов, Дүсмәкәй Уразманов, Гобәйдулла Исмәгыйлов һәм Рәфыйк Шәриповны дарга астыра. Мичән, Олыяз авылларында да шундый ук хәл кабатлана. Биектау, Чыршы, Сасмак, Мәңгәр, Җөри, Саба, Нырсы, Мәтәскә, Теләче, Тимершык һәм башка дистәләгән авыллардагы меңәрләгән татар крестьяннары «падишаһ» гаскәренә теләп кушыла. Хәзерге Балык Бистәсе районындагы Тегермәнлек авылы крестьяннары «падишаһ»ны танырга теләмәгән йөзбашын юк итәләр һәм, 61 кешелек отряд төзеп, Пугачев янына китәләр (*С. Алишев*. «Татары...»).

10 июльдә Казаннан губернатор Брандт юллаган полковник Толстой отряды Пугачев гаскәрен Биектау районындагы Ямаширмә һәм Чыпчык авыллары арасында каршылый. Нибары 100 солдат, 100 карабинердан торган һәм 1 туп белән коралланган әлеге отряд, билгеле инде, фетнәчеләр гаскәрен туктатырдай көч булмый. Пугачев фәкать 1000 кешелек кенә отряд алып карательләргә ташлана. 53 солдат шундук Пугачев ягына чыга, калганнары тулысынча, шул исәптән Толстой үзе дә юк ителә *(В. Мавродин).*

11 июльдә гомуми саны белән 20 меңнән арткан Пугачев гаскәре Казан тирәсенә килеп җитә һәм шәһәрдән 7 чакрым ераклыктагы Троицк монастыреның тегермәне янында (хәзерге компрессорлар заводы каршында) лагерь корып урнаша. Пугачев, сәркатипләр Алексей Дубровский һәм Идеркәй Мәхмүтов тарафыннан язылган указларны биреп, атаман Овчинниковны калага озата. Әмма шәһәр администрациясенә, калада яшәүче урыс һәм татар халкына адресланган әлеге өч указны сакчылар кабул итми. Ул арада Пугачев янына каладан качкан ике татар һәм бер урыс вәкиле килеп җитә. Алар каланың аеруча Арча юлы ягыннан бик көчсез саклануын хәбәр итәләр. 50 кешелек отряд алып, Пугачев шәхсән үзе дә Казанның оборона системасын карап чыга һәм штурм урыннарын билгели. Шул көнне үк кич белән Пугачев янына Казаннан качып чыккан тагын 70 ләп татар һөнәрчесе килә һәм «падишаһ»ка шикәр, бал, тукыма шикелле бүләкләр бирә *(В. Мавродин).*

## *КАЗАННЫҢ ХӘЛЕ*

Ул чакта Казан каласы 3 өлешкә бүленә: озынлыгы белән 750 сажинга җиткән таш Кремль, шәһәр урамнары һәм тирә-яктагы бистәләр. Шәһәрдә барысы 93 таш, 9 агач чиркәү һәм 4 мәчет исәпләнә. Кала 9 зур һәм 170 кә якын кечкенә урам вә тыкрыклардан тора. Йортлар бер-берсенә терәлеп диярлек утыра, шәһәр төзелешендә һичнинди система яки тәртип булмый. Каланы Постаучылар (Сукночылар), Кирпеччеләр, Ямчылар, Савино, Кызыл, Архангел, Пләтән, Җиләк, Юеш, Бишбалта, Кәҗә, Иске һәм Яңа Татар исемнәрендәге бистәләр урап алган була. Шәһәрдә 70 кә якын завод-фабрика исәпләнә. 3939 йортта 15 меңнән артык кеше яши (*С. Алишев*. «Татары...»).

Шәһәрне фетнәчеләр һөҗүменнән саклану өчен ныгыту эшләре әле 1773 елның ноябрь аенда ук башлана. Әмма шәһәр халкы арасында паника тудырмау максатыннан, губернатор Брандт бу эшләрне актив рәвештә алып бармый. Шәһәргә алып керүче һәр юлга капка һәм рогаткалар, алар янына каравылчылар куела. Каравылчылар юлда очраган һәр шикле кешене тикшерәләр. Моннан тыш, Брандт Кама буйлап берничә судно җибәрә, һәм шулар фетнәчеләргә елга аша кичү юлын бикләргә тиеш була. Брандт шәһәр арсеналында булган барча коралларны тикшерттерә, һәм каланың оборонага хәзерлеге шушы чаралардан артмый.

Казанда тупланган регуляр командалардагы солдатлар саны 1500 чамасы исәпләнә. Адмиралтейство карамагында тагын 200 кешелек хәрби отряд була. Гимназия директоры фон Канниц 74 укучыны коралландыра. Губерна канцеляриясендә, Казан төрмәләрендә «эшләгән» хәрбиләрне дә санагач, Брандт кул астындагы сакчылар саны 2000 чамасы исәпләнә. Моннан тыш, калада яшәүче 6000 гә якын ир-ат та фетнәчеләргә каршы көрәшергә тиеш була *(С. Алишев)*.

Брандт Казанны 4 саклану зонасына бүлеп чыга. Пләтән белән Ямчылар бистәсе арасын безгә яхшы таныш генерал, берничә ай элек кенә башкомандующий булып торган А. Бибиковның туганы Ларионов сакларга тиеш була. Әмма әлеге җебегән генерал, юк сәбәпләрне бар итеп, 3 июль көнне Казанны ташлап кача *(Н. Дубровин)*. Шуннан соң Кабан күленнән, Казансу елгасыннан Арча кырына кадәр булган зур араны саклау бурычы генерал-майор Баннерга йөкләнә. (Әлеге генерал Мәскәү легионы белән идарә итә алмаган өчен 1771 елда армиядән читләштерелгән була. — *Н. Дубровин*.) Ямчылар бистәсе ягын — Адмиралтейство башлыгы полковник Свечин, Казансу елгасы буен — Адмиралтейство офицеры Щелин, Сукночылар бистәсе ягын — сәүдәгәр И. Дряблов, Татар бистәләре ягын Адмиралтейство комиссары Андрей Алкин командалары сакларга тиеш була. Кремльне оборонага әзерләү һәм саклау аның коменданты полковник Лецкий бурычы булып кала. Моннан тыш, Брандт, Казанда булган тупларны бүлеп, 4 урында махсус батареялар урнаштыра.

7 июль көнне губернатор Брандт сатлык татар Мөсәлим Әлмәмәтов юллаган хат аша «карак» Пугачевның Мамадышка килүе турында белеп ала. Брандт җитез Михельсон ярдәменә өметләнә, әмма шәһәрдә тиңсез мәхшәр куба. 8 июль көнне Казанга Екатерина тарафыннан озатылган генерал П. Потемкин килеп төшә. «Һавалы» генерал шәһәрдә булган көчне барлап та тормый, әмма инде патшабикә исеменә «шәһәргә һичнинди куркыныч янамый», дип хат язарга да «фетнәчеләрне Казанга һөҗүм иттергәнче мин үләргә әзер» дип ант сулары эчәргә дә ашыга. Шул ук Потемкин губернатор Брандттан үзенә аерым отряд бирүләрен таләп итә. Брандт бүлеп биргән 450 солдат, 300 чуваш һәм татар крестьяны, 2 туп белән Потемкин шәһәрне Арча кыры ягыннан сакларга тиеш була. Фон Канниц гимназистлары Потемкин батареясы белән янәшәдә урнаша. Шушы ук төбәккә апрель аенда Екатеринага рапорт илтеп подполковник дәрәҗәсен алуга ирешкән җәллад Неклюдовның 80 кешелек һәм 2 туплы отряды да куела. 11 июль кичендә Пугачев 50 «казак» белән бергә Казан ныгытмаларын карап йөргәндә һичнинди атыш купмаса да, «һавалы» Потемкин Екатеринага «фетнәчеләр Казанга һөҗүм ясады, без аларны кудык» дип ялган рапорт юллый *(Н. Дубровин)*.

## *КАЗАННЫ АЛУ*

11 июль кичендә һәм төнлә Пугачев гаскәре сан ягыннан һаман үсә бара. Тирә-яктагы авылларда яшәгән халык туктаусыз «падишаһ» армиясенә агыла. Фетнәчеләр, төнлә вак-төяк отрядларга бүленеп, Казан каласын төрле яктан урап алалар. Һәр тарафта каравыллар куела, отряд командирлары билгеләнә. Яу барышында буталыш, хаталану булмасын өчен, фетнәчеләр сул кулларына ак төстәге яулыклар һәм чүпрәкләр бәйлиләр. Штурм җиңелләшсен һәм корбаннар аз булсын өчен, татар крестьяннары якын-тирә авыллардан печән, салам төялгән олаулар алып киләләр. Таң атканчы Пугачев гаскәренә яңа отрядлар өстәлә тора. Ташлы, Күперле, Күлбаш, Бигеш, Юныс, Коргуҗа, Салавыч, Утар, Ташсу, Әки, Коркачык, Аркатау шикелле дистәләгән татар авылларыннан килгән крестьяннар төп гаскәргә иртә белән генә килеп

кушыла. Пугачев армиясендәге фетнәчеләр саны 25 меңгә җитә. «Пугачев армиясенең берчакта да бу кадәр зур булганы юк иде» — дип моны соңыннан хыянәтче Иван Творогов та таный. Армиянең зур күпчелеген, һичшиксез, татар крестьяннары тәшкил итә.

12 июль көнне сәгать 4 тә «падишаһ» үз атаманнарын һәм полковникларын хәрби киңәшмәгә дәшеп ала. Җаек казаклары И. Творогов, Е. Васильев, Ф. Федульев, А. Овчинников, А. Перфильев, Г. Леонтьев белән бергә киңәшмәдә урыс атаманнары И. Белобородов, И. Грязнов, Д. Загуменнов, Г. Филинков, Усада төзелгән Казан полкы командиры Ф. Минеев, башкорт крестьяннарының юлбашчысы Кинҗә Арысланов, татар җитәкчеләре Идеркәй Мәхмүтов, Муса Алиев, Садыйк Сәгыйтов, Исхак Әхмәтов, башка күренекле фетнәчеләр катнаша. Киңәшмәдә армияне 4 зур колоннага бүләргә карар кылына. Арча кыры ягыннан һөҗүм итәчәк колонна белән атаман Белобородов, Сукночылар бистәсенә каршы Пугачев үзе, Арча кыры белән Казансу елгасы арасыннан Минеев, дүртенче колонна белән А. Овчинников, И. Мәхмүтов, М. Алиев җитәкчелек итәргә тиеш була.

Казанны штурмлау иртәнге 6 да, берьюлы 4 яктан башлана. Фетнәчеләр, алдан ук хәзерләнгән печән, салам олаулары артына яшеренеп, калага якынлаша. Ике олау арасына яшерелгән туплар шәһәрне саклаучы батареялар өстенә ут яудыра башлый. Коралсыз крестьяннар, иңкүлекләр һәм чокырлар буенча хәрәкәт итеп, сакчылар өстенә ташлана. Неелов әрәмәлегендәге (анда секунд-майор Яков Неелов йорты була. — *Н. Агафонов.* — Хәзер биредә М. Горький исемендәге Мәдәният һәм ял паркы) агачлар артына ышыкланып килгән крестьяннар да шәһәр урамнарына бик тиз үтеп керә. Подполковник Неклюдов, гимназия директоры фон Канниц, генерал Потемкин кул астындагы батареяларның туктаусыз ут яудыруы бернинди нәтиҗә дә бирми. Белобородов җитәкчелегендәге колонна сакчылар линиясен җимерә. Фон Канниц һәм 19 гимназист үтерелә. Калганнары Кремльгә чигенә. Неклюдов 80 кешелек үз отряды белән, алга таба чыгып, фетнәчеләр һөҗүмен туктатырга омтылып карый. Әмма кул астында 450 сугышчысы булган генерал Потемкин аңа ярдәм итми. Җитмәсә, аның командасындагы татарлар фетнәчеләр ягына качып чыга. Гимназистлар отрядының тар-мар ителүен күрүгә үк, «коры куык» генерал Кремльнең таш стеналары артына кача. Белобородов сугышчылары санаулы минутлар эчендә хәзерге Зур Кызыл, Толстой, Бутлеров урамнарына бәреп керәләр. Заманында вице-губернатор Никита Кудрявцев төзеткән зур йорт, байлык белән тулы Грузин чиркәве, Адмиралтейство конторасы, сәүдәгәрләрнең йортлары — һәммәсе фетнәчеләр өчен табышка әверелә.

Сукночылар бистәсенә һөҗүм башлаган Пугачев та эшне бик тиз тота. Генерал Баннер, фабрикант Дряблов командалары «падишаһ»ка ныклы каршылык күрсәтә алмый. Һәрьяктан бердәм ташланып, фетнәчеләр әүвәл Сукночылар бистәсен ала. Дряблов фабрикаларында газап чиккән эшчеләрнең зур күпчелеге Пугачев ягына чыга, шуларның берсе — Андрей Яковлевны «падишаһ» үзенең полковнигы итеп билгели. Аннары Пугачев хәзер финанс-икътисад институты урнашкан тау башына туплар куя да шуннан шәһәр урамнарына ут яудырырга тотына. Татар-башкорт яугирләре дә биредән Баннер солдатлары өстенә ук һәм ядрә яңгыры яудыра.

Татар каһарманнары И. Мәхмүтов, М. Алиев җитәкләгән колонна Татар бистәләре һәм Болак ягыннан һөҗүм итә. Юеш бистәсен сакларга тиеш булган татар алпавыты, Адмиралтействоның комиссары Андрей Алкин, шулай ук полковник Свечин отрядлары фетнәчеләрнең һөҗүменнән соң үзләренә тапшырылган постларны ташлап кача. Алкин хәтта Зөя өязенә кадәр качып китә. Ә татар бистәләрендә яшәүчеләр «падишаһ» гаскәрен колач җәеп каршылый.

Дүртенче колонна белән һөҗүм башлаган Минеевка да җитди каршылык күрсәтүче табылмый (мәгълүмат өчен шунысын да өстик: Казан полкы составындагы бер отряд белән әле 20 көн элек кенә Уса коменданты булып торган поручик Пироговский җитәкчелек итә). Минеев хәзерге Зур Кызыл, К. Маркс урамнарына бәреп керә. Тиздән инде Казанның барча урамнары һәм бистәләре фетнәчеләр кулына төшә. Шәһәр сакчылары Кремль эченә кереп бикләнәләр.

Пугачев ирешелгән уңышлар белән генә канәгатьләнми. Ул Кремльне дә алырга карар кыла. Шул максат белән ул үзе Гостиный двор (ул кунак йорты түгел, бәлки 777 кибет урнашкан сәүдә үзәге; хәзерге Татарстан Республикасының Милли музее тирәсендә булган) түбәсенә ике туп урнаштыра. Аның әмере буенча Минеев та кызлар монастырен (менә бит ул «язмыш ирониясе»: хәзер бу йортта педагогия институтының кызлар яши торган тулай торагы урнашкан) ала һәм аның түбәсенә ике туп куя. Хәзерге Бауман урамы ягында да махсус батарея урнаштырыла. Менә шушы өч батарея белән Пугачев Кремль эченә бикләнгән «сакчылар» өстенә ут яудыра башлый. Кремль эчендәге агач йортларга ут каба. Архиепископ Вениамин, Кремльдәге Собор эченә бикләнеп, «Ходайдан ярдәм сорый». Фетнәчеләр, стеналар буена якынаеп, «сакчылар»ны «падишаһ»ка бирелергә кыстыйлар. Ул да булмый, «сакчылар» арасында да икеләнү туа. Бик күпләр инде, ташлар, бүрәнәләр белән ныгытылган капкаларны ачып, «падишаһ»ны каршыларга үгетли башлый. Потемкин шундый ике үгетчене дарга астыра *(Н. Дубровин)*.

Ләкин фетнәчеләргә Кремльне тагын да штурмларга мөмкин булмый. Шәһәрнең һәр почмагында диярлек янгын башлана. Җил төтен һәм янгынны Кремль тарафына, Пугачев белән Минеев урнашкан йортларга таба куа. Җитмәсә, Пугачевка подполковник Михельсон отрядының Казанга якынлашуы турындагы хәбәрне китерәләр. Башка чарасы калмаган Пугачев Кремльне штурмлауны туктатырга һәм төштән соң үз гаскәре белән Арча кырына чигенергә мәҗбүр була.

Пугачев штурмы алдыннан Казан төрмәләрендә 415 фетнәче әсирлектә тотылган була. Ә Пугачев һөҗүмгә ташлангач, генерал Потемкин төрмәдәге офицерларга тоткыннарны юк итәргә әмер бирә. Тоткыннар арасындагы Пугачев атаманы, 1767 елгы Уложение комиссиясе депутаты һәм шул депутатлыгы өчен Екатерина тарафыннан җәзасыз гомер вәгъдә ителгән Гаврила Давыдов каравыл офицеры тарафыннан шпага белән кадап үтерелә. Дөрес, каравылчылар барча тоткыннарны да юк итәргә өлгермиләр. Төрмәләрдә һәм Бишбалта бистәсендәге махсус лагерьда тотылган мәхбүсләрнең зур күпчелеге фетнәчеләр тарафыннан азат ителә. Алар арасында Тимершык, Балыклы һәм башка авыллардан Урал заводларына барып эшләгән һәм, шунда Пугачев армиясенә кушылып, Татищев крепосте янындагы яуда әсирлеккә төшкән Бәшир Мөэминов, Әмирхан Хәсәнов шикелле дистәләгән тоткыннар да була (*С. Алишев.* «Татары...»).

Фетнәчеләр Пугачевның Казан төрмәсендә тотылучы хатыны Софья белән аның балалары Трофим, Аграфена һәм Христинаны да азат итәләр. Пугачев, Кремль буеннан чигенеп, Арча кырына таба барган чакта, 11 яшьлек Трофим әтисен танып кычкыра:

— Әни, әни, карале, безнең әти бара!

Билгеле инде, «падишаһ» кеше үзенең гаиләсен «танырга» тиеш булмый. Әмма, шул ук вакытта, ул аларны ташлап та китә алмый. «Падишаһ» әлеге четерекле хәлдән бик тә «коры» чыга:

— Ә-ә, болар заманында миңа яшеренеп йөрергә ярдәм иткән Пугачев дигән казакның якыннары. Аларга махсус олау бирегез дә минем чатырымның берсенә урнаштыры- гыз, —ди ул.

(Соңыннан, төнлә, Пугачев хатыны Софья белән очраша да үзен сатмауларын таләп итә.)

Шул ук сәгатьләрдә төрмәдән Пугачевның Нагайбәк крепостендагы атаманы Вәлит Торнов та азат ителә. Пугачев аны шундук полк командиры итеп билгели.

Ул арада шәһәр өстендә коточкыч янгын давылы уйный. Бистәләрдә һәм шәһәрдә урнашкан 2091 йорт янып юкка чыга. 777 кибете белән Гостиный двор, 28 чиркәү янып бетә. Яу барышында хөкүмәт гаскәрләре сафыннан 162 кеше һәлак була, 129 ы яралана, 486 кеше эзсез югала *(С. Алишев, Н. Дубровин, А. Пушкин)*. Власть вәкилләренең соңыннан исәпләве буенча Пугачев армиясенең штурмы нәтиҗәсендә Казан шәһәренә 1 миллион 898 мең сумлык зыян китерелә *(С. Алишев)*. Хәтта «һавалы» генерал Потемкин да «атаклы» абыйсына юллаган хатында үз хәлен: «Маңгайга пистолет терәү — минем өчен бердәнбер чара», — дип бәяләргә мәҗбүр була.

### *ҖИҢЕЛҮ*

Патшабикә карательләре арасыннан бердәнбер курку һәм тынгы белмәс командир булып танылган подполковник Михельсон, Пугачевның үкчәсенә басып, Казанга якынлаша. Юл уңаеннан ул «карак» ягына кушылган яки аңа ярдәм иткән авыл крестьяннарын җәзага тартырга да онытмый. Казансу елгасы буендагы Кече Ил авылында, мәсәлән, фетнәчеләргә ризык һәм фураж белән ярдәм иткән, Пугачевның шәхсән үзенә бүләк биргән берничә татар крестьянын, хәтта аксакалларын да коточкыч рәвештә камчылар белән кыйната. Шул кыйналудан картларның берничәсе җан бирә *(В. Мавродин)*.

Михельсон 12 июль кичендә Казан янына килеп җитә. Пугачев аны Арча кыры артындагы Царицыно авылы янында 12 мең кешелек гаскәрен сафларга тезеп каршылый *(В. Буганов)*. Михельсон якынайгач, Пугачев туплардан ут ача. Аннары, фетнәчеләрне 2 колоннага бүлеп, Пугачев карательләр өстенә ташлана. Ул, бер колонна белән тылга үтеп, Михельсон отрядын камалышка алырга исәп тота. Әмма Михельсон да үз отрядындагы 800 кешене 2 өлешкә бүлә һәм бер команданы майор Харин карамагына тапшыра. (Безгә калса, рапортларда Михельсон үзенең кул астындагы көчне гел киметеп күрсәтә. Бу очракта да ул үз янында Солтанморат Янышев, Шәрип Киеков, Мөхсин Әбдесәламов, Ишмөхәммәт Сөләйманов җитәк-челегендәге хыянәтче башкорт-мишәр җайдаклары булуын әйтми калдыра һәм фәкать регуляр гаскәрдәге солдатлар санын гына телгә ала кебек.) Фетнәчеләр Харин командасына каршы аеруча уңышлы сугышалар. Яу барышында Харин командасына җиңелү куркынычы туа. Ләкин Михельсон аңа ярдәмгә килеп өлгерә. Канлы яу төн уртасына кадәр дәвам итә. Ике як та уңышка ирешә алмыйча чигенә. Михельсон отрядында 23 кеше һәлак була, 38 сугышчы яралана. Фетнәчеләр арасыннан 800 гә якын кеше һәлак була, 737 се әсирлеккә эләгә. Фетнәчеләрнең 6 тубы карательләр кулына төшә. Пугачев Казансу елгасы аръягына чигенә *(Н. Дубровин, В. Мавродин, С. Алишев, Х. Муратов, В. Буганов)*.

13 е көнне иртән Михельсон Казанга Кремль эченә бикләнгән гарнизон янына үтәргә омтыла. Ләкин Арча кырында аны Пугачев гаскәре каршылый һәм тагын һөҗүмгә ташлана. Яу башлангач, генерал Потемкинга да кыюлык иңә. Ул Кремль эчендәге отряд белән Арча кырына килеп җитә һәм Пугачев гаскәренә икенче яктан һөҗүм ясый. Ике ут арасында калган Пугачев Казансу елгасы аръягына чигенергә һәм шәһәрдән 20 чакрым читтә, Сухая Река авылы янында махсус лагерь корып урнашырга мәҗбүр була. Ә Михельсон белән Потемкин отрядлары, Кремль гарнизоны бергә кушыла.

Әлбәттә, Пугачев алдагы көндә үзенә нинди куркыныч янавын да, карательләрнең берләштерелгән гаскәренә каршы тору өчен Сухая Рекага тупланган көчнең генә җитмәячәген дә яхшы аңлый. Шуңа күрә ул үз гаскәрен яңа отрядлар белән тулыландыруга аеруча зур игътибар бирә. Полковник Исхак Әхмәтов белән йөзбашы Сәлим Гаделшин, шулай ук Борис Савельев ашыгыч рәвештә хәзерге Питрәч районына озатыла. Алар Кавал авылына килеп отряд туплый башлый. Шундый ук эмиссарлар Казан тирәсендәге башка авылларга да озатыла. Нәтиҗәдә 15 июль иртәсенә Пугачев кул астына кабат 15 меңнән артык фетнәче туплана (С. Алишев, В. Буганов, Н. Дубровин. Ә В. Мавродин белән Х. Муратов бу көндәге фетнәчеләр санын да 25 мең дип күрсәтә).

Пугачев шушы көч белән янә Царицыно авылына юнәлә. Арча кырында фетнәчеләрне Михельсон командалыгындагы берләштерелгән отряд каршылый. Бер-берсен күрә алмас көчләр ике сәгать буена туп һәм мылтыклардан ут яудыра. Шуннан соң Пугачев үз гаскәрен һөҗүмгә ташлый. Фетнәчеләр кире чигенмәсен өчен, Җаек казаклары аларның тылын озын сөңгеләр белән «каплап» тора. Фетнәчеләр әүвәл Михельсонның Харин командалыгындагы сул флангын кысрыклауга да ирешәләр. Ләкин Михельсон ул тарафка ярдәм җибәрә. Аннары инде карательләрнең бердәм һөҗүме башлана. Фетнәчеләр ак-караны күрмичә чигенергә һәм качарга тотына. Карательләр 2 000 гә якын фетнәчене юк итә. 5 000 нән артык кеше, 9 туп, 17 байрак карательләр кулына эләгә. (Чагыштыру өчен шунысын да өстик: Михельсон отрядында 35 каратель һәлак була, 121 кеше яралана.) Һәлак булучы һәм әсирлеккә төшүче фетнәчеләрнең зур күпчелеген татар крестьяннары тәшкил итә. Казан янындагы яулар барышында Пугачевның күренекле ярдәмчеләреннән берсе Иван Грязнов һәлак була («Документы ставки Е. И. Пугачева...»), ә Казан полкы командиры Ф. Минеев, татар каһарманнары Муса Алиев белән Идеркәй Мәхмүтов карательләр кулына эләгә *(Н. Дубровин)*. 16 июль төнендә Кавал авылында Исхак Әхмәтов, Сәлим Гаделшин белән Борис Савельевны да хыянәтче крестьяннар кулга ала һәм, Казанга алып килеп, карательләр кулына тапшыра *(С. Алишев)*. Гаиләсе белән урманда качып йөргән атаман Иван Белобородов 18 июль көнне «Иван Шеклеинов» исемендәге крестьян булып Казанга килә. Әмма аны да хыянәтчеләр «сата», һәм шул көнне үк Белобородов Михельсон кулына эләгә. (Әлеге каһарманнар исемен кабат искә алып булмас, язмышлары белән таныштырып үтик. Патшабикә армиясендә — подпоручик, «падишаһ» кул астында полковник булган Минеев Михельсон әмере буенча 1000 кешелек хәрби саф уртасыннан унике (!) тапкыр шомполлар белән кыйнап уздырыла һәм, әлбәттә инде, шунда җан бирә. И. Әхмәтов, С. Гаделшин, Б. Савельев әүвәл Казан мәйданнарында җәзалана, борын-колаклары киселә, аннары гомерлек сөргенгә озатыла. Атаман Белобородовны да Казан мәйданында чыбыркы белән 100 тапкыр суктыралар, ә 5 сентябрьдә Мәскәүдә аның башын чабып өзәләр. — «Следствие и суд над Пугачевым»; *С. Алишев; Ю. Лимонов*. — Муса Алиевның алдагы язмышын тасвирлаучы тарихи документлар әлегә табылмаган. Әмма бу каһарманның да йә зинданда, йә сөргендә шәһит булуына шигебез юк.)

Арча кыры белән Царицыно авылы уртасында тар-мар ителгәннән соң, Пугачев калдык гаскәр белән Идел елгасы буйлап Кокшайск (Йошкар-Ола) ягына кача. Майор Харин командалыгындагы карательләр фетнәчеләрне 37 чакрым буе эзәрлекләп бара, ләкин бернинди уңышка да ирешмичә, кире борылырга мәҗбүр була. 17 июльдә Пугачев Сундырь авылына (хәзерге Волжск каласы) барып җитә һәм шушы урында үз янында калган 1000 гә якын фетнәче белән Иделнең сул ягына кичә *(В. Мавродин)*. Бу вакытта инде Пугачев янында атаклы Кинҗә Арыслановтан кала бер башкорт вәкиле дә булмый («Следствие и суд на Пугачевым»// Вопросы истории.— 1966.— №4). «Падишаһ»ны Җаек казаклары, берникадәр урыс крестьяннары һәм Оренбург янындагы Каргалы бистәсенең сәүдәгәре, Пугачевның Хәрби совет әгъзасы Садыйк Сәгыйтов кул астына тупланган татарлар озатып бара.

# КӨРӘШ ДӘВАМ ИТӘ

***БӘХТИЯР КАНКАЕВ***

17 июль көнне Пугачев Татарстан территориясеннән чыгып китсә дә, Казан провинциясендә фетнә хәрәкәте тукталмый. Мамадыш — Казан арасында көрәшне Бәхтияр Канкаев аеруча уңышлы алып бара.

«Падишаһ» тарафыннан Мамадышта баш полковник дәрәҗәсе һәм атаулы фәрман алганнан соң, Бәхтияр Кама елгасы ягындагы авылларга һәм хәзерге Балык Бистәсе, Саба, Теләче, Питрәч районнары территориясенә юнәлә. Ул үзенең походын Мамадыш янындагы Ушма, Яке, Кирмән, Сөн, Уразбакты, Үсәли, Катмыш, Баскан авылларыннан башлый һәм әлеге төбәктә яшәүче крестьяннарны да отряд туплау эшенә җәлеп итә. Бәхтияр Катмыш авылы крестьяны Рахманкул Дуслиевка подполковник дәрәҗәсе бирә һәм аны граф И. Воронцовның Шомбыт авылында урнашкан аракы заводына озата. Шушындый ук бурыч заводның үз эшчесе Иван Зайцевка да җиткерелә. Рахманкул Дуслиев, заводтан 3 чуен, 1 бакыр туп алып, аерым отряд туплап кайта. Шул көннәрдә үк Рахманкул Дуслиев — полковник, ә крестьян Собханкул Ичкаев подполковник дәрәҗәсенә лаек була. Бәхтиярның бик күп кенә бүтән эмиссарлары Омар, Сикәнәс, Берсут кебек дистәләгән авылларга юнәлә, һәм алар да яңадан-яңа отрядлар белән әйләнеп кайталар. Бәхтияр Алексей Федоров, Сөбәй Аскин (Азиков), Макай (Мөхәммәтҗан?) Сәгыйтов, Муса Хәсәнов, Морат Шәрипов, Гомәр (фамилиясе билгесез) кебек йөзбашлары билгели. Алар кул астына 10 июль көнне үк инде Колышчы, Берсут, Шомырбаш, Алан, Үри, Казаклар, Иванай, Мәшләк, Шомбыт, Катмыш, Тәберде Чаллысы, Чаллыбаш, Ямаш, Күки, Кирмән, Котлы Бөкәш, Таулар, Бикчурай Чаллысы, Мордово, Уразбакты, Баскан, Урта-Түбән-Кече Сөн, Югары һәм Түбән Яке, Мирәтәк, Урманчы һәм башка авылларның һәркайсыннан дистәләгән крестьяннар туплана. 13 июльдә Бәхтиярның отряды 600 кешегә җитә («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Походный старшина Балтач Сәетов Теләче районындагы авыллардан отряд туплау өчен озатыла, һәм тиздән ул Карaширмә авылында лагерь корып урнаша. Әлбәттә, ул да турыдан-туры Бәхтиярга буйсына.

«Падишаһ»ның Мамадыш авылында булуы, шуннан соң Казанны штурмларга юнәлүе турындагы хәбәрләрне бу төбәктәге һәрбер авыл халкы олы шатлык белән каршылый. Аеруча татар крестьяннары Әби патша явызлыгыннан качкан һәм хәзер шуннан үч алырга юнәлгән «гадел падишаһ»ның үзләренә урыс изүеннән, талавыннан, көчләп чукындыруыннан азат, иркен тормыш алып килер дип өмет итә. Ирекле тормыш бирергә вәгъдә иткән мондый «падишаһ»ка татар крестьяннары чын күңелдән озын гомер тели. Шуңа күрә алар «падишаһ»ның баш полковнигы Бәхтияр Канкаевны, авыл капкасыннан чыгып, ипи-тоз белән каршылыйлар. Һәр авылда крестьяннар Бәхтияр отрядына теләп кушыла. Шунысын да ассызыклыйк: бер генә авылда да Пугачевны «падишаһ» дип танудан баш тартучы булмый, ***отряд туплаганда, Бәхтияр бер генә кешене дә җәзага тартмый!***

Күп санлы зур отряд туплаудан тыш Бәхтияр, әлбәттә, Кама, Нократ кичүләрен саклау турында да онытмый. Шул максат белән ул үзенең ярдәмчесе, походный старшина Габдулла Мостаевны Шуран кичүен (Казан — Чистай юлындагы хәзерге Саескан Тавы кичүе) сакларга озата. Керәшен татары, йөзбашы Герасим Сабаевка Чистай янындагы кичүне саклау бурычы җиткерелә, һәм бу эштә аңа Тәберде Чаллысы, Көчек, Котлы Бөкәш, Бикчурай Чаллысы, Мәмле-Казаклар Чаллысы, Сатлыган, Мордово, Чаллыбаш авылы крестьяннары 10—15 кешелек отрядлар белән ярдәм итәргә тиеш була. Сикәнәс авылы рухание, Бәхтияр тарафыннан йөзбашы итеп билгеләнгән Федот Никитинга Нократ елгасының Соколка янындагы кичүен саклау бурычы тапшырылган була. 12 июль көнне әлеге кичүгә Уфа провинциясеннән Казанга таба ашыгучы секунд-майор М. Мельгунов командасы килеп җитә. Ф. Никитин үзенең кул астындагы 50 кешелек каравыл отряды белән, әлбәттә, Мельгунов карательләренә каршы тора алмый. Мельгунов крестьяннарны куып тарата да Михельсонга ярдәмгә омтыла. Әмма ул 15 июль көнне Арча кырында узачак соңгы яуга да килеп өлгерми. Мельгунов Казанга таба киткәннән соң, фетнәчеләр отряды янә Соколка янындагы яр буена җыела. Шул ук 12 июль көнне шушы ук кичү янына килеп җиткән полковник Обернибесов, фетнәчеләрне күреп, Нократның уңъягына чыгарга батырчылык итми («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Бүтән кичүләрне саклаучы отрядлар да карательләрне хәлләреннән килгәнчә тоткарлыйлар.

Шуран кичүенә 10 июльдән соң гына озатылган Габдулла Мостаев Балык Бистәсе районы авылларыннан 14 июльгә кадәр 700—800 кешелек отряд туплап өлгерә. Каравылда торучылар тиздән аңа секунд-майор граф В. Меллин җитәкчелегендәге карательләр отрядының Кама аша кичәргә әзерләнүе турында хәбәр итәләр. Габдулла Мостаев кичү урынына ашыга һәм Меллин отряды белән яуга керә. Ләкин нигездә чалгы-сәнәк белән коралланган крестьяннар, билгеле инде, Меллинның 850 солдаттан гыйбарәт регуляр командасына каршы тора алмый *(В. Буганов)*. Яу барышында фетнәче Иван Степанов граф Меллинның бер поручигын юк итә. Ахырда Мостаев отряды чигенергә мәҗбүр була. Тиздән Мостаевка Балык Бистәсе янындагы Шиланка авылы крестьяны Гаврила Лихачев җитәкчелегендәге отряд ярдәмгә килеп җитә. Лихачев та, нәкъ Бәхтияр Канкаев кебек үк, Мамадышта Пугачев белән очраша. «Падишаһ» Лихачевка әллә есаул, әллә полковник дәрәҗәсе бирә (Лихачевның 15 июльдә һәм шуннан соң Бәхтияр Канкаевка язган рапортлары сакланган; беренче рапортларында ук ул үзен әле есаул, әле полковник дип атый, надан икәнлеге күзгә бәрелеп тора, шуңа күрә аның кайсы дәрәҗәне һәм кем тарафыннан алуын

һичничек аңлап булмый; галимнәр дә аның хакында баш ватып тормаганнар) һәм аны да Җөри, Ногай юлларына урыс авылларындагы крестьяннардан отряд туплау өчен озата. Аның сәркатибе итеп Алексей Поторочинов, ярдәмчесе итеп Н. Иванов билгеләнә. Лихачев Кама буена урнашкан урыс авылларында отряд туплый һәм Мостаевка килеп кушыла. Әмма берләштерелгән отрядлар да Меллин карательләренә каршы тора алмый. Шулай да алар Меллин командасын юлда тоткарлауга ирешә. Подполковник Михельсон һәм генерал П. Потемкин тарафыннан Казанга ашыгырга боерган аерым-аерым фәрманнар килеп төшсә дә, Меллинның вакыты Мостаев һәм Лихачев отрядлары белән бәрелештә үтә. 15 июльдә Михельсон Меллинның ярдәменә өмет итсә дә, ул акланмый. Меллин отряды Казанга 16 июль көнне генә килеп җитә *(Н. Дубровин)*. Габдулла Мостаев исә үзенең калдык отряды белән әүвәл Мирәтәк авылында тукталыш ясый, ә 18 июльдә Саурыш (Сауш) авылында Бәхтияр Канкаев янына кайтып кушыла. 15 июльдән башлап Гаврила Лихачев та турыдан-туры Бәхтиярга буйсына, ләкин Бәхтияр янына ул 19 июльдә генә килеп җитә.

Безгә калса, Бәхтиярның үз хәле дә бу көннәрдә әллә ни җиңелдән булмагандыр. 13 һәм 14 июнь көннәрендә аңа берничә чапкын каршылыклы хәбәрләр китерә. 13 июльдә Бәхтиярга подполковник Михельсонның һәм аның карательләренә кушылган Солтанморат Янышев кул астындагы хыянәтче мишәрләр командасының, Нократ аша чыгып, Казанга юнәлүе турында хәбәр итәләр. Өстәвенә, чапкыннар Михельсон һәм Янышев отрядларындагы көчне 6 туп белән коралланган 2000 кеше дип күпертеп күрсәтә. 14 июль көнне исә Бәхтияр инде майор Мельгунов командасының Соколка янында Нократ аша кичүе турындагы хәбәрне ала. Шул ук көнне «князь Щербатов Шуран янында Каманы кичеп чыкты» дигән ялган хәбәр китерәләр (чынында исә сүз граф Меллин отряды турында барырга тиеш була). Һәм шушы ук көнне ул Пугачевның Казанны яндыруын ишетә. Өстәвенә бер җайдакның, Екатерина указларын тотып, авылдан авылга «падишаһ»ның падишаһ түгел, бәлки Пугачев атлы карак икәнлеген хәбәр итеп йөрүе турында да белеп ала. Әлбәттә, бу вакытта Бәхтияр инде үзе дә «падишаһ»ның чынлыкта кем булуын төгәл чамалый. Әмма җәза командалары турындагы ялган һәм күпертелгән хәбәрләр аны да хафага сала. Шушы көнне ул, үз янына 100 кешелек отряд һәм туплар җибәрүен таләп итеп, Габдулла Мостаевка фәрман юллый. Бәхтияр һаман җиңүдән өметен өзми. Шуңа күрә ул Пугачевка хәленнән килгәнчә ярдәм итәргә тырыша. Михельсон, Мельгунов, «Щербатов» командалары турында кисәтеп, ул 13 е һәм 14 е көнне ашыгыч рәвештә Казанга чапкыннар озата.

Ә бик тиздән Бәхтиярга инде тагын да өметсезрәк хәбәрләр килеп ишетелә. 15—17 июльләрдә ул Шәдке, Янсуар аша үтә һәм Саурыш авылына килеп, Апакай Ишмәтов йортында вакытлыча штаб корып урнаша. Үзе үткән һәр авылда отрядына сугышчылар туплый, ераграк төбәкләргә озатылган махсус эмиссарлар да аерым командалар алып кайта. 17 июль тирәсендә исә Саурышка Казан янындагы яулардан соң карательләр кулыннан качып котылган фетнәчеләр дә кайтып җитә. Балтач (Юлбусино) крестьяны Атнагол Курманаев, Арыш вәкилләре Якуб Әрмәтов, Мостафа Юлдашев, Тенисовка (Тегермәнлек булырга тиеш) авылыннан Юзәй Сәламов һәм билгесез авылдан Биккенә атлы крестьян карательләр җәзасыннан котылып кайта һәм, һичшиксез, Казан янында булган яулар турында дөресен сөйләп бирә. Карательләр кулыннан качып котылган крестьяннар саны алдагы көннәрдә арта гына бара. Шундый 13 фетнәче Карашырмә авылында торучы походный старшина Балтач Сәетов кулына эләгә. Әлеге качаклар арасында бер мари крестьяны Балтач Сәетовка «падишаһ»ның Казан янында тулысынча тар-мар ителүе һәм гаскәрен ташлап качуы турында сөйли. «Падишаһ»ның кая качуын ачыклау өчен, Сәетов яраннары мари крестьянын кыйнап та карыйлар, ләкин әлеге бичара, билгеле инде, аларга Пугачев турында яңа мәгълүматлар бирә алмый. Ул фәкать Казан яныннан тагын Ягъфәр исемле полковникның исән-имин качып котылуы һәм аның бер юлдашы белән бергә Күкчә авылына (Теләче районында) кайтып китүе турындагы хәбәрне генә өсти ала. Балтач Сәетов әлеге Ягъфәр артыннан 12 кешелек команда юллап карый, ләкин аны таба алмый. Ә үз кулына эләккән 13 качакны ул Тәмте авылы (Теләче районында) йөзбашы Сәгыйтов сагы астында Бәхтияр Канкаев янына озата. *(Без Балтач Сәетов исеме белән бәйле әлеге вакыйганы «Воззвания и переписка...» китабының 99 нчы (№99) документына нигезләнеп бәян иттек. Китапны төзүче М. Госманов, С. Алишев, И. Гыйләҗев, Ф. Хисамова кебек галимнәр әлеге документны 1774 елның апрель ае белән тамгалап хата җибәргәннәр. Галимнәр документта сөйләнгән вакыйганы Пугачевның 2 апрельдә Сакмар буенда тар-мар ителүе белән бәйли. Галимнәрнең ялгышуын бик җиңел исбат итә алабыз. 1. Апрельдә Бәхтияр Канкаев походный старшина була һәм фәкать 29 ыннан соң гына полковник дәрәҗәсен йөртә башлый. 2 һәм 29 апрельләр арасында да, Сакмар, Көнгер, Теләче арасында да аерма зур. 2. Бәхтияр апрельдә Уфа өязенең Уса һәм Себер юлларында хәрәкәт итә. Ә 99 нчы документта Тәмте, Күкчә дигән авыллар аерымачык телгә алына. Башкортстанда мондый авыллар юк, алар бездәге Теләче районында. 3. Апрель аенда Балтач Сәетов Бөре өязендә хәрәкәт итә. Бәхтияр белән алар 1 июнь тирәсендә генә очрашалар... Хаклы булуыбызны исбатлау өчен, без яңа дәлилләр дә китерә*

*алыр идек, ләкин санаган кадәресе дә җитеп торыр. Бер уңайдан шунысын да өстик: «Воззвания...» (Әлеге хезмәт атамасы алда шушы рәвешле кыскартып бирелгәгк) китабын төзүчеләр байтак документларны ялгыш даталар белән билгеләгәннәр. Әйтик, 10 май вакыйгалары турында сүз барган 100 нче документны «4 майга кадәр язылган» дип билгеләү берәр төрле мантыйкка сыямы соң? Гомумән, без әлеге китаптагы 15, 23, 24, 26, 99, 100, 101, 148, 160 нчы һәм тагын берничә документларны билгеләүче даталарга ризасызлык белдерәбез.)*

Бәхтияр Канкаев исә Балтач Сәетов юллаган качаклар аңлатмасына инде мохтаҗ булмый. Чөнки дистәләгән авылларга куелган каравыл пикетлары болай да аның янына качакларны күпләп тотып китерә. Аларның бик күбесе Казан янындагы яуларда яраланган яки карательләр тарафыннан кыйналган була. Әлбәттә, Бәхтияр аларны үз отрядына көчләп куша алмый һәм байтагын, махсус билетлар язып, туган авылларына озата. Ә мондый качаклар һаман шул ук Балтач Сәетов карамагына да китерелә. Балтач шундый качакларның берьюлы 26 сын, Караширмә авылында тотып, Имәнкул Шәрипов атлы йөзбашы сагы астында янә Бәхтияр янына җибәрә. Дөрес, Казан яныннан кайтучы качаклар арасында Бәхтияр һәм Балтач отрядларына кушылучы крестьяннар да була. Бүләк, Олы Әлмәт, Сикия авылларының (Мөслим районында) крестьяннары Тимеркәй Кадерголов, Мөстәкыйм Әлимбәтов, Имәнкул Биҗанов (Баһауҗанов?), мәсәлән, «Ходайга рәхмәт укый-укый», Балтач Сәетов отрядына язылалар («Воззвания...»).

Ләкин «падишаһ»ның Казан янында тар-мар ителүе турындагы хәбәрләр Бәхтияр Канкаев отряды өчен яңа кыенлыклар һәм яңа хәвеф тудыра. 18 июль төнендә Егор Иванов йөзлегендәге 3 урыс крестьяны фетнәчеләр сафын ташлап кача («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Ул да булмый, кайбер отрядларда башбаштаклык башлана. Походный старшина Баязит Килмәтов, мәсәлән, каядыр киткән чакта үзе урынына отряд башлыгы итеп Алакай дигән кешене калдыра. Ә «сәнәктән көрәк булган» Алакай йөзбашы дәрәҗәсен йөртүче Сөярмәт Котышевны кыйнап ташлый («Воззвания...»). Шул ук вакытта Бәхтиярга Казан тирәсендәге җәза отрядларының Җөри, Ногай, Арча юлы буйлап фетнәчеләргә каршы чыгуы турындагы хәбәрләр дә килеп җитә. Ул да булмый, Уфа ягыннан килгән майор Мельгунов командалыгындагы карательләр, Кама аша чыгып, Казан провинциясенә керәләр. Июль уртасында Бәхтияр алар белән берничә тапкыр бәрелешә һәм карательләрне Нократка таба чигенергә мәҗбүр итә.

Сүз дә юк, Бәхтияр кул астына тупланган дистәләгән отрядлар өчен дә, юлбашчының шәхсән үзе өчен дә кискен хәл туа. Әмма менә шундый каршылыклы, авыр хәлдә дә Бәхтияр Канкаевның рухы сынмый һәм җиңүгә, азатлыкка өмете сүнми. Хәтта шушы кискен хәл аны тагын да үҗәтләндерә.

Ул байтак отрядларны үз янына чакыртып ала. 18 июльдә аның янына Габдулла Мостаев кайтып җитә. Гаврила Лихачев отряды да Шуран кичүе янындагы бәрелештән соң, Олы Елга, Неелово, Югары Мәтәскә авыллары аша үтеп, 19 июльдә Бәхтияр янына килә. Шушы көнне Бәхтияр үз штабын Караширмә авылына күчерә, шунда Балтач Сәетов отряды белән кушыла. Хәзер инде Бәхтияр кул астына тупланган фетнәчеләр саны 2000 нән артып китә. Моннан тыш әле дистәләгән авылларда 10—20 кешелек каравыл пикетлары тора, 50—100 кешелек командалар Кама елгасы аша кичү урыннарын саклый.

Бәхтияр үзенә яңа ярдәмчеләр билгели. Гаврила Лихачев белән Рахманкул Дуслиевтан тыш, Бәхтияр мулла Халит Әминевка да полковник дәрәҗәсен бирә һәм аны Арча юлындагы авыллардан яңа отрядлар туплау өчен озата. Халит мулла шушы көннәрдә карательләр белән бәрелешә, яуда яралана һәм шул килеш тә сугышчылар туплавын, аларны Бәхтияр янына озатуын дәвам итә. 18 июльдә Бәхтияр Сөбәй Азиков (Аскин) атлы крестьянны да подполковник итеп билгели («Воззвания...»; «Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Пугачевны табу, аның белән элемтә урнаштыру максатыннан, Бәхтияр янә 19, 21, 22 июльләрдә Хәрби коллегия исеменә рапортлар яза һәм Казан тарафына чапкыннар юллый. Шундый ук бурыч Байлар Сабасы авылыннан Габделваһап Мөхсиновка да җиткерелә. Ләкин нәкъ алдагылары шикелле үк бу чапкыннар да эзсез югала. Ул арада Бәхтияр отряды хәрәкәт иткән төбәкне һәрьяклап җәза командалары урап ала башлый. Губернатор Брандт белән генерал Потемкин бирегә подполковник Неклюдов, капитан Гиршфельд командаларын юллыйлар. Тәберде Чаллысы авылында 2000 кешелек җәза отряды пәйда була. Бәхтияр үз кул астындагы гаскәрне хәзер кабат берничә отрядка бүләргә карар кыла, һәркайсына аерым-аерым фәрманнар биреп, ул аларны төрле якка озата. Гаврила Лихачев отряды Мирәтәк, Керәшен Казысы авыллары аша үтә һәм Балык Бистәсе тирәсендә хәрәкәт иткән карательләр командасына каршы бара («Документы ставки...»). Кама буена җиткәч, лихачевчылар елга аръягында хәрәкәт итүче Каранай Моратов, Канзафар Усаев, Качкын Самаров, Галибай Морзаголов отрядлары белән бәйләнешкә керергә тиеш була. Бәхтияр, Кама буенда хәрәкәт иткән барча отрядларны берләштереп, янә Казанга һөҗүм итәргә исәпли. Каманың сулъягында көрәшүче отряд командирларын уңъяк ярга чыгарга чакырып язган хатларны алып, чапкыннар елга аша кичә. Уфа провинциясендә көрәшүче отряд башлыкларына юлланган мондый хатларның берсен Байлар Сабасы авылы крестьяны А. Мәгъсүмов алып бара. Ә Яңа Ил авылы крестьяны

Гази Дәүләтов Казан өязенең Ногай юлы буйлап разведкага җибәрелә. Полковник дәрәҗәсен алган Габдулла Мостаев Казан юлын җәза отрядларыннан сакларга һәм үз кул астына яңа көчләр тупларга тиеш була.

Габдулла Мостаев үз эшчәнлеген бу юлы да гаять актив башлый. Ул тиз арада 90 кешелек беренче отрядны, туплап, Бәхтияр янына юллый. Аннан соң 110 кешелек икенче отрядны да төп гаскәргә җибәрә. Габдуллага бу эштә Бәхтияр тарафыннан нәкъ шундый ук фәрман алган, әмма инде карательләр белән булган яуда яраланырга өлгергән Әдһәм исемле йөзбашы ярдәм итә. Яраланган Хәмит мулла да, Әдһәм шикелле, Габдуллага хәленнән килгәнчә ярдәм күрсәтә. Балык Бистәсе районындагы Иске Арыш, Укмас, Яншык авыллары да Габдулла Мостаев туплаган яңа отряд өчен һәр ике йорттан бер сугышчы бирә. Бәхтияр Канкаев кул астына тупланган төп гаскәрдәге фетнәчеләр саны 22—23 июль көнне 3000 гә, туплар саны 7 гә җитә («Воззвания...»).

Казаннан фетнәчеләргә каршы озатылган подполковник С. Неклюдов җитәкчелегендәге күп санлы җәза командасы 22 июль көнне Балык Бистәсендә тора. Шул көнне Неклюдов 200 кешелек бер отрядын разведка ясау өчен Карашырмә төбәгенә юллый. Ләкин разведка отряды, Керәшен Казысы авылына килеп җитүгә үк, Лихачев җитәкчелегендә фетнәчеләрне күреп ала һәм, яуга да кереп тормыйча, кире Балык Бистәсенә борылып кайта. Лихачев үзенең карательләр белән очрашуы хакында хәбәр иткәч, Бәхтияр есаул Егор Иванов җитәкчелегендәге йөзлекне аңа ярдәмгә озата.

Балык Бистәсеннән озатылган разведка отрядының «хисапсыз фетнәчеләр өере» турында хәбәр алып кайтуы подполковник Неклюдовны да хафага сала. 23—24 июльләрдә ул якын-тирәдәге авыллардан үзенә ярдәмгә 250 кешелек отряд туплый.

24 июльдә Лихачев Байтирәк авылына барып җитә. Ул отрядының бер өлешен Кама буена, елга аръягына чыгу һәм андагы фетнәчеләр белән бәйләнешкә керү өчен озата. Ә үзе 400 крестьян һәм 2 туп алып Балык Бистәсенә юнәлә. Юлда ул Неклюдов туплаган хыянәтчеләр отряды белән бәрелешә, 11 кешене әсирлеккә ала.

Ләкин 25 июль көнне подполковник Неклюдов, үз кул астында булган барча көчне туплап, фетнәчеләргә каршы юнәлә. Төш вакытында ул Байтирәк авылына килеп җитә һәм аяусыз яудан соң Лихачев отрядын тулысынча тар-мар итә. Лихачев үзенең отрядындагы йөзбашы, Балык Бистәсе авылы крестьяны Никифор Чванин һәм тагын 3 иптәше белән бергә Нократ елгасына таба качып котыла («Документы ставки...»). Байтирәк авылындагы яу барышында Лихачев отрядының сәркатибе Алексей Поторочинов карательләр кулына эләгә. Златоуст заводларында эшләгән чакта фетнәчеләр сафына кушылган 50 яшьлек аксакалны җәлладлар кызганып тормый. Соңыннан Казанда аның «падишаһ» исеменнән фәрманнар язган кулын чабып өзәләр. Аннары Владимир шәһәренә илтеп дарга асалар *(Ю. Лимонов)*. Ә Шиланка авылы крестьяны Гаврила Лихачев үзе 9 август көнне Большой Кильмез авылы янындагы яуда һәлак була («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Июль ахырында Бәхтияр Канкаев гаскәре өчен дә санаулы гына көннәр кала. Казан тарафына разведкага юлланган отряд командиры Юзкәй Биккенин туплар белән коралланган 200 кешелек ике команданың Арча һәм Җөри юллары буйлап Бәхтиярга каршы юнәлүен хәбәр итә (әлеге командаларның берсен капитан Гиршфельд җитәкли). Балык Бистәсе ягыннан Бәхтиярны Неклюдов командасы кысрыклап килә. Нократ аръягында полковник Обернибесов отряды сакта тора. Тәберде Чаллысы авылындагы җәза отряды Кама аша кичү юлын бикли. Һәрьяклап кысылган тимер боҗра эчендә калу фетнәчеләр арасында паника тудыра. 26 июль төнендә Дегетле, Покровское, Омар, Колышчы авылының Григорьев, Селехев, Никитин, Семенов, Апашев кебек унбашлары Бәхтияр отрядын ташлап кача («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Шушындый кискен һәм авыр хәл туура да карамастан, Бәхтияр Канкаев үз карамагындагы бөтен көчне Җөри авылы янына туплый. 27 июль көнне Бәхтияр отряды белән подполковник С. Неклюдов кул астына тупланган җәза командалары арасында аяусыз, канкойгыч бәрелеш башлана. Бер як та тулысынча җиңүгә ирешә алмый. Фетнәчеләр, кечкенә отрядларга бүленеп, төрле якка тарала. Бәхтияр Канкаев үз янында калган 400 кешелек отряды белән Келәүш авылы (Мамадыш районында) кырындагы урманга чигенә. Ләкин биредә ул тагын Минзәлә ягыннан килүче карательләрнең яңа отряды белән очраша. Яу барышында Бәхтияр отряды тулысынча тар-мар ителә. Полковник Рахманкул Дуслиев, сәркатип Әбүбәкер Теләчев җәлладлар кулына эләгә. Ә Бәхтияр үзе бер туп һәм берничә иптәше белән качып котыла. Шуннан соң бер ел дәвамында патшабикә администрациясе ничек кенә эзләмәсен, Пугачевның каһарман бригадиры Канкай углы Бәхтияр табылмый. Халык күңелендә бердәнбер истәлек булып, аның турындагы җыр гына кала:

Бәхтияр егет ир, имеш,
«Буем бирмәм», — дигән, имеш.
Армияләре таралгач,

«Ходаем орды», — дигән, имеш...

*Кем белә, җырдагы юллар, бәлки, бик күпләрнең колагына ятышсызрак булып яңгырыйдыр. Чөнки татар арасындагы обыватель (мәнсез җан) бүген: «Беренче хатын — Миләүшә, икенчесе — Эр-рәйсә, өченчесен дә алырбыз, Эр-рәйсә кәкерәйсә», — дип, яки бәрәңге чәчәге турында акыручы бушбугазларны күреп мөкиббән китә, шундыйларга алкышлар гына түгел, хәтта автомашиналар да бүләк итә. Шул ук обыватель бүген театрга барып, милли каһарман түгел, бәлки мокыт юлбасар итеп тасвирланган Бәхтияр маҗаралары белән күңелен ачып кайта. Шуңа күрә Пугачев армиясендә бер үк дәрәҗәгә ирешкән каһарманнар арасыннан Салават Юлаев исемен бөтен җиһан белә, ә татар дөньясында Бәхтияр Канкаев, Ярмөхәммәт Кадермәтов, Канзафар Усаев, шулай ук бертуган Үрәзмәтовлар, Мәсәгуть Гомәров, Рахманкул Дуслиев... исемнәрен йөрткән тыкрык та юк. Без күрше, кардәш милләт тырышлыгына, хәтеренә сокланырга мәҗбүр. Тарихына гамьсез татарга Ходайның җәзасы шулдыр. Нәкъ атаклы шагыйрь әйткәнчә: «Син үткәнеңә пистолет төбисең икән, киләчәк сиңа туптан атып җавап бирәчәк».*

Бәхтияр көрәштәшләренең язмышын ачыклап үтик. 61 яшьлек Рахманкул Дуслиевны соңыннан җәлладлар туган авылына алып кайтып дарга асалар. Ә «падишаһ» исеменнән указлар язган өчен Казанда Әбүбәкер Теләчевның әүвәл кулын, аннары башын чабып өзәләр («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Балтач Сәетов, Халит Әминев, Габдулла Мостаев турында тарихи документлар табылмаган. Бәлки, бу өч каһарман Бәхтияр Канкаев белән бергә качкандыр.

## *КАРАТЕЛЬЛӘР БОҖРАСЫНДА*

Патшабикә Екатерина хөкүмәте, фетнәне Рәсәйнең башка төбәкләренә таратмау, Пугачевның Мәскәүгә таба юлын бикләү һәм, гомумән, «караклар» чуалышын бастыру максатыннан, Казан белән Оренбург губерналарын һәрьяктан җәза полклары белән урап ала. Июль ахырында шушы ике губернага тупланган карательләр көчен тагын да төгәлрәк санап чыгыйк:

— 7 гарнизон полкы (исемнәре — Владимир, Томск, Нарва, Великолуцк (Великие Луки), Воронеж, Ладога, 2 нче гренадер);

— төрек фронтыннан сугыштан кайтарылган 7 регуляр полк (Петербург, Архангельск, Лейб-кирасир, Смоленск, Чугуй, Изюм, Новгород);

— 9 хәрби-кыр командасы;

— 18 гарнизон батальоны;

— 3 рота җәяүле гаскәр (пехота);

— 11 эскадрон регуляр кавалерия;

— Дон казакларыннан төзелгән 4 полк;

— 1000 украин казагы;

— Казан дворяннары корпусы;

— Пенза дворяннары корпусы;

— Себер губернасының генерал-поручик Деколонг кул астына тупланган хәрби отрядлары *(Н. Дубровин).*

Болардан тыш тагын хыянәтче башкорт, татар, казах старшиналары һәм бәкләре, урыс алпавытлары һәм руханилары тарафыннан оештырылган дистәләгән отрядларның булуын онытмыйк. Сугыш фәненә өйрәтелмәгән, оешмаган һәм коралсыз крестьяннарга каршы тупланган коточкыч зур армия!

Ләкин шушы кадәр көч тә «падишаһ» чакыруы буенча кузгалган крестьяннар көрәшен туктата алмый. 1774 елның июлендә Пугачев явы иң югары ноктасына җитә. Пугачев гаскәре Казан каласын ала, ә губерна үзе, аеруча аның үзәк провинциясе, дөрләп янган учакны хәтерләтә. Пугачевның Казан провинциясенә керүе турындагы хәбәрне алуга ук, җәза отрядлары һәрьяклап шушы төбәккә агыла.

4 июль көнне, ниһаять, Оренбург каласын калдырырга җөрьәт иткән башкомандующий генерал-поручик Ф. Щербатов 11 ендә Бөгелмәгә кайтып җитә (ул әле үзенең башкомандующийлыктан читләштерелүе турындагы указны алып өлгермәгән) һәм биредә хәрәкәтсез торучы полковник Н. Кожин полкы белән кушыла. 12 июльдә Уфага барып җиткән генерал Голицын, Пугачевның Мамадышка керүе турындагы хәбәрне алгач, 14 е көнне янә юлга чыгарга мәҗбүр була һәм 19 ында инде Зәй каласына килә. 12 июль тирәсендә, Нократ аша чыгып, провинциягә майор Мельгунов карательләре бәреп керә. Подполковник Муфель командасы 16 июльдә Бозаулык крепостен калдыра һәм тиздән Чирмешән крепостена күченә. Шушы ук крепостьта генерал Миллер командасы тора. Полковник Обернибесов Нократның Камага кушылган җирендә урнаша һәм ике елга аша булган кичүләрне үз кулына ала. Биләр,

Кичү, Ерыклы, Чишмә крепостьларында хәрби гарнизоннар тора. Ә Казанның үзендә без инде югарыда телгә алып өлгергән губернатор Брандт, генерал П. Потемкин, подполковник Михельсон, секунд-майор граф Меллин, подполковник С. Неклюдов, майор Черносвитов, капитаннар Я. Михальчуков, Гиршфельд, Череватов, хыянәтче С. Янышев һәм башка карательләр кул астындагы җәза командалары туплана. 19 июльдә Михельсон, Казанны калдырып, Пугачев артыннан куа чыга. Ә Неклюдов, Михальчуков, Гиршфельд, Черносвитов, Череватов һәм башка офицерлар кул астындагы хәрби командалар провинциянең төрле төбәгендә хәрәкәт итүче фетнә отрядларына каршы юнәлә. 22 июль көнне Казанга генерал Щербатов та кайтып җитә («Воззвания...»; *С. Алишев; Н. Дубровин*).

Казанның Пугачев тарафыннан алынуы турындагы хәбәр Петербургка 21 июльдә барып ирешә һәм, әлбәттә, ул башка- лада коточкыч паника уята. «Надан карак»ны тар-мар итү өчен озатылган хәрби генералларның булдыксызлыгы Екатеринаны шулкадәр ярсыта ки, шул ук көнне Дәүләт Советы җыеп, патшабикә шәхсән үзе фетнәчеләргә каршы юнәлергә теләк белдерә! Н. Панин, А. Голицын, З. Чернышев, А. Вяземский, Г. Орлов, К. Разумовский кебек генераллар патшабикәне әлеге уеннан көч-хәл белән генә кире кайтаралар. Патшабикә даирәсен Пугачевның Казаннан соң Мәскәүгә юнәлү мөмкинлеге аеруча нык куркыта. Хәрби коллегия 8 июль көнне Мәскәүгә инде болай да 3 полк өстәмә гаскәр озаткан булуга карамастан, 22 июльдә яңа фәрман игълан ителә. Шул ук көнне Петербург белән Новгородтан тагын 4 полк Мәскәүгә озатыла. Дәүләт Советы карары буенча Мәскәү дворяннары, нәкъ Казанныкылар шикелле үк, үз корпусларын да төзергә тиеш була. Җәза гаскәрләрендә тупланган көчне Екатерина хәтта үзе дә: «Каракларга каршы озатылган мондый армия белән күрше илләрне дә куркытып булыр иде», — дип таный.

Әлбәттә, Екатерина әле 8 июль көнне генә башкомандующий итеп билгеләнгән генерал-майор П. Голицыннан канәгать булмый (ә бичара Голицын ул фәрманны июль ахырында гына алып өлгерә һәм фәкать 1 августта гына башкомандующий вазифаларын үти башлый). Ул Голицын урынына моңа кадәр яуларда танылган хәрби генерал кандидатурасын эзләргә боера. Никита Панин отышлы моментны кулыннан ычкындырмый. Канцлер, 21 һәм 22 июльләрдә кат-кат кереп, патшабикәдән үзенең туганы генерал-аншеф Петр Панинны башкомандующий итеп билгеләвен ялвара. Гәрчә Петр Панин заманында ямьсез сүзләр әйтеп Екатеринаны нык рәнҗеткән булса да, фетнәгә урыс крестьяннарының да күпләп кушылуы һәм Пугачевның Мәскәүгә юнәлү куркынычы патшабикәне канцлер тәкъдиме белән ризалашырга мәҗбүр итә.

Екатерина бер тәүлеккә ашыга. 23 июль көнне Петербург Рәсәй — Кырым сугышының тәмамлануы (вакытлыча) һәм солых төзелү турында фельдмаршал А. Румянцев рапортын ала (әгәр Румянцев рапорты 22 сендә килеп өлгерсә, ай-һай, Петр Панин башкомандующий була алыр идеме икән?). Екатерина Кырым фронтына сугышкан өч хәрби генералны — Казан, Нижний Новгород, Мәскәү дивизияләренең командирларын — ашыгыч рәвештә Пугачевка каршы озатырга боера. Әмма куштаннары Екатеринаны Европа каршында көлкегә калмаска үгетлиләр. Нәтиҗәдә генерал А. Суворовка гына фетнәчеләргә каршы юнәлергә әмер бирелә. Тарихка даһи полководец буларак кереп калган, каратель булуы гел-гел яшерелгән Суворов, артына ут капкандай хәрәкәтләнеп, 24 августта башкомандующий Панин янына килеп җитә *(Н. Дубровин)*. Дөрес, ул көнгә кадәр әле шактый вакыт бар. Ә татар халкы яшәгән төбәкләрдә фетнә һаман да тынмый. Татар һаман үзенең азатлыгы өчен көрәшә.

### *КАЗАН ПРОВИНЦИЯСЕ*

Пугачев Казанга юнәлгән чакта провинциядәге күпчелек татар авылларындагы крестьяннар аның гаскәренә кушылса да, байтак төбәкләрдә мөстәкыйль фетнә отрядлары хәрәкәт итә. Алар аеруча христиан руханиларына, урысларның колонизатор алпавытларына, шулай ук карательләр ягына чыккан татар хыянәтчеләренә каршы көрәшәләр. Вознесенское, Сүнчәли авыллары (Аксубай районында) янында хәрәкәт итүче отряд 18 июль тирәсендә Сабанчей исемле руханины дарга аса. Черемыш, Шихазда, Казыли, Олы һәм Кече Елан, Венета, Карабаян, Страховка һәм башка авыллар (Питрәч, Биектау, Арча, Теләче районнарында) янында Туктаргалин, Макаров, Алексеев кул астына тупланган фетнәчеләр дә үз төбәкләрендәге дистәләгән руханиларны һәм урыс алпавытларын юк итә, утарларын талый. Карп Карасев әмере буенча чыбыркы белән суктырылган Мурзиха авылы приказчигы Михайловны (Михаил Гаврилов булырга тиеш) соңыннан татар крестьяннары асып үтерә. Икенче бер отряд 15 июль көнне Кышкар авылында (Арча районы) сәүдәгәр Сәгыйт Усманов утарын талый. Яр Чаллы авылы крестьяннары бертуган Казый һәм Мокай (Мөхәммәтҗан?) Мортазиннар, Рахманкул Кучаев, Исмәгыйль Биккулов, Бикташ Биккенин, Сәгыйт Кәлимов, Тәрҗемәнов Казаннан килеп төшкән Кәрим Яковлев исемле сәүдәгәрне, аның олауларын кулга төшерәләр һәм Федотово авылына алып китәләр. Биредә аларны 300 кешелек фетнә отряды каршы ала.

Яковлевны кылыч белән тураклап ташлыйлар, олаулардагы байлыкны үзара бүлешәләр. Алат юлында татар сәүдәгәрләренең 7090 сумлык байлыгы талап алына. Минзәлә өязендәге Әхмәт (Аметьево) авылында крестьяннарны изеп тоткан сәүдәгәр утары талана. Керәшен татары Герасим Федотов кул астына тупланган крестьяннар Камай авылында (Биектау районы) Казан сәүдәгәрләре Михаил һәм Александр Тарасовларның 2434 сумлык товарын тартып ала. 13 июль көнне Кузнечиха авылында (Спас районы) фетнәчеләр алпавыт утарын юк итәләр. Июль ае дәвамында провинциянең һәммә төбәгендә әнә шул рәвешчә фетнә уты дөрли. Яу барышында татар крестьяннары провинциядәге 237 христиан руханиен юк итә (исемлек тулы түгел), 14 монастырь һәм 63 чиркәү талана *(С. Алишев)*.

Әлбәттә, крестьян чыгышлары стихияле рәвештә генә бармый. Провинциядә оешкан төстә, куркусыз хәрәкәт итүче отрядлар да күп була. Андыйларга каршы Казан администрациясе июль ахырында регуляр отрядлар юллый. Капитан Череватов Югары Ослан авылы янындагы фетнәчеләрне тар-мар итә. Майор Черносвитов командасы Шуран кичүен саклаучы фетнәчеләргә каршы озатыла. Лаеш һәм Балык бистәсе артындагы фетнә отрядларын куып тараткач, Черносвитов Каманың сулъягына чыга. Хәзерге Әлки районы төбәгендә инде болай да капитан Суворов командалыгындагы карательләр фетнәче крестьяннарны куып йөри. Суворов Юхмачы авылы крестьяннарын «тынычландырып» китә. Әмма ул китүгә Юхмачыда янә «караклар» командасы туплана. Август аенда шушы ук авылга Черносвитов карательләре килеп җитә һәм «каракларны авылга керткән өчен» крестьяннарны чыбыркылар белән җәзалый.

Бәхтияр Канкаев отряды тар-мар ителгәннән соң, ниһаять, Казаннан Мамадышка таба капитан Яков Михальчуков командасы хәрәкәт итә башлый. Әмма Бәхтияр гаскәреннән таркалып исән калган кечкенә отрядлар аңа туктаусыз һөҗүм итеп тора. Михальчуков нибары 17 август көнне генә Мамадыш янына килеп җитә. Фетнәчеләр аны авыл читенә чыгып каршы алалар, ләкин туп залплары астында янә Мамадыш эченә чигенергә мәҗбүр булалар. Туп ядрәләре тиюдән Мамадышта олы янгын куба. Фетнәчеләр авылны ташлап китәргә мәҗбүр була *(С. Алишев)*.

Июль — август айларында Каманың сул ягында Усман Тимеров отряды аеруча актив көрәшә. Әлеге отряд Әлки, Биләр, Чирмешән, Аксубай, Норлат төбәкләрендә хәрәкәт итә, шушы тирәдәге дистәләгән авыллардагы колонизатор һәм хыянәтче алпавытларның утарларын талый, җәзачыларның кечкенә отрядларына каршы тора. Кичү, Чирмешән тирәләрендә үк Герасим Иванов җитәкчелегендәге икенче бер отряд та карательләргә каршы сугышып йөри. Ләкин Мәләкәс аракы заводына таба барган чакта, аны җәзачылар командасы тар-мар итә. Г. Иванов отрядының калдыклары Усман Тимеровка килеп кушыла. Яңа Ибрай авылы янында Усман отряды Кичү крепостеннан чыккан җәзачылар белән бәрелешә һәм аны тар-мар итә. Кама аръягындагы крепостьларда торучы гарнизоннарның башлыгы генерал-майор Миллер хәзер инде У. Тимеров крестьяннарына каршы майор Астафьев кул астындагы көчәйтелгән команданы юлларга мәҗбүр була. Бу турыда белеп алгач, Усман Тимеров Чирмешән елгасы артына чигенә, Тукмак авылы (Лениногорск районында) янындагы урманда лагерь корып урнаша. Тимеровка Макар Николаев, Матвей Безродный, Габдерәшит Ибраев кебек йөзбашлары ярдәм итә. Ләкин фетнәчеләр лагере турындагы хәбәр, билгеле инде, Екатерина колларына да барып ишетелә. Генерал П. Потемкин 20 августта Миллерга ярдәмгә Казаннан секунд-майор Самарцев һәм капитан Суворов җитәкчелегендәге җәза командалары җибәрә. Ә генерал Миллер Астафьев артыннан сентябрь башында майор Елкин командалыгындагы тагын бер отряд юллый. Җәзачыларның берләштерелгән гаскәре 6 сентябрь көнне Усман Тимеров лагерен чолгап ала. Канкойгыч яудан соң крестьяннар тар-мар ителә. Усман үзе һәм бик күп фетнәчеләр әсирлеккә эләгә. Усман Казандагы Яшерен комиссия карамагына озатыла һәм, генерал П. Потемкин җәлладларының җәзалауларына түзмичә, әле хөкем карары чыгарылганчы ук, зинданда вафат була *(С. Алишев)*.

Шуннан соң инде җәза гаскәрләре белән шыплап тутырылган провинциядә фетнәче крестьяннарга актив рәвештә көрәшү мөмкин булмый. Ләкин карательләрнең туктаусыз эзәрлекләвеннән котылып тын алырга бераз гына мөмкинлек туугa, крестьяннар янә кечкенә отрядларга берләшәләр. Кама буендагы авылларның Рождественск, Ижевск заводларына беркетелгән крестьяннары 1774 елның декабрендә, ә Урал заводларына йөреп газап чигүче крестьяннар хәтта 1775 елның җәендә дә кабат-кабат фетнәгә күтәреләләр. Әлеге чыгышларның һәркайсы дәһшәтле Пугачев явының дәвамы була, әмма алар да көчәйтелгән хәрби командалар тарафыннан бастырыла.

### *КАНЗАФАР УСАЕВ*

Урыс хөкүмәтенә, колонизаторларга һәм хыянәтчеләргә каршы Уфа провинциясендә яу алып баручы татар каһарманнары белән 1774 елның июнь ахырында аерылышкан идек. Янә аларның милли-азатлык көрәшен яктыртуга кайтыйк.

Канзафар Усаев белән Салават Юлаев, 23 июнь көнне Рождественск заводы каршында, Кама аша кичү урынында, падишаһ кулыннан атаулы указ алганнан соң, үзләренең туган төбәкләренә кайтып китәләр. Пугачев тарафыннан аларга «һәртөрле ясакларсыз ирекле тормыш вәгъдә итеп гаскәр туплау, Уфа каласын алу һәм җәза отрядларына каршы көрәшү» бурычы җиткерелгән була.

Уфа өязенең Ногай юлына Канзафар 26 июньдә кайтып җитә һәм, бер минут та көтеп тормыйча, шушы ук көнне ул әлеге төбәк волостьларындагы татар старшиналары Ибраһим Уразбахтин белән Мәкъсүт Морзакаевны янә фетнәгә чакырып хәбәр юллый. Тегеләр Канзафар Усаевның нияте турында башкорт старшиналарына хат язалар. Шунысын да искәртик: Галибай Морзаголов, Илчегол Таймасов, Кәип Зиямбәтев, Ибраһим Мерәсев, Аслай Курманаев кебек башкорт старшиналары инде күптән патшабикәгә тугры булырга ант иткән булалар һәм фетнә хәрәкәтендә катнашмыйлар. Ә хыянәтче Кыдрач Муллакаев, берничә отряд командирын җәлладлар кулына тапшырып, хөкүмәт каршында ышаныч һәм абруй да яулап өлгерә. Ләкин Пугачевның Урал заводлары, Башкортстан, Пермь өлкәсе, Удмуртия аша бер-бер артлы җиңүләр яулап үтүе һәм Казан губернасына таба юнәлүе, әлбәттә инде, башкорт старшиналары арасында икеләнү хисе уята. Алар бер үк вакытта «падишаһ» озаткан бригадир Канзафар Усаев үченнән дә, яңа хыянәт өчен хөкүмәт тарафыннан җәзага тартылудан да куркып калалар. Шуңа күрә 26 сы көнне Ногай юлы волостьларының баш старшинасы Галибай Морзаголов Ибраһим Уразбахтин белән Мәкъсүт Морзакаевка «бик шома» җавап язарга мәҗбүр була. Ул кырда игеннәр өлгерүен, крестьяннарның уракка хәзерләнүен сылтау итә (информация өчен шунысын да өстик: бу җәй гаять коры килә һәм игеннәр уңмый). Шушы хат аша ул Канзафарны крестьяннарны отрядларга мәҗбүриләп тупламаска, үзара бозылышмаска һәм әлегә тыныч кына яшәргә үгетли.

Ләкин Канзафар башкорт старшиналарының «акылга килүен» көтеп ятмый. Ул санаулы көннәр эчендә үз кул астына яңа отряд туплый һәм июль башында Ногай юлындагы фетнәчеләрнең юлбашчысына әверелә. Аны Ашказар елгасы буендагы крестьяннар гына түгел, хәтта ерак Оренбург ягындагы командирлар да җитәкче дип таныйлар. Атаклы Кинҗә Арыслановның улы, Нокыш елгасы буенда хәрәкәт итүче полковник Селәүсен Кинзин да Канзафарга аны хөрмәтле командиры санап хат яза («Воззвания...», док. №160). Канзафарга яңа отряд туплауда Савакул (?) авылы татары, фетнәчеләр йөзбашы Әмир Әбдекәев аеруча зур ярдәм күрсәтә *(И. Гвоздикова)*.

Мишәрләрнең баш полковнигы дәрәҗәсен йөртүче Канзафар куйган тырышлыкның нәтиҗәсе озак көттерми. Июль башында Ногай юлы волостьларын тоташ фетнә ялкыны чолгап ала. Каранай Моратов кул астындагы 800 кешелек отряд 4 июль көнне Ашказар һәм Эстәрлетамак пристаньнарына һөҗүм ясый. Моңа кадәр икеләнеп торган башкорт старшиналары Г. Морзаголов, К. Муллакаев, К. Зиямбәтов, И. Таймасов, И. Мерәсев, А. Курманаев, татар командирлары Ибраһим Уразбахтин, Мәкъсүт Морзакаев, Габделкәрим Рахманкулов кул астына тупланган отрядлар да 5 июль көнне Эстәрлетамак янына килеп җитә һәм Каранай Моратов белән кушыла. Шушы ук көнне алар Оренбургтан Уфага таба баручы генерал П. Голицынның 2000 кешелек корпусына һөҗүм итәләр. Әмма регуляр гаскәр фетнәче крестьяннарны куып тарата. Полковник И. Денисов командалыгындагы Дон казаклары, подполковник А. Бедряга җитәкчелегендәге Изюм полкы гусарлары, фетнәчеләрне эзәрлекләп, 320 кешене юк итәләр («Крестьянская война... на территории Башкирии»). Генерал Голицын Эстәрлетамак пристаненда подполковник П. Шепелевка буйсынучы отрядларны калдыра да үзе Уфага китеп бара. 14 июльдә Голицын инде янә юлга чыга һәм Пугачев артыннан Казанга ашыга. Башкорт старшиналары Г. Морзаголов, К. Муллакаев, К. Зиямбәтев, И. Таймасов һәм башкалар Голицынның Уфадан чыгуын яңа җәзалау походы дип кабул итәләр, күрәсең. Алар, 17 июль көнне Кармасан елгасы янында Голицын каршына килеп, янә гафу үтенәләр һәм моннан соң инде хөкүмәткә «мәңге тугры булырга» ант итәләр.

Шул ук көннәрдә Сүүн-Кыпчак волосте старшинасы башкорт җирбиләүчеләре арасыннан беренче булып Пугачевка кушылган, әмма 4 апрель көнне Голицын каршында хөкүмәткә тугры булырга ант иткән Ямансарый Яппаров та сәер һәм гыйбрәтле адым ясый. Кинҗәнең улы Селәүсен, татар командиры Турай Ишаев (Ишалин), Бөрҗән волосте старшинасы Акбулат Ракаев 16 июльдә 1000 кешелек отряд белән Имәнкул авылы янында камап алгач, Ямансарый «фетнәчеләр ягына чыга». Ә 24 июльдә аның волостена хыянәтче мишәр старшинасы Миндәй Тупеев җитәкчелегендәге җәза отряды килеп җиткәч, Ямансарый бу юлы тагын хөкүмәткә тугры булырга ант итә. Өстәвенә, Тупеевка үзенең улы Киекбай Ямансарин җитәкчелегендәге җәза отрядын да кушып җибәрә.

Уфа провинциясендәге әлеге дулкынланулар турындагы хәбәр Казандагы генерал П. Потемкинга да барып ишетелә. 17 июль көнне махсус күрсәтмә язып, ул Михельсон полкына кушылган хыянәтче башкорт старшинасы Шәрип Киеков белән мишәр Мөхсин Әбдесәламов отрядларын ашыгыч рәвештә үз төбәкләрендә «тынычлык урнаштыру» өчен озата.

Ногай юлында яшәгән күпчелек башкорт старшиналары арасында июль дәвамында менә шундый икейөзлелек һәм хыянәт хөкем сөрсә дә, мишәр каһарманы Канзафар Усаевның рухы сынмый. Июль уртасында Канзафар Ашказар һәм Агыйдел буйларында хәрәкәт итә. 20 июль тирәсендә аның кул астына 1000 гә якын фетнәче туплана. Отрядында Дим, Үршәк, Авыргазы, Үзәк елгалары янына урнашкан авылларның вәкилләре дә була. Әлеге төбәк авыллары фетнәдән читләшкән өчен Канзафар, шунда юнәлеп, андагы хыянәтчеләрдән үч алырга исәпли.

Ләкин Канзафар «падишаһ» тарафыннан үз алдына нинди бурыч куелган булуын онытмый. Июль дәвамында ул, Ногай юлындагы барлык фетнә отрядларын бер йодрыкка төйнәп, Уфага һөҗүм итәргә хәзерләнә (әлбәттә, юл уңаеннан Бозаязга кереп, апрель аенда үзен җәлладлар кулына тапшырырга җыенган хыянәтче мишәр старшиналары Ишмөхәммәт Сөләйманов белән Мөхсин Әбдесәламовтан үч алырга да план кора). Бу вакытта Кондырак елгасы буенда Каранай Моратов, Канбулат Юлдашев, Кинҗәнең туганы Котлыкилде Габдрахманов кул астындагы отрядлар хәрәкәт итә. Селәүсен Кинзин һәм Турай Ишаев җитәкләгән 1000 кешелек отряд Имәнкул авылы (Учалы районында) янында хыянәтчеләргә каршы көрәш алып бара. Дүсмәт һәм Сарманай авылы татарлары секунд-майор В. Юшков карательләре белән өч мәртәбә яуга керәләр («Крестьянская война... на территории Башкирии»).

Канзафар Усаев менә шушы отрядларның һәркайсы белән бәйләнешкә керә. Ул Каманың уңъягында көрәшүче Бәхтияр Канкаевны да үз янына чакырырга җыена, шул максат белән Рахманкул исемле мулланы да юллый. Рахманкул Бәхтияр янына барып җитә. Әмма Ногай юлындагы күп кенә башкорт старшиналарының «падишаһ»ка хыянәт итүен күреп һәм төп максаты Казанга һөҗүм ясау булганга күрә, Бәхтияр Канзафарның чакыруын кабул кылмый. Күрәсең, мондый җавап алу Канзафарны да Ногай юлында хәрәкәт иткән җитәкчеләргә каршы кыюрак басым ясауга этәргәндер. Отряд командирлары икеләнү күрсәткән чагында, ул аларны хыянәттә гаепләүдән дә тартынмый. Канзафарның таләпчәнлек күрсәтүе эзсез узмый. Ногай юлы волостьларының баш старшинасы Галибай Морзаголов 27 июль көнне янә фетнәчеләр ягына күчәргә җыена башлый. 1 август тирәләрендә башкорт старшинасы Ибраһим Мерәсев, мишәр җитәкчесе Габдессәлам Мәмдәлев, татар старшиналары Ибраһим Уразбахтин белән Мәкъсүт Морзакаев, башкорт полковнигы Моратшаһ Сыртланов һәм башкалар, үз отрядларын туплап, Канзафар янына килеп кушылалар. Канзафар аңа кадәр үк Салават Юлаев, Каранай Моратов, Качкын Самаров, Канбулат Юлдашев янына да чапкыннар юллый. Максат һаман шул ук — бөтен көчне бер йодрыкка төйнәп, Уфа каласына һөҗүм итү. 3 август көнне Шәрип исемле мишәр чапкыны аңа Салаватның да Уфага һөҗүм хәзерләве турында хәбәр итә. Шул көнне Селәүсен Кинзинның аның белән кушылырга юнәлүе турында хәбәр җиткерәләр. Канзафарның иңнәренә канат үскәндәй була. Әмма башимәс каһарманның ниятләре чәлпәрәмә килеп җимерелә.

Кара Табын волостеның башкорт старшинасы Кыдрач Муллакаев — әле 1737 елда ук үз милләтенең каһарман юлбашчысы Килмәк Норышевны мәкер белән әсирлеккә төшереп «чирканчык» алган, 3—4 ай элек кенә тагын «падишаһ» атаманнары Гаврила Давыдов белән Вәлит Торновны патшабикә җәлладларының кулына ыргытып «азау тешен чыгарган» явыз хыянәтче — хәзер инде Канзафарның башын ашау өчен хәйлә кора. Күрәсең, 3 август кичендәдер, үз отрядым белән сиңа кушылам дигән мәкер корып, ул Канзафарны Ермолкино авылы (Бишбүләк районында) янына очрашуга чакыра (без башкорт старшиналарының июль дәвамында никадәрле икейөзле булулары хакында инде әйтеп уздык). Соңыннан, сорау алу вакытында биргән аңлатмасына караганда, Канзафар үзе белән нибары 2 мишәр крестьянын гына алып бара. Әмма аның ул ярдәмчеләре дә хыянәтче булып чыгалар. Кыдрач Канзафарны шундук кулга ала (соңыннан Кыдрач Канзафарны 100 чакрым буе куып бардым, дип шапырына, ләкин, билгеле инде, бу аның үз дәрәҗәсен күтәрү һәм кыйммәтлерәк бүләк алу өчен уйлап тапкан хәйләсе генә була). 4 август көнне Кыдрач Канзафарны Бөгелмәдә торучы полковник Н. Кожин кулына илтеп тапшыра. Канзафардан шул көнне үк сорау алырга керешәләр («Крестьянская война... на территории Башкирии»). Ә хыянәтче Кыдрач соңыннан генерал П. Потемкин тарафыннан 50 тәңкә акча һәм «мактау» кәгазе белән бүләкләнә. Дөрес, Потемкин Екатеринага язган хатында бу сумманы 100 тәңкә дип күрсәтә. Ни хәл итәсең, генерал кешегә дә акча кирәк...

*Башкортстанның Дәүләкән районындагы бер авыл әле бүген дә әшәке җан Кыдрач исемен йөртә. Республика хөкүмәте һәм гайре милләтчеләр адресына безнең сорау: әлеге бәндә исемен мәңгеләштерү, бөтен милләт өчен зур кара тап булган истәлекне саклау бүген кемгә кирәк? Республикагызда башкорт халкының Килмәк абыз Норышев, Йосыф Арыков, Бәпәнәй Торыпбирдин, Сәетбай Алкалин, Күчәп Солтанголов, Канбулат Юлдашев, Моратшаһ Сыртланов кебек каһарманнары исемендәге авылларыгыз, урамнарыгыз юк икәнен яхшы беләбез. Әллә соң сездә каһарманлыкны бәяләүче үлчәмнәр икенчеме?*

Фетнәчеләр юлбашчысы Канзафар Усаев җәлладлар кулына эләксә дә, аның отряды әле сентябрь аенда да җәза командаларына һәм Кыдрач хыянәтчеләренә каршы көрәшә. Нәдер волосте старшинасы Ибраһим

Уразбахтин, Дуван-Табын волосте старшинасы Кунаккул Әтҗетәрев кебек татар командирларын карательләр хәтта ноябрь аенда да тота алмыйлар.

### *ЯРМӨХӘММӘТ КАДЕРМӘТОВ*

1774 елның июнь — июль айларында Пугачев явы гаять зур территориягә җәелә. Ярты Рәсәйне биләгән һәм бөтен дәүләтне дер селкеткән иң көчле яу турында эзлекле рәвештә язу, һәммә төбәкне берьюлы колачлап бару мөмкин түгел. Яуның хронологик үсешен саклау бәрабәренә төбәктән төбәккә күчеш ясарга мәҗбүр булган өчен укучылар безне гафу итсен. Хәзер сезне кабат Бөре өязенә алып кайтабыз.

Без «Фетнәчеләр маршы» дигән бүлектә бер кат әйткән идек инде, хәзер тагын кабатлыйбыз: полковник Якубович, майор Дуве, хыянәтче старшиналар Ихсан Баязитов һәм Аблай Исмәгыйлов җитәкчелегендәге 1000 кешелек җәза командасына каршы Сатана (Емаш) авылы янында 15 июнь көнне булган бәрелештән соң башкорт крестьяннарыннан төзелгән фетнә отрядлары «үз даругаларын саклау өчен» туган төбәкләренә кайтып китә. Бәхтияр Канкаев аларның Сухояз авылына туплануын таләп итсә дә, башкорт командирлары аңа буйсынмыйлар («Воззвания...», док. №140). Бәхтияр Канкаев Татарстан җиренә чыгып киткәч тә, һаман да шул татар вәкиле, Казан өязенең ясаклы крестьяны Яркәй (Ярмөхәммәт) Кадермәтов Уфа провинциясенең әлеге төбәгендә барча фетнә отрядларының хәрби җитәкчесе, юлбашчысы булып кала. Мулла, атаман Гадел Бигашев, полковник Габделҗәлил Рыскулов, атаманнар Аладин Биктуганов һәм Арыслан Рангулов, походный старшиналар Хәмит Мөхәммәтов, Габделваһап Хәсәнов һәм Зөлкәрнәй Йосыпов, старшиналар Сәлим Әитов, Мирас Миңлебаев кебек отряд командирлары һәм дистәләгән йөзбашлары шушы татар каһарманы җитәкчелегендә хәрәкәт итә башлый. Хәтта Бөредән шактый еракта, Елдәк крепостенда урнашкан Әбил Байдашев (чукынганнан соңгы исем-фамилиясе Иван Иванов), Усман Исламов, Исхак, Сәет Килмөхәммәтов, Сәйфулла һәм Рахманкул Юнысов кебек йөзбашлары һәм старшина Әхмәр дә Яркәйгә буйсына. Бөтен Пугачев явы барышындагы кебек үк, 1774 елның җәендә дә татар вәкилләре Бөре төбәгендәге, Уса юлындагы фетнәне хәрәкәтләндерүче төп көч була.

Дөрес, июнь ахырында Бөре төбәгенә җәза отрядлары бәреп керү биредәге башкорт һәм мари старшиналарын да татар командирлары кул астына берләшүгә этәрә. Уран волостеннан Бәйки Туйкиев, Федоська Янбактин, Әит Сәгыйтов, Мәһди Миндияров шикелле старшиналар карательләргә каршы бергәләп көрәшәләр («Воззвания...»).

Ләкин июнь аеның соңгы көннәре һәм июль башы Бөре тирәсенә тупланган фетнәчеләр өчен гаять зур авырлыклар тудыра. Бу көннәрдә Пугачевның Уса крепостеннан Казанга таба юнәлүен белеп, аның юлын кисәргә өметләнеп, бик күп җәза отрядлары «падишаһ»ның төп гаскәренә каршы юнәлә. Әмма Уфадан Усага яки Сарапулга таба хәрәкәт иткән чакта, карательләр иң элек Бөре өязен фетнәче крестьяннардан арындырырга тиеш була. Шуңа күрә җитез Михельсонның 20 июньнән алып 2 июльгә кадәр булган барча көннәре Бөре төбәгендә хәрәкәт итүче татар фетнәчеләренә каршы бәрелешләрдә үтә. Шул сәбәпле ул Казанга таба җиңүле марш белән баручы Пугачевка комачаулый алмый. Бөре төбәгендәге татар фетнәчеләре әнә шул рәвешчә Пугачевка бөтен яу барышындагы иң зур гаскәр тупларга һәм Казан каласын алырга ярдәм итә.

Безгә билгеле инде, Бөре төбәгендә Михельсон берьялгызы гына «тузынып» йөрми. Уфа каласында чагында ук аңа үз отряды белән Солтанморат һәм Бәхтияр Янышев, Шәрип Киеков, Мөхсин Әбдесәламов кебек хыянәтче старшиналар да кушыла. Июньнең соңгы көннәрендә шушы ук төбәккә майор М. Мельгунов отряды бәреп керә. Фетнәчеләрне Уса ягыннан ата хыянәтче башкорт алпавыты Кулый Балтачев туплаган җәзачылар командасы кысрыклый. Июль башында биредә майор Дуве, полковник Якубович юллаган карательләр хәрәкәт итә. Сарапул һәм Касево авыллары ягында да җәза отрядлары тынгы бирми.

Фетнәчеләр туплар белән коралланган карательләргә каршы тора алмыйлар. Байтак крестьяннар туган йортларын һәм авылларын сакларга кайтып китә, эре отрядлар таркала. Җитди каршылык тоймаган җәзачылар, авылларга ташланып, юлбасарларча байлык талый. Йөзәрләгән крестьяннар яу барышында һәлак була, исән калганнары чыбыркылар белән суктырыла. Командирлар җәза гаскәреннән азат төбәкләргә чигенергә яки отрядларын вакытлыча таратып торырга мәҗбүр булалар. Шунысы сокландыра: *Бөре төбәгендәге бер генә старшина яки отряд башлыгы да карательләр каршына тез чүгеп һәм гафу үтенеп килми!*

12 июльдә Уфага генерал П. Голицын килеп җитә. Без бу хакта әйттек. 14 е көнне ул ашыгыч рәвештә Казанга чыгып китә. Ләкин Уфада калган полковник П. Шепелев, махсус отряд юллап, Бөре төбәген

«буйсындырып тотарга» тиеш була *(Н. Дубровин)*. Бер төбәккә берьюлы әллә ничә җәза отрядының туплануы крестьяннарга янә фетнәгә күтәрелергә мөмкинлек бирми. Җитмәсә, 20 июльдән соң бирегә «падишаһ»- ның Казан янында тар-мар ителүе турындагы хәбәр дә кайтып җитә. Ә ул, үз чиратында, мөгаен, крестьяннарда төшенкелек һәм икеләнү хисе дә тудыргандыр.

Әмма санаулы гына көннәр үтә, Бөре төбәге М. Мельгунов, С. Янышев, Ш. Киеков, М. Әбдесәламов кебек карательләрдән арына һәм июль ахырында, август башында татар каһарманнары янә Ярмөхәммәт Кадермәтов янына туплана. Яркәйнең нәкъ шул көннәрдәге эшчәнлеген тасвирлаучы тарихи документлар әлегә табылмаган. Ләкин безгә «падишаһ» бригадирлары Салават Юлаев белән Канзафар Усаевның июль ахырында, август башында Уфага һөҗүм хәзерләүләре билгеле. Хәтта хыянәтче старшина, 1767 елда Екатерина төзегән комиссия депутаты булган, ә Пугачев армиясендә полковник дәрәҗәсен алган Туктамыш Ишбулатовны да Канзафар шушы һөҗүмдә катнашырга күндерә. Дөрес, әлеге старшина бергә кушылып милли-азатлык өчен көрәшүне төп максаты итми, күрәсең. Ул генерал Голицын Кызылъяр авылында калдырып киткән трофей-байлыкны талый да шундук фетнәдән читкә тайпыла («Воззвания...», док. №176). Шушы старшинаның вакытлыча булса да фетнәгә кушылуы һәм июль дәвамында Канзафар күрсәткән активлык безне бер нәтиҗәгә этәрә. Мөгаен, йә Канзафар, йә Салават июль ахырында яки август башында Бөре төбәгендәге фетнә башлыкларына да бергәләп Уфаны штурмларга чакыру ташлагандыр. Ә Бөре өязендәге отряд башлыклары бергә туплангач, Ярмөхәммәт Кадермәтовны баш полковник итеп сайлаган булырга тиеш. Шундый нәтиҗәгә килми мөмкин түгел. Чөнки Пугачев явы барышында бер генә мөселман командирының да үз-үзенә хәрби дәрәҗә алу очрагы булмаган. Ә тарихи документлар Ярмөхәммәтнең 11 августта бригадир дәрәҗәсендә булуын күрсәтә («Воззвания...», «Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Казан һәм Уфа провинциясендә яшәүче фетнәчеләр өчен август аенда, бер уйласаң, өметсез чор башлана. «Падишаһ» Идел аръягына качкан, фетнә отрядларының зур күпчелеге тар-мар ителгән һәм туздырылган. Ләкин «падишаһ»сыз калу да, яу барышында меңәрләгән көрәштәшләрен югалту да татар һәм башкорт крестьяннарын фетнә хәрәкәтеннән читләштерә алмый. Идел буендагы халыкларның төп хыялы Рәсәйдәге патшаларны алыштыру түгел, ә бәлки колонизаторлар изүеннән азат, мөстәкыйль дәүләт төзү була. Сугышчан полкларның һәм җәза командаларының Пугачев артыннан Идел аръягына китүеннән, Кама елгасы белән Урал арасында карательләрдән чагыштырмача буш мәйдан барлыкка килүеннән файдаланып, фетнә җитәкчеләре милли-азатлык өчен көрәшне дәвам итәләр. Тагын шунысын да ассызыклап өстик: ***1774 елның июленнән соң Казан һәм Оренбург губерналарында урыс крестьяннары фетнәдә бөтенләй диярлек катнашмыйлар!***

*Алдан ук әйтә алабыз: Уфа провинциясендә Канзафар Усаев, Салават Юлаев, Яркәй Кадермәтов һәм тагын дистәләгән җитәкчеләр кул астына июнь аеннан соң тупланган меңәрләгән фетнәчеләр арасында Елдәк крепостенда кушылган нибары* ***70 урыс фамилияле казактан тыш*** *(аларның да әле байтагы керәшендер),* ***бүтән бер генә урыс отряды да билгеле түгел*** *(«Крестьянская война... на территории Башкирии», док. № 147). Хакыйкать шундый икән, Пугачев явын урыс фетнәсе итеп тасвирлау яки «урыс булмаган халыклар фетнә барышында социаль изүгә каршы гына көрәшкәннәр», дип күрсәтү чын, фәнни калыпларга сыямы соң? Кызганыч, Рәсәй империясендә әле бүген дә миллионлаган балалар мәктәпләрдә ялган тарих укып агулана. Ә тагын да аянычрагы: алар арасында ирекле, мөстәкыйль дәүләт төзеп яшәүгә лаек булган татар, башкорт, мари, чуваш, удмурт... балалары да бар...*

Бөре төбәгендә җәелгән милли-азатлык көрәше 10 август тирәсендә инде шактый оешкан төс ала. 11 август көнне язган фәрманыннан күренгәнчә, баш полковник Яркәй Кадермәтов бу вакытта үзе Бәдрәш авылында (Тәтешле яки Янаул районында) тора һәм киләсе дүшәмбедә (?) өяздәге фетнә отрядларын Эмчәйбаш ягында тупларга исәпли. *(«Эмчәйбаш» сүзен «Воззвания...» китабын төзүчеләр шулай тәрҗемә иткән. Алар аңа «Әминбаш төбәге» дип аңлатма биргәннәр. Ләкин Башкортстанда андый исем йөртүче авыл да, елга яки тау да юк. Август аенда Яркәй Кадермәтовның Агыйдел, Буй, Әмзә, Танып елгалары буенда хәрәкәт итүе билгеле. Безгә калса, бу сүзнең дөресе Калтасы районындагы Әмзәбаш авылы булырга тиеш. Җитмәсә, шушы төбәктә үк Буй елгасына кушылучы Әмзә елгасы да ага. — «Словарь топонимов Башкирской АССР».)* Яркәй фәрманда Сипирган ягындагы *(тарихчы галимнәр аңа «Уран волостендагы авыл» дип аңлатма биргән. Ә дөресе: Борай районы территориясендә Ургыл (Җитез) Танып елгасына килеп кушылучы Себергән елгасы һәм шуның янында утыручы Себергән авылы)* отрядларның да шимбәгә каршы төндә Уран волостена (Янаул, Краснокама, Барда районнары территориясе) таба юнәлүе турында хәбәр итә. Яркәй шушы фәрман белән Уран волостеның старшинасы Әит Сәгыйтовка, мари старшинасы Бәйки Туйкиевка, удмурт Исмай Туманаевка һәр йорттан берешәр ирне алып отрядлар тупларга һәм ашыгыч рәвештә Әмзәбаш янына килергә боера. Яркәй үз хатында җитәкчеләрне гамьсез булмаска чакырса да, Әит Сәгыйтов фәрманны үтәргә ашыкмый. Яркәй, яңадан-яңа

хатлар язып, аның янына янә чапкыннар юлларга мәҗбүр була. Бу вакытта инде Ангасяк (Әңгәсәк дигән елга исеменнән) заводы ягындагы (Дүртөйле районында) карательләр дә активлаша. Шуңа күрә 14 августта язган фәрманында Яркәй Кадермәтов Әит Сәгыйтовны соңгы тапкыр кисәтә һәм аны, «падишаһ» полклары җибәреп, җәзага тарттыру белән яный («Документы ставки Е. И. Пугачева...», «Воззвания...»). Яркәй күрсәткән таләпчәнлек һәм тәвәккәллек нәтиҗәсез калмый. Тиздән Бәйки Туйкиев һәм Әит Сәгыйтов отрядлары баш полковник Яркәйгә килеп кушылалар. 20 августтан соң Яркәй кул астындагы фетнәчеләр саны 2000 гә җитә *(В. Мавродин, И. Гвоздикова).*

Шушы урында тукталыш ясап, тагын бер әйберне искәртик. Уфа провинциясендә фетнәчеләрнең активлашуы турындагы хәбәрләр август башында Казанга, генерал П. Потемкинга да барып ирешә. 10 сы көнне махсус белдерү язып, ул кылган гөнаһлары өчен гафу үтенеп килгән фетнәчеләрне җәзага тартмаска вәгъдә бирә. Фетнә хәрәкәте тукталмаса, Потемкин 1 октябрьдән соң Уфа провинциясенә 10 мең Запорожье казагы җибәрү һәм төбәкне тулысынча туздыру белән яный («Крестьянская война... на территории Башкирии», док. № 142).

Генерал фәрманы кайбер отряд җитәкчеләре арасында вакытлыча икеләнү тудыра. Фетнә барышында «зур гөнаһка чуммаган» старшиналар «судан коры чыгу» җаен карый башлый. Әйтик, 18 майда хыянәтче Туктамыш Ишбулатов отряды кысрыклап килгән чакта карательләр ягына чыккан, ә 18 июньдә Уса янына «падишаһ» килеп җиткәч, шул ук Туктамышның үзе белән бергә фетнәчеләр ягына «авышкан» Әдигот Тимачев «гөнаһлар»дан җәзасыз котылырга омтылган җитәкчеләрнең берсе була. Июнь — июль айларында гына Бәхтияр Канкаев һәм Ярмөхәммәт Кадермәтов җитәкчелегендә яу кылып йөргән атаман Аладин Биктуганов та, күрәсең, менә шушы Әдиготның үгетләүләренә бирелгәндер. Ничек кенә булмасын, әмма әлеге ике атаман һәм Габдессәлам Рәмзин, Җумакай Әскәров, Рахманкул Иртуганов кебек старшиналар 31 август көнне хыянәтче Шәрип Киеков, Кулый һәм Сәгыйть Балтачевлар исеменә хат язалар. Алар, үзләренең ***диндәш*** булуларын искәртеп, киләчәктә кан коймаска чакыралар, фетнәне «Ходай каргышы» дип атыйлар һәм җәза отрядларын «махсус указ чыкканчы» өйләрендә хәрәкәтсез утырырга өндиләр («Крестьянская война... на территории Башкирии», док. № 146). Карательләр җавабы турында тарих дәшмәсә дә аңлашыла: «падишаһ» Идел аръягына куылгач, «иңнәренә канат үскән» карательләр, әлбәттә, фетнәчеләр шартын кабул итми. Икеләнеп торучыларның кайсылары кыюрак эш йөрткән фетнәчеләр янына барып кушыла, кайсылары туган төбәгендә яткан килеш кенә вакыйгалар агышын күзәтә.

Ә Яркәй Кадермәтов кул астына тупланган 2000 фетнәче хөкүмәт «миһербанлыгы»нә өмет тотмый, август ахырында хыянәтчеләргә каршы көрәш алып бара, тагын бик тиздән премьер-майор И. Штерич җитәкчелегендәге карательләр командасы белән дә аяусыз яуга керә. Штерич солдатлары атаман Н. Назаров җитәкчелегендәге Җаек казаклары отряды белән дә көчәйтелгән була.

Яркәй Кадермәтов белән Штерич отрядлары арасындагы беренче бәрелеш 30 август көнне Музяк авылы янында (Краснокама районында, Әмзә елгасы буенда) була. Карательләр басымына түзмичә һәм башка фетнәче отрядлар белән кушылуга өмет итеп, Яркәй Кадермәтов көнчыгышка таба чигенә. Майор Штерич командасы Яркәйне эзәрлекләп бара һәм 4 сентябрьдә Ивановская (В. Мавродин хезмәтендә шулай, ә И. Гвоздикова китабында — Иваново) авылына барып җитә. Штерич карательләрен биредә мөселман фетнәчеләренең 1500 кешелек яңа бер отряды каршы ала (ул Тулва татарларыннан торган Габделҗәлил Рыскулов отряды булырга тиеш). Фетнәчеләр үзләре карательләр өстенә һөҗүмгә ташлана. Ләкин Штеричның регуляр отряд солдатларына, Җаек казакларына, туплар утына каршы тору мөмкин булмый. Штерич карательләре фетнәче крестьяннарны куып тарата. Фетнәчеләрнең әлеге отряды соңыннан Бөре елгасы буена чигенә.

*Хәзер инде 4 сентябрьдә булган яу белән бәйле тарихи мәгълүматларга тукталыйк һәм аңлатма бирик. Ләкин аларны берничә өлешкә бүләргә туры килә.*

*1. Укучы инде, мөгаен, үзе дә төшенгәндер: тарихчы галимнәр Иван авылының кайсы төбәктә урнашкан булуын төгәл расламыйлар. Аның Балтач районында бүген марилар яши торган Югары яки Түбән Иванай булуы мөмкин, хакыйкатькә шунысы якынрак, ләкин «нәкъ шул» дип өзеп кенә раслауга алынмыйбыз. Чөнки Башкортстан территориясендәге бүген «бөек» Иван исемен йөртүче 34 (!) авыл бар. Бөек урыс халкының «чиксез бай фантазияле» булуына ишарәләп, Башкортстанда әле тагын Александр исемендәге — 32, Андрей атлы — 17, Алексей кушаматлы — 21, Ходайга мәхәббәт белдергән — 9, Василийсыз яши алмаган — 18, Дмитрийны олылаган — 19, Ильяга гашыйк — 9, «комсомоллар белән тулы» — 10, Кузьма «яраткан» — 12, Михаилга баш игән — 50 (!), Николай белән аерылырга телмәгән — 66 (!), «октябрь тудырган» — 16, Петрга мөкиббән киткән — 39, «Покрау» бәйрәмен сагынып көтүче — 34, каенлы — 22, имәнле — 11, наратлы — 13 һәм башка «оригинал» исемдәге урыс авыллары барлыгын искәртеп китәсе килә. Шушы «бөек» исемнәрне санап чыкканнан соң, ирексездән безне «Урыс туган ватанмы соң бу, әллә мөселманнар яши торган илме, йә Ходаем?» дигән сорау газаплый башлый. Без аң-*

*латмый калдырган бүтән төр кинаяләр, бәлки, тугандаш республика хөкүмәтенә дә барып җитәр? Ә гайре милләтчеләр колагына ишеттерәсе сүзебез шундый: «татар килеп безнең җирне баскан» дип, «урыс чаңын» какканчы, иң элек, сезгә газиз республикагыздагы авыл исемнәрен генә булса да барлап чыгасы иде. Бәлки, шуннан соң күзләрегез ачылыбрак китәр?*

*2. Петербург галиме В. Мавродин 4 сентябрьдә Штерич командасына һөҗүм иткән фетнәчеләрне Салават Юлаев юллаган отрядларның берсе дип күрсәтә. Шуннан кала бер генә тарихчы да әлеге отряд командирының исемен атамый. Әмма «хөрмәтле» оппонентыбыз И. Гвоздикова 4 сентябрьдә яу алып барган командирны, әлбәттә инде, Салават Юлаев дип раслый. Аның фикеренчә, майор Штерич рапортында «чая җайдак» итеп телгә алынган командир — ул ни өчендер, һичшиксез, Салават кына булырга тиеш һәм вәссәлам! Дәлилләвен дәвам итеп, И. Гвоздикова 4 сентябрьдә атаман Аладин Биктуганов отрядын да Салават Юлаев кул астында сугышкан дип күрсәтә. Сүзләрен раслау өчен ул Көнгер каласында 5 сентябрь көнне алынган хәбәрне дә өсти. Ул хәбәр буенча, Уфа елгасы аръягында Салават кул астында 1000 кешелек башкорт отряды тора һәм аларга Тол (Тулва) елгасы яныннан килгән 2000 татар килеп кушыла (И. Гвоздикова, 172 б.). Ләкин әлеге авторга үз китабының 173 битендә язылган җөмләсен кабатлыйбыз: «Аладин Биктугановның 1000 кешелек отряды сентябрь башында Уран волостенда торган». Шушы ук биттә Салават Юлаевның сентябрь дәвамында туплаган 3000 кешелек гаскәре составында полковник Габделҗәлил Рыскулов, атаман Арыслан Рангулов, походный старшина Бүләк Якупов туплаган отрядлар да булган дигән җөмләләр бар. И. Гвоздикованың логикасы «каш төзәтәм дип, күз чыгару»га охшый түгелме соң? Әгәр Салават үзе — 1000, Аладин Биктуганов 1000 фетнәче белән килгән, аларга 2000 Тулва татары өстәлгән, җитмәсә, Г. Рыскулов, А. Рангулов, Б. Якупов та үз отрядлары белән кушылганнар икән, аларның гомуми саны 3000 эченә һич кенә дә сыймый. Хәтта шул ук 4 сентябрьдә булган яуны гына тикшергән очракта да безгә кайсы командирны рәнҗетергә соң? Штерич командасына һөҗүм ясаган фетнәчеләр саны 1500 дип күрсәтелә, ә фәкать Салават белән Аладин отрядларын гына кушкан очракта да алар 2000 гә тиңләшә. Фәнни дәлилләү түгел, хәтта мантыйк та юкка чыга. И. Гвоздикова тәкрарлавы белән ризалашып булмый.*

*3. Бөре өязендәге Иван авылы янындагы бәрелештә «Себер юлыннан килгән Салават отряды, бәлки, чыннан да катнашкандыр», дигән фаразны дәвам итсәк, безне башкорт каһарманының әхлакый сыйфатлары гаҗәпкә калдырачак. Чөнки Салаватның 10 сентябрь көнне Катау-Иван заводы янында торуы, 18 ендә Елдәк крепостен алуда катнашуы тарихи документларда төгәл яктыртылган. И. Гвоздикова һәрбер фараз белән бик ансат килешсә дә, бригадир дәрәҗәсен йөрткән һәм үзе җыйган 1000 кешелек отряд язмышы өчен җаваплы булган Салават, яугирләрен карательләр «бугазына» ташлап, туган төбәгенә сәяхәт ясый алыр идеме икән? 4 сентябрьдә җиңүгә ирешкән Штеричның алдагы көннәрдә тагын фетнәчеләр өстенә ташлануы мөмкин бит. Шундый куркыныч янавын белә торып, 1000 кешелек отрядны ташлап китү — монысы инде милли каһарманны бизәүче сыйфат түгел. Ә Салаватны безнең чын ир-егет итеп күрәсебез килә. Шуңа күрә, әхлакый яктан да, И. Гвоздикова фаразлары белән килешмибез.*

*4. Соңыннан карательләр кулына эләккән отряд җитәкчеләренең берсе дә сорау алу вакытында «4 сентябрьдәге яуда Салават катнашты» дип искә алмый. Хәтта Салаватның кан дошманы булган Кулый Балтачев кебек хыянәтче дә башкорт каһарманына 4 сентябрьдәге яу белән бәйле яла якмый. Ә Салават кылган «гөнаһларны» тикшерү, аларны бәйнә-бәйнә ачыклау 1774 елның 25 ноябреннән башлап 1775 елның 15 июленә кадәр бара. Салаватны «батыру» өчен, дистәләгән фетнәчеләрнең күрсәтмәләре туплана. Әмма тикшерү барышында Иван авылы яки 4 сентябрь көнне булган яу ялгыш та телгә алынмый.*

*5. Каратель И. Рылеев тарафыннан язылган тагын бер тарихи документка нигезләнсәк, сентябрь башында Бөре һәм Танып елгалары арасында нигездә Гайнә, Ирәкте, Уран волостьлары крестьяннарыннан төзелгән фетнә отрядлары гына хәрәкәт итә. Алар арасында Елдәк крепостеннан кушылган 70 урыс казагы да була. Уфа өязенең Себер волостьлары да, Салават исеме дә әлеге документта телгә алынмый («Крестьянская война... на территории Башкирии», док. №147).*

*6. Көнгер каласында 5 сентябрь көнне алынган хәбәрдә «Салават отряды Уфа елгасы аръягында тора» дип анык әйтелә. Җитмәсә, «үзенә кушылган 2000 Тулва татары белән бергә Салават Ачыт крепостена һәм Көнгер каласына һөҗүм итәргә хәзерләнә» дип тә өстәлә (Ю. Лимонов, В. Мавродин, В. Панеях, И. Гвоздикова). Ә Көнгердә яшәүчеләр өчен Уфа елгасы аръягы — ул Себер юлы дигән сүз. Өстәвенә, Уфа белән Бөре елгалары арасында да шактый ераклык бар.*

*7. Әгәр 4 сентябрь көнне Салават Юлаев Иван авылы янына килеп җиткән булса, алар, һичшиксез, Ярмөхәммәт Кадермәтов отряды белән берләшерләр иде. Чөнки карательләр боҗрасы эчендә фәкать бердәм хәрәкәт итү генә җиңүгә өмет тудыруын Ярмөхәммәт тә, Салават та бик нык аңларга тиеш*

*була. Ә вакыйгалар агышыннан күренгәнчә, Ярмөхәммәт сентябрь дәвамында ялгыз көе генә хәрәкәт итә. «Ике тәкә башы бер казанга сыймый» дигән күзлектән чыгып караганда, ике бригадирның бер-берсенә буйсынырга теләмәвен фараз итү — монысы инде алар тарафыннан — дуамаллык, безнең өчен җитди фикер йөртмәү булыр иде.*

*Үз дәлилләребезнең беркадәрен санап чыктык. Ләкин укучыларыбыз да аңлагандыр: сентябрь башында Уфа провинциясендә милли-азатлык көрәше алып баручы отряд җитәкчеләре Ярмөхәммәт Кадермәтов, Аладин Биктуганов, Бүләк Якупов, Габдулла Туктаров, Гадел Бигашев, Арыслан Рангулов, Габделҗәлил Рыскуловның, шулай ук Салават Юлаевның да эшчәнлекләрен төгәл генә итеп, бәйнә-бәйнә чагылдыручы тарихи документлар юк. Шуңа күрә бүген бер генә галим һәм тарихчы да абсолют, какшамас хакыйкатькә дәгъва итә алмый. Сентябрь аенда һәм, гомумән, фетнә ахырында Уфа провинциясендә хәрәкәт иткән отрядларның эшчәнлеге галимнәр тарафыннан бик сай өйрәнелгән. Тарих фәне яңа галимнәр, яңа фидакарьләр эзләнүен көтә.*

4 сентябрьдә 1500 кешелек фетнәчеләр отрядын куып таратса да, майор Штерич солдатлары һәм атаман Назаров казаклары камалыштан чыга алмыйлар. 6 сентябрьдә Иван авылына инде Ярмөхәммәт Кадермәтов кул астына тупланган татарлар һәм Бәйки Туйкиев командалыгындагы марилар һө-җүм итә. Ләкин регуляр гаскәр ярым-йорты рәвештә коралланган крестьяннар отрядын бу юлы да куып тарата *(В. Мавродин, И. Гвоздикова).*

Штерич командасына бер-бер артлы һөҗүм ясап торучы фетнәчеләр турындагы хәбәрләр Уфага да барып җитә. 13 сентябрьдә подполковник И. Рылеев җитәкчелегендәге яңа бер команда Штерич янына ярдәмгә җибәрелә һәм ашыгыч рәвештә Бөре төбәгенә юнәлә («Крестьянская война... на территории Башкирии», док. №147). Карательләрнең яңа командасы турындагы хәбәр Салаватка да барып ишетелә. Ул да ашыгыч рәвештә Уфа елгасы янына килә һәм андагы 3000 кешелек отряд өстеннән башлык булып Бөре ягына юнәлә. Подполковник Рылеев Салаватка каршы борыла һәм 18 сентябрь көнне аның белән беренче мәртәбә яуга керә. Ярмөхәммәт белән Салават бергә кушылып, бердәм көрәшергә омтылса да, аларның ниятләре барып чыкмый. Майор Штерич Ярмөхәммәт отрядының юлын бүлә һәм туктаусыз эзәрлекләвен дәвам итә. Әллә ничә мәртәбә булып узган яулардан соң Ярмөхәммәт кул астында 500 генә фетнәче кала. 28 сентябрь көнне майор Штерич карательләре Ярмөхәммәт отрядына соңгы тапкыр һөҗүм ясый һәм фетнәчеләрне тар-мар итүгә ирешә. Яудан соң берничә көн үткәч, баш полковник Ярмөхәммәт Кадермәтов карательләр кулына әсирлеккә төшә *(В. Мавродин).*

*Татар халкы арасыннан бригада генералы дәрәҗәсенә ирешкән өченче каһарман сентябрь дәвамында кайсы төбәкләргә таба чигенгән, нинди авырлыклар кичергән, нинди батырлык күрсәткән — ул кадәресе дә һәм, гомумән, Ярмөхәммәт Кадермәтовның 28 сентябрьдән соңгы язмышы да бөтенләй билгеле түгел. Пугачев явын өйрәнгән татар галимнәре Татарстанның бүгенге чикләрен атлап чыгарга «кыенсынган». Ә татарның үзе үк төкереп караган тарихын да, аның искиткеч каһарманнары язмышын да урыс, башкорт, чуваш, мари... галимнәре, әлбәттә, «читкә типкән». Туган халкыбызның газиз тарихына гамьсез булып яшәве өчен хурланудан йөрәктән кан тама, җаныбыз өзгәләнә. Үз милләтен, үз тарихын сөяр фидакарьләр татар халкы арасында кайчан ишәер икән?..*

# «ПУГАЧАУ ПАТША» АРТЫННАН

Уфа провинциясендәге татар-башкортларның сентябрь ахырында да карательләр каршында тез чүкмәве инде аңлашылгандыр. Ләкин күзәтүне тагын яңа төбәккә күчермичә чарабыз юк. Чөнки Пугачев белән киткән татар фетнәчеләреннән июль уртасында ук аерылышкан идек. Алар янына кайтыйк.

Пугачев 18 июль таңында Сундырь авылы янында Идел аръягына чыга. Аны 300 ләп Җаек казагы, берникадәр урыс крестьяннары һәм татар фетнәчеләре озатып бара. Якыннары арасында да А. Овчинников, И. Перфильев, И. Творогов, И. Федулов (Федульев), Ф. Чумаков, фетнә буе «падишаһ» гвар-диясенең башлыгы булып торган Я. Давилин, атаман Вәлит Торнов, Хәрби коллегия секретаре А. Дубровский (чын аты — Иван Степанов, бөлгән сәүдәгәр), берүзе генә калса да, башкорт халкының баш полковнигы дигән дәрәҗәне йөртүче Кинҗә Арысланов һәм, 1 октябрьдә үк «падишаһ»ка кушылып, Хәрби совет әгъзасы булып торган Садыйк Сәгыйтов кебек көрәштәшләре генә кала. Казаннан әүвәл майорлар Меллин белән Муфель, 19 ында Михельсон отряды Пугачев артыннан куа чыга.

Тарихи документларда Пугачев кул астында булган татарлар турында аерым мәгълүматлар юк. Шуңа күрә «падишаһ»- ның 18 июльдән соңгы походын без кыскача гына яктыртырбыз.

Идел аръягына чыккач, Пугачев әүвәл Мәскәүгә таба юнәлә һәм бер-ике көн эчендә Цивильск, Курмыш калаларын ала. Карательләр «карак»ның Мәскәүгә һөҗүм итүеннән куркып кала һәм барчасы диярлек шул юлны сакларга ташлана. 20 июль көнне Пугачев көньякка борыла һәм Иделнең уңъяк яры буйлап хәрәкәт итә башлый. Аның походы Рәсәй җирләрендә аяусыз сыйнфый көрәш яки гражданнар сугышы рәвешен ала. Пугачев юлда искиткеч тиз бара, һәр шәһәрдә, өяздә һәм һәр авылда диярлек воеводаларны, отставкадагы офицерларны, руханиларны, алпавытларны, аларның хатыннарын, балаларын, гомумән, үзен «патша» дип танымаган йөзәрләгән кешеләрне дарга аса. Капкынга куып кертелә башлаган Пугачев хәзер үзе узган һәр шәһәр һәм авылда коточкыч тәвәккәллек һәм кансызлык күрсәтә. Шул ук вакытта ул үз кул астына меңәрләгән яңа фетнәчеләрне дә җыеп өлгерә. Пугачев карательләр эзәрлекләвеннән качып бара, ләкин аның качуы, Пушкин әйткәнчә, «юлдагы һәр каршылыкны җимереп баручы дошман һөҗүменә охшый».

«Падишаһ» 23 июльдә — Алатырьны, 27 сендә — Саранск каласын, 1 августта — Пензаны, 5 есендә — Петровск шәһәрен, 6 сында Саратовны ала. Алпавыт катлавыннан булган дошманнарның җенесенә яки яшенә дә карап тормастан, фетнәчеләр Алатырь, Саранск өязләренең һәркайсында ким дигәндә 300 кешене асып үтерәләр (*А. Пушкин*. «История Пугачева»). Пенза өязендә фетнәчеләр 600 алпавыт вәкилен юк итә *(В. Буганов)*. Алатырьга кергәндә, Пугачев кул астында 2000 крестьян булса, Саранскины алгандагы «гаскәр» 7000 кеше исәпләнә *(В. Буганов)*. Ләкин әлеге «гаскәр» карательләрнең регуляр отрядына каршы торырлык көч булмый, билгеле. Чөнки «төп армия»дәге крестьяннар даими рәвештә алышынып тора. Өстәвенә, Меллин һәм Муфель отрядлары аларның эзенә басып килә. Әйтик, Пугачев Пензадан 2 августта чыгып китсә, 4 есендә бирегә карательләр керә.

«Падишаһ»ның шәһәр артыннан шәһәр яулавы, фетнәчеләр күрсәткән кансызлык турындагы хәбәрләр алда торган калаларга да барып ишетелә һәм, билгеле, андагы халык күңеленә шом сала. Шуңа күрә 15 тубы, 780 кешелек гарнизоны булган Саратов каласында 4000 тирәсе фетнәчедән торган Пугачев гаскәренә җитди каршылык күрсәтүче табылмый. Кыска гына вакытлы штурмнан соң ук гарнизонның бер өлеше һәм коралланган халык шәһәр капкаларын ача, фетнәчеләр калага бәреп керә. Воевода полковник Бошняк һәм атаклы Державин көч-хәл белән качып котыла *(В. Буганов, Н. Дубровин)*. Яу барышында «падишаһ» ягына чыккан майор А. Салманов Саратовның «воеводасы» итеп билгеләнә. Ул соңыннан карательләр кулына төшә. Екатерина аны, дворян дәрәҗәсеннән мәхрүм итеп, Таганрогка каторга эшләренә җибәрә *(Х. Муратов)*.

*Янә бер тарафка игътибар итми булмый. Казаннан Саратовка барган чакта, Пугачев Мари иле, Чувашстан, Түбән Новгород өлкәсенең Сергач өязе, Мордовия, Пенза, Саратов өлкәсендәге дистәләгән районнар аша уза. Мари иленең — Бәрәңге; Чувашстанның — Батыр, Комсомол, Козлов, Демьян, Цивильск, Торбеево районнарында; Сергач өязендә яртылаш; Мордовиянең — Инсар, Рузаевка, Ковылкино, Зубова Поляна; Пензаның — Неверкин, Кузнецк, Лопатин; Саратов өлкәсенең Дергач һәм башка районнарында элек-электән үк татарлар яшәгән. Алар арасыннан да, һичшиксез, фетнәгә кушылучылар булган.*

*Тагын шуны да искәртик: ул төбәкләргә таралган татарларның байтак өлеше динен һәм әкренләп исем-фамилиясен, тора-бара милләтен алыштырган. А. Пушкин Алатырь, Пенза, Саратов өязләрендә фетнәчеләр кулыннан вафат булган күп кенә корбаннар исемлеген төзегән. Безгә калса, алар арасында чукынган татар алпавытлары да бик күп. Берничә генә мисал китерәбез: төрле хәрби дәрәҗәдәге Мещериновлар, прапорщик Иван Ашанин, тол калган алпавыт хатыны Агафья Тахтарова, кенәз Сульдешев, кенәз Максим һәм Онисим Чюрмантаевлар, кенәз Семен һәм Спиридон Мамлеевлар, Бурнашевлар, кенәз Михаил Ишеев, поручик хатыны Евгения Исаева, прапорщик Василий Гадеев, кенәз Кугушев, татар Бикмай Дубин, төрле дәрәҗәдәге Шахматовлар, прапорщик Козьма Рахманинов, прапорщик Михаил Ахматов, капитаннар Семен Агишев, Андрей Маматов, Алексей Тагаев һәм фамилияләре үк татар нәселеннән булуларын кычкырып торган бик күп, бик күп башка корбаннар. Без Саратов «воеводасы» А. Салмановны да шуларга өстибез. Пугачев узган төбәкләрдә керәшен байларыннан шулкадәр корбаннар булган икән, һичшиксез, ярлы керәшен татарлары фетнәгә һич югы 5—10 мәртәбә күбрәк кушылганнар.*

9 августта Пугачев Саратовны калдыра, 11 ендә бирегә — Муфель белән Меллин, 14 ендә Михельсон килеп җитә *(Н. Дубровин)*. 11 ендә Пугачев Камышин шәһәрен ала. 16 августта аның инде 10—15 мең кешелек «гаскәре» Пролейка елгасы буенда полковниклар Кутейников һәм Дундуков, майор Диц командалыгындагы 3000 солдат һәм казаклы карательләр корпусын тар-мар итә. Майор Диц һәлак була, Кутейников белән калмык Дундуков качып котыла. 17 сендә Пугачев Дубровканы ала һәм Царицын (Волгоград) каласына юнәлә. 19 августта Мәчетле елгасы буенда Пугачев өч мәртәбә Дон казаклары белән бәрелешә. Яраланган Кутейников әсирлеккә эләгә (әлеге полковник гыйнвар аенда Пугачевның Зимовейскаядагы гаиләсен кулга алып Казанга озаткан һәм «падишаһ» яшәгән йортны яндырып юк иткән була. —

*Н. Дубровин*). Пугачев бер татар «сугышчы»сына Кутейниковны атып үтерергә боера, әмма тегесе юньләп атмый, 2 сәгатьтән соң Кутейников һушына килә һәм качып котыла *(Н. Дубровин)*. Әлеге яуда 400 Дон казагы Пугачевка кушыла, калганнары Царицынга кайтып бикләнә *(В. Буганов)*.

21 августта Пугачев армиясе Царицынны камый. Шәһәрне 24 туптан 5 сәгать буена утка тоту уңыш китерми. Икенче көнне Пугачев, тагын бер мәртәбә һөҗүм ясагач, шәһәрне алудан өмет өзә. Ул арада Царицын янына полковник Михельсон гаскәре килеп җитә. Пугачев шәһәрне калдыра да Идел тамагына юнәлә. Сарепта дигән урында тукталып, «падишаһ» бер тәүлек буена үзенең сөяркәләре янында күңел ача *(А. Пушкин, Н. Дубровин, В. Буганов)*. Шушында Җаек казакларының атаманнары Овчинников, Чумаков, Творогов, Перфильев, Давилинга «генерал» дәрәҗәләре өләшә.

Ә 24 август көнне Царицын белән Черный Яр арасында, Солениковая ватага (Царицын сәүдәгәре Солениковның балык тотучылар әртиле) дигән җирдә полковник Михельсон фетнәчеләр гаскәрен куып җитә. Пугачев тупларны бер линиягә тезә, крестьяннарны шуларның артына туплый. Михельсон уртага пехота полклары куя, флангларга Чугуй полкы һәм Дон полкы казакларын бастыра. Канкойгыч авыр яудан соң фетнәчеләр тулысынча тар-мар ителә. Михельсон җайдаклары крестьяннарны 40 чакрым буе эзәрлекли. Нәтиҗәдә 2000 нән артык фетнәче һәм Җаек казакларының атаманнары Андрей Овчинников белән Яков Давилин юк ителә, 6000 крестьян әсирлеккә төшә *(Н. Дубровин, С. Алишев)*. Һәлак булучылар һәм әсирлеккә эләгүчеләр арасында, һичшиксез, йөзәрләгән татар крестьяннары да була. Карательләр әсирләрне исемлеккә теркәп тормый. Башкомандующий-җәллад П. Панин фәрманы буенча, әсирлеккә төшкән 6000 фетнәче дә чыбыркы, камчылар белән җәзалана һәм күпчелеге өйләренә кайтарып җибәрелә.

Карательләр кулыннан исән-имин качып котылучы татарлар да була. Мөслим авылы крестьяны Хәбзә Әбдүшев, мәсәлән, үзенең 6 иптәше белән бергә карательләр кулыннан кача һәм туган ягында янә «падишаһ исән-сау, мин аның яңа яуга әзерләнергә боерган фәрманын алып кайттым» дип хәбәр таратып йөри *(С. Алишев)*.

Пугачев шәхсән үзе 164 кеше белән бергә Черный Ярга таба кача һәм аңа җиткәнче 17 чакрым ераклыкта Идел елгасының сулъягына чыга. Бу вакытта Пугачев янында аның хатыны Софья, улы Трофим, алар белән бергә Кинҗә Арысланов, Садыйк Сәгыйтов һәм Казан өязеннән бирле килүче 2 татар була («Следствие и суд над Пугачевым», «Народы в крестьянской войне 1773—1775 гг.»; *Н. Дубровин, Ю. Лимонов*).

Бик озакка сузылган бәхәсләрдән соң пугачевчылар көнчыгышка, Җаек шәһәрчегенә таба юнәләләр. 10 көн чамасы барып, Үзән елгасы янына җиткәндә аларның инде икмәкләре дә, сулары да калмый. «Падишаһ» яраннары арасында тарткалашу башлана. Отряд икегә бүленә. Афанасий Перфильев җитәкчелегендәге 40 лап казак туп-туры Җаек шәһәрчегенә юнәлә. Шул ук вакытта тагын күпмедер урыс крестьяннары да «падишаһ»ны ташлап китә. Пугачев янында хәзер 100 чамасы гына кеше кала. Кинҗә Арысланов һәм татарлар элеккечә «падишаһ» эргәсендә була («Следствие и суд над Пугачевым»; *Н. Дубровин*). *Бу инде Кинҗә һәм татарлар турында соңгы мәгълүмат. Шуннан соң алар белән ни булган, үзләре качканнармы, әллә аларны үтереп ташлаганнармы? Моны әсирлеккә төшкән Пугачев та, хыянәтчеләр дә әйтми. Җаек казаклары Кинҗә хакында: «Ул «падишаһ»ка аеруча тугры һәм нык бирелгән иде. Әгәр Кинҗәне ташлап калдырсак, «әшәке җан» (ягъни Пугачев) бездән шундук шикләнә башлар иде», — дип кенә әйтеп үтәләр (В. Панеях, Ю. Лимонов, В. Мавродин). Димәк, Пугачев шигеннән куркып, хыянәтчеләр Кинҗәне үтерә алмаганнар. Ә татарлар, әлбәттә, Кинҗәне яклар һәм хыянәтчеләргә аларны да юк итәргә туры килер иде. Кинҗә һәм 3 татар шушы вакыттан соң (5—8 сентябрь) Пугачев белән дә бармаганнар. Кая киткән алар, язмышлары ничек төгәлләнгән? Тарихчылар өчен әлеге сораулар бүгенге көнгәчә зур табышмак...*

Ә Пугачевның җиһанда «падишаһ» булып йөрүенә санаулы гына көннәр кала. Җаек казакларының бер өлеше «гөнаһларын юу» һәм үз гомерләрен саклап калу бәрабәренә әле Саратовта чагында ук Пугачевка каршы заговор оештыра башлый. Ниһаять, 8 сентябрь көнне Олы Үзән елгасы буенда «генерал-поручик» И. Творогов, атаман И. Федульев, «артиллерия генералы» Ф. Чумаков, яу дәвамында җәллад бурычын башкарган И. Бурнов, тагын Т. Железнов, Д. Арыков, И. Фофанов кебек казаклар Пугачевны кулга алалар. 14 сентябрь көнне хыянәтчеләр тоткынны Бударино форпостында бай казаклар йөзбашы Харчевка китерә. (Менә бит ул язмыш мәсхәрәсе: нәкъ бер ел элек, 18 сентябрьдә, Пугачев үзенең 200 кешелек тәүге отряды белән беренче булып шушы форпостны ала.) Харчев 15 сентябрь төнендә Пугачевны Җаек шәһәрчегенә илтеп, Яшерен комиссия әгъзасы капитан Маврин кулына тапшыра. (Шунысын да өстик: йөзбашы Харчевка соңыннан «акылдан шашкан» Екатерина тарафыннан шундук полковник (!) дәрәҗәсе бирелә. — *Н. Дубровин*.)

16 сентябрьдә капитан Маврин Пугачевтан тәүге сорау алуга керешә. Шул көнне үк Җаек шәһәрчегенә атаклы Суворов килеп җитә. Җиңелмәс полководец (!) җитәкчелегендәге каравыл сагы астында Пугачевны шуннан әүвәл Сембергә (1 октябрь), аннары Мәскәү каласына (4 ноябрь) алып киләләр.

Пугачевның кулга алынуы турындагы «тантаналы» хәбәр 19 сентябрьдә — Казанга, 1 октябрьдә Петербургка барып җитә. Пугачев явын бастыруга, крестьяннар канын коюга аеруча зур өлеш керткән 4 атаклы шәхес: җәллад П. Панин, генерал П. Потемкин, А. Суворов һәм Екатерина II тарафыннан зур бер өяз байлыгына торырлык бүләкләр алган полковник И. Михельсон 1 октябрь көнне Сембер каласында кавышалар *(Н. Дубровин)*. «Һаваланып» алган Панин шәхсән үзе шушында Пугачевны кыйный. Әйе, карательләр лагеренда шашынулы тантана башлана. Ләкин алар турында язарга кулыбыз бармый.

# УФА ПРОВИНЦИЯСЕ.. ФЕТНӘНЕҢ СОҢГЫ УЧАГЫ

Ярмөхәммәт Кадермәтов отряды 28 сентябрь көнне тар-мар ителсә дә, Уфа провинциясендә фетнә хәрәкәте тукталмавы хакында кисәткән идек инде. Мөгаен, укучыларга Салават Юлаевның 1774 елның җәендәге көрәш юлы аңлашылып бетмәгәндер. Кыскача гына шуңа тукталыйк.

Уса янында 23 июнь көнне «падишаһ»тан фәрман алганнан соң, яралы Салават туган төбәгенә кайта. Аның этисе Юлай Азналин отряды инде май ахырыннан бирле Катау-Иван заводын камалышта тоткан була (*И. Гвоздикова*, 175 б.). 19 июнь көнне Юлай отряды заводны штурмлап карый, ләкин уңышка ирешә алмый һәм чигенә (*В. Мавродин*, 69 б.). Салаватның 13 июньнән 10 сентябрьгә кадәрге көрәш юлын ачыклаучы, дәлилләүче тарихи документлар бик аз, ә үз кулы белән язылганнары бөтенләй юк. Карательләр дә аны бу дәвердә телгә алмаган. Шуңа күрә июль — август айларында Салават нигездә яңа отряд туплау белән шөгыльләнгән, карательләр белән бәрелешләргә кермәгән, дип нәтиҗә ясарга туры килә. Чөнки бу чорда Уфа провинциясенең Себер юлында фетнә хәрәкәте актив бармаган. Патша администрациясе дә бу төбәккә җәза отрядлары юлламаган. Гомумән, июль — август дәвамында Себер юлында чагыштырмача тынычлык хөкем сөргән. Дөрес, август башында Канзафар белән Салават Уфага һөҗүм итәргә исәп тотканнар. Ләкин Канзафарның хыянәтче Кыдрач Муллакаев кулына әсирлеккә төшүе бу ниятне дә өзгән.

Сентябрь аенда да фетнәчеләр Катау-Иван заводын камалышта тота. 10 сентябрь көнне Салават Юлаев белән Юлай Азналин завод приказчикларына хат җибәрә. Алар приказчикларга әсирләр алышырга һәм фетнәчеләр ягына чыгарга тәкъдим ясыйлар. Билгеле, май аеннан бирле фетнәчеләргә бирешмәгән завод сакчылары хәзер дә Салават белән Юлай тәкъдимен кабул итмиләр. Ә фетнәчеләрнең көче аз була, шунлыктан алар заводны штурмларга тырышып та карамыйлар. Шуннан соң Салават Бөре төбәгенә китеп бара.

Сентябрь уртасында Ярмөхәммәт Кадермәтов отрядыннан тыш Бөре төбәгендә 3000 кешелек тагын бер отряд хәрәкәт итүе турында инде әйткән идек. Аның составында полковниклар Габделҗәлил Рыскулов һәм Габдулла Туктаров, атаманнар Арыслан Рангулов, Аладин Биктуганов һәм Гадел Бигашев, походный старшиналар Бүләк Якупов һәм Габдессәлам Рамзин кебек җитәкчеләр булуы билгеле. Ләкин кайсы командир кайсы көнне һәм нинди сандагы отряд белән килеп кушылган — моны төгәл ачыклау мөмкин түгел. 3000 кешелек әлеге отрядны Салават Себер юлында җәй көне туплаган 1000 башкорт һәм алар белән кушылган 2000 Тулва татары тәшкил итүе генә анык билгеле. Салават менә шушы отряд янына килә һәм, бригадир буларак, аның җитәкчесенә әверелә.

18 сентябрь көнне иртән 3000 кешелек отряд Елдәк крепостен ала. Ләкин шушы көнне үк бирегә 13 е көнне Уфадан чыккан подполковник И. Рылеев командалыгындагы карательләр килеп җитә. Карательләр Кулый Балтачев, Солтанморат һәм Бәхтияр Янышевлар, Ишмөхәммәт Сөләйманов кебек хыянәтче старшиналарның отрядлары белән дә ныгытылган була. Фетнәчеләр крепостьны калдыралар һәм Бөре елгасы буена чигенәләр. Подполковник Рылеев отряды әүвәл 25 чакрым ара калышып, аларны эзәрлекләп бара. Әмма Тимошкино авылына (Борай районында) җиткәндә, Салават отрядындагы бертөркем җайдак көтмәгәндә Рылеев карательләренә һөҗүм итә. Кыска гына яудан соң фетнәчеләр шундук юкка да чыгалар. Шомга төшкән Рылеев Тимошкино авылында тукталырга мәҗбүр була. Салават отрядындагы төп көчләрне ачыклау өчен, Рылеев разведка җибәрә. Шуннан соң гына карательләр янә юлга чыга.

22 сентябрь көнне Нөркәй исемле татар авылы янында (Балтач районында) Салават һәм Габделҗәлил җайдаклары үзләре Рылеев отрядына һөҗүм итәләр. Аяусыз һәм канлы яу бик озак бара. Фетнәчеләр берничә мәртәбә һөҗүмгә ташлана. Ләкин туп һәм мылтык залплары аларны һәр очракта артка алып ташлый. Яу барышында 400 крестьян һәлак була. Фетнәчеләр карательләр эзәрлекләве астында Елдәк крепостена таба чигенәләр. 25 сентябрь көнне Рылеев отряды Елдәк крепостена кереп урнаша. Салават үз

отряды белән Себер юлына, Катау-Иван заводына, Тулва татарлары Уса юлына кайтып китә («Крестьянская война... на территории Башкирии»; «Участие народов Башкирии...»; *И. Гвоздикова, В. Мавродин*).

*Хәзер тагын бер тукталыш ясауны үзебезнең бурычыбыз дип саныйбыз. Хикәя барышында Елдәк исеме күп мәртәбә телгә алынды, әмма без ул урнашкан районны күрсәтмәдек. Моның сәбәбе түбәндәгеләрдән гыйбарәт иде. Башкортстан территориясендә бүген Елдәк исемен йөртүче бер генә авыл бар, ул Дүртөйле районында. Әмма, безгә калса, Елдәк крепосте әлеге төбәктә булмаган. 1939 елда нәшер ителгән Башкортстан картасында Елдәк — ул Уфа елгасында, Уфа —Красноуфимск арасында, хәзерге Нариман районында булган пристаньлы авыл. Сугыштан соң әлеге зонада Павлов сусаклагычы төзелгән, Елдәк авылы юкка чыккан, аның каравы Уфа елгасының сулъяк ярында Павловка поселогы пәйда булган. Пугачев явындагы вакыйгалар агышына карап фикер йөрткәндә, Елдәк пристанен элеккеге крепость дип карау хакыйкатькә күп мәртәбә якынрак тора.*

*Инде янә 1774 елга кайтыйк һәм һичшиксез игътибарга лаеклы фактны искә төшерик.*

Без Казанда торучы генерал П. Потемкинның Кама аръягында милли-азатлык өчен көрәш алып баручы мөселман яугирләренә фетнәне туктатырга чакырып махсус белдерү язуы һәм алар буйсынмаган очракта 1 октябрьдән соң Уфа провинциясенә «10 мең Запорожье казагын» җибәреп төбәкне тулысынча туздыру белән янавы турында инде язган идек. Уфа провинциясендә яшәүче крестьяннар, билгеле инде, явыз генерал тарафыннан ясалган кисәтүне онытмыйлар. Гафу үтенеп килү көне 1 октябрь якынлашу, һичшиксез, байтак крестьяннарны уйланырга, хәтта тынычланырга мәҗбүр итә. Ул да булмый, 20 сентябрьдән соң бу төбәккә дә «падишаһ»ның Әби патша янараллары кулына әсирлеккә эләгүе турындагы хәбәр кайтып ирешә. Әлеге «кара хәбәр» моңа кадәр дә аумакайрак позициядә торучы старшиналарга тәэсир итми калмый. 22 сентябрь көнне Потемкин янына *12 старшина* гафу үтенеп килә. Ләкин мондый гына «күндәмлек», әлбәттә инде, Потемкинны канәгатьләндерми. Котырына-тузына фәрманнар язып, ул аларны Уфа провинциясендә хәрәкәт итүче җәза отрядларына юллый. Потемкин отряд командирларыннан Уфа һәм Исет провинциясендәге 150 гә якын старшинаның, алай гына да түгел, хәтта 20 меңгә якын йортның һәркайсын буйсындыруларын таләп итә. Аптыраган полковник П. Шепелев Мәсәли авылына (Авыргазы районында) кадәр җитеп, Дим һәм Үршәк елгалары буена урнашкан волость старшиналарына, шулай ук Качкын Самаров, Бүләк Гомәров, Күчәпкул Гадәтбаев һәм башка җитәкчеләргә аларның үз каршына баш иеп килүләрен таләп иткән хатлар язып карый. Ләкин 30 сентябрь («изге күңеллелек»нең соңгы көне!) җитә, Шепелев янына баш иеп килүче табылмый! («Крестьянская война... на территории Башкирии».)

Салават Юлаев Катау-Иван заводы янына менә шундый катлаулы көннәрдә кайтып төшә. Октябрь башында аның кул астында ничә фетнәче калган — бу кадәресен ачыклау мөмкин түгел. 22 сентябрьдәге яудан соң Тулва татарлары һәм байтак командирлар үз отрядлары белән туган якларына кайтып киткән була. Шул көннәрдә Уфа провинциясендә карательләр каршына килеп «гафу үтенүләр» башлана. Октябрь аенда, мәсәлән, Гайнә һәм Ирәкте волостьларындагы 957 фетнәче подполковник Папава каршына килеп «тез чүгә». Алар арасында Туктамыш Ишбулатов, Көчекбай Габдуллин, Бикташ Шәрипов кебек старшиналар да була («Крестьянская война... на территории Башкирии»).

Әмма котылгысыз һәлакәт куркынычы каршында да азатлык сөю рухын саклап калган старшина һәм җитәкчеләр Уфа провинциясендә байтак исәпләнә әле. Мәсәлән, Себер юлындагы Кущин волостеның старшинасы, «падишаһ» полковнигы Илчегол Иткулов, әле 10 октябрьдә дә үзенең карательләр каршында баш имәячәген белдереп, Красноуфимск җитәкчеләренә хат яза. Хәтта ул «падишаһ»тан атна саен «хат алып торуын» да хәбәр итә («Воззвания...»).

Уфа провинциясендәге фетнәчеләрнең баш имәвен күреп, 18 октябрь көнне инде баш җәллад П. Панин башкорт халкына махсус белдерү язарга мәҗбүр була. Ул барча старшина һәм фетнәчене хөкүмәт гаскәрләре каршына гафу үтенеп килергә, ә Салават Юлаев белән башка җитәкчеләрне тотып китерергә чакыра. Билгеле инде, фетнә тукталмаган очракта баш җәллад башкортларның барча ир-атын ерткычларча үтереп бетерү, ә хатыннарын һәм кыз балаларын коллыкка өләшү белән куркытырга да онытмый.

Хөкүмәт күрсәткән басым, куркыту һәм янаулар, «падишаһ»сыз калу, карательләр тарафыннан туктаусыз җиңелүләр — болар һәммәсе фетнәчеләр арасында төшенкелек тудыра. Ул да түгел, крестьяннар арасында хыянәтчеләр пәйда була. Кайбер җитәкчеләр үз гомерләрен һәм старшина дәрәҗәләрен саклап калу бәрабәренә фетнә отрядларының командирларын карательләргә тотып бирәләр. Ясаклы татар крестьяны, фетнә башыннан бирле Салаватның тугры ярдәмчесе булган полковник Габдулла Туктаров әнә шулай — хыянәт юлы белән — 15—17 октябрь тирәсендә карательләр кулына эләгә («Крестьянская война... на территории Башкирии», док. №164). Атаманнар Арыслан Рангулов белән Гадел Бигашев, йөзбашы Әбил Байдашев та карательләр кулына төшә, октябрь аенда алардан Уфа провинциясенең канцеляриясендә сорау алына (*И. Гвоздикова*, 163, 169 б.). Сугышчыларны таратып

отрядларсыз калган Качкын Самаров, Каранай Моратов кебек берничә полковник та чарасызлыктан 25 октябрьдә Зелаир крепостена килеп И. Тимашевка «баш ия» («Крестьянская война... на территории Башкирии», док. №165). Тимашев бөтен фетнә барышында каһарманлыгы белән дан алган Каранайны 4 ноябрь көнне Казанга генерал П. Потемкин янына озата (шунда ук, 409 б.).

Октябрь аенда Уфа провинциясендә баш имәгән җитәкчеләр санаулы гына кала. Пермь провинциясе канцеляриясенең рапортына караганда, 18 октябрьдә Уса юлында Аладин Биктуганов, Гадел Әзмәнов һәм башка берничә җитәкче кул астындагы фетнәчеләр отряды хәрәкәт итә. Ноябрь башында генерал П. Голицын Уса юлына һәм Көнгер өязенә өстәмә көчләр җибәрергә мәҗбүр була (*И. Гвоздикова*, 178 б.).

Ә Себер юлында карательләргә горур җанлы Салават тынгы бирми. Ул октябрь ае буена Катау-Иван заводын камалышта тота. 20 октябрьләр тирәсендә 300 кешелек отряд җибәреп, Салават үз отрядына яңа сугышчылар тупларга тырыша. Бу эштә аңа Касягул (?) авылы татары Иман Аласимов (Аладинов) аеруча зур ярдәм күрсәтә (*И. Гвоздикова*, 177 б.). Әмма тырышлык әллә ни зур уңышка китерми. Октябрь ахырында Салават кул астында нибары 400 гә якын гына фетнәче кала («Крестьянская война... на территории Башкирии», док. №168).

Салаватның үҗәтлеге Екатерина генералларының да үзәгенә үтә. 29 октябрь көнне хат язып, генерал П. Потемкин янә бер мәртәбә Салаватны «гафу үтенергә» чакыра. Ул хатына хәтта: «Патшабикә галиҗәнапләре гафу итсен өчен, син үз отрядың белән башка фетнәчеләргә һөҗүм ит, аларны үтер», — дигән сүзләр дә язып куя. Ләкин Салаватның мондый хыянәткә бару мөмкинлеге аны шикләндерә, һәм Потемкин ул сүзләрне соңыннан сызып ташлый.

Провинциядәге фетнә утын бастыру өчен, Оренбургтан генерал Фрейман да килеп җитә. 7 ноябрь көнне ул подполковник И. Рылеевның хыянәтче старшиналар отряды белән тулыландырылган командасын Катау-Иван заводына җибәрә. Бу вакытта Салават янында аның әтисе булмый. Ул октябрь ахырында фетнәдән читләшә («Крестьянская война... на территории Башкирии», док. №173).

Шул ук ноябрь аенда генерал Фрейман, Салаватны кулга алу өчен, Себер юлына подполковник Н. Аршеневский җитәкчелегендәге карательләр командасын да озата. Аршеневскийга хыянәтче мишәр старшинасы, әле 1756 елда ук легендар Батыршаны кулга эләктереп хөкүмәт каршында «абруй» аулаган Мөхсин Әбдесәламов отряды да ярдәмгә бирелә. Карательләрнең әлеге командасы Сим белән Әй елгалары арасына килә һәм Шәрип исемле татар авылында (Салават районында) урнаша.

Бу вакытта Салават инде, артык корбаннар булмасын өчен, үз отрядын тараткан була. Үзе Зәйнәш Сөләйманов, Юртом Гаделев, бертуган Ракай һәм Габдерәшит Галиевләр белән урманда, ә риваятьләргә караганда, Йөрүзән елгасы буендагы Чишмәле мәгарәсендә яшеренеп ята. 24 ноябрь көнне Аршеневский хыянәтче Мөхсин Әбдесәламов җайдакларын һәм поручик В. Лесковский отрядын Салаватны тотарга җибәрә. Хыянәтче Мөхсин җайдакларын Салават фетнәчеләр дип кабул итә. Ул аларга якынаерга мөмкинлек бирә. 25 ноябрь көнне Миндәш авылы янындагы (Салават районында) урманда Салават бертуган хыянәтчеләр Мөхсин һәм Җәмгур Әбдесәламовлар кулына төшә. Тегеләр аны поручик Лесковскийга тапшыра. Лесковский Салаватны һәм аның 4 иптәшен шул ук көнне Калмык авылына, подполковник Аршеневский кулына илтеп бирә («Крестьянская война... на территории Башкирии»; *И. Гвоздикова.* Информация өчен шунысын да өстик: әлеге «каһарманлыгы» өчен Лесковскийга капитан дәрәҗәсе бирелә). Крестьяннар патшасы Пугачевның башимәс соңгы бөркете Салават та шулай итеп иректән һәм көрәштән мәхрүм ителә.

### ***ЙОМГАК***

Ниһаять, без Пугачев явына кушылган төбәкләрнең күбесен йөреп чыктык. Гәрчә максатыбыз әлеге яуда татар халкының өлешен, аның милли-азатлык көрәшен яктырту гына булса да, фетнә уты кабынган һәр төбәк, һәр күренекле вакыйга телгә алынды, дисәк тә ярый. Хәзер инде Пугачев явы турында һәммә укучыбыз фикер йөртә ала. Ә без янә үз фикеребезне кабатларга бурычлы: тарих фәнендә бүгенгәчә «Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар явы» дип бик шома һәм бик кыска гына исем белән аталып йөртелгән яу — ул сыйнфый изелү-газап кичергән крестьяннарның фәкать алпавытларга гына каршы күтәрелгән фетнәсе дә, урыс катлаулары арасындагы урыс сугышы да түгел. **Пугачев явы — ул нигездә урыс булмаган һәм иреккә сусаган халыкларның Рәсәй колонизаторларына каршы милли-азатлык көрәше.**

Фетнәне 1773 елның сентябрь уртасында Җаек казаклары башлаган. Ә аларның ярлы дип аталган катламы да ул елларда татар, башкорт, мари, чуваш ... хәтта шул ук урыс крестьяннары шикелле сыйнфый изелү, талау-мәсхәрә кичермәгән. Гәрчә Пугачев явына нәкъ шул Җаек казаклары сулыш өрсә дә, кыска гына нәтиҗә ясаганда, аларның чыгышын «Рәсәй хөкүмәте каршында какшый башлаган абруйларын

ныгыту һәм үзләре өчен ниндидер өстенлекләр, ташламалар яулау бәрабәренә күтәрелгән фетнә» дип кенә бәяләргә мөмкин булыр иде. Алар һич кенә дә фетнә ярты Рәсәйгә җәелер һәм бөтен дәүләтне дер селкетер дип уйламаганнар. Патша хөкүмәтен өркетү өчен аларга фәкать үз төбәкләрендә генә спектакль кору да бик җиткән. Казаклар шул спектакльдә төп рольне — исеме белән генә дә Әби патшаның котын очырачак «Петр Федорович галиҗәнапләре»н уйлап тапканнар. Алар исәбенчә, спектакльдәге башка рольләрне тәкәббер Җаек казаклары һәм, җитди фетнә утыннан куркып, әледән-әле ташламалар ясаучы «умырткасыз, күндәм» патша хөкүмәте генә уйнарга тиеш булган.

Әмма фетнә утын кабызучылар «падишаһ» ролен башкарачак Емельян Пугачевтагы талантны да, Рәсәй тырнагындагы халыкларның изелү һәм газаплар нәтиҗәсендә шартлау дәрәҗәсенә җитүен дә исәпкә алмаганнар. Җаек казаклары шырпы гына сызган, ләкин аның ялкыны, яшен булып, бөтен Идел һәм Урал арасына таралган. Шуңа күрә Җаек казаклары бик тиздән үзләре үк спектакль-яуның гади тамашачыларына охшап калганнар. 1773 елның ноябрендә үк алар инде фетнәдәге җитәкче рольне югалтканнар. Гәрчә Шигаев, Падуров, Каргин, Зарубин, Ульянов, Овчинников, Толкачев, Перфильев, Творогов һәм тагын берничә Җаек казагы фетнәнең билгеле бер этабында һәм төбәгендә җитәкчелек итсә дә, дөресен генә әйткәндә, бу инде аларның үзләре сайлаган рольне ахыргача уйнарга тырышуы гына булган.

Хикәят барышында без эшләре һәм шәхси каһарманлыклары белән игътибарга лаек булган урыс җитәкчеләрен дә күрсәтергә тырыштык. Аларны санап чыгыйк: Соколов-Хлопуша, Иван Белобородов, Иван Грязнов, милләте билгесез Григорий Туманов, «урыс һәм азиат халыкларының юлбашчысы» Иван Кузнецов, атаманнар Иван Губанов, Иван Васев, А. Вязовой, Илья Арапов, Семен Волков, Федор Калабин (Шмота), Андрей Носков, Елдәк крепостендагы фетнәче казаклар башлыгы А. Шеметов, Уса янындагы отряд җитәкчесе полковник Степан Кузнецов, Балык Бистәсе янында хәрәкәт иткән полковник Г. Лихачев, полковниклар Дорофей Загуменнов, Григорий Филинков, Казан өязендә көрәш алып барган Макаров, Алексеев, Попов, Герасим Иванов, Иван Черняев, Карп Карасев һәм тагын берничә җитәкче.

Без әлеге исемнәрне тиктомалдан гына санамадык. Урыс тарихчыларының бик күбесе бүген: «Пугачев армиясендәге күренекле җитәкчеләр саны 200 гә җиткән, шуларның 52 се — казак, 38 е — алпавытларга, 35 е заводларга беркетелгән урыс крестьяннары булган», — дип, фетнәдәге үз милләт вәкилләренең ролен күпертеп күрсәтергә тырышалар (*В. Буганов*. «Емельян Пугачев».—1990.— С. 105). Шулай итеп, алар Пугачев явыннан урыс фетнәсе ясыйлар.

Ләкин без эшчәнлекләре һәм шәхси каһарманлыклары игътибарга лаек казак җитәкчеләренең дә, урыс вәкилләренең дә исемнәрен санап чыктык. Укучы болай да аңлагандыр: алар арасында аерым төбәкләрдә Салават Юлаев, Бәхтияр Канкаев, Канзафар Усаев, Әит Үрәзмәтов, Качкын Самаров, Нагайбәк Әсәнов, Каранай Моратов, Аренкол Асеев, Бакый Абдуллов, Батыркай Иткинин, Муса Мостафин, Ярмөхәммәт Кадермәтов, Юскәй Кудашев, Вәлит Торнов, Усман Тимеров кебек фетнә уты кабызып, отрядлар туплап, крепостьлар һәм калалар яулап йөргән командирлар бик аз. Саналганнары арасында да Карп Карасев кебек, гомумән, отряд тупламаганнары яки элеккеге «танышлык» өчен генә полковник дәрәҗәсен алганнары һәм шулай ук, Загуменнов, Филинков кебек, инде җыелган, төзелгән отрядларга башлык итеп куелган җитәкчеләр дә бар. Ә Җаек казагы булган һәм «спектакль» серен белгән өчен генә полковник дәрәҗәсендә йөргән Иван Шибаев, Дмитрий Лысов эше эчкече, карак бәндәләрне, октябрь аенда ук Оренбургка качкан һәм соңыннан фетнәчеләр тарафыннан дарга асылган «полковник» Копеечкинны, Бирдә бистәсендә 5—6 ай буена «командир» булып саналган, әмма бернинди дә батырлык кылмаган дистәләгән башка казакларны сан яки ялган максат өчен генә җитәкчеләр исемлегенә кертү һич урынлы түгел.

Урыс тарихчылары фетнә җитәкчеләре исемлегенә 50 генә татар-башкорт вәкилләрен керткән; мари, чуваш, удмурт, казах, калмык командирларына урын юк... шулай отышлырак. **Пугачев явы урыс җитәкчелегендә үткән фетнә булып яктыртылса, империя тарихына зур күләгә төшми. Шуның өчен урыс тарихчылары фетнәдә катнашкан крестьяннарның гомуми санын яшерә һәм фетнәчеләрнең милли составын күрсәтми. 1774 елның июленнән соң Казан һәм Оренбург губерналарында бер генә урыс отряды да фетнә күтәреп йөрми. Татар, башкорт, мари, чуваш, удмурт, калмык, казах фетнәчеләрен бөтен яу барышында нигездә старшиналар, тарханнар, солтаннар әйдәп йөри. Һәр мөселман отрядының үз байрагы була. Карательләр ул байракларны хәтта дар агачларына да кадаклыйлар. Татар, башкорт, мари, чуваш, удмурт, калмык халыклары фетнә барышында сыйнфый гына түгел, бәлки аеруча колониаль, милли һәм дини изүгә каршы көрәшәләр. Аларның төп максаты урыс изүеннән, талавыннан азат тормыш була. Ләкин урыс тарихчылары алар турында да дәшми.**

Татар галимнәре турында да: «Пугачев явында катнашкан үз милләттәшләрен ачыклау буенча зур фидакарьлек күрсәтәләр»,— дигән мактау сүзләре әйтә алмыйбыз. Фән докторлары М. Госманов белән С. Алишев, мәсәлән, фетнәдә катнашкан татар полковникларының санын — 9 га, походный старшиналарны

— 20 гә, йөзбашларын 40 ка гына тиңлиләр (*М. Госманов, С. Алишев*. Бөек крестьяннар сугышына 200 ел // Казан утлары.— 1973.— №9). Без алар белән ризалаша алмыйбыз һәм хезмәтебез ахырында үзебез төзегән исемлекне китерәбез. Ул да тулы һәм камил булмас, әмма хакыйкатьне ачыклауда мөгаен ярдәм итәр.

* * *

Инде аңлашылганча, 1774 елның ахырында Пугачев явы Рәсәйнең барча төбәкләрендә дә бастырыла. Коралсыз крестьяннарның нигездә Казан һәм Оренбург губерналарына шыплап тутырылган «чит илне дә өркетерлек» карательләрнең армиясенә каршы көрәшерлек көче калмый. Җитмәсә, фетнә барышында крестьяннарның юлбашчыларына әверелгән һәм каһарманлыклары белән танылган дистәләгән җитәкчеләренең дә һәммәсе диярлек йә яу кырларында яки җәлладлар кулыннан һәлак була, йә карательләр кулына әсирлеккә төшә. Шул күренекле җитәкчеләрнең исемнәрен янә хәтергә төшерик.

**Яу кырында һәлак булганнар:**

Андрей Овчинников, Иван Грязнов, Иван Кузнецов, Федор Дербетев, Ишмән Иткулов, Гаврила Лихачев, Яков Давилин...

**Җәлладлар тарафыннан юк ителгәннәр:**

Гаврила Давыдов, Йосыф Енгалычев, Соколов-Хлопуша, Иван Губанов, А. Вязовой, Рахманкул Дуслиев, Габделҗәлил Сөләйманов, Чүрә Рәсүлов, Собханкул Килтәков, Назар Алексеев, хорунжий Невзоров, Михаил Уржумцев, Әит Үрәзмәтов, Усман Тимеров, Попов, Иван Белобородов, Мәсәгуть Назыйров, Аптыш Тангаев, Әбүбәкер Теләчев, Уразкилде Аманов, Габдулла Ягъфәров, Матвей Чигвинцев, Михаил Мальцев, Ф. Минеев, Андрей Витошнов, Михаил Толкачев, Никита Каргин, Исмәгыйл Туктамышев, Гәбдерәшит Бикеев...

**Әсирлеккә төшүчеләр:**

Емельян Пугачев, Тимофей Падуров, Афанасий Перфильев, Максим Шигаев, Мәсәгуть Гомәров, Канзафар Усаев, Ярмөхәммәт Кадермәтов, Салават Юлаев, Габдерәшит Әитов, Муса Алиев, Идеркәй Мәхмүтов, Иван Почиталин, Максим Горшков, Илья Ульянов, Денис Караваев, Иван Васев, Каранай Моратов, Качкын Самаров, Михаил Толкачев, Чика-Зарубин, Григорий Закладнов, Вәлит Торнов, Исхак Әхмәтов, Макар Попов, Гадел Бигашев, Арыслан Рангулов, Семен Шеметов, Габделҗәлил Рыскулов, Габдулла Туктаров...

**Эзсез югалучылар:**

Бәхтияр Канкаев, Габдулла Мостаев, Халит Әминов, Балтач Сәетов, Батыркай Иткинин, Бакый Абдуллов, Юскәй Кудашев, Кинҗә Арысланов, Садыйк Сәгыйтов, Григорий Туманов, Тимербулат Үрәзмәтов, Андрей Носков, Аренкол Асеев, Сәнфин, Шәрип Якупов, Шәфи Туйхуҗин, Күзмәт Ишмәтов, Байсак Биктимеров, Кадермәт...

Карательләр кулына әсирлеккә төшкән каһарманнарның язмышы, мөгаен, укучыларда хаклы рәвештә кызыксыну уяткандыр. Кызганычка каршы, без Ярмөхәммәт Кадермәтов, Габделҗәлил Рыскулов, Бүләк Якупов, Сөләйман Күзкәев, Гадел Бигашев, Арыслан Рангулов, Муса Алиев, Идеркәй Мәхмүтов, Габделкәрим Рахманкулов, Габдерәшит Әитов, Габдулла Туктаров, Әбди Абдуллов, Аладин Биктуганов кебек күренекле җитәкчеләр турында бер сүз дә әйтә алмыйбыз, тарихи документлар алар хакында дәшми. Ә башка юлбашчыларның алдагы язмышы турында үзебезгә билгеле мәгълүматларны сезгә дә бәян итик.

Емельян Пугачев шәхсән үзе 4 ноябрьдә Мәскәү каласына китерелә. Аны Монетный двор подвалында тимер рәшәткәле махсус читлеккә биклиләр. Пугачевның кул-аяклары богаулана, чылбыр очы стенага ныклап беркетелә. Шулар өстенә, Пугачевны көчәйтелгән зур каравыл саклый. Мәскәү обывательләре һәм чиксез тантана кичерүче байлар аны ике ай буена подвал тәрәзәсеннән карап «күңел ача».

Тиздән Пугачев «җинаятьләр»ен «зыялы» Екатерина тарафыннан оештырылган «законлы тикшерү» башлана. Яу башында ук Пугачевның көрәштәшләренә әверелгән Чика-Зарубин, Падуров, Закладнов, Горшков, Караваев, Тимофей Мясников, Василий Плотников, Иван Почиталин кебек Җаек казаклары, юлбашчыны кулга алып карательләргә тапшырган хыянәтчеләр, «падишаһ»ның беренче һәм «икенче» хатыннары Софья белән Устинья, балалары Трофим, Христина, Аграфена, шулай ук Вәлит Торнов, Астафий Долгополов, И. Мамаев, Илья Аристов, хыянәтче дворян офицеры Михаил Шванович, Каранай Моратов, татар каһарманнары Канзафар Усаев һәм Идеркәй Мәхмүтов — барлыгы 40 ка якын кеше — «хакыйкатьне ачыклауда ярдәм итү өчен» Мәскәүгә китерелә. 18 ноябрьдән алып 5 декабрьгә кадәр алар-

ның һәркайсы тикшерүчеләр каршында Пугачев белән очраша, күрсәтмәләр бирә. 19 декабрьдә «тикшерү» тәмамлана. Генерал-прокурор А. Вяземский, генераллар П. Панин, А. Глебов, М. Мартынов, П. Потемкин, 10 сенатор, тагын әллә никадәрле графлар, кенәзләр катнашында 29—31 декабрьләрдә Мәскәү Кремленең тәхет залында (!) суд үткәрелә. 1775 елның 9 гыйнварында хөкем карары игълан ителә.

10 гыйнвар көнне власть вәкилләре обыватель һәм байларны Мәскәү каласының Сазлы (Болотная) мәйданына җыя. Дар агачлары һәм җәзалау мәйданчыклары инде әзер була. Көчле каравыл сагы астында мәйданга Пугачевны һәм аның көрәштәшләрен алып киләләр. «Законлы» хөкем карарын игълан иткәннән соң, җәзалау башлана. Пугачевның башын чабып өзәләр һәм биек колга өстенә кадап куялар. Гәүдәсен 4 кисәккә чабып Мәскәүнең төрле почмагына илтеп яндыралар. «Пугачевны тотып китерәм»,— дип Екатерина сөяркәсе генерал Г. Орловны алдаган Афанасий Перфильев та кисәкләргә чапкалап үтерелә. Гаепләрен танымаган һәм баш имәгән Максим Шигаев, 1774 елның 12 июлендә Казан төрмәсеннән азат ителгәч, янә «падишаһ»ка ияргән Вәлит Торнов, 1767 елгы Уложение комиссиясе депутаты буларак «кагылгысыз кеше» дәрәҗәсен алган, әмма «зыялы һәм гадел» Екатеринаның «закон»лы карары буенча үлемгә дучар ителгән Тимофей Падуров дарга асыла. Үлемгә хөкем ителгән Чика-Зарубин, шушы җәзалауларны карап торганнан соң, Уфага озатыла һәм 24 февраль көнне аның да гомере киселә.

«Падишаһ»ның үлемен карап торган, әмма «изге күңел»ле Екатерина тарафыннан «гафу ителгән» башка җитәкчеләр шушы ук көнне, шушы ук мәйданда чыбыркылар белән җәзалана, борыннары кисеп алына, маңгайларына һәм яңакларына «махсус» мөһерләр салына. Шуннан соң Тимофей Мясников — Себергә, И. Мамаев белән Идеркәй Мәхмүтов — Таганрогка, Илья Аристов — Ревельгә, ә Иван Почиталин, Максим Горшков, Илья Ульянов, Василий Плотников, Денис Караваев, Григорий Закладнов, Астафий Долгополов һәм Канзафар Усаев Балтыйк диңгезе буендагы Рогервик портына гомерлек каторга газапларын кичәргә озатыла. Рогервик партиясендәге тоткыннарны поручик А. Мәкъсүтов җитәкчелегендәге каравыл командасы озатып бара. Җәлладлар җәзалаганнан соң алган ялардан Закладнов белән Плотников 28, 29 гыйнварда Ревель каласында вафат булалар. Калган тоткыннарны, ниһаять, 31 гыйнварда Рогервик портына илтеп тапшыралар *(Р. Овчинников)*.

Пугачевның ике хатыны һәм балалары Ладога күле буендагы Кексгольм крепостена (хәзерге Приозерск шәһәренә) озатыла. 1803 елда патша Александр I «экскурсия» ясап йөргәндә, Пугачевның 5 якыны да әле исән була. Аларның соңгысы — Аграфена — 1833 елның 5 апрелендә шул ук Кексгольм крепостенда дөнья куя *(В. Сидоров)*.

Пугачевны карательләр кулына тотып биргән хыянәтче казаклар Творогов, Чумаков, Федулов, Бурнов, Коновалов, Пустобаев, Кочуров, Семен Шелудяков (соңгысы Пугачевка «баҗай» тиешле бәндә, ул Устинья Кузнецованың апасы Мариягә өйләнгән булган; бу очракта халыкның «кәҗә — хайван, баҗай туган түгел», дигәне, валлаһи, хак инде), Яков Почиталин (Пугачев сәркатибе Иванның әтисе), әлбәттә инде (!), патшабикә тарафыннан «гафу ителәләр». Алар өчен 11 гыйнвар көнне Мәскәүнең Иван мәйданында махсус указ укыла, ләкин аны тыңларга һәм хыянәтчеләрне күрергә бик аз кеше килә *(Н. Дубровин)*. Хыянәтче казакларның Җаек буенда озак яши алмаячакларын хөкүмәт үзе дә аңлый. Шуңа күрә хыянәтчеләр туган якларына кайтарылмый, бәлки Эстониядәге Пернава (Пярну) шәһәренә озатыла. Шунысын да өстик: әшәке җаннарның кайберсе әле 1803 елда да исән була *(Р. Овчинников)*.

Инде Мәскәү каласындагы «суд»тан тыш җәзага хөкем ителгән мөселман каһарманнарын да телгә алыйк. 1774 елның гыйнвар башында ук үз кул астына 3000 кешелек отряд туплап, Казанга һөҗүм итәргә хәзерләнгән полковник Мәсәгуть Гомәров генерал П. Потемкин җитәкчелегендәге Яшерен комиссия карары буенча туган төбәгенә озатыла. Җәлладлар аны Камышлы, Әсән-Елга, Пычак һәм башка авылларда чыбыркы белән кыйнап җәзалыйлар. Кукмара районында яшәгән риваятьләргә караганда, үзенең туган авылы Пычакта кыйналганнан соң, Мәсәгуть җәлладларның йөзенә төкерә. Шуның өчен җәлладлар аны ат койрыгына бәйлиләр һәм Әсән-Елга авылына кадәр җирдән сөйрәтеп баралар. Аннары ике күзен төртеп тишәләр, борынын кисәләр, маңгаена һәм яңакларына мөһер сугалар. Мәсәгуть шуннан соң гына Таганрогка каторга эшләренә озатыла. Аның карательләр тарафыннан кулга алынган әтисе Гомәр, абыйлары Мәгъсүт белән Мансур, хатыны Мәрфуга турында мәгълүматлар юк. Аларның җәлладлар кулыннан җәзасыз котыла алуы бик икеле.

Башкорт халкының батыр улы Салават Юлаев та нәкъ Мәсәгуть Гомәров кебек үк җәзага тартыла (димәк, патша җәлладлары аларның «гөнаһын»-батырлыгын бер үк дәрәҗәдә бәяли). Казан, Мәскәү, Оренбург, Уфа калаларына йөртеп 339 көн буена «тикшерү» үткәргәннән соң, Юлай Азналин — 140, Салават Юлаев 175 мәртәбә чыбыркы белән суктыруга хөкем ителә. 1775 елның июль — сентябрь айларында аталы-уллы ике каһарманны бер төбәктән икенчесенә йөртеп җәзалыйлар. 19 ноябрь көнне алар Рогервик зинданына илтеп тапшырыла. Ике халыкның бөек уллары Салават белән Канзафарның язмышы

биредә тагын бергә кушыла («Крестьянская война... на территории Башкирии»; *И.Гвоздикова, Р. Овчинников, В. Сидоров*).

Шушы ике каһарман үткән юлны хәзер янә бер мәртәбә күз алдыннан кичерик. Канзафар Усаев 1773 елның октябрь аенда ук, Бирдә бистәсенә барып, Пугачев гаскәренә кушылган. Салават Юлаев 10 ноябрь көнне генә 1200 кешелек отряд составында фетнәчеләр ягына чыккан. Декабрь аенда аларның һәр икесе полковник дәрәҗәсен алган һәм отрядлар туплау, фетнә ялкынын тарату өчен туган төбәгенә озатылган. Салават 12 гыйнвар көнне генә Красноуфимск каласына, анда да Бәхтияр Канкаев чакыруы буенча, һәм инде яуланган крепостька килеп җитә. Ә Канзафар отряды 6 гыйнварда Ачыт крепостен ала, 9 гыйнвар көнне Көнгер каласын камый. 18 е көнне генә биредә Салават пәйда була һәм 23, 24 гыйнварда алар бергәләп Көнгерне штурмлыйлар. Яраланган Салават 26 сы көнне туган авылы Тәкәйгә кайтып китә, Канзафар «юлбашчы» Иван Кузнецов тарафыннан кулга алына. Яз барышында һәр ике каһарман да яңа отряд туплый һәм 3 июнь көнне икесе бергә Пугачев белән кушыла. 5 июньдә Пугачев аларның икесен дә бер үк урында, бер үк сәгатьтә бригадир дәрәҗәләре белән олылый. Шуннан соң алар Уса шәһәренә кадәр бер үк юлны үтәләр. 23 июнь көнне Пугачев янә шушы ике каһарманны Уфа провинциясендә фетнәне дәвам итү өчен калдыра. Канзафар 26 июнь көнне үк Ногай юлына кайтып җитә, июль дәвамында 1000 кешелек отряд туплый, бу төбәкнең баш юлбашчысына әверелә, хәтта ерак Балык Бистәсе, Саба, Теләче районнарында хәрәкәт иткән Бәхтияр Канкаев белән дә бәйләнешкә керә, август башында аның янына тагын 1000 гә якын фетнәче килеп кушыла. Салават бу вакытта Себер юлында хәрәкәт итә һәм 1000 кешелек отряд туплауга ирешә. Алар икесе тиң Уфа каласына һөҗүм хәзерлиләр. Ләкин мишәр каһарманы Канзафар хыянәтче башкорт старшинасы Кыдрач Муллакаев тарафыннан мәкер юлы белән кулга алына. Ә башкорт батыры Салават 25 ноябрьдә хыянәтче мишәр старшиналары Мөхсин һәм Җәмгур Әбдесәламовлар кулына эләгә. Канзафар Рогервик портына 1775 елның 31 гыйнварында китерелә. Салават бирегә 19 ноябрьдә килеп җитә. Шуннан соң алар 25 ел (!) буена каторга газапларын бергә кичерә. 1797—1800 еллар арасында алар бергәләп Юлай Азналинны җирлиләр. 1800 елның 26 сентябрендә Салават 48 яшендә вафат була. Каторга шартларында да ясин укып, аны соңгы юлга Канзафар озата. Рогервик зинданында тотылган 11 фетнәченең соңгысы булып, 1804 елның 10 июлендә Канзафар Усаев үзе 66 яшендә вафат була («Крестьянская война... на территории Башкирии»; *И. Гвоздикова, Р. Овчинников, В. Сидоров*).

*Инде хәзер, хөрмәтле укучылар, укудан тукталыгыз да, зинһар, уйланыгыз һәм әйтегез: әлеге ике каһарманның көрәш юлы, гомумән, язмышлары игезәкләрнеке шикелле тәңгәл түгелмени? Валлаһи, бер ана балалары да һәм махсус «тырышкан» очракта да бу кадәр үк тәңгәл тормыш кичерә, бердәй батырлык кыла алмас иде. Ләкин менә башкорт батыры Салаватның исемен бөтен дөнья белә, ә аның «игезәге» — татар каһарманы Канзафар Усаевны искә алучы да юк. Шушы чагыштырудан соң үзенең батыр улларына төкереп караган татарга «и син, мескен милләт» дип әйтмичә түзү, гомумән, мөмкинмени?! Шул ук халыкның 220 ел дәвамында Пугачев явы турында татар телендә язылган бер генә китап та нәшер итмәвен искә төшергәч, «син үз улларыңнан фәкать коллар гына тәрбияләргә җыендыңмыни соң, татар?!» дип, йөз кат, мең кат кабатлыйсы килә...*

Ә хәзер татар гына түгел, бәлки башкорт колагына да тагын бер сүз ишеттерергә телибез. Кайчандыр, инде йөз еллар элек үк, башкорт даласында мондый кобаер туган:

...Салаватның тугры дуслары —
Кинҗә батыр белән Канзафар.
Кыйгыр-бөркет булып, яу кыйратып,
Мәлгунь дошманнардан көл ясар...

Әйе, гади халык татар белән башкортның бергәлеген-дуслыгын йөз еллар элек үк шулай раслаган. Чөнки татар белән башкорт әле 1552—1553 елларда ук урыс итеге астына бергә килеп кергән. Хәтта әнә һәр милләтнең символлары булырдай ике каһарман — Салават белән Канзафар да урыс патшасының бер үк зинданына бикләнгәннәр, 25 ел буе бергә, иңгә-иң торып газап чиккәннәр. Башкорт вәкиле дөньядан алдарак киткән, аннан соң гына татар вафат булган. Шушы факт үзе үк безгә, татар белән башкортка, язмыш кисәтүе булып тоелмыймы?

Безнең милләтләр бүген дә урыс империясе тарафыннан иза чигә. Әле Салават һәм Канзафар кебек иңгә-иң торып көрәшсәләр дә, аларның мөстәкыйль дәүләт төзи алуы бик икеле. Ә шул ук вакытта башкорт «зыялылары» арасында үз халкын татарга каршы котыртып ятучы «эшлеклеләр» дә бар. Уфада Әкрәм Бейеш, Асылгужа Багуманов кебек «даһи тарихчылар» табылган да, «Башкорт халкының тарихы һәм азатлык көрәше» дигән китапны нәшер итеп, алар татар халкы өстенә иң нәҗес пычракны өяләр. Имеш, татар халкы элек-электән үк илсез, җирсез, дәүләтсез, мәдәниятсез, кансыз, явыз, иң әшәке бер

милләт булган да, шулар гына 1236 елда килеп, 2 миллион булып исәпләнгән башкортларны 300 ел эчендә 200 меңгә калдырган икән. Җитди тәнкыйтькә, гомумән, игътибарга да лаек булмаслык шушы ялган Башкортстанда 30 мең (!) данә итеп таратылган. Надан укучының шул ялганны хакыйкать дип кабул итүе бар. Хурлык, оят! Мондый милләтчеләргә каршы тарихның 1800 елда ясалган символик кисәтүен генә кабатлыйсы килә. Урыс империясенең Рогервик зинданында әүвәл — башкорт, аннан соң гына татар вафат булган. Без бүген дә урыс коллыгында. Башкорт халкының саны бүген бер миллионнан артык, татарныкы — сигез миллион... Бергә кушылмасак, безне Салават һәм Канзафар язмышы көтә. Бу — сәясәт түгел, бу — тарих!

Ә тарих ул гел кисәтеп тора. Әнә сау-сәламәт һәм гаярь булган чакта Салават белән Канзафар, шулай ук Кинҗә, Каранай, Бәхтияр һәм Ярмөхәммәт тә аерым хәрәкәт иткән. Алар кирәк чакта бер йодрык булып туплана белмәгәннәр. Алай гына да түгел, шул бер-берсенә баш бирергә теләмәү дуамаллыгы татар белән башкортка фәкать бер юлбашчы үстерергә, һәр халыкка шул мөселман «пәйгамбәре» кул астына берләшергә комачаулаган. Хәер, моны без фәкыйрегез түгел, ә 1709 елның 10 мартында ук Казан губернасының беренче хакиме Петр Апраксин шул рәвешчә әйткән: «Башкорт халкы — күп санлы һәм яугир. Әмма алар, Дон казаклары шикелле, бер генә атаман астына туплана белми» («Материалы по истории Башкирской АССР», часть 1, док. №117). Апраксинга «шуңа күрә аларны бастыруы җиңел» дигән сүзләрне генә өстисе калган.

Патша генералы моннан 295 ел элек биргән бәяне бүген татар халкы да бер үзгәрешсез кабул итә ала. Сабак ала белмәгән милләтләр өчен тарих кабатлана. 1682 елгы Сәгыйть — Теләкәй, 1705 елгы Алдар — Күчем, 1735 елгы Акай — Килмәк, 1755 елгы Батырша, 1773 елгы Пугачев яулары чорында татар белән башкорт бер гаилә булып берләшә белмәгән. Зуррак отряд туплаган һәр җитәкче, кысла, аккош һәм чуртан шикелле, үз төбәгенең иминлеге яки үз мәнфәгате, үз мин-минлеге турында гына кайгырткан. Һәм менә бүген дә ирек өчен көрәштә татар белән башкорт аерым кыймылдый. Дистәләгән җәмгыять, партия, оешма җитәкчеләре, «зыялылар» үткән тарихны һәм булмаган тәхетне бүлешә, пыяла савыт эченә ябылган үрмәкүчләр шикелле берсен-берсе ашый. Татарны да, башкортны да һаман шул көнчелек, тар күңеллелек, таркаулык, ахыр чиктә наданлык эзәрлекли. Шуңа күрә мөстәкыйльлек, ирек үре бер йодрык булып туплана белмәгән татар-башкорт өчен һаман ерагая. Сызланудан авырткан йөрәкне басу өчен «Пугачау патша» турындагы җырны гына кабатлыйсы кала:

Пугачау патша бар диләр,  
Постау бишмәтләре тар диләр,  
Җаек та буе яу җирләрен  
Айкап та йөргән шул диләр.  
Пугачау патшаны күрсә идең,  
Алларыннан буй бөгеп узса идең,  
Аргамак менеп, дан тотып,  
Җаек яуларында йөрсә идең...

*КУШЫМТА*

# ПУГАЧЕВ КАҺАРМАННАРЫ

## *ПОЛКОВНИКЛАР ҺӘМ АТАМАННАР*

### 1. Канзафар Усаев (Ханзәфәр Усейнов)

1738 елда Уфа өязенең Чакмагыш авылында туган, 1757 елдан соң Бозаязга (Кырмыскалы районында) күчкән. Канзафар әүвәл шунда мулла, аннары йөзбашы (100 хуҗалык өстеннән башлык) булып торган, урыс һәм татар телләрен яхшы белгән.

Оренбург губернаторы И. Рейнсдорптан башкорт-мишәр җайдакларын Пугачевка каршы туплау турында фәрман килеп төшкәч, бозаязлылар да Эстәрлетамак пристанена бара. Мишәр старшинасы Ягъфәр Күчүкәев һәм 6 иптәше белән бергә Канзафар шуннан Бирдә бистәсенә кача. Анда Кинҗә Арысланов белән бергә Хәрби коллегиядә сәркатип вазифаларын башкара. Берничә мәртәбә Оренбург янындагы бәрелешләрдә катнаша. Шуларның берсендә батырлык күрсәтеп, полковник дәрәҗәсенә лаек була.

Бирдә бистәсендә бер ай чамасы торганнан соң, Пугачев аны 8 иптәше белән бергә Көнгер өязендә отряд туплау һәм крестьяннарны фетнәгә кутәрү өчен озата. Туган ягына кайткач, декабрь дәвамында Канзафар 500 кешелек отряд туплауга ирешә һәм Көнгергә юнәлә. Ул 1 гыйнварда Богородское авылын ала, шундагы вак сәүдәгәр Иван Белобородов өендә төн үткәрә һәм аны «падишаһ казаклары»ның йөзбашы

итеп билгели. Юл уңаенда Канзафар тагын Ырга һәм Шуртан заводларын кулга төшерә. Белобородовка атаман дәрәҗәсен, 160 ка якын «сугышчы» бирә һәм аны Бисерт заводын штурмларга озата. Үзе 6 гыйнвар көнне хәйлә белән Ачыт крепостен алуга ирешә, комендант капитан Воиновны дарга астыра. Ул крепость атаманы итеп керәшен татары Иван Аширминны билгели.

8 гыйнвар көнне Канзафар отряды Суксун заводын ала, крестьяннарның 54 мең сумлык «бурыч» кәгазьләре юкка чыгарыла. 9 гыйнварда ул Көнгер каласы янына килеп җитә һәм Батыркай Иткинин отряды белән кушыла. Фетнәчеләр шул көнне үк бергәләп штурмга ташланалар. Әмма подполковник А. Папава карательләре аларны чигенергә мәҗбүр итә. 11,15 гыйнварда яңа бәрелешләр булып уза.

18 гыйнварда Көнгер янына Салават Юлаев отряды, 20 сендә «барча азиат гаскәрләренең юлбашчысы» Иван Кузнецов килеп җитә. 23 гыйнварда 4 мең фетнәче Көнгерне бердәм штурмлауга ташлана, ләкин бу һөҗүм дә уңышсыз чыга. 24 ендә Канзафар һәм Салават отрядлары янә һөҗүмгә ташланып карыйлар, әмма туплар уты астында кире чигенәләр.

26 сы көнне фетнәчеләр Көнгергә соңгы тапкыр һөҗүм ясый. Секунд-майор Д. Гагрин һәм А. Папава отрядлары бу юлы да сугыш тәҗрибәсе булмаган крестьяннарны куып тарата. Яраланган Салават туган авылы Тәкәйгә (Юлайга) кайтып китә. Ә «юлбашчы» исемен акламаган Иван Кузнецов Канзафарны кулга алдыра һәм Чесноковка лагерендагы Иван Зарубин янына хөкемгә озата. Гаҗәп хәл: Алтынное авылын узып киткәч, богауланган Канзафар ниндидер хәйлә белән качып котыла. Ул, озын юллар узып, Бирдәгә Пугачев янына хакыйкать эзләп бара. Пугачев аны 7 иптәше белән бергә янә Уфа провинциясенә җибәрә. 23 мартта Канзафар Чесноковкага Чика-Зарубин янына килеп төшә. Әмма 24 ендә Чесноковкага подполковник Иван Михельсон корпусы һөҗүм ясый, Канзафар карательләр кулына әсирлеккә төшә. Ялган үкенү күрсәтеп, антлар биреп, Канзафар Михельсонны алдауга ирешә һәм ирекккә җибәрелә. 5—10 апрельләр тирәсендә Канзафар Бозаязга кайта һәм, «янарал Фрейман кушты» дип, мишәр старшиналары Мөхсин Әбдесәламов белән Ишмөхәммәт Сөләймановтан 500 кешелек отряд таләп итә. Ялган барып чыкмый, мишәр старшиналары Канзафарны тагын богаулаталар да Уфа каласына озаталар. Гаҗәпнең дә гаҗәбе: юлда Канзафар янә качып китә.

Апрель ахырында һәм май дәвамында Канзафар Уфа өязенең Ногай, Себер юлларында хәрәкәт итә, яңа отряд туплый. Канзафар туплаган әлеге (икенче) отрядтагы фетнәчеләрнең саны төгәл билгеле түгел, шулай да аны 1000 гә генә тиңләргә тулы нигез бар. Канзафар әнә шул көч белән 1—2 июньдә Кыйгы районына килеп җитә, анда Салават отряды белән кушыла. 2 се көнне кич бирегә «падишаһ» үзе дә килеп җитә.

3 июньдә фетнәчеләрнең берләштерелгән отряды Әй елгасы ярында Михельсон корпусына һөҗүм ясый. Әмма яу барышында 400 крестьян һәлак була, Пугачев Әй аръягына чигенә. 5 июньдә Михельсон янә бер мәртәбә Пугачев отряды белән бәрелешкә керә. Ләкин Михельсон бер төрле уңышка да ирешми, карательләрнең көчсезләнгән отряды Уфа каласына кайтып китә. Шуннан соң, билгеле инде, фетнәчеләр тантанасы башлана.

5 июнь кичендә Пугачев Канзафар белән Салаватның икесенә дә бер үк урында, бер үк минутта бригадир дәрәҗәләре бирә. Шуннан ары Канзафар да, Салават та «падишаһ» белән бергә хәрәкәт итәләр. 11 ендә Красноуфимск каласын, 18—21 июньнәрдә Усаны алуда катнашалар. 23 июнь көнне Кама елгасы аша кичкәндә, Пугачев Канзафарны, җиңелчә яраланган Салаватны һәм тагын 4 полковникны Уфа провинциясендә фетнәне дәвам итү өчен калдыра.

26 июньдә Канзафар Ногай юлына кайтып төшә, шул ук көнне әлеге юлдагы башкортларның баш старшинасы Галибай Морзаголовка, татар старшиналары Ибраһим Уразбахтин белән Мәгъсүт Морзакаевка отрядлар таләп иткән хатлар юллый. Гәрчә Ногай юлындагы башкорт старшиналарының бик күбесе бу вакытка инде фетнәдән читләшкән булса да, алар бик тиздән «падишаһ» бригадирына буйсына башлый. Чөнки Канзафар үзе бу көннәрдә гаять зур активлык күрсәтеп хәрәкәт итә, Ашказар, Бозаяз, Үршәк елгалары буеннан тиз арада 1000 кешелек (инде өченче) отряд туплый. Канзафар бөтен Ногай юлындагы фетнәчеләрнең юлбашчысына әверелә. Шуның басымы астында башкорт старшиналары да фетнәгә кушылалар һәм 5 июльдә Эстәрлетамак пристане янында генерал П. Голицын корпусына һөҗүм итәләр. Ни үкенеч, Голицын карательләре бу юлы да мөселман фетнәчеләрен куып тарата. 17 июльдә башкорт старшиналары янә милли-азатлык көрәшенә хыянәт итә, алар генерал Голицын каршына барып гафу үтенәләр.

Татар каһарманы Канзафарның барыбер рухы сынмый. 20 июльләр тирәсендә ул үзенең 1000 кешелек отряды белән Дим, Авыргазы, Үршәк, Үзән елгалары буенда хәрәкәт итә, авыллардан крестьяннарны кушып отрядын зурайта. Ул, барча мөселман отрядларын бергә туплап, Уфага һөҗүм итәргә әзерләнә башлый. Шул максат белән Салават Юлаев, Селәүсен Кинзин, Каранай Моратов, хәтта Кама аръягында, бүгенге Татарстан җирендә көрәш алып барган Бәхтияр Канкаев янына да чапкыннар юллый. 1 августтан

соң Канзафар янына старшиналар Ибраһим Мерәсев, Габдессәлам Мәмдәлев, Мәгъсүт Морзакаев, Ибраһим Уразбахтин, полковник Моратшаһ Сыртланов отрядлары килеп кушыла, фетнәчеләр саны 2000 гә җитә. Салават белән Селәүсеннән дә уңай җавап килә. Канзафарның иңнәренә канат үскәндәй була, ул саклану турында бөтенләй оныта.

Шушы хәлдән хыянәтче башкорт старшинасы Кыдрач Муллакаев оста файдалана. 3 август кичендә ул, ялган вәгъдәләр биреп, Канзафарны очрашуга чакыра. Канзафар үзе белән 2 генә мишәр крестьянын алып юлга ашыга. Бишбүләк районындагы Ермолкино авылы янында Кыдрач аны кулга ала, 2 мишәр крестьяны хыянәтчеләр ягына чыга. 4 августта Кыдрач инде Канзафарны Бөгелмә крепостенда торучы полковник Н. Кожин кулына илтеп тапшыра. Канзафарны зинданга ыргыталар, ә ул төзеп калдырган отряд әле сентябрь ахырына кадәр карательләргә каршы сугышып йөри.

Аннары Канзафарны Казан төрмәсенә күчереп газаплый башлыйлар. Шуннан Пугачевның иң якын көрәштәше һәм фетнәнең иң күренекле җитәкчеләренең берсе сыйфатында Мәскәүгә «падишаһ җинаятьләре» буенча күрсәтмәләр бирергә озаталар. 18 ноябрьдән 5 декабрьгә кадәр булган көннәрнең берсендә Канзафар тикшерүчеләр каршында Пугачев белән янә бер мәртәбә очраша. 31 декабрьдә фетнәчеләргә хөкем карары чыгарыла.

10 гыйнварда башка юлбашчылар белән бергә Канзафарны да Мәскәү шәһәренең Сазлы мәйданына китерәләр. Мишәр фетнәчеләренең юлбашчысы Канзафар җәлладларның Пугачевны җәзалап үтерүен карап тора. Аннары шунда ук Канзафарның үзен дә чыбыркылар белән җәзалыйлар, борынын кисәләр, маңгаена һәм яңакларына кыздырылган тимер белән мөһерләр сугалар. Канзафар шуннан каторга газапларын кичәргә озатыла. 1775 елның 31 гыйнварында ул Рогервик (хәзерге Палдиски) зинданына илтеп ябыла. Шул ук елның 19 ноябрендә бирегә Салават Юлаев белән Юлай Азналин да китерелә. Өч мөселман, иңгә-иң торып, 25 ел буе бергә каторга михнәтләрен кичә. 1797—1800 еллар арасында Юлай, 1800 елның 26 сентябрендә Салават вафат була. Аларның һәр икесен Канзафар ясин укып соңгы юлга озата. Ә үзе, пугачевчы тоткыннар арасындагы иң соңгы кеше булып, 1804 елның 10 июлендә дөнья куя. («Документы ставки...»; «Воззвания...»; «Крестьянская война... на территории Башкирии»; *Ә. Әсфәндияров, Р. Овчинников, В. Сидоров, И. Гвоздикова*; ЦГАДА, 6 фонд, 428 эш). *Салават «башкортларның баш полковнигы» дәрәҗәсенә ия булмаган, мәгәр аны бөтен дөнья белә. Ә «мишәр гаскәрләренең юлбашчысы» дигән дәрәҗәне йөрткән Канзафар Усаев турында бер мәкалә (!) язучы да юк!..*

*ЧАГЫШТЫРУ ӨЧЕН*

### *Салават Юлаев*

Соңыннан дөньядагы бердәнбер очрак буларак республика кадәр республиканың туграсына төшereләчәк каһарман, башкорт халкының буыннардан буыннарга күчеп килгән байрагы Салават Юлаев 1752 елда Уфа провинциясендәге Шайтан-Көзәй волостеның Тәкәй авылында туа. Аның әтисе Юлай Азналин төрле сугышчан походларда катнаша, 1768 елда шушы волостьның старшинасы итеп сайлана. Аңа башкортларның 115 йорты (хуҗалыгы, утары) буйсына *(И. Гвоздикова).*

Пугачев фетнәсе турындагы хәбәр Уфа провинциясенең Себер юлына 1773 елның октябрь аенда килеп ирешә. Оренбург губернаторы генерал Рейнсдорп, Уфа һәм Исет провинцияләреннән 5000 кешелек мишәр һәм башкорт отряды туплап, Оренбургка җибәрергә әмер бирә. Юлай Азналин үзенә буйсынган йортлардан 80 ир-егетне (икенче төркем документларда 95 кеше) хәрби походка әзерли, алар өстеннән башлык итеп үзенең улы Салаватны билгели. Җайдаклар Эстәрлетамак пристанена кадәр булган 400 чакрым араны 15 көн буена киләләр. Эстәрлетамакта Рейнсдорп күрергә хыялланган 5000 урынына 2355 кенә җайдак җыела. Алар патшабикә офицеры капитан И. Ураков, Ногай юлының баш старшинасы Галибай Морзаголов, старшина Качкын Самаров җитәкчелегендә, ике төркемгә бүленеп, ноябрь башында гына Оренбургка таба юлга чыгалар һәм Бөгелмәдән хәрәкәт итүче генерал-майор В. Кар отрядлары белән Биккол авылы янында бергә кушылырга тиеш булалар. Ләкин 7—9 ноябрьләрдә Кар корпусын Пугачев атаманнары Андрей Овчинников, Иван Чика-Зарубин, татар каһарманы Идеркәй Мәхмүтов җитәкчелегендәге фетнәчеләр гаскәре тар-мар итә. Шөбһәгә калган И. Ураков, баш старшина Г. Морзаголов җитәкчелегендәге, составында Салават Юлаев та булган 1200 кешелек отряд 10 ноябрь көнне «үз теләге белән» Пугачев ягына чыга. 11 ноябрьдә К. Самаров җитәкчелегендәге икенче отряд та «падишаһ»ка кушыла.

Салават Бирдә бистәсендә хезмәт итә башлый, Оренбург гарнизоны белән фетнәчеләр арасында барган көндәлек бәрелешләрдә катнаша. Бер яу барышында аның җилкәсе, кулы һәм яңагы яралана, ләкин нindидер батырлык күрсәтеп өлгерә. Салават турында «падишаһ» шәхсән үзе ишетә һәм яшь батырны

полковник дәрәҗәсе биреп олылый. Гаҗәп: бер документта бу хәл «падишаһ» Салаватка полковник дәрәҗәсен «аның командасындагы башкортлар үтенече буенча бирде» дип бәяләнә («Крестьянская война 1773—1775 гг. на территории Башкирии»; *И. Гвоздикова, В. Буганов һ.б.*). Ә Пугачев әле Каргалы бистәсендә чагында ук фетнәчеләргә килеп кушылган Кинҗә Арысланов бу вакытта инде «падишаһ» штабында хезмәт итә һәм «барча башкорт гаскәрләренең юлбашчысы» дигән исемгә лаек була.

Декабрь башында Пугачев башка төбәкләрдә дә фетнә уты кабызу өчен Канзафар Усаев, Каранай Моратов, Качкын Самаров, Вәлит Торнов, Бакый Абдуллов кебек берничә полковник һәм старшинаны Красноуфимск, Көнгер, Уфа, Бөгелмә, Минзәлә, Сарапул төбәкләренә юллый. Яраланган Салават үзенең туган ягы — Себер юлына кайтарып җибәрелә. Декабрь ахырында Салават үзенең кул астына берничә йөз крестьянны туплауга ирешә, аңа бу эштә этисе Юлай да ярдәм күрсәтә.

Салават отрядына азатлыкка сусаган башкортлар да, татарлар, удмуртлар һәм марилар да кушыла. Себер юлында яшәгән 19 старшинаның 7 се үзләре туплаган кечкенә отрядлар белән Салаватның кул астына килеп баса. Татар халкы вәкилләре Габдулла Туктаров, Сөләйман Күскәев, Чүрә Рәсүлов Салаватның иң якын ярдәмчеләренә әвереләләр. Башкорт старшинасы Илчегол Иткулов, мари старшинасы Каникей Яшпохтин Салават белән иңгә-иң торып яуларда катнашалар. Дөрес, башкорт старшиналары Колый Балтачев, Хәлил Якупов, мишәр старшинасы Солтанморат Янышев кебек Салават отрядына каршы көрәшүче байлар — өстен, изүче сыйныф вәкилләре дә бик аз булмый.

Декабрь ахырында Салават 800 кешелек отряд  белән Красноуфимск каласына юнәлә. Әмма Салават барып җиткәнче үк, 1774 елның 9 гыйнварында бу каланы Пугачев тарафыннан әлеге төбәккә юлланган икенче бер эмиссар — мишәр каһарманы Бәхтияр Канкаев яулап ала. Шушы ук районда Пугачев полковниклары Әбди Абдуллов, Батыркай Иткинин, Гадел Ишменев (Ишмәтов) отрядлары да хәрәкәт итә. Шулай ук нәкъ 9 гыйнвар көнендә Көнгер каласына татар каһарманы Канзафар Усаев отряды килеп җитә һәм крепостька кереп бикләнгән җәзачылар белән туктаусыз бәрелешләр алып бара башлый.

Красноуфимск крепостен алганнан соң, фетнәче отрядларның башлыклары, старшиналар Бәхтияр Канкаев, Илчегол Иткулов, Собхангол Килтәков, бирегә таба Салават Юлаев җитәкчелегендәге җайдакларның хәрәкәт итүен белеп, каладагы чиркәүнең 19 яшьлек пономаре Макар Попов белән Әвләзи Саккуловны аларны каршылау һәм шәһәргә чакыру өчен 110 чакрымдагы Котыш авылына озаталар. 12 гыйнварда үзенең отряды белән Салават Красноуфимск каласына килеп җитә. Үзенең хәрби дәрәҗәсе буенча Бәхтияр Канкаев, Илчегол Иткуловларга караганда югарырак булганга күрә, шәһәр белән шундук Салават җитәкчелек итә башлый. 13 гыйнварда ул 19 яшьлек Макар Поповны калада яшәүче казаклар тарафыннан сайлап куелган бистә ызбасының — Красноуфимскидагы идарә органының башлыгы итеп билгели. Казак хезмәтендә 20 еллык тәҗрибәсе булган йөзбашы М. Чигвинцев Поповның ярдәмчесе итеп тәгаенләнә.

Мөселман халкын гомер-гомергә үзара килешә һәм берләшә белмәү, көнчелек һәм ызгышу кебек яман гадәтләр эзәрлекләгән. Шушы яман чирдән арына белмәгәнгә күрә, безнең мәмләкәттәге һәммә мөселман милләте кол хәленә төшкән. Шушы ук тискәре, яман гадәт үзен әлеге Красноуфимск төбәгендә дә сиздерә, мөселман отрядларының башлыклары, юк кына сәбәпләр аркасында, үзара тарткалаша, ызгыша башлый. Бу хактагы хәбәрләр Пугачев фетнәсенең икенче төп үзәге булган Чесноковка авылына да (Уфадан 12 чакрым ераклыкта) барып ирешә. Пугачевның иң ышанычлы ярдәмчеләреннән берсе — Чесноковкадагы фетнәчеләр башлыгы Чика-Зарубин, Красноуфимск тирәсендәге мөселман җитәкчеләре арасында туган ызгыш-талашны туктату максатыннан, бу төбәккә үзенең эмиссарын юллый. Әмма «азиат гаскәрләренең төп юлбашчысы» дигән дәрәҗә астында Красноуфимскига килеп төшкән Табын казагы, Пугачев бригадиры Иван Кузнецов та отряд җитәкчеләре арасындагы башбаштаклыкны киметә алмый, хәтта, киресенчә, ул килгәннән соң биредәге таркаулык җәелә генә төшә. Чөнки мөселман батырлары, билгеле инде, үзләре өстеннән «гади» Табын казагының юлбашчы итеп җибәрелүен кабул итми, Кузнецовны йөз чөереп кенә каршылый.

Мөселман батырлары, 15 гыйнварда Красноуфимскины калдырып, хәзер инде бөтен көчне Көнгер каласын алуга туплыйлар. Канзафар Усаев, Салават Юлаев, Гадел Бигашев, Илчегол Иткулов, Сөләйман Күскәев отрядлары — һәммәсе дә дүрт мең кешелек көч белән 18 гыйнварда Көнгерне яңа камалышка ала. 19 гыйнварда шушы ук отряд башлыклары, күмәк рәвештә кул куеп, Көнгер каласы хуҗаларына «падишаһ» гаскәрен шәһәр капкаларын ачып каршыларга тәкъдим ясаган хат та юллап карыйлар. Ләкин бу вакытта инде шәһәр гарнизонына ярдәмгә подполковник А. Папава җитәкчелегендәге 500 кешелек хөкүмәт отряды да килеп кушылган була. Хатны китерүче казак И. Дружининны Көнгер офицерлары зинданга ябып куя.

20 гыйнварда Көнгер янына «азиат гаскәрләренең төп юлбашчысы»  Иван Кузнецов килеп җитә. Салават белән алар Иске Посад (Троицкое) авылында очрашалар. Шушы ук көнне Кузнецов инде шәхсән

үз исеменнән Көнгер офицерларына корал ташларга һәм капкаларны ачарга чакырып хат яза. Аңа мөселман җитәкчеләре арасыннан фәкать 2 кеше — Салават белән Гадел Бигашев кына кул куялар. Ләкин шәһәр капкалары барыбер ачылмый.

23 гыйнварда барча фетнә отрядлары шәһәргә бердәм һөҗүм башлый, кайбер отрядлар шәһәр урамнарына да бәреп керә, тик ахырда барыбер кире чигенергә мәҗбүр була.

24 гыйнварда Салават белән Канзафар Усаев отрядлары янә бер мәртәбә шәһәрне штурмлап карый, әмма җиңү килми, җитмәсә дошман пулясы Салаватның аягын яралый.

25 гыйнварда, фетнә җитәкчеләре арасында ызгыш барган чакта, шәһәрдәге гарнизонга ярдәмгә секунд-майор Д. Гагрин җитәкчелегендә килгән 400 кешелек яңа җәза отряды үтеп керә. 26 гыйнварда фетнәчеләр һәм инде көчәйгән гарнизон арасында яңа бәрелеш башлана. Гарнизон, шәһәрдән чыгып, фетнәчеләрне кылыч белән тураклый башлый. Пугачевчылар якын-тирәдәге авылларга чигенә.

Аягы яраланган Салават, отрядын старшина Чүрә Рәсүловка *(Ә. Фатыйхов «Гайнә иле» китабында язуынча, Чүрә фетнәгә кадәр Гайнә волосте татарларының старшинасы булып торган, 35 яшьтә)* калдырып, туган авылына кайтып китә. Көнгерне штурмлап бернинди уңышка да ирешә алмаган Иван Кузнецов, Канзафар Усаевны кулга алып, Чесноковкага озаттыра. Мондый «үрнәк» башка «бөекләргә» дә йога башлый. Чика-Зарубинның писаре сыйфатында йөргән Иван Суконников, Ордынское авылы янындагы бәрелештә куркаклык күрсәткәне өчен дигән булып, 30 гыйнварда старшиналар Чүрә Рәсүлов белән Собханкол Килтәковны кулга ала һәм Демидовның Суксу заводына илтеп зинданга бикли. Җәзачылар соңыннан бу ике батырны шушылай, куллары богауланган көе кулга төшерәләр һәм аяусыз газаплаулардан соң, Көнгер каласына илтеп, 17 февраль көнне асып үтерәләр.

Салаватның таркатылган отряды Красноуфимскига таба чигенә, аның белән хәзер полковник Ишмән Иткулов *(Ә. Фатыйхов китабы буенча ул Көнгер өязе татары)* җитәкчелек итә башлый. Аларны Д. Гагрин белән А. Папава командалары эзәрлекләп килә. 19 февральдә шәһәр янындагы кырда башланган яуда Ишмән Иткулов та хыянәтче казаклар тарафыннан үтерелә. Салават отряды, Уфа елгасының аръягына чигенеп, Красноуфимскидан 40 чакрым ераклыктагы Богалыш авылында лагерь корып урнаша.

Бу вакытта Салават та туган авылында тыныч кына ятмый. Үзе яралы булса да, ул татар есаулы (йөзбашы) Иләтбай Илимбаевны, яңа көчләр туплау өчен, Себер юлына озата.

Салават үзенең отрядына февраль ахырларында гына әйләнеп кайта. Шәхсән үзе, Сарапул волостена барып, андагы авыллардан «патша» гаскәре өчен яңа «казаклар» җыя башлый. Тиздән аның отрядына 2000 чамасы кеше туплана. Шул көч белән ул 12 мартта Красноуфимск каласына юнәлә. Бу вакытта Гагрин белән Папава полклары, фетнәчеләрне эзәрлекләп, Себер һәм Уса юлларына киткән булу сәбәпле, шәһәрдә Салават гаскәренә каршы торырлык көчләр табылмый. Салават калага яусыз-нисез диярлек килеп керә.

Красноуфимскиның янә Салават кулына төшүен ишетеп, подполковник Папава ашыгыч рәвештә Көнгер каласыннан чыга һәм фетнәчеләргә каршы юнәлә. 14 мартта Красноуфимскидан 2 чакрым ераклыктагы кырда яңа яу башлана. Ул 3 сәгать буена дәвам итә. Фетнә отрядларыннан берсенең җитәкчесе — калмык вәкиле Осман яуда һәлак була. Папава полкы җиңүгә ирешә һәм каланы янә үз кулына төшерә. Салават Богалыш авылына чигенә, аны Папава эзәрлекләп бара. 17 мартта Богалыш авылы янында кабат зур бәрелеш куба. Салават җәзачыларны 1500 кешелек көч белән каршылый, сугышчыларын вак-вак төркемнәргә бүлеп, аларны печән төялгән 30 дан артык олаулар артына яшереп куя. Әмма бу юлы да нигездә сәнәк-чалгы белән коралланган крестьяннар тупларга каршы тора алмыйлар. Салават Әй елгасы буена чигенергә мәҗбүр була. Үзе үткән һәр авылдан отрядына яңа сугышчылар туплый. Себер юлына озатылган татар есаулы Иләтбай Илимбаев берүзе генә дә 23 март көнне Сала- ват янына 163 яңа сугышчы җыеп алып кайта *(И. Гвоздикова)*.

Әмма нәкъ менә шушы көннәрдә Пугачев армиясе коточкыч җиңелүләр кичерә. 22 мартта Татищево крепостенда, 2 апрельдә Бирдә бистәсе белән Сакмар елгасы арасында Пугачев үзе, 23 мартта восстаниенең икенче үзәге булган Чесноковка лагеренда Чика-Зарубин гаскәрләре карательләр тарафыннан тулысынча тар-мар ителә. Билгеле, бу хәбәрләр Уфа провинциясенә дә барып ирешә, фетнәчеләр арасында тәшвиш кузгала. Җитмәсә, елгаларда да язгы ташулар башлана, юлларда хәрәкәт бикләнә. Шулай да Салават, Урал таулары ягына таба хәрәкәт итеп, март ахырында Сатка заводы янындагы Кызылбай авылында Пугачев атаманы, әллә ни гомер элек түгел, әле 1 гыйнвар көнне генә татар каһарманы Канзафар Усаев тарафыннан отряд башлыгы итеп озатылган, аннан соң завод арты заводлар яулаган Иван Белобородов белән очраша. Шуннан соң алар бергәләп Красноуфимск белән Көнгер ягына таба хәрәкәт итә башлыйлар.

24 апрельдә Уфадан Себергә таба подполковник И. Михельсон командалыгындагы җәзачылар корпусы юлга чыга, «песи-тычкан уены» башлана. Бу вакытта үзенең кул астына 3000 кешелек отряд туплап өлгергән Салават җәзачыларны Сим заводы янында каршылый. 7 майда заводтан 17 чакрым ераклыктагы

яланда беренче бәрелеш булып уза. Салават җиңелә һәм Ерал авылына таба чигенә. 8 майда Михельсон һәм Салават отрядлары янә бәрелешә. Фетнәчеләр үз-үзләрен аямый сугышса да, Салават тагын чигенергә мәҗбүр була. Михельсон Сатка заводына таба үтеп китә. Шыганай авылы яныннан әйләнеп, Салават исә Сим заводына кайта. 23 майда фетнәчеләр, Сим заводына ут төртеп, аны юкка чыгаралар. Шуннан соң Салават Катау-Иван заводына юнәлә. Ләкин аны тагын Михельсон корпусы куып килә.

Салават Михельсонны Сим заводыннан 30 чакрым ераклыкта, Әй елгасы ярында көтеп ала. Җәзачылар елганың икенче як ярында, фетнәчеләргә капма-каршы урында тезеләләр. Михельсон отряды елганы кичә алмасын өчен, Салават көймә һәм паромнарны алдан ук яндырып куйган була. Ләкин туплардан көчле ут ачып, Михельсон фетнәчеләрне яр буеннан чигендерә. Шул туп уты астына ышыкланып, җәзачылар елганы бик уңышлы рәвештә кичеп тә чыга. Салават янә Урал тауларына таба чигенергә мәҗбүр була. 31 майда янә бер бәрелеш булып ала, һәм бу юлы да Михельсон уңышка ирешә.

1—2 июньдә Әй елгасы буенда Салават татар каһарманы Канзафар Усаев отряды белән кушыла. 2 июньдә бирегә Пугачев үзе дә төп гаскәре белән килеп җитә. Шул көнне кич Кыйгы авылы янында Салават белән Канзафар «падишаһ» гаскәренә барып кушылалар.

3 июньдә Пугачев, Салават, Канзафар кул астындагы фетнәчеләр, инде бергәләп, янә яннарына килеп җиткән Михельсон отрядына каршы яуга керәләр. Сугыш көне буе дәвам итә, яуда 400 чамасы фетнәче һәлак була, әле бер, әле икенче як өстенлеккә ирешә, ләкин җиңү яулый алмый. 5 июньдә Әй елгасы буенда Пугачевның берләштерелгән гаскәре белән Михельсон отряды тагын бер яу башлап карыйлар, ләкин бу бәрелеш тә нәтиҗәсез тәмамлана. Әмма йөзләрчә чакрым юл үткән һәм байтак җәзачыларын югалткан Михельсонның Пугачевны тагын да эзәрлекләрдәй көч-куәте калмый, ул, үз отрядын тулыландырам дигән сылтау белән, Уфа каласына кайтып китә.

Эшләрнең мондый борылыш алуы белән канатланган Пугачев 5 июнь көнне кич Әй елгасы буенда олы тантана үткәрә. Ул үз янына отрядлар туплап килгән, яулар барышында батырлыклар күрсәткән старшиналарга яңа хәрби дәрәҗәләр өләшә башлый. Салават Юлаев белән Канзафар Усаев бригадир дәрәҗәләренә лаек була. Бу хәрби дәрәҗәләрнең тасмаларын «падишаһ» шәхсән үзе батырларның иңнәренә кидерә. Салаватның уң кулы — татар каһарманы Габдулла Туктаровка полковник дәрәҗәсе эләгә. Салаватның атасы Юлай Азналин Себер юлындагы волостьларның баш атаманы булып йөри башлый. Үз чиратында, Салават та башка ярдәмчеләрен яңа хәрби дәрәҗәләр белән олылый.

Шуннан соң Салават та, Канзафар да вакытлыча Пугачевның төп гаскәре составында хәрәкәт итәләр. Пугачевның бөтен Рәсәй буйлап җәеләчәк җиңү маршы башлана. Пугачев гаскәре составында иң алда, авангард булып, Салават отряды бара. 10 июньдә фетнәчеләр тагын бер мәртәбә Красноуфимск каласын алалар. 11 июньдә Ачыт крепосте янында подполковник А. Папава җитәкчелегендәге җәзачылар отряды белән бәрелешкә керәләр һәм аны 20 чакрым буе эзәрлекләп баралар.

14 июньдә Б. Иткинин тарафыннан Кама буендагы Уса крепостен штурмлау башлана. Беренче һөҗүмнәр нәтиҗәсез тәмамлана, фетнәчеләр башка калаларга һөҗүм башлаудан тыелып тора. Җитмәсә, 18 июньдә крепость гарнизонына ярдәмгә Казаннан секунд-майор Ф. Скрипицын командалыгындагы өстәмә отряд килеп кушыла. 18—20 июнь көннәрендә Пугачевның шәхси җитәкчелегендә яңадан-яңа һөҗүмнәр оештырыла. Бер яу барышында Салаватның аягы яралана. Фетнәчеләр 21 июньдә, гарнизон үз теләге белән бирелгәннән соң гына, Уса каласын алуга ирешәләр.

23 июньдә Пугачев инде, Кама елгасын кичеп, Ижевск һәм Воткинск заводларына, Казанга таба юнәлә. Яраланган Салаватны, күренекле бригадир Канзафар Усаев белән бергә, Пугачев, фетнәчеләр гаскәренә өстәмә көч туплау, җәза отрядларын тоткарлау өчен, Уфа провинциясенә озата.

Салават июль аенда ук яңа отряд туплап өлгерә. Ул нигездә Себер юлындагы җәзачыларга каршы сугыш алып бара. Уфа провинциясендә калдырылган фетнә башлыклары Салават Юлаев, Канзафар Усаев, Качкын Самаров, Туктамыш Ишбулатов, Селәүсен Әдҗәтиров, Ибраһим Уразбахтин июль ахырында, бөтенесе бергә берләшеп, Уфа каласына һөҗүм ясарга план коралар. Ләкин фетнә башлыкларының нияте җимерелә. Канзафар Усаев сатлык башкорт старшинасы Кыдрас Муллакаев тарафыннан август башында мәкерле рәвештә әсирлеккә алына. Шуннан соң башка юлбашчылар Уфага һөҗүм ясау ниятеннән кире кайта.

Август ахырында, сентябрь башында Салават Катау-Иван заводы янында тора. Сентябрь уртасында Салават Семен Шеметов, Әбдеҗәлил Рыскулов, Арыслан Рангулов, Бүләк Якупов, Әбделсәлам Рәмзин, Аладин Биктуганов отрядлары белән бергә кушыла, һәм фетнәчеләрнең гомуми саны 3 мең кешегә җитә.

Провинциянең төньягында хәрәкәт итүче фетнәчеләр гаскәренә каршы 13 сентябрьдә Уфадан подполковник И. Рылеевның җәзачылар командасы чыга. 18 сентябрьдә Уфадан 90 чакрымдагы Тимошкино авылы янында Салават җайдаклары көтмәгәндә Рылеев отрядына һөҗүм ясыйлар. 22 сен-

тябрьдә шушындый ук яу Нөркәй авылы янында булып уза. Бу яу озын көн буена сузыла, әмма 400 гә якын көрәштәш- ләрен югалтып, фетнәчеләр чигенергә мәҗбүр булалар.

Салават бу юлы Елдәк крепостена таба чигенә. Ләкин 24 сентябрьдә крепостька Рылеев отряды бәреп керә. Октябрь башында Салават Катау-Иван заводына юнәлә. Чөнки июнь аеннан бирле әлеге заводны Салаватның этисе Юлай Азналин отряды камап тоткан була. Моңа кадәр дә Салават аның янына берничә мәртәбә ярдәмгә килеп китә.

Инде хәзер октябрь башында Салават килү дә уңышка китерми, заводны камалышта тоту ноябрь аена кадәр дәвам итә. Тик фетнәчеләр заводны алуга барыбер ирешмиләр. Октябрь башында Уфа провинциясенә хөкүмәтнең өстәмә җәза гаскәрләре китереп тутырыла. Мөселман старшиналары, отряд башлыклары арасында хыянәтләр башлана. Бөтен яу буена Салаватның тугры ярдәмчесе булып йөргән татар полковнигы Габдулла Туктаров 15—17 октябрьләр тирәсендә әнә шул хыянәтчеләр ярдәмендә җәзачылар кулына әсирлеккә төшә. Күптән түгел генә Салават белән бергә яу чыгып йөргән атаманнар Гадел Бигашев һәм Арыслан Рангулов та кулга алына. Салаватның үз әтисе Юлай Азналин да патшабикәгә каршы көрәшүдән баш  тарта.

Тик Салават кына бирешергә һич тә исәпләми. Ноябрь аенда ул үзенә каршы җибәрелгән 600 солдат һәм 200 казак белән бәрелешкә керә. Бу Салаватның патша җәлладларына каршы соңгы явы була. Шуннан соң Салават, көрәштәшләрен тигезсез үлемнән, кан коюдан һәм җәзалаулардан саклап калу максатыннан, бөтенләй таратып җибәрергә карар кыла. Каһарман юлбашчы үзе урманнар, таулар аша казах далаларына качып китәргә исәпли. Ләкин 25 ноябрь көнне Салават сатлык мишәр старшиналары ярдәме белән җәзачылар кулына эләгә.

Пугачевчыларга каршы көрәшүче бөтен җәза гаскәрләренең башкомандующие, канэчкеч П. Панин әмере буенча Салават гыйнвар аенда Казанга озатыла. Минзәлә аша үтеп, Салават Казанга февраль башында гына килеп җитә. Аның әтисе Юлай Азналин да 5 февральдә Казанга китерелә. Барлыгы 7 ай буена сузылачак тикшерү башлана. Аталы-уллы каһарманнардан сорау алу Казаннан соң Мәскәүдә, Оренбургта, яңадан Уфада дәвам иттерелә. Ниһаять, 1775 елның 22 июлендә генә хөкем карары игълан ителә: «Юлай Азналинны Сим, Усть-Катау, Катау-Иван заводларында, Орловка авылында камчы белән 45 әр тапкыр кыйнарга. Салават Юлаевка Сим заводында, Юлай, Ләк, Красноуфимск, Көнгер, Усад һәм Нөркәйдә 25 әр тапкыр камчы белән сугарга. Соңыннан икесенең дә борыннарын өзеп, маңгайларына һәм яңакларына «фетнәче, карак һәм хыянәтче» дигән сүзләрне аңлатучы мөһерләр сугарга. Ахырда фетнәчеләрне Балтыйк диңгезе буендагы Рогервик портына гомерлек сөргенгә озатырга».

Аталы-уллы каһарманнарны коточкыч җәзалау август аенда башлана һәм 16 сентябрьгә кадәр сузыла. Орловка һәм Нөркәй авыллары янында Юлай белән Салаватның борыннары киселә, яңакларына кыздырылган тимер ярдәмендә мөһерләр сугыла. Ләкин Уфа зинданына кайтарылгач, борыннары тиешенчә киселмәгән, мөһер эзләре төзәлгән дигән сылтау белән, патша җәлладлары аларны янә бер мәртәбә шушы ук җәзаларга дучар итәләр.

2 октябрьдә көчәйтелгән сак астында Салават белән Юлай газаплы ерак юлга чыга. Уфа — Минзәлә — Казан — Түбән Новгород — Мәскәү — Тверь — Новгород — Псков — Дерпт — Ревель һәм, ниһаять, 1775 елның 29 ноябрендә Рогервик порты (Эстониядәге хәзерге Палдиски каласы). Аларга кадәр үк инде бирегә күренекле пугачевчылардан И. Почиталин, М. Горшков, И. Ульянов, Д. Караваев, И. Аристов,  Е. Тюленев, А. Долгополов һәм Салаватның тугры көрәштәше Канзафар Усаев китерелгән була. 1718 елда Петр патша шәхсән үзе нигез корган портта батыр пугачевчылар таш кисү һәм диңгездә кораблар өчен причаллар төзү белән газаплана. Шторм булган саен, диңгез суы богаулы әсирләр ташыган ташларны юып алып китә. Салават 25 ел буе шушындый коточкыч сөрген хезмәтендә газаплана, шушында үзенең әтисен югалта һәм 1800 елның 26 сентябрендә вафат була *(Сидоров В. В.).*

**2. Бәхтияр Канкаев**

Уфа провинциясенең Кущин волостендагы (хәзерге Мәчетле районы) Олы Ака авылы мишәре. Туган елы, шөгыле билгеле түгел. Фетнәгә 1773 елның ноябрендә кушыла. 3 декабрьдә аңа Бирдә бистәсендә Пугачевның Идеркәй Мәхмүтов кулы белән язылган манифесты бирелә. Бәхтияр үзе походный старшина, аның иптәше Габделкәрим Күзкәев йөзбашы дәрәҗәсенә лаек була. Пугачев фәрманы буенча алар Себер юлына һәм Красноуфимск төбәгенә крестьяннарны фетнәгә күтәрү өчен озатылалар.

Бәхтияр үз отрядын Мәчетле районындагы Абдулла, Олы һәм Урта Ака авылларында оештыра башлый. Аннан соң Урта Богалыш, Шарами авылларыннан да фетнәчеләр җыя. 800—1000 фетнәче туплагач, Бәхтияр Санар (Саранинск) заводына юнәлә. Эшчеләр, Бәхтиярны заводтан 7 чакрым алга чы-

гып, ипи-тоз белән каршылыйлар, шунда ук аңа 2 ат та бүләк итәләр. Бәхтияр Красноуфимск каласына да үгетчеләр җибәрә, һәм нәтиҗәдә шәһәр воеводасы Н. Бахматов та аны кырга чыгып каршы ала.

9 гыйнвар көнне Бәхтияр Красноуфимскига керә. Шуннан 110 чакрым ераклыкта торган полковник (!) Салават Юлаевны чакыру өчен 19 яшьлек пономарь Макар Поповны Котыш авылына (Мәчетле районында) җибәрә. Салават Красноуфимскига 12 гыйнварда килеп җитә, аларның Бәхтияр белән аралары бозылыша. 15 гыйнварда Көнгергә чыгып киткәндә, Салават Бәхтиярны түгел, бәлки аның якташы, Кызылбай авылы вәкиле Ишмән Иткуловны Красноуфимскидагы фетнәчеләр башлыгы итеп калдыра.

Бәхтияр 19 февральгә кадәр Красноуфимск каласында тора. Аңа кадәр үк инде шәһәргә Көнгер янында җиңелгән фетнәчеләр кайтып төшә. Аларның эзенә басып А. Папава һәм Д. Гагрин карательләре килеп җитә. 19 февральдә кала читендә булган яуда Ишмән Иткулов, Бәхтияр Канкаев һәм башка җитәкчеләр кул астындагы отрядлар да тар-мар ителә.

Бәхтияр Себер юлына чигенә. Ул отрядын йөзбашлары Габделкәрим Күзкәев, Йосыф Юнысов карамагына калдыра да, үзе Бирдә бистәсенә Пугачев янына китеп бара. Шунда Салават өстеннән шикаять яза. Әмма «падишаһ»ның шәхсән үзе белән очрашуга ирешми, күрәсең. Шикаятен бирми һәм, Бирдәне калдырып, 23 мартка кадәр туган төбәгенә кайтып китә.

Бәхтияр Үр-Кыйгы авылына кайта һәм 9 апрельдә шунда «падишаһ» атаманы Иван Белобородов белән очраша. Белобородов Пугачевтан ашыгыч рәвештә яңа отрядлар туплау турында фәрман алган була. Шул фәрманны ул походный старшина дәрәҗәсен йөртүче Бәхтиярга да җиткерә. Бәхтияр Мәчетле, Караидел районнарына, Себер юлына кергән авыллардан яңа (икенче) отряд туплый. Удмуртиядәге заводлар һәм Уса янында җиңелеп карательләр эзәрлекләвеннән качып котылган полковник, 1767 елгы Уложение комиссиясе депутаты Бакый мулла Абдуллов та беркадәр ара Бәхтияр отряды белән бергә хәрәкәт итә («Воззвания...»). 28 апрель тирәсендә Бәхтиярга полковник дәрәҗәсе бирелә.

4 май тирәсендә атаман Иван Белобородов Магнитная крепосте янына Пугачев белән кушылырга китеп бара. 6—31 майларда Салават отряды Михельсон карательләре эзәрлекләвеннән качып йөри. Бәхтияр май ае дәвамында Уфа —Көнгер арасындагы фетнә отрядларының башлыгы булып кала.

Бәхтияр май ахырында Уса юлына юнәлә һәм Балтач районындагы Уразай исемле татар авылында лагерь корып урнаша. Биредә аңа атаман Гадел Бигашев отряды да кушыла.

2 июнь көнне Бәхтияр Бөре янына килә һәм гомуми саны белән 5000 кешегә җиткән фетнәчеләр гаскәренең баш командирына әверелә. 4 июнь таңында крестьяннар Бөрене штурмларга ташлана. Янгын куба. Шәһәр эчендәге майор Дуве Агыйделнең сул ягына кача. Ул Бөре янына 3 июньдә килгән Якубович, А. Исмәгыйлов, И. Баязитов карательләре белән кушыла алмый. Бөре фетнәчеләр кулына төшә.

Бәхтияр фетнәне бөтен Уса юлына тарату өчен көрәшә башлый. Карательләрнең отрядларын эзәрлекләп, ул үзе Сухояз авылына юнәлә. Атаман Гадел Бигашев — Ангасяк заводында, полковник Габделҗәлил Рыскулов — Тимкә, походный старшина Балтач Сәетов — Туктар, Әбил Байдашев — Сатана (Емаш), Зөлкәрнәй Йосыпов — Суслово, Сәетьягъфәр Зәйсәнов — Бишмәче авылларына урнаша, Бүләк Якупов белән Арыслан Рангулов Атар һәм Барда (Гайнә) юлларын саклый.

15 июнь көнне Бәхтияр отряды Сатана авылы янында каратель Якубович командасына һөҗүм итә. Якубович Дуванеи авылына чигенә. Бәхтияр алдагы якшәмбегә (17 июнь булырга тиеш) яңа һөҗүм хәзерли, шуның өчен полковник Г. Рыскуловны да үз янына дәшә.

Әмма 16 июнь тирәсендә Бәхтияр Канкаевка Пугачевның 13 июнь көнне язган фәрманы килеп төшә. Бәхтияр Красноуфимскидан Усага баручы Пугачев армиясен Уфа ягындагы карательләр һөҗүменнән сакларга, шулай ук зур отряд туплау белән шөгыльләнергә тиеш була. Бәхтияр Сухоязда Ярмөхәммәт Кадермәтов, Габдулла Туктаров отрядларын калдыра, ә үзе, Борай районындагы Чалкак аша үтеп, Курча авылына (дөресе Иске Күрзә — Борай районында) күченә. Әмма 21 июньдә Ярмөхәммәт отрядын Бурново авылы янында И. Михельсон тар-мар итә. 22 сендә Ярмөхәммәт янә Бәхтиярга килеп кушыла.

Бәхтияр, Пугачев отрядының тылын саклап, Борай, Краснокама районнары аша үтә, Калтай авылына барып урнаша. Бу вакытта Сарапул төбәгендәге карательләрнең активлашуын белеп, Бәхтияр 22 июньдә Бәйки Туйкиев, Федоська Янбактин, Әит Сәгыйтов, Биккенә Уразов кебек старшиналарга фәрман юллый, аларның карательләргә каршы юнәлүен таләп итә. 24 июньдә әлеге старшиналар Чурумак (Енактай) авылы янындагы 600 карательне куып тараталар. Карательләргә каршы көрәшү, яңа отряд туплау өчен Бәхтияр Ярмөхәммәт Кадермәтовны да Ангасяк заводына озата.

Тиздән Бәхтиярга Пугачевның Казан өязенә керүе турындагы хәбәр килеп җитә. Ул Бөре төбәгендә карательләргә каршы көрәшүче фетнәчеләр башлыгы итеп полковник Ярмөхәммәтне калдыра да, үзе 1 июль тирәсендә төп гаскәрнең тылын саклау өчен Пугачев артыннан китеп бара.

4 июльдә Пугачев Мамадышка керә. 4—7 июль көннәренең берсендә үз отряды белән аның янына Канкаев та килә. Бәхтияр шул көнне Пугачев янында куна. Ә таңда Бәхтиярга баш полковник яки бригадир

дәрәҗәсе һәм яңа фәрман бирелә. Ул Мамадыш өязенең Кама елгасы буендагы авылларыннан яңа отряд тупларга һәм, элеккечә үк, Пугачев армиясенең тылын карательләр һөҗүменнән сакларга тиеш була.

Бәхтияр 6 иптәше белән юлга чыга, үз походын Мамадыш янындагы авыллардан башлый, аннан соң Балык Бистәсе, Саба, Теләче, Питрәч районнарына юнәлә. 13 июльдә аның отрядындагы сугышчылар саны — 600 гә, 22 июльдә 3000 гә җитә. Бәхтияр кул астында Габдулла Мостаев, Гаврила Лихачев, Рахманкул Дуслиев, Халит Әминев кебек полковниклар пәйда була, Собханкул Ичкаев, Сөбәй Азиков (Субай Аскин) кебек подполковниклар үсеп чыга.

Бәхтияр Нократ, Кама аша кичүләрне саклауга аеруча зур игътибар бирә. Аңа буйсынучы Федот Никитин 12 июльдә Соколка кичүе янында секунд-майор М. Мельгунов карательләрен тоткарлый. 14 июльдә Габдулла Мостаев белән Гаврила Лихачев отрядлары Шуран кичүе янында граф В. Меллин командасы белән кат-кат бәрелешәләр. Бәхтияр фетнәчеләреннән куркып, Нократ тамагында полковник Обернибесов отряды хәрәкәтсез тора. Нәтиҗәдә әлеге карательләрнең берсе дә Казан янына барып подполковник И. Михельсонга ярдәм итәргә җитешми.

Пугачев Татарстан җирен ташлап киткәч, Казан администрациясе Бәхтиярга каршы карательләрнең берничә командасын юллый. Алар 25 июльдә Байтирәк авылы янында әүвәл Гаврила Лихачев отрядын тар-мар итәләр. 27 июльдә алар Җөри авылында тупланган Бәхтияр Канкаев отряды янына килеп җитә. Карательләрнең подполковник С. Неклюдов командалыгында берләшкән отряды дәвамлы яудан соң фетнәчеләрне куып тарата. Бәхтияр үз янында калган 400 крестьян белән Keләүш авылына чигенә. Август башында бирегә карательләрнең яңа отряды килеп җитә. Фетнәчеләр тулысынча тар-мар ителә. Бәхтияр үзе бер туп һәм берничә иптәше (алар арасында, мөгаен, Габдулла Мостаев, Халит Әминов, Балтач Сәетов та булгандыр) белән качып котыла. Гәрчә 1775 елның мартында Екатерина фетнәчеләрне тулысынча гафу итү турында указ чыгарса да, баш җәллад П. Панин татар каһарманы Бәхтияр Канкаевны ел ахырына кадәр эзләтә. Һәм, әлбәттә, аның «гөнаһлары»н кичерергә җыенмый. Кызганыч, бригадир Бәхтиярның фетнәдән соңгы язмышы әлегә һичкемгә билгеле түгел («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»; «Крестьянская война... на территории Башкирии»; *С. Алишев;* ЦГАДА, 6 фонд, 416 эш, I кисәк).

### 3. Ярмөхәммәт Кадермәтов
### (Яркә Кадыйрмөхәммәтов)

Пугачев армиясендә баш полковник яки бригадир дәрәҗәсенә ирешкән өченче татар каһарманы Ярмөхәммәтнең дә туган елы билгеле түгел. Тарихчылар аны «Казан өязендәге Ишбулды авылының ясаклы крестьяны» дип күрсәтә. Бүген Татарстанда мондый исемдәге авыл юк. (Башкортстанда Ишбулды авылы бар. Кардәшләребез: «Яркәй безнеке!» — дип дәгъва белдерә күрмәсен. Сезнең Ишбулды — Әбҗәлил районында. Ул Ишбулды белән без сөйләячәк Минзәлә арасында 1000 км ара ята.) Авылның дөрес исеме Әгерҗе районындагы Иж-Бубый булмадымы икән? Шулай дип уйларга тулы нигез бар. Чөнки Ярмөхәммәтнең исеме тарихи документларда беренче мәртәбә Минзәлә төбәгендә искә алына. Ә безгә билгеле булганча, әгерҗелеләр үзләренең тәүге депутатларын полковник Каранай Моратов янына 3 декабрь көнне үк озата.

Ярмөхәммәт Минзәлә янына, чыннан да, декабрь аенда ук килгән булырга тиеш. Чөнки 1774 елның гыйнвары белән тамгаланган тәүге документта ук Ярмөхәммәт «атаман» дип телгә алына («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Ул бу көнне походный старшина Балтач Сәетовка үз отряды һәм туп белән Уфаны штурмларга бару өчен билет язып бирә. Ә атаман дәрәҗәсе Ярмөхәммәткә, әлбәттә, тиктомалдан гына бирелмәгән. Ул мондый дәрәҗәгә йә зур отряд туплаган, йә 23—26, 31 декабрьләрдә Минзәләне штурмлау вакытында искиткеч батырлык күрсәткән өчен лаек булган.

Ярмөхәммәт Кадермәтовның көрәш юлын яктыртучы тарихи документлар бик аз күләмдә сакланган. Шуңа күрә без аның турында тарихи вакыйгалар агышына нигезләнеп сөйләрбез.

Декабрь ахырындагы штурмнар уңышка китермәгәч, Минзәләне камалышта тотучы фетнәчеләр Дәвек һәм Мажын авылларында лагерь корып урнашалар. Әмма 12 гыйнварда карательләр әлеге лагерьлардагы крестьяннарны куып тарата. Фетнәчеләр Тәкермән, Бикбау авылларына күчеп лагерь коралар.

11 гыйнварда Каранай Моратов Кама буендагы Бәтке пристанена китеп бара һәм 14 гыйнварга кадәр шунда тора. Ярмөхәммәт Минзәләне камалышта тотучы гаскәр башлыгы булып кала. 20 гыйнвар көнне Минзәлә гарнизоны янә фетнәчеләргә каршы юнәлә. Сарсаз авылы янындагы яуда крестьяннар 45 кеше, 50 ат югалталар.

30 гыйнварда Минзәлә янына полковник Ю. Бибиков карательләре килеп җитә һәм ике ай буе каланы камалышта тотучы фетнәчеләр гаскәрен куып тарата. Крестьяннарның бер өлеше Әгерҗе районындагы Пьяный Бор авылына, икенче өлеше Бакалы районындагы Нагайбәк крепостена чигенә.

Карательләр китеп баруга ук, крестьяннар янә отрядларга берләшәләр. Февраль аенда Минзәлә тагын камалышка алына. Янә биредә Ярмөхәммәт Кадермәтов фетнәче отрядларның юлбашчысы булып тора.

Әмма март ахырында минзәләлеләргә дә Пугачевның — Татищев крепосте, Зарубинның Чесноковка янында тар-мар ителүе турындагы хәбәрләр килеп җитә. Бу төбәккә тупланган фетнәчеләр инде үзләре дә Минзәлә каласын «тезләндерә» алмаячакларын аңлыйлар. Һәр төбәктәге шикелле үк биредә дә фетнә хәрәкәте төшенкелек кичерә. Вак отрядлар туган якларына кайтып китә.

Ярмөхәммәт Кадермәтовның март ахыры—май башындагы эшчәнлеге Уфа провинциясенең Уса юлы белән бәйле. Үз отряды белән килеп кушылып, ул байтак кына ара Салават белән бергә хәрәкәт итә, карательләр эзәрлекләвеннән качып авыр яулар кичерә. Аның исеме тарихи документларда 1774 елның май аенда Бөре өязе белән бәйләнештә калкып чыга.

Май ахырында Ярмөхәммәт Бөре янына килә һәм үз отряды белән андагы фетнәчеләр сафына кушыла. 1 июньдә Б. Якупов, А. Рангулов, А. Биктуганов белән бергә Я. Кадермәтов та Уразай авылында торучы полковник Бәхтияр Канкаев һәм атаман Гадел Бигашевка хат язалар. Аларны Бөре янына чакыралар. 2 июньдә бирегә Канкаев белән Бигашев та килә. 4 июньдә 5000 кешелек фетнә гаскәре Бөрене штурмларга ташлана һәм аңа бәреп керә.

Шушы көннәрдә Ярмөхәммәт Бәхтиярның тугры көрәштәшенә әверелә. Тарихи документлар бу турыда дәшми, әмма, безгә калса, алар рухи яктан үзара туганлык тоеп кына калмагандыр, бәлки яу барышында Ярмөхәммәт хәрби осталык, оештыру сәләте һәм шәхси батырлык та күрсәтеп өлгергәндер. Шулай булмаса, инде 5 июньдә үк (очрашуларына нибары 3 кенә көн үткәч), Бәхтияр белән Ярмөхәммәт «падишаһ» исеменә рапорт язып, аннан һәммә милләт вәкилләрен зур гаскәр итеп тупларга рөхсәт сорамаслар иде.

6—17 июнь көннәрендә Ярмөхәммәт Бәхтияр белән иңгә-иң торып хәрәкәт итә. Алар фетнә ялкынын бөтен Уса юлына тарату өчен көрәшә. Үз отрядлары белән алар полковник А. Якубович, майор О. Дуве, хыянәтче старшиналар Аблай Исмәгыйлов һәм Ихсан Баязитов җитәкчелегендәге карательләрне эзәрлекләп бара. 15 июнь көнне алар Сатана (Емаш) авылында торучы әлеге карательләр командасына һөҗүм итәләр. Карательләр Дуванеи авылына чигенә. Фетнәчеләр Сухояз авылына кайтып урнаша. Бәхтияр, Ярмөхәммәт, Габдулла Туктаров, Хәмит Мөхәммәтов (Мәхмүтов), Рамазан Урманчиев кебек җитәкчеләр алдагы якшәмбе көненә яңа һөҗүм хәзерлиләр, үзләренә ярдәмгә Тимкә авылында торучы полковник Габделҗәлил Рыскулов отрядын да чакыралар.

Ләкин аларның ниятләре тормышка ашмый. 16 июньдә есаул Салих Нәүрүзов Бәхтияр белән Ярмөхәммәткә Пугачев фәрманын алып кайта. Аларга һәр милләт вәкилен зур бер гаскәргә тупларга һәм Пугачев армиясенең тылын сакларга әмер бирелә. Салих Нәүрүзов әлеге фәрман белән бергә, күрәсең, Ярмөхәммәткә полковник дәрәҗәсе бирелү турындагы Указны да алып кайткандыр. Чөнки 17 июньдә Ярмөхәммәт документларга инде полковник дип тамга сала башлый.

Гәрчә «падишаһ» яңа фәрман җиткерсә дә, Бәхтияр белән Ярмөхәммәтнең икесе дә Сухоязга тупланган фетнәчеләрне ташлап китә алмый. Полковниклар көчне икегә бүлергә карар кыла. Бәхтияр Канкаев Хәмит Мөхәммәтов белән Борай районына юнәлә. Ярмөхәммәт Габдулла Туктаров белән Сухоязда кала. Фетнәчеләрнең яңа һөҗүменнән курыккан полковник Якубович Усак авылына чигенә («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Әмма 17 июнь көнне подполковник И. Михельсон командасы Уфа каласыннан чыга һәм Бөре төбәгенә юнәлә. Шул ук көнне ул майор О. Дуве отряды белән кушыла. Шуннан соң Михельсон Сухоязга килә. Фетнәчеләр чигенә. Михельсон 21 июньдә Ярмөхәммәт отрядын Бөре елгасы буендагы Бурново (Старобурново) авылы янында куып җитә. Канлы яуда 70 фетнәче үтерелә. Ярмөхәммәт Уса юлы буйлап чигенә һәм 22 июньдә Краснокама районында янә Бәхтияр Канкаев белән кушыла. Шушы көнне үк аларга Уран волосте старшиналары Бәйки Туйкиев, Федоська Янбактиннар Касево авылы янында хәрәкәт итүче 600 кешелек карательләр отряды турында хәбәр итәләр. Бәхтияр белән Ярмөхәммәт әлеге ике старшинага һәм, шулай ук, Әит Сәгыйтов белән Ишкенә Уразовка ашыгыч рәвештә Касево карательләренә каршы чыгарга фәрман юллыйлар. Старшиналар отряды Чурумак (Енактай) авылы янында карательләр белән яуга керә һәм аларны Сарапул ягына качарга мәҗбүр итә. 24 июньдә Уран волосте старшиналары Бәхтияр белән Ярмөхәммәткә шул хакта хәбәр җибәрә.

Ләкин Бөре төбәгенә төрле яктан бәреп кергән карательләрнең аяусызлыгы көннән-көн активлаша. Хыянәтче Кулый Балтачев Борай һәм Балтач районнарындагы фетнәче татар авылларын талап йөри. Майор М. Мельгунов Дүртөйле районындагы авылларны буйсындыра, Ангасяк заводы янындагы фетнәчеләрне куып тарата.

24—25 июнь тирәсендә Бәхтияр белән Ярмөхәммәт тагын аерыла. Ярмөхәммәт Ангасяк яныннан таралган фетнәчеләрне янә бер отрядка туплау өчен юлга чыга. Аңа бу эштә походный старшина

Габделкәрим Собханкулов ярдәм итә. Ярмөхәммәт бик күп төбәкләргә махсус чапкыннар юллый, 26 июньдә үк инде отряд туплауга ирешә. Ул дүшәмбе көнне (?) янә Бәхтияр белән кушылырга өметләнә. Әмма 27 се көнне ул Гүрҗә (дөресе Иске Күрзә авылы — Борай районында) волостенда карательләр отряды хәрәкәт итү турында белеп ала һәм дошманнарына каршы юнәлә. Ул Бәхтиярны да ярдәмгә чакырып хат яза. Ләкин аларга очрашырга насыйп булмый.

1 июль тирәсендә Бәхтияр, Агыйделне кичеп, Татарстан җиренә юнәлә. Аңа кадәр үк атаман Гадел Бигашев исеменә хат язып, Ярмөхәммәт Кадермәтовны Бөре төбәгендәге фетнәчеләр башлыгы итеп билгеләргә куша. Бәхтияр тәкъдимен полковник Габделҗәлил Рыскулов, старшина Хәмит Мәхмүтов (Мөхәммәтов), йөзбашы Сәетьягъфәр Зәйсәнов та яклый. Әмма ай башында ук Бөре өязендә майор М. Мельгунов, майор О. Дуве, полковник А. Якубович, хыянәтче старшиналар Солтанморат һәм Бәхтияр Янышевлар, Мөхсин һәм Җәмгур Әбдесәламовлар, Кулый Балтачев, Аблай Исмәгыйлов, Ихсан Баязитов җитәкчелегендәге җәза отрядлары фетнәче авылларны буйсындырып һәм канга батырып йөри башлый. Шул басым астында вак отрядлар туган якларына таралырга һәм фетнәне вакытлыча туктатып торырга мәҗбүр була. Ләкин карательләр Пугачев артыннан Казан провинциясенә юнәлгәч, крестьяннар янә отрядларга берләшәләр, хыянәтче старшиналарның авылларын һәм утарларын талый башлыйлар.

Ярмөхәммәт Кадермәтовның нәкъ кайсы көндә баш полковник дәрәҗәсенә лаек булуы төгәл билгеле түгел. Аны Бөре өязендә хәрәкәт итүче отряд командирлары үзләренең төп хәрби җитәкчесе итеп сайлаган булырга тиеш. Ярмөхәммәт 11 августта язылган документта баш полковник дип телгә алына. Документ Ярмөхәммәтнең Уса юлындагы отряд командирлары Әит Сәгыйтов, Исмай Туманаев, Бәйки Туйкиев кебек башкорт, удмурт, мари старшиналары өстеннән дә җитәкчелек итүе турында сөйли.

20 августтан соң Ярмөхәммәт кул астына 2000 фетнәче җыела. Аларга каршы Уфадан премьер-майор И.Штерич, Җаек казакларының атаманы Н. Назаров җитәкчелегендәге җәза отрядлары озатыла. 30 августта Краснокама районындагы Музяк авылы янында беренче бәрелеш була. Ярмөхәммәт көнчыгышка чигенә, юлда аңа карательләр эзәрлекләвеннән качып йөрүче Арыслан Рангулов, Аладин Биктуганов отрядлары да кушыла. Штерич фетнәчеләрне эзәрлекләп бара һәм (мөгаен, Балтач районында урнашкан) Иванай авылында туктый. 6 сентябрь көнне Ярмөхәммәт үзе Штерич командасына һөҗүм итә. Ләкин туплар уты астында чигенергә мәҗбүр була.

Сентябрь ахырында Ярмөхәммәт отрядында 500 генә сугышчы кала. Штерич командасы 28 сентябрьдә аңа соңгы тапкыр һөҗүм ясый һәм тар-мар итә. Баш полковник Ярмөхәммәт Кадермәтов октябрьдә әсирлеккә эләгә. Татар каһарманының шуннан соңгы язмышы әлегә ачыкланмаган («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Крестьянская война... на территории Башкирии»; «Воззвания...»; *В. Мавродин, С. Алишев, И. Гвоздикова*; ЦГАДА, 6 фонд, 416 эш, I кисәк).

*Ярмөхәммәт каһарманның туруннары исән, Башкортстанның Ишимбай каласында яшиләр. 2002 елның июлендә бер туруны — Мөсәвир Бикмөхәммәтов — китап авторына рәхмәт сүзләрен җиткерергә дип Чаллыга килде. Бабалары калдырган истәлекләрдән күренгәнчә, алар, чукындырудан качып, Башкортстан җиренә Татарстандагы авыллардан күченгәннәр икән. Урман эченә урнашкан авыллары тулы бер гасыр буена «Яшеренгән авыл» исеме белән аталып йөргән. Ни үкенеч, тарихчылар арасында ул заманның бригада генералы дәрәҗәсен йөрткән Ярмөхәммәт батыр турында ике юллык мәгълүмат та язып чыгучы юк.*

### 4. Мәсәгуть Гомәров

1746 елда туган. Татарстанның Кукмара районы Пычак авылыннан. Казан Адмиралтействосына беркетелгән лашман, ягъни урман кисүче, агач хәзерләүче. Фетнәгә 1773 елның ноябрендә кушыла. Үзенең туган төбәгендә, Казан өязенең Арча юлында отряд туплый башлый. 200 кешелек отряд белән ул әүвәл сәүдәгәр И. Осокинның Бемыш заводын, Удмуртиядәге Аргабаш, Кизнер авылларын, Кобелевларның Пыжман заводын ала, 7 тупны кулга төшерә. Соңрак Асаф Иноземцевның Таиш заводы һәм андагы 4 туп та мәсәгутьчеләр кулына эләгә.

Декабрь аенда Мәсәгуть кул астында тупланган фетнәчеләр саны 1700 гә җитә. Гомәров үзе полковник дәрәҗәсен йөртә башлый (кайбер мәгълүматларга караганда, ул декабрьдә Бирдәгә бара һәм Пугачев шәхсән үзе аңа полковник дәрәҗәсен бирә). Татарстанның — Кукмара, Мамадыш, Саба, Арча, Балтач, Питрәч; Киров өлкәсендәге — Вятские Поляны, Малмыж; Удмуртиядәге Кизнер, Бемыш районнарындагы бик күп авыл крестьяннары Мәсәгутьне үзләренең җитәкчесе дип таный.

Декабрь ахырында Казан администрациясе Мәсәгуть Гомәровка каршы капитан Г. Кардашевский җитәкчелегендәге отряд юллый. Балтач районының Кариле авылы янында зур яу була. 38 фетнәче әсирлеккә төшә. Моннан тыш, Мәсәгутьнең әтисе Гомәр Әширов, хатыны Мәрфуга, абыйлары Мәгъсүт

белән Мансур да кулга алына. Карательләр Мәсәгутьнең баш иеп килүенә өметләнә. Ләкин гыйнвар башында Мәсәгуть тагын да зуррак активлык күрсәтә. Аның отрядындагы фетнәчеләр саны 3000 нән арта. Мәсәгуть шул көч белән Казанга һөҗүм итәргә хәзерләнә. Әмма аңа Бирдәдән «падишаһ» фәрманы килеп төшә. Мәсәгуть 1500 кешелек бер отрядны — Минзәләне, 250 кешелек икенче отрядны Алабуганы штурмлау өчен озатырга мәҗбүр була.

4 гыйнвар көнне Казаннан капитан Г. Кардашевский отряды икенче мәртәбә җәза походына чыга. Мәсәгутьчеләр Камышлы, Чокырчы, Пычак авыллары янында карательләр белән берничә мәртәбә яуга керәләр, әмма җиңеләләр. Мәсәгуть үзе әүвәл Нагайбәк крепостена, аннан Эстәрлетамак авылына чигенә. 10 мартта биредә дә тар-мар ителгәннән соң, Мәсәгуть Уфа провинциясенең Уса юлына китә. Уса, Көнгер төбәгендәге авыллардан 60 кешелек отряд туплагач, ул Чесноковка лагерендагы атаман Чика-Зарубин янына юнәлә, аның 24 март көнне тар-мар ителүен белми. Юлда ул хыянәтче мишәр старшинасы Миндәй Тупеев кулына эләгә. Тупеев аны Уфага, подполковник И. Михельсонга илтеп тапшыра. Мәсәгуть Троицк чиркәве астындагы зинданга ябыла. Михельсон «бөек Казан юлбасары» Гомәровның әсирлеккә эләгүен 16 апрель көнне башкомандующий А. Бибиковка зур горурлану белән хәбәр итә.

Восстание бастырылганнан соң, Мәсәгуть туган ягында авылдан авылга йөртеп чыбыркы белән суктырыла. Җәлладлар аның борынын кисәләр, маңгаена һәм яңакларына кыздырылган тимер белән мөһер сугалар. Мәсәгуть Таганрог сөргененә каторга эшләренә җибәрелә. Шәхсән Мәсәгутьнең дә, аның әтисе, хатыны, абыйларының да шуннан соңгы язмышлары билгеле түгел («Крестьянская война... на территории Башкирии», док. 80; *С. Алишев*. Пугачев полковнигы; ЦГАДА, 6 фонд, 467 эш, I кисәк) .

*1994 елның 22—25 ноябрьләрендә «Башкортостан» газетасының берьюлы 4 санында «Ялганга батырылган яу» исемле күләмле мәкалә дөнья күрде. Авторы Эстәрлетамак каласында тарих фәнен укытучы Салават Таймасов атлы кеше һәм аның мәкаләсе без фәкыйрегезнең «Сәет батыр», бигрәк тә андагы «Татарлар Пугачев явында» хезмәтенә каршы юнәлтелгән иде. Ошбу Таймасов әфәнде безне Пугачев явында ялган татар каһарманнары уйлап табуда, «үзе уйлап тапкан геройлары белән милли батырыбызның (Салават Юлаевның) ролен киметергә, шуның белән аны кимсетергә омтылуда» гаепләде. Аның мәкаләсендә мондый гаеп тарих фәннәре докторы Сәлам Алишев өстенә дә байтак ыргытылды. Таймасов фикере бик сәер: башкорт милләте Салават кебек каһарманнарны үстерергә лаек, ә татар милләтендә аңа тиңнәр һич булмаска тиеш икән. Тибешкәндә тиңең булсын, диләр, Таймасов әфәнде белән бәхәсләшеп тормыйбыз. Ләкин аның мәкаләсендәге мондый юллар үтебезгә тия: «1773 елның ноябрь азакларына тиклем ул яктагы (Казан губернасындагы) чуалышлар турында бер мәгълүмат та юк, кыскасы, алар булмаган... Әгәр анда баш күтәрүләр башланса, хәрби эшкә өйрәнмәгән татарлар бик тиз кыйратылыр һәм юк ителер иде...» Алга таба китик, ул юллар турыдан-туры М. Гомәров язмышына кагыла. «Мәсәгуть Гомәров баш күтәрүчеләргә Пугачев гаскәре Казан губернасына килгәч кенә кушыла... Татар полковнигы зур хәрби җитәкчеләр сафына иңмәгән... Тарихта ул җитәкчелек иткән бер яу да билгеле түгел, кыскасы, алар юк...» Бу күңеле сукыр башкорт патриотына җавап сүзләре урынына тарихи даталарны гына кабат исенә төшерик: Пугачев Казан губернасы туфрагына гаскәр белән 1774 елның 29 июнь көнендә генә аяк баскан. Ә безнең каһарманыбыз Мәсәгуть Гомәров 16 апрель көнне үк Михельсон кулына әсирлеккә төшкән һәм Пугачев тантана кылып йөргән көннәрдә Уфа каласының Троицк чиркәве астындагы зинданда җәфа-газап чиккән. Аннары Таймасов әфәнде «Мәсәгутькә полковник дәрәҗәсен Каранай Моратов биргән» дип бара. Тик инде март аенда ук җиңелеп Татарстан җиреннән чыгып киткән Каранай Моратов Таймасовча фәкать 1774 елның июлендә генә фетнәгә кушылган Мәсәгутькә ничек итеп дәрәҗәләр бирә алды икән? Аерма өч ай, Таймасов арифметиканы бутый, мантыйк бөтенләй юк.*

### 5. Габделфаикъ Усманов

Әүвәл Мәсәгуть Гомәров отрядында йөзбашы, аннары полковник. Аның турында мәгълүматлар бик аз. Усмановның Арча районында хәрәкәтләнүе, декабрьдә прапорщик Иван Федоров кул астындагы каравыл командасына һөҗүм ясап, 200 поляк конфедератын азат итүе генә билгеле (*С. Алишев*. «Татары...», 112 с.).

### 6. Габделҗәлил Сөләйманов

Чукынган татар алпавыты Йосыф (Осип) Тәвкилевкә беркетелгән Тирсә волостеның Тоба авылы крестьяны. Хуҗалары Тәвкилев Пугачевка каршы отряд туплау өчен октябрь ахырында әүвәл Уфа, аннары Бөгелмә төбәгенә киткәч (Йосыф 6 декабрь көнне Акбаш авылы янында җәзалап үтерелә), Тирсә волостендагы крестьяннар алпавытка эшләүдән баш тарта. 3 декабрь көнне волостьтагы барча авыл

крестьяннары Тирсәгә җыелалар һәм Минзәлә янындагы Каранай Моратовтан «падишаһ» указы алып кайту өчен делегатлар сайлыйлар. Шулар арасында Габделҗәлил (Әбҗәлил) дә Каранай янына бара. Аны Каранай Тирсә волостеның башлыгы һәм походный старшина итеп билгели, кулына указлар бирә. Волостька кайткач, крестьяннар Тәвкилев утарын, аның Барҗы-Алексеевск заводын талыйлар. Габделҗәлил тирә-юньдәге авыллардан 500 кешелек отряд туплый һәм полковник дәрәҗәсенә лаек була. Шуннан соң ул Удмуртиягә (Вятка провинциясенә) юнәлә, отрядын яңа фетнәчеләр белән тулыландыра. Тирсәлеләр идарәсе, шулай итеп, башка төбәкләргә дә тарала.

Каранайдан Минзәләне штурмлауга чакыру турында фәрман килеп төшкәч, Габделҗәлил үз отряды белән аның янына килә. 23—26 декабрьдә Минзәләне штурмлау үткәрелә, 12 гыйнварда — Дәвек һәм Маҗын, 20 гыйнварда Сарсаз авылы янында карательләр белән бәрелешләр була. Габделҗәлил Сөләйманов шәхсән үзе кайсы көнге яуларда катнашкандыр — ул кадәресе анык билгеле түгел. Ә 30 гыйнварда инде Минзәлә янына полковник Ю. Бибиков командасы килеп җитә һәм бу төбәктәге фетнәчеләрне куып тарата. Тирсәлеләр, туган якларына чигенеп, Пьяный Бор авылына тупланалар. Әмма 31 гыйнвар көнне бирегә Ю. Бибиковның подполковник А. Бедряга командалыгындагы гусарлары килеп җитә. 2000 фетнәче 4 сәгать буена карательләргә каршы тора. Ләкин гусарлар крестьяннар каршылыгын җиңә, 400 крестьян юк ителә.

Габделҗәлил Тирсә волостена кайта, үз кул астына яңа отряд туплый. Бөтен волостьта крестьяннар хакимияте урнаштыра. Волость аша узучы фетнәчеләргә ярдәм күрсәтә. Карательләрнең вак отрядларына һөҗүмнәр оештыра. Нәтиҗәдә волость крестьяннары 1774 елның май аена кадәр һичнинди изелү-кайгы күрмичә гомер кичерәләр.

«Азатлык утравы»ндагы тантана ярты ел чамасы гына дәвам итә. 11 майда волостька поручик Красильников җитәкчелегендәге карательләр бәреп керә. Сөләйманов аларны 200 кешелек отряд белән Тирсәдән 18 чакрымда каршылый. Әлбәттә инде, Тирсә крестьяннары туплар утына каршы тора алмый. Габделҗәлил үзенең иптәшләре белән Иж елгасы артындагы урманга кача. Ләкин 14 май көнне аны Красильников командасына кушылган хыянәтче татарлар әсирлеккә ала.

Габделҗәлил Казандагы Яшерен комиссиягә озатыла, анда җәзалана. 6 июньдә аны Усага баручы майор Скрипицынга тапшыралар. 12—14 июнь тирәсендә Скрипицын Габделҗәлил Сөләймановны Тирсә авылындагы дарга асып үтерә (ә 23 июньдә Скрипицынны Пугачев дарга аса.— *С. Алишев, В. Мавродин*; ЦГАДА, 6 фонд, 416 эш).

**7. Юскәй Кудашев**

Шул ук алпавыт Тәвкилевтә эшләүче Тирсә авылы крестьяны.  (Ул бөлгенлеккә төшкән, ягъни «чабаталы морза» нәселеннән булган, дигән мәгълүматлар да бар, бик мөмкин, аның гаҗәп укымышлы булуы шуңа ишарәли; җитмәсә, документларга да ул кайчакларда «Юскәй морза» дип кул куйган.) Фетнәгә килү юлы, мөгаен, нәкъ Габделҗәлил Сөләймановныкы кебек үк булгандыр. 1773 елның декабрь аенда Юскәй үз кул астына башкорт, удмурт крестьяннарыннан торган 800 кешелек отряд туплый һәм Ижевск заводына юнәлә. Завод крестьяннары Юскәй отрядын, Юски авылына (исемнәр буенча гаҗәеп тәңгәллек!) килеп, ипи-тоз белән каршылыйлар. Юскәй заводка ярдәмчесе АндрейНосковны озата, ә үзе Чесноковка лагерена, «граф» Чика-Зарубин белән күрешергә бара. Шунда Юскәй «падишаһ»Пугачевның Идеркәй Мәхмүтов тарафыннан 1 декабрьдә язылган һәм фетнәне Җаек яки Оренбург кына түгел, бәлки бөтен Рәсәй явына әверелдерергә чакырган манифестын урыс теленә тәрҗемә итә. Юскәй 1 гыйнвар көнне Ижевск заводына кайта. Фетнәчеләр биредә Кама буендагы казна (дәүләт) заводларының башлыгы полковник Венцель һәм завод идарәчесе И. Алымов йортларын, контораны талыйлар, «бурыч» кенәгәләрен юк итәләр. Заводтан алынган 2 бакыр туп, атлар, 9000 сум акча, фетнәгә кушылган 170 эшче Чесноковкага озатыла. Кудашев отрядындагы крестьяннар Уса ягыннан килгән Бакый Абдуллов белән бергә Барҗы-Алексеевск, Рождественск, Камбарка, Шермяит, Аннинск заводларын алуда да катнашалар.

Гыйнвар башында Кудашев янына Воткинск заводы вәкиле Кузьма Полкин килә һәм аны үз заводларын алырга чакыра. Бу вакытта инде Юскәйгә Каранай Моратовтан да Минзәләне штурмларга чакырган фәрман килеп җитә. Шуңа күрә Юскәй үзе отрядының бер өлеше белән Минзәлә ягына китеп бара. Ә Андрей Носков җитәкчелегендә калган фетнәчеләр 10 гыйнвар көнне Воткинск заводын да алуга ирешәләр. Юскәй Кудашевның шуннан соңгы язмышы турында тарихи документлар әлегә дәшми («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; *С. Алишев*; ЦГАДА, 6 фонд, 507, 467 эшләр).

**8. Бакый Абдуллов**

Әлеге татар каһарманының  язмышын ачыклауда инде «Сәет батыр» китабы басылап чыкканнан соң, Барда районы тарихчысы Әмир Фатыйховның «Гайнә иле» исемле басмасы ярдәм итте, аңа рәхмәтлебез.

Бакый Абдуллов — тумышы белән Көнгер өязеннән, мулла, 1767 елгы Уложение комиссиясе депутаты. Ул фетнәгә 1773 елның октябрь аенда ук Бирдә бистәсенә барып кушыла, Пугачевның ныклы ышанычын яулый. Полковник дәрәҗәсе биреп, «падишаһ» аны, Кама елгасының Уса — Ижевск арасындагы заводларына, эшчеләр һәм крестьяннарны фетнәгә күтәрү өчен, махсус эмиссар итеп озата. Октябрь азагында ук Бакый Абдуллов фетнәчеләр отряды туплауга ирешә һәм бер-бер артлы Рождественск, Камбарка, Шермяит, Аннинск заводларын ала. 1 гыйнварда Юскәй Кудашев белән бергә ул да Ижевск заводына керә. Бакый, Юскәй, шулай ук походный старшина дәрәҗәсен йөртүче Вәлит Җәгъфәров бу көнне заводтагы байтак крестьяннарга саклау билетлары язып бирәләр. 10 гыйнварда фетнәчеләр Воткинск заводын ала.

Ләкин Кама буендагы казна заводларының башлыгы полковник Венцель, Ижевск һәм Воткинск идарәчеләре И. Алымов белән А. Клепиков бу вакытта карательләр отряды туплап өлгерәләр. 26 гыйнвар көнне алар Бакый Абдуллов, Андрей Носков кул астындагы фетнәчеләрне Воткинск заводыннан куып чыгаралар һәм эзәрлекләп баралар. 29 гыйнварда заводтан 40 чакрым ераклыктагы Полозово авылы янында канлы бәрелеш уза. Крестьяннар җиңеләләр һәм Сарапулга таба чигенәләр. Аннан соң Бакый Абдулловның исеме документларда 1774 елның апрель аенда гына күренеп ала. Ул вакытта Бакый Уфа провинциясенең Себер юлында Бәхтияр Канкаев белән бергә хәрәкәт итә. Шуннан соң Бакый Абдуллов эзсез югала («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»; *С. Алишев, В. Мавродин, Ә. Фатыйхов*).

### 9. Муса Алиев (Галиев)

Оренбург янындагы Каргалы бистәсе старшинасы. 1773 елның 1 октябрендә Пугачев килгәннән соң, шушы авылда 500 кешелек полк төзелә. Муса Алиев аның командиры итеп билгеләнә. Муса полкы Оренбург гарнизоны белән бәрелешләрдә, 1773 елның 7—9 ноябрендә генерал В. Карга каршы Йөзәй — Мостафа янында, 1774 елның 22 мартында — Татищев крепостенда, 2 апрельдә Каргалы — Сакмар буенда узган яуларда катнаша. Муса 2 апрельдән соң Пугачев белән бергә Казанга кадәр озын һәм авыр юлны уза. Аның Пугачев кичергән һәммә яуларда катнашуы бәхәссез. Казанны штурмлаган чакта, ул Татарстан җирендә тупланган полкларның берсе белән җитәкчелек итә. 12, 13, 15 июльләрдә Михельсон корпусы белән бәрелешләрдә катнаша. Соңгы яуда Муса Алиев Идеркәй Мәхмүтов белән бергә әсирлеккә төшә. Казандагы Яшерен комиссия җәлладлары тарафыннан җәзалана. Әлеге татар полковнигының да алдагы язмышы билгесез *(С. Алишев, Н. Дубровин)*. *«Уяу» оппонентыбыз Салават Таймасов Мусаны үзенең «Ялганга батырылган яу» мәкаләсендә Соколов-Хлопушаны тотып карательләр кулына тапшыручы хыянәтчеләр юлбашчысына әверелдергән һәм Каргалыда аерып калдырган. Чынында исә Башкортстан далалары бик киң, Сакмар буеннан Урал таулары аша урап Казанга юл тотканда, Пугачев янәшәсендә Мусага да урын табылган бит.*

### 10. Казан татары Абдул

Әлеге татар каһарманының язмышы да, хәтта фамилиясе дә билгеле түгел. 1773 елның көзендә Оренбург янындагы Бирдә бистәсенә тупланган татарлардан яңа полк оештырыла, аның белән тарихи документларда «Казан татары Абдул» дип кенә телгә алынган шәхес җитәкчелек итә. 1773 елның 7—9 ноябрендә Йөзәй — Мостафа янында генерал В. Карга каршы яуда 1500 татар-башкорт катнашуы мәгълүм *(В. Буганов)*. Абдул полкы шул яуда, Оренбург гарнизоны белән бәрелешләрдә катнашкан, гомумән, 1774 елның 2 апреленә кадәр Бирдә лагеренда торган дип уйларга тулы нигез бар *(Н. Дубровин, С. Алишев).*

### 11. Идеркәй Мәхмүтов

Җаек казагы. Ничә яшьтә булуы һәм кайсы елда Җаек шәһәрчегендә яши башлавы билгесез. Тарихи хезмәтләрдә аның исем-фамилиясен шактый буташтырып, «Балтай Идоркин, Бахмутов, Байбеков» һәм төрекмән, татар, башкорт дип телгә алганнар.  Безнең «сөекле» оппонентыбыз Салават Таймасов мәкаләсендә дә, билгеле ки, каһарман Идеркәй «Баймеков» фамилиясенә һәм башкорт милләтенә ия булган. Башкорт галимнәренең хезмәтләрендә моның ише үзләштерүләр һич яңалык түгел, ә дөресе болай: Идеркәйнең Яр Чаллы авылында Миңлебикә исемле туганы була. Ул Габбас Тодошев атлы төрекмәнгә кияүгә чыга. Пугачев явы башланганда, Габбас белән Миңлебикәнең Балтай (Болтай) исемле инде үсеп җиткән уллары була. Пугачев янына Идеркәй шул туганы — Балтай белән бергә килеп кушыла. Фетнәчеләр аларны аталы-уллы кешеләр дип кабул итәләр. Шушы факт тарихчыларны буталышка кертә

(*С. Алишев*. «Татары...», 77 с.). Инде аңлашылганча, Идеркәй — Яр Чаллыда туып, Җаек шәһәрчегенә күченгән татар.

Ул Җаек казаклары арасында бик зур ышаныч казанган, абруйлы шәхес була. Шуңа күрә 1773 елның әле 15 сентябрендә үк казаклар аны бик санаулы кешеләр арасына «падишаһ»ны карарга чакыралар. Бу вакытта «падишаһ»ның Усиха елгасы буенда, Кожевниковлар хуторында яшеренеп ятуын, 20—30 лап кына казак белә.

Әлбәттә, укымышлылыгы белән башкалардан нык аерылып торган Идеркәй Пугачевның нинди «падишаһ» булуын бик шәп аңлагандыр. Әмма ул аны булачак фетнәнең какшамас юлбашчысы дип кабул итә һәм аңа Җаек буенда яшәгән татарларны алып килергә вәгъдә бирә. Һәм икенче көнне үк Идеркәй 20 ләп татар белән Толкачевлар хуторында Пугачевка килеп кушыла. 16 сентябрьдә «падишаһ» кул астына тупланган иң тәүге отрядтагы 60 кешенең 20 се Идеркәй алып килгән татарлар була (*В. Буганов*. «Емельян Пугачев», 51—52 с.).

Идеркәй моннан соң да Пугачев гаскәренә татарларны җәлеп итү өчен күп көч куя. 18 сентябрьдә 200 кешелек отрядтагы татарлар саны 40 тан арта. Шул көнне Идеркәй казах ханы Нуралига хат яза һәм аны «падишаһ»ка кушылырга өнди. Шушы көнне үк Пугачев янына Нурали ханның сәркатибе, Казан татары Зәбир мулла килә. Гәрчә Зәбир Петербургта Петр III не күргән кеше булса да, Пугачевны «патша» дип таный. Ул Нуралигә Идеркәй кулы белән язылган хатны алып китә һәм тиздән Нурали Дусали солтан җитәкчелегендәге 200 кешелек отрядны «падишаһ» карамагына җибәрә. Зәбирнең «падишаһ»ны тануында да, Нурали ханны үгетләү- дә дә Идеркәйнең йогынтысы, һичшиксез, гаять көчле була.

Крепость артыннан крепость яулап, Пугачев отряды 1 октябрьдә Оренбург янына килеп җитә. Бу вакытта ук инде аның сафында 200 гә якын татар була. Гәрчә казаклар Пугачевны тизрәк Оренбургны камарга өндәсә дә, «падишаһ» иң әүвәл Каргалы бистәсенә юнәлә. Ул чорда Каргалы Оренбургка караганда да зуррак сала була. Ә Пугачев Каргалыга андагы татарлар чакырганга гына түгел, бәлки Идеркәй тәкъдиме буенча да килә. Нәтиҗәсе билгеле: Пугачевка Каргалыда 500 татар кушыла.

Гомумән, фетнәнең тәүге көннәрендә һәм Пугачев отрядын туплауда татарлар арасыннан нәкъ менә Идеркәй Мәхмүтов гаять зур активлык күрсәтә. Ул татарларны гына түгел, инде башкортларны да фетнәгә кушылырга чакырып хатлар юллый. Башкорт старшиналары Кинҗә Арысланов, Галибай Морзаголов, Ямансарый Яппаров исеменә хатларны һаман да шул Идеркәй язып җибәрә. Аның бу эшчәнлеге дә уңышка китерә: октябрь башында Кинҗә белән Ямансарый отрядлары фетнәчеләр сафына килеп кушыла. Оренбург янында октябрь аенда булган бәрелешләрдә дә Идеркәй Мәхмүтов, һичшиксез, татар отрядларының җитәкчесе буларак катнаша.

Пугачев аның фидакарьлеген һәм укымышлылыгын югары бәяли. 6 ноябрьдә Бирдә бистәсендә Хәрби коллегия оештырылгач, Идеркәй белән Кинҗә аның әгъзалары булып билгеләнә. Алар Хәрби совет киңәшмәләрендә дә катнашалар.

Ә 7 ноябрьдә Йөзәй авылы янына генерал В. Кар килеп җиткәч, 1500 кешелек татар-башкорт отрядына башлык итеп билгеләп, Пугачев Идеркәйне карательләргә каршы озата (*В. Буганов*, шул ук хезмәт, 85 б.). Моның да нәтиҗәсе билгеле: Андрей Овчинников, Чика-Зарубин, Соколов-Хлопуша отрядлары белән бергә хәрәкәт итеп, Идеркәй җайдаклары генерал А. Карны Мостафа, Сарманай авылларына кадәр эзәр- лекли.

Шушы урында тагын бер мәгълүмат өстик. Без 10 ноябрь көнне Биккол авылы янына Галибай Морзаголов җитәкчелегендәге 1200 кешелек татар-башкорт отряды килеп җитү хакында күп тапкырлар яздык (Салават Юлаев та шушы отряд составында була). Атаман Зарубин соңыннан, допрос вакытында, шушы отряд янына үгетче мөселманнар группасы җибәрелү, алар арасында Кинҗәнең туганы да (ул — Котлыкилде Габдрахманов) булуы турында телгә ала (*И. Гвоздикова*, 125 б.). Бу группаны фәкать Кинҗәнең генә юллавы мөмкин түгел. Чөнки 1500 татар-башкорт җайдагы белән Идеркәй җитәкчелек итә, димәк, Кинҗә аңа буйсына. Шулай икән, үгетчеләр Идеркәй ризалыгы белән сайланган. Нәтиҗәсе: Идеркәй белән Кинҗәнең йогынтысы Г. Морзаголов җитәкчелегендәге 1200 татар-башкорт җайдагының Пугачев ягына чыгуына ярдәм иткән.

Идеркәй Бирдә лагеренда Пугачевның иң якын һәм иң ышанычлы ярдәмчеләренең берсе булып тора. 2 апрельдә Каргалы — Сакмар арасында тар-мар ителгәч, Идеркәй Пугачев белән бергә кача. Ташлы авылында Кинҗә белән бергә Идеркәй дә Пугачевны Урал тауларына, Уфа провинциясенә китәргә үгетли. Шуннан соң Казанга кадәр Пугачев белән бергә авыр юл уза, һәммә яуларда катнаша. Казанны штурмлаган чакта фетнәчеләрнең бер колоннасы белән җитәкчелек итә, татар бистәләрен кулга төшерүдә зур роль уйный. Казанны штурмлау һәм Михельсон корпусы белән бәрелешләргә керү алдыннан татар крестьяннарын отрядларга туплауда, аларның командирларын билгеләүдә Идеркәй зур активлык күрсәтә.

15 июльдәге яудан соң Идеркәй Мәхмүтов карательләр кулына төшә. Әүвәл Казандагы Яшерен комиссиядә җәзага тартыла. Ноябрьдә аны Пугачев «җинаятьләре»н тикшерү комиссиясенә «күрсәтмәләр бирү» өчен Мәскәүгә алып китәләр. 18 ноябрь—5 декабрь көннәренең берсендә Идеркәй тикшерүчеләр каршында Пугачев белән очраша.

10 гыйнварда Сазлы мәйданында Идеркәй дә Пугачевны һәм аның көрәштәшләрен җәзалап үтерүне карап тора. Шуннан соң аны чыбыркы белән кыйныйлар, борынын кисеп алалар, маңгаена һәм яңакларына мөһер сугалар. Идеркәй Таганрог крепостена каторга газапларын кичәргә озатыла. Мөгаен, ул анда татар халкының тагын бер батыр улы Мәсгуть Гомәров белән очрашкандыр. Әмма бу турында мәгълүматлар юк, Идеркәйнең шуннан соңгы язмышы билгесез («Следствие и суд над Пугачевым»; *С. Алишев, И. Гвоздикова, Н. Дубровин, В. Мавродин*).

### 12. Садыйк Сәгыйтов

Каргалы бистәсе татары, сәүдәгәр, 1744 елда Байлар Сабасыннан күчеп, Каргалыга нигез салучы Сәгыйт байның улы. Пугачев отрядына 1 октябрьдә кушыла. Мөгаен, ул октябрь аенда Оренбург гарнизоны белән бәрелешләрдә зур батырлык һәм хәрби осталык күрсәтеп өлгергәндер. Бирдә бистәсендә ноябрь аенда Хәрби совет оештырылгач, Пугачев бу каһарманны тиктомалдан гына аның әгъзасы итеп билгеләмәс иде.

Садыйк Сәгыйтов исеме телгә алынган тарихи документлар бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Әмма вакыйгалар агышына карап нәтиҗә ясаганда, Садыйк Пугачев белән янәшәдә иң озын юлны үтүчеләрнең һәм аның иң якын көрәштәшләренең берсе була.

1773 елның 5 октябреннән 1774 елның 2 апреленә кадәр Оренбург, аннары Магнитная, Троицк, Кундрава, Кыйгы, Красноуфимск, Уса, Ижевск, Казан, Саратов, Царицын, Солениковая ватага янында булган яуларның һәммәсендә, һичшиксез, Садыйк Сәгыйтов та катнаша. Пугачев белән бергә Иделнең сулъягына качкан 164 кеше арасында Садыйк Сәгыйтов, Кинҗә Арысланов һәм тагын ике Казан татары да була. Алар 8 сентябрьгә кадәр Пугачевны озатып баралар, шуннан соң 4 мөселман да эзсез югала («Следствие и суд над Пугачевым»; *Н. Дубровин, В. Панеях*).

### 13. Асылхуҗа Мутачев

Минзәлә янындагы Бикбау авылына тупланган фетнәчеләр башлыгы. 1774 елның 13 гыйнварында Асылхуҗа Нагайбәк крепостенда торучы атаман Вәлит Торновка хат юллый һәм үзенең дәрәҗәсен «полковник» дип күрсәтә («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Билгеле булганча, Минзәләне камалышта тотучы фетнәчеләр башлыгы полковник Каранай Моратов 11 гыйнварда Кама буендагы Бәтке пристанена китә («Воззвания...», док. №61). Ә 12 гыйнварда Минзәлә гарнизоны шәһәрдән чыга һәм Дәвек, Мажын авылларында торучы фетнә отрядларын куып тарата *(С. Алишев)*. Крестьяннар Тәкермән һәм Бикбау авылларында лагерь корып урнашалар. Каранайның Тоба крестьяны Габделҗәлил Сөләймановка да полковник дәрәҗәсен бирүе мәгълүм. Шулай булгач, Бикбау лагере башлыгы Асылхуҗа Мутачевка да полковник дәрәҗәсен Каранай Моратов биргәндер, дип нәтиҗә ясарга ныклы нигез бар. Асылхуҗа турында бүтән мәгълүматлар юк.

### 14. Габделкәрим Рахманкулов

Азнакай районындагы Чалпы авылының ясаклы татары. Фетнәгә 1773 елның ноябрендә Уфа янына барып кушыла. Ноябрь ахырында Уфа каласы камалышка алына. Татар, башкорт, мари крестьяннарыннан торган отрядлар алдагы җомгада (?) Уфага штурм ясарга хәзерләнәләр. Штурм өчен туплар белән ярдәм итүен сорап, Пугачевка хат язалар һәм Бирдә бистәсенә чапкын юллыйлар. Хатка старшиналар Мәгъсүт Үтәгәнов, Ихсан Баязитов (соңрак хыянәтче), Сәетбаттал (Бабтай) Мөслимов, Турай Ишалин (Ишаев), йөзбашы Гали Хөсәенов, депутат Габделкәрим Мәгъсүтов, мари Байки Урмекеев белән бергә сәркатип Габделкәрим Рахманкулов та кул куя («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Әлбәттә, Чалпы авылыннан Уфа янына Рахманкулов берьялгызы гына бармагандыр.

Вакыйгалар агышыннан билгеле булганча, 24 ноябрьдә Уфа янына Пугачев эмиссары Качкын Самаров килеп җитә. Шул көнне Чесноковка авылындагы 1000 нән артык фетнәче Уфа администрациясенә беренче мәртәбә ультиматум җибәрәләр, гарнизонны «падишаһ» гаскәренә буйсынырга чакыралар. Гарнизон фетнәчеләр таләбен кабул итми. Ә көчләр аз булу сәбәпле, фетнәчеләр штурм ясарга җөрьәт итмиләр.

Уфа янына яңа отрядлар алып килү өчен, һәр якка чапкыннар озатыла. Рахманкулов үзенең туган төбәгенә кайтып китә. Бу вакытта инде Бакалы — Азнакай — Минзәлә төбәген дә фетнә ялкыны чолгап алган була. Азнакайлылар хәзерге Бакалы районының чигендә урнашкан Нагайбәк крепостена юнәләләр. Крестьяннарны Чалпы авылы каһарманнары Нагайбәк Әсәнов һәм Габделкәрим Рахманкулов әйдәп бара. Крепостька нинди куркыныч янавын ишеткәч, Бөгелмә каласында торучы генерал Ф. Фрейман секунд-майор Осип Тәвкилев җитәкчелегендәге 400 татар-башкорт җайдагын Нагайбәк гарнизонына ярдәмгә озата. Әмма 6 декабрь көнне Тәвкилев Акбаш авылына җиткәч, аңа Качкын Самаров отряды һөҗүм итә. Татар-башкорт җайдаклары Самаров ягына чыга, Тәвкилев кырда җәзалап үтерелә («Крестьянская война... на территории Башкирии», 352 с. *Безнең оппонентыбыз Салават Таймасов ни өчендер Йосыф Тәвкилевне гомерлерәк иткән, Бирдә бистәсенә алып барып астырган. «Әллә ярата микән?»).*

Нагайбәк крепосте камалышта кала. Комендант секунд-майор Рушинский белән капитан Алексеев, Нагайбәкне ташлап, Минзәләгә кача. Крепость Рахманкулов һәм Әсәнов отрядлары кулына күчә. Әлеге җиңү турындагы хәбәр 15 декабрьдә Пугачевка барып җитә. Фәрман язып, Пугачев чукынган фарсы кешесе Вәлит Торновны Нагайбәккә атаман итеп җибәрә.

Торнов 20 декабрьдә Нагайбәккә килеп җитә һәм Кама аръягында хәрәкәт итүче фетнә отрядларының юлбашчысына әверелә. Рахманкулов аның сәркатибе һәм походный старшина булып хезмәт итә башлый. Ә Нагайбәк Әсәновка 900 кешелек отряд биреп, Торнов аны Зәй каласын штурмларга озата.

Торнов һәм Рахманкулов гыйнвар аенда яңа отрядлар туплау белән шөгыльләнәләр, аларны Уфа һәм Минзәләне камалышта тотучы гаскәр сафына озаталар. Чесноковкада торучы атаман Зарубинга хат язып, алар туплар да сорыйлар. Ләкин Зарубин аларга ярдәм итми («Крестьянская война... на территории Башкирии», док. № 48). Һаман да шул туплар алу максатыннан 25 гыйнвар тирәсендә Торнов үзе Зарубин янына китә. Инде полковник дәрәҗәсенә лаек булган Габделкәрим Рахманкулов ул югында крепостька тупланган фетнәчеләр башлыгы булып кала («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

Казаннан чыккан полковник Ю. Бибиковның җәза командасы тиздән әлеге төбәккә дә килеп җитә. 30 гыйнварда Бибиков Минзәләне камалышта тотучы крестьяннарны куып тарата. Андагы фетнә отрядларының җитәкчесе Каранай Моратов Нагайбәк крепостена чигенә. Әле аңа кадәр үк Кукмара, Зәй янында тар-мар ителгән отрядларның башлыклары Мәсәгуть Гомәров, Нагайбәк Әсәнов та Нагайбәккә килгән булалар. Бер крепостька Пугачевның биш-алты атаманы туплану да фетнәчеләрне җиңелүдән коткара алмый. Дөрес, Каранай белән Торнов Пугачевтан ярдәм сорау өчен Бирдә бистәсенә китеп бара (*С. Алишев*. «Татары...», 123, 132 с.). 6 февральдә Нагайбәк янына полковник Ю. Бибиков карательләре килеп җитә һәм фетнәчеләр каршылыгын җиңеп крепостька керә.

Крестьяннар Бакалыга чигенә. Бибиков аларны эзәрлекләп бара һәм 11 февральдә Бакалыны да ала. Шуннан соң Бибиков Бөгелмәгә китеп бара. Ә төрле авылларга таралган 2000 гә якын фетнәче янә бер йодрык булып туплана. Аларга ярдәмгә Чесноковкадан атаман Иван Кузнецов белән полковник Илья Ульянов та килеп җитә. 17 февральдә крестьяннар Бакалыны кабат үз кулларына төшерәләр. Ул арада Бакалы янына Бирдәдән Вәлит Торнов белән Каранай Моратов та кайтып җитә. Крестьяннар Бакалы күл авылына тупланалар, шуннан килеп Нагайбәккә һөҗүм итәләр. Секунд-майор Перский командалыгында калган бер рота солдат крестьяннарның һөҗүменә каршы тора алмый. 19 февральдә крестьяннар крепостька бәреп керә, Перский үтерелә.

Ләкин 6 март көнне Нагайбәк янына генерал Ларионов корпусы килеп җитә һәм фетнә отрядларын куып тарата. Крестьяннар Эстәрлетамак авылына чигенә. Карательләрнең бер отряды аларны эзәрлекләп бара һәм 10 март көнне Эстәрлетамакны да ала. 13 мартта Бакалы янына тупланган фетнәчеләр дә тар-мар ителә.

Гәрчә тарихи документларда аның исеме аерым телгә алынмаса да, һичшиксез, югарыда саналган яуларның һәркайсында полковник дәрәҗәсен йөртүче Рахманкулов та катнаша. Ә 24 мартта Чесноковкада — Зарубин, 22 март һәм 2 апрельдә Пугачев гаскәрләре дә тар-мар ителә. Барча төбәкләрдәге шикелле үк Нагайбәк — Азнакай — Бөгелмә янында да фетнә хәрәкәте вакытлыча туктала.

Рахманкуловның апрель — июнь айларындагы эшчәнлеген тасвирлаучы тарихи документлар юк. Аның исеме документларда кабат 1774 елның 26 июнендә генә пәйда була («Воззвания...», док. № 130). Әлеге документтан күренгәнчә, Габделкәрим бу вакытта Галибай Морзаголов отрядында сәркатип булып тора.

Билгеле булганча, 26 июньдә Уса яныннан Уфа провинциясенең Ногай юлына бригадир Канзафар Усаев кайтып төшә һәм ашыгыч рәвештә яңа отряд туплый башлый. Ул, чапкын юллап, Галибай Морзаголовның да фетнәгә кушылуын таләп итә. Галибай әүвәл, төрле хәйлә табып, читтә калырга тели, әмма Канзафарның тиз арада 1000 кешелек отряд туплавын күреп, ул да фетнәгә кушыла. 5 июльдә Галибай отряды да Аслай Курманаев, Ибраһим Уразбахтин, Кәип Зиямбәтов, Илчегол Таймасов, Ибраһим

Мерәсев, Кыдрач Муллакаев командалары белән кушыла һәм Эстәрлетамак пристане янында генерал П. Голицын корпусына һөҗүм итә. Фетнәчеләр җиңелә. Ә 17 июльдә Галибай Морзаголов, Кыдрач Муллакаев, Кәип Зиямбәтов һәм башкалар Кармасан елгасы буенда генерал Голицыннан гафу үтенә. Дөрес, Аслай Курманаев әле сентябрь аена кадәр фетнәдә катнаша. Ә Нәдер волостеның татар старшинасы Ибраһим Уразбахтинны карательләр хәтта ноябрь аенда да кулга төшерә алмый.

Июльдән соң Пугачев полковнигы Габделкәрим Рахманкулов исеме телгә алынган документлар юк. Шуңа күрә без аның алдагы язмышы турында берни дә әйтә алмыйбыз («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»; «Крестьянская война... на территории Башкирии»; *С. Алишев*; ЦГАДА, 6 фонд, 431 эш).

### 15. Әит Үрәзмәтов

### (1718—1774)

Бөгелмә төбәгендәге Абдул авылының (Әлмәт районындагы Түбән Абдул, хәзерге Елховой) ясаклы татар крестьяны. Аның исеме тарихи документларда әле 1760 елда ук пәйда була. Ул елны батыр Морат мулла, урыс коллыгыннан котылу һәм Казан ханлыгын кабат торгызу өчен, мөселман халкына милли-азатлык көрәше башларга чакыру ташлый. Үзенең якыннарын төрле төбәкләргә үгетчеләр итеп озата. Бала чакта ук Морат мулла мәдрәсәсендә укыган Әит Үрәзмәтов та шулар арасында була. Ләкин хыянәтчеләр Морат мулла турында Казан администрациясенә хәбәр итә. Морат үзе, аның якыннары тиз арада кулга алына һәм Петербургка озатыла. Морат мулланың шәхсән үзе турында мәгълүмат юк. Мөгаен, ул 1755 елгы фетнә башлыгы Батырша кебек үк кайсы да булса зинданга ябылгандыр һәм гомерен шунда төгәлләгәндер. Ә башкаларга карата патша хөкүмәте «киң күңеллелек» күрсәтә. Зинданнарда җәзаланганнан соң, алар иреккә чыгарыла.

1773 ел уңышын җыеп алганнан соң, 56 яшьлек Әит икмәк сату өчен Оренбургка бара. Ул анда «падишаһ» хакында ишетеп өлгердеме икән? Монысы мәгълүм түгел. Ләкин мондый хәбәр Абдул авылына килеп җитүгә үк, октябрь аенда, мондагы крестьяннар отрядка берләшәләр. Бертуган Әит һәм Тимербулат Үрәзмәтовлар, Әитнең улы Габдерәшит отрядның җитәкчеләренә әверелә. Яше буенча өлкән, җитмәсә, укымышлы һәм тәҗрибәле Әит отрядның башлыгы итеп сайлана. Абдуллылар Тимербулатны «падишаһ» янына указ алырга җибәрәләр. Тимербулат Бирдәдә Пугачев белән очраша. Пугачев аңа кафтанлык ал тукыма бүләк итә, указ бирә. Тимербулат кайткач, алар Әит, Габдерәшит белән өчесе күрше авыл крестьяннарын да үз отрядларына туплый башлыйлар. Фетнәчеләр саны әүвәл 200 гә, аннары 900 гә җитә. Отряд Бөгелмә янында хәрәкәт итә, Бөгелмәгә бикләнгән генерал Ф. Фрейман белән башка крепостьларда торучы җәза отрядлары арасындагы элемтәне өзә. Рәҗәп авылында (Самара өлкәсе чигендә, Шөгердән 30—40 чакрымда) торган секунд-майор Шишкин Бөгелмәдә камалышта калган гарнизон өчен 40 олау белән азык-төлек озаткач, Үрәзмәтовлар отряды аңа һөҗүм итә. Фетнәчеләр каравыл командасын юк итәләр, азык-төлекне крестьяннарга өләшәләр. Каравыл командасы офицерын Маклауш авылында (Старый Маклауш — Самара өлкәсе чигендә, Акбаштан 30—40 чакрымда) асып үтерәләр. Шуннан соң Әит Үрәзмәтов шушы ук төбәктә хәрәкәт итүче фетнә отрядларының башлыклары — урыс крестьяны Иван Черняев, походный старшина Муса Мостафин, керәшен татарлары Гаврила Давыдов һәм Осип (Йосыф) Енгалычев белән бәйләнешкә керә. Алар бергәләп Шишкин командасына һөҗүм итәргә сүз беркетәләр. Беренче булып Рәҗәп авылы янына Әит Үрәзмәтов һәм Черняев отрядлары килеп җитә. Үрәзмәтов кул астында 2 генә туп булса да, фетнәчеләр беренче булып һөҗүм ясый. Давыдов үз отряды белән кичке якта гына пәйда була. Муса Мостафин яуга килеп өлгерми, ул бу вакытта Шәрип авылында (дөресе «Колшәрип» булырга тиеш, Әлмәт районында) кала. Йосыф Енгалычев Рәҗәп янына кайчан килеп җиткән? Монысын әйтеп булмый. Барлык отрядлар бергә кушылгач, фетнәчеләр саны 3000 кешегә, туплар 4 кә җитә. Ләкин тәмам караңгы төшкәнче һөҗүм итсәләр дә, крестьяннар регуляр гаскәрне җиңүгә ирешмиләр. Икенче таңда депутат Давыдов Сок-Кармала авылына (Новая Кармала булса, Самара өлкәсе чигендә, Нурлаттан 50 чакрымда) китә. Ә Үрәзмәтов белән Черняев Ташлы авылына (Баулы районында) кайтып урнаша.

Әит шуннан үзенең улы Габдерәшитне һәм энесе Тимербулатны янә Бирдә бистәсенә Пугачев янына озата. «Падишаһ» Рәҗәп авылы янында күрсәткән батырлыгы өчен Әит Үрәзмәтовка корпус старшинасы (!) дәрәҗәсен бирә, шул хакта махсус указ җибәрә («Документы ставки Е. И. Пугачева...» китабын төзүчеләр Әит Үрәзмәтовны атаман һәм полковник дип күрсәтәләр.— 441 б.; С. Алишев аны полковник дип яза. — «Татары...», 97 б. Без тагын шуны гына ассызыклап китәргә телибез: Пугачев «корпус старшинасы» дәрәҗәсен Иван Черняев һәм Әиттән кала бер кешегә дә бирми!). Тимербулат походный старшина

дәрәҗәсенә лаек була. Ә этисе эзеннән киткән Габдерәшит Әитовны «падишаһ» полковник дәрәҗәсе белән олылый һәм аны үз янында калдыра.

Гыйнвар аенда да Әит Бөгелмә ведомствосында хәрәкәт итүче отряд башлыклары О. Енгалычев, М. Дмитриев, И. Черняев белән тыгыз бәйләнештә тора. Алар Мәләкәс заводын камалышка алалар, Тиинск (?), Биляр-Озеро (Октябрь районында) авыллары аша үтәләр. Гыйнвар уртасында фетнәчеләр, үзара берләшеп, Чирмешән крепостена килгән генерал-майор Александр Миллер командасына һөҗүм итәргә карар кылалар.

16 гыйнвар көнне Үрәзмәтов белән Иван Черняев генерал Миллер исеменә хат язалар һәм аны, Андрей Тимофеев атлы малайга тапшырып, крепостька җибәрәләр. Фетнә җитәкчеләре Миллерны төрлечә мыскыл итә, үзләренең «12 меңлек» гаскәре һәм ярдәмгә килеп җитәчәк «граф Чернышев» (ягъни Зарубин) дивизиясе белән яный. Миллер да, нәкъ Бөгелмәдәге генерал Фрейман шикелле үк, бу вакытта әле Биләр, әле Чирмешән крепостенда яшеренеп ята. Ә Чирмешән крепостенда Миллер туплап алып килгән отрядтан тыш тагын комендант секунд-майор Иван Токарев командасы да була. Якын-тирәдә секунд-майор В. Елагин командасы йөри.

Фетнәчеләр Чирмешәннән 20 чакрымдагы Подлесный авылында лагерь корып урнашалар. Лагерьга Әит Үрәзмәтов, Енгалычев, Черняев, Попов җитәкчелегендәге 2000 крестьян туплана, аларның 5 тубы була. 20 гыйнвар көнне фетнәчеләр Чирмешән крепостена юнәлә. Ләкин аңа җиткәнче үк аларны карательләр командасы каршы ала. Канлы яу барышында фетнәчеләр тар-мар ителә. Әит Үрәзмәтов, Йосыф Енгалычев, Попов һәм тагын берничә җитәкче карательләр кулына эләгә. Аларны әүвәл секунд-майор Астафьев җәзалый, 2 февральдә Казандагы Яшерен комиссия карамагына озата. Комиссия җәлладлары да аларны коточкыч газаплап сорау ала. Шул газапларга түзмичә, Әит Үрәзмәтов 7 февральдә Казан төрмәсендә җан бирә («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; *С. Алишев*. «Татары...»; ЦГАДА, 6 фонд, 456 эш).

**16. Габдерәшит Әитов**

Бөгелмә төбәгендәге Абдул авылының ясаклы татар крестьяны. Бөгелмә янында хәрәкәт итеп, карательләрнең үзәгенә үткән, әмма соңыннан әсирлеккә эләгеп Казан төрмәсендә вафат булган каһарман Әит Үрәзмәтовның улы. Гәрчә соңыннан, сорау алу вакытында, Габдерәшит үзе турында «мин фетнәгә 1773 елның декабрендә кушылдым» дип белдерсә дә, мөгаен, бу аның үз гаебен киметеп күрсәтергә тырышуы гына булгандыр. Мондый алымны соңыннан Салават Юлаев, Канзафар Усаев кебек каһарманнар да куллана. Габдерәшит тә байтак серне җәлладлардан яшереп калдыра.

Безгә Әит Үрәзмәтовның энесе Тимербулатның Пугачев янына Бирдә бистәсенә октябрь ахырында баруы билгеле. «Падишаһ»тан указ алып, ул ноябрь башында Абдулга әйләнеп кайта. Шуннан соң Әит һәм Тимербулат гаять энергияле рәвештә отряд туплый башлый. Бу эштә, һичшиксез, аларга Габдерәшит тә ярдәм итә. Әле 1760 елда ук милли-азатлык явы кузгатырга җыенган, шуның өчен кулга алынып, Петербург зинданнарында җәзаланган, әмма күңелендә гыйсъянлык рухы сүнмәгән Әит тәрбиясендә үскән Габдерәшитнең, этисе отряд туплап йөргәндә, читтә гамьсез хәлдә ятуы мөмкин түгел. Татар дөньясында ата сүзе, ата үрнәге, гомумән, тайпылышсыз закон булуын да онытмыйк.

Декабрь ахырында Әит Үрәзмәтов әүвәл Иван Черняев отряды белән кушыла. Аннан соң Әит Йосыф Енгалычев, Гаврила Давыдов, Муса Мостафин белән дә бәйләнешкә керә һәм бергә хәрәкәт итәргә сүз беркетә. Әит Үрәзмәтов белән Иван Черняев отряды Рәҗәп авылында торучы секунд-майор Шишкин командасына һөҗүм итә. Икенче көнне алар Баулы районында Ташлы авылына кайтып китә.

Габдерәшит Әитов үзенең агасы (этисенең энесе) Тимербулат Үрәзмәтов белән бергә Ташлыдан Бирдә бистәсенә юнәлә. Гыйнвар башында «падишаһ» янына кереп, алар Рәҗәп авылы янында булган яу турында рапорт бирәләр. Пугачев Үрәзмәтовлар күрсәткән активлыкны югары бәяли. Әит Үрәзмәтов белән Иван Черняев — корпус старшиналары, Тимербулат походный старшина дәрәҗәсенә лаек була. Этисе Әит үрнәгенә ияргән Габдерәшитне «падишаһ» аеруча ошата һәм якын итә, күрәсең. Ул аны полковник дәрәҗәсе биреп олылый һәм, үз янында «хезмәт итү» өчен, Бирдә бистәсендә калдыра. Оренбург янына тупланган татар крестьяннарының саны гыйнвар аенда инде меңәрләп исәпләнә. Казан татары Абдул һәм Каргалы сәүдәгәре Муса Алиевтан тыш, алар белән җитәкчелек итү өчен, татар полковниклары да кирәк була. Габдерәшиткә дә аерым полк тапшырыла һәм, вакыйгалар агышыннан күренгәнчә, Пугачев әлеге каһарман егетне, чыннан да, якын күрә һәм үзе белән походларга алып йөри.

Февральнең 10 нары тирәсендә Пугачев Бирдәдән Җаек шәһәрчегенә юнәлә. Бозаулык крепостена җиткәч, «падишаһ» Габдерәшит отрядын шунда калдыра, ә үзе ары китә. 14 февральдә Бозаулык янына генерал-майор Мансуров кул астындагы подполковник Гринев командасы килеп җитә. Атаман Илья

Арапов отряды, Саратов янындагы Мачын бистәсе татарлары белән бергә полковник Габдерәшит Әитов җайдаклары да Гринев карательләренә каршы яуга керә. Ләкин Бозаулык янына генерал Мансуров үзе килеп җитә, фетнәчеләр Сорочинск крепостена чигенә.

Март башында «падишаһ» үзе дә әлеге крепостька килә. Секунд-майор В. Елагин җитәкчелегендәге карательләрнең Пронькино авылына керүләре турындагы хәбәрне алгач, Пугачев Сорочинск крепостендагы 2300 җайдакны үзе белән ала. Бер төн эчендә 37 чакрым ара үтеп, 7 март иртәсендә фетнәчеләр Пронькинога бәреп керә. Габдерәшит Әитов Пугачев белән иңгә-иң торып сугыша. Ләкин тиздән авылга Хорват полкы килеп фетнәчеләрне куып тарата.

22 мартта Татищев крепосте янында булган яуда да Габдерәшит Әитов янә Пугачев янәшәсендә була. Тар-мар ителүдән соң, Габдерәшит карательләр кулыннан качып котыла һәм Бирдә бистәсенә кайта. Әмма 2 апрельдә Каргалы — Сакмар арасында булган яуда Пугачев атаманнары Шигаев, Витошнов, Иван Почиталин, Горшков һәм башкалар белән бергә татар полковнигы Габдерәшит Әитов та карательләр кулына эләгә. Аны Оренбург зинданында Яшерен комиссия җәлладлары җәзалый. Кызганычка каршы, абыйсы Тимербулатныкы кебек үк, аның да алдагы язмышы мәгълүм түгел (ЦГАДА, 6 фонд, 467 эш, XIII бүлек, 192—195 б.; «Под знаменем Пугачева»).

*Башкортлар арасыннан аталы-уллы Юлай Азналин белән Салават Юлаев кебек каһарманнар үсеп чыгу бөтен дөнья халыкларын сокландырып килде. Коточкыч гамьсезлек, наданлык: корпус старшинасы Әит, походный старшина Тимербулат, полковник Габдерәшитнең бер гаилә вәкилләре булуын, хәтта татар дөньясында да искә алучы һәм белүче юк! Ата кеше зинданда җәлладларның коточкыч җәзалавына түзмичә җан биргән. Шуның улы Габдерәшит һәм энесе Тимербулат та, мөгаен, йә ерак сөргендә, йә һаман да шул җәлладлар җәзалавыннан вафат булганнардыр. Газиз халкының азатлыгы хакына бу чаклы корбаннар бирү, мондый фидакарьлек — ул бөтен Пугачев явы дәвамындагы бердәнбер үрнәк! Шул каһарман гаиләне татар халкы белми. Оят, хурлык! Шушы мисалдан соң нинди бөеклек, нинди бердәмлек, нинди данлы тарих турында сөйләү мөмкин?!*

*Шушы урында үзебезнең шәхси үпкәбезне дә белдерми уза алмыйбыз. 1999 елда Казанда «Татар энциклопедия сүзлеге» дөнья күрде, 2002 елда янә шул ук Татарстан энциклопедия институты киңәйтелгән «Татар энциклопедиясе» хезмәтенең 1 томын рус телендә бастырып чыгарды. Соңгысында Габдерәшит Әитов турындагы язма астына «мәгълүматлар 1973 елда Чиләбедә чыккан «Под знаменем Пугачева» исемле китаптан алынды» дип аңлатма бирелгән. Бу китапның бер нөсхәсе безнең шәхси китапханәбездә дә саклана. Әмма әлеге китапта без югарыда санап чыккан мәгълүматларның йөздән бер өлеше дә юк. Институт хезмәткәрләре әлеге энциклопедияне хәзерләгәндә, бездән 2000 елның язында «Мәдәни җомга» газетасында «Исемең ничек, татар авылы?» дигән топографик язмада шушы ук институтны татар авылларының тарихын белмәүдә һәм бутап бирүдә гаепләгән өчен үч алган дип нәтиҗә ясамый мөмкин түгел. Гәрчә 1994 елда дөнья күргән безнең «Сәет батыр» китабына кадәр татар дөньясында Әит Үрәзмәтов белән Габдерәшитнең аталы-уллы каһарманнар булуын, Габдерәшитнең исә хәтта исемен дә белүче юк иде. Шулай ук Канзафар Усаев белән Ярмөхәммәт Кадермәтовның Пугачев армиясендә бригада генералы дәрәҗәсенә ирешүен, Бакый Абдуллов, Садыйк Сәгыйтов, Балтач Сәетов, Халит Әминев, Габдулла Мостаев, Рахманкул Дуслиев, Батыркай Иткинин, Гадел Бигашев, Әбди Абдуллов, Габдулла Туктаров, Әдигот Тимачев кебек полковникларның исемнәрен дә татар тарихында тәүге мәртәбә без күтәреп чыктык. Тарихның төпкеленәрәк төшсәк, безнең «Татарларның Ватан сугышы» һәм «Запрятанная история татар» китаплары басылып чыкканчы 1682, 1705, 1735 еллардагы милли-азатлык яуларын җитәкләгән Теләкәй — Күчем—Акай — Габдрахманның бер нәсел каһарманнары икәнлеген белүче юк иде. Әлеге һәммә батыр бабаларыбызның исемнәре энциклопедиядә безнең ярдәм белән урын алганга, әлбәттә горурланабыз.*

**17. Исхак Әхмәтов**

Казан янындагы Татар Кавалы авылында (Питрәч районындагы хәзерге Кавал) туган. Пугачевның сәркатибе булып хезмәт иткән, 1774 елның апрелендә Казанда җәлладлар тарафыннан дарга асылчак Исмәгыйль Туктамышев белән бергә уйнап үскән. XVIII гасыр башында кайсыдыр урыс алпавыты шушы авыл янына Владимир өязендәге 138 крепостной крестьянны күчереп утырткан. Урыслар, килгәч, татарларның җирләрен талый башлаганнар. Исхак буйга җитеп килгәндә, аның әтисе вафат була. Хуҗалыкны алып бару кыенлаша. Исхак әүвәл Урал заводларына барып эшли, шулай итеп акча тупламакчы була. Ләкин, билгеле инде, ул хуҗалыгын рәткә кертә алмый. Әнисе дә дөнья куйгач, Исхак Оренбург ягына чыгып китә һәм 1763 елда Мостафа авылына барып урнаша (шунысын искәртү дә артык булмас: Мостафа — Муса Җәлил туган авыл). Бер елдан соң ул хатыны белән 2 кызын да шунда алып килә.

1773 елның сентябрендә Исхак, үзе җыйган уңыштан 20 пот он алып, Оренбургка китә. Онны сатып, базардан товар карап йөргәндә, Оренбургның капкаларын биклиләр. 5 октябрьдә Пугачев отряды шәһәрне тулысынча камалышка ала. Гарнизон башлыклары бер кешене дә капкадан чыгармый, һәр капка янына, стеналарга көчле сак куела (шуңа да карамастан 28 октябрьдә шәһәрдәге — 44; 18 ноябрьдә — берничә дистә; 10 декабрьдә — 78; 24 ендә 100 гә якын татар Пугачев армиясенә кача. — *С. Алишев*. «Татары...», 82—83 б.).

Бер ай буе мәҗбүри «тоткынлыкта» йөргәннән соң, Исхакны Оренбург өлкәсендәге казна заводларының башлыгы Иван Тимашев чакыртып ала һәм губернатор Иван Рейнсдорп янына алып керә. 2 ноябрь көнне генерал В. Кар корпусы Бөгелмәдән чыга һәм Оренбургка бикләнгән гарнизонга ярдәмгә ашыга. 7 сендә Кар Йөзәй авылына килеп җитә. Кар белән бәйләнешкә керү өчен, Рейнсдорп татар крестьяны Исхак ярдәменнән файдаланмакчы була. Соңыннан икеләтә кайтарып бирү «шарты» белән Исхакның атын һәм олавын Оренбургта калдыралар. Ә үзенә генерал Карга адресланган махсус пакет бирәләр.

Әмма Исхак, Оренбургтан чыгуга ук, Бирдәгә юнәлә һәм пакетны Пугачев кулына тапшыра. Пугачев Исхакны Муса Алиев полкына йөзбашы итеп билгели. 7—9 ноябрьләрдә үк инде Исхак Кар корпусына каршы бәрелешләрдә катнаша. 13 ноябрь көнне Сембер коменданты полковник П. Чернышев җитәкчелегендәге Оренбург янына килеп җиткән «карательләр» корпусын камалышка алган чакта, һичшиксез, Муса Алиев полкы да читтә калмаган булырга тиеш.

Исхакның декабрь — февраль айларында күрсәткән эшчәнлеген яктыртучы документлар табылмаган. Әмма бу чорда Оренбург гарнизоны белән булган бәрелешләрдә Алиев полкының да катнашуына шигебез юк. Безгә калса, Исхак Әхмәтов шул бәрелешләрдә үзен кыю һәм оста җитәкче итеп тә танытып өлгергән булырга тиеш. Чөнки, вакыйгалар агышыннан күренгәнчә, Пугачев моннан соң Исхак йөзен (сотнясын) һәрчак үзе белән алып йөри башлый.

Исхак 7 мартта Пронькино авылында секунд-майор В. Елагин, полковник Г. Хорват командаларына каршы бәрелешләрдә, 22 мартта Татищев крепосте янында булган канлы яуда катнаша. Карательләр кулыннан исән-имин котылып, Исхак та 23 март көнне Бирдә бистәсенә кайта. Пугачев Бирдәгә тупланган фетнәчеләргә кая теләсәләр шунда таралырга куша. Ә үз янында калган отрядны 3 өлешкә бүлә. Соколов-Хлопуша отряды Каргалы бистәсе аша үтәргә, ә калмыклар көнчыгышка, казах даласына чигенергә тиеш була. Пугачев үзе, Переволоцкая крепостена таба чигенеп, Җаек шәһәрчегенә качарга ниятли. Бу очракта да Пугачев Исхакны үз янында калдыра. Хәтта Хлопушаны һәм башка фетнәчеләрне кулга алган өчен 26 мартта хыянәтчеләрдән үч алырга Каргалы бистәсенә барган чакта да, Пугачев Исхакны үзеннән калдырмый. 2 апрель көнне Каргалы — Сакмар арасында булган яуда да Исхак Әхмәтов Пугачев янында иңгә-иң торып көрәшә. Яудан исән чыккан 500 фетнәче составында Исхак та Пугачев белән бергә Ташлы авылына кача.

Шушында башкорт каһарманы Кинҗә Арысланов Исхакка шәхси задание җиткерә. Иң яхшы чаптарны биреп, ул Исхакны Югары Җаек крепосте янында хәрәкәт итүче башкорт тарханы Мәхмүт Кадриев янына озата. Мәхмүт тарханнан отряд алып, Исхак Воскресенск (Вознесенск булырга тиеш) заводында янә Пугачевка килеп кушыла.

10 май көнне Пугачев гаскәре Карагай (Уклы Карагай) крепостена килеп җитә. Крепостьта прапорщик Вавилов җитәкчелегендәге карт солдатлар командасы гына калган була. Пугачев юкка кан коярга теләми. Ул атаман Иван Белобородовны Вавилов белән сөйләшергә кертеп җибәрә. Шул вакытта Исхак Әхмәтов җайдаклары искәрмәстән һөҗүмгә ташлана һәм крепостька бәреп керә. Шушы кыюлыгы өчен Исхак полковник дәрәҗәсенә лаек була. Бу вакытта «падишаһ» кул астында 10 меңгә якын фетнәче туплана. Пугачев Исхакны 500 кешелек бер полкка җитәкче итеп билгели. Ләкин 21 май көнне Пугачевның әлеге «гаскәре» генерал Деколонг тарафыннан тар-мар ителә. 22 майда Пугачев кул астында 2000 генә фетнәче кала. Шуңа күрә Исхакка әлегә аерым полк бирелми.

Шуннан соң Исхак янә Пугачев янында озын һәм катлаулы юл үтә. Кундрава, Кыйгы, Красноуфимск, Уса, Ижевск янындагы яуларда катнаша. Казан провинциясенә кергәч, Исхак татар крестьяннарыннан аерым полк туплый. Шул полк белән ул Казанны штурмлый, 12, 13 июльләрдә Михельсонга каршы бәрелешләрдә катнаша.

Соңгы яуда җиңелгәннән соң, Пугачев Исхакны үз янына чакыртып ала һәм аңа аерым бурыч йөкли. Исхак, якын-тирә авылларга барып, ашыгыч рәвештә яңа отряд тупларга тиеш була. Ул Борис Савельев белән Әлмәт авылы вәкиле, йөзбашы Сәлим Гаделшинны ала да туган авылы Кавалга китә.

Ләкин авылда ирләр күп булмый. Чөнки аларның байтагы инде болай да Пугачев гаскәренә кушылган була; әлбәттә, качып китүчеләр дә табыла. Исхак 15 июль кичендә 100 гә якын гына крестьянны үз кул астына туплап өлгерә. Әмма инде соң була. Бу көнне Казан янында Пугачев гаскәре тулысынча тар-мар

ителә. Яудан исән чыккан 2 крестьян Кавалга кайтып җитә һәм әлеге «кара хәбәр»не халыкка җиткерә. Исхак туплаган отряд таркала. Ә караңгы төшкәч, йөзбашы Үтәгәнов һәм аның тирәсенә тупланган хыянәтчеләр Исхак Әхмәтов, Сәлим Гаделшин, Борис Савельевның өчесен дә кулга алалар. Бер-берсенә бәйләнгән хәлдә аларны арба артына тагалар һәм 16 июльдә Казанга илтеп тапшыралар. Өч каһарман да Яшерен комиссиядә җәзалана, борын-колаклары киселә һәм мәңгелек каторгага озатыла (*С. Алишев, В. Мавродин*; ЦГАДА, 6 фонд, 467 эш).

## 18. Гаврила Давыдов (1727—1774)

Керәшен татары. Тумышы белән Зөя өзенең Бәки авылыннан (Кама тамагы районында). Соңыннан Богырыслан бистәсенә күчкән. 1767 елда Екатерина II оештырган Уложение комиссиясенә Бөгелмә ведомствосындагы ясаклы татарлар депутаты булып сайланган. Димәк, инде ул чорда ук үзенең укымышлылыгы, куркусызлыгы белән бөтен тирә-юньдә зур ихтирам казанган.

*Без укучыларга Оренбург губернасы буенча сайланган депутатлар турында башка мәгълүматларны да җиткерә алабыз. Бу губернадан әлеге комиссиягә тагын 8 мөселман депутаты сайлана, шуның 6 сы татар вәкиле була. Һәммәсен дә саныйк: Исет провинциясе мишәрләреннән, ягъни мишәр булып язылган татар крестьяннары катламыннан — Габдулла морза Даушев, Уфа өязе мишәрләреннән — Габделҗәлил Мәгъсүтов, Исет ясаклы татарларыннан — Әлмөхәммәт мулла Ибраһимов, Оренбург янындагы Каргалы бистәсе татарларыннан — Мансур Палатаев, Уфа өязендәге типтәр булып язылган татарлардан — Мансур Ибраһимов, Исет башкортларыннан — Базаргол Юнаев, Уфа өязе башкортлары исеменнән — татар Туктамыш Ишбулатов һәм Оренбург өязе башкортларыннан — Мөхәммәтрәхим Ибраһимов (А. Асфандияров. «История сел и деревень Башкирской АССР». I кн., 60 с.). (Мөхәммәтрәхим дә башкорт катламына язылган татар түгел микән?) Безгә Көнгер өязендә яшәгән татарларның мулла Бакый Абдулловны депутат итеп сайлаулары мәгълүм («Воззвания...», док. №100). Читтән сайланган депутатларның һәммәсен ачыклап була. Ә менә Казан губернасыннан сайланган депутатларны төгәл санау мөмкин түгел. Һаман да шул, ничә әйтсәң, бер сүз — бездә үз халкының үткән тарихын күтәрүче фидакарьләр сирәк.*

Гаврила Давыдов Мәскәүдә, әлбәттә, без югарыда телгә алган кешеләр белән дә, шулай ук Оренбург казаклары арасыннан сайланган депутат, йөзбашы Тимофей Падуров белән дә очраша. Екатеринаның «бөек» фәрманы буенча депутатларның һәркайсы да үлем һәм тән җәзасыннан «гомерлеккә» азат ителә, алар «кагылгысыз» кешеләргә әверелә. Гаврила фетнәгә 1773 елның ноябрендә кушыла. Ул әүвәл Богырысланда яшәүче крестьяннардан отряд оештыра, аннары Бирдә бистәсенә юнәлә. Шунда 4 көн торганнан соң, аны Пугачев кабул итә. Давыдовка атаман дәрәҗәсе, махсус указ бирелә, һәм ул Богырысланга яңа отряд туплау өчен кайтып китә. Аңа үзе белән кайткан 30 «казак» та ярдәм итә, Давыдов тиз арада 500 кешелек отряд туплый, Богырысланның бөтен кешесе «падишаһ»ка тугры булырга ант итә.

Әлбәттә, Давыдов үз бистәсендә «тәртип» урнаштыру белән генә канәгатьләнми. Ул Бөгелмә ведомствосы авылларына юнәлә. Аңа урыс крестьяны Степан Синебрюхов отряды килеп кушыла. Һәр татар авылында Давыдовның отряды сан ягыннан арта бара. Давыдов Суровцево авылында (әгәр хәзерге исеме «Суркино» булса, Самара өлкәсендә, безнең Чирмешәннән 60 чакрымда) лагерь корып урнаша. Ул шушы ук төбәктә хәрәкәт итүче Муса Мостафин, Солтангол Иманканкаев, Әит Үрәзмәтов отрядлары белән бәйләнешкә керә. Отряд җитәкчеләре Рәҗәп авылында торучы секунд-майор Шишкин командасына һөҗүм итәргә сүз куешалар. Әмма яу урынына Давыдов отряды соңарып килә. Фетнәчеләр караңгы төшкәнче сугышалар, әмма уңышка ирешмиләр. Икенче көнне Давыдов Сок-Кармала авылына китә, Самара өлкәсе һәм Татарстан чигендә урнашкан дистәләгән авыллар аша уза. Соңыннан Богырысланга кайтып урнаша.

8 февральдә Богырыслан янына полковник Г. Хорват командасы килеп җитә. Давыдов оборона оештырып каршыласа да, карательләр бистәгә бәреп керә. Үз отрядының исән калган өлеше белән Давыдов янә Бөгелмә ягына кача. Бөгелмә — Оренбург арасында урнашкан татар авылларында отрядын тулыландырып, ул карательләрнең вак отрядлары белән берничә мәртәбә бәрелешә. Ләкин апрель башында генерал П. Голицын юллаган бер команда аның отрядын тулысынча тар-мар итә. Давыдов нибары 17 крестьян белән генә качып китә. Әмма әсирлектән котыла алмый. Суровцево авылы янында ул хыянәтче башкорт старшинасы Кыдрач Муллакаев тозагына эләгә һәм әсирлеккә төшә.

Давыдовны Казандагы Яшерен комиссиягә озаталар. Генерал П. Потемкин, 8 июльдә Казанга килеп төшкәч, шәхсән үзе аннан сорау ала. Рухы сынмас атаманны Потемкин асып үтерергә ниятли, шул эш өчен рөхсәт сорап, Екатеринага хат яза. Әмма «изге күңелле» Екатерина, үзенең әлеге депутатка «кагыл-

гысызлык» дәрәҗәсе бирүен искә алып, Давыдовны «фәкать» Ригага каторга газабына озатырга гына «рөхсәт бирә».

Ләкин Екатерина хаты Казанга килеп җиткәндә, Давыдов инде исән булмый. 12 июльдә Казанга Пугачев бәреп кергәч, Потемкин каравыл офицерларына төрмәдәге тоткыннарны юк итәргә әмер бирә. Җәлладлар Давыдовны төрмә камерасында шпага белән кадап үтерәләр (*Г. Голынский*. «Бугурусланский сподвижник Пугачева»; «Под знаменем Пугачева»; «Крестьянская война... на территории Башкирии»; *С. Алишев, Н. Дубровин*; ЦГАДА, 6 фонд, 431 эш).

## 19. Йосыф (Осип) Енгалычев (1719—1774)

Керәшен татары, морза нәселеннән. Әстерхан төбәгеннән. Аның әтисе гвардия полкында подпоручик булып хезмәт иткән, Йосыфка яшь ярым вакытта вафат булган. Сабыйны әтисенең туганы тәрбияләп үстергән. Йосыф игенчелек белән шөгыльләнеп караган. Күршедәге урыс алпавытларының кысуына, җәберләвенә түзмичә, ул үз җирен саткан һәм Бөгелмә ведомствосына күчеп киткән.

Пугачев явы башлану турында хәбәр алгач, ул Бөгелмә воеводасы Иван Кирьянов янына бара, аны фетнәгә кушылырга өнди. Кирьянов баш тарткач, Йосыф өенә кайтып китә. Күрәсең, Йосыф инде элек үк крестьяннар арасында үзенең гыйсъянлыгы (бунтарьлыгы) белән дан алган кеше булгандыр. Хатыны Йосыфка аны Абдул авылыннан Багдай (?) мулла җитәкчелегендәге крестьяннар эзләп килүе турында әйтә. Шул ук мулла кабат Йосыф янына килә һәм Абдул авылы крестьяннарыннан төзелгән йөзлекнең башлыгы булырга өнди (безгә калса, әлеге үгетчеләрне Әит Үрәзмәтов җибәргән булырга тиеш).

Йосыф Абдул авылына бара һәм йөзбашына әверелә. Аннары ул хәзерге Октябрь районына таба юнәлә, һәр авылда үз отрядына сугышчылар туплый. Девлезери авылында (Самара өлкәсендәге Девлезеркино, Нурлаттан 40 чакрымда) чуваш крестьяннары «үтенече» буенча попны асып үтерә, аның утарын талый. Биляр-Озеро авылында (Нурлаттан 25 км) тагын Иван Степанов дигән попны да дарга астыра (үзе керәшен булган атаманның попларга булган бу кадәр нәфрәтен татарларның көчләп чукындыруга каршы протесты дип уйлаудан тыш, әле тагын Йосыф үзе христиан динен тотмагандыр дип нәтиҗә ясауга да этәрә). Сиделькино авылында (Самара өлкәсендә, Нурлат — Чирмешән арасында) яшәүчеләр дә үзләренең попларыннан зарланалар, фетнәчеләр аларны таба гына алмый.

Йосыф үзенең отряды белән Чирмешән крепостеннан 25 чакрымдагы Калярино авылына(?) кайтып лагерь кора. Ул Герасим Владимиров дигән фетнәчене өч иптәше белән бергә Кривоозерки авылына (Аксубайда) озата, һәм алар декабрь башында 200 кешелек отряд туплап кайта. Башка командаларны ул якын-тирә авыллардагы алпавыт утарларын таларга озата. Отставкадагы капитан Мальковскийны үз янына китертеп җәзага тарттыра. Алпавытлардан талап җыелган байлыкны Әит Үрәзмәтов отряды белән бүлешә. Шулай ук Солтан авылындагы (?) татар алпавытының утары да талана.

Тиздән Енгалычев отряды, Әит Үрәзмәтов, Гаврила Давыдов, Иван Черняев фетнәчеләре белән берләшеп, Рәҗәп авылында торучы секунд-майор Шишкин командасына һөҗүм итә, әмма кире чигенергә мәҗбүр була.

Гыйнвар уртасында фетнәчеләр тагын, берләшеп, Чирмешән крепостена һөҗүм итәргә карар кыла. Подлесный авылында 2000 крестьян туплангач, алар Енгалычев, Попов, Әит Үрәзмәтов, Иван Черняев җитәкчелегендә 20 гыйнвар көнне Чирмешәнгә юнәләләр. Аларны карательләрнең берләштерелгән отряды каршы ала һәм тар-мар итә. Йосыф Енгалычев, Әит Үрәзмәтов, Попов һәм тагын берничә җитәкче әсирлеккә эләгә. Аларны әүвәл секунд-майор Астафьев җәзалый, 2 февральдә Казанга озата. Монда җитәкчеләрне янә җәзалыйлар, Әит вафат була. Ә Енгалычев белән Поповны кабат генерал Миллер карамагына озаталар. 13 февральдә Миллер бу ике каһарманны Биләр крепостенда дарга астыра *(С. Алишев)*.

## 20. Муса Мостафин

Бөгелмә төбәгендәге бер татар авылы кешесе. Фетнәгә 1773 елның ноябрь аенда кушылган булырга тиеш. Декабрьдә аның кул астында тупланган фетнәчеләр саны 700 гә җитә. Хәзерге Татарстан белән Самара өлкәсе чигендә хәрәкәт итә, алпавытларның утарларын талый, үзе үткән байтак авылларда фетнәчеләр отряды оештырып китә. Кандыз (Татар Кандызы — Баулы районында), Сәйтәнгол (?), Спас (Бөгелмәдән 20 км), Дмитриевка (Баулыда) авыллары аша үтә. Шәрип (Әлмәт районындагы Колшәрип) авылында лагерь корып урнаша.

28 декабрьдә Муса Бирдә бистәсенә бара. (Йосыф Енгалычев, Гаврила Давыдов, Әит Үрәзмәтов турында язганда, «Рәҗәп авылындагы секунд-майор Шишкин командасына фетнә отрядлары бергәләп

һөҗүм иткән чакта, Муса Мостафин отряды килми, ул Шәрип авылында тора» дип белдердек. Кем белә, Муса үзе, бәлки, нәкъ шул көннәрдә Бирдәдә булгандыр.) Хәрби коллегия аңа походный старшина дәрәҗәсе һәм махсус указ бирә. Пугачев планы буенча, Чесноковкада торучы Чика-Зарубин, зур гаскәр туплаганнан соң, Бөгелмәгә килергә һәм андагы генерал Ф. Фрейман корпусына һөҗүм итәргә, ә Муса шул чакта аңа булышырга тиеш була. Мусага барча мөселман крестьяннарын үз кул астына тупларга фәрман бирелә.

Туган ягына кайткач, Муса Бөгелмә ведомствосы территориясендә хәрәкәт итүче барча фетнә отрядлары белән бәйләнешкә керә, бердәм җитәкчелек оештырырга тырыша. Давыдов отряды белән очрашкач, ул үз кул астындагы урыс крестьяннарын аңа бирә, ә аның командасындагы татарларны үзенә ала (*С. Алишев.* «Татары...», 93—96 с.).

Муса эшчәнлеге турында 1774 елның гыйнварыннан соңгы мәгълүмат юк. «Документы ставки...» китабын төзүчеләр аны «1774 елның язында фетнәдән читләшкән» дип күрсәтәләр (393 б.).

### 21. Габдулла Мостаев

1774 елның июль аенда Бәхтияр Канкаев отрядында походный старшина була. Ясаклы татар. Мамадыш өязендә үзе үк туплаган 700—800 кешелек отрядның башлыгы булып тора, Кама буендагы Шуран кичүен саклый. 14 июльдә секунд-майор В. Меллин карательләренә каршы сугыша. Җиңелә. 18 июльдә яңадан Бәхтияр Канкаев янына килеп кушыла. 22—25 июльләрдә хәзерге Балык Бистәсе районындагы Иске Арыш, Укмас, Яншык авылларыннан 200 кешелек яңа отряд туплый. 25 июльдә полковник дәрәҗәсенә лаек була. 27 се көнне Җөри авылы янындагы яуда катнаша. Август башында Келәүш авылы янында Бәхтияр кул астындагы фетнәченең 400 кешелек отряды тар-мар ителә. Исән калган берничә иптәше белән бергә Бәхтияр карательләр кулыннан качып котыла һәм эзсез югала. Габдулла Мостаев турында да һичнинди мәгълүмат юк. Ул Бәхтияр белән бергә качып киткәндер, дип нәтиҗә ясарга туры килә («Воззвания...»; *С. Алишев*; ЦГАДА, 6 фонд, 416 эш).

### 22. Гали Кадыйров

Мәсәгуть Гомәров отрядында йөзбашы. 1774 елның гыйнварында Пугачевтан фәрман килеп төшкәч, Мәсәгуть, үз отрядыннан 1500 кешене аерып, аларны Гали Кадыйров җитәкчелегендә Кукмара яныннан Минзәләгә җибәрә (*С. Алишев.* «Пугачев полковнигы»). Пугачевның 500 кешелек отряд туплаган өчен башка җитәкчеләргә полковник дәрәҗәсен бирүен искә алсак, Гали Кадыйров бу исемгә, һичшиксез, лаеклы. Кызганычка каршы, әлеге шәхес турында шуннан артык бер мәгълүмат та юк.

### 23. Хәсән Мостаев

Җаек буендагы татар казагы. 1774 елда ул 500 кешелек казахлар отряды өстеннән командалык итә. Сарайчык крепостен камалышта тота. 500 кешелек отряд туплый алган командирларга Пугачевның полковник дәрәҗәсен бирүен искә төшерсәк, өстәвенә аның фетнә зонасыннан читтә, берьялгызы гына хәрәкәт итүен дә исәпкә алсак, Хәсән Мостаев та күренекле җитәкчеләр исемлегенә кертелүгә лаек (*С. Алишев*. «Татары...»).

### 24. Рахманкул Дуслиев (1713—1774)

Мамадыш районындагы Катмыш авылының ясаклы крестьяны. 1774 елга кадәрге тормышы мәгълүм түгел.

1774 елның 10 июльләре тирәсендә Бәхтияр Канкаев килгәч, 61 яшьлек әлеге мөхтәрәм карт Катмыш авылы крестьяннарының җитәкчесе буларак аның отрядына кушыла. Катмышка терәлеп диярлек утырган Баскан, Кирмән, Яке, Шөн, Уразбакты авылларының крестьяннары да, күрәсең, Рахманкулга буйсынгандыр. Чөнки Бәхтияр Рахманкулга фетнәгә кушылган беренче көннәрдә үк подполковник дәрәҗәсен бирә һәм үзенең ярдәмчесе итеп билгели. Ул аны Шомбыт авылындагы (Балык Бистәсе районындагы) аракы заводына озата. Рахманкул заводтан 3 чуен, 1 бакыр туп алып һәм аерым отряд туплап кайта. 12 июль көнне язылган указларда ук Рахманкулның инде полковник дәрәҗәсен йөртүе күренә. 22 июльдә Бәхтияр кул астында 3000 фетнәче тупланувы билгеле. Димәк, Рахманкул 500 кешелек бер полкның командиры да булып тора. Ә Собханкулый Ичкаев атлы крестьян, күрәсең, Рахманкулның ярдәмчесе булып билгеләнгәндер.

12 июльдән соң да Рахманкул Балык Бистәсе, Мамадыш, Саба, Теләче районнарында фетнә отрядлары туплау белән шөгыльләнгән булырга тиеш. Чөнки 14—25 июльләрдә Бәхтияр кулы белән иҗат ителгән документларда Дуслиевның исеме телгә алынмый.

Ә 27 июльдә инде Бәхтиярга буйсынучы барча крестьяннар Җөри авылы янына туплаadmin. Шушы көнне аларны карательләрнең подполковник С. Неклюдов кул астына берләшкән командасы тар-мар итә. Рахманкул карательләр кулына әсирлеккә төшә. Җәлладлар соңыннан аны үзе туган Катмыш авылында дарга асып үтерәләр («Воззвания...»; «Документы ставки Е. И. Пугачева...»; *С. Алишев*. «Бәхтияр Канкаев»; ЦГАДА, 6 фонд, 416 эш).

**25. Халит Әминов**

Әлеге шәхес турында мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә. Ул 1774 елның июлендә Мамадыш өязендә Бәхтияр Канкаев отрядына кушыла. 19 июль көнне Бәхтияр аны Казан провинциясенең Арча юлына отряд туплау өчен озата. Бу вакытта Халит инде полковник дәрәҗәсенә ия була. Ул документларда мулла дип телгә алына. Шуңа күрә ул Мамадыш, Балык Бистәсе районнарындагы авылларның берсендә мулла булып торган, Бәхтияр янына отряд туплап кушылган, аннары 500 кешелек бер полкның башлыгы итеп куелган, дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

Халит Арча юлындагы авылларда ике йортның берсеннән сугышчылар алырга, Казан янында тар-мар ителеп кайткан фетнәчеләрне үз отрядына тупларга тиеш була. 20—22 июльләрдә Халит әллә үзенә каршылык күрсәтүче хыянәтчеләр, әллә карательләр кулыннан яралана, Бәхтияр янына кайтырга чыга. Әмма 22 июль көнне Балык Бистәсе районының Иске Арыш, Укмас, Яншык авылларыннан отряд тупларга чыккан полковник Габдулла Мостаев белән очраша. Хәтта яралы килеш тә Халит мулла Габдуллага сугышчылар туплауда ярдәм итә. Халит кебек үк яралы йөзбашы Әдһәм белән өчесе бергә алар әүвәл 90, аннары 110 кешелек отряд туплап Бәхтияр янына озаталар. Аннары үзләре дә аның янына кайтып кушылалар.

27 июльдә аларны подполковник С. Неклюдов карательләре куып тарата. Август башында Келәүш авылында тар-мар ителәләр. Халит Әминов турында башка бертөрле дә мәгълүмат юк. Ул Бәхтияр Канкаев белән бергә качып котылмадымы икән дигән фараз бар («Воззвания...», док. №161, №174).

**26. Ягъфәр ( ? )**

Әлеге шәхеснең язмышы гына түгел, хәтта фамилиясе дә билгесез. Ул походный старшина Балтач Сәетовның Бәхтияр Канкаевка язган рапортында телгә алына («Воззвания...», док. №99). «Воззвания...» китабын төзүчеләр әлеге документның датасын дөрес билгеләмәгән. Без бу хакта әйттек. Ягъфәр язмышына аңлатманы ерактанрак башлыйк.

Пугачев 11 июль көнне Казан янына килеп җиткән чакта, аның гаскәрендә 25 меңгә якын фетнәче була. Мамадыш —Казан арасында яткан районнарда Пугачев гаскәренә 15 меңгә якын крестьян кушыла. Аларны полкларга бүләргә, командирлар билгеләргә кирәк була. Бу эш, беренче чиратта, татар полковниклары Муса Алиев, Исхак Әхмәтов, Садыйк Сәгыйтов һәм, әлбәттә, Идеркәй Мәхмүтовка тапшырыла. Ягъфәрне һәм Арча юлындагы Ует авылыннан (Саба районында) Әхмәр исемле крестьянны Идеркәй подполковниклар, ягъни полк командирларының ярдәмчеләре итеп билгели һәм аларга байраклар да бирә (*С. Алишев*. «Татары...», 163 с.). Һичшиксез, Идеркәй мондый югары постларга теләсә кемне билгеләми. Мөгаен, Әхмәр белән Ягъфәр, Пугачев янына килгәндә, отряд башлыклары булганнардыр.

Казан янында 12, 13, 15 июль көннәрендә өч яу була. Безгә калса, 12, 13 июль яуларының берсендә Ягъфәрнең командиры һәлак булган яки әсирлеккә төшкән һәм шуннан соң Ягъфәр инде үзе полк җитәкчесе булып калган.

15 июльдә тар-мар ителгәннән соң, полковник Ягъфәр карательләр кулыннан качып котылган һәм туган авылына кайтып киткән. Әмма аны һәм тагын 12 кешене 17—18 июль көнне Тәмте авылында (Теләче районында) торучы походный старшина Балтач Сәетов куйган каравыл отряды тоткарлаган. Тәмтедән Сәгыйтов дигән кеше җитәкчелегендәге каравыл сагы астында Балтач аларның барысын да Саурыш (Сауш) авылында торучы Бәхтияр Канкаев янына озата. Ләкин Ягъфәр юлда тагын качып китә һәм Күкчә авылына (Теләчедә) юнәлә. Бу хакта белеп алгач, Балтач Сәетов аның артыннан 12 кешелек отряд җибәреп карый, әмма тегеләр Ягъфәрне таба алмыйлар. Балтач Бәхтиярдан да, Ягъфәрне эзләү өчен, Күкчәгә кешеләр җибәрүен сорый. Бәхтияр тыңлаганмы, юкмы, моны әйтеп булмый. Ягъфәр турында бүтән бер мәгълүмат та юк.

## 27. Балтач Сәетов

Без Балтачны сүз барышында күп мәртәбәләр телгә алдык. Ул фетнәгә 1773 елның ноябрендә кушыла, аның исеме тарихи документларда 1774 елның августына кадәр бик еш кабатлана. Балтач озын һәм катлаулы юл уза, күп яуларда катнаша. Гәрчә документларда аның дәрәҗәсе походный старшина дип кенә телгә алынса да, фетнә барышында искиткеч активлык күрсәткән әлеге шәхесне күренекле пугачевчылар исемлегеннән төшереп калдырсак, бу безнең тарафтан Балтач каһарманлыгына тиешле бәя бирмәү, аның рухын рәнҗетү булыр иде. Тарихчы галимнәр безне башка ниятләрдә гаепләмәсен. Максатыбыз берәү: Балтач Сәетов каһарман бабаларыбыз исемлегенә кертелүгә лаек!

Мәскәү галимнәре Балтачны «Уфа провинциясенең Казан юлындагы Бикмәт авылы башкорты» дип күрсәтәләр. Бүген Казан белән Уфа арасында ике Бикмәт бар. Берсе — Сарман районындагы Түбән Бикмәт, икенчесе — Чакмагыштагы Бикмәт. Икесе дә татар авыллары!

*Ә хәзер укучыларга гыйбрәтле бер исемлек китерәбез. Без еракка китмәдек, Татарстан белән Башкортстанның күрше районнарындагы авыл исемнәрен генә чагыштырып чыктык. Укыгыз, уйланыгыз:*

| *Татарстан* | *Башкортстан* |
|---|---|
| *Иске Теләкәй (Актаныш)* | |
| *Актаныш* | |
| *Солтангол (Актаныш)* | |
| *Тәмьян (Мөслим)* | |
| *Иске Карамалы (Мөслим)* | |
| *Тереш (Азнакай)* | |
| *Түреш (Мөслим)* | |
| *Иске Әгъбәс (Актаныш)* | |
| *Иске Әлмәт (Мөслим)* | |
| *Уразай (Азнакай, Әгерҗе, Актаныш)* | |
| *Аккүз (Әгерҗе, Актаныш)* | |
| *Әҗми (Актаныш)* | |
| *Балтач (Әгерҗе, Азнакай, Балтач)* | |
| *Иске, Яңа, Югары Богады (Актаныш)* | |
| *Габдрахман (Әлмәт)* | |
| *Иске һәм Яңа Сәет (Мөслим)* | |
| *Калмаш (Тукай)* | |
| *Усы (Актаныш)* | |
| *Иске Уръяды (Актаныш)* | |
| *Гөлек (Минзәлә)* | |
| *Абдул (Әлмәт)* | |
| *Тымытык (Азнакай)* | |
| *Наратасты (Мөслим)* | |
| *Бүләр (Мөслим)* | |
| *Нәдер (Әлмәт)* | |
| *Карабаш (Бөгелмә)* | |
| *Калмия (Минзәлә)* | |

*Җитеп торыр. Әгәр Татарстанда Каманың уң ягына һәм Башкортстанда Уфа каласы артына күчсәк, без бу исемлекне әле бик озак дәвам итә алыр идек. Башкортстан җирендәге әлеге авылларның яртысы бүген башкорт исемлегендә йөри. Бәхәсләшәсе килми. Әмма искәртмичә үтү гамьсезлек булыр: ике республика, ике милләт тамырлары әнә ничек тирәнгә кереп бәйләнгән. Шуңа күрә татар белән башкортның тарихын аерырга тырышу, аларны кара-каршы котырту «Башкорт халкының тарихы һәм*

*азатлык көрәше», «История Башкортстана» дигән хезмәтләрне тудырган Ә. Бейеш, А. Багуманов, И. Акманов, Н. Мәҗитов, Р. Янгузов, Ә. Әсфәндияров, М. Колшәрипов кебек «зыялыларга» нигә кирәк икән? Сез, башкорт халкы урыс дәүләтенә үз теләге белән кушылган дип, күпме генә акны кара итеп күрсәтергә тырышмагыз, әмма «өлкән агай» моңа карап кына сезгә бертөрле өстенлек тә бирми. Башкорт белән татар — икесе тиң бер үк коллыкта. Билгеле булганча, кулның бармаклары аерым булган чакта тизрәк сына бит ул. Ә «бүлгәлә һәм хакимлек ит» кубызына буйсынып биюне без һич кенә дә батырлык димәс идек. Нәтиҗәсен аек акыллы укучылар ясар.*

Ә без Балтач Сәетов язмышына кайтыйк.

Балтачның исеме тарихи документларда тәүге тапкыр 1773 елның 12 декабрендә телгә алына. Ул бу вакытта Уфаны камалышта тотучы фетнәчеләр сафында була. Безгә Качкын Самаровның 6 декабрьдә Минзәлә — Азнакай — Бөгелмә зонасына килеп отряд туплавы һәм шул көнне керәшен алпавыты Йосыф Тәвкилевне үтерүе мәгълүм. Һичшиксез, ул Елан волосте аша да уза һәм, безгә калса, волость старшинасы Сәлим Әитовка буйсынган Балтач Сәетовны да үзе белән Уфа янына алып китә. Балтач әле отряд туплау барышында ук зур фидакарьлек күрсәткән булырга тиеш. Һәрхәлдә, Качкын Самаров аны юкка гына сайлап алмый һәм 12 декабрьдә Балтачны кабат Елан волостена һәр йорттан бер сугышчы хисабыннан яңа отряд туплау өчен кайтарып җибәрә.

Туган ягына кайткач, Балтач отряд туплый. Әмма Уфа янына китми, бәлки Минзәләне камалышта тотучы гаскәргә барып кушыла. Бу вакытта «сәнәктән көрәк булган» җитәкчеләр арасында мин-минлек һәм башбаштаклык хәттин ашкан була. Күрәсең, бу юлы Балтачка да походный старшина дәрәҗәсен йөртүче Качкын Самаровка караганда зуррак командир — полковник Каранай Моратовка буйсынырга туры килгәндер. Безгә Чика-Зарубин белән Каранай Моратовның Уфа һәм Минзәләне штурмлау өчен бер үк көнне — 23 декабрьне билгеләве мәгълүм. Шәһәрне штурмлау өчен Каранайның Кама аръягындагы Әгерҗе авылларыннан да фетнә отрядларын чакыртуын беләбез. Шулай булгач, Балтач Каранай фәрманына буйсынган һәм Минзәләне камалышта тотучыларга кушылган, дип нәтиҗә ясарга туры килә. Балтач Сәетов Минзәлә янында ук походный старшина дәрәҗәсенә лаек була.

Балтач 23—26, 31 декабрьләрдә Минзәлә янында булган бәрелешләрнең берсендә яралана. Аның отряды Чесноковкадагы «граф» Чика-Зарубин таләбе буенча Уфа янына китә. Гәрчә Балтач үзе 10 гыйнварда Минзәләне камалышта тотучы гаскәр башлыгы Яркәй (Ярмөхәммәт) Кадермәтовтан Уфа янына бару өчен рөхсәт алса да, ул көнне юлга чыга алмый (мөгаен, аңа ярасының азуы комачаулагандыр). 15 гыйнварда ул Яркәй урынына калган Рахманкул Исаев атлы җитәкчедән яңа билет ала.

Ләкин Балтач бу юлы да Уфа янына бик тиз генә китми, күрәсең. Соңыннан үз кулы белән язган бер документта ул: «Минзәлә янында 6 атна буе хезмәт иттем»,— дип искә ала. Әгәр Балтачны Минзәлә янына 18—20 декабрьдә килгән дип исәпләсәк тә, димәк, ул биредә 1 февральгә кадәр торган була.

Уфа янына килгәч, Кызылъяр авылында Балтач тагын 6 атна буе «хезмәт итә» (Минзәләдән Уфа янына 6—7 көн баруын истә тотсак, Балтач 8—9 февральдән 24 мартка кадәр — Михельсон тар-мар иткәнче — Уфа янында торган дигән нәтиҗәгә киләбез).

Балтач Минзәлә янында чыннан да зур батырлык кылган, фидакарьлек күрсәткән дигән нәтиҗә ясамый да мөмкин түгел. Чөнки ул Уфа янына киткәч тә, Минзәләне камалышта тотучы җитәкчеләр һаман аның туган ягына кайтуын таләп итә. Командирлар арасында тарткалашу бара. Аптырагач, Балтач 11 март көнне Чесноковкага, инде полковник дәрәҗәсен йөртүче Качкын Самаров янына бара һәм аның ни дә булса хәл итүен сорый. Балтач докладына караганда, ул туплаган отрядның 45 кешесе бу вакытта Бирдә бистәсендә, 25 е Уфа, 12 се Көнгер янында, калганнары аның кул астында Кызылъярда «хезмәт итә». Качкын Самаров Балтачка Уфа янында калырга һәм үз кул астындагы кешеләрне Минзәләгә кайтарып җибәрмәскә әмер бирә. Ә 24 мартта Чесноковка һәм Кызылъяр лагерьлары тар-мар ителә.

Шуннан соң тарихи документларда Балтач исеме июнь аена кадәр югалып тора. Безгә калса, ул апрель — майда Бөре каласын камалышта тотучылар сафына барып кушылган һәм шул вакыт эчендә үз кул астына яңа отряд туплап өлгергән булырга тиеш. Чөнки 4 июньдә Бөрене алганнан соң, Бәхтияр Канкаев Балтач отрядын Агыйдел елгасындагы Туктар кичүен (Мишкә районында) сакларга озата.

8 июньдә Бәхтияр Балтачка, отрядын икегә бүлеп, Бәдрәк кичүен дә (Олы Бәдрәк — Борай районында) сакларга боера. Шуннан бирле Балтач ике кичүнең иминлеге өчен җавап бирә.

Балтачның, Бәхтиярга язган рапортларына караганда, хәлләре җиңел булмый. 17 июньдә Балтач отрядындагы ике «сугышчы» качып китә. Бәхтияр, аларны кулга төшереп, чыбыркылар белән кыйнарга боера. Ул да түгел, Туктар авылына бер мари крестьяны әйләнеп кайта һәм карательләрнең Сагушун (?), Базаново (Бөре районындагы Баженово түгелме?) авылларын яндыруы турында хәбәр итә. Балтач җитәкчеләрдән үз янына йөзбашы Бакый сотнясын ярдәмгә җибәрүләрен сорый. Бәхтияр яки башкалар аны тыңладымы икән, билгеле түгел. Шулай да, июнь ахырында карательләрнең беренче отрядлары килеп

җиткәч, Балтач аларны кире чигенергә мәҗбүр итә. Яу барышында ике урыс кешесен әсирлеккә төшерә һәм аларны, Ягъфәр Әитовка тапшырып, полковник Кадермәтов янына озата. Ярмөхәммәт 28 июньдә аңа элеккечә үк Туктар кичүен сакларга боера. Ләкин карательләр Балтачны да чигенергә мәҗбүр итәләр, һәм 29—30 июнь тирәсендә ул Краснокама районында торган Бәхтияр янына килеп кушыла.

4—7 июльләрдә Мамадышта үз сугышчыларын Пугачевка тапшырганнан соң, Бәхтияр, сәркатип Әбүбәкер Теләчев белән бергә Балтач та Кама буендагы авыллардан яңа отряд туплау өчен озатыла. Мамадыштан чыккач, Бәхтияр Балтачны Казан провинциясенең Ногай юлына аерып җибәрә. Балтач Мамадыш, Саба, Теләче районнары аша уза һәм 17—18 июльләр тирәсендә Тәмте авылында урнаша. Бу вакытта аның кул астында фетнә барышында үзе туплаган өченче отряд була. Шул көннәрдә Балтач Казан янында тар-мар ителеп кайткан крестьяннарны тоткарлый башлый. Аның кулына әүвәл — 13, аннары 26 шундый качак эләгә. Пугачевның тар-мар ителүе турындагы хәбәр Балтачка бик нык тәэсир итә, күрәсең, 19 июль көнне ул Саурышка, Бәхтияр белән очрашырга бара. Аннары фетнәчеләр һәммәсе дә Караширмә авылына кайтып тупланалар. Казан янындагы яулардан исән кайткан берничә крестьян «ходайга рәхмәт укый-укый» старшина Балтач отрядына языла.

Ләкин фетнәчеләр әүвәл 27 июльдә Җөри янында, аннары август башында Келәүш авылында тар-мар ителәләр. Балтач Сәетов эзсез югала. Мөгаен, ул Бәхтияр белән бергә качып котылгандыр. Хәзер инде янә кабатлыйбыз: фетнә барышында өч мәртәбә яңа отряд туплаган, әллә ничә җиңелү кичерсә дә, милли азатлыкка омтылуда сынмас рухлы булып калган Балтач Сәетов каһарманнар исемлегендә урын алуга лаек («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»).

### 28. Аренкол Асеев

Әлеге шәхеснең татарча исеме ничектер, ачыклавы читен. Үзе Зәй районындагы Аксар исемле татар авылыннан, старшина. Ул 1773 елның декабрь аенда тирә-яктагы татар һәм керәшен авылларыннан берничә йөз кешелек отряд туплый һәм Зәй шәһәрен камалышка ала.

1773 елда Зәйне 512 йорт тәшкил итә, анда 932 ир-ат исәпләнә. Моннан тыш, шәһәр янында Александровка, Камышенка бистәләре була, аларда да йөзләрчә ир-ат яши. Шәһәр ике яктан Далалы Зәй һәм Урманлы Зәй елгалары, башка тарафтан ерымнар белән саклана. Тау башына урнашкан каланы 8 метр биеклектәге имән стеналар саклый. Пугачев фетнәсе турында хәбәр килгәч, Казан Кремленең коменданты полковник А. Лецкий бирегә 200 өстәмә мылтык җибәрә.

Зәйнең камалышта калуын ишетүгә үк, Бөгелмәдә торучы генерал Ф. Фрейман капитан Евсеев җитәкчелегендәге команданы шәһәр гарнизонына ярдәмгә озата. 24 декабрьдә Александровка бистәсе янында зур яу була, берничә керәшен татары әсирлеккә төшә. Фетнәчеләрне куып тараткач, Евсеев шәһәргә үтә. 23 е көнне фетнәчеләрнең Минзәләне штурмлавы турындагы хәбәрне ишетеп, капитан Евсеев 25 ендә андагы гарнизонга ярдәмгә чыгып китә. Евсеев китүгә, фетнәчеләр Зәйне тагын камап ала. Тиздән Нагайбәк крепостеннан Аренкол Асеевка ярдәмгә Нагайбәк Әсәнов җитәкчелегендәге 900 кешелек отряд килеп җитә. Югары Налим, Ләке, Сухарево авылларындагы вак отрядлар да аларга килеп кушыла. Фетнәчеләр саны 2000 гә җитә. Аларны Аренкол белән Нагайбәк җитәкли. Фетнәчеләр шәһәрдән кырга печән алырга чыккан 16 кешене әсирлеккә алалар. Шәһәр эчендә паника хөкем сөрә.

Ул да түгел, Зәй гарнизонындагы подпрапорщик Богдан Буткевич Нагайбәк крепостендагы атаман Торнов янына очрашуга бара һәм, шәһәргә кайтуга ук, андагы офицерларны «чын падишаһ» каршында тез чүгәргә үгетли башлый. Аңа гарнизондагы солдатлар һәм шәһәрдәге халык та иярә. Нәтиҗәдә 15 гыйнвар көнне шәһәр капкалары ачыла. Зәйлеләр фетнәчеләр ягына чыга.

Әмма бу чакта Казаннан Зәйгә таба полковник Ю. Бибиков җитәкчелегендәге карательләр отряды хәрәкәт итеп килә. Бибиков 13 гыйнварда Сухарево авылында йөзбашлары Габдулла Токмәтов (Төхбәтов) һәм Исмәгыйль Биккулов җитәкчелегендәге фетнәчеләр отрядын тар-мар итә. Юл уңаенда Ерыклы, Тоба һәм тагын 4 татар авылы яндырыла. 16 гыйнварда Бибиков Аксар авылы янына килеп җитә. Аренкол Асеевның 600 кешелек отряды карательләрне 4 туптан ут ачып каршылый. Бибиков та туплардан атып җавап кайтара. Фетнәчеләр тегермән янына чигенә. Монда тагын канкойгыч бәрелеш башлана. Ләкин подполковник А. Бедряга гусарлары фетнәчеләрне куа башлый. Тирән кар җәяүлеләргә качарга комачаулый. Карательләр 200 крестьянны кылычлар белән чабып үтерәләр. Калганнары качып котыла.

17 гыйнварда Бибиков командасы Зәй янына килеп җитә. 1200 фетнәче аны шәһәр читендә туплар уты белән каршылый. Өч туп артына 15 е көнне крестьяннар ягына чыккан канонирлар баса. Ләкин көчләр тигез булмый. Бибиков Бедряга гусарларын фетнәчеләрнең тылына озата, калган көчне секунд-майор С. Неклюдов, капитан Плахута, поручик Кошелев җитәкчелегендәге 3 колоннага бүлә. Фетнәчеләр әүвәл шәһәр эченә чигенәләр, аннары Әлмәт, Сарман ягына чыгып качалар. Бу көнне 500 крестьян һәлак була.

Нагайбәк Әсәнов Кәшер авылына чигенеп урнаша. Атаман Аренкол Асеев эзсез югала (*С. Алишев.* «Татары...»; *В. Малахов*. «Очерки по истории Заинска»).

### 29. Нагайбәк Әсәнов (1736—1802)

Азнакай районындагы Чалпы авылыннан. Ясаклы татарлар старшинасы. Фетнәгә 1773 елның декабрендә кушыла. Исеме документларда телгә алынмаса да, аның фетнәгә иртәрәк тә кушылуы, әйтик, ноябрьдә авылдашы Габделкәрим Рахманкулов белән бергә Уфаны штурмлау өчен баруы мөмкин.

Декабрьдә ул Рахманкулов белән бергә үзенең туган төбәгендә отряд туплый һәм хәзерге Бакалы районы чигендә урнашкан Нагайбәк крепостен алуда катнаша. 20 декабрьдә крепостька «падишаһ» эмиссары атаман Вәлит Торнов килеп җитә. Ул, Нагайбәк Әсәновка 900 кешелек отряд биреп, аны Зәй каласын штурмларга озата.

15 гыйнварда атаманнар Нагайбәк Әсәнов һәм Аренкол Асеев җитәкчелек иткән 2000 фетнәче Зәйне бер атышсыз кулга төшерә. Әмма 17 се көнне фетнәчеләр тар-мар ителә. Нагайбәк әүвәл Сарман районындагы Кәшер авылында туктала. Зәй яныннан исән-имин качып котылган крестьяннарны 18 ендә янә үз кул астына туплый. Аннары Нагайбәк крепостена, Торнов янына кайта.

6 февральдә Нагайбәк крепостен полковник Ю. Бибиков карательләре яулап ала. 19 ында фетнәчеләр аны янә кулга төшерәләр. 6 мартта генерал Ларионов фетнәчеләрне Нагайбәк крепостеннан куып чыгара, 10 ысында Эстәрлетамак янында тар-мар итә. Шуннан соң атаман Нагайбәк Әсәнов эзсез югала («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; *С. Алишев*).

*1994 елда дөнья күргән «Сәет батыр» китабында без Нагайбәк Әсәнов турында мәгълүматларыбызны менә шул рәвешчә тәмамлаган идек. Язучының бәхете булмыймы соң?! 1999 елда, көтмәгәндә-уйламаганда, өебезгә Мәскәү каласыннан бандероль килеп төште. Бактың исә, Нагайбәк каһарманның туруннары исән, аларның берсе — Татарстан Республикасының Рәсәйдәге вәкаләтле илчесе Назыйф әфәнде Мириханов икән. Ул нәселләренең бөтен шәҗәрәсен, Нагайбәк бабасы турындагы истәлекләрне туплап җибәргән. Сезгә дә игълан итик.*

*Нагайбәк батыр 1736—1802 елларда гомер иткән, ул Хәсән байның бердәнбер улы булган. Нәкъ ул туган елда Ык елгасы буенда нигезләнгән кирмәнгә бәйләп, Хәсән бай улына Нагайбәк исемен кушкан. Хәсән улын Самарадагы байлар мәктәбенә биреп тә белем алдырган. Әтисенең вафатыннан соң, Нагайбәк туган төбәгендәге ясаклы татарларның старшинасы булып калган. Хыялында йөрткән милли азатлык хакына 1773 елның ноябрендә Пугачев фетнәсенә кушылган.*

*1774 елның 10 мартында Эстәрлетамак янында булып узган яудан соң, карательләр Нагайбәк Әсәновны күздән югалталар. Нагайбәк исә айлар буе Казан хакимияте һәм Әби патша җәлладларының җәзасыннан качып йөри. Ул туган авылына кабат фетнә давыллары тәмам тынгач кына әйләнеп кайта. Укымышлы Нагайбәк, мөгаен, Әби патшаның 1775 елның мартында фетнәдә катнашкан крестьяннарны тулысынча гафу итү турындагы указы белән дә таныш булгандыр. Калган гомерен Нагайбәк туган авылында үткәрә, 1802 елда, вафатыннан соң, Чалпы зиратында җирләнә.*

*Нагайбәк җиһанга 9 ул калдыра. Хөрмәкәй исемле улы белән Шәнгәрәй исемле оныгы XVIII гасыр башында һәм уртасында Оренбург губернасындагы 12 нче кантон башлыклары булып тора. Нагайбәк нәселеннән соңыннан «Елховнефть» идарәсе башлыгы Ардинат Ногайбәков, «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең баш табибе Айрат Ногайбәков, юстиция генералы Галим Абдуллаев, газ эшләре буенча академик Заһидулла Галиуллин, безгә таныш илче Назыйф Мириханов һ. б. күренекле шәхесләр үсеп чыга.*

### 30. ( ? ) Сәнфин

Аның турында да мәгълүмат бик аз, хәтта исеме дә билгеле түгел. Минзәлә районындагы Наратлы Кичү авылыннан ясаклы татар крестьяны. Фетнәгә 1773 елның ноябрендә кушыла. Декабрь башында фетнәчеләр Минзәләне тулы камалышка алалар. 23, 25 декабрьдә шәһәрне 14 туп утка тота. 26 сында крестьяннар аны штурмларга ташлана. 10 мең кешелек гаскәр белән бу көнне Каранай Моратов һәм Сәнфин җитәкчелек итә. Фетнәчеләр уңышка ирешми. Алар әүвәл Дәвек һәм Маҗын авылларында лагерь корып урнаша. 12 гыйнварда аларны биредән карательләр куып тараткач, Бикбау һәм Тәкермән авылларына күченеп, штаб коралар. 20 гыйнварда Сарсаз авылы янында зур яу була. 30 гыйнварда Минзәлә янына полковник Ю. Бибиков карательләре килеп җитә һәм фетнәчеләрне куып тарата. 6 февральдә Бибиков Нагайбәк крепостена киткәч, фетнәчеләр тагын Минзәләне камалышка алалар. Шәһәр март ахырына кадәр камалышта тотыла, әмма гарнизон белән крестьяннар арасында әһәмиятле бәрелешләр

булмый. Аннары крестьяннар башка төбәкләргә тарала. Сәнфин турында башка бернинди мәгълүмат та юк *(Р. Игнатьев, С. Алишев).*

**31. Шәрип Якупов**

Кайсы авылдан булуы, фетнәгә кадәр һәм аннан соңгы язмышы мәгълүм түгел. Фетнәгә 1773 елның ноябрендә кушыла, отряд туплый, декабрьдә сәүдәгәр Красильниковның Сарайлыдагы (Бехтерево) заводын ала һәм тиздән Алабуганы камалышта тотучы фетнәчеләрнең җитәкчесенә әверелә.

Отряд башлыклары әүвәл Алабуга шәһәре вәкилләрен кырга, тугайлык урынына чакырып сөйләшәләр. Фетнәчеләр «падишаһ» указын укыйлар һәм шәһәр башлыкларын тез чүгәргә үгетли башлыйлар. Ул бернинди уңышка да китерми. Фетнәчеләр Танайка һәм Сарайлы авылларына лагерь корып урнаша. Шәһәр гарнизоны да стеналарны ныгыта башлый. Тиздән секунд-майор Перский җитәкчелегендәге 100 кешелек гусарлар отряды шәһәр гарнизонына ярдәмгә килеп җитә. Перский, ярдәмгә Минзәләгә барырга тиеш булса да, бер айга якын Алабугадан чыга алмый.

Фетнәчеләр сафына якын-тирәдәге Яр Чаллы, Орловка, Шилнә, Боровецкое, Бәтке, Тарловка гына түгел, бәлки хәзерге Актаныш районындагы Байсар, Яхшый, Терпеле кебек авыллардан да крестьяннар килә. Алабуга янындагы фетнәчеләр саны 6000 гә җитә. Гәрчә Шәрип Якупов үзе походный старшина дәрәҗәсен генә йөртсә дә, Балта Юлдашев, Әхмәр Шәрипов, Тимофей Григорьев, Назар Алексеев, Василий Иванов, Ягъфәр (?), Иван Ракаев, Әскәр Арусаев, Ефрем Иванов, Сәет Исмәгыйлов, Мөслим Бикбаев кебек йөзбашлары турыдан-туры аңа буйсына.

Гыйнвар барышында фетнәчеләр Алабуганы тулысынча камалышка ала. Нәкъ Оренбург янындагы Пугачев шикелле, мондагы крестьяннар да, гаскәрдәге санны зуррак итеп күрсәтер өчен, берешәр кешелек тезмәдән озын бөжра төзиләр. Коралсыз фетнәчеләр озын таякларның очын корымга буяп, сөңге рәвешенә китереп сафларга тезеләләр.

Алабуга янында барлыгы 12 бәрелеш уза. Фетнәчеләр шәһәрне 4 мәртәбә — 6, 10, 13 һәм 19 гыйнварларда штурмлап та карыйлар. Ләкин күмәк һөҗүмнәрнең берсе дә уңыш китерми. Крестьяннарга корал җитми. Бәтке пристанендагы йөзбашы Үтәгән Моратовтан да, Минзәлә янындагы фетнәчеләр башлыгы Каранай Моратовтан да туплар сорап карыйлар, әмма тегеләр дә алабугалыларга ярдәм итә алмый. Алай гына да түгел, полковник дәрәҗәсен йөртүче Каранай Моратов үзе алабугалылардан сугышчылар таләп итә. Йөзбашы Василий Иванов сотнясын һәм башка крестьяннарны алып, Шәрип Якупов Гөлек авылына барып кайта. Аннары инде Каранай Моратов үзе дә 11 гыйнварда Бәтке пристанена килә, шуннан торып Алабуга һәм Минзәлә янындагы гаскәрләр белән җитәкчелек итә. Шәрип Якупов үзе Алабуга янына кайткач, 100 крестьян җибәреп, Мамадышта торучы фетнәчеләргә дә ярдәм күрсәтә.

Ләкин, билгеле булганча, 4—5 гыйнварда Казаннан полковник Ю. Бибиков һәм капитан Г. Кардашевский командалары чыга. Арча юлында Мәсәгуть Гомәров отрядын тар-мар итеп, Кардашевский Алабугага якынлаша. 17 гыйнварда Зәйне алганнан соң, полковник Ю. Бибиков та секунд-майор С. Неклюдов җитәкчелегендәге 400 кешелек гусарлар командасын Алабуганы азат итү өчен юллый. Алар турындагы хәбәрне алуга ук, Сарайлыны калдырып, Шәрип Якупов Танайка авылына күченә.

22 гыйнвар көнне фетнәчеләр карательләрне туплардан ут ачып каршылыйлар. Әмма гусарлар Танайка урамнарына бәреп керә. Фетнәчеләр төрле якка сибелә. Авылдагы картлар, хатын-кызлар, бала-чага йорт түбәләренә, базларга, сарайларга кача. Карательләр һичкемне кызганып тормый. Алар яшеренгән балаларга кадәр эзләп табалар һәм юк итәләр. Танайка читендәге басуда 200 дән артык фетнәче кылычлар белән чабып үтерелә. Әсирлеккә төшкән йөзбашы, Шәрип Якуповның ярдәмчесе Назар Алексеев дарга асыла.

Шәрип Якупов әүвәл Минзәлә янына, аннан Нагайбәк крепостена чигенә. 10 мартта Эстәрлетамак янында генерал Ларионов отряды тарафыннан тар-мар ителгәнче, ул Каранай Моратов кул астында хезмәт итә.

Апрель — июль айларында Шәрип Якупов турында бер мәгълүмат та юк. 24 июль белән тамгаланган бер документта Шәрипнең Уфа провинциясендә, Ураз, Югары Ураз һәм Аслай авылларында (Учалы районы) яңа отряд туплап йөрүе тасвирлана. Каранай Моратовның 4 июльдә Бөгелчән пристане янында генерал П. Голицын корпусына һөҗүм ясавы мәгълүм. Ул чакта Голицын фетнәчеләрне куып тарата. Күрәсең, Каранай Шәрипне Урал буена яңа отряд тупларга озаткандыр. Соңыннанрак Каранай үзе дә шушы төбәккә килә һәм 25 октябрьгә кадәр Урал тауларында карательләргә каршы көрәшеп йөри.

Кызганыч, Шәрип Якупов турында башка мәгълүмат юк («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»; «Над Шишкинским бором рассвет»; *И. Шишкин*. «История города Елабуги»; *Н. Дубровин, С. Алишев*; ЦГАДА, 6 фонд, 416 эш, I кисәк).

**32. Күзмәт Ишмәтов (Хуҗамәт Ишмәнов)**

Кайсы авылдан булуы мәгълүм түгел. Йомышлы татар крестьяны. Ул, Шәрип Якупов белән бергә Алабуганы камалышта тотучы гаскәр башлыгы булса да, походный старшина дәрәҗәсен генә йөртә.

*Укучылар инде болай да игътибар иткәндер: татар җитәкчеләре фетнәнең аеруча беренче этабында хәрби дәрәҗә алуга омтылмый. Фетнә барышында Пугачев полковник дәрәҗәсен, гадәттә, 500 кешелек отряд туплый алган җитәкчеләргә бирә. Ә инде Каргалы — Сакмар арасында, Троицк крепосте янында җиңелеп Исет, Уфа провинцияләренә качкач, ягъни үзенең һәм фетнәнең язмышы кыл өстендә торган чакта, ул үз янына килеп кушылучы волость старшиналарына полковник, атаман дәрәҗәләрен аеруча мул өләшә. Исет провинциясендә яшәүче башкортларның баш старшинасы Базаргол Юнаевка (икенче төр документларда Юламан Кушаевка) ул хәтта фельдмаршал дәрәҗәсен дә бирә. Әлбәттә, бу инде каһарман эшләр белән казанып алынган, «гадел» дәрәҗә түгел, бәлки старшиналарны (димәк, волостьларны да) фетнәгә кушылырга үгетләүче бер чара гына була.*

*Ә татар җитәкчеләре Бирдә бистәсенә барып, үзләренә дәрәҗә дәгъвалап йөрми. Хикәятебездән күренгәнчә, Ярмөхәммәт Кадермәтов (Минзәлә янында, декабрь — март), Сәнфин, Кадермәт, Шәрип Якупов, Шәфи Туйхуҗин (Тәүфыйгов), Аренкол Асеев, Нагайбәк Әсәнов, Надыйр Туктаргалин, Хәсән Мостаев, Иван Илекәев, Муса Мостафин һәм күп кенә башка җитәкчеләр ноябрь аенда ук фетнәгә кушылалар, аларның һәркайсы кимендә 600—700 кешелек отряд белән җитәкчелек итә. Пугачев фетнәнең иң беренче көннәрендә үзен «падишаһ» дип таныган һәм юлбашчы итеп күтәргән, әмма яу барышында искитәрлек батырлык күрсәтмәгән 30—40 Җаек казагының һәркайсына атаман, полковник, генерал дәрәҗәләре биргән икән (мисал өчен, «падишаһ»ны саклаучы «гвардия»дәге 25 казак өстеннән җитәкчелек иткән Яков Давилин 1774 елның 24 августында генерал (!) дәрәҗәсен ала), 600—700 крестьянны бер йодрыкка туплап, азатлык хакына кан коеп йөргән татар командирлары да, һичшиксез, күре- некле җитәкчеләр исемлегенә кертелергә тиеш. Җитмәсә, алар «падишаһ» Татарстанга килгәч түгел, ә яу башында һәм аннан бик еракта, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт иткән көрәшчеләр бит. Ә Күзмәт Ишмәтов турында бәхәс булу, безгә калса, бөтенләй мөмкин түгел. Алабуга янында тупланган 6000 фетнәче өстеннән алар Шәрип Якупов белән икесе җитәкчелек иткән икән, аларны гади (гадәти) походный старшиналарга тиңләү гаделлекмени?*

Шушы экскурстан соң Күзмәт язмышына кайтыйк. Ул да фетнәгә ноябрь аенда кушыла, отряд туплый һәм декабрьдә Алабуганы камалышка алучылар сафына килеп кушыла. Гыйнвар башында ул үз отряды белән Мамадышка юнәлә. Биредә аңа Мамадыш кына түгел, якын-тирә авыл халкы да килеп баш ия. Күп крестьян Күзмәт отрядына кушыла. Шуннан соң Күзмәт Алабуга янына кайта. Шәрип Якупов белән бергә 6000 фетнәченең җитәкчесенә әверелә. Алабуга янында булган яуларның һәммәсендә диярлек катнаша.

Карательләр якынлашу турында хәбәр алгач, ул Танайка авылына юнәлә, яу барышында фетнәчеләр белән җитәкчелек итә. Әмма карательләр коточкыч вәхшилек күрсәтеп сугышалар. Танайкадан соң алар тагын 17 авылны кылыч һәм камчы белән буйсындыра.

Күзмәт Ишмәтов, исән калган фетнәчеләрне туплап, әүвәл Минзәләгә чигенә. 30 гыйнварда бирегә Ю. Бибиков карательләре килеп җитә һәм фетнәчеләрне куып тарата. Күзмәт үз отряды белән Маткауш авылына (Минзәлә районында) чигенә. Аның отрядында элеккеге Кыргыз волостена караган Мари-Суыксу, Терпеле, Байсар, Яхшый (һәммәсе дә Актаныш районында), Калтау, Ишкар (Илеш районында) авылларының крестьяннары тупланган була. Әлеге отряд февраль аенда да Маткауште тора. Волость старшинасы Шәриф Айдаровка хат язып, алар үзләрен фетнәчеләрнең яңа отряды белән алыштыруын сорыйлар. Бу хат — Күзмәт Ишмәтов (Ишмәнов) турындагы соңгы хәбәр. Шуннан соңгы мәгълүматлар юк («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»; *С. Алишев, М. Госманов*).

**33. Шәфи Туйхуҗин (Тәүфыйгов)**

Минзәлә районының Тәкермән авылыннан. 1773 елның декабрь башында Шилва заводын яулап ала. Декабрь азагында, гыйнвар башында Минзәләне камалышта тотучы 10 мең кешелек гаскәр башлыкларының берсе була. Полковник Каранай Моратов, Казаннан Ю. Бибиков һәм Г. Кардашевский командалыгындагы карательләрнең үзләренә каршы чыгулары турындагы хәбәрне алгач, 1774 елның 11 гыйнварында Кама буендагы Бәтке пристанена килә. Каранай шуннан торып Алабуга, Яр Чаллы, Минзәлә янындагы фетнә отрядлары белән җитәкчелек итә башлый. Шәфи Тәкермән авылына тупланган фетнә отрядлары өстеннән командалык итә. Ю. Бибиков карательләре 13 гыйнварда Сухарево авылында Габдулла Токмәтов (Төхбәтов) һәм Исмәгыйль Биккулов отрядларын тар-мар итә. Зәй янындагы татар авылларының крестьяннары килеп, Каранайдан аларны яклавын сорыйлар. Берничә отряд алып, Каранай

Зәй янына китә. Ә үзе урынына Алабуга, Яр Чаллы янына тупланган фетнәчеләр җитәкчесе итеп старшина Шәфи Туйхуҗинны калдыра. Походный старшиналар Шәрип Якупов, Күзмәт Ишмәтов, йөзбашлары Василий Иванов, Үтәгән Моратов, Назар Алексеев моннан ары Шәфигә буйсына башлый. Якупов белән Ишмәтов та 21 гыйнвар көнне Танайка авылына, карательләргә каршы сугышырга киткәндә, Шәфине Алабуга янындагы фетнәчеләрнең баш җитәкчесе итеп раслыйлар.

Мәгълүм булганча, Танайка һәм Алабуга янындагы крестьяннар җиңелә. Аларның бер өлеше Бәтке, Хлыстово, Тарловка, Яр Чаллы, Орловка, Мальцево авылларына кайтып туплана. Гомуми саны белән 8000 гә җиткән фетнәчеләр белән җитәкчелекне Шәфи Туйхуҗин үз кулына алырга тырышып карый. Ләкин тиздән әлеге авылларга С. Неклюдов, А. Перский, Г. Кардашевский командалары килеп җитә һәм фетнә отрядларын берәм-берәм куып тарата.

Шәфи әүвәл Минзәлә янына, аннары Нагайбәк крепостена чигенә. Аның язмышы ничек тәмамланган, анысы билгесез («Воззвания...»; *С. Алишев, М. Госманов*).

**34. Габдулла Туктаров**

Уфа провинциясенең Уса юлыннан ясаклы татар крестьяны. Авылын, яшәгән елларын төгәл әйтеп булмый.

Соңыннан, сорау алу вакытында, ул үзенең эшчәнлеге турында: «Фетнәгә 1773 елның ноябрендә кушылдым, Уфаны камалышта тотуда катнаштым»,— дип белдерә. Әмма Габдулла гел Уфа янында гына тормый. Ул Нагайбәк крепостен алуда катнаша. Безгә Нагайбәкнең ике мәртәбә фетнәчеләр кулына төшүе билгеле. Беренче тапкыр аны декабрь башында Нагайбәк Әсәнов белән Габделкәрим Рахманкулов отрядлары ала. 6 февральдә әлеге крепостька полковник Ю. Бибиков карательләре бәреп керә. Бу хакта хәбәр килгәч, атаман Чика-Зарубин Чесноковкадагы бригадир Иван Кузнецов белән полковник Илья Иванов кул астындагы бер отрядны шул төбәккә ярдәмгә җибәрә. 19 февральдә фетнәчеләр Нагайбәк крепостен янә үз кулларына төшерәләр, секунд-майор Перскийны кылыч белән чабып үтерәләр. 6 мартта гына Нагайбәккә кабат генерал-майор Ларионов карательләре бәреп керә. Эстәрлетамакка таба чигенгән фетнәчеләр — 10 мартта, Бакалы янындагылар 13 мартта тагын бер мәртәбә тар-мар ителә.

Безгә калса, Габдулла Туктаров нәкъ менә 19 февраль көнне үткәрелгән штурмда катнашкан булырга һәм мартның 20 ләре тирәсендә генә кабат Уфа янына кайтырга тиеш. Ә 24 мартта инде Чесноковка һәм Кызылъяр лагерьлары да тар-мар ителә. Шуннан соң Габдулла Туктаров Көнгергә таба чигенә. Март ахыры—апрель башында Салават Юлаев шушы төбәктә яңа отряд туплау белән шөгыльләнә. Габдулла аның отрядына килеп кушыла, тиз арада Салаватның ярдәмчесенә әверелә, йөзбашы дәрәҗәсен ала. Апрель ахырында Салават Габдулланы Елдәк крепостен алырга озата. Габдулла Туктаров юлда Бәхтияр Канкаев, Гадел Бигашев отрядлары белән кушыла. Фетнәчеләр саны 2000 гә җитә. Алар Елдәкне ала, крепостьтагы казаклар «падишаһ»ка тугры булырга ант иттерелә, А. Шеметов атаман итеп билгеләнә. Шуннан соң Канкаев, Бигашев, Туктаров Бөре каласы янындагы авылларга юнәләләр.

4 июнь көнне Габдулла Бөрене штурмлауда катнаша. Аннан соң да Бәхтияр белән янәшәдә походный старшина дәрәҗәсендә хәрәкәт итә. 15 июньдә Бәхтияр, Ярмөхәммәт, мишәр старшинасы Хәмит Мөхәммәтов белән бергә Габдулла Туктаров Сатана (Емаш) авылында торучы полковник Якубович карательләренә һөҗүм итә һәм аларны Дуванеи авылына чигендерә. Фетнәчеләр Сухояз авылына кайтып лагерь коралар. 16—17 июньдә Бәхтияр Канкаев «падишаһ» фәрманы буенча Борай районына киткәч, Кадермәтов белән бергә Габдулла Туктаров Сухоязда кала. Нәкъ шул көннәрдә Ярмөхәммәт Кадермәтов белән Габдулла Туктаровка шәхсән Пугачевның үзе тарафыннан полковник дәрәҗәләре бирелә («Воззвания...», док. №123, №125, №140). Ләкин мондый «үсеш» тә ярдәм итми, карательләр басымына түзмичә, Ярмөхәммәт белән Габдулла отрядлары 18 е көнне чигенергә мәҗбүр булалар. 21 июньдә аларны Бурново янында Михельсон тар-мар итә. Кадермәтов Краснокама районына, Бәхтияр янына китә.

Ә Габдулла турында сентябрь аена кадәр мәгълүмат юк. Күрәсең, Бурново янында җиңелгәннән соң, ул үз отряды белән әүвәл ялгыз көе генә хәрәкәт иткәндер, аннары Салават янына барып кушылгандыр. Моны өзеп кенә әйтүе бик читен. Габдулланың 5 сентябрьгә кадәр Гадел Бигашев, Аладин Биктуганов, Арыслан Рангулов, Бүләк Якупов отрядлары белән бергә хәрәкәт итүе дә мөмкин. Кем белә, 4 сентябрьдә Иван авылы янында майор И. Штерич командасына һөҗүм ясаган 1500 фетнәче арасында, бәлки, Габдулла отряды да булгандыр?

18 һәм 22 сентябрьләрдә подполковник И. Рылеев командасына каршы Тимошкино — Елдәк арасында, Нөркәй авылы янында булган яуларда Габдулла Туктаров та катнаша. Аннары Салават Юлаев белән бергә Габдулла Себер юлына чигенә. Ул башкорт каһарманының алыштырмас ярдәмчесе була. Салават отряды

Катау-Иван заводы янына кайтып урнаша. Салават белән Габдулла отрядка яңа сугышчылар туплау өчен күп көч куялар. Аларның берсе дә дошманнар алдында тез чүгәргә җыенмый.

Ләкин 15—17 октябрьләр тирәсендә Габдулла кичә генә үзе белән бергә көрәшеп йөргән хыянәтче фетнәчеләр тозагына эләгә. Үз гомерләрен саклап калу хакына берничә фетнәче аны кулга ала һәм подполковник И. Рылеевка илтеп тапшыра. Габдулланы Уфа провинциясе канцеляриясе җәлладлары җәзалый башлый. Алдагы язмышын ачыклап булмый («Крестьянская война... на территории Башкирии»; «Воззвания...»; «Документы ставки Е. И. Пугачева...»; *И. Гвоздикова*; ЦГАДА, 349 фонд, 7248 эш).

### 35. Батыркай Иткинин

Уфа өязенең Уса юлындагы Гайнә волостеның Усман авылы (Тауавыл) йөзбашы. Ул тарихи хезмәтләрнең һәммәсендә диярлек башкорт дип телгә алына.

*Без хикәятебез барышында инде бер мәртәбә әйтеп үткән идек. Хәзер тагын бер тапкыр кабатлыйбыз:*

*1. Усман авылын 1738 елда ясаклы татарлар нигезләгән. Алар бирегә Себер юлындагы Имән авылыннан күчеп килгәннәр. Авылга нигез салучы Усман Әзмәтов аңа үз исемен биргән (А. Асфандияров. «История сел и деревень Башкортстана», III кн., 134 с.).*

*2. Бу төбәктә башкортлар (милләт вәкиле түгел, ә бәлки башкорт катламы, ягъни җир хуҗасы булып язылучылар), гомумән, аз булган. 1781 елдан соң Бөре өязе дип аталган әлеге төбәктә 1795 елда үткәрелгән V ревизия ике җенес вәкиленнән 80 мең кеше яшәвен ачыклаган, аларның нибары 20 меңе генә үзен башкорт дип яздыра алган (шунда ук, 118 б.).*

*3. Уфа провинциясендәге крестьяннарга җир аларның кайсы катлам вәкиле булуына карап бирелгән. 1832 елның 10 апрелендә чыгарылган Указ нигезендә, мәсәлән, башкорт булып язылган һәр ир-атка — 40, мишәр һәм типтәрләргә — 30, ә ясаклы татарларга нибары 15 дисәтинә генә җир бүленгән (шул ук хезмәт, I китап, 9 бит). Шулай икән, ясаклы татарларның күбрәк өстенлек, яшәү җиңеллеге китерә торган катламга күчүе, мул тормышка омтылуы кемгәдер гаҗәпмени?!*

*4. Пугачев фетнәсендә Уфа өязенең Уса юлыннан 9435 татар, 263 мишәр һәм нибары 1373 кенә башкорт (алары арасында да, һичшиксез, башкорт булып язылган катлам вәкилләре бихисап) катнашкан (Ә. Фатыйхов. «Гайнә иле», 103 б.).*

*5. Башкортстан Республикасында яшәгән татарларны көчләп «башкортлаштыру» сәясәтенең нинди күләмдә алып барылуын да күз алдыгызга китерү өчен, без сезгә мондый мәгълүмат та тәкъдим итәбез: шушы ук Усман авылында 1906 елда — 1050; 1920 елда 1200 кеше үзен типтәр дип яздырган (Ә. Әсфәндияров, III китап, 135 бит). Шушы ук Усман халкы 1972 елда төзелгән исемлектә тулысынча «башкорт» булып йөри («Башкирская АССР: административно-территориальное деление», с. 60). Шул ук Балтач районында элек татар булган Мишәр (хәтта, исеме үк кычкырып тора!), Чурапан, Нөркәй, Чәпчек, Яхшый (Яумәт), Солтангол, Яңа Кизгән, Магашты, Рәхимкол, Чокалы, Иске һәм Яңа Тимкә, Шауьязы, Богдан, Еләзекүл, Уразай, Янбай, Начар, Көндәшле, Бигелде, Чишмә, Иштирәк, Ялангач авылларының халкы бүген һәммәсе «башкорт» булып йөри (Чагыштырып карагыз: А. Асфандияров. «История сел и деревень Башкортстана», III кн.; «Башкирская АССР: административно-территориальное деление»; «Идел», 1993, №9). Ә электән үк яртылаш татар, яртылаш башкорт булган Иске Балтач, Түшкыр, Илекәй, Кочкилде, Көнтүгеш, Тозлыкуыш, Түбән һәм Югары Кансөяр, Сәйтәк, Туйчыбай авыллары турында әйтеп торасы да юк. Алар халкы, «әлбәттә», тоташ рәвештә «башкорт» исемлегендә. Кардәш милләт безнең туганнарны бүген дистә меңнәрләп үзенә «йота» икән, әллә кайчан «юкка чыккан» Батыркай Иткининны гына үзләштерү аларга кыенмыни? Уйланырлык сүзләр байтак булды, инде мөхтәрәм Батыркайның язмышына кайтыйк.*

Ул фетнәгә 1773 елның декабрь башында кушыла. Үзе яшәгән төбәктә отряд туплый, Ширәмәт бакыр заводын яулап ала, андагы 12 530 сумлык «бурыч» кәгазьләрен яндыра. Аннары йөзбашлары Габделкәрим Айтуганов, Габдулла Шәрипов белән берлектә Уса каласына юнәлә һәм 21 декабрьдә яусыз-нисез аны үз кулына төшерә. Шул ук көнне Усага походный старшиналар Әбди Абдуллов һәм Жумакай Әскәров отрядлары да килеп җитә. Шәһәр коменданты поручик Ф. Пироговский «падишаһ»ка тугры булырга ант итә. Фетнәчеләр Пироговскийны Чесноковка лагерена, «граф Чернышев»ка баш иярге озаталар. Чика-Зарубин аның чәчен казакларча итеп кистерә һәм, билет биреп, кабат Усага кайтарып җибәрә. Шуның аша Зарубин Батыркай Иткинин һәм Әбди Абдулловка Указлар да озата, күрәсең. Чөнки 24 декабрьдән соң Иткинин, Абдуллов белән Әдигот Тимачев (Өдеһет Төмәсов) атаман һәм полковник дәрәҗәләрен йөртә башлыйлар.

Батыркай Усаны Әдигот белән Әбдигә калдыра да үзе Көнгергә юнәлә. 28 декабрьдә ул сәүдәгәр И. Осокинның Югов заводын, 29 ында Никита Демидовның Ашап бакыр заводын ала, һәр икесендә 6426 һәм

8335 сумлык «бурыч» кәгазьләрен яндыра. 31 декабрьдә Ордынское кирмәнен үз кулына эләктерә, Көнгердән разведкага җибәрелгән ике попны дарга астыра. 2 гыйнварда Батыркай инде Көнгер янына да килеп җитә һәм шул көнне үк андагы хакимнәргә «падишаһ»ка тугры булырга, шәһәр капкаларын ачарга өндәгән хат юллый. Фетнәчеләрнең Усаны алуы турындагы хәбәрне ишеткәч үк, 23 декабрьдә Көнгер воеводасы Миллер, шәһәрне ташлап, Чусовка шәһәрчегенә качкан була. Шәһәрдә капитан Бутримович, тау эшләре офицеры подполковник М. Башмаков, аталы-уллы сәүдәгәр Хлебниковлар гарнизон һәм ополчение башлыклары булып кала. Алар Батыркай таләбенә буйсынмыйлар. 3 гыйнварда Батыркай, «падишаһ» манифестын тоттырып, ике попны шәһәргә озата. Поплар зинданга ябыла, гарнизон баш ияргә җыенмый. 4 есендә подпоручик Посохов җитәкчелегендәге 100 кешелек карательләр отряды килеп җитә һәм шәһәргә үтә. Ярсыган Батыркай үз отрядын штурмга ташлый. Әмма туп уты астында чигенергә мәҗбүр була. Бераздан шәһәр янында Посохов отряды белән яңа бәрелеш башлана. Посохов үзе юк ителә.

5 гыйнварда ясалган һөҗүм дә уңыш китерми. Өстәвенә, шул көнне Көнгергә майор А. Папаваның 400 кешелек отряды килеп җитә. 6 сында 300 кешелек отряд алып, воевода Миллер да шәһәргә кайта. Батыркай чигенми. 9ы көнне аның янына Канзафар Усаев отряды ярдәмгә килә. Фетнәчеләрнең берләштерелгән отряды тагын шәһәр стеналарын штурмлап карый. 11 һәм 15 гыйнварларда да шәһәр янында бәрелешләр кабатлана. Ләкин һәр очракта фетнәчеләр чигенергә мәҗбүр була.

18 гыйнварда Көнгер янына Салават Юлаев отряды да килеп төшә. Фетнәчеләр саны 4000 гә җитә, шулар арасында 1000 гә якыны гына урыс крестьяннары була. 23, 24 гыйнварда янә Көнгерне штурмлау кабатлана. Шәһәр гарнизоны бирешми. Ә 26 сына каршы төндә 400 кешелек майор Д. Гагрин командасы да Көнгергә ярдәмгә килеп өлгерә.

26 гыйнварда фетнәчеләр шәһәрне соңгы тапкыр штурмлап карыйлар. Ләкин бу юлы да чигенәләр. 30 ы көнне инде Папава белән Гагрин үзләре Ордынское авылына тупланган крестьяннарга һөҗүм итә һәм аларны куып тарата. 19 февраль көнне Красноуфимск янында соңгы яу була. Шуннан соң фетнәчеләр туган якларына таралалар.

Батыркай Иткинин үз отряды белән Уса юлына кайта. Биредә ул Степан Кузнецов, Әбди Абдуллов, Әдигот Тимачев отрядлары белән бергә хәрәкәт итә. Март — апрель дәвамында алар Югов заводына лагерь корып урнашкан подполковник М. Башмаков карательләренә каршы көрәшәләр. Шулай ук алар Югов һәм Аннинск заводларының идарәчеләре Яковлев, Бахман һәм Берглин командалары белән дә каткат бәрелешәләр. 9 апрельдә Башмаков, Берглин, Лоханинның берләштерелгән җәза отряды Усага бәреп керә. Әмма фетнәчеләр чигенми. Усаны һаман камалышта тота. Карательләр май аенда шушы ук төбәккә ике якка да авышып йөргән хыянәтче старшина-депутат Туктамыш Ишбулатов төзегән отрядны да чакыралар. Туктамыш хыянәтчеләре Яковлевның 1200 кешелек командасы белән кушыла. 23 майда алар фетнәчеләрнең 3000 кешелек отряды белән бәрелешкә керәләр. Фетнәчеләр карательләрне тар-мар итә, хәзер инде «ике яклы пычак» Туктамыш Ишбулатов крестьяннар ягына чыга. Яковлев Уса каласына кайтып бикләнә. Крестьяннар тагын Усаны камалышка ала.

Казан губернаторы Я. Брандт 6 июньдә Скрипицын командасын Уса гарнизонына ярдәмгә җибәрә. Моны белгәч, Усадагы Яковлев та 14 июньдә үз отряды белән Скрипицынга каршы юнәлә. Әмма Гамицы авылы янында Батыркай Иткинин, Әбди Абдуллов, Степан Кузнецовның берләштерелгән отряды Яковлев командасына һөҗүм итә. Канлы, авыр яуда крестьяннар җиңә. Яковлев кабат Усага кайтып бикләнә. 18 е көнне иртән ул Югов заводы ягына чыгып китмәкче булса да, Иткинин һәм Кузнецов отрядлары Яковлевны каладан чыгармыйлар.

Шул ук көнне Уса янына ике зур, әмма бер-берсен күрә алмас көч килеп җитә. Майор Скрипицын карательләре, крепость эченә үтеп, шәһәр гарнизоны белән кушыла. Шуннан соң 2—3 сәгать үтүгә үк Усаны Пугачевның 7000 кешелек гаскәре камап ала. Батыркай 18 еннән 21 енә кадәр барган бәрелешләрнең һәркайсында катнаша. 21 ендә гарнизон «падишаһ» каршында, ниһаять, тез чүгә. Фетнәчеләрнең үзәгенә үткән каратель Яковлев дарга асыла. Мондый карар чыгаруда, мөгаен, Батыркайның да йогынтысы булмый калмагандыр.

23 июньдә Пугачев төп армия белән Кама елгасын кичә һәм Казанны штурмларга юнәлә. Фетнә утын дәвам итү өчен, Батыркай Иткинин туган төбәгендә калдырыла. Аның июнь аеннан соңгы эшчәнлеген дә, алдагы язмышын да тарихи документлардан табып булмый. Пугачев атаманы Аладин Биктугановның Уса юлы волостьларында әле ноябрь аенда да карательләргә каршы яу чыгып йөрүе билгеле. Бу төбәкне «тынычландыру» өчен, генерал П. Голицын 13 ноябрьдә карательләрнең өстәмә командаларын да җибәрә. Ә Батыркай Иткинин шәхсән үзе ул баш имәс фетнәчеләр арасында булганмы, моны әйтүе кыен (»Воззвания...»; «Документы ставки Е. И. Пугачева...»; *В. Мавродин, И. Гвоздикова, Н. Дубровин, А. Фатыхов*).

**36. Габделҗәлил Рыскулов (Рыскуҗин)**

Әлеге каһарман турында документлар бик аз. Аның туган авылы, шөгыле, фетнәгә кайчан кушылуы, фетнәдән соңгы язмышы мәгълүм түгел. «Воззвания...» китабын төзүчеләр аны «Уфа өязенең Уса юлы мишәре» дип күрсәтә (394 бит). «Документы ставки Е. И. Пугачева...» җыентыгында ул «Уса юлының Уран волостеннан» дип ачыклана, милләте күрсәтелми. «Танышыбыз» И. Гвоздикова гына бер урында аны «Себер юлындагы Кара Табын волосте (хәзерге Учалы районы) башкорты» дип «чиерттереп» уза. Учалының Урал аръягында ятуын, Габделҗәлилнең исә яу барышында, гомумән, Себер юлына аяк та басмавын гына әйтәбез дә, сүзне озынга сузмас өчен, без 2 генә мисал китерәбез:

1. 1774 елның июнендә Бөре төбәгендәге һәммә фетнә отрядлары өстеннән җитәкчелек иткән Бәхтияр Канкаевның 16 июньдә Габделҗәлил Рыскуловка язган хатында «Бөре каласын бергә алып, Сухояз авылына кайтканнан соң, барча башкорт отрядлары «үзебезнең юлны (күрәсең, Себер, Ногай юлларын) саклыйбыз» дип туган якларына китеп барды» дигән сүзләр, ай-һай, күпне сөйли («Воззвания...», док. № 140).

2. Шул ук Бәхтиярның шул ук айда атаман Гадел Бигашевка язган хатында «Минем командам мишәрләрдән тора» дигән сүзләр дә бар. Аңа Бәхтияр белән янәшәдә Габделҗәлил Рыскулов та кул куйган (шунда ук, док. № 138).

Инде аңлашылгандыр? Алайса, төп темага кайтыйк.

Габделҗәлилнең исеме тарихи документларда 1774 елның 8 июнендә генә пәйда була. Бу чакта ул Бөре янында хәрәкәт итә, инде полковник дәрәҗәсен йөртә. Шунысы сәер: нәкъ Габделҗәлил кебек үк, Уфа өязенең Уса юлында туып-үскән Арыслан Рангулов белән Аладин Биктугановның исемнәре дә тарихи документларда 1 июньдә генә күренә башлый, әмма алар да бу вакытта инде атаман дәрәҗәсендә була. Аларның һәр өчесе мондый зур дәрәҗәләргә Пугачев әле Уфа провинциясенә кергәнче үк лаек булган. Әлбәттә, аларга зур хәрби дәрәҗәләр бу вакытта инде бер яу барышында күрсәткән батырлык өчен генә бирелмәгән, монысы бәхәссез. Уса юлында яшәгән мишәрләрнең 1773 елның декабрь башында ук фетнәгә кушылуы мәгълүм (кара: «Воззвания...», док. №5). Шуларның ук 21 декабрьдә Усаны алуын, 2 гыйнварда Көнгерне камавын да беләбез. 14 декабрьдә Чесноковкага килеп төшкән һәм Уфа провинциясе, Көнгер, Минзәлә өязе, Ижевск, Сарапул төбәге — кыскасы, Агыйдел — Кама буендагы фетнә белән җитәкчелек иткән «граф Чернышев», ягъни Чика-Зарубин, әлбәттә инде, Уса юлындагы отрядлар өчен дә төп юлбашчы булган. Шул ук Зарубин хәрби дәрәҗәләр дә өләшкән. Шуңа күрә безгә Габделҗәлил Рыскулов, Арыслан Рангулов, Аладин Биктугановның һәркайсы фетнәгә декабрь — гыйнвар айларында ук кушылган; Уса юлында, Көнгер өязендә яшәгән татар-башкорт крестьяннарыннан отрядлар төзегән; шулар белән йә Бөре, йә Уфа янында, яки үзләренең туган төбәкләрендә яу чыгып йөргән һәм шул фидакарьлекләре өчен Чика-Зарубин аларны полковник, атаман дәрәҗәләре белән бүләкләгән дип нәтиҗә ясарга туры килә. Дөрес, мондый нәтиҗә дә тайпылышсыз хакыйкать була алмый.

Мөгаен, Габделҗәлил Рыскулов та Бөре янына Арыслан Рангулов, Аладин Биктуганов, Бүләк Якупов һәм Ярмөхәммәт Кадерматов чакыруы буенча килгәндер. 4 июньдә ул да үз отряды белән Бөрене штурмлауда катнаша. Полковник Якубович, майор Дуве, старшиналар Аблай Исмәгыйлов, Ихсан Баязитов җитәкчелегендәге карательләр һәм хыянәтчеләр Уфа ягына качканнан соң, Габделҗәлил Рыскулов берничә көн буена Бәхтияр Канкаев һәм атаман Гадел Бигашев белән бергә хәрәкәт итә. Алар фетнәне бөтен Уса юлына тарату, Көнгер өязенә күчерү өчен көрәшәләр. Мәсәлән, алар 8 июньдә Зөлкәрнәй Йосыпов атлы старшинаны Суслово авылына, андагы халыкны «падишаһ»ка тугры булырга ант иттерү һәм яңа отряд туплау өчен озаталар («Воззвания...», док. № 113). Шул ук көнне аларның өчесе исеменнән Туктар, Бәдрәк кичүләрен саклаучы Балтач Сәетовка да фәрман җибәрелә (док. № 114). Ә 9 ы көнне төп җитәкчеләр үзләре дә, аерым отрядлар алып, төрле якка тарала. Гадел Бигашев, Ангасяк заводын карательләрдән арындыру өчен, Дүртөйле районына китә. Бәхтияр Канкаев белән Ярмөхәммәт Кадерматов Уфа ягына качкан Якубович һәм Дуве отрядлары артыннан куа чыга. Полковник Габделҗәлил Рыскулов шул көнне үк Балтач районындагы Тимкә авылына килә һәм 4 көн буе шунда тора. *(1920 елдан соң Иске Тимкә исемен алган әлеге авыл 1713 елда Уса юлындагы Бишалап (Барда районындагы Башап түгелме?) авылыннан күченгән йомышлы татар, ягъни хәрби хезмәткә беркетелгән, соңыннан мишәр катламы булып күченүче Үтәшев Баек углы Тимкә морза исеме белән аталган. 1905 елда анда 2156 мишәр яшәгән. Яңадан шушы авылдан Яңа Тимкә аерылып чыккан. — Ә. Әсфәндияров, III китап, 150—151 б. — Хәзер әлеге ике авылның халкы да «совет паспортлары» буенча «башкорт» булып йөри. — «Башкирская АССР: административно-территориальное деление», 58 с.).*

Безгә мәгълүм булганча, май ахырында Бөрене камалышта тотучы отряд җитәкчеләре Бүләк Якупов, Арыслан Рангулов, Аладин Биктуганов, ярдәмгә чакырып, Салават Юлаевка да хат юллыйлар. Салават аны

6 июнь көнне Әй елгасы буенда чакта ала. Бу вакытта Пугачев белән бергә хәрәкәт итү сәбәпле, Салават Бөре янына ярдәмгә бара алмый. Алай гына да түгел, ул Бөре төбәгендәге отрядларның да кайберләрен Пугачевның төп гаскәренә кушылырга чакыра. Салаватның шул хатын алганнан соң, 12 июньдә, Бүләк Якупов һәм Габделҗәлил Рыскулов Пугачев белән көрешү өчен Көнгер өязенә китәләр. Габделҗәлил 13—14 июнь көннәренең берсендә Пугачев белән очраша һәм 15—16 июнь тирәсендә кабат Тимкәгә кайта. Габделҗәлилдән хәбәр алуга ук, 16 сы көнне, Бәхтияр Канкаев аңа үз отрядлары белән Сухояз авылына килергә боерып фәрман юллый («Воззвания...», док. № 140). Инде әйткәнебезчә, Бәхтияр алдагы якшәмбедә (ул 17 июнь булырга тиеш) Дуванеи авылында торучы Якубович командасына һөҗүм итәргә җыена. Ләкин нәкъ шул көнне Бәхтиярга Пугачев фәрманы килеп төшә. «Падишаһ» армиясенең тылдагы иминлеген тәэмин итү өчен, Бәхтиярга Борай районына күченергә туры килә.

18 июнь тирәсендә Бәхтияр белән Габделҗәлил отрядлары Курча (Иске Күрзә) авылында кушылалар. Шул көнне үк Якубович командасы Сухоязда калган Ярмөхәммәт Кадермәтов һәм Габдулла Туктаров отрядларына һөҗүм итә. Карательләрнең Ангасяк заводы ягыннан икенче бер отряды Чалкак (Борай районындагы Челкак) авылын талый. Карательләрнең активлашуы турындагы хәбәрләр, билгеле инде, атаман Гадел Бигашев күңелендә нигезле шөбһә уята. Ул Бәхтияр белән Габделҗәлилнең ни сәбәпле Күрзә авылына күченүен белми. Шуңа күрә аларны туган якларына кайтып китәргә омтылуда, хәтта ваемсызлыкта гаепли. Шуннан соң инде Бәхтияр Канкаев Гадел Бигашевка шактый кискен тондагы хат яза һәм Ярмөхәммәт Кадермәтовны Бөре төбәгендә отрядларның җитәкчесе итеп билгеләргә боера. Хатка Габделҗәлил дә кул куя.

Сүз дә юк, Бәхтияр белән Габделҗәлил дә Күрзәдә ял итеп ятмыйлар. Алар отрядларына яңа сугышчылар туплыйлар, каравыл пикетлары оештыралар, крестьяннарга Танып елгасы аша 3 күпер төзергә бoералар. Әмма Бәхтияр үзе тиздән Краснокама районына күченә, 22 сендә ул шундагы Калтай авылына барып җитә. Габделҗәлил Борай төбәгендә кала. Шуннан соң Бәхтияр белән алар башкача күрешмиләр.

Июль аенда полковник Габделҗәлил Рыскуловның исеме тарихи документларда искә алынмый (без кисәттек инде: Уфа провинциясендә хәрәкәт иткән отрядларның 1 июльдән соңгы көрәшен чагылдыручы документлар, гомумән, аз). Августта ул атаман Арыслан Рангулов, походный старшина Бүләк Якупов отрядлары белән бергә хәрәкәт итә. 3 сентябрь тирәсендә алар янына атаман Аладин Биктуганов та килеп кушыла. Габделҗәлил берләштерелгән шушы отрядның баш җитәкчесе булып исәпләнә (*И. Гвоздикова*. «Салават Юлаев», 111 с.). Гомуми саны белән әлеге отряд 1500 кешегә җитә. Алар белән бер үк төбәктә Ярмөхәммәт Кадерматов отряды да хәрәкәт итә. 4 сентябрьдә алар бергәләп Иван (Балтач районындагы Иванай) авылында торучы майор Штерич һәм атаман Назаров карательләренә һөҗүм итәләр. Әмма фетнәчеләр чигенергә мәҗбүр була.

Шуннан соң Габделҗәлил Рыскулов Салават Юлаев отряды белән кушыла (*И. Гвоздикова*, шунда ук). 18 сентябрь тирәсендә алар Елдәк крепостена һөҗүм итәләр һәм аны кулга төшерәләр. Ләкин озакламый крепостька подполковник И. Рылеев командасы килеп җитә, Габделҗәлил белән Салават Уса юлына чигенә. Рылеев аларны куа чыга. Тимошкино авылы (Борай районы) янында Габделҗәлил белән Салават отрядларындагы бертөркем җайдаклар Рылеев командасына һөҗүм итәләр. Рылеев вакытлыча туктала, соңыннан кабат фетнәчеләрне эзәрлекли башлый. 22 сентябрьдә Нөркәй авылы янында Габделҗәлил белән Салават отрядлары тагын беренче булып Рылеев карательләренә һөҗүм ясыйлар. Канлы, авыр яуда фетнәчеләр тар-мар ителә, 400 гә якын крестьян һәлак була. Шуннан соң Салават үз отряды белән Катау-Иван заводы янына, татар-мишәрләр Уса юлына кайтып китәләр.

24 сентябрьдән соң Габделҗәлил Аладин Биктуганов белән бергә карательләргә каршы көрәшеп йөри, алар әле октябрь азагында да карательләргә буйсынмый. 13 ноябрьдә генерал П. Голицын Уса юлына җәзачыларның өстәмә командаларын җибәрергә мәҗбүр була. Кем белә, соңгы баш имәс фетнәчеләр арасында, бәлки, Габделҗәлил Рыскулов та булгандыр? Әлеге Пугачев полковнигының да язмышы мәгълүм түгел («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»; *И. Гвоздикова*).

**37. Гадел Бигашев**

Гадел Бигашевны тарихчылар Уфа өязенең Себер юлындагы бер волость вәкиле дип күрсәтәләр. Фетнәгә кадәр аның әүвәл флотта — капрал, туган ягына кайткач, мулла булуы мәгълүм.

Мөгаен, Гадел Бигашев фетнәгә 1773 елның декабрендә кушылгандыр. Гыйнвар аенда ул инде Көнгер каласын камап торуда катнаша. Көнгер, Красноуфимск янында фетнәчеләр тар-мар ителгәннән соң, Гадел Бигашев 15—20 май тирәсендә Бәхтияр Канкаев отряды белән кушыла. Бу вакытта Гадел инде атаман дәрәҗәсен йөртә.

Май ахырында Бәхтияр белән бергә Гадел Уса юлына юнәләләр, Уразай авылында лагерь корып урнашалар. 1 июньдә фетнәче отряд башлыклары Б. Якупов, А. Рангулов, А. Биктуганов, Я. Кадермәтов аларның икесен дә Бөре каласын штурмлау өчен ярдәмгә чакыралар. 2 июньдә Бәхтияр белән Гадел Бөре янына киләләр һәм фетнәче отрядларның төп җитәкчеләренә эвереләләр. 4 июньдә фетнәчеләр Бөрене ала. 11 июньдә Гадел Бигашев Дүртөйле районындагы Ангасяк заводы янындагы авылларны талап йөрүче карательләргә каршы юнәлә һәм 24—25 июньгә кадәр шул төбәктә хәрәкәт итүче фетнәчеләр башлыгы булып тора. Июль — сентябрь айларында да Бигашев Бөре төбәгендә карательләргә каршы көрәшеп йөри. Ул октябрь аенда гына карательләр кулына эләгә. Уфа төрмәсендә җәзалана («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Крестьянская война... на территории Башкирии»; «Воззвания...»; *В. Мавродин, И. Гвоздикова* һ.б.).

### 38. Әбди (Габди) Абдуллов
### 39. Әдигот Тимачев (Өдеһет Тимисев/Төмәсов)

Икесе дә Уса юлындагы Гайнә волостеның Елпачиха (Үдик) авылыннан. Елпачиха хәзер Пермь өлкәсенең Октябрь районына керә, нигездә татарлар яшәгән Бардага терәлеп тора. Елпачихада яшәүче татарлар үз авылларын Сараште дип тә йөртә. Барда районында да Сараш, Сараштыбаш исемле чиста татар авыллары бар (*Д. Исхаков*. Пермь татарлары// Казан утлары. — 1991.— № 8; *Ә. Фатыйхов*. Гайнә татарлары. Алар кемнәр? //Таң йолдызы. — 1991. — 29 гыйнвар). Укучыларга бүген Пермь өлкәсендә 200 меңнән артык татар яшәве, анда 92 татар мәктәбе эшләве дә мәгълүм булсын («Шәһри Казан», 1992.— 9 октябрь).

Әбди Абдуллов фетнәгә 1773 елның ноябрь аенда ук кушыла. Шул төбәктәге крестьяннардан отряд туплый һәм 2 декабрь көнне ул инде Уса юлындагы Нагорье авылын ала, анда яшәгән урысларны «падишаһ»ка тугры булырга ант иттерә. Аннан соң Көнгер өязендәге Медянка авылына юнәлә һәм андагы урысларны да «падишаһ»ка буйсындыра. 19—20 декабрьдә ул Уса янына кайтып җитә, Усман авылы (Тауавыл) йөзбашы Батыркай Иткинин төзегән отряд белән кушыла. 21 е көнне алар Усаны алалар. Уса воеводасы поручик Пироговский Чесноковкага, Чика-Зарубин янына баш иярgә китә һәм тиздән Әбди Абдуллов белән Әдигот Тимачевка Зарубин тарафыннан бирелгән полковник дәрәҗәләрен алып кайта. Батыркай Иткинин 24 декабрьдә Көнгер каласын штурмлау өчен китеп бара. Әбди Абдуллов белән Әдигот Тимачев Усага тупланган фетнә отрядларының башлыклары булып кала. Алар соңыннан атаман дәрәҗәсен алачак Степан Кузнецов, походный старшина Җумакай Әскәров белән берлектә Усада крестьяннар идарәсе урнаштыралар. Шул төбәктәге бик күп авыл үз крестьяннарын Усага, «казак» хезмәтенә озатып торырга тиеш булалар.

Гыйнвар аенда Степан Кузнецов, Әбди Абдуллов, Әдигот Тимачев һәм Уса юлындагы тагын берничә отряд командиры, һәммәсе бергәләп, карательләргә каршы көрәшә башлыйлар. Тау эшләре офицеры, подполковник М. Башмаков, Югов һәм Аннинск заводларының идарәчеләре Яковлев, Бахман, Берглин, Лоханин үз кул асларына җәза командалары туплыйлар. Көнгер тирәсе фетнәчеләрдән арындырылганнан соң, әлеге карательләр Югов заводында лагерь корып урнашалар һәм хәзер инде Усаны фетнәчеләрдән чистарту өчен көрәшә башлыйлар. Февраль — март дәвамында Усага ясаган һөҗүмнәр карательләргә уңыш китерми. Кузнецов, Абдуллов, Тимачев, Батыркай Иткинин отрядлары аларның командаларын һәр-чак кире чигендерә.

Ләкин 9 апрельдә карательләр, ниһаять, фетнәчеләрне Усадан куып чыгара. Крестьяннар якын-тирәдәге авылларга чигенә, әмма каланы тимер боҗрага ала. Май аенда карательләр аумакай старшина, 1767 елгы Уложение комиссиясе депутаты Туктамыш Ишбулатов отрядын ярдәмгә чакыра. Туктамыш алып килгән хөкүмәт манифестындагы вәгъдәләр тәэсир итә, күрәсең, полковник Әдигот Тимачев 18 майда аның ягына чыга.

Усага бикләнгән Яковлевның 1200 кешелек командасы 23 майда шәһәрдән чыга һәм хыянәтче Туктамыш отряды белән кушыла. Аларга 3000 фетнәче һөҗүм итә, Туктамыш крестьяннар кулына төшә. Фетнәчеләр Яковлев командасын 15 чакрым буе куалар. Яковлев Усага кереп бикләнә. Подполковник М. Башмаков, ярдәм сорап, Казанга чапкын юллый. 6 июньдә Казаннан майор Скрипицын командасы чыга. Моны белгәч, Яковлев та үз командасы белән аңа каршы юнәлә, Скрипицын белән кушылырга ниятли. Ләкин 14 июньдә Гамицы авылы янында фетнәчеләр янә Яковлев командасына һөҗүм итәләр. Карательләр Усага кайтып бикләнә. 18 июньдә Уса янына Пугачев гаскәре килеп җитә. Әдигот Тимачев, Туктамыш Ишбулатов янә «падишаһ» ягына чыга.

Пугачев Казанга таба киткәннән соң, Әбди Абдуллов белән Әдигот Тимачев Уса янында калалар. Әдигот 1 сентябрьгә кадәр карательләргә каршы көрәшеп йөри. Аннан соң фетнәдән читләшә.

Әбди Абдуллов турында мәгълүматлар юк («Воззвания...»; «Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Крестьянская война... на территории Башкирии»; *В. Мавродин, И. Гвоздикова, Н. Дубровин*).

*Безнең өчен шактый сөенечле хәл: Пугачев полковнигы булган Әдигот Тимачевның да туруннары табылды. Аларның берсе — «Япониядәге кардәшләребез» китабының авторы Рафаил Адутов Чаллы каласында яши, нәсел шәҗәрәсен бик кадерләп саклый. Аннан күренгәнчә, Әдигот мулла бөтен Уса юлында атаклы Һөд-һөд (Бөркет) нәселеннән, аның ерак бабасы хәтта «Чыңгызнамә» китабында да телгә алынган. Әдигот мулла үзе дә балалары өчен җан атып яшәгән, күрәсең. Аның улы Баһаветдин белән оныгы Низаметдин XVIII гасыр башында 1 кантон җитәкчеләре булып торганнар.*

Ә хәзер сан куеп тормыйча гына, соңгы 7—8 елда ачыкланган татар каһарманнарының исемнәрен атыйбыз:

**Карабай Әшмәнев (Ишмәнев, Ишмәтов) —** Уса юлындагы Гайнә волостеның Үдик (Елпачиха) авылыннан, полковник (*Ә. Фатыйхов*. «Гайнә иле»).

**Гамил Даутов** — Көнгер өязеннән, мулла, полковник. Баш күтәрүчеләргә таныклык бирүче буларак телгә алына (*Ә. Фатыйхов*. Шунда ук).

**Габдерәшит Гомәров, Габделсәлим Мәмдәлин, Мәмәткол Бакиров, Миңнегол Котлымәмәтов, Нигъмәтулла Бакиров, Санар Бикеев.** Әлеге каһарманнарны үзенең «Ялганга батырылган яу» исемле мәкаләсендә безгә таныш оппонент Салават Таймасов полковниклар дип санап чыкты. Шунысы сәер: әлеге мәкаләдән тыш бер генә тарихи хезмәт яки язмада да югарыда саналган 6 шәхеснең берсе дә яу яки отряд башлыклары буларак телгә алынмый. Таймасов әфәнде әле **Габделкәрим Күзкәев, Ибраһим Уразбахтин, Мәсәгуть Назыйровны** да полковниклар исемлегенә кертә. Гәрчә соңгы 3 шәхес тә бер генә документта да андый югары дәрәҗәләр белән күрсәтелми. Ә без исә әлеге исемнәрне, белә-аңлый торып, махсус санап чыктык. Бәлки, бездән соң да каһарман пугачевчы бабаларыбызның язмышлары белән кызыксынучылар табылыр? Бирсен, бирсен Ходай!

### *СТАРШИНАЛАР ҺӘМ ЙӨЗБАШЛАРЫ*

#### 1. Аптыш Тангаев

Җаек буендагы татар казагы. 1773 елның 18 сентябрендә үк Җаек казакларының беренче 60 кешелек отряды составында Пугачев янына килә һәм аны «падишаһ» дип таный. Пугачев фәрманы буенча 1773 елның ноябрендә казахларның Кече Җүз солтаны Дусали янына бара һәм 200 кешелек отряд ала. Кабат Пугачев янына кайтканда, Кулагинск крепосте янында Җаек казакларының атаманы М. Бородин кулына әсирлеккә төшә. 1774 елның июлендә Тангаевны Җаек каласында кисәкләргә чапкалап үтерәләр («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; *В. Мавродин, В. Буганов, С. Алишев*).

#### 2. Гомәр Ермаков

Оренбург янындагы Кызылтау (Красногорская) крепостенда татар казакларының есаулы. Фетнәгә 1773 елның 1—2 октябрьләре тирәсендә үк кушыла. 1774 елның мартында Пугачев тарафыннан Бирдәгә чакыртыла. 23 мартта үз отряды белән Татищев крепосте янындагы сугышта катнаша. Әсирлеккә төшә. Оренбургта чыбыркы белән суктырыла. Хәрби дәрәҗәсеннән мәхрүм ителә («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

#### 3. Габделҗәлил Мәгъсүтов

Уфа өязендәге мишәр старшинасы, 1767 елгы Уложение комиссиясе депутаты. 1773 елның ноябрендә фетнәгә кушыла, Уфаны камап торуда катнаша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; *Ә. Әсфәндияров*). Соңыннан карательләр ягына чыга.

#### 4. Ибраш (Ибрай, Ибраһим) Уразбахтин

Казан — Уфа арасындагы Нәдер волостенда ясаклы татарлар старшинасы. Фетнәгә 1773 елның ноябрендә кушыла. Шуннан алып 1774 елның мартына кадәр Уфаны камап торуда катнаша. Апрельдә фетнәдән читләшә, ләкин шуннан соң кабат карательләргә каршы яу чыгып йөри. Карательләр әле ноябрь аенда да аны тота алмыйлар. Ул эзсез югала («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; Воззвания...»). Оппонентыбыз Салават Таймасов Ибраһимны полковниклар исемлегенә кертә.

**5. Сәгыйть Сәйтуганов**

Уфа өязендәге бер волостьтан татар крестьяннары старшинасы. Декабрьдә Уфаны камап торуда катнаша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**6. Мәсәгуть Бикмәмәтов**

Уфа өязендәге татар йөзбашы. Декабрьдә Уфаны камап торуда катнаша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**7. Чурагол Үрәзмәтов**

Уфа өязендәге татар йөзбашы. Декабрьдә Уфаны камап торуда катнаша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**8. Бүләк Якупов**

Казан — Уфа арасындагы Дуванеи волостеның Бәйки авылы (хәзер Кушнаренко районында) крестьяны. Походный старшина. 1774 елның июнь башында Бөре каласын штурмлауда катнаша. Фетнәдә иң актив көрәшүче походный старшиналарның берсе. С. Юлаевның 6 июньдә Көнгер каласын штурмларга чакырып язган хатын алганнан соң, 12 июньдә, Б. Якупов Пугачев янына китә. Аның белән очраша һәм Усаны штурмлауда катнаша. Август — сентябрь айларында ул Салават Юлаев, Ярмөхәммәт Кадермәтов белән берлектә Бөре һәм Танып елгалары буенда хәрәкәт итә, Тимошкино, Нөркәй авылларында подполковник И. Рылеев карательләренә каршы сугыша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»; *И. Гвоздикова*). Кылган батырлыклары буенча Бүләк Якупов күренекле пугачевчылар исемлегенә кертелүгә лаек.

**9. Мәгъсүт Морзакаев**

Уфа — Казан арасындагы Нәдер волосте (Лениногорск, Әлмәт районнары территориясендә) старшинасы. Аның 1774 елның июлендә фетнәдә катнашуы билгеле. Соңыннан карательләр кулына эләгә. Ноябрь аенда Уфа төрмәсендә тотыла («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**10. Ишкилде Ишмурзин**

Казан — Уфа арасындагы Калнин (Калмия, Калмаш — ?) волостеннан ясаклы татарларның походный старшинасы. 1773 елның декабрендә үз отряды белән Сөн буендагы Шаран заводы, Бакалы крепосте, Әгерҗе районындагы Барҗы-Алексеевск заводы тирәсендәге яуларда йөри һәм Нагайбәк крепостена В. Торновка килеп кушыла. Старшина Муса Мөслимов җитәкчелегендәге Бүләр волосте крестьяннарын февраль аенда «падишаһ»ка тугры булырга ант иттерә. Апрельдә карательләр ягына чыга («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**11. Ишкуәт Дәүләтбаев**

Нәдер волосте татарларының походный старшинасы. 1773 елның декабрендә үз отряды белән Шаран заводы, Бакалы крепосте, Барҗы-Алексеевск заводы тирәсендәге яуларда йөри һәм Каранай Моратов янына килеп кушыла. 20 гыйнварда Ишкуәткә Сарсаз авылында бер урыс сәнәк белән кадый. Ишкуәт шул яралардан Бикбау авылында вафат була («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**12. Гадел Игъмәтев**

Йөзбашы. 1773 елның декабрендә үз отряды белән Шаран заводы, Бакалы крепосте, Барҗы-Алексеевск заводы тирәсендәге яуларда йөри һәм Нагайбәк крепостена В. Торновка килеп кушыла («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**13. Монасыйп Йосыпов**

Нәдер волосте татарларының походный старшинасы. 1773 елның декабрь ахырында, 1774 елның гыйнварында Нагайбәк крепосте тирәсендәге яуларда катнаша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**14. Габдулла Токмәтов (Төхбәтов)**

Зәйдән 30 чакрымдагы Сухарево авылында фетнәчеләр йөзбашы. 1774 елның 13 гыйнварында полковник Ю. Бибиковның карательләренә каршы сугыша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**15. Исмәгыйль Биккулов**

Зәйдән 30 чакрымдагы Сухарево авылында фетнәчеләр йөзбашы. 1774 елның 13 гыйнварында полковник Ю. Бибиковның карательләренә каршы сугыша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**16. Бикбау Муллаголов**

1774 елның гыйнварында Зәй тирәсендәге фетнәчеләр гаскәрендә йөзбашы, Торновка буйсына («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**17. Субай Килмәтев**

Тәкермән авылы (Минзәлә районында) старшинасы. Бу авыл 1774 елның гыйнварында фетнәчеләрнең вакытлы лагере ролен үти. Каранай Моратов бу авылда штаб тота. Субай Ю. Бибиков карательләренә каршы яуларда катнаша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**18. Исмәгыйль Биккенин**

Уфа — Казан арасындагы Юрмин (?) волосте старшинасы.

**19. Биккенә Якушев**

Исмәгыйль Биккенинның атасы. 1773 елның декабреннән алып 1774 елның апреленә кадәр икесе дә яуда актив катнашалар. Нагайбәк крепостендагы В. Торновка буйсыналар («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**20. Әхмәр Хөсәенов**

Старшина. И. Биккенин отрядында йөзбашы («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**21. Биккол Мөслимов**

Старшина. И. Биккенин отрядында йөзбашы («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**22. Тимербай ( ? )**

Йөзбашы. Зәй һәм Нагайбәк, Кичү крепостьлары арасындагы юлларны контрольдә тота, карательләр кулына эләккән әсирләрне коткара («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**23. Габдулла Ягъфәров**

Нәдер волостендагы ясаклы татарлар старшинасы. Март — апрель айларында карательләргә каршы сугыша. Әсирлеккә төшә. 1774 елның җәендә аны асып үтерәләр («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**24. Гомәр Госманов**

Г. Ягъфәров отрядында йөзбашы. Бәтке пристанендагы (Яр Чаллы янында) солдатларны фетнәчеләр ягына алып чыга («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**25. Габделкәрим Күзкәев**

Бәхтияр Канкаевның уң кулы. Пугачев гаскәренә кушылуы документларда 1773 елның 3 декабрендә үк тамгаланган. Декабрь — июльдә Б. Канкаев отрядында йөзбашы. Шуннан соңгы язмышы билгесез («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Тарихи китапларда ул «Казан өязе мишәре» дип телгә алына.

Ләкин аның Казан тирәсеннән булуы бик икеле. Чөнки ул фетнә башында Красноуфимск, Көнгер калалары янында яу чыгып йөри, Казан өязенә килми. Безгә калса, Пугачев, йөзбашы дәрәҗәсе биреп һәм отрядлар туплау бурычын йөкләп, Күзкәевне аңа таныш түгел якка озатмас иде. Безнең оппонентыбыз Салават Таймасов аны күренекле җитәкчеләр исемлегенә кертә.

**26. Субай Солтанов**
**27. Киләй Исмәгыйлов**

Походный старшиналар. Алар 1773 елның ноябрендә Казан Адмиралтействосы комиссары Наумовны кулга алалар. Декабрь —гыйнвар айларында Арча юлындагы фетнәчеләрнең отряд башлыклары булып торалар («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**28. Әбдүш Уразбаев**

Мәсәгуть Гомәров отрядында йөзбашы. Питрәч тирәсендә хәрәкәт итә. 1774 елның 7 гыйнварында үзе туган Салауш авылына отряд туплау өчен озатыла. Хыянәтче татар байлары, тотып, аны карательләр кулына тапшыра. Карательләр Уразаевны дарга аса («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**29. Усман Иванов**

Йөзбашы. Полковник М. Гомәровка да, походный старшиналар Хуҗәхмәт (Күзмәт) Ишмәтов белән Шәрип Якуповка да буйсына. Гыйнварда Алабуга тирәсендәге яуларда катнаша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**30. Назар Алексеев**

Илбакты авылы (Тукай районында) крестьяны. Шәрип Якупов отрядында йөзбашы. 22 гыйнварда Танайка авылы янындагы яуда секунд-майор С. Неклюдов кулына төшә. Аны карательләр кырда дарга асып үтерәләр («Документы ставки...»; «Воззвания...»).

**31. Рөхсәбай ( ? )**

Шәфи Туйхуҗин отрядында йөзбашы. 1773 елның декабрендә Шилва заводын ала. Минзәлә районындагы Тәкермән авылыннан (*С. Алишев.* «Татары...»).

**32. Рамазан Исхаков**

1773 елның декабрендә Минзәләне камалышта тотучы отрядларда походный старшина («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**33. Туйхуҗа Мамыков (Мәмәков)**

1773 елның декабрендә Минзәләне камалышта тотучы отрядларда походный старшина («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**34. Солтангол Тимәнәев**

Тархан, Абдул авылларында (Оренбург өлкәсендә район үзәге) фетнәчеләр отрядында походный старшина («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**35. Собханкол Сәгыйтов**

Абдул авылында фетнәчеләр йөзбашы («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**36. Габделрәфыйк Габдуллин**

Оренбург янындагы Каргалы авылы старшинасы. Фетнәгә 1773 елның октябрь аенда ук кушыла. 1774 елның 22 мартында Татищево крепосте янындагы яудан соң карательләр ягына чыга («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**37. Сөләйман Күзкәев**

Уфа өязенең Дуванеи волостенда мишәрләр старшинасы. Декабрь — февраль айларында Красноуфимск, Көнгер янындагы, май-июньдә Бөре янындагы сугышларда катнаша. Бәхтияр Канкаев, Салават Юлаевның ярдәмчеләреннән берсе. 1774 елның җәендә карательләр ягына чыга («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; »Воззвания...»).

**38. Ишмәт Мәмәткулов**

Башкортстанның Караидел районындагы Бәйкибаш авылы татары. 1774 елның гыйнварында Көнгерне штурмлауда катнаша, апрельдә Бәхтияр Канкаев отрядында йөзбашы, майда полк атаманы («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**39. Ишәли Кадрәлиев**

Уфа өязенең Уса юлындагы Убай волосте (Кушнаренко районындагы Купай авылы түгелме?) йөзбашы. Гыйнвар —февральдә Бәхтияр Канкаев отрядында йөзбашы («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»).

**40. Гали Хөсәенов**

1773 елның декабрендә Уфаны камалышта тотучы фетнәчеләрнең йөзбашы («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**41. Әмир Нәүрүзов**

Б. Канкаев отрядында есаул, сәркатип («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»).

**42. Габдулла Мәмәтов**

1774 елның июнендә Б. Канкаев һәм Я. Кадермәтов отрядында йөзбашы («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**43. Әбүбәкер Түләчев**

1773 елның декабрендә походный старшина Балтач Сәетов отрядында йөзбашы, 1774 елның июненнән Б. Канкаев отрядында сәркатип. Казан — Уфа арасындагы Каргинск (?) авылыннан. 1774 елның 27 июлендә Җөри авылы янындагы яуда карательләргә әсирлеккә эләгә. Казанда Яшерен комиссиядә җәзалана. Комиссия хөкеме буенча «падишаһ» исеменнән указлар язган өчен әүвәл аның кулын, аннары башын чабып өзәләр («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»).

**44. Зөлкәрнәй Йосыпов**

Көнгер өязендә фетнәче татарларның походный старшинасы. Б. Канкаевка буйсына («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**45. Габделваһап Хәсәнов**

Июнь аенда Б. Канкаев отрядындагы мишәрләрнең походный старшинасы. Бөре янында сугыша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**46. Хәмит Мәхмүтов (Мөхәммәтов)**

Июнь аенда Б. Канкаев отрядындагы мишәрләрнең походный старшинасы. Бөре янында сугыша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**47. Сөбәй Аскин (Азиков)**

Июль аенда Б. Канкаев отрядында йөзбашы. Мамадыш-Казан арасында сугыша. 18 июльдә ул инде подполковник («Документы ставки Е. И. Пугачева...»; «Воззвания...»).

**48. Муса Хәсәнов**

Июль аенда Б. Канкаев отрядында йөзбашы. Мамадыш —Казан арасында сугыша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Шуннан соң ул, күрәсең, карательләр ягына чыккандыр һәм патшабикәгә тугрылыкка ант китергәндер. 1774 елның 23 декабрендә аның Байлар волостеның старшинасы булуы билгеле (ОӨДА, 3 фонд, 1 тасвир, 148 эш, 33 бит).

**49. Морат Шәрипов**

Июль аенда Б. Канкаев отрядында йөзбашы. Мамадыш —Казан арасында сугыша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**50. Гомәр ( ? )**

Кече Мирәтәк авылыннан (Теләче районында). Июль аенда Б. Канкаев отрядында йөзбашы. Мамадыш — Казан арасында сугыша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**51. Абакай (Апакай) Ишмәтов**

Саурыш (Теләче районы) авылында фетнәчеләр башлыгы. Июль аенда Б. Канкаев отряды вакытлыча шунда лагерь корып урнаша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**52. Әдһәм ( ? )**

Б. Канкаев һәм Габдулла Мостаев отрядында йөзбашы. Июль аенда карательләргә каршы сугышта яралана («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**53. Юз(и)кәй Бикташев**

Мамадыш — Казан арасында отряд башлыгы. Б. Канкаевка буйсына («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**54. Әтнәгул Тимеров**

Казан — Уфа арасындагы Гәрәй волосте (Актаныш районында) старшинасы. 1773 елның декабрендә, 1774 елның гыйнварында Алабуга янында сугыша (Хәйретдинов С., Сирматов И.).

**55. Мөхәммәтрәхим Йосыпов**

Алабуга, Минзәлә янындагы фетнәчеләр гаскәрендә походный старшина. Аның отрядында Актаныш районыннан күп кенә крестьяннар сугыша (Хәйретдинов С., Сирматов И.).

**56. Мәсгуть Мусакаев**

Алабуга, Минзәлә янындагы фетнәчеләр гаскәрендә походный старшина. Аның отрядында Актаныш районыннан күп кенә крестьяннар сугыша (Хәйретдинов С., Сирматов И.).

**57. Ишкәй Уразаев (Ишкенә Уразов — ?)**

Минзәлә төбәгендә походный старшина (Хәйретдинов С., Сирматов И.). Ишкенә Уразов белән бер үк кеше булса, ул Бөре каласы янындагы сугышларда аерым отряд башлыгы, Бәхтияр Канкаев белән Ярмөхәммәт Кадермәтовка буйсына («Воззвания...»).

**58. Табыш Абдуллин**

Алабуга, Минзәлә янындагы фетнәчеләр старшинасы. Аның отрядында Актаныш районының Куян авылыннан — 43, Чишмәдән 50 крестьян була (Хәйретдинов С., Сирматов И.). 1774—1775 елларда ул

Кыргыз волостендагы (Актаныш районы) ясаклы татарлар старшинасы (ОӨДА, 3 фонд, 1 тасвир, 148 эш, 36 б.).

**59. Үмэткул Тәвкилев**

Алабуга, Минзәлә янындагы фетнәчеләр гаскәрендә походный старшина. Аның отрядында Актаныш районының Пучы авылыннан — 114, Әнәктән — 37, Колыннан — 12, Ахуннан 9 крестьян сугыша (Хәйретдинов С., Сирматов И.).

**60. Сабир Якупов**
**61. Сәгыйть Даутов**

Минзәлә төбәгендә хәрәкәт итүче бу ике походный старшина отрядында Актаныш районының Суыксу авылыннан — 88, Адайдан — 30, Байсардан 31 крестьян сугыша (Хәйретдинов С., Сирматов И.). С. Даутов отряд башлыгы булып Дусай-кичү, Сарсак, Төрәле авыллары тирәсендә дә хәрәкәт иткән *(С. Алишев)*.

**62. Мәсгуть Назыйров**

Мәсәгуть Гомәров отрядында походный старшина. Чапшар авылы (Балтач районында) крестьяны. Балтач тирәсендәге авыллардан отряд туплый. Туеш заводын ала. Сосна авылында була. Полковой старшина дәрәҗәсендә дә йөри. Балтач, Кариле, Югары Читай авылы байлары, «киңәшмәгә» дигән мәкер белән, М. Назыйровны Балтачка чакыралар. Әсирлеккә алып, полковник Г. Хорват кулына тапшыралар. Хорват аны декабрь уртасында Норма авылында (Балтач районы) асып үтерә (*С. Алишев*. «Татары...»). Салават Таймасов М. Назыйровны полковник дип яза.

**63. Габдерәшит Бикеев**

Казанда торучы 3 нче батальоннан фетнәчеләр ягына качкан солдат. М. Гомәров фәрманы буенча Арча тирәсендә авыллардан отряд туплый. Хыянәтче байлар мәкере белән әсирлеккә төшә. Бикеевны 29 декабрьдә Казанның Арча кырында дарга асалар *(С. Алишев)*.

**64. Гали Назыйров**

Сасмак авылы (Биектау районында) крестьяны. М. Гомәров өчен отряд туплый *(С. Алишев)*.

**65. Габдулла Габдерәзәков**

Чапшар авылы крестьяны. М. Гомәров отрядында йөзбашы. Туеш заводын ала. Татар байларының хыянәте белән әсирлеккә төшә, җәзалана *(С. Алишев)*.

**66. Мухай (Макай) Сәгыйтов**

М. Гомәров отрядында походный старшина. Алабуганы штурмлау өчен ярдәм кирәк булгач, М. Гомәров 250 кешене М. Сәгыйтов кул астында атаман Шәрип Якупов карамагына озата *(С. Алишев)*. Июль аенда Б. Канкаев отрядында йөзбашы. Мамадыш — Казан арасында сугыша («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**67. Надыйр Туктаргалин**

1774 елның май — июнь айларында 600 кешелек гаскәр белән Казан янында ук хәрәкәт итә. Алексеев, Макаров җитәкләгән урыс отрядлары белән бергә ул Шехазда, Аркатово, Страховка һәм башка авылларда алпавыт утарларын туздыра *(С. Алишев*). Отрядындагы сугышчылар саны буенча ул полковник дәрәҗәсенә лаек.

**68. Йосыф Юнысов**

1774 елның апрелендә Б. Канкаев отрядында йөзбашы («Крестьянская война... на территории Башкирии»).

**69. Юлдаш Ишбулдин**

Казан — Уфа арасында ясаклы татарлар старшинасы. Апрельдә карательләр ягына чыга («Крестьянская война... на территории Башкирии»).

**70. Исмәгыйль Үрәзмәтов**

Казан — Уфа арасындагы Елан волостенда ясаклы татарлар старшинасы. Апрельдә карательләр ягына чыга («Крестьянская война... на территории Башкирии»). Ул 1774—1775 елларда да волость старшинасы булып тора (ОӨДА, 3 фонд, 1 тасвир, 148 эш, 36 б.).

**71. Солтангол Имәнканкаев**

Шәрип (Колшәрип — Әлмәт районында) авылында торган отряд башлыгы. Муса Мостафин, Гаврила Давыдов белән тыгыз элемтәдә тора. Алар фетнәчеләргә каршы бергәләп көрәшәләр («Под знаменем Пугачева»).

**72. Габдулла Ягәфиев**

Походный старшина. 12 гыйнварда Дәвек авылы (Минзәлә районында) янында карательләр кулына әсирлеккә эләгә *(С. Алишев).*

**73. Шәрип Юнысов**

Оренбург янындагы Йөзәй авылы старшинасы. 1773 елның октябрендә үк Пугачев армиясенә отрядлар туплый башлый *(С. Алишев)*.

**74. Байсак Биктимеров**

Походный старшина. 1773 елның октябрь аенда ук отряд туплый һәм Минзәләне штурмлау өчен барган сугышларда катнаша. Бу төбәктәге күренекле җитәкчеләрнең берсенә әверелә *(С. Алишев)*.

**75. Кадермәт ( ? )**

Походный старшина. 1773 елның октябрь аенда ук отряд туплый һәм Минзәләне штурмлау өчен барган сугышларда катнаша. Бу төбәктәге күренекле җитәкчеләрнең берсе (*С. Алишев).*

**76. Тимербулат Үрәзмәтов**

Бөгелмә ведомствосының Абдул авылыннан. 1773 елның октябрь аенда ук аны шушы авылның ясаклы татарлары Бирдәгә Пугачев янына җибәрәләр. Аңа Пугачев кафтанлык ал тукыма бүләк итә, указ бирә. Ноябрь башында Үрәзмәтов кире кайта һәм үзенең туганы Әит, Әитнең улы Габдерәшит белән бергә отряд туплый. Әүвәл аларның отряды 200 кешегә җитә. Секунд-майор Шишкин Рәҗәп авылыннан (Самара өлкәсендә) Бөгелмәгә 40 олау озаткач, Үрәзмәтовлар аңа һөҗүм итә һәм олауны эләктерә. Аннары Әит Үрәзмәтов белән Гаврила Давыдов Шишкин отрядына бергәләп һөҗүм итәргә карар кылалар. Әмма Давыдов соңга калып килә. Ә Әит Үрәзмәтов үзе генә һөҗүм ясый. Бәрелеш Рәҗәп авылы янында була, караңгы төшкәнче дәвам итә. Давыдов белән Иван Черняев отрядлары да килеп кушылгач, фетнәчеләр саны 3 меңгә җитә. Аларның 4 тубы була. Ләкин крестьяннар җиңүгә ирешә алмыйлар һәм иртән Давыдов — Сок-Кармала (Самара өлкәсендә), Черняев белән Әит Үрәзмәтов Ташлы авылына (Баулы районында) чигенә.

Әит Үрәзмәтовның улы Габдерәшит белән бергә Тимербулат Пугачевка рапорт илтә. Пугачев Тимербулатка походный старшина дәрәҗәсе бирә. Полковник дәрәҗәсенә лаек булган Габдерәшит Бирдәдә кала. Гыйнвар аенда Үрәзмәтовлар отряды Мәләкәс заводы, Тиинск, Биляр-Озеро авылларын алуда катнаша. Подлесный авылында лагерь корып урнашалар. Чирмешән крепостен камалышка алалар, хәрби гарнизоннар командиры генерал А. Миллер Биләргә бикләнә. 20 гыйнварда карательләр Үрәзмәтовлар җитәкләгән отрядны тар-мар итә. Әит әсирлеккә төшә, Казанга озатыла һәм җәлладлар кыйнавыннан төрмәдә вафат була. Тимербулат язмышы турында мәгълүматлар юк *(С. Алишев)*. Кылган батырлыклары буенча Тимербулат күренекле җитәкчеләр исемлегенә кертелүгә лаек.

**77. Мөхәммәтәмин Әитов**

Походный старшина. Минзәләне камалышта тотучы бер отряд башлыгы, Әсән авылыннан (Кушнаренко районындагы татар авылы). Полковник Каранай Моратов белән бергә Мәлкен авылында алар 500 кешелек чирү өстеннән командалык итәләр *(С. Алишев*).

### 78. Юлкәй Әиткулов

Походный старшина. Биләр крепосте тирәсендә хәрәкәт итүче отрядлар башлыгы. Кыязлы, Ибрайкино, Кривоозерки, Андреевка, Караса, Сүнчәли, Мошкино (Аксубай, Октябрь районнарында) һәм башка авыл крестьяннарыннан тупланган отрядлар, Әиткуловка бердәм буйсынып, Биләргә һөҗүм итәргә юнәләләр. Аңа 40 чакрым кала генерал-майор Миллер отряды белән очрашалар. Бәрелеш Мокшино авылы янында була. Фетнәчеләр карательләр тарафыннан тар-мар ителә *(С. Алишев).*

### 79. Үтәгән Моратов

Декабрь — гыйнвар айларында Алабуга янындагы фетнәчеләр йөзбашы. Бәтке тоз пристаненең (Тукай районында) солдаты («Воззвания...»). Апрель аенда да фетнәчеләр сафында була («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

### 80. Гомәр Ибраев

Үрнәле авылы крестьяны. Отряд башлыгы. Декабрь (1773) аенда полковник Габделфаикъ Усманов белән бергә хәрәкәт итә. 200 поляк конфедератын Себергә озата баручы прапорщик Иван Федоров отрядына һөҗүм ясый *(С. Алишев)*.

### 81. Григорий Артемьев

Йөзбашы. Кече Шилнә авылыннан (Тукай районында). Яңа (1731 елдан соң) чукынган татар. Бу авыл крестьяннары Авзяно-Петровск заводына, Олы Шилнәнекеләр Ижевск заводына беркетелгән була. Г. Артемьев, үзе кебек үк заводларда михнәт чиккән крестьяннарны туплап, Җөри юлында хәрәкәт итә. Алпавытларга каршы көрәшә, крестьяннарны заводларга барудан азат итә *(С. Алишев)*.

### 82. Тимерхан Мостафин

Ләшәү-Тамак авылының (Сарман районында) ясаклы крестьяны. Пугачев гаскәрендә походный старшина. Зәй һәм Бөгелмә арасында хәрәкәт итә. Февральдә аның отряды карательләр тарафыннан тар-мар ителә *(С. Алишев)*.

### 83. Нигъмәтулла Бакиров

Мәчкәрә авылы (Кукмара районы) крестьяны. Отряд башлыгы. Походный старшина. Мөгаен, ул әүвәл М. Гомәров отрядында сугышкандыр һәм, карательләр тарафыннан җиңелгәч, М. Гомәров белән бергә Нагайбәк крепостена чигенгәндер. Март аенда Н. Бакиров үз отряды белән Эстәрлетамак авылында тора *(С. Алишев)*. Салават Таймасов Нигъмәтулланы полковниклар исемлегенә кертә.

### 84. ( ? ) Миңнеголов

Куян авылы (Минзәлә яки Актаныш районында) крестьяны, отряд башлыгы. Походный старшина. Ул 1773 елның 13 ноябрендә Оренбург янында полковник Чернышев отрядыннан Пугачев ягына чыга. Аннан соң туган төбәгенә фетнә кузгату өчен озатыла. Март аенда үз отряды белән Эстәрлетамак авылында тора *(С. Алишев)*.

### 85. Усман Тимеров

Отряд башлыгы. Походный старшина. Аның отряды 1774 елның май — сентябрендә Аксубай, Чирмешән районнары территориясендә хәрәкәт итә. У. Тимеров үзе һәм аның кул астында хәрәкәт иткән отрядтагы йөзбашларының күбесе 1773 елның октябрендә мәҗбүри рәвештә Сембер коменданты полковник П. Чернышев командасына алынган була. Чернышев камалышта калган Оренбург янына килеп җиткәч, депутат Падуров әлеге полковникны алдауга ирешә һәм аның 1200 кешелек командасын Пугачев ягына алып чыга. Тимеровлылар шул рәвешчә әле 13 ноябрьдә үк фетнәчеләр сафына кушылалар. Соңыннан Пугачев аларны фетнә кузгату, отрядлар туплау өчен Татарстанга озата. Тимеров отряды Яңа

һәм Иске Ибрай, Сүнчәли, Тимошкино, Караса һәм башка авыллар аша уза. Ямаш, Юсупкино, Шентала авылларында алпавыт утарларын туздыра. Отряд Яңа Ибрай авылында торган чакта Кичү крепостеннан аларга каршы карательләр гаскәре озатыла. Ләкин фетнәчеләр карательләрне тар-мар итә. Генерал Миллер янә майор Астафьев һәм майор Елкин командалыгындагы яңа отрядлар юллый. Фетнәчеләр Чирмешән елгасы аръягында Тәкмәкле авылында лагерь корып урнашкан була. Карательләр Тимеров отрядын 6 сентябрьдә шунда тар-мар итәләр. Бик күп крестьяннар әсирлеккә төшә. Усман Тимеров үзе, әле Яшерен комиссия хөкем карары чыгарганчы ук, җәлладлар җәзалавыннан Казан төрмәсендә вафат була *(С. Алишев)*. Кылган батырлыклары һәм күргән газаплары өчен ул иң күренекле пугачевчылар исемлегенә кертелүгә лаек.

**86. Габдерәшит Ибраев**

Усман Тимеров отрядында йөзбашы *(С. Алишев)*.

**87. Исмәгыйль Туктамышев**

Казан Адмиралтействосында эшләүче ясаклы татар. Тумышы белән ул Питрәч районындагы Кавал авылыннан. Пугачев полковнигы Исхак Әхмәтовның яшьлек дусты. Адмиралтействога эшкә беркетелгәч, Казандагы татар бистәсендә яши. Ул 16 декабрь (1773) көнне Пугачевка каршы озатылачак хәрби командага билгеләнә. Ләкин 22 декабрьдә Казаннан кача һәм Курса авылында фетнәчеләргә кушыла. Шуннан ул Бирдәгә Пугачев янына юнәлә. Анда барышлый, Минзәлә янында туктала, Каранай Моратов белән көрешә. Ясаклы татар крестьяны Мәннән Габделмәнов белән бергә Бирдәгә бара. Пугачев белән очраша. «Падишаһ» белән әңгәмәдән соң Туктамышевны Хәрби коллегиягә сәркатип итеп билгелиләр. (Әлбәттә, ул Бирдәдә үзенең яшьлек дусты Исхак Әхмәтов белән очрашкандыр һәм Исмәгыйльнең Хәрби коллегиягә урнашуында, мөгаен, Исхакның да өлеше булгандыр.) Һәртөрле йомыш белән ул берничә кат Оренбург янындагы Каргалыга бара. Аннан соң ул Нагайбәк крепостена, Вәлит Торновның сәркатибе итеп озатыла. Апрель аена кадәр, Эстәрлетамакта карательләр кулына әсирлеккә төшкәнче, Торнов янында хезмәт итә. Торновны һәм аны хыянәтче башкорт старшинасы Кыдрач Муллакаев кулга ала һәм, Бөгелмәгә илтеп, 13 апрельдә полковник Кожинга тапшыра. Туктамышевны Казанга алып килеп Яшерен комиссиядә газаплыйлар. Шуннан соң аны ике татар бистәсе арасындагы кырда дарга асып үтерәләр *(С. Алишев)*. Безгә калса, Исмәгыйльнең дә исеме күренекле пугачевчылар исемлегендә булырга тиеш.

**88. Мәмәткол Бакиров**

Ишмән (?) авылы крестьяны. Походный старшина. Декабрь — февраль айларында Кама аръягында, май — июльдә 300 кешелек отряд белән Казан өязенең Арча юлында хәрәкәт итә *(С. Алишев)*. Салават Таймасов аны полковник дип исәпли.

**89. Хәлил Уразаев**

Йөзбашы. Казанга һөҗүм итү алдыннан Пугачев аны 50 кешелек отряд белән Яңа Татар бистәсе ягына җибәрә. Казанга каратель отрядлары якынайса, Хәлил бу хакта Пугачевка хәбәр итәргә тиеш була *(С. Алишев).*

**90. Әхмәр ( ? )**

Арча юлындагы Ует (?) авылы крестьяны. Ул Казанны штурмлауда катнаша һәм Идеркәй Мәхмүтов тарафыннан Пугачев гаскәрендәге бер татар полкының подполковнигы итеп билгеләнә.

**91. Сәлим Гаделшин**

Йөзбашы. Бөгелмә өязенең Әлмәт авылыннан ясаклы татар. Ул 1773 елның 13 ноябрендә Оренбург янында полковник Чернышев отрядыннан Пугачев ягына чыга. Аның белән бергә озын юл үтә. Казанны штурмлауда катнаша. 12 июльдән соң Кинҗә Арысланов кушуы буенча ул татар полковнигы Исхак Әхмәтов белән бергә якындагы авылларга отряд туплау өчен озатыла. Алар Кавал һәм башка авылларда булалар. Крестьяннарны үгетләп Казанга, Пугачев гаскәренә җибәрәләр. 16 июльдә хыянәтчеләр кулына әсирлеккә төшәләр. Казанның Яшерен комиссиясендә җәзаланалар һәм мәңгелек сөргенгә озатылалар *(С. Алишев)*.

**92. Габделвahап Мөхсинов**

Байлар Сабасы крестьяны. Б. Канкаев hәм Г. Мостаевка буйсынучы фетнәчеләр отрядында походный старшина. 1774 елның әле 22 июлендә дә ул Б. Канкаев белән бәйләнештә тора («Воззвания...»).

**93. Турай Ишалин (Ишаев)**

Уфа провинциясендәге бер волость старшинасы. 1773 елның ноябрендә Уфаны камалышка алучы бер отряд башлыгы («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Декабрь — гыйнвар айларында Минзәлә янында отряд башлыгы. Июльдә Уфа провинциясенең Ногай юлында полковник Селәүсен Кинзин отрядында хәрәкәт итә («Воззвания...»).

**94. Ягъфәр Балбеков**

1774 ел җәендә Казан өязендә отряд башлыгы («Воззвания...»).

**95. Туктар Юзкәев**

1774 елның җәендә Балык бистәсе — Берсут арасында хәрәкәт итүче отряд башлыгы *(С. Алишев).*

**96. Минәй Султыков (Сөлтеков)**

Дусай-кичү, Сарсак, Төрәле авыллары тирәсендә хәрәкәт итүче отряд башлыгы *(С. Алишев)*.

**97. Герасим Сабаев**

Походный старшина, керәшен татары. Б. Канкаев тарафыннан Балык бистәсе районындагы Тәберде Чаллысы, Котлы Бөкәш, Чаллыбаш, Сатлыган, Чураш, Казаклар авылларындагы крестьяннар өстеннән башлык итеп куела. Каманың Чистай янындагы кичүен саклый («Воззвания...»).

**98. Нурый Ишәев**

1773 елның декабрендә Уса юлында хәрәкәт итүче атаман («Воззвания...»).

**99. Бабтай (Сәетбаттал) Мөслимов**

1773 елның декабрендә Уса юлында хәрәкәт итүче походный старшина («Воззвания...»).

**100. Рахманкул Гомәров**

1773 елның декабрендә Уса юлында хәрәкәт итүче мишәрләр йөзбашы, мулла («Воззвания...»).

**101. Бакый Сәфәров**

1773 елның декабрендә Юскәй Кудашев отрядында йөзбашы («Воззвания...»). Шушы ук кешенең 1774—1775 елларда Уфа — Минзәлә арасындагы Сеңгерән волостенда татар hәм башкорт крестьяннарының баш старшинасы булып торуы да мөмкин (ОӨДА, 3 фонд, 1 тасвир, 148 эш, 36 б.).

**102. Әмирхан Хәлилов**

1773 елның декабрендә Юскәй Кудашев отрядында йөзбашы («Воззвания...»).

**103. Солтанморат Мортазин**

1773 елның декабрендә Каранай Моратов отрядында йөзбашы hәм походный старшина. Уфа өязенең Ногай юлы мишәре («Воззвания...»). Безгә калса, декабрь — гыйнвар айларында Каранай Моратов исеменнән фәрман язып, Алабуга янындагы Шәриф Якупов hәм Назар Алексеевка хатлар юллаучы Гомәр Мортазин — ул Солтанморатның бертуганы.

**104. Юскәй Юнысов**

1773 ел декабрендә Б. Канкаев отрядында йөзбашы («Воззвания...»).

**105. Мөхәммәтәмин Гобәйдиев**

Декабрь — гыйнвар айларында Казан — Уфа арасында хәрәкәт итүче фетнәчеләр отрядында походный старшина («Воззвания...»).

**106. Гомәр Мортазин**

Декабрь — гыйнвар айларында Алабуга янында хәрәкәт итүче фетнәчеләр йөзбашы, писарь, мишәр («Воззвания...»). Безгә калса, ул Каранай Моратов белән янәшә, иңгә-иң торып көрәшүче Солтанморат Мортазинның туганы.

**107. Балта Юлдашев**
**108. Әхмәр Шәрипов**

Декабрь — гыйнвар айларында Алабуга янында хәрәкәт итүче фетнәчеләрнең йөзбашлары («Воззвания...»).

**109. Вәлит Ягъфәров**

1774 елның гыйнвар аенда Бакый Абдуллов һәм Юскәй Кудашев отрядларындагы походный старшина («Воззвания...»).

**110. Мәүлит Әитов**

1774 елның гыйнварында Көнгер янында хәрәкәт итүче фетнәчеләр отрядында полковой старшина («Воззвания...»).

**111. Мәгъсүт Сөендеков**
**112. Мәгъсүт Илекәев**

Декабрь — гыйнварда Алабуга янында сугышучы фетнәчеләр отрядында походный старшиналар («Воззвания...»).

**113. Рахманкул Исаев**

Гыйнвар аенда (1774) Минзәләне камалышта тотучы җитәкчеләрнең берсе. Каранай Моратов һәм Ярмөхәммәт Кадермәтов югында бу төбәктәге барлык фетнәче отрядларның башлыгы булып тора. Походный старшина («Воззвания...»).

**114. Рахманкул Мостафин**

Декабрь — гыйнвар айларында Уса юлында хәрәкәт итүче Канзафар Усаев отрядында походный старшина. Бырма авылын, Осокинның Югов заводын ала («Воззвания...»).

**115. Ягъфәр ( ? )**

1774 елның гыйнварында Алабуга янында хәрәкәт итүче Шәриф Якупов отрядында йөзбашы («Воззвания...»).

**116. Иван Ракаев**

1774 елның гыйнварында Алабуга янында хәрәкәт итүче Шәриф Якупов отрядында йөзбашы («Воззвания...»).

**117. Әскәр Арусаев**
**118. Сәгыйт Исмәгыйлов**

1774 елның гыйнварында Алабуга янында хәрәкәт итүче Шәриф Якупов отрядында йөзбашлары («Воззвания...»).

**119. Мөслим Бикбаев**
**120. Искәндәр Дукаев (Тукаев?)**

1774 елның гыйнварында Алабуга янында хәрәкәт итүче Шәриф Якупов отрядында йөзбашлары («Воззвания...»).

**121. Шәфи Байчурин**

1774 елның гыйнварында Көнгер янында хәрәкәт итүче крестьяннарның йөзбашы («Воззвания...»).

**122. Муса Мөслимов**

Казан — Уфа юлындагы Буләр волосте старшинасы. Фетнәгә 1773 елның декабрендә кушыла («Воззвания...»).

**123. Шәриф Айдаров**

1774 елның гыйнвар — февралендә Казан — Уфа арасындагы Кыргыз волосте (хәзерге Актаныш районы) старшинасы, Алабуганы штурмлау өчен отрядлар туплап озата («Воззвания...»).

**124. Зәйнәш Сөләйманов**

Уфа өязенең Себер юлындагы Бәйкибаш (Караидел районында) авылыннан ясаклы татар. 1774 елның апрелендә Б. Канкаев отряды өчен крестьяннар җыюда катнаша. Аннан соң ул Салават Юлаев отрядына кушыла. Аның отрядында иң актив фетнәчеләрнең берсе була. С. Юлаев белән бергә 25 ноябрь көнне әсирлеккә алына («Воззвания...»).

**125. Җамай Шәмиев**

Бикмәт авылыннан. Декабрь — гыйнвар айларында Минзәлә янында алты атна буе Балтач Сәетов отрядында тора. Аннары Уфаны штурмлау өчен өстәмә көчләр кирәк булгач, үзе белән туп алып, ул Уфа янына китә. Анда шулай ук алты атна хезмәт итүе билгеле. Май — июнь аенда Я. Кадермәтовка буйсына, ул чакта Сәлим Әитов отрядындагы йөзбашы («Воззвания...»).

**126. Сәлим Әитов**

Казан — Уфа арасындагы Елан волосте (хәзерге Минзәлә, Сарман районнары территориясе) старшинасы. 1773 елның ноябреннән Минзәлә, Оренбург һәм Уфаны камалышта тоту өчен отрядлар юллый. 1774 елның гыйнвар — мартында Качкын Самаровка, май — июнь айларында Я. Кадермәтовка буйсына («Воззвания...»).

**127. Әмир Кәримов**

1774 елның май — июнь айларында Я. Кадермәтов отрядында йөзбашы («Воззвания...»).

**128. Сәгыйтьягъфәр Зәйсәнов**

Йөзбашы. 1774 елның июнендә Б. Канкаевка һәм Гадел Бигашевка буйсына. Пермь өлкәсендәге Бишмәче (хәзер Федорково) авылы янында хәрәкәт итә («Воззвания...»).

**129. Габделкәрим Собханкулов**

1774 елның июнендә Бөре янында хәрәкәт итүче Я. Кадермәтов отрядында походный старшина («Воззвания...»).

**130. Салих Нәүрүзов**

Йөзбашы. Б. Канкаевка Пугачевның 13 июньдә язылган, төрле милләт вәкилләреннән зур гаскәр тупларга һәм Казан өязенә юнәлергә боерган Пугачев указын алып кайта («Воззвания...»).

**131. Рамазан Урманчиев**

1774 елның июнендә Б. Канкаев отрядында йөзбашы. Мишәр. Бөре каласын алуда катнаша, аның янында полковник Якубович һәм майор О. Дуве карательләренә каршы сугыша («Воззвания...»).

**132. Субханкулый Ичкаев**

1774 елның июль аенда Б. Канкаев отрядында подполковник («Воззвания...»).

**133. Мостафа Мәмәтәев**

Казан өязендә Җөри юлындагы фетнәчеләрнең походный старшинасы. 1774 елның июлендә Б. Канкаевка буйсына («Воззвания....»).

**134. Әбдәссәлам Мәмдәлев**

Мишәр старшинасы. 1774 елның 31 июлендә дә ул әле фетнәдә катнаша («Воззвания...»). Салават Таймасов аны Габделсәлим Мәмдәлин исеме белән полковниклар исемлегенә кертә.

**135. Имәнгол Шәрипов**

1774 елның июлендә Б. Канкаевның Карашырмә авылында (Теләче районында) торучы отряд башлыгы. Казан яныннан карательләр тарафыннан тар-мар ителеп кайткан 26 качак фетнәчене тоткарлап, Балтач Сәетов карамагына тапшыра («Воззвания...»).

**136. Габделкәрим Әитов**

Уфа өязе мишәре. 1774 елның 6 июнендә Пугачевның Хәрби коллегиясе тарафыннан есаул дәрәҗәсен ала. С. Юлаев белән Бүләк Якупов арасында элемтә йөртә. Үзе Уса юлында хәрәкәт итә. Б. Канкаев отряды өчен июнь аенда сугышчылар туплый («Воззвания...»).

**137. Габделкәрим Мәгъсүтов**

Уфа провинцисенең Уса юлы мишәре, 1767 елгы Уложение комиссиясе депутаты. 1773 елның ноябрь — декабрендә Уфаны камалышта тотучы походный старшиналарның берсе («Воззвания...»; «Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**138. Габдерәзәк ( ? )**

Казан — Уфа арасында хәрәкәт итүче фетнәчеләр йөзбашы («Воззвания...»).

**139. Габдерәзәк Галимов**

Уфа өязенең Казан юлындагы Кыргыз волостенда фетнәчеләр йөзбашы, атаман («Воззвания...»).

**140. Әбил Байдашев (Иван Иванов)**

Керәшен татары. Аскын районындагы Кыйгазы авылыннан. Уфа өязенең Себер юлындагы Елдәк крепостенда торучы татар фетнәчеләренең йөзбашы. Фетнәдә 1774 елның мартыннан октябрь уртасына кадәр катнашуы документлар белән расланa. Төрле вакытларда Салават Юлаев, Бәхтияр Канкаев, Ярмөхәммәт Кадермәтов, Гадел Бигашевка буйсына. Июньдә Бөрене алуда катнаша. Октябрьдә карательләр кулына эләгә. Уфа провинция канцеляриясендә җәзалана («Воззвания...»; *И. Гвоздикова*).

**141. Усман Исламов**

Елдәк крепосте янында хәрәкәт итүче фетнәчеләр йөзбашы. 1774 елның июнендә Б. Канкаевка буйсына («Воззвания...»).

**142. Мәхмүт Мансуров**

1774 елның май — июнь айларында Б. Канкаев отрядында йөзбашы («Воззвания...»).

**143. Мәһди Туктамышев**

1774 елның июлендә Чистай турысында Кама елгасы аша кичүне саклаучы фетнәчеләр отряды башлыгы. Тарихи документларда ул Көчек авылыннан дип телгә алына. Документта саналган тагын җиде авылның һәммәсе — бүген Балык бистәсе районында. «Көчек» тә шул ук районд агы, хәзер инде исеме алышынган авыл булырга тиеш («Воззвания...»).

**144. Мостафа Баеков**

1774 елның июлендә Уфа өязендә хәрәкәт итүче фетнәчеләр йөзбашы. Мишәр. Ул вакытлыча походный старшина вазифаларын да башкара («Воззвания...»).

**145. Юзәй Биктимеров**

Уфа өязенең Ногай юлындагы Карамалы авылыннан (Авыргазы районында) ясаклы татар, йөзбашы («Воззвания...»).

**146. Әлмөхәммәт Хөсәенов**

Уфа өязенең Ногай юлындагы Балыклы күл авылыннан (Авыргазы районында) ясаклы татар, йөзбашы («Воззвания...»).

**147. Солтакай Аптикеев**

Уфа өязенең Ногай юлындагы Лекәнде авылы (Авыргазы районында) мишәре. Югарыда саналган өч актив фетнәче Уфадан 12 чакрымдагы Чесноковка авылы янында 1774 елның 27 июнендә яуда карательләр полковнигы А. Якубович кулына әсирлеккә төшәләр һәм Уфа каласында дарга асып үтереләләр *(И. Гвоздикова)*.

**148. Исмәгыйль Исмәгыйлов**

Подполковник. 1774 елның гыйнварында Канзафар Усаев белән бергә Пермь өлкәсендәге Суксун заводын, Ачыт крепостен алуда катнаша («Воззвания...»; *И. Гвоздикова*).

**149. Иван Ислюков**

1774 елның март — апрель айларында Көнгер өязендә хәрәкәт итүче татар отряды башлыгы, керәшен. Салават Юлаев, Иван Васев белән берлектә 5000 кешелек гаскәр туплап, бу өч юлбашчы Көнгер каласын штурмларга телиләр *(И. Гвоздикова)*. Бу татар командиры турында да башка мәгълүматлар юк.

**150. Кунаккул Әтҗетирев**

Уфа өязенең Ногай юлындагы Дуван-Табын волосте старшинасы. 1774 елның июлендә Канзафар Усаев белән бергә Бөгелмә тирәсендә хәрәкәт итә. К. Усаевны кулга алсалар да, Кунаккул карательләрдән качып котыла *(И. Гвоздикова)*.

**151. Әмир Әбдекәев**

1774 елның июлендә Уфа өязенең Ногай юлында хәрәкәт итүче Канзафар Усаев отрядында йөзбашы. Савакул (?) авылыннан ясаклы татар. 1774 елның җәендә ул С. Юлаевның туган йортында да була, шунда яраларыннан дәвалана. Соңыннан карательләр кулына әсирлеккә төшә *(И. Гвоздикова)*.

**152. Иман Аласимов (Аладинов)**

Уфа өязенең Себер юлындагы Кәсәкул авылы татары. 1774 елның гыйнварында Көнгерне штурмлауда катнаша. Отряд җитәкчесе була. Май аенда Бәхтияр Канкаев отрядында йөзбашы («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Октябрь ахырында ул С. Юлаевка Уфа елгасы буендагы авыллардан сугышчылар җыюда ярдәм итә *(И. Гвоздикова).*

**153. Рәхим Әсвиев**

Казан өязенең Арча юлындагы Измаил (?) авылының ясаклы татары. 1774 елның гыйнварында аны авылдашлары Бирдә лагерена «падишаһтан указ сорау өчен» озаталар. Рәхим Пугачевның Хәрби коллегиясе тарафыннан үз төбәгендә отрядлар төзергә, хыянәтчеләрне тотарга фәрман ала («Пугачевщина»).

**154. Әит Сәгыйтов**

1774 елның июнендә Бөре төбәгендәге яуларда аерым отряд башлыгы, походный старшина. Бәхтияр Канкаев белән Ярмөхәммәт Кадермәтовка буйсына («Воззвания...»; «Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**155. Дмитрий Юсупов**

1774 елның гыйнварында Уса янындагы фетнәчеләр йөзбашы, керәшен татары *(Ю. Лимонов, В. Мавродин, В. Панеях)*.

**156. Арыслан ( ? )**

1773 ел декабрендә Канзафар Усаев отрядында йөзбашы («Воззвания...»).

**157. Зиянбелгәбуян ( ? ) Рысмәтов**

Оренбург губернасында яшәгән ясаклы татар, отряд башлыгы. Пугачев явындагы активлыгы, халыкны фетнәгә күтәргәндә әйткән «әшәке вә әдәпсез» чакырулары өчен губернатор И. Рейнсдорп тарафыннан 1775 елның 8 гыйнварында ул камчы, батогалар (очында тимер ыргаклары булган чыбыркы) белән җәзалануга хөкем ителә (ОӨДА, 3 фонд, 1 тасвир, 148 эш).

**158. Аккулай (Арнукай, Аккүссәй) Пулатов**

Уфа өязенең Казан юлындагы Байлар волостенең Чебенле авылыннан ясаклы татар. Фетнәгә 1773 елның ноябрендә кушыла. Әүвәл Мәсәгуть Гомәров отрядында йөзбашы, аннары походный старшина. Таиш, Бемыш, Пыжман заводларын алуда катнаша, Удмуртия авыллары аша уза. Ике мәртәбә капитан Г. Кардашевский карательләренә каршы яуларда була. Яулардан исән чыккан крестьяннарны туплап, Минзәлә янына юнәлә. Атаман Сәнфин белән бергә хәрәкәт итә. Июль аенда Казанны штурмлауда, аннан соң подполковник И. Михельсон командасына каршы яуларда катнаша. Бәрелешләрнең берсендә карательләр кулына эләгә. Ул хәтта әле 1775 елның 10 июнендә дә (патшабикәнең фетнәчеләрне гафу итү турындагы 1775 ел 17 март указын җирле җәлладлар менә ничек үтәгән!) Минзәлә төрмәсендә аяклары һәм куллары богауланган килеш тотыла. Пулатов алпавыт утарларын һәм заводларын талауда, Минзәлә һәм Казанны штурмлауда катнашуы өчен гаепләнә, моны үзе дә таный. Соңыннан Оренбург губернаторы И. Рейнсдорп фәрманы буенча гына ireккә чыгарыла (ОӨДА, 3 фонд, 1 тасвир, 148 эш). Оппонентыбыз С. Таймасов аны Мәсәгуть Гомәров өстеннән башлык, ягъни полковник итеп тасвирлый.

**159. Аллакул Акаев**

Ясаклы татар крестьяны. 1774 елның маенда Канзафар Усаевның ярдәмчесе («Документы ставки Е. И. Пугачева...»).

**160. Габделмәннән Мөслимов**

Ул әүвәл офицер дәрәҗәсендә Екатерина II яклы отряд командиры була. Пугачев явы башлангач, фетнәчеләр ягына чыга, 5—6 ай буе карательләргә каршы сугышып йөри. Шагыйрь була. Аның турында башка төр мәгълүмат юк («Татар әдәбияты тарихы», 2 том).

**161. Рахманкул Иртуганов**

1774 елның гыйнварында Уфа провинциясенең Уса юлы Гайнә волостенда Елпачиха авылында торучы фетнә отрядында походный старшина («Документы ставки Е. И. Пугачева...»). Әле 31 августта да карательләргә буйсынмый. Бу вакытта ул атаман Аладин Биктуганов белән бергә хәрәкәт итә («Крестьянская война... на территории Башкирии»). Аладинның сентябрьдә майор Штерич, подполковник Рылеев командалары белән яуга керүе мәгълүм. Ул хәтта ноябрьдә дә баш ими. 13 ноябрьдә генерал Голицын Аладин Биктуганов һәм башка җитәкчеләр кул астында тупланган фетнәчеләргә каршы җәза командасы юллый *(И. Гвоздикова)*. Рахманкул Иртугановның да Аладин белән бергә хәрәкәт итүе мөмкин.

**162. Сәйфулла Сәйдәшев**

Уса юлының Гайнә волостендагы Үдик (Елпачиха) авылыннан, мулла. Красноуфимск янында карательләргә каршы көрәшүче Әбди Абдуллов отрядында походный старшина. Фетнә бастырылгач, гомерлек солдат хезмәтенә озатыла *(Ә. Фатыйхов).*

**163. Гадел Әшмәнев (Ишмәнев, Ишмәтов)**

Үдик (Елпачиха) авылыннан. Фетнәгә 1773 елның декабрь аенда кушыла, Красноуфимск янындагы яуларда катнаша. 1774 елның октябрендә кулга алынып, Казандагы Яшерен комиссиягә озатыла, җәзалана. Кинәт сукыраюы сәбәпле, өенә кайтарып җибәрелә *(Ә. Фатыйхов)*.

**164. Мөхәммәди Чүтиев**

Уса юлындагы Гайнә волостеннан, йөзбашы. Фетнәдә актив катнашканы өчен, 1774 елның октябрендә кулга алына һәм Казандагы Яшерен комиссиягә җәзаланырга озатыла (*Ә. Фатыйхов)*.

**165. Габделкәрим Айтуганов**
**166. Габдулла Шәрипов**

Уса юлындагы Гайнә волостеннан, полковник Әбди Абдуллов отрядында йөзбашлар *(Ә. Фатыйхов)*.

**167. Иләтбай Илимбаев**

Салават Юлаев отрядында йөзбашы. 1774 елның мартында Себер юлы авылларыннан Салават янына 163 сугышчы туплап кайта *(И. Гвоздикова)*.

**168. Абзакай Абдуллов**

Уса юлындагы Гайнә волостеның Үдик (Елпачиха) авылыннан. Полковник Әбди Абдулловның туганы һәм ярдәмчесе *(Ә. Фатыйхов)*.

**169. Җумакай Әскәрев**

Уса юлындагы Гайнә волостеның Усман авылыннан (Тауавыл). Походный старшина. Уса каласын яулап алучы бер отряд башлыгы *(Ә. Фатыйхов).*

**170. Ягъфәр Исмәгыйлов**

Көнгер өязе татары. Уса һәм Көнгер янындагы яуларда фетнәчеләр гаскәрендә походный старшина *(Ә. Фатыйхов)*.

* * *

Башимәс халык гаскәре составында киләчәк буыннар бәхете, азатлыгы өчен көрәшеп йөргән һәм гомерләрен биргән каһарманнар исемлеге, әлбәттә, шушы урында гына төгәлләнми. Без бүген дә азат тормыш һәм мөстәкыйльлек өчен көрәшәбез. Сафларыбыз ишәйсен, күңелләребезгә ышаныч һәм ныклык иңсен өчен, каһарман бабаларыбыз рухына урынны түрдән бирик. Халкыбызның мәшһүр шагыйре Шәүкәт Галиев сүзләре белән әйткәндә:

Үлгәннәрнең каберен бел,

Исәннәрнең кадерен бел.

*1992—1994, 2003 еллар,*
*Чаллы.*

## БАБАЛАРЫБЫЗ КАҺАРМАНЛЫГЫНА МӘГЪНӘВИ ҺӘЙКӘЛ

Тарихи романнары һәм башка төр гыйбрәтле язмалары белән танылган Вахит Имамовның иҗатын күптәннән күзәтеп барам. Һәм аның һәр әсәрен тарихчы сыйфатында да, гади укучы буларак та кызыксынып укыйм, тәкъдир итәм, яңаларын исә көтеп алам.

Вахит Имамов белән безне бер уртак хезмәт тә берләштерә. Ул «Татарларның Ватан сугышы» дип атала. Әлеге китап «Бәйсезлек өчен көрәш», «Яшерелгән тарих» дигән ике кисәктән тора һәм 1993 елда Чаллы шәһәренең «КамАЗ» газета-китап нәшриятында дөнья күрде. Сөенечкә күрә, автор хезмәтләре исемлегендә бу китап та лаеклы урын били. Шуннан соң мин Вахит әфәнденең «Запрятанная история татар» (1994), «Сәет батыр» (1994), «Могикан» (2001), «Утлы дала» (2001) исемле оригиналь әсәрләрен укып чыктым һәм авторның чал тарих чынбарлыгын нечкә тоемлаучы сирәк авторларның берсе булуына инандым.

Хәзер укучыларга тәкъдим ителә торган «Татар яугирләре» («Татарлар Пугачев явында») дигән хезмәт югарыда искәртелгән хасиятләргә тулаем диярлек җавап бирә, ягъни В.Имамовның тарихи җирлектә эзләнүләренең бәрәкәтле чагылышын гәүдәләндерә. Дөрес, әлеге әсәр укучыга авторның «Сәет батыр» китабы аша мәгълүм инде, чөнки «Татарлар Пугачев явында» дигән тарихи очерк әлеге китапның икенче зур кисәген тәшкил итә. Ләкин «Сәет батыр» китабының нәшер ителүенә ун ел үтеп китүен, бу дәвер эчендә тарих сөючеләрнең яңа карашлы яңа буыны җитлегүен игътибарга алсак, «Татар яугирләре»нең нәшрият «таба»сыннан бик вакытлы төшүен күрәсең.

Хезмәт белән яңабаштан, «яңа күз» илә танышып чыкканнан соң, күңелне җылы бер канәгатьләнү хисе сарып ала. Бу әсәрнең, тарихчы буларак, күп җәһәтләрдән минем рухыма, фикри кыйблама туры килүе белән аңлатылса кирәк. Тугыз-ун елдан бирле үземә якыннан таныш булган текстта мин хәзер нindидер яңа мәгънәләр, өстәмә төсмерләр табам.

Хезмәтнең җитдилеген һәм әтрафлылыгын күп яктан аның йөзләгән чыганакка, тарихи әдәбиятка таянып иҗат ителүе раслый (китапның азагында 120 берәмлектән торган әдәбият исемлеге китерелгән). Алар арасында 1817 елдан алып 1993 елларны үз эченә алган төрле шәкелдәге чыганаклар бар.

Аңлашылса кирәк, «Татар яугирләре» («Татарлар Пугачев явында») әсәре нәтиҗәле һәм өлгер иҗат итүче язучының бөтен бер тарихи эзләнүләр «чылбыр»ына кергән мөһим бер боҗрасыдыр. Шуңа күрә В. Имамовның әдәби эшчәнлеген, иҗади мирасын аннан башка бәяләү бик берьяклы, чатак килеп чыгар иде. Эш шунда ки, әлеге әсәре аркылы язучы татар халкының колониаль изү шартларындагы бөтен фаҗигасен дә, аның кара көчләр золымына каршы булган баһадиранә көрәшен дә органик бөтенлектә сыйфатлауга ирешкән. Татар трагедиясе һәр җөмләдә татарның азатлыкка, мөстәкыйльлеккә омтылышы, каһарманлыгы, азаматлыгы белән үрелеп тора. Бәлки шуңадыр да, автор Пугачев явында катнашкан бабаларыбызны (гәрчә терминологик яктан бераз бәхәслерәк булса да) баш күтәрүчеләр, ихтилялчылар (борынгырак термин) дип түгел, ә «татар яугирләре», ягъни тулы мәгънәсендәге татар сугышчылары дип атаган. Ихтимал, моның белән килешергә кирәктер, чөнки мантыйкый җәһәттән баш күтәрүчеләр бөтен бер отрядлар сыйфатында хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан. Һәрхәлдә, В. Имамов карашында баш күтәрүчеләр яугирләр хөкемендә йөри. Ә инде автор хикәяләвендә ара-тирә кулланылган «фетнәчеләр» сүзе (русча варианты: «бунтовщики», «мятежники»), телисеңме-теләмисеңме, бу «яугир» төшенчәсенә каршы килә.

Әлеге хезмәттә авторның төп иҗади казанышларыннан берсе — логик эзлеклелеккә ирешүен дә әйтеп үтү зарур. Әйе, әдип хаклы: Емельян Пугачев җитәкчелегендәге халыклар сугышы, аннан алдагылары кебек үк, моңарчы фәкать крестьяннарның патша хөкүмәтенә, эре җирбиләүчеләргә, урыннардагы эреле-ваклы канэчкеч түрәләргә каршы юнәлдерелгән сыйнфый көрәше буларак кына тасвирланып килде. Әлеге күренеш совет рәсми фәненең миңле тамгасы булды. Чөнки, В. Имамов билгеләп үткәнчә, «совет галимнәре өчен дә, бүленмәс һәм бердәм совет халкы тәрбияләүгә йөз тоткан сәясәтчеләр өчен дә шундый тәкъбир отышлырак, файдалырак иде». Мондый алым Е. Пугачев явына карата гына түгел, татарның үз дәүләтчелеген, мөстәкыйльлеген кайтару өчен 1553—1557 еллардагы азатлык (дөресрәге, Ватан) сугышына карата да «уңышлы» кулланылды. Ватаны яулап алынган, йорт-җире таланган, яндырылган, тартып алынган, җиреннән сөрелгән, дистәләрчә мең асыл ирләре кылычтан кичерелгән, диндәшләре көчләп чукындырылган, хатын-кызы мәсхәрәләнгән, бала-чагасы кол ителгән халыкның үз бәйсезлеге, дөньяда яшәве өчен тигезсез фидаи көрәше реакцион, сепаратистик, үзәк хөкүмәткә каршы җинаятьчел гамәл дип бәяләнде, бу көрәшкә хакимиятен югалткан җирле морза-алпавытларның хан тәртипләрен торгызу буенча көчәнүләре генә дигән мөһер сугылды. Монысы инде тарихи чынбарлыкка туры килмәү генә түгел, каһарман бабаларыбыз рухын рәнҗетүгә, аларга бәддога укуга тиң. Гаҗәп хәл: XX гасырның икенче яртысында бушменнарның, папуасларның, КАР (ЮАР) негрларының милли бәйсезлек, ирек өчен көрәшүе гадел, ә татарларныкы (нинди генә дәверне алсаң да) «реакцион» булып чыкты.

Намуслы рус тарихчылары (Н. А. Фирсов, М. Г. Худяков һ.б.) мәсьәләнең асылын белеп эш итүчеләрдән булса да, мәгълүм идеология алдында тез чүккән рәсми совет фәне аларга «арты белән» борылды, карашларын исә аяусыз тәнкыйтьләүдән бушамады. Әйтик, автор билгеләп үткәнчә, Казанда яшәп иҗат иткән «дворян тарихчысы» Н. А. Фирсов, Е. Пугачев җитәкчелегендәге халыклар сугышын күздә тотып, болай дигән: «Башкортлар урыс хакимиятеннән котылып, бәйсез, мөстәкыйль ислам ханлыгын төзү өчен, татарлар элекке ханлыкларын һәм иске тәртипләрен торгызу өчен көрәшкәннәр». Н.А.Фирсовның бу фикере белән бернинди искәрмәләрсез килешеп бетеп булмый, мәгәр галим татар-башкортның нигездә үз милли бәйсезлеге өчен көрәшкән булуын дөрес тотып алган.

Вахит Имамов үзенең хезмәтендә, социаль-сыйнфый мотивларны да читкә этәрмичә, татар халкының милли, дини изүгә каршы күтәрелүенә басым ясый, бу гөманын күп санлы үтемле мисаллар белән ныгыта. Мәсәлән, төрле архив материалларына һәм махсус әдәбиятка таянып, ул башка рус булмаган халыклар белән беррәттән, азатлык көрәшендә татарның ярлы-ябагайлары гына түгел, бәлки шактый зур мөлкәт ияләре дә (тарханнар, старшиналар, йөзбашлары) актив катнашуын, ул гына да түгел, ихтилял отрядларын үзләре туплап, аларга җитәкчелек итүләрен исбатлый. Әлеге факт шунысы белән әһәмиятле, рус алпавыт-түрәләренең берсе генә дә үз теләге белән Пугачев ягына чыкмаган, байлыгына һәм дәрәҗәсенә кул селтәп, «падишаһ» гаскәрендә отряд башлыгы булып йөрмәгән. Димәк, рус һәм башка халык крестьяннарының көрәш мотивлары еш кына очракта бер-берсенә тәңгәл килмәгән, беренчеләре социаль мәнфәгатьләрне генә алга сөрсә, икенчеләре, моннан тыш, милли һәм дини, хәтта ки үзбилгеләнү мәнфәгатьләре өчен кан койган.

Бу хакыйкатьтән икенче бер мөһим хикмәт килеп чыга. Ул Пугачев явында катнашкан татарларның саны белән бәйле. Автор әлеге принципиаль мәсьәлә буенча тулы бер тикшеренү үткәрә, аерым галимнәр, дөреслеге шөбһәле «статистик материаллар» белән үлчәмле бәхәскә керә, төрле чыганакларда төрлечә теркәлгән саннарны тәфтишләп (ләкин абсолют хакыйкатьне дәгъваламыйча), үзенең нәтиҗәсен чыгара. Һәм бу нәтиҗә, кем әйтмешли, шаккатмалы. Әби патшаның (Екатерина II) Пугачев явында катнашкан ихтилялчыларны 200 меңгә тиңләвен нигезгә салган автор пугачевчыларның 150 меңе (әле киметелгән исәп буенча) рус кешесе түгел дип белдерә. Иң таң калдырганы шул: аларның 100—105 меңен татарлар тәшкил иткән икән. «Димәк,— дип мөһим нәтиҗә ясый В. Имамов,— Пугачев явы — ул яртылаш диярлек татар явы».

Е. Пугачев гаскәренең яртысын татарлар тәшкил итүе (ә бу хакта рәсми совет тарихы ләм-мим) яуның табигатенә үтә гыйбрәтле төсмер бирә, намуслы галимнәр дә аңа карата икенче караш калыплануга этәрә. Гаскәрендә шуның кадәр ишле татарларның булуы «падишаһ Петр Федорович»ка «өстәмә бурычлар» йөкли, аны татар мәнфәгатьләрен дә алгы планга куярга мәҗбүр итә.

Пугачев явына бары тик сыйнфый эчтәлек кенә салучы тикшеренүчеләр байтак «инородец»ларның (бигрәк тә мөлкәт ияләре һәм имамнарның) императрица Екатерина II ягыннан торып «ялган патша»га каршы сугышуын, димәк ки, бу баш күтәрү дәвамында «милли-сепаратистик» тенденцияләрнең асылда булмавына ишарәли. Әлбәттә, «Әби патша» тарафын алып, алар карашынча, «карак» һәм «җинаятьче»гә каршы хәрәкәт кылган фиркаләр дә булган. Моны инкяр итү объективлык җәһәтеннән дөрес булмас иде. Хәлбуки бу теләсә нинди (милли-азатлыкмы, сыйнфыймы) сугыш хәрәкәтләренә хас күренеш. Ерак барасы юк: Ичкериядә бер үк чеченнар арасында «федераль үзәк»кә каршы сугышкан көчләр дә, шуңа ук «бил буып» хезмәт иткән даирәләр дә бар. Моңа карап кына чечен халкы тарафыннан алып барылган сугышның асылы үзгәрми. Еракка рак китсәк, тагын бер мисал. 1552 елда Мөдһиш Иванның Казанны алырга дип килгән 150 меңле гаскәрендә Шаһгали командалыгында берничә дистә меңле татар чирүе булган. Шулай итеп, Казанны саклаучылар Ватан иминлеге өчен рус гаскәрләренә генә түгел, үз кан-кардәшләренә каршы да сугышырга мәҗбүр ителгән. 1553—1557 елгы бәйсезлек өчен сугыш та шуңа охшаш драматик сәхифәләрдән гыйбарәт: кемдер юк ителгән дәүләтчелеген торгызу юлында башын сала, кемдер, кан һәм дин кардәшләре дип тормый, шуларга яу чабып, асып-кисеп йөри.

Вахит Имамов, киң мәгълүматлы, хәзерлекле язучы буларак, мондый «закончалык» һәм «чыгарма»ларны һәрвакыт күз уңында тота һәм хакыйкатьнең теге яки бу якка «чалышуы»на ирек бирми. Аның «Татар яугирләре» әсәрен уку дәвамында бер тотрыклы, «нык нигезле» инану калыплана: безнең бабаларыбыз, татарлар, иҗтимагый-сәяси вакыйгаларны битараф төстә күзәтүче булмаган, ә бәлки бу гөрелтеле вазгыятьнең үзәгендә кайнаган. Алай гына да түгел, аларга билгеле бер күләмдә юнәлеш биргән, еш кына хәрби хәрәкәтләрнең дилбегәсен үз кулында тоткан.

Язучы күтәргән инде «XVIII гасырның 70 нче елларында яшәгән крестьяннар»ның патшаларга, ялган патшаларга, соңгырак дәвернең төрле «сорт» хөкемдарларына, аларның буш вәгъдәләренә ышану мәсьәләсен дә шәрехләп китик. Минем карашымча, күп мәртәбәләр «төп башына» утырткач, «ярык тагарак» янында калдыргач, иң томана кешенең дә күзеннән «элпә» төшүчән була. Бүгенге кебек гаммәви мәгълүмат чараларына (газета-журнал, радио-телевидение, интернет һ. б.) ия булмаса да, крестьяннар табигый инстинкт, гамәли акыл, социаль һәм милли-дини изүгә реакциясе җәһәтеннән бер дә «төшеп калган» халык түгел. Бердән, татарның һичьюгы югары катлавы Пугачевның бернинди «Петр Федорович» түгеллеген генә чамалаган, икенчедән, үзләрен «законлы падишаһлар» дип игълан итмәгән С. Разин, Карасакал, Батырша һ. б. ихтилялында актив катнашкан. Тыенкы һиммәте (энергиясе) булган ярлы-ябагай үз мәнфәгатьләренә туры килерлек форсатны көтеп кенә торган, бу җай килеп чыгу белән үк, сынын турайтып һәм яшәүчәнлек авазына буйсынып, аяусыз көрәшкә

күтәрелгән. 1877—1878 еллардагы татар крестьяннары хәрәкәте, 1885 елгы «Сөләй», 1906 елгы «Бәйрәкә» восстаниесе кебек масштаблы вакыйгалар бу фикерне җитәрлек раслый.

Ә менә монысы белән инде автор тулысынча хаклы: Пугачев явы, анда татарларның катнашуы, саны, «статусы» хакында татарча хезмәтләр, чыннан да, бик аз, булганнарының да күбесендә сыйнфый-партиячел алым хөкем сөрә. Мондый «кысырлык»ның үз объектив сәбәпләре бар, аларны монда җентекләп тормыйбыз. Шулай да урыны туры килгәндә, шуны искәртик: Оренбургта революциягә кадәр нәшер ителгән энциклопедик характердагы «Шура» журналында («Киңәш» мәгънәсендә) 1911—1913 елларда әлеге мәсьәләгә багышланган бөтен бер мәкаләләр тезмәсе басылган («Пугачев».—1911, # 20—23; 1912, # 1—6). Авторы Мөнир Һадиев. Бу җәһәттән М. Аитовның «Пугачев» исемле язмасын (1913, # 13) һәм югарыдагы тезмә уңаеннан бирелгән мәкалә барлыгын (М.-Р. Әсәди, 1912, # 5) телгә алу да максатка ярашлы булыр.

Китаптагы бер моментка, мөгаен, аерым игътибар итәргә кирәктер. Әби патша заманында да, аннан элек вә соңрак та хөкемдарлар инде классик дәрәҗәдә шәкелләшкән «бүлгәлә һәм хакимлек ит» принцибына таянып эш иткән. Бу төрле халыклар арасына чөй сугуның иң «үтемле» ысулларыннан санала. Екатерина II дәверендә моны без рус, татар, башка гайре рус ихтиляльчыларына каршы немец генераллары һәм зур дәрәҗәле әфисәрләре җитәкләгән җәза отрядлары җибәрелү мисалында күрәбез. Автор болар арасында В. Кар, Ф. Венцель, Я. Даннеберг, А. Корф, А. Миллер, И. Михельсон, К. Муфель, Ф. Фрейман һәм башка дистәләгән алман хәрби җитәкчеләрен атый һәм аларның киңкырлы «эшчәнлеген» тасвирлап китә. Россия «инородецлар»ын кешегә дә санамаган генераллар башкортны татардан, казакъны калмыктан аера белмәгән һәм «фетнә»не бастырганда аеруча кансызлык күрсәткән, үзләренең ерткучы гамәлләрен аклау өчен, баш күтәрүчеләрне «воры», «толпа сволочей» кебек җете эпитетлар белән «бүләкләгән».

Автор шуңа охшаш яссылыкта «татары» һәм «башкирцы» атамалары турында да бай мәгълүмат бирә, этник («асаба») башкорт белән «социаль катлам»га, сословиегә нисбәтле «башкорт» арасындагы аерманы төрле фактлар нигезендә «берәгәйле» итеп тәгаенли. Шул ук вакытта язучы бик хаклы рәвештә татар белән башкорт халыклары тарихын бер-берсеннән аерып карарга ярамый, дип саный һәм бу ике тугандаш халыкның «хәят һәм ихтилял учагын мәңге-мәңге бергә ягуын» мөкатдәс фал дип бәяли.

Безнең бурыч, әлбәттә, китапның эчтәлеген сөйләп, андагы вакыйгалар агышын тәфтишләү түгел. Монысы — әсәрне кулына алган укучы эше. Алай да хезмәтнең тотрыклы хронологик нигезгә корылуы, вакыйгаларның логик яктан эзлекле-дәвамчыл тасвирлануы, теге яки бу эпизодны сурәтләгәндә, әдипнең һәм тарихи, һәм мәгънәви җәһәттән бер чиктән икенче чиккә ташланмавы, үлчәмле хикәяләүгә өстенлек бирүе хакында әйтмичә булмый. Теле бай, үтемле, сыгылмалы-образлы. Тарихи фонны сыйфатлаганда, авторның ифрат зур мәгълүмат иясе булуын, бу мәгълүматның кадерен, чын бәһасен белүен күреп куанасың. Төп тарихи текстның эшлекле, талгын (кайчагында — сискәндергеч) агышына В. Имамовның, язучы буларак, әдәби фантазиясе килеп өстәлә һәм документаль чалымлы әсәрне яңа төсмерләр белән баетып, зиннәтләп җибәрә. Боларны үзенчәлекле «лирик чигенеш» дип кабул итәргә мөмкин. Ихтимал ки, биредә шуңа охшаш стильдә Газиз Гобәйдуллин иҗат иткән «Пугачев явы» дигән җыйнак кына әдәби әсәрнең дә йогынтысы бардыр.

Китапның гамәли әһәмиятен дисбенең «Мәрьям анасы»н хәтерләткән «Пугачев каһарманнары» дигән кушымта тагын да көчәйтә. (Бәлки аны «Пугачевчы татар каһарманнары» дип атау дөресрәк булгандыр.) «Полковниклар һәм атаманнар» өлешендә 50 ләп, «Старшиналар һәм йөзбашлары» бабында 170 ләп исемнең теркәлүе (әле бу да тулы исемлек түгел), бер яктан, Вахит әфәнденең нинди мәгълүмати колач белән эшләвен күрсәтсә, икенче яктан, татар халкының үз азатлыгы, мөстәкыйльлеге, кешечә яшәве хакына күпме каһарман-нарның җан фида кылуының тетрәткеч мисалы булып тора. Мул эчтәлекле кушымта материалларының төп текстны күп җәһәтләрдән баетуын авторның янә бер казанышы дип бәяләргә кирәктер.

Инде сүзебезне йомгаклыйк. Әйе, Пугачев явы буенча татарча әсәрләр кытлыгын киметү юлында эшләүче галимнәребез, каләм осталарыбыз аз безнең. Ләкин бит шунысы хак: бу «бушлык»ны тутыру юлында иң нәтиҗәле эшләүче кеше бүген Вахит әфәнде Имамов үзе! Борынгырак тәкъбир белән әйтсәк, «афәрин һиммәте-ңезгә!» Без сүз алып бара торган егәрле әсәр кирәк эзлеклелек, кирәк колач, кирәк тарихи хәтерне яңарту җәһәтеннән иң таләпчән вә нечкә зәвыклы укучының да күңеленә хуш килерлек хезмәтләрнең берсе, минемчә. Бәс, әгәр шулай икән, безгә: «Төкле аягың белән, ”Татар яугирләре”»,— диясе генә кала.

*Равил Әмирхан,*
*тарих фәннәре докторы.*

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ*


1. Документы ставки Е. И. Пугачева, повстанческих властей и учреждений.—М., 1975.
2. *Мавродин В. В.* Крестьянская война в России в 1773—1775 годах. Восстание Пугачева. I—III т. —Л., ЛГУ, 1961, 1966, 1970.
3. *Буганов В. И.* Крестьянские войны в России XVII—XVIII вв. — М., 1976.
4. *Буганов В.И.* Пугачев (ЖЗЛ).— М., 1984.
5. *Буганов В. И.* Емельян Пугачев. — М., 1990.

6. История Татарии в документах и материалах. — М., 1937.
7. Материалы по истории Башкирской АССР. Ч. I. — М.-Л., 1936.
8. Крестьянская война 1773—1775 гг. на территории Башкирии. — Уфа, 1975.
9. Из истории Башкирии. Дореволюционный период. — Уфа, 1968.
10. *Дубровин Н.* Пугачев и его сообщники. I—III т. — С.-Петербург, 1884.
11. *Шишков В.* Емельян Пугачев. I—IV т. — М., 1983.
12. Воззвания и переписка вожаков Пугачевского движения в По- волжье и Приуралье. — Казань, 1988.
13. *Муратов Х. И.* Крестьянская война под предводительством Е. И. Пугачева (1773—1775). — М., 1980.
14. *Алишев С. Х.* Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании. — Казань, 1973.
15. *Алишев С. Х.* Каһарман бабайлар. — Казан, 1976.
16. *Алишев С. Х.* Пугачев полковнигы //Казан утлары. —1967.—№1.
17. *Алишев С. Х.* Бәхтияр Канкаев //Казан утлары. —1968.— №1.
18. *Семевский В. И.* Крестьяне в царствовании императрицы Екатерины II.
19. *Добротворский Н. А.* Пугачев на Каме. «Исторический вестник». —1884, 18 т.
20. *Лимонов Ю. А., Мавродин В. В., Панеях В. М.* Пугачев и пугачевцы. — Л., 1974.
21. *Лимонов Ю. А.* Пугачев и его соратники. — Л., 1975.
22. Народы в крестьянской войне 1773—1775 гг. — Уфа, 1977.
23. *Сахаров А. Н., Троицкий С. М.* Последние дни Е. И. Пугачева. «Живые голоса истории». — М., 1978.
24. Следствие и суд над Е. И. Пугачевым//Вопросы истории. —1966.— №4—7.
25. *Пушкин А. С.* История Пугачева. — Уфа, 1978.
26. *Пушкин А. С.* Капитанская дочка. — М., 1978.
27. *Злобин С. П.* Салават Юлаев. — Свердловск, 1973.
28. *Ибраһимов Г. Г.* Кинзя. I—II т. — Уфа, 1982, 1987.
29. *Брикнер А. Г.* Первые годы царствования Екатерины II. «Исторический вестник».— 1884, 18 т.
30. *Шушканов Н. Г.* Крепостной Златоуст.— Челябинск, 1959.
31. История СССР. Учебник для вузов. — М., 1956.
32. История Татарской АССР.— Казань, 1980.
33. *Калинин Н. Ф.* Казань (Исторический очерк).— Казань, 1952.
34. Казанский Кремль. — Казань, 1959.
35. *Фукс К. Ф.* Краткая история г. Казани. — Казань, 1817.
36. *Агафонов Н.* Казань и казанцы. I—II т. — Казань, 1906—1907.
37. Сказание казанского купца И. А. Сухорукова о пребывании Пугачева в Казани и о состоянии ее в то время. (Записано К. Ф. Фуксом) //Казанские губернские ведомости. —1843. — №44.
38. Сказание казанского купца Л. Ф. Крупеникова о пребывании Пугачева в Казани //Казанские губернские ведомости. —1843. —№51.
39. Салават (Песни и предания).— Уфа, 1953.
40. *Акманов И. Г.* Башкирское восстание 1735—1736 гг. — Уфа, 1977.
41. Очерки по истории Башкирской АССР. — Уфа, 1956.
42. *Хасанов Х. Х.* Формирование татарской буржуазной нации.— Казань, 1977.
43. *Акманов И. Г.* Башкирские восстания XVII — первой трети XVIII вв. — Уфа, 1978.
44. Участие народов в крестьянской войне 1773—1775гг. — Уфа, 1974.
45. Участие народов Башкирии в крестьянской войне 1773—1775 гг. под предводительством Е. И. Пугачева. — Уфа, 1974.
46. *Игнатьев Р. Г.* Осада г. Уфы пугачевскими войсками под руководством И. Н. Чики-Зарубина и Василия Губанова. «Памятная книжка Уфимской губернии». — Уфа, 1873.
47. *Игнатьев Р. Г.* Осада г. Мензелинска в Пугачевском бунте. «Памятная книжка Уфимской губернии». — Уфа, 1873, ч. II.
48. *Гвоздикова И. М.* Салават Юлаев. — Уфа, 1982.
49. Пугачевщина. Т. I. — М.-Л., 1926.
50. Под знаменем Пугачева. — Челябинск, 1973.
51. *Батталов Ф. З., Попов С. А.* Село Каргала (рукопись). 1973.
52. По родному краю.— Чкалов, 1956.
53. *Федоров Е. А*. Каменный пояс. I—III т. — Фрунзе, 1988.
54. *Мамин-Сибиряк Д. Н.* Город Екатеринбург. «Седой Урал». Серия «История Отечества», 18 век, — М., 1983.
55. *Крамаренков В. И.* Выписка о горных делах. 1777. — М, 1983.
56. *Чулошников А. П.* Восстание 1775 г. в Башкирии. — М.-Л., 1940.
57. Молодость древнего города. — Казань, 1978.
58. История Казани. I т. — Казань, 1988.
59. Өфө тарихы. — Өфө, 1983.
60. Казань в художественной литературе. — Казань, 1977.
61. Знаменитые люди о Казанском крае. — Казань, 1987.
62. *Форш О. Д.* Радищев. — Л.: Художественная литература, 1986.
63. *Нефедов Ф. Д.* Движение среди башкир перед Пугачевским бунтом. Салават — башкирский батыр. «В горах и степях Башкирии».—Уфа, 1988.
64. *Хәйретдинов С., Сирматов И.* Еллар шаһит. — Казан, 1982.

65. *Воробьев Н. И.* Казанские татары. — Казань, 1953.
66. *Каримуллин А. Г.* У истоков татарской книги. — Казань, 1971.
67. *Әхмәт Фәйзи.* Пугачев Казанда. — Казан, 1951.
68. *Мәхмүт Галәү*. Пугач явы. — Мәскәү, 1926.
69. *Афзал Таһиров.* Ямәлкә тавы. — Мәскәү, 1929.
70. *Гобәйдуллин Г.* Пугачев явы. — Казан, 1924.
71. *Гобәйдуллин Г.* Пугачев явында татар-башкортлар//Безнең юл. —1923.— №10—11.
72. *Ахунов Г., Зарипов М.* Мы из Казани, из Волги. — М., 1971.
73. *Миңнуллин Т.* Канкай углы Бәхтияр. «Китәр юлың еракмы?» — Казан, 1978.
74. *Сальников Ю.* И вольностью жалую. — М.,1974.
75. *Чивилихин В*. Память. — М., 1983.
76. *Фехнер М. В.* Великие Булгары. Казань. Свияжск. — М., 1978.
77. *Фәхретдинов Р.Г.* Ташлар моңы. — Казан, 1978.
78. *Исхакова-Вамба Р. А.* Народные песни казанских татар крестьянской и городской традиции. — Казань, 1976.
79. Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. — Казан, 1988.
80. Татар халык иҗаты. Бәетләр. — Казан, 1983.
81. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар.— Казан, 1987.
82. Татар әдәбияты тарихы. I т. — Казан, 1984.
83. *Ходасевич В.* Державин.— М., 1988.
84. *Хөсәенов Г. Б.* Батырлар кыйссасы. — Уфа, 1986.
85. *Алимжанов А. Т.* Степное эхо. — М., 1980.
86. *Есенберлин И.* Кочевники. I—III т. — М., 1976.
87. *Гобәйдуллин Г. С.* Тарихи сәхифәләр ачылганда. — Казан, 1989.
88. *Мәрҗани Ш. Б.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар.— Казан, 1989.
89. *Асфандияров А. З.* История сел и деревень Башкирской АССР. I кн. — Уфа, 1990.
90. *Асфандияров А. З.* История сел и деревень Башкортстана. III кн.. —Уфа, 1993.
91. История Башкортстана. Ч. I — Уфа, 1991.
92. *Сидоров В. В.* По следам Салавата. — Уфа, 1988.
93. *Мыльников А. С.* Легенда о русском принце. — Л., 1987.
94. Башкирская АССР. Административно-территориальное деление на 1 июля 1972 года. — Уфа, 1973.
95. Словарь топонимов Башкирской АССР. — Уфа, 1980.
96. *Овчинников Р. В*. Над «пугачевскими» страницами Пушкина. — М., 1981.
97. *Малахов В. С.* Очерки по истории Заинска. — Наб. Челны, 1992.
98. *Госманов М., Алишев С.* Бөек крестьяннар сугышына 200 ел//Казан утлары. —1973.— №9.
99. Административно-территориальное деление Республики Татарстан.— Казань, 1992.
100. *Гаврюшкин А. В*. Граф Никита Панин. — М., 1989.
101. *Шахмагонов Н.* Храни, господь, Потемкина. — М., 1991.
102. *Евгеньева М.* Любовники Екатерины. — М., 1990.
103. *Мавродин В.* Крестьянская война под руководством Пугачева. —М., 1973.
104. *Лебедев В. И.* Крестьянская война под руководством Емельяна Пугачева. — М., 1951.
105. *Успенский Г. И.* От Оренбурга до Уфы. — Уфа, 1982.
106. *Рәхимов Җ. Г.* Батырша. — Казан, 1992.
107. *Борзаковский П. К.* Императрица Екатерина Вторая Великая. — М., 1991.
108. Белорецк.— М., 1990.
109. Над Шишкинским бором рассвет. — Казань, 1989.
110. *Шишкин И. В.* История города Елабуги. — М., 1871.
111. Поиски и находки. Краеведческий сборник. — Уфа, 1984.
112. *Войнов В.* Правда об Оренбургском казачестве. «Отечество». Краеведческий альманах. Вып. I. — М., 1990.
113. *Рамазан Д.* Ык ага чик сызыгы булып//Идел. —1993.— №9.
114. Менә ул башкортлаштыру җимешләре//Идел. —1993.— №9.
115. *Пикуль В. С.* Фаворит. I,II т. — М., 1991.
116. *Валишевский К.* Роман одной императрицы. — М., 1989.
117. Сочинения Екатерины II. — М., 1990.
118. *Чулошников А. П.* Восстание 1775 г. в Башкирии. — М.-Л., 1950.
119. *Устюгов Н. В.* Башкирское восстание 1737—1739 гг. — М.-Л., 1950.
120. *Фатыйхов Ә.* Гайнә иле. — Барда, 1995.

## ВАХИТ ИМАМОВНЫҢ БАСЫЛЫП ЧЫККАН КИТАПЛАРЫ

1. Ир канаты (шул исемдәге повесть һәм тугыз хикәя). — Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.
2. Нәзер («Күке», «Нәзер» повестьлары, ун хикәя).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.
3. Әфган «кызалаклары» (Әфганстанда һәлак булган якташларыбыз турында әдәби-публицистик очерклар. Җыентыкны оештыручы, төзүче, тәрҗемәче, мөхәррир һәм берничә очерк авторы — В. Имамов). — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.

4. Афганские «тюльпаны».— Казань: Тат. кн. изд-во, 1991.
5. *Равил Әмирхан, Вахит Имамов.* Татарларның Ватан сугышы (XVI—XVIII гасырлардагы милли-азатлык яулары турында тарихи очерклар). — Чаллы: «КамАЗ» газета-китап нәшр., 1993.
6. Запрятанная история татар.— Н. Челны: Газетно-книжное изд-во, «КамАЗ»газета-китап нәшр., 1993.
7. Запрятанная история татар. (2-е изд-е).— Н. Челны: Газетно-книжное изд-во, «КамАЗ»газета-китап нәшр., 1994.
8. Сәет батыр. Татарлар Пугачев явында. (Тарихи роман һәм тарихи очерк). — Чаллы: «КамАЗ»газета-китап нәшр., 1994.
9. Могикан («Кәнәфи» һәм «Могикан» повестьлары, тарихи очерк). —Чаллы: «КамАЗ»газета-китап нәшр., 2001.
10. Утлы дала (тарихи роман, беренче китап). — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.

ЭЧТӘЛЕ К

*Кереш*...................................................................................
Пугачев һәм Казан.................................................................
Җаек буе һәм Оренбург. Яуның башлануы..................................
Казан провинциясе..................................................................
Арча юлы. Мәсәгуть Гомәров..............................................
Алабуга.............................................................................
Зәй...................................................................................
Минзәлә............................................................................
Әгерҗе..............................................................................
Әгерҗе — Ижевск.................................................................
Бөгелмә.............................................................................
Нагайбәк...........................................................................
Уфа провинциясе.....................................................................
Уфа өязе. Ногай һәм Казан юллары....................................
Уса һәм Себер юллары........................................................
Исет провинциясе. Урал, Себер................................................
Янә Оренбург..........................................................................
Җәзачылар лагерендагы тантана...............................................
Урал таулары аша..................................................................
Фетнәчеләр маршы..................................................................
Красноуфимск, Бөре...........................................................
Уса...................................................................................
Удмуртия...........................................................................
Янә Бөре төбәге.......................................................................
Җәзачылар лагерендагы ыгы-зыгы..............................................
Пугачев Татарстанда.................................................................
Казанның хәле.................................................................
Казанны алу.....................................................................
Җиңелү............................................................................
Көрәш дәвам итә.....................................................................
Бәхтияр Канкаев................................................................
Карательләр боҗрасында.....................................................
Казан провинциясе............................................................
Канзафар Усаев.................................................................
Ярмөхәммәт Кадерматов........................................................
«Пугачау патша» артыннан........................................................
Уфа провинциясе. Фетнәнең соңгы учагы...................................
*Йомгак*...................................................................................
Пугачев каһарманнары *(Кушымта)*.............................................
Полковниклар һәм атаманнар...............................................
Старшиналар һәм йөзбашлары..............................................
Әдәбият исемлеге....................................................................
Вахит Имамовның басылып чыккан китаплары...........................

Литературно-художественное издание

Серия «Наш след в истории»

**Имамов Вахит Шаихович**

**БОРЦЫ ЗА СВОБОДУ**

(Татары в Пугачевском восстании)

Исторический очерк

*(на татарском языке)*

Редакция мөдире *Л. Г. Шәрифуллина*
Редакторы *И. И. Кадыйрова*
Бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Рәссамы *Р. Р. Шәмсетдинов*
Техник редакторы һәм
компьютерда биткә салучысы *Л. И. Матвеева*
Корректорлары *Р. Ә. Фәйзуллина, Т. Н. Сәгъдуллина,*
*Г. Р. Сафиуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 8.12.03. Форматы 60ә90 1/16. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы
21,0+форз. 0,25. Нәшер-хисап табагы 19,45+форз. 0,37. Тиражы 2000 д.
Заказ К 4/12.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.